# КАЗАН УТЛАРЫ

2. 1993



## КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Редакция фонды хисабына иганә акчалары күчерүчеләр арткан-нан-арта бара. Без аларның кайдан, кемнәр булуларын укучыларыбызга һәрдаим хәбәр итеп торырга булдык.

Соңгы вакытта безгә Казан беренчел йон эшкәртү фабрикасы (директоры — Әгъмәлетдин Шәйхетдин углы Шәрәфетдинов) 40 мең сум күләмендә акча күчерде. Без әлеге предприятие коллективына бик рәхмәтлебез!

Исегезгә төшерәбез: безгә ярдәм итәргә теләүчеләр хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005. Для фонда редакции журнала «Казан утлары».**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**2**

**(844)**

**1993**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

М. ХӘБИБУЛЛИН. Шайтан каласы. *Тарихи роман* . . . 3
Р. ЗАКИРОВ. Гамьле моң. *Шигъри кыйсса* . . . 74
Р. НИЗАМИЕВ. Кызыл кар яугач. *Повесть* . . . 98

ПУБЛИЦИСТИКА

М. МӘҺДИЕВ. Каһәрләнгән хәрәкәт, каһәрләнгән тема . . . 141

ДИСКУССИЯ
БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ

Г. ТАВЛИН. Иман яңартканда . . . 147

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

И. НУРУЛЛИН. Гаяз Исхакыйга йогынты . . . 153

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Б. СОЛТАНБӘК. Гаделсезлек тантанасы . . . 158
Солтангалиев эше . . . 163

СӘНГАТЬ

З. ХӘЙРУЛЛИНА. Моң тулы язмыш. *(Әхмәт Фәйзинең тууына 90 ел)* . . . 181

ЛАТИН ГРАФИКАСЫ НИГЕЗЕНДӘ
ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Мәҗит Гафури хаты . . . 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 189

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: продолжение исторического романа М. ХАБИБУЛЛИНА «Чертово городище», повесть Р. НИЗАМИЕВА «Когда выпадет красный снег», поэма Р. ЗАКИРОВА.
«Публицистика»: статья М. МАГДЕЕВА «Проклятое движение, проклятая тема».
«Наша жизнь. Наша литература»: статья Г. ТАВЛИНА «Восстановление веры».
«Литературная критика»: статья И. НУРУЛЛИНА «Влияние на Гаяза Исхаки».
«Из страниц истории»: статья Б. СУЛТАНБЕКА «Торжество несправедливости»; статья «Дело Султангалиева».
«Искусство»: статья З. ХАЙРУЛЛИНОЙ о жизни и творчестве писателя А. Файзи.
Навыки чтения на основе латинской графики.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Похищение Европы» — картина художника В. Ханнанова; известный писатель М. Хузин.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Кояш Тимбикова, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 5.01.93 ел. Басарга кул куелды 5.02.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 26 369. Заказ Я-8. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ШАЙТАН КАЛАСЫ

ТАРИХИ РОМАН

20

Тәүге тапкыр ул аны сарайда күрде, күрде дә йөрәге жу итеп китте. Атасы, суеп каплагандай, Гали угланына охшаган иде. Сурәте башка, олыгаеп барган кеше, әмма күз карашы, йөз-кыяфәте, килеш-килбәте ике тамчы судай угланыныкы иде. Ул башта аңардан күзен алалмый торды. Ахыр әмир моңа игътибар иткәч, кызарынып балкыды, күзләрен аска төшерде. Аны әмир янына Назлыгөл алып керде. Һәм: «Абам, Зөләйха атлы мөгаллимә угланыма сабак укытырга тели, ризалыгың бир,»— диде. Нәкъ шулай диде: «... ризалыгың бир?» Нигә ул абасыннан ризалыгын сорый, үзе генә хәл итә алмый идеме?.. Әнә шулай дип гаҗәпләнергә дә өлгермәде, әмир Хаҗи урыныннан күтәрелде, аның янына килде, күзләренә карады.

— Минем сезне күптән күрәсем килгән иде, Зөләйха туташ.

Зөләйха тәмам каушап калды, ни әйтергә белми торды. Ул хатын-кыз иде һәм инде утызны тутырып узып бара иде. Ләкин аңа беркайчан да сазаган кыз димәделәр. Ул һәрчак кыз балаларны сабакка өйрәтте, гәрчә шагыйрьләр аның хакында җырлар язсалар да, ул берәүне дә күңеленә якын җибәрмәде. Дөрес, кемнедер сагынып, иңрәп яткан мәлләре аз булмады, чөнки хыялый мәхәббәт чорыннан күптән узган иде инде. Илләә күңел түренә кереп оялаган үсмер — хан оныгы Галине һич кенә дә йөрәгеннән җуеп ташлый алмады. Ә монда аның атасы, угланына охшаган, җанны тетрәтерлек карашлы атасы!..

— Зөләйха мөгаллимә миндә яшәр, абам.

— Яшәр, яшәр, мин риза, Назлыгөл,— диде ашыгыбрак әмир Хаҗи.

— Алайса хуш, абам.

Хан кызы Назлыгөл өйдә генә түгел, урамда да йөзен капламады. Киресенчә, очраган бер ир-атка менә кара, мин нинди гүзәл, дигәндәй елмаебрак куяр иде. Бүген исә алар икәү атлыйлар, ике гүзәл. Үткән-сүткән ир-ат, егет-җилбәзәк аларны күргәч, туктап кала, аяклары җиргә ябышкандай, кузгала алмый тора. Казан халкы, гомумән, гүзәл хатын-кызга сокланырга ярата иде, кемнән килә бу гадәт, берәү дә белми иде, әмма бу хәл хак иде. Казан байлары вә сәүдәгәрләре әллә кайларга барып, кызларның иң гүзәлләрен табып алып кайтырлар, кирәк икән урлаштыргалыйлар да иде. Тәтеш шәех аларның барысына да никах укыды. Ул үзе яратыр иде гүзәлләрне, ләкин ул шәех иде. Ә шәехнең

Ахыры. Башы 1 нче санда.

жаны юкмыни! Шуның өчен ул аларга һәрчак туры карады һәм гүзәлләрне мактарга бер дә иренмәде. Менә бүген дә аңа Назлыгөл белән Зөләйха туташ очрагач, ул сукмактан читкәрәк чыкты һәм йөрәк турына кулын куеп, гүзәлләргә сәлам юллады, игелек теләде.

Тәтеш шаех күптән инде Зөләйха туташка күз атып йөри, әмма һаман жае чыкмый иде. Ләкин ул барыбер үз дигәненә ирешер. Мөгаллимә кыз балалар укыта, димәк, алар һәркөн булмаса да, очрашырлар һәм, ул җай чыгып, аңа тәкъдим ясар.

Өйгә кайтып кергәч, әллә нигә минем хәлем китеп тора, дип, Зөләйха үз ягына кереп китте. Керде дә сәкегә барып, ятагына капланды. Хикмәтле хәл, нәрсә булды аңа? Бөтен бите яна, йөрәге чыгардай булып тибә. Зөләйха торып утырды, ут кебек янган битләрен учларына алды. Хикмәт, нигә әле ул аны күргәч балкып китте, ул гынамы — йөрәге талпына башлады... Куркумы бу, хиссияти куанычмы, бер күрүдә гашыйк булумы, әллә соң күптәнге, үсмер чактагы мәхәббәтенең ялкынланып кабынып китүеме?.. Бәхәссез, Гали аның хыялында гына яшәгән мәхәббәтедер. Ә менә җисми сурәткә төренгән мәхәббәт җиле килеп кагылгач, күңеле тулышудан чарасыз калды. Зөләйха белә иде инде, әмир Хажиның бикәсе киткән. Кая, кем белән? Ул кызыксынмады. Ләкин Назлыгөл бер тапкыр аңа: «Акбикә җиңгәчәй кайтмаячак, ул яшьлек бәхетен тапты»,— диде. Нинди яшьлек бәхете тагын!? Ул соң яшьлек бәхетен әле булса көтмиме?.. Әллә соң шулмы бәхете? Әмир Хажимы?..

Йа хода, бу ни инде тагын! Атасы Ягкуб бәк аңа еш кына, кешегә бары тик өч чара гына үтә зарур, дияр иде. Беренчесе — яшәү мәгънәсе. Икенчесе — бәхеттер. Өченчесе — мәхәббәттер. Адәми затка бу чараларның төрлесе төрле вакытта килергә мөмкин. Зөләйхага яшәү мәгънәсе үз нәүбәтендә килде. Унөч яшендә ул шигырьләр язды, атасының китапханәсендә булган китапларны укыды, шигырьләр ятлады. Шуның белән ул үзен барысыннан да бәхетле итеп тойды. Көтмәгәндә аңа мәхәббәт килде. Ул аны сизми дә калды. Һәм кем йөзендә — хан оныгы Гали йөзендә. Башта ул аны онытырмын дип уйлады. Булдыра алмады. Яше арта барган саен хан оныгы Галигә булган мәхәббәте, киресенчә, ныгый, тирәнәя, сафлана гына барды. Ул үзен әлегә кадәр бәхетле кешеләр арасында йөртте. Мәхәббәтнең җисми асылын тоймаса да, ул аны кичергән, тоеп караган иде инде. Һәрхәлдә, Зөләйха шулай дип уйлар, шулай дип үз-үзен тынычландырыр иде. Әйе, бүгенге көнгә кадәр. Бүген исә әмир Хажины күрде дә үз-үзенә урын табалмый башлады. Әллә соң язмыш аны үзе Казанга китердеме? Үзе очраштырдымы аның атасы белән?.. Зөләйха шәхси тормышы турында берәү белән дә киңәшмәде, ул үзенә-үзе ия иде, хәтта анасы да аның шәхси тормышына тыкшынмады, атасы турында әйтеп тә торасы юк. Ул мөгаллимә иде, аны бөтен халык яратыр иде. Казанга күчеп килгәч тә ул шулай булды.

Яучылар да килмәде түгел аңа, килделәр, әмма атасы Ягкуб бәк аларны һәрчак туп-туры кызына җибәрер иде. Ул аларга: «Кыз минеке — хак, әмма мин түгел, ул кияүгә чыга, миңа түгел, хәләл җефет сурәтендә аңа яшәргә, үзе хәл итсен»,— дияр иде. Атасына Зөләйха рәхмәтле иде. Хан оныгына булган мәхәббәте хакында белгәне өчен генә түгел, хәленә кергәне өчен, шәхси тормышын мөстәкыйль хәл итәргә рөхсәт биргәне өчен. Атасы белән анасы канаты астында яшәгәндә ул үзен иркен тотты. Китаплар укыды, халык белән очрашты. Кая теләсә — шунда барды. Еш кына базарга чыкты, китаплар алды, еракган килгән дәрвишләр белән бәхәскә керде. Көнчыгыштан килгән укымышлы халык аңа аптырар, хатын-кыз буларак үзен иркен тотуына гаҗәпләнер, хәтта кайберләре оялтыр иде. Тормышның мәгънәсен ул аңлый иде инде, бәхетне аз-маз гына булса да тойды кебек, мәхәббәтне дә татыган иде.

Кыскасы, тормышы һәрчак шулай агар да агар кебек иде. Кинәт аңа нидер булды. Ни булганын ул белә, ләкин хәтта үз-үзеннән дә яшерәсе килә иде. Әмма йөрәктән чыкканга йөгән салып буламы? Бәлкем ул

ялгышадыр, әмир Хажи аңа гадәти хатын-кызга караган кебек караган-дыр... Җисми яктан хатын-кызга кызыгып карау — ир-ат өчен матди сыйфаттыр. Баккан — әле аткан түгел. Иллә барыбер әмир Хажи йөзендә вә карашында ул иман күрде, иман исә һәр мөселман кешесе өчен дә олуг ышанычтыр, алшарттыр.

Зөләйха бик озак кымшанырга да куркып, уйланып ятты, кымшанса, нәзакатьле хиссияткә бай уйлары чайкалып, түгелеп китәр төсле иде. Халәтен аңлагандай, Назлыгөл дә аны борчымады. Ул да аңлаган иде мөгаллимә Зөләйханы. Ул да күргән иде ни тамаша йотлыгып абасының мөгаллимәгә карап торуын. Нindидер китапта ул укыган иде: абруйлы кешедә дә кимчелекләр була, кимчелекләре булып та абруйлы аһын йөрткән кеше асыл заттыр. Әмир Хажи турында бикәсен аерган, сараен-да җария кызлар тота, дип сөйлиләр. Зөләйханың моңа ышанасы кил-мәде. Аннары ул хатын-кыз иде, ә атасы хатын-кызга бары тик өч нәрсә хас булырга тиеш, ди торган иде: хатын-кыз аллаһы тәгаләнең хатасы-дыр; иллә кияүгә чыгар ул мәхәббәт белән; бала табар үзсүзлеге ар-касында, бала тапкан саен акылы камилләшә барыр; холыксызлыгы нәтиҗәсендә ире аерыр һәм: «И балалар, балалар»,— дип дөньядан китәр. Атасы, гомумән, хатын-кыздан бераз көлемсерәп яшәде. Әйтик, Зөләйханың әнисенә ул еш кына: чибәр хатын-кыз картая барган саен иләсләнә төшә, мин яшь чакта гүзәлләрнең гүзәле идем, дип тәкърар-лавы шуның бер мисалыдыр, дияр иде. Ләкин, шундый булуына карама-стан, атасы әнисен һәрчак хөрмәт итте, беркайчан да рәнҗетмәде һәм, башка бәкләр кебек, дүртәр хатынга өйләнмәде. Иллә Зөләйха шундый тормышны да кабул итмәгән иде...

## 21

Яким Кучтем Сүрә елгасын кичте дә Городец каласына чаптар җибәрде. Юрий кенәзнең Владимирга кире кайтуы хакмы? Хак булмаган хәлдә, аның бер дә Константин кенәз каршына кайтасы килми иде. Ростов кенәзләре, гомумән, Владимир сәүдәгәрләрен яратмадылар, ан-нары ул сәүдәгәр генә түгел иде — Юрий кенәзнең илчесе дә. Димәк, Юрий кенәзнең алдына кайтып баш та ияргә тиеш.

Өч көн дигәндә чаптары кайтып җитеп Яким Кучтемне куандырды: Юрий кенәз чынлап та Владимирга кайткан икән, Константин Суздальгә утырган, әмма күп тә үтми вафат булган. Әнә шуннан соң аллаһы тәгалә юк дип әйт инде. Яким Кучтем, чукынып, аллаһы тәгаләгә дога кылды.

Атна дигәндә ул Владимир каласының Алтын капкасын узды. Ил-ченең илгә кайтуын кенәзгә җиткергән тиун сөенче алган һәм әйләнеп Яким Кучтемгә дә килеп җиткән иде. Яким Кучтем аңа болгари читек бүләк итте. Аннары оныкларына Болгардан алып кайткан бүләкләрен өләште, һәрберсенең аркасыннан сөйде, зур үскәнсең инде, дип кинән-дереп җибәрде. Аннары йорт-каралтыларына күз ташлап чыкты, хезмәт-челәре товарларын бушата, хуҗаның исән-имин кайтуына шатланган хатын-кыз тыз-быз йөри. Дуняшканың анасы янынан узганда Яким Кучтем: «Дуняша исән-сау, сәлам юллады»,— диде. Хатын аңа рәхмәт әйтә-әйтә китеп барды.

Шулчак аның артыннан кенәз тиуны килде. Яким Кучтем өстен алыштырды да кенәз сараена китте.

Юрий кенәз аны каршы килеп алды, күреште һәм терсәгеннән алып, түргә әйдәде. Утырыштылар.

Тәхетенә утыргач, Юрий кенәз борын тартып куйды, салкын тигән, дип зарланып алды. Аннары кинәт кенә күптән түгел вафат булган Константин абасына үпкәсен белдерде.

— Хак анысы,— диде кенәз.— Абам Константин кенәз Владимирне үз ирке белән кире кайтарды. Ләкин кыска гына вакыт эчендә ул миңа

шактый зыян ясап куйган. Даладан килгән кыпчак катыш энесенә Стародуб каласын бирә, Ростовка үз угланы Василькaны утырта, ә бәлигъ булмаган Всеволод угланына Ярославны билгели. Әнә шулай кыска гына вакыт эчендә ата-бабаларыбыз берләштергән Владимир-Суздәл кенәзлеген ваклый, сибә, тарата мәрхүм кенәз, Яким Степанович. Миңа хәзер аларны яңадан җыярга туры киләчәк. Бу хәлдә син миңа ярдәм итәрсең дип ышанам, Яким Степанович. Константин кенәз җир астында ята, ә кылган гөнаһларын миңа төзәтергә туры киләчәк.

— Язмыштан — узмыш юктыр, кенәз,— диде Яким Кучтем.— Барысы да без дигәнчә бармый шул. Мин дә әнә буш кул белән кайттым. Чуен кою серен дә белә алмадым, чуен коючыны да алып кайта алмадым.

— Йә-йә, ниләр күрдең, Илһам хан ни эшләп ята?..

Яким Кучтем Болгарда булган хәлләрне тәфсилләп сөйләп бирде. Юрий кенәз урыныннан торды, ишекле-түрле йөренеп килде.

— Димәк,— диде ул Яким Кучтемгә карамый гына, үзалдына сөйләнгәндәй.— Болгарда да ике туган тынышмый. Һәм шул җайдан син миңа файдаланырга кушасың.

— Моны миңа Илһам хан үзе киңәш итте, кенәз.

— Әмир Хаҗи эшне бозып куймасмы соң?.. Аның кулында тимер, туплар да коя башлаган икән.

— Әмир Хаҗида гаскәр начар түгел, гөнаһка керәсем килми. Әйе, әмир күз йомып ятмас. Ләкин кенәз кул астында да гаскәр шактый. Бабаларыбызның, атагызның Болгардан буш кул белән кайтканы булмады кебек. Кһм, мин моны болай гына әйтүем, кенәз. Нигездә мин болгар белән сәүдә итеп, тату яшәү ягында. Мин бары тик илче генә, мин бары тик Илһам ханның үтенечен сиңа җиткердем, кенәз.

— Киңәш бирүең өчен рәхмәт, Яким Степанович, игелегең онытмам. Ә сиңа тагын Болгарга барырга туры килер. Кем безнең иң хәтәр дошманыбыз, Яким Степанович?.. Болгар. Бөтен сәүдә юлы Болгар кулында дияргә була. Аннары болгарлар — бусурманнар, безгә аларга яу барырга ходай үзе кушкандыр.

Яким Кучтем телен тешләде. Аның кенәз белән бу хакта сөйләшәсе килми иде. Ул һәрчак Болгар белән тату яшәү ягында торды. Аннары нәкъ менә әмир Хаҗи азатлары аның олавын коткарып калдылар, олавын гына түгел, гомерен дә. Ә ул аларга каршы кенәзне котырта булып чыга. Яким Кучтемгә кыен иде. Яңа мыек чыгарып, Владимир тәхетенә утырган Юрий кенәзгәме моны аңларга? Урыс кенәзләре борын-борыннан сугышны кәсепкә әвереплдереп көн күрә. Бу да, ахры, ата-бабаларыннан ерак китмәгәндер. Ә бит тыныч сәүдә итүгә ни җитә! Моны аңлау өчен кенәзгә һич югы Яким Кучтем гомерен яшәргә кирәктер шул. Ә кенәзләрнең ни сәбәпледер гомерләре кыска була. Әллә соң аларны аллаһы тәгалә бинахакка кеше каныи койган өчен ашыгыбрак җир астына аламы?.. Булмас димә. Бу да әнә яуга ашкына. Ә яуның төрлечә бетүе бар, яшь кенәз, дөнья диләр аны. Тик Яким Кучтем сизә, Юрий кенәз барыбер Болгарга яу чабар, туктата алмас ул аны. Хәерлегә генә була күрсен...

— Мин синең киңәшеңә мохтаҗ, Яким Степанович. Болгарга яу чабыймммы, әллә булмаса, башта энеләремне, кардәш кенәзләрне буйсындырыйммы?.. Атабыз әнә Болгардан баеп кайткан иде...

— Баеп кайткан иде, әйе,— диде Яким Кучтем кенәзгә булган үпкәсен сиздермәскә тырышып.— Өч мең сугышчысы ятып калды, яраткан кенәзе Изяслав һәлак булды. Ә ул синең кебек яшь, чибәр, шат вә күр күңелле иде. Киңәшем шул булыр минем сиңа, кенәз. Болгар белән орышырга түгел, сәүдә итәргә кирәк!

Юрий кенәз бертын дәшми генә Яким Кучтемгә карап утырды.

— Бәхәссез, син хаклы, Яким Степанович. Ләкин минем дә хәлемә кер. Мин бүген яу чапмасам, иртәгә бу тәхеттә утыра алмаячакмын. Сиңа бу хәл билгеледер, Яким Степанович. Әйткәнемчә, мин башта

туганнарыма яу чабачакмын, башта аларны буйсындырачакмын. Тәре үбепме, куркытыпмы — анысы минем эш. Мин гаскәремә ышанам. Бу хәл миңа илне берләштерергә мөмкинлек бирәчәк. Шуннан соң бергәләп без Болгарга юнәлербез, төп дошманыбызга. Кыскасы, хөрмәткә ия Яким Степанович, яу чабу минем өстә, ә теге кызына өйләнгән һәм кызыңны мөселман иткән чуен коючы — синең өстә. Син аны миңа җир астыннан булса да алып кайтырсың!

— Якшы, кенәз. Тик минем сиңа бер үтенечем бар иде. Чуен коючы артыннан минем оныгымны җибәр, ягъни Митәй тиунысын.

— Митәйнең башы яшь әле, Яким Степанович. Әйткәнне тыңла. Җыенып тор. Мин сиңа хәбәр итәрмен.

Аның белән сүзе бетүен аңлатып, Юрий кенәз кулындагы таягы белән идәнгә төртте. Яким Кучтем һавага чыкты, күк йөзенә күз салды. Күк йөзе чалт аяз иде. Бүген Покров көне бит әле, дип уйлады. Көз салкын, коры булыр, кәбестә алып тозлатырга вакыт. Ләкин ул кәбестәне ашый алырмы, кенәз аны өйдә тотмас, каныкты, буйсынмаса, чарасын табар. Балта кенәзләр кулында. Бердәнбер кеше кала — епископ. Андрей кенәз тәхеттә утырганда да епископлар алар ягына авышканнар иде. Андрейның мәетен өч көн күммичә, ягъни фатыйха бирмичә, бакчада яткырдылар. Болгарга яу чыгуны да епископ кузгаткандыр. Яким Кучтемне берәүнең дә болай мыскыл иткәне булмады әле. Болгар ханы Илһам аңа үзе кымыз салып бирде, ә син бер савыт шәрабеңне кызганып, аксакаллы илчеңне куып чыгаргандай иттең. Башка кенәзләр Яким Кучтемне хөрмәт итәрләр иде, урыны һәрчак түрдән булыр иде, киңәш-табыш сораулары турында әйтеп тә торасы юк, аның белән киңәшмичә кыл да кыймылдатмаслар иде. Күр әле бу Юрий кенәзне, ни кылана. Ирексездән Болгарга куа, җитмәсә, чуен коючыны алып кайт, ди. Сорамый, үтенми, боера. Әүвәл уйлап карар идең, кенәз. Ялгышмыйсыңмы?! Әйе, заманында Андрей кенәз дә Яким Кучтемгә кизәнгән иде, тәпәче үз башына төште. Владимир кенәзлегенә Болгар белән орышырга түгел, сәүдә итәргә кирәк, сәүдә! Ачлык килгәндә кем урысны ачтан коткарды, кем олау-олау ашлык китерде? Болгар. Башың яшь әле, кенәз, башың яшь. Яким Кучтем илче генә түгел ул, сер ташучы, корал-корбансыз гына илләр яулаучы. Ә син бүген чуен коючы турында авыз суың корытасың. Ә коралның асылы — кеше күңелендә. Хак, корал орыша, ир мактана, диләр. Әмма дин әһелләре кебек кеше күңелен үз ягына аудару хәерлерәк булыр иде. Син, кенәз, мине чакырганчы, епископ Савва белән очрашкансыңдыр, ә ул кем соң? Кем? Епископ Савва, мине халык сайлап куйды, дип мактана. Епископ Феодорны да халык сайлаган иде, Андрей кенәз аны хәтта митрополит итмәкче иде, барып чыкмады, Феодорны Киевкә чакыртып алып, шул ук дин әһелләре җәзалап үтерде. Халыкны тыңла — үзеңчә кыл, дигән борынгылар. Ә син, күрәм, әлегә халыкны да тыңламыйсың, үз фикереңдә дә кала алмый изаланасың. Шундый чакта сиңа епископ Савва киңәшкә килгән һәм Болгарга яу чабарга дәртләндергән. «Соңы хәерле була гына күрсен», — дип үзалдына сөйләнде Яким Кучтем. Һәм бүген үк Боголюб калачыгына китәргә дигән ниятгә килде. Анда ул үзен тынычрак тоя иде.

## 22

Шаһ кызы Рабигага Булат угланын өйләндереп, туй мәшәкатьләрен ~~пошырып~~ ~~уздырганнан~~ соң, Илһам хан яңадан Биек Калага килеп төшкән кенәз илчесе Яким Кучтемне сараена чакыртты. Олуг илче гадәттәгечә башын ия-ия, чукына-чукына тәхет ягына килеп керде. Сәламнәр алышкач, Илһам хан аңа урын күрсәтте.

— Йә, Якимкә агай, ни белән куандыра аласың Илһам ханны?

— Хан, сиңа хөрмәтем зурдыр, баштан ук әйтеп китим: бер дә теләп килмәдем. Кенәз ирексезләп җибәрде диярлек. Билләһи шулай. Иллә тәүге уй-теләкләрең хак булса, кенәз сиңа ярдәм итәргә булды — Ашлы каласына яу килергә ризалашты. Кайчан, тәгаен әйтмәде. Иллә сүзендә торуына иманым камилдер.

Әүвәл башта канкардәшләрен канат астына җыймакчы. Юрий кенәз, мәрхүм Константин дәүләтемне бүлгәләгән, дип зарлана.

— Аның башына да минем кайгы төшкән икән,— диде Илһам хан.— Мин дә әнә абам белән тыныша алмыйм. Шайтан каласында калдырган меңбашымны куып җибәргән, җитмәсә кисәткән, имеш, хан үзе килсә, ул төбәктә башын салыр, дигән.

— Әнә ничек,— диде Яким Күчтем.— Кыю кылана абаң, гәрчә олуг хан булмаса да.

— Атама да баш бирми маташты ул. Үсте, азынды. Мәрхүм Константин кенәз кебек, калаларын угланнарына, кардәшләренә бүлгәли. Җаббар угланны Ашлыга җибәрде, Казанны колчурадан туган Хансөяр энесенә калдырмакчы.

— Үзе кая юнәлергә исәпли соң?

— Белгән кеше юк. Кашанына кайтадыр. Атам биргән Кашанына.

— Моны ул Шайтан каласын күздән яздырмас өчен эшли, хан, бер дә бүтән түгел.

— Бик ихтимал. Тик мин аңа моны эшләргә бирмәм. Бу хәлдә миңа Юрий кенәз ярдәм итәр.

— Хактыр, итәр, хан, итәр.

— Ярый, бу кайгыларны куеп торыйк әле, Якимкә агай. Үзең ни җимереп ятасың соң? Владимирда нинди хәлләр?.. Кенәзбикә Рокыя белән Сәкъсингә киткән кече угланы Юркәй грузин шаһинәсе Тамарага өйләнгән, диләр, хакмы шул?

— Хак, хан. Өйләнгән. Кыпчаклар шулай теләгән. Сәкъсин хәзер Акбикә җиңгәчәң кулында, диләр. Сарбай хан кызы бит, ир агалары калмагач, аны күтәргәннәр икән. Баһадиры Бачман, ди.

— Бу хакта мин хәбәрдар, Якимкә агай.

— Бачман баһадир кем ягына каера икән соң?

— Бачман баһадир үз даласында, Якимкә агай. Аны хәзер аркан белән дә бире таба тартып китереп булмаячак.

— Ә мин аны китерер идем, хан.

— Нәрсә син, Якимкә агай, әллә Сәкъсингә барырга исәбеңме?

— Тәүбә дәгеп, Яким Күчтем кенәзләргә дә, ханнарга да күп игелек кылды. Кем әйтмешли, ходай ярлыкалый күрсен. Картайды Яким Күчтем, сакалы агарды, акылы кыскарды. Кешегә яманлык кыласым килми, хан, бер дә килми, тиздән аллаһы тәгалә алдына барасы, ни дип җавап бирермен.

— Гөнаһ кылмый булмас, Якимкә агай. Кылмый чараң юк.

— Йа хода, хан, бу ни дигән сүз тагын! Ходаның язганына чара юктыр, мәгәр акылы вә зиһене саф кеше һәрчак җаен табар, ди.

— Иншалла, күбесенә тапканны, монысына да табарсың, Якимкә агай. Үзең әнә минем түремдә утырасың, үзең Казан каласында урам салып, базар ачып ятасың икән. Хәләл кәсеп итәргә исәп тотасың икән, фатыйханы миннән алыр идең.

— Мин түгел, Митәй онытым, эттән туган нәмәстәкәй. Бөек Каладагы базар гына җитмәгән аңа... Уйласаң, кәсеп итү гөнаһмы, хан! Ходай тәгалә алдында минем йөзем пакьтер, кеше хакына кермәдем, ихлас сәүдә иттем. Хак анысы, онытымны да, энем Афанасийны да шул һөнәргә юнәттем.

— Бөек Каладагы чиркәүне, чираттагы чиркәүне кем исәбенә салалар, Якимкә агай?

— Чиркәү — алла йорты ул, хан. Аңа тел тидерергә куркам. Һәр изге кеше чиркәү салырга омтылырга тиеш. Китап шулай куша. Мин

үзем, хан, тар күнелле кеше түгел, яңа чиркәү күрәм икән, куанам, яңа мәчет күрәм икән, аңа да шатланам, алла йорты ла.

— Хуш, Якимкә агай, хуш. Әйдә син дигәнчә булсын. Тик бер нәрсә турында онытмасаң иде: монда сөйләшкәнебез монда калсын. 1220 елдыр. Еллар исәбе аңлашыладыр. Олуг кенәз Юрий Всеволодович илчесе Яким Күчтем Болгарның олуг ханы Илһамда булды һәм вәгъдә итте. Ни вәгъдә иткәнен беләсең...

Яким Күчтем җавап бирмәде, бары тик тамак кырды.

## 23

Хәрәземшаһ Олуг Мөхәммәт бөтен дөнья халкын яуларга керешкән Чыңгыз хан белән кара канга килеп орышканда, Идел буе Болгарында Сәлим хан угланы Илһам тәхет биләгәндә, язның ямьле бер көнендә Болгар каласы бакалдагына зур булмаган корабтан чал сакалы биленә җиткән, билбавына буш янчык кыстырган, керләнеп беткән яшел чалмасына көмеш төсенә буялган бака кабырчыгы кыстырган мосафир килеп төште.

Идел өсте тыныч, күк йөзе аяз, яңа туган көн эсселәнеп кенә килә. Бу мәлдә һәммә тереклек уянып эшкә керешәдер, тамак кайгыртадыр, әмма мосафир ярга аяк басуга, биленә таккан ризык капчыгына тотынмады, чирәмгә аяк басуга, йөзе белән дымлы җиргә капланды һәм бермәл туфрак исе килгән әчкелтем сөрсүрәк һава сулап торды, ахыр күтәрелеп, зәңгәр һавага бакты.

Олы кеше иде инде мосафир, бик олы, иллә гәүдәсендәге җинеллек, туган туфрагына аяк баскач, кодрәтле дәрте аны яшәртеп җибәргән шикелле иде. Ул бер торды, бер җиргә капланды, ахыр биленә бәйләгән намазлык төргәген сүтеп җибәрде дә намаз укырга кереште. Намазын укып бетергәч, тирә-ягына күз ташлады, ипләп кенә намазлыгын төреп, биленә кыстырды һәм янәдән яшел чирәмгә тезләнде. Табигатьтәге хәерхакны күрепме, утырды, аякларын сузып җибәрде. Бакалдактагы шау-шу, ыгы-зыгы, акчарлаклар чәрелдәвен ул гелән ишетмәде. Мосафир тикторганда үзалдына сөйләшә башлады.

— Йа алла, туган туфрагыма да аяк басар көнем бар икән. Саумы, Болгарым, саумы, туган туфрагым! Саумы, Иделем, саумы, кояшым! Синең йөзеңә, туфрагым, дөньяны җәяү кичкән казый Нисбах баш ора. Ул Хаҗдан кайта. Картайган, олыгайган, иллә күзләре күрә, зиһене, шөкер ходага, саф. Мин сиңа Каф таулары аша, җиде ил, җиде чик аша дөнья гизеп кайттым! Вәләкин кайларда гына булсам да, синнән хозур, синнән гүзәл, синнән бәрәкәтле ил-җир тапмадым. Йа аллам, кичерә күр мосафирыңны! Хаҗ дигән җир, пәйгамбәребез ил-туфрагы изге булса да, миңа ошап җитмәде. Шәрә таулар, тоташ чүлләр диярргә була. Бер йотым суга интегеп, туйганчы су эчәргә зар-интизар булып йөрисең. Су булмау сәбәпле чүл комы белән тәһарәт алдым. Елан-көлтә, чаян-кортның исәбе-хисабы юктыр. Әлхәмделилләһи раббил-л-галәмин, исән-сау калдым. Хак тәгалә, мәмләкәтемә кайту юлым озын булды, иллә шөкер итәм, аягым туган туфрагымда, йөзем зәңгәр күгендә.

Пәйгамбәребез илендә атамыз Адәмнең каберен күрдем, аннары Җәддә шәһәрендә анабыз Һава каберен дә зиярәт кылдым. Ахыр Мәккәи мөкәрәмәгә киттем, кала уртасында Кәгъбә бинасы урнашкан икән, шунда юнәлдем. Кәгъбә дигәне дүрт почмаклы өй икән, кара таштан салынган. Ишеге көнчыгыш якта, саф көмештән эшләнгән. Ишек бусагасы да көмештән. Кәгъбә бинасы тышкы яктан кара ефәк белән тышланган. Ефәк чаршауның уртасыннан алтын җеп белән тукылган билбау сыман нәрсә уздырылган. Кәгъбәнең эче исә кызыл ефәк белән корылган. Идәне ак мәрмәрдер. Хаҗга килгән адәмнәр гөнаһлы йөзләрен тидерә торган кара таш Кәгъбә ишегенең сул ягына урнаштырылган, кара

ташның баш-башлары көмешләнгән. Таштан туры барсаң — Зәмзәм коесы. Кәгъбәнең тирә-ягына да мәрмәр җәйгәннәр. Кәгъбә эчендә һәрчак салкынча, тышта эсселек бик югары булганда да Кәгъбә эчендә рәхәт. Кара ташны кояш кыздырмый, ул һәрвакыт салкынча, талгын килеш тора.

Мин Кәгъбәнең бар җирен карап, үз күзем белән күреп, кулларым белән капшап чыктым. Бер мизгелгә дә догамны өзмәдем. Зәмзәм суын эчтем, Ибраһим мәчетенә кереп, намаз укыдым. Аннары пәйгамбәребезнең хәләл җефете Хәдичә каберенә барып, зиярәт кылдым. Булмаган җирем калмады, иллә дә гыйбрәтле урыннарда булдым. Бибифатыйма өендә җаныйның кул тегермәнен күрдем. Пәйгамбәребез оныклары Хәсән вә Хөсәен имамнарның бишекләрен багуга ирештем.

Кайда гына барсам да, һәр тарафта янымда Хаҗ кылучы мөселманнар булды. Инде, ниһаять, җиде кат Кәгъбәи шәрәфнең тирәсен әйләнеп йөгердем, кереп кара ташка йөзем тидердем, үптем, җаныма тиңсез рәхәт агынты керүен тойдым, ирексездән егъладым. Аннары, Хаҗга килгән мөселманнарга ияреп, Минә тавына мендем... Йөрмәгән җирем, күрмәгән хикмәтләрем калмады. Гарәфәт тавы янында ике мәчет бар икән, анда кереп җомга намазым укыдым. Бу Гарәфә көн иде, иң бөек вә изге көн, әлхәмделилләһи, гөнаһсыз икәнмен әле дип кинәндем, чөнки шул изге көнгә туры килдем. Шул көнгә туры килгән адәмгә унике ел Хаҗ кылганның савабы тияр, диләр. Раббе тәгалә кабул итә күрсен.

Иллә, туган илем, кайларда гына йөрсәм дә, күңел түремдә һәрчак син булдың! Сиңа бер ил дә, бер җир дә җитми икән! Эчсәм — суың салкындыр, ашасам — ризыгым татлыдыр, бассам — җирем хәтфә үләндер.

Ачлы-туклы булсам да, ходаның рәхмәте, Өргәнечкә кайтып егылдым. Әмма андагы хикмәткә таң калдым. Халык орыш көтә. Олуг Мөхәммәт тәхетеннән ваз кичеп, ил белән идарә итүне угланы солтан Җәләлетдингә биргән. Ә үзе ил-халкын ташлап, нинди дер утрауга китеп барган, диделәр. Гөнаһысы алла йөге күтәрә алмаслык, диделәр. Динеиманы булмаган Чыңгыз хан атлы илтабарның илчеләрен кылычтан уздырган икән. Чыңгыз ханның шуңа җен ачуы чыгып, көче-куәте тиңсез булган кыргый зат Олуг Мөхәммәтнең калаларын яуларга керешкән. Мин Өргәнечкә кайтканда каланы баһадир Тимер Малик саклый иде. Гаскәре орыш җанлы кыпчаклардан торса да, ул да гайрәтле көч-куәткә ия булган Чыңгыз хан гаскәрләрен туктата алмастыр. Мин анда бер көн дә тора алмадым, булган мал-мөлкәтемне алдым да Сәкъсин каласына юнәлдем. Минем белән меңләгән мөһаҗирләр кузгалды, җан биргәнгә җүн бирер әле дип, аллаһы тәгаләдән ярдәм сорап, сәфәр чыктым. Сәкъсинда да озак юана алмадым. Урам-тыкрыкларга кадәр мөһаҗирләр белән тулган, төн кунгач, тамак ялгадым да беренче корабка утырып, булган акчамны түләп, илемә юнәлдем. Һәм менә мин туган илемдә. Олуг Мөхәммәт җире денсез Чыңгыз хан тарафыннан кан белән ашланганда, минем туган илем күгендә мөлдерәп кояш балкый, җирдән хуш ис бөркелә, егет кызга, кыз егеткә елмая, сәүдәгәр сәүдәгәргә затлы товар тәкъдим итә. Баш очымда тургай сайрый, кырларым хозурлыгына таң калып торам. Чөнки ватандашыгыз Нисбах казый бик күп илләрне күрде, дөнья гизде; ары таба барган саен җәннәткә тап булырмын дип өмет иттем, әмма һәр җирдә дә җәбер-золым, богау-чылбыр күрдем. Туган илеңдәге хакыйкатьне күрү өчен чит-ят җирләргә китеп карау кирәк икән. Туган илемдә яшәгәндә җәбер-золым мине дә читләтеп үтмәде, ахыр баш алып читләргә китәргә мәҗбүр булдым. Иллә бер дә үкенәсем килми — дөнья гиздем, Хаҗга бардым. Алай да ыру-кардәшләремә әйтер сүзем бар: хакыйкатьне туган илеңдә эзлә, сәфәргә яшь чагыңда чык, тел вә ләгать кануннарын саклап, шәригать кушканча вакытында өйлән, вакытында балалар үстер, картлык килгәч, менә минем кебек ялгыз башың торып калуың бар.

— Әссәламегаләйкем, мосафир агай! — диде колак төбендә генә берәү.

Казый Нисбах гүя аны ишетмәде дә, бермәлгә авыз эченнән генә дога укып утырды, аннары гына сәлам бирүчегә башын күтәреп карады. Әйе, кем дәшә аңа, кем туган якның хозурлыгына сокланып туймаган мосафир картны борчый. Изге кешеме, үзе кебек үк мосафирмы, әллә булмаса хан кортымы? Казый Нисбах торып басты, яткан үләннәрне торгызгандай итте һәм үзенә дәшүчегә карап сакалына ябышты.

— Вәгаләйкем әссәлам, алла бәндәсе! — диде ул, ниһаять.

Сизде, жаны-тәне белән тойды казый Нисбах — сәлам бирүче игелекле кеше түгел, ниндидер яман йомыш белән йөри. Юка борынлы, чандыр йөзле, юка иренле бу кешене кайдадыр күргәне дә бар кебек, әмма тишек хәтере моны исенә төшерә алмады.

— Әллә танымадың да инде, картлач! — диде ят кеше.

— Мин сиңа, алла бәндәсе, мал да, кол да түгел, изге жан. Хаждан кайтып киләм. Атап килеп борчыдың, маңгаемда тамгам юктыр бит?!

— Бар тамгаң, казый Нисбах, бар. Оныттың дамыни, мин Илһам хан бусагабашы Субай булам.

— Ходавәндә, Илһам хан Болгар тәхетендә утыра. Мин аңа нигә кирәк булдым инде, алла бәндәсе?

— Йә-йә, юк белән башым катырма, картлач. Тел белән юуыңны ташламагансың икән әле. Сине исән дигәч, мин генә түгел, Илһам хан да шаккатты.— Субай бусагабаш бакалдак ягында торучы арбачыга кул болгады.— Миңа сине, хөрмәткә ия казый Нисбах, сарайга алып китәргә кушылды. Кәттә кеше булып кайтасың икән ич! Хан кадәр хан дәштерде үзеңне.

— Акыл аласы киләдер,— диде казый Нисбах.

— Үзеңә житмәгән акылны, кешегә өләшергә исәбеңме? — Ул арада затлы арба жиккән ат килеп житте.— Утыр, Нисбах бабай, сиңа хәзер бабай дисәң дә ярыйдыр инде.

Казый Нисбах иплән кенә арбага менеп утырды, чапан чабуларын жыебрак куйды һәм арбачы атны кузгатуга, янәшәсенә кунаклаган бусагабаш Субайга:

— Акылга кагылма, Субай энем, акылны кеше үзе жыя. Мин аны дөнья бетереп жыйдым. Нисбах казый белән иплә сөйләшсәң, сиңа да арттырып куюым бар,— диде.

— Менә шуның өчен мин сине ат белән алырга килдем дә, Нисбах бабай.

— Гөнаһтан да курыкмыйсыңмы? Алла бар ул, Субай, бар. Аның кодрәте барыбызга да житә.

— Әйттем вә кайттым, Нисбах бабай. Илһам ханның Өргәнечтәге хәлләрне беләсе килә. Ә син анда булгансың, дип әйтеп әйттеләр.

— Булдым, күрдем ул шәһәрне, ходай тәгалә янадан күрергә язмасын.

— Монда да тыныч түгел, Нисбах бабай. Мөһажирләр басты. Мөселман башына авыр кайгы килде, Нисбах бабай.

— Сәлим хан вәгъдәсен бозды, барысы да шуннан. Хан вәгъдәсе — аткан таш ул. Вәзир Исхак башына житте, Гали оныгына вәгъдә иткән тәхетен әнәтерәк Илһам угланына калдырган. Ә ул бала исән кала, хан сәүдәгәре Биккол коткара. Хәрәземдә тәрбияләнде ул олан, мин дә аның янында булдым. Олуг кеше булды. Шаһ мәдрәсәсендә мөдәррис-мөгаллим вазифасын үтәде. Сабакны Пәһлеван Мәхмүттән алды.

— Илдә диләр аны хәзер, илгә кайткан икән. Әмма кеше күзенә күренми, ди. Берәүләр Кашанда дигән булалар, икенчеләре Казанда, дип саташалар. Бөек Калада да күренгәләгән.

— Нигә яшеренә, нигә кеше күзенә күренергә куркып йөри? Ул олуг шәех, шагыйрь, мәүләдер,— диде казый Нисбах.— Ул балага аллаһы

тәгалә үзе дога кылган, фәрештәләр яклый аны, изге җан ул. Теге вакытта мәрхүм Сәлим хан тәхетне кемгә вәгъдә иткән иде?

— Сабан туендамы?

— Әйе, Чәчкә бәйрәмендә, Нәүрүздә?.. Гали оланына, Субай бусагабаш, Гали оланына! Соңыннан ул оланны кала нигезенә күмдермәкче итә, иллә изге җанны янә фәрештәләр коткара. Хәзер әнә Болгарда ул олуг шәех. Илһам хан, ике тәкә башы бер казанга сыймый дип, олуг шәех Галигә каршы низаг-әзәрлекләү оештырса, намазлыгыма утырып, иң әүвәл үзем каргаячакмын аны.

— Син, Нисбах бабай, әкәмәт сәер вә хикмәтле кеше икәнсең ич! Күр инде, әллә каян торып, барчасыннан да хәбәрдар тагын үзе.

— Карачымы әллә син, Илһам хан карачысы булдыңмы?..

— Шуннан ни, Нисбах бабай?

— Шуннан шул, Субай бусагабаш. Мин сине белмим, син мине. Телем суырып ала алмаслар, мин һичнәрсәдән дә курыкмыйм, яшисен яшәдем, күрәсен күрдем, иншалла. Аннары ул олан кырыктан өстә ич инде. Һәм ул бер дә тәхет өчен лаф ормый, ахры. Иң әүвәл шәех, шагыйрь ул, Субай бусагабаш.

— Киләсе атнага туй була. Хан сәүдәгәре Ярулла Олуг Мөхәммәт кызы Рабиганы көч-хәл белән Болгарга алып кайтты. Булат углан өйләнә, шаһ кызын өченче хатыны итеп ала.

— Ходавәндә, сөбханалла, ни кыла бу халык. Мөселман илләрендә кан-җан коела, алар монда туй үткәреп яталар. Килешми, килешми, бусагабаш Субай. Әмир Хаҗи ни карый, ул һәрчак гадел булыр иде.

— Әмир Хаҗи өскөйләр белән сугышып ята. Сәүдәгәрләрен талаганнар. Үч алырга китте.

— Үч үчкә илтер, диләр. Алай кирәкмәс иде. Кулына кылыч алган кешенең гакылы җиңенә китәр, ди гарәпләр. Карале, арбачы, ул чаклы атың куалама әле, миңа хәзер ашыгасы юк, мин туган илемдә. Өч аршын җир генә табарлар, иншалла. Алай да вакытлы-вакытсыз якты дөньядан китәсем килми. Кайчандыр казый Нисбахтан Ишкул казый үзе киңәш сорар иде. Мәрхүмдер инде, теге чакта ук сакалы биленә җиткән иде. Ә теге, акыл иясе, кәтиб Хафиз исәнме?.. Исән! Бәрәкалла, сарайда ул чакта аннан да акыллы кеше юк иде, хәзер дә шулайдыр, акылны хода һәр кешегә бизмәнгә салып бирсә дә, үзе теләгән кеше китаптан җыя аны. Китап — акыл иясе ошбу дөньяда, бусагабаш Субай. Ханнар исәптә түгел, ханнар тумыштан тәкәббер була, ә тәкәббер вә үтә горур кешене китап яратмый. Илһам хан да белемгә омтылмыйдыр, бала чактан ук юк-бар уенга хирыс иде.

— Син, картлач, иплән сөйләш, Илһам хан ишетсә!

— Син житкермәсәң, ишетмәс. Аннары ишетсә ни? Сигезенче унны ваклый башлаган картны зинданга яптырырмы!? Йә алла, әллә ниләр тел очына килә дә тора. Соң инде, соң Нисбах картны җәзаларга, соң, бусагабаш Субай. Гөнаһсыз сабый мин хәзер, өстемдәге кыршылган чапанымнан башка ике бөртек алтыным да юк. Мәгәр акылым камил, күңелем көр әле, аллага шөкер.

— Бик күп сөйләнсәң, байлыгыңны күрсәтер әле сиңа Илһам хан. Ул сине ыжгырып көтеп тора. Сине күп нәрсәдән хәбәрдар дип уйлый.

— Анысы хак, хәбәрдар, Хаҗдан кайтып киләм. Әй, мин аңа бер изгелек кыла алам. Аллаһы тәгалә кодрәте белән Хаҗ таҗым аңа бирә алам. Алсын әйдә, халык алдында дәрәҗәсе артсын.

— Әүвәл миңа керәбез, Нисбах бабай. Чәй эчәрбез, дога кылырсың, балаларым күрерсең, гаиләмне.

— Йә хода, бәрәкалла, бик әйбәт булыр. Изге җирдән кайткан хөрмә бирермен, зәм-зәм суы тамызырмын.

Көнозын йомшак кар яуды. Ак күбәләктәй очынып төшкән кар бөртекләренә карап, Кол Гали атасы әмир Хажи турында уйланды. Барысы да күз алдында: илгә кайтуның икенче көнендә үк, ул атасын күрергә теләде. Әмма Биккол каршы төште. Нигә ашыгасың, диген булды, мең төрле сәбәп тапты. Кол Гали аны аңламады, гомере буе атасы урынына күрсә дә, күңел төпкелен жан атасы һәрчак борчып торды. Җитмәсә, анардан анасы Акбикә киткән, дип әйттеләр. Бу хәбәрләрнең барысы да бер ноктага жыелып, аны гасага салды. Ләкин атасының янадан өйләнүенә ул шаккатмады, киресенчә, дөрес иткән, диген иде. Бу хәбәрне житкергән Биккол үзалдына көлемсерәп куйгач, Гали аптырабрак калган иде. «Кемгә өйләнде соң?» — дип сорыйсы итте, әмма кыймады. Көннәрдән бер көнне ул Биккол атасына:

— Мин аны күрергә тиеш! — дип катгый итеп әйтте.

— Ашыкма, күрерсең,— диде Биккол.— Бүген түгел, бераз сабыр ит. Азмы-күпме Бөек Калада торыйк, кеше күзенә төшик. Мәчетләргә йөрештерик, мәүлә Хужа Әхмәт килгән ди әнә...

— Хужа Әхмәт! — диде жанланып китеп Кол Гали.— Олуг Мөхәммәт шагыйре. Сарайда балда-майда гына йөзә, диләр иде аның турында! Кайда ул хәзер, кемгә туктаган?! Күрәсем килә аны, атам! Алып барчы янына, мөмкин булса, хәзер үк алып бар!

— Киен! Тик вәгъдә ит, син аны белмисең. Хәер, ул сине белмидер дә, иллә дә мәгәр барыбер үз-үзеңне сиздермәвең хәерлерәк булыр.

— Якшы, атам, син дигәнчә итәрмен,— диде Кол Гали жылы чапанын, киез итекләрен кия-кия.

Хан мәчетенә килеп кергәндә халык анда шактый иде инде. Биккол белән Кол Гали намаз укып чыккач, төрле тарафтан жыелган дәрвишләргә ияреп, мәүлә Хужа Әхмәт урнашкан кәрвансарайга киттеләр. Юлда ук ишеттеләр: Хужа Әхмәтне Илһам хан кабул иткән, бик жылы каршы алган. Хужа Әхмәт янына юнәлгән дәрвишләр хәтта: «Олуг Мөхәммәткә мәдхия укыган шагыйрь минем шәхесемне дә күккә күтәреп мактар, дип өмет итәдер»,— дигән яман сүзләр дә ишеттеләр. Биккол да, Гали дә дәрвишләрнең сүзенә кысылмадылар. «Мәдхияне укыр мәүлә, таланты вә илаһы алладандыр, әмма ханның күзен ача алыр микән?» Дәрвиш шул сүзләрен әйткәч кенә, шикләнгәндәй, артларыннан килүче Гали белән Бикколга күз төшереп алды. «Мәүләнең ханда кайгысы юк, ул үзенә шәкертләр жыя башлаган икән, диләр. Хакмы икән шул?» — дип сорады икенчесе. «Агай-эне, нигә әле ул изге бәндәгә каныктыгыз, хода аңа тел ачкычы биргән, безне шуның белән куандыра, күңелләргә изге ниятләр сала. Рәхмәт әйтергә кирәк аңа»,— диде өченчесе.

Ул арада кәрвансарайга життеләр. Каланың биек вә урта бер төбәгенә салынган кәрвансарай ишегалдында хезмәтчеләр кар көриләр, сукмакларны себерәләр иде. Кар көрәүчеләр дәрвишләрне баш иеп каршы алдылар. Кол Гали белән Биккол кар көрәүчеләргә бишәр тиен бакыр өләшеп чыктылар.

Кәрвансарай халык белән шыгрым тулы иде инде. Кунаклар халыкны ыра-ера түр яккарак уздылар. Биккол ны таныдылар һәм аларга иң яхшы урынны бирделәр. Кечкенә мәйданчыкта ак киезгә яланаяк баскан берәү тора. Өстендә кара чикмән, билен буган киндерә очлары сүтелгән, башында көләпүш. Шул рәвешчә каршысына баскан да түр яктарак утыручы мәүләгә баккан. Хужа Әхмәт гади киенгән. Яшел чапан, ак чалма, аягында кара болгари читек. Мәүлә мөнбәр кебек жирдә утыра. Нигәдер кара күзлек кигән. Биккол Гали колагына:

— Әллә бөтенләй күрмиме мәүләбез? — дип сорады.

— Сукыр да, бераз чукрак та мәүлә,— диде Кол Гали изге заттан күзен дә алмый. Ул аның һәр хәрәкәтенә дикъкать белән карап торды. Ничәмә тапкыр Өргәнечтә шагыйрь Хужа Әхмәтне күрәсе килгән иде

анын, насыйп булмады, ә менә иленә кайткач, әйтерсең, ходай аны бирегә үзе җибәргән иде. Хуҗа Әхмәтнең могҗизалары турында бик күп ишеткән иде ул, әмма болай ук булыр дип уйламаган иде. Үзе сукыр, ә үзе, гүяки, күрә. Чөнки шәкертнең мәһди була алуына инану өчен билен киндерә белән буган егеттән сынау алачак. Булачак мәһдинең куллары кып-кызыл, хәзер генә тыштан кергәндер, ахрысы. Ләкин шәкерт үзен тыныч тота.

— Пәйгамбәребез миңа җиткерде, син мәһди аты алырга, изге юлга басарга телисең икән,— диде Хуҗа Әхмәт йомшак вә ягымлы тавыш белән.— Безнең юлда сиңа яман кәттә сынаулар узарга туры килер, шәкерт. Бәгырең тимер, йөрәгең таш булганда гына теләгеңә ирешә алырсың. Инде, шәкерт, йөрәгеңә колак сал. Нә, ди, сынаулардан куркып калмасмы?

— Мин барысын да кылырмын, кирәк булса, җаным кыюдан да курыкмам, мәүлә. Сынауга әзермен.

— Шәкертне барыгыз да ишеттегезме?— диде Хуҗа Әхмәт үзен вә шәкертне уратып алган халыкка.— Ошбу алла бәндәсе һәр сынау нисбәтенә дә разыйдыр. Инде лә иләһә илләллаһу мөхәммәдуррәсулу-ләһи, диярен.

— Йа алла, мөхәммәдерәсүллулла, йа алла, мөхәммәдерәсүлулла, йа алла, мөхәммәдерәсүлулла...

— Җитәр. Инде әйт, шәкерт: мәһдиләрдә ничә әгъза ябык?

— Өчтер, мәүлә.

— Әйтеп бир.

— Телдер, күздер, билдер.

— Ни өчен күз йомыла?

— Кешедә булган гөнаһны вә оятны күрмәс өчен, мәүлә.

— Ничә ачык әгъза бар?

— Дүрттер, мәүләм.

— Әйтеп бир.

— Кулдыр, йөздер, табандыр, йөрәктер.

— Табында ничә ашау кагыйдәсен сакларга тиешсең?

— Уникедер.

— Әйтеп бир.

— Сул аягың аска куеп утырырга, уң аякны аның өстенә бөкләп куярга. Аз-аз кабып ашарга. Капкан ризыкны әүвәл уң як белән, аннары сул як белән чәйнәргә. Кулларың җәеп утырмаска. Селәгәең агызмаска. Валчык сипмәскә. Кеше кулындагы ризыкка карамаска. Баш кашымаска. Көлмәскә. Затлы ризыкны кунакка калдырырга. Ашаганнан соң бисмилла әйтеп амин тотарга, кулларың юарга...

— Якшы. Инде йөрү кагыйдәләрен әйтеп бир.

— Йөрү кагыйдәсе биштер, мәүләм.

— Санап бир.

— Күкрәк киереп, баш чөеп йөрмәскә. Як-якка карамаска. Үткән-сүткән кешегә игътибар итмәскә. Олыларны куып узмаска. Юлдашыңны көттереп ялыктырмаска...

— Хуш, мәһди, хуш,— диде мәүлә һәм бертын дәшми торды.— Йә, сез ни әйтерсез, җәмәгать?

— Лаек,— диештеләр дәрвишләр.

— Инде, дәрвиш, киндерәң белән билең бу,— диде мәүлә.

Сынау үткән мәһди киндерә билбавын сүтте, янадан әйбәтләп буды һәм идәнгә тезләнде дә мәүләгә рәхмәт әйтте, аннары киезгә бөкләнеп утырып, дога кылды.

— Әйдә,— диде Галигә Биккол.— Кайтыйк.

Алар һавага чыктылар, бер-берсен карамый гына шактый атладылар. Күңелгә нindидер юшкын утырган сыман иде. Даны Туран дөньясына таралган шагыйрьне шушындый рәвештә күрү Кол Галигә сәер тоелды. Нигә кирәк булды микән ошбу шәкертне мәһди итү? Дәрвишләр-

не ул чарасыз кешеләр сафында йөртә иде. Мөселман дөньясын яман Чыңгыз хан гаскәрләре яулаганнан соң, Бөек Калада аерата күбәеп киткән дәрвишләр, язганга разый булып, Болгарга күчәләр. Кол Галигә бу могҗиза хәрәкәтне аңлавы кыен иде. Ул аларның хәлләренә дә керергә тели, шул ук вакытта илне кем саклар дип уйга да калгалый иде. Яман яу Болгарга да килер. Дошман өчен барысы да артык тамак. Димәк, дошман иң әүвәл карт-корыны, дәрвишләр кебек беркемгә дә игелек күрсәтә алмаган кешеләрне кырачаклар. Белеклеләрне дә санламаслар, бары тик һөнәрчеләрне саклап алып калырлар. Аларны да үз илләренә куып алып китәрләр.

— Атам, син бар, керә тор, мин бераз йөрим әле,— диде Кол Гали Бикколга. Һәм Мәләкә елгасына таба китте.

Нигә әле бу яшьлек еллары бик еш хәтеренә килеп изалый?.. Нигә рәхимсез рәвештә тәшвишләнә?.. Атасы янына барасы иде, Биккол җибәрми. Кол Галинең күз алдына Ягкуб бәк кызы Зөләйха килә. Ул аны һичкайчан оныта алмады.

Бу да хактыр. Ниләр кылып ята икән? Итәк тутырып бала үстерәме, анын кебек кангырып йөримe?.. Билгесезлек, билгесезлек. Ә күрәсе иде үзен, һич югы күзенә чалынып китәсе иде.

Ягкуб бәк өе, җылы, саф һава, янәшәсендә Зөләйха. Бераз ояла да кебек, шул ук вакытта аңа да тартыла үсмер чак. Күптән, бик күптән булган хәл, тик күңел аны һәрдаим сафландырып, кичә генә булгандай җанландырып тора. Зөләйханың йомшак кулларын бүгенгедәй уч төбендә тоя, кайнар бите, ислемай борынына бәрелеп киткәндәй итә. Тавышы, тавышы тагын — тылсым тулы моң иде, рухын нәкъ әнә шул йомшак тавышы сындырды бугай, ягымлы һәм назлы итеп дәшер иде дә мөләем итеп елмаер иде.

Бу ниткән саташу инде тагын? Ул хәлләргә бишбылтыр, искә төшереп, хәтер яңартып йөрүдән ни мәгънә!

Акрын гына кар ява. Эңгер-меңгер вакыт житте, күрше урамда сыерлар мөгри, сарык бәрәне бә-әләп куя. Йөри торгач, Кол Гали Хан күленә килеп чыкты. Көз көнендә бу күлдә Илһам хан угланы Булатның кәләше — Олуг Мөхәммәт кызы Рабига батып үлә. Бу хакта ишеткәч, Кол Гали ике төн рәтләп йоклый алмады. Нигә кирәк булды микән Булат туганына Рабиганы өченче хатын итеп алу? Туганын ул аңламады. Күрәсең, хода аларны икесен ике кыйблага каратып яраткандыр. Булат өченче хатынга өйләнергә иткән, Гали исә бер тапкыр өйләнмичә картаеп килә. Ә бит икесе дә — хан оныклары.

Кинәт күңелгә әллә ниткән уйлар, гаруз вә рәдифкә йөз тоткан юллар килде.

Йа Тәңрем!
Хәтеремә шик-шөбһәне чәчрәтеп бир,
Җанга хикмәт орлыкларын син чәчеп бир,
Миңа ярдәм капусыны син ачып бир,
Гаклым тугры, телем тәзек итче имди.
　　Ярдәм бир Син хикмәтләргә кайту өчен,
　　Гакылым вә аңым-зиһнем байту өчен,
　　Йосыф-Зөләйха әхвәлен әйтү өчен,
　　Гыйльмем камил, телем нәфис итче имди.

Ни сәбәпледер өйгә ашыкты. Биккол аны капка каршында көтеп тора икән, эңгер инеп килүгә карамастан, еpактан ук дәште:

— Озак йөрисең, озак, Кол Гали. Тыныч түгел бездә хәзер. Кала мөһаҗирләр белән тулды, алар арасында тамак өчен тәмугка керергә торучылар бар.

— Күңелем җилкенеп тора, атам. Кемгәдер, нидер әйтәсем килә, рухым белән күккә ашар хәлләргә житәм.

— Илһам килүедер. Утыр, яз. Күңеленә нә килә, шуны яз. Саф күңел алдамый ул. Ни бит әле, Гали, сиңа әйтер сүзем бар. Атаң Казанда түгел, Кашанда икән. Бикәсе дә янында, ди. Аның бикәсе турында әлләниләр сөйлиләр. Сиңа таныш икән бит ул бала. Миңа бу хакта кәтиб Хафиз әйтте.

— Зөләйха?!

— Үзең дә беләсең икән ич. Атаң әмир Хажи күптән түгел ил аксакалы Ягкуб бәк кызы Зөләйхага өйләнгән. Тату гына яшәп яталар икән, ә син аны...

Кол Гали бер сүз әйтмәде, кабаланып өйгә керде, бүлмәсенә үтте һәм арлы-бирле йөренергә кереште. Бу хәбәргә ул кинәнергә дә, көенергә дә, сөенергә дә белмәде. Ниндидер үзе дә аңлап бетермәгән халәттә иде. Итеген салып, түргә үтте, сузылып сәкегә ятты. Озак ятты, озак уйланды. Ахыр сикереп торды, язу өстәлчегенә килеп таянды.

Кимсенү хисе дә түгел иде кебек, ә йөрәкне нидер кыса, нидер бәгырьне телгәли. Зөләйха турындагы хәбәр аны кисәк тетрәтеп җибәрде. Әле ул үзен агалары тарафыннан рәнҗетелгән Йосыф хәлендә тойды, әле үзен Мәҗнүнгә тиңләде. Кем кемне рәнҗетте, Гали — —Зөләйханымы, ул Галинеме?.. Язмышмы аның белән шулай шаярды?.. Ә күңел җилкенә, ашкына, кемгәдер, нидер әйтергә тели. Кулына каләм алды, кара савытын ачты.

Бисмиллә-иһи-р-рәхмани әр-рәхим...
Мактау шөкер вә дан Аллага,
Мөлке даим, үзе мәңге ул Мәүлага.
Мөлкәтенең эчендә юк шәрик Аңа,
Аны бакый һәм Олуг дип белдек имди...
    Аннан соңра Аның дусты Мөхәммәткә,
    Пәйгамбәр итеп сайланган ул Әхмәткә,
    Хакъка ике җәя ара калган Затка,
    Аңара бик күп дан-мактаулар улсын имди...*

Бер шәм бетте, икенчесен кабызды, өченчесенә ут салды, ә күңеле гелән язгы ташкын сыман шаулады, илһамланды.

Биккол ишекне кысып кына ачып карады, әмма Кол Галинең язып утыруын күргәч, сак кына ишекне япты да үз ятагына китте.

Иртәнге якта, кояш чыгып тәрәзәләргә нурлары төшкәч кенә Биккол күзләрен ачты, беренче булып Кол Галине исенә төшерде. Кабаланып өстен ачты, чүәкләрен элде, кыштыр-кыштыр Кол Гали бүлмәсенә таба үтте. Әмма ишекне ачып карарга кыймады. Алай да түзмәде, бертын басып торгач, һичнинди тавыш-мазар ишетмәгәч, күңеленә әллә ниткән шик килеп, акрын гына ишекне ачты, эчке якка күз салды. Кол Гали башын күтәрми язып утыра, кояш тәрәзәдән нурлар сибә, ә шәмдәлендә шәм яна. Биккол янә дәшмәде, акырын гына ишекне япты да асрау кызга юынырга таз-комган кертергә кушты.

## 25

Аңа хан сараеның һәр ишеге, һәр бүлмәсе, һәр тарлавыгы таныш иде. Сарайга килеп кергәч, Кол Галинең тыны кысылды. Әйе, гомер аккан елгадыр, кайчан гына шушы тарлавыкларда йөгереп-уйнап йөрер иде. Менә иркен вә якты тәхет ягы. Халык инде җыела да башлаган. Ни өчен җыя аксакалларны, түрә-тарханнарны хан — берәү дә белми иде. Былтыр һиҗри белән 617, милади белән 1220 елда урыс кенәзе Юрий Всеволодович туганы Святослав Болгарга яу килә. Иделнең сул ягына

* Шигырьләр Кол Галидән һәм Утыз Имәнидән алынды.

чыгарга кыймый, әмма Иделнең уң ягына урнашкан Җаббар бәк кулындагы Ашлы каласын талый, яндыра, бик күп кешеләрне әсир итеп Үлдәмиргә алып китә. Кол Галинең энесе Җаббар шушы орышта һәлак була. Бу хәбәрне ишеткәч, атасы әмир Хаҗи нә кылгандыр, әмма Кол Гали ай буена кулына каләм тота алмады.

Бүген Болгар һиҗри белән 618, милади белән 1221 елга аяк басты. Урыс кенәзе Юрий, үзенең хатасын аңлапмы, Илһам ханга солых төзергә илчеләр җибәргән. Солых төзүне, әлбәттә, Үлдәмир сәүдәгәрләре таләп иткәндер. Шулай дип сөйләделәр. Илчеләр башында Яким Кучтем атлы зат килгән икән. Үлдәмир кенәз белән солых төзү мәҗлесенә чакырдымы аларны Илһам хан: Кол Гали белми иде. Илһам хан, әлбәттә, Бикколны гына дәштергән, ләкин Биккол хан мәҗлесенә үзе белән Кол Галине дә алды.

Килгән бер кеше зур итеп әзерләнгән табынга утыра. Биккол белән Кол Гали тәхет тирәсеннән ераккарак бер урынга чүмәштеләр. Биккол тәхеттә утыручы Илһам ханга күз төшергәләп алды. «Ә бит ошбу тәхеттә Кол Гали утырырга тиеш иде»,— дип уйлап куйды. Әмма язмыш хан оныгы белән әнә нинди дер яман уен уйнап ала. Болгар тәхетендә утырасы кеше — ишек янында, ә әмир буласы кеше — тәхеттә.

Ул арада мәҗлескә Зөбәрҗәт ханбикә килеп керде. Угланына итагатьле генә баш игән итте дә, урынына барып утырды. Илһам ханның өстендә парчалы яшел чапан, башында алтын төсендәге чалма, маңгаенда зур гына зөбәрҗәт таш. Шәмнәр яктысына хан маңгаендагы таш җем-җем итеп китә. Вәзир Камай торып басты һәм Илһам ханга карап өч тапкыр баш иде.

— Галиҗанәпләре, Бөек Болгарның олуг ханы Илһам, безгә күршемез Всеволод угланы Юрий кенәз илчеләре килеп төште. Йомышлары сөенечледер. Инде башларга рөхсәт итегез!

— Башлагыз! — диде Илһам хан, кам таягын идәнгә төртеп алды.

Бусагабаш Субай кул чапты, шундук домбра зеңләде, кайсыдыр курай тартты, кубыз чиртте, аларга кәмәнчә кушылды. Мәйдан уртасына үтәли күренмәле өрфә күлмәкләр кигән кызлар йөгереп чыкты һәм күнелләрне җилкендереп бии башладылар. Никадәр илаһилык, хозурлык һәм күркәмлек иде кызлар биюендә. Кол Гали биегән кызларга исе китеп карап торды. Аның әле мондый мәҗлесләрдә бер тапкыр да булганы юк иде.

— Шәех Игънәй кая, нигә күренми икән? — диде Биккол.

— Йә авырып киткәндер.

— Сырхаулап тора дигәннәр иде шул,— диде Биккол.— Аннары Булат углан да юк. Аңлашыла, атасы белән сүзгә килгән дип әйтеп әйткән иде. Димәк, Илһам хан угланны килерлек итмәгән. Түе бик кызганыч бетте шул. Кызга ирексезләп диярлек никах укыйлар. Ә ул җай табып чыгып китә дә Хан күленә чума. Ары ташлана халык, бире ташлана. Яшь кәләш юк та юк. Ике көннән бичараны күлдән тартып чыгаралар. Шуннан бирле Хан күлен Рабига күле дия башладылар.

— Килерлек булмаган икән шул Булатка,— диде Кол Гали.

— Әйе, кызганыч, кызганыч бетә шаһ кызының язмышы.

Өргәнечтән алып киткәндә үк йөргән егете бар дигәннәр иде...

— Әнә теге кара чәчле кызны кара әле, Биккол атам, карале, гел аккош кебек йөзә ич!

— Үтте инде гомер, үтте, Кол Гали. Картлык килде. Яшьрәк чакта мин дә алардан күземне дә ала алмас идем. Хәзер әнә кызыгудан ары китә алганым юк. Күзгә күчте, күзгә, Гали олан. Күр әле, Тәтеш шәех тә монда. Аның янәшәсендә шагыйрь Әхмәт Югнәки утыра. Сарай шагыйре ул хәзер. Сәлим хан алып калдырды. Чәчән әйтү булса, чыкмый калмас, түзмәс. Әллә мәйтәм, Гали олан, син дә бәхетең сынап карыйсыңмы? Кем белә сине монда!..

— Мин нигәдер сукыр Хуҗа Әхмәтне күрмим. Пәхлеван Мәхмүт аның хакында: «Мәдинәдә Мөхәммәт булса, Өргәнечтә Хуҗа Әхмәт»,— дип әйтергә яратыр иде.

— Димәк, чакырулы түгелдер.

— Хан аны сараенда тота, нигә чакырып торырга. Хуҗа Әхмәтнең бер шигыре исемә төште әле. «Алла каршында адәм баласы тузандыр, нәфсем озын, телем кыска, кулым әллә кая сузамдыр».

— Шәп әйткән,— диде Биккол.— Гелән минем турымда шигыре. Биючеләр китте, хәзер җырчылар чыгар. Илһам хан бер дә мәрхүм атасы Сәлим ханнан ким куймый. Әнә, әнә чыкты да. Кашан егете, беләм мин аны.

Курайчы сыздырып җибәрде, җырчы егет кулын-кулга куйды да җырлап җибәрде.

Шәһре Кашан — җиһан гөшә, олуг кечег һөнәр итә,
Әһле Кашан — җиһан гөшә халаекы һөнәр итә.
Шәһри Кашан манарасы язулы икән башлары,
Шәһри Кашан мәчетендә бар ди әүлия башлары.
Шәһре Кашанга бардым, зират күрермен диеп,
Чулман суларын эчкәч, сихәтләнермен диеп...
Җиһанны тетрәтмәкче иде синең әмирең,
Кайда шәһрең, кайда илең, кайда әмерең, әмирем?!

Җырчы туктады, бил бөкте, кул чаптылар. Илһам хан җырны тыңламады, ахырысы, вәзиренә нидер сөйләп калды.

— Кем турында җырлады дип беләсең инде бу җырчы, Кол Гали?

— Атам турында булса кирәктер.

— Миңа калса, бу җырчыны юри чыгарган Илһам хан. Имеш, әмир Хаҗи хәзер Кашанга ия түгел, Казанга ия.

— Ашыкма, атам, нәтиҗә ясарга. Җырның ертыгы юк, диләр. Илһам абамда мин ниндидер бәрәкәт күрәм. Авызы белән кош тотмаса да, урыс белән солых төзеп ята бит әле.

— Нә бәрабәренә төзелә бу солых дип беләсең?.. Илһам хан эрҗәмукшы илтабарларын якламаска тиеш булачак. Әнә нәстә бәһасенә төзелә бу солых, Кол Гали олан.

— Эрҗә-мукшы илтабарлары үзләре ризалык биргән булсалар?

— Кем инде үзе теләп муенына элмәк сала, Гали олан!? Тукта, нигә әле миңа Илһам ханның сәясәте... Мин картайдым, сакалым билемә житте, акылым сыекланды... Житте. Күр әле курайчыны, ничеккенәләр өздерә! Карале, хан кызы Назлыгөл дә күренми. Туйда булган дип әйтеп әйткәнннәр иде. Тагын бер җырчы чыкты. Җаек-Карамалы кирмәненнән. Ишеткәнем бар минем моны. Җырлап җибәрсә, тәннәр чемер-чемер килер иде. Һәр җырчы үз төбәге турында җырлый. Уралым, диде түгелме...

Һәй, Уралым, уралып яткан Уралым,—
Ил саклаган коралым, ил саклаган коралым.
Анам килен төшкән җир, атам кияү булган җир,
Кендегемне кискән җир, татлы суың эчкән җир...

Урал-Җаек кирмәненнән килгән җырчыны сары чәчле урыс алыштырды. Моны илче Яким Күчтем алып килгән булса кирәктер, дип утырды халык. Һәм шулай булып чыкты да, егет сыбызгыга иярәп, балалайка зеңләтүчегә карап, җырлап җибәрде.

Полно, солнышко, из-за лесу светить,
Полно, красно, в саду яблоки сушить!
Полно, девица, по молодому тужить,

Полно, красная, по удалому тосковать...
Как мне, девушке, не плакать, не тужить?
Такого дружка на свете не нажить!..

— дип кайдандыр килеп чыккан кыз егетнең җырын тәмамлады.

Җыр тәмамлаган кыз егетне култыклап алып китәм генә дигән иде, икенче тарафтан янә бер кыз килеп чыкты, җыр башкарды да егетне үзенә таба тарта башлады. Егет югалып калмады, кызларның икесен дә култыклады да түр якка алып кереп китте.

Көлештеләр, кул чаптылар. Ниһаять, чәчәннәргә нәүбәт житте. Уртага чәчән Әхмәт Югнәкәй чыкты, думбрасын көйләгән итте, жайлабрак утырды. Акырын гына чиртә башлады. Кол Гали чәчәннен һәр сүзен күңеленә сендерергә тырышты. Көйле, жай вә тигез итеп әйтә иде шигырен чәчән Югнәкәй.

Туган ягым яман-явыз мәлгун басты,
Анам-атам, хөрмәт халкым дарга асты...
Явызлыкка түзә алмый зар егълыймын,
Туган ягын ташлап халкым качты.
Адәм, мескен, җәннәт эзли гомер буе...
Онга мәгәр җәннәт икән туган иле,
Җәннәт икән адәм өчен туган өе,
Туган иле, туган жире, туган бәе.
Җәннәт икән сылуынның йөзен күрү,
Җәннәт икән алсу битләреннән үбү,
Җәннәт икән үз илеңдә бәхет тою,
Җәннәт икән үз илеңдә яшәп үлү.
Бер кәңәшем вардыр сезгә, кардәшләрем,
Бер кәңәшем вардыр сезгә, һәй дусларым,
Җәннәт дигәннәре туган илдер,
Ялан тәпи баскан туган жирдер.
Сакла илең, ханым, көчең булган чакта,
Сакла илең, туган халкың сакла.
Сакла илең — җәннәт икән жирең,
Җәннәт икән жирең, җәннәт икән илең...

Илһам хан тәхетеннән күтәрелде, чәчән янына килде, нидер әйтте, кул чапты. Биккол Кол Галинең кабыргасына төртеп алды.

— Син дә чык, Гали! Сине монда берәү дә белми. Син минем кунагым.— Биккол урыныннан купты, думбрачыга дәште: — Уйна әле минем кунагыма. Ерактан килгән мосафир. Шөһратлем олуг хан, игелеңегез биреңезче?

— Йә-йә, чыксын,— диде Илһам хан һәм тәхетенә утырды. Дәүәнисенә күтәрелеп карарга базмыйча, Кол Гали мәйдан уртасына чыкты. Думбрачыга рәхмәт әйтте, кирәкмәссең, диде. Дога укыгандай көйләп жибәрде.

— Бисмилләһи-рәхман әр-рәхим! — Күңелендәге барлык хиссиятен жыеп, Кол Гали яза башлаган шигъри юлларын укый башлады. Ул берәүне дә күрмәде, берәүгә дә күтәрелеп карамады, ул бөтен жаны-тәне белән шигърияте тәэсиренә кереп чумган иде.

Кол Гали шигырен укып бетергәч, Илһам хан бармак изәп кенә вәзире Камайны янына чакырып алды, колагына нидер әйтте. Боларның барысын да күздән кичереп утырган Биккол Кол Гали янына утыруга, пышылдап кына:

— Безгә чыгып китәргә кирәк, Гали олан,— диде.

Шулчак Тәтеш шәех күтәрелде һәм:

— Олуг хан, мәҗлесләрдә чәчәннәрнең исем-атын әйтү гадәткә кермәгән. Кем генә булмасын, бу чәчән аллаһы тәгалә юллаган адәмдер, аңа

ходай үзе тел ачкычы бирсен. Рәхмәт сиңа, чәчән! — диде шәех торып Кол Галигә бил бекте.

— Ишетәсеңме, Гали олан, безгә чыгып китәргә вакыт. Илһам хан игътибар итте. Мин ханның ниятен белмим, иллә аллаһы тәгалә саклаганны сакләрмын, дигән. Мин хәзер торам да товар ишем Якимкәгә таба кузгалам. Шаулабрак барырмын. Ә син тиз генә чыгып шыл...

Шулай диде дә кайчандыр Сәлим хан сәүдәгәре булган Биккол каршысында утырган Яким Күчтемгә таба китте. Ул арада Кол Гали торып ишеккә юнәлде. Ул аркасы белән тойды, Илһам хан аңа карап калды. Аның артыннан дүрт-биш азат чыкты. Кол Галигә сарай тирәсендәге тыкрык-аралыклар таныш иде. Ул сул якка борылды, кызлар өенә таба китте.

— Кая китте!? — дип сорады артыннан чыгучыларның берсе.

Кол Гали диварга сыенды. Аның янынан ике кеше йөгереп узды. Бертын торгач, Кол Гали үзенә генә таныш аралыклардан урамга чыкты һәм өенә кайтканчы артына әйләнеп карамады.

## 26

Чыңгыз хан солтан Җәләлетдиннең кыюлыгын үз күзе белән күрде. Гаскәре белән тулганага алынып, камалып, тәгаен елга ярына кысылган яшь солтан аты белән дәрьяга сикерде һәм аръякка йөзеп чыгып, Чыңгыз ханга йодрык күрсәтте. Чыңгыз хан ни әйтергә дә белми яр башында басып калды. Янәшәсенә килеп туктаган угланнарына ул, әйләнеп карамый гына:

— Кызганыч, ошбу батыр егет минем улым түгел,— диде.

Сүбәдәй баһадир ханның бу сүзләрен ишетте дә чак кына хан алдына килеп: «Мин үзем тотып алып кайтам ул батыр егетне!» — дип әйтмәде. Нинди дер бер мәлдә, инде кузгалырга иткәч, аны абасы Җәбәй тотып калды. Җәләлетдин солтанны Сүбәдәй баһадир төмәне тулганга алган иде, үзе качса да гаскәре кырылды, сугышчыларының күбесе әсир ителде.

Юртага керүгә, Сүбәдәй баһадир түр якка күз ташлады. Чыңгыз хан тезен чәнчеп йомшак мендәрдә утыра, алдында яшь хатыннан туган Кулан углан. Ханның уң ягында өлкән угланы Җуси, сул ягында энесе Хасар.

Юртага керүгә, абасы Җәбәй нойон ханга баш иде, бер аягына тезләнеп, кулын-кулга куеп бил бөкте. Сүбәдәй баһадир да шул ук хәрәкәтләрне кабатлады.

Чыңгыз хан сабыр-тыйнак кына, үтегез, утырыгыз, дип ияк какты, урын ягына күрсәтте. Аннары тезендә утыручы Кулан угланны төшереп җибәрде дә, табында торган кәсәләрне күтәрергә кушты. Зур гына кәсә иде, Сүбәдәй баһадир эчеп бетерде дә мыегын сыпырып, кәсәне кире урынына куйды. Чыңгыз хан тамак кырды, барысы да шым булды.

— Нойоннарым, баһадирларым, мин сезгә Тәңре илаһы вә күк йөзе ярдәме белән ошбу мәмләкәтне яуладым. Инде Тәңре илаһы вә күк йөзе ярдәме белән сез миңа Олуг Мөхәммәтне тотып алып кайтыгыз.— Чыңгыз хан кымызчыга кәсәләргә кымыз кой дигән ишарә ясады.— Бу йөкне мин иң ышанычлы кешеләрем Җәбәй нойон белән Сүбәдәй баһадирга тапшырырга булдым. Үле килешме, тере килешме, сез миңа шаһны алып кайтыгыз. Сезгә мин янә бер төмән өстим — Гөмәй бәк барыр. Яу башында Җәбәй нойон торыр.

Чыңгыз хан кәсәсен күтәрде, эчеп куйды, барысы да аның хәрәкәтен кабатлады.

Атна дигәндә Сүбәдәйнең төмәне яуга чыгарга әзер иде инде. Тагын ике көннән Җәбәй нойон, Сүбәдәй баһадир һәм Гөмәй бәк төмәннәре белән көнбатышка таба кузгалдылар. Хәрәземшаһ Олуг Мөхәммәтне эзәрлекли-эзәрлекли, утыз меңнән торган гаскәр ике ай дигәндә Гөр-

жиләр жиренә аяк басты. Ниндидер елга буена тукталып, тирә-юньдәге авыл-торакларны талап, һичкемгә буйсынмыйча, үзбаш яшәп ятканда берләштерелгән гөрҗи-әрмән гаскәре килмешәкләр белән орышка әзерләнә. Бу хәлне сизеп алган чыңгызлылар да югалып калмыйлар, орышны кабул итәләр, гадәти хәл буларакмы, башка бер-бер сәбәп беләнме, гөрҗи-әрмән гаскәрен тар-мар итәләр һәм Төньяк Кавказ җирләренә юнәләләр. Тимер Капка каласына җитәрәк туктыйлар, кышлыйлар. Гөрҗи-әрмән гаскәрен тар-мар иткән чыңгызлыларга берәү дә каеп каршы тормый. Чыңгызлылар үзләрен иркен тоталар, Тимер Капка аша үтәсе сәүдәгәрләрне туктатып, мәгълүмат җыярга керешәләр. Тимер Капка дигәннәре далага чыгу өчен бердәнбер юл икән — әнә шуны белә чыңгызлылар.

Яз килеп, кояш карый башлагач, Тимер Капка әмиренә илчеләр җибәрәләр. Бу эшләр белән Җәбәй нойон шөгыльләнә, Сүбәдәй баһадир исә сугышчыларын орышырга өйрәтә, тирә-яктагы халыклардан азык-төлек җыя. Тимер Капкага киткән илчеләр кире кайтмыйлар. Бу хәлгә ачуы чыккан Җәбәй нойон Тимер Капка әмиренә янә илчеләр җибәрә, әмиргә:

«Син, әмир, калаңны гына түгел, халкыңны да, үзеңне дә кыен хәлгә куясың»,— дип әйтергә куша. Тимер Капка каласы, әмире хатасын аңлапмы, ошбу көтелмәгән дошман ыстанына илчеләр юллый. Илчеләрне Җәбәй нойон үзе кабул итә. Илә әмир илчеләр Җәбәй нойон белән койты сөйләшәләр, әллә ниткән шартлар куялар. Каласы аша үткән һәр сәүдәгәрдән, мосафир-сәфәрчедән салым алырга өйрәнгән әмир ниндидер кыргый халыкны һич тә бушлай гына каласыннан уздырасы килми. Ләкин ул Тимер Капка каршына килеп туктаган чыңгызлыларның кем икәнен белеп бетерми. Иң әүвәл Җәбәй нойон ишләре күз алдында илбашны кылычтан уздырырга куша. Илчене Сүбәдәй баһадир үзе кылычтан уздыра. Шуннан бу хәлне күреп, котлары алынган ике илчегә:

— Әгәр дә мәгәр каланы үтәр юлны күрсәтмәсәгез, сезне дә шундый ук үлем көтә,— ди.

Бу тамаша явызлыкны гомер бакый күрмәгән илчеләр күзгә-күз карашып алалар, урталай чабылып ташланган илбаш мәетенә күз төшерүгә: «Күрсәтербез, күрсәтербез»,— дип әйтергә мәҗбүр булалар.

— Без хәзер менә монда,— диде Гөмәй бәк.— Менә Тимер Капка, менә без үткән таулар, тарлавыклар.

— Утыр, Сүбәдәй,— диде абасы күтәрелеп карамый гына.— Син дә тыңла. Хак әйтәсең, Гөмәй бәк, без хәзер аланнар иленә килеп чыккanбыз. Ары таба кыпчаклар иле башлана икән, кыпчакларга күрше — урыслар. Ә менә бу якта, төн ягына табарак болгарлар иле. Безгә аланнар да, урыслар да, болгарлар да кирәкми, безгә Олуг Мөхәммәт кирәк. Ә ул Тимер Капка аша узмаган, илчеләр әйттеләр. Димәк, Олуг Мөхәммәт йә диңгез аша кичкән дә Идел кыпчаклары ягына тайган, йә болгарларга ук качкан.

— Шулкадәр ерак китәрме? — дип сорады Гөмәй бәк.

— Авыз-колагыңа кайнаган кургашын тутыртасың килмәсә, син дә китәр идең,— диде Җәбәй.

Сүбәдәй баһадирның әле дә күз алдында: Чыңгыз хан Әтрәр әмирен әсир иткәч, тегенең авыз-колагына кайнаган кургашын койдырткан иде. Андый үлемне дошманыңа күрсәтмәсен.

— Алан кенәзе килеп киткән, минем меңбашны кисәтеп куйган, иртәгә даладан кузгалып китмәсәгез, куып җибәрәчәкбез, дип әйтеп әйткән,— диде Сүбәдәй.

Нойоннар икесе дә Сүбәдәйгә күтәрелеп карадылар.

— Синең ул меңбашың нә караган, нигә аны тотып миңа китермәгән? — диде Җәбәй нойон.

— Ул илче исәбендә килгән, кисәтергә дип. Ничек инде шуның өчен аны әсир итмәк кирәк!

Җәбәй нойон сикереп үк торды, энесенең изүенә ябышты.

— Моннан ары, миннән рөхсәт алмыйча, бер кеше дә ыстанга аяк басмасын. Ишеттеңме! Сүбәдәй дим?!

— Җибәр, ишеттем, саңгырау түгелмен,— диде ачуланыбрак Сүбәдәй.

— Ишетсәң, утыр, тыңла. Аланнар безне биредән чыгармыйлар икән, без алар белән орышырбыз! Безнең юлга аркылы төшмәсеннәр. Гөрҗиләрне кырган кебек кырырбыз үзләрен...

Юртасына әйләнеп кайткач, Сүбәдәй баһадир бик озак йоклый алмый ятты. Хәтер кәтүге сүтелеп китте. Күз алдына өйләнү мәлләре килде. Бүген-иртәгә Хәрәземшаһ иленә яу чыгасы көн иде.

Кояш кичкә авышып килә иде инде. Сүбәдәй баһадир авыз эченнән генә сызгыра-сызгыра юртасына кайта. Юлы чишмә яныннан уза. Шунда хикмәтле бер сурәткә тап булды. Чишмә янында ике итеген дә салып, нинди дер бер изге җан — кыз, аякларын юып тора. Кыз аны күрми, арты белән утырган. Итәген күтәргән, күзне камаштырырлык ак тән, Сүбәдәйнең гүя ки, йөрәген тартып алды. Башта ул кызга дәшәргә итте. Ахыр бу уеннан кире кайтты. Рәхәт иде карап торулары, кыз авыз эченнән нидер көйли, аның карап торуын искәрми дә. Сүбәдәй баһадир якын ук килде, ул хәтта аның тән җылысын тойды сыман, шулхәтле якын тора иде ки, чарасыз вә ихтыярсыз калды. Әчке бер тоемлау белән кыз нидер сизде, артына әйләнеп карады һәм янәшәсендә үк басып торган ир-атны күрде дә, күлмәк итәген дә төшерергә онытып:

— Йә, нигә туктап калдың, үт! — диде.

Кәрият нәселеннән алар шулай эре сөяклеләр, һавалылар, кыюлар, горурлар. Ләкин Сүбәдәй дә төшеп калганнардан түгел иде, югалып калмады.

— Мин сиңа бүген үк яучы җибәрәм,— диде. Шулай диде дә камчысын җиргә ташлады: — Атың әйт!

— Кем син сорнайга кияүгә чыксын. Әнә үзең әсир иткән мөртәт кызларына өйлән, йә булмаса ханың кебек татар кызларына!

— Миңа татар кызлары да, мөртәт кызлары да кирәкми, миңа син кирәк. Мин сиңа өйләнәм. Юртаң кай тарафта?

Итеген салган, күлмәк итәген күтәргән хатын-кызга карау — мәлгуннәрдә килешмәгән хәл. Әмма Сүбәдәй андый хикмәтле хәл-горефләрдән ерак тора иде. Иң әүвәл ул — сугышчы. Һәм шактый батыр, тәвәккәл сугышчы. Кыз аңа торган саен ошый иде. Сүбәдәй кызга таба бер адым ясады. Нидер сизенеп, кыз читегенә үрелде. Сүбәдәй аны кочарга дип кулларын сузды, ләкин шунда ук тәгәрәп китте. Кыз аның күкрәгенә шундый итеп типте ки, кая барып төшкәнен сизми калды. Сикереп торды, кыз аңардан качып, каенлыкка кереп бара иде инде.

Юк, сорнай Сүбәдәйдән кача ала буламы! Сүбәдәй сикереп торды, җан-фәрманга кызны куа китте. Кызны ул шактый тиз куып җитте. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, үрелеп чәченнән эләктерим генә дигәндә абынып китте һәм сөрлегеп егылды. Тагын торды, тагын куды. Аның тәмам ачуы чыкты, ул тешен кысып чапты, ә үзе: «Сүбәдәйдән берәүнең дә кача алганы булмады әле, сине генә тотар ул, тотар»,— дип сөйләнде. Нинди дер куаклыкларны уздылар, куаклыклар артында кызның юртасы булу ихтималы бар иде. Сүбәдәй бар көченә йөгерә башлады. Кызның чинаяктай ак балтырлары күренеп китә, чәч толымнары уңга-сулга җилпенә, күлмәк итәге күпергән, кулында итекләре, ташламый, иң мөһиме кычкырмый, ярдәмгә берәүне дә чакырмый иде.

— Тукта! Тукта, диләр сиңа! Боланмы әллә син, җәйранмы?..

Кыз әйләнеп карады, нәкъ шунда Сүбәдәй аның беләгеннән эләктереп алды һәм кыз белән бергә тәгәрәп тә китте.

— Җәйран, кая болай чабасың!

Кыз аңына килгәләгәнче, ул аның өстенә менеп ятты. Калганын сизми дә калды, табигать биргән җисми тойгы зиһенен томалады. Кыз

кычкырды бугай, әмма ул ишетмәде, артык мавыккан иде. Бары тик хәйвани нәфесен туйдыргач кына аңына килгәндәй:

— Мин сиңа өйләнәм, син минем хатыным,— диде.

Кыз дәшмәде, аскы ирнесендәге теш эзләрен ялаштырды, мөлдерәп тулган күз яшен тыя төшеп, үкси башлады. Сүбәдәй ыштан бавын элмәкләде һәм кызның җәйрәп ятуын күреп, курка калды. Ул аның янына тезләнде, итәген төшерде, битен кызның битенә тидерде.

— Ишетәсеңме, мин сиңа өйләнәм, син минем хатыным.

— Күтәр мине, батыр булсаң, күтәр,— диде кыз. Сүбәдәй каударланып кызны кулына күтәреп алды, кыз аның муенына сарылды. Кызның шушы хәрәкәтеннән, чәчләре битенә тиеп китүдән Сүбәдәйнең йөрәге ашкынып тибә башлады.

— Син минем хатыным, мин сиңа өйләнәм,— диде ул чарасыз калып.— Кем син, кем кызы?

— Билгәтәй батыр кызы мин. Атам мөртәтләр белән орышта ятып кала. Анам белән икәү генә торабыз. Син миңа өйләнмәссең, мин беләм...

Сүбәдәй туктады, кызны аягына бастырды, ике битен учларына алды.

— Билгәтәй батыр кызы минем хатыным булыр. Мин моны ханга кадәр җитеп әйтермен. Ишетәсеңме, Билгәтәй батыр кызы! Атың ничек, атыңны әйт?

— Сөярсу дияр иде, әтием. Сөярсу мин.

— Сөярсу,— диде Сүбәдәй һәм янә кызны кулына күтәреп алды.

Күк йөзе куе зәңгәр төстә, йолдызлар белән чуарланган, ары таба күгелҗемләнеп таулар күренә. Шул тарафта авып китәргә торган ай кыйпылчыгы йөзә. Аяк астында дымсу үлән, һава саф, сулыш алырга җиңел. Барыбер туган як һавасы түгел. Туган якларда һава болай бөркү түгел, сулышка җиңеллектән йөгереп китәсе килә. Ә монда нидер итәктән тартып тора сыман.

Ни генә булмасын, Сөярсу Сүбәдәй баһадирга үзе теләп кияүгә чыкмады, аны мәҗбүр иттеләр. Кем? Әлбәттә инде сорнай Сүбәдәй. Күңелен түгел, йөрәген ярып керде, әрсез вә рәхимсез рәвештә.

Сөярсу анасы еш кына әйтер иде: «Кызым, бер-бер кеше кулың сораса, карышып, сайланып торма, килеш. Ир-ат булмагач, яшәүләре кыен. Гомер дигәнең бик тиз үтүчән ул, иңеңә таяныр ир-заты булмагач, ни кылмак кирәк»,— дияр иде. Бәлкем җан-фәрман йөгергәндә анасының шул сүзләре бераз гына тыелырга мәҗбүр иткәндер, аннары сабырсызланып, җанын койганда да кычкырмады, янә шул әнисе сүзләрен исендә тотты. Кияүгә чыгарын белә иде Сөярсу, әмма болай чыгар дип күз алдына да китермәгән иде. Сөелеп, сөешеп туйгач кына кияүгә чыгам, дип әйтер иде, ә ул әнә ничек килеп чыкты. Әйе, ул Сүбәдәйне яратмады, ул аңа усал, явыз күренде.

Сөярсу баланы атасыннан башка тапты, Ә Сүбәдәйнең әле ул баланы кулына алганы юк.

Ялгыз ай кыйпылчыгы да тау артына кереп бара. Ят таулар, ят дала, ят җир. Моңсулана күңел, сагышлана, күз алдыннан Сөярсу китми. Нигә, ни сәбәпле шул хәтле сагына ул Сөярсуын? Җәбәй абасы әнә илдә калган хатыннарын исенә дә төшереп карамый, юртасы тулы кызлар тота, әйтерсең лә яуда да түгел. Сөярсуны сагынуымы шулай, әллә булмаса хатын-кызны тансыклавымы?.. Алай дисәң, аның кулы аша нинди кызлар гына үтмәде, һич берсенә күзе төшмәде, теләге булса, җаны тартылмаса, тәне тартылыр иде. Әйтик, иң әүвәл Хәрәземшаһ кызын үзендә калдырган булыр иде. Ә ул аны абасына бирде. Тәңре шулай язгандыр, тәңре шулай язмаган булса, Сөярсуыннан аермас иде. Сөярсу хәзер ярлы түгел, унлап юртага ия, көтүчеләре бар, аннары Сүбәдәй шактый байлык җибәрде. Боерган итсә, үзе белән дә алып кайтыр.

Сөер бер хәл, ул бит аны күреп, гашыйк булып та йөрмәде, ә менә очратуы булды, гүя кыз үзен сихерләде, йөрәген йөрәгенә бәйләргә

мәҗбүр итте. Юан сыйраклы, нечкә билле, күперенке артлы хатын-кызны күп күрде ул, мәгәр берсенә дә өйләнмәде. Ә моны күрде дә үзенеке итте дә куйды! Теге вакытта кызны куып җитә алмаган булса, бәхәссез, бәлкем өйләнмәгән дә булыр иде, бик ихтимал. Ә менә җенес җенескә кушылгач, Сүбәдәй алышынды, бөтенләй башка кешегә әверелде. Кыска гына вакыт эчендә Сүбәдәй хатынына шулкадәр иләнде ки, хатын кая барса, бозау кебек аның артыннан йөри башлады. Баһадирның бу халәтен күреп, Чыңгыз хан аны юртасына чыкыртып алды.

— Өйләнгәнсең икән бит, Сүбәдәй баһадир, әйтмәдең дә,— дип үртәләгәндәй итте хан.— Утыр, утыр. Димәк, син дә юрталы булдың. Юртаң кая утыра?.. Хатының кем?.. Батыр Билгетәй кызы! Менә сиңа мә! Аның шундый җиткән кызы бар идемени?! Бик әйбәт булган. Хәзер әйт, ничә асрау кирәк? Әйт-әйт, ятсынып торма! Мин атаң Җирсүдәйгә сезне кеше итәрмен дип ант иткән идем, антым бозмам, атаң игелеген онытмадым. Атаң мәрхүм мондый көннәрне күрә алмады. Ләкин атаңның корыч холкы, нык рухы синдә, миндә калды.

— Миңа берни дә кирәкми, хан.

— Әйтмә миңа алай. Ул нәрсә синең эшең түгел, хан эше. Без синең белән яңадан-яңа илләр яуларга чыгасы кешеләр. Без ул илләрне яуларбыз. Яуларбыз бит!?

— Яуларбыз анысы, нигә яуламаска! — диде Сүбәдәй.

Сүбәдәй хан юртасыннан чыкты да ишек яры баскан кишектиннең иңбашына сугып алды.

— Хәлләр ничек, батыр!

— Шәп, баһадир! — диде кишектин. Ул яшь иде әле, бик яшь. Чөнки Чыңгыз хан унбиш яшьтән аль , җитмеш яшькә кадә[ барлык ир-атны да атка атландырырга боерган иде. Ләкин Сүбәдәй баһадир моңа шаккатмады, иң мөһиме хан аны үз итте.

Чыңгыз ханның ни ышандырганын ул белми иде, әмма шатлыгы йөзенә үк бәреп чыккан иде.

— Бәхет өләшкән җирдә булган берәү,— диде Сөярсу ире яктырып кайтып керүгә.

Хатыны табынга аш куйды, кашыклар тезде, анасына дәште, шуннан соң гына ир-канаты янына утырды. Сүбәдәй киезе тишелә башлаган юрта эченә күз йөртеп чыкты.

— Тиздән без моннан китәрбез. Яңа юрта салып бирерләр, ашны хезмәтчеләр пешерер, киемне дә алар тегәр.

— Ә мин нишләрмен? — диде хатын ирнең күзләренә карап.

— Син баһадир хатыны, син боерык биреп кенә торырсың.

— Миңа асрау да, хезмәтчеләр дә кирәкми, Сүбәдәй. Ашны мин үзем дә пешерә алам. Анам менә дигән итеп кием тегә.

Сүбәдәй баһадир тагын мактанырга иткән иде, тыелып калды. Табигате белән ул мактанырга яратмый иде. Аннары хан сүзенә дә бик үк ышанып җитмәде. Чыңгыз ханның вәгъдәсендә тормаган чакларын да күп күрде ул. Хатын-кыз алдында буш куык булуны, гомумән, килештермәде.

— Кичер, мин болай гына. Мин үзем дә син пешергән ашны яратам,— дигән булды.

— Көнбатышка яу чабырга җыенасыз икән,— диде хатын, тулышып килгән корсагына халат итәген каплый төште.— Синнән башка табармыйнмы бу оланны?..

— Кем әйтте сиңа яу чабабыз дип?

— Бар да сөйли. Хан унбиштән алып, җитмеш яшькә хәтле ир-затны яуга алып китәргә әмер биргән, диләр.

— Бирде, хак. Ләкин без анда озак булмабыз...

— Авызың ачсаң — сүзең бер: орыш та кан кою, орыш та кан кою. Халыкны кырып, дала бушап калса, нә кылырсыз? Хан бу хакта уйлый микән?!

— Хан әйтә, мәлгуннәргә бөтен дөнья халкы буйсынырга тиеш, ди. Хан барыбер сүзендә торыр, Сөярсу. Чөнки аңа тәнре үзе фатиха биргән.

— Үзе шулай диме?

— Төптәнре. Ә ул алдан күрә белә.

— Килер бер вакыт, Сүбәдәем, төптәнре дә хан юртасына сыймый башлар әле. Шөһрәт, дан боза кешене... Йә, аша, асраулар килгәч, аш пешереп тә ашата алмам.

Урынга яткач, Сөярсу әйтеп куйды:

— Нигә бик ябыктың әле болай, Сүбәдәй, сөякләрең төртеп тора. Үзең ашыйсың да кебек.

— Сине сагынганга ул. Янымда ятасың, һаман сагынам, тансыклыйм. Китсәм нә кылырмын, күз алдыма китерергә дә куркам. Әмма мин синең янга барыбер кайтырмын, Сөярсу, мүкәләп булса да кайтырмын.

— Тәүбә диген, тиле. Тәнре сакласын. Күк йөзенә күз тидерүең бар. Әйтмә башка алай!

— Яуга китсәм дә мин сине бу черек киезле юртада калдырмам. Әйтте диярсең, Сөярсу.

Һәм калдырмады да. Китәргә өч көн калгач, хан аның гаиләсен яңа авылга күчерттерде. Хан әмере белән олы юрта тирәли уннан артык кече юрта куелган иде. Аларны җиде асрау кыз, ике көтүче, йөз баш куй каршы алды. Сүбәдәй баһадир юрталарны күрде дә, атыннан төшми авызын ачып, ни әйтергә белми торды.

— Болар барысы да миңамы? — дип сорады ул көтүчеләрнең берсеннән.

Җавап урынына көтүче аның аягына төште. Ул арада хан әмерен үтәгән Бүртәй атлы нойон килде һәм асрау кызларга, көтүчеләргә иягез шул булачак, моннан соң сез карусыз аңа буйсынасыз, хан боерыгы, диде.

Аннары Сүбәдәйгә борылды да:

— Арак бармы, әйдә берәр кәсә салыйк та мин китим, хан көтә,— дип беренче буып юртага кереп китте. Ә анда инде табын әзерләнгән, табын тулы ризык-нигъмәт иде. Алдан кергән Бүртәй бөкләнеп утырды да, бу хәлләргә ышанмый торган Сөярсуга:

— Табының, киленкәй, һәрчак шулай мул булсын! — диде.

Килен белән анасы бил бөгә-бөгә нойонга рәхмәт әйттеләр. Сүбәдәй нойонга арак салды, үзе күтәрде.

— Игелегеңне онытмам, Бүртәй нойон!

Бүртәй нойон чыгып киткәч, Сөярсу иренә килеп сыенды һәм тыенкы гына:

— Рәхмәт сиңа, Сүбәдәй,— диде.— Тик әйт әле, Сүбәдәй, нигә бу юрталар безгә син булмагач?

— Мин бит үләргә китмим, карлыгачым! — дип, иркәләгәндәй итте хатынны Сүбәдәй, әмма Сөярсу моны үзенчә аңлады.

— Сугыш үлемсез вә корбансыз булмый, Сүбәдәй. Анам әнә утыз яшендә ирсез калды. Миңа да шул язмыш килер микәнни?!

— Тынычлан, мин кайтырмын, Сөярсуым, менә күрерсең, кайтырмын. Хан илчеләрен үтергән Олуг Мөхәммәт дигән шаһтан гына үч алачак. Мин сиңа аннан тиңе булмаган затлы әйберләр төяп җибәрермен.

— Кирәкми миңа синең әйберләрең, кирәкми, Сүбәдәй!

— Әйдә алай булгач минем белән. Хан да әнә яшь хатынын ала.

— Мөртәт Дәян бай кызы кәнтәй Хуланнымы?

— Кәнтәй икән, кәнтәй Хуланны. Аннары Чыңгыз ханга сүз тидермәсәң иде. Хан безгә әнә нинди изгелек кылды.

— Муены асты-өскә килсә дә мин аңа каһәр укыячакмын, Сүбәдәем. Атамның башына да ул житүче.

— Туктал, Сөярсу! — Сүбәдәй сикереп торды, камчы сабын сындырып, аяк астына ташлады.— Туктал, Сөярсу, үтенәм! — диде.

Сөярсу дәшмәде, башын ия төште дә чаршау артына, анасы янына кереп китте. Сүбәдәй Сөярсуның анасына рәхмәтле иде, ул бервакытта да ир белән хатын арасына кермәде, кысылмады.

Хатыны аның янына чыкмады, ә иртән иртүк аны Чыңгыз хан чакыртып алды һәм яуга алып китте. Түмәннәрне озатырга килгән хатын-кыз, бала-чага, карт-коры арасыннан Сүбәдәй хатынын эзләде, тапмады. Атына атланып, тирә-юньне урап килде, очратмады Сөярсуын. Эзәңгесенә басып, халык арасыннан караштырды. Юк, күренмәде хатын. Шуннан соң атын камчылый-камчылый түмәнен куа китте.

Уянды ул кояш күтәрелгәч кенә. Юынды, ашады-эчте һәм туры абасы Җәбәй янына юнәлде.

— Мин бүгең орыш кырын сайларга китәм. Телиме, теләмиме дошман, без аның белән шунда очрашырга тиешбез,— диде ул яңа йокысыннан торып, ашап утырган абасына. Чаршау артында кемдер тамак кырды.

— Кем анда? — дип сорады Сүбәдәй.

— Шаһ кызы түгел, мин аны Гөмәй бәккә бирдем.

— Һаман кызлар белән мәшгульсең, абам. Хан нә дигән иде.

— Хан нә димәс. Аңа ярый, безгә ярамыймы! Бар юлыңда бул, кысылма минем шәхси эшемә. Бик батыр булсаң, орыш кырында һөнәрең күрсәтерсең, башкага сәләтең юктыр... шымчы кебек арттан йөрмәс идең... Аланнар безне барыбер моннан чыгармаслар...

— Сүзеңнең аты-башы юк. Ярамас иде алай. Без монда нинди максат белән килдек!..

Сүбәдәй баһадир тәгаен ачуланды, муенындагы кан тамырлары бүртенеп чыкты, әмма кабат сүз катмады, борылды да чыгып китте.

Абасыннан кайнарланып кайткан Сүбәдәй меңбашларын дәштерде һәм орыш кырын сайларга китте. Бик озак йөрделәр, ахыр тигез урын таптылар, әмма дошман бире килерме, аларның теләгән үтәрме, меңбашларның берәүсе дә әйтә алмады.

Сүбәдәй баһадир тирә-якка карап торды да:

— Без алар белән орышмыйбыз, без иртәгә үк кузгалабыз,— диде.— Хәрәкәттә бәрәкәт, дигәннәр. Туктатсалар — орышырбыз, туктатмыйлар икән, ары китәрбез...

Сүбәдәй баһадир торып атын иярләде, бавырчысы китергән бер кәсә кымыз эчте дә казылык кабып чәйни башлады. Шул чакта баһадир янына багучы сугышчы чаптырып килде.

— Баһадир, баһадир, дошман күренде, Карахан меңбаш орышка тезмәгә басты,— диде сугышчы сулышына кабып, әйтерсең лә ат өстендә түгел, үзе чабып килгән иде.— Илбакты меңбаш та орышка әзер.

— Дөңгер кагыгыз! — дип боерды Сүбәдәй.— Җайдак атларны калдырырга!

Җайдак ат йөртүне күчмә халыклар гасырлар буена кулланганнар. Бер аты арый, сугышчы икенче атына күчеп утыра, ә җайдак ат ял итә, аннары орыш кырында бер атның яраланып ятып калуы да бар иде, бу очракта да сугышчыны җайдак ат орыш кырыннан алып чыгачак. Шуның өчен күчмә халык сугышчысы өчен җайдак ат ул аның, гүя икенче гомере иде.

Гомумән, күчмә халык беркайчан да җәяү орышмаган, Сүбәдәй баһадир, күчмә халык вәкиле буларак, җәяү орышуның тактикасын да белми иде. Аның өчен атыннан егылган сугышчы — сугышчы түгел, сугыш кырында аттан егылган сугышчы үлгән кешегә тиң санала. Ләкин күчмә халык һәр орышка да җайдак ат белән кермәгән. Торыш-хәлгә карап, җайдак атларны ат караучыларга калдыру хәлләре дә булган. Сүбәдәй баһадир үз меңбашларына ошбу орышка җайдак атсыз барырга боерды. Һәм аның боерыгын карусыз үтәделәр.

Орыш башланды, алдынгы сафлар дошман белән бәрелеште һәм туп кебек тегесе дә, монысы да кире чиктеләр. Сүбәдәй баһадир Җәбәй нойон

белән Гөмәй бәк төмәннәренә орыш башларга вакыт дип ишарә ясады. Аның боерыгын сары әләм белән күрсәтеп торучы кишектинә әләмне уңга һәм сулга болгады — янә ике төмән һөҗүмгә кузгалды. Мәлгүннәрнең «Хүррә!» тавышыннан дала уянып киткәндәй итте, бөтен тереклек хәрәкәткә килде.

Орыш кичкә хәтле барды, бер як та алдыра алмады. Сүбәдәй баһадир каны кыза төшеп, үзе дә орышка чыккалады, ләкин бик тиз сайлаган калкулыгына кире әйләнеп кайтты. Бары тик караңгы төшә башлагач кына, Сүбәдәй баһадир орышны туктатырга, чигенергә боерды. Дошман да арыган иде, күрәсең, янадан һөҗүмгә ташланмады. Сүбәдәй баһадирның тәмам кәефе кырылды. Беркайчан да аның мондый хәлгә тарганы юк иде әле. Ул дошманны йә чигенергә мәҗбүр итәр, йә тулганага алыр, йә куа китәр иде. Ә монда бер адым да алга бара алмады. Дошман, чигенү генә түгел, хәтта кайбер төбәкләрдә мәлгүннәрне дә кысырыклый башлады.

Гаскәр тирәли сакчыларны куйгач, өч төмәнбаш та бер җиргә җыелды. Олаучылар янында корылган юртада бераз тынчу, һавада кан исе килеп тора кебек иде.

— Югалтулар шактый булды,— диде Гөмәй бәк.— Минем ике йөзгә якын сугышчым орыш кырында ятып калды.

— Миндә дә аз түгел югалту. Ләкин без хәзер дошманның көчен белдек. Дошман безне моннан чыгармаячак. Нә кылабыз?— диде Җәбәй нойон Юлай картасын уртага салып.

— Орышабыз,— диде Сүбәдәй баһадир.— Без аларны җиңәчәкбез.

— Аланнарны җиңгән дә булыр идек, кыпчаклар да килеп кушылгач, булмастыр. Оста орышалар, бездән бер дә ким сугышмыйлар.

Гөмәй бәк картаны тигезләде, әйткән сүзе ничегрәк тәэсир итте микән дип, Сүбәдәй баһадирга карады.

— Орышабыз,— диде Сүбәдәй баһадир.— Без аларны җиңәрбез. Җиңмәсәк тә бирешмәбез. Иртәгә тагын бер тапкыр бәхетне сынап карыйк.

— Орыш кырында бәхет сынамыйлар, Сүбәдәй,— диде ачуланыбрак Җәбәй абасы.

— Әллә соң кыпчакларга илчеләр җибәреп карыйкмы,— диде Гөмәй бәк нигәдер Җәбәй нойонга карап.— Минем төмәндә төркиләр бар, телләре бер. Аннары алар да, без дә күчмә халык, бер җайда көн күрәбез.

— Кыпчаклар аланнардан аерылып китсәләр, безгә юл ачылыр иде,— диде Җәбәй нойон.

— Аланнар безгә каршы тора алмаслар дисеңме?— дип сорады Җәбәй абасыннан Сүбәдәй.

— Мин күрдем аланнар ничек орыша. Тора алмаслар.

— Мин кыпчакларга илчебаш итеп Илбактыны җибәрәм. Ут-су кичкән кеше.

— Меңбашның кире әйләнеп кайтмавы бар,— диде Сүбәдәй.

— Аның орыш кырында да ятып калуы бар, Сүбәдәй баһадир.

— Иртәгә тагын орышып карыйк.

Җәбәй нойон белән Гөмәй бәк күзгә-күз карашып алдылар. Килешәбез дигәндәй, бер-берсенә аяк кактылар.

## 27

Дошман белән күзгә-күз очрашудан беркайчан да курыкмады Сүбәдәй баһадир. Күп орышларда ул, кылычын күтәреп, үзе алгы сафка чыгып һөҗүмгә ташланды. Ләкин тора-бара, бигрәк тә Сөярсуга әйләнгәч, аннан да битәр Күлкән улы тугач, Сүбәдәй кылыч күтәреп дошманга каршы бармый башлады. Элекке курку белмәс батырлыкларын истә тотыпмы, сугышчылар аңа ышаналар, аның боерыгын карусыз үтиләр

иде. Ничәмә тапкыр кыю унбашларын ул орышның иң кызган жирләренә өстерде. Орыш кырында корычка-корыч орынган, йомшак тәнне үтеп кергәннән соң «аһ!» дип кычкырып, иярдән авып төшкән сугышчыларны күрде ул. Атыннан төшеп кала алмыйча, аяклары өзәңгегә эләгеп, башсыз гәүдәләрнең сөйрәлеп барганын да күрергә язды аңа, күзләре мөлдерәп яшь белән тулган яралы атларның үлеп ятканнарын да аз күрмәде. Орыш кырында һәрчак кан исе килер, һавада явыз козгыннар очыныр иде.

Кояш төшкелеккә житкәндә аланнардан исән сугышчы калмаган иде инде. Кача алганнары качсалар да, меңләгән алан сугышчысы мәлгуннәр угыннан һәм кылычыннан үлемен үз аланнарында тапканнар иде.

Бу хәлдән соң айга якын ял иттеләр. Жәбәй абасы кызлар белән мавыкты, Сүбәдәй баһадир исә янә Сөярсуын сагына башлады. Кайчак ул үз-үзенә шакката. Нигә аның төшенә гелән Сөярсуы керә?

Талаган-җыйган затлы киемнәрне һәр нойон иленә озата торды, моның өчен махсус олаучылар булдырылган иде. Элемтә эшен, олы сәүдә юлларын Чыңгыз хан ышанычлы нойоннарына сакларга тапшырды. Жибәргән кием-салым, ихтимал, Сөярсуына барып та житмәс, житкән хәлдә дә Сөярсуның ул байлыкларга исе китмәс — аңа мал-байлык кирәкмәде. Сүбәдәе кирәкте... Бәлкем шуңа сагынадыр ул аны!

Шулай истәлекләргә бирелеп, ял итеп ятканда аның янына куллары чи каеш белән бәйләнгән бер сәүдәгәрне алып керделәр. Гадәттәгечә, Сүбәдәй бу сәүдәгәрне Жәбәй абасына жибәрергә иткән иде, нигәдер башта үзе сорау алырга булды. Кем белә, бәлкем Олуг Мөхәммәтнең кай тарафка олакканын беләдер.

— Кулларын чишегез! — диде ул боерып.— Утыр, сәүдәгәр.

Сәүдәгәр берни дә аңламады, тылмач чакыртырга туры килде.

Тылмач авызыннан шуны белде Сүбәдәй: сәүдәгәр Болгар дигән илдән, шунда кайтып бара икән, әмма Сүбәдәйнең сугышчылары аны эләктереп алганнар.

— Болгар иленнән мин, баһадир. Болгар иленнән. Иделкәй буенда ул ил, Иделкәй буенда.

Сүбәдәй баһадир Жәбәй абасындагы картаны китерергә кушты, картаны китергәч, сәүдәгәр алдына жәеп салды да, күрсәт илеңне, диде.

— Менә ул, менә, Иделнең аръягында, Жаекның бирьягында, Чулманның төп үзәгендә.

Ерак иде сәүдәгәр күрсәткән ил. Олуг Мөхәммәт алай ерак китмәс. Диңгезне кичү белән туктагандыр, дип уйлады Сүбәдәй.

— Син Олуг Мөхәммәт атлы шаһны беләсеңме, сәүдәгәр?

— Йа алла мөхәммәдресселулла, белми буламы? Мәмләкәт билгән кеше, Туран дөньясын кулында тотар иде. Аллаһы каһәре төшсен ул шаһка, муены асты-өскә килсен. Илен, халкын ташлап качты. Тиле беткән шаһ, язмыштан качып буламы...

— Сәүдәгәрнең байлыгы зурмы? — дип сорады кишектиненнән Сүбәдәй баһадир.

— Әллә ни түгел, биш дөясе, ун ише, ике кыз алып кайта иде.

— Сакчылары бар идеме?

— Илледән артык. Унысыннан артыгын сөңгегә алдык, орышып маташтылар.

— Калганнарын берәм-берәм унбашларга беркетегез! — дип боерды Сүбәдәй баһадир.

Күп тә үтми сәүдәгәрнең байлыгын юрта янына китерделәр, ике кызны эчкә алып керделәр. Сүбәдәй баһадир кызларга йөзләрен ачарга кушты, кызлар һични аңламый тордылар, ахыр бер кишектин кызларның башларына бөркәнгән шәлъяулыкларын тартып алды. Сәер хәл: хатын-кызның берсе төсе-йөзе белән генә түгел, хәтта гәүдә-сыны белән дә Сөярсуга охшаган иде. Сүбәдәй үз күзләренә үзе ышанмыйча, кызга карап торды, елмайды. Элек ул хатын-кызлар күргә, шундук Жәбәй

абасына озатыр иде, хәзер исә дәшмәде, ә кишектине әмер көтте. Моны сизеп, Сүбәдәй баһадир:

— Кызларны чаршау артына кертеп җибәр,— дип боерды.

— Кызларны каян алдың?— дип сорады Сүбәдәй сәүдәгәрдән.

— Языклы булдым, баһадир, языклы булдым, кичер мин бахырны, кичерә күр!

— Торгыз әле үзен,— диде Сүбәдәй. Кишектине йөзе белән баһадир алдына капланган сәүдәгәрне күтәреп аягына бастырды.

— Нинди товар алып кайта идең?

— Товар түгел, хан, бирнә, калым. Кызы Рабигага биргән шаһ бирнәсе.

Һични аңламыйча, Сүбәдәй тылмачка текәлде. Тылмач сәүдәгәрдән бик озак сорашты, шуннан соң гына Сүбәдәйгә аңлатты.

— Сәүдәгәрнең аты Ярулла, Болгар ханы угланына шаһ кызы Рабиганы алырга килгән. Кая карама — орыш-сугыш, тоткарланганнар, ахыр килеп сезнең кулга килеп капканнар.

— Шаһ кызы?! — дип чак кына сикереп тормады Сүбәдәй баһадир.— Кайсысы шаһ кызы?..

— Кечерәге, кечерәге. Тегесе караучысы, карачы кыз.

— Әнә ничек икән,— диде Сүбәдәй.— Димәк, бу сәүдәгәр Болгар ханы угланына килен алып кайта торган булган. Ә бит инде шаһ мәмләкәте безнең кулда, шаһ үзе юк. Бәлкем ул беләдер шаһның кая икәнен, йә булмаса кызы?..Тылмач сәүдәгәрдән Олуг Мөхәммәт турында сорады.

— Олуг Мөхәммәт Хәзәр дингезе аша качкан булырга тиеш. Без киткән идек инде, орышлар баргакда таулар арасында яшеренеп яттык,— диде сәүдәгәр Ярулла.

Сүбәдәй баһадир арлы-бирле йөренде, сакалына ябышып уйланып торды, чаршауны ачып, Сөярсуына охшаган кызга күз төшереп алды.

— Менә нәрсә сәүдәгәр,— диде ул ахыр килеп.— Мин синең олавыңны да, үзеңне дә җибәрәм. Тик бер шарт белән: кайту белән миңа чаптар җибәрәсең — шаһ сездә түгелме? Чаптарың килми икән, без әле синең белән очрашырбыз. Шаһ кызын да алып кит, ә менә карачысын алып калырмын. Амәнәт итеп. Йә, килештекме!? Карачы кызның аты ничек?

— Карачы кызның аты Карлыгач, хан.

— Мин сиңа хан түгел, мин баһадир,— диде Сүбәдәй.

Сәүдәгәр ашыга төшебрәк бил бөгә башлады, ул моны һич тә көтмәгән иде, хәтта Сүбәдәй баһадирның чапан чабуын үбәргә үрелде.

— Җибәрегез сәүдәгәрне, шаһ кызы да китсен. Карачы кыз миндә кала,— диде Сүбәдәй баһадир һәм гомерендә беренче тапкыр кишектиннәреннән оялды булса кирәк, колакларына кадәр кызарынып чыкты. Ләкин кылынасы кылынган иде инде, үкенмәде, киресенчә, шатлыгы эченә сыймады. Ниһаять, ул да Җәбәй абасы кебек юртасында кыз тотачак. Дөрес, өч-дүртне түгел, берне, ләкин бер булса да берәгәйләне: кыз аның иләндә калган Сөярсуына охшаган иде.

Шаһ кызына шәльяулыгын кайтарып бирделәр һәм сәүдәгәр Ярулла кызны җитәкләп алып чыгып китте. Шаһ кызы артыннан чыгарга иткән Карлыгачны Сүбәдәй тотып калды.

— Ә син калырсың,— диде ул аңа. Гаҗәп хәйран, кыз гүяки аны аңлады, чаршау артына кереп китте.

«Буйсынырга өйрәнгән, болай бик тиз риза булмас иде»,— дип уйлады Сүбәдәй баһадир, юртадагы кызны сакларга кушып, һавага чыкты. Тизрәк абасы янына барып, шатлыгын уртаклашасы килде. Җәбәй нойон юртасында иде, энесе килеп керүгә, түргә дәште, арак салып бирде.

— Уникe бәлеш[1] алтыным кыпчак ханына китте. Товар турында әйтеп тә тормыйм, ничәмә олау. Син хаклы булгансың, Сүбәдәй, без аларны барыбер җиңгән булыр идек.

— Мин дә унике бәлеш алтыным бирдем, Гөмәй бәк тә. Инде алтының, товар-малың бик кызганасың икән, без аны кире ала алырбыз.

— Ничек? — дип энесенең күзләренә текәлде Җәбәй нойон.

— Яу чабып. Кыпчаклар күчмә халык. Яз килде. Барысы да җәйләүләренә таралды. Җәйләү саен өч-дүрт меңбашны җибәрәсе дә биргән байлыкны бәлешләргә кадәр җыясы да аласы.

— Һә, баш та соң үзеңдә, энекәш. Ә бит бер уйлаганда бер дә булмастай хәл түгел!..

— Тик моны бик тиз тотарга кирәк,— диде Сүбәдәй.

## 28

Бер ай дигәндә җәйләүгә таралган кыпчаклар таланган, үзләре биргән бөтен байлыклары артыгы белән кайтарылган иде инде. Бу хәл тормышка ашкач, Җәбәй нойон ни кылырга да белмәде. Бөтен җыелган байлыкны олауларга төятте дә көчле каравыл куйды. Олауны, көтүләрне далада калдырдылар, сакчылар куйдылар, үзләре исә янә тирә-юньне таларга керештеләр. Ахыр кыпчак ханы Көнчак гаскәренә тап булдылар. Каты орыштан соң кыпчаклар кача башлады. Мәлгуннәр аларны Днепр елгасына кадәр куа бардылар һәм елга ярында туктап калдылар. Берәүләр, елганы кичик тә ары барыйк, диделәр, икенчеләре, борылыйк, дип теңкәгә тиделәр. Сүбәдәй баһадир бер якка да бер сүз дә әйтмәде. Ул әсир ителгән кыпчактан ары таба нинди илләр булуы турында сорашты һәм кич белән елганы кичик тә берара барып карыйк, дигән тәкъдим кертте.

Җәбәй белән Гөмәй аның белән килешмәделәр. Шунда туктап, атларын ял иттереп, аръякка багучылар җибәреп карарга кирәк, дигән нәтиҗәгә килделәр.

Багучылар өч көннән әйләнеп кайттылар, алда мәһабәт кала күрүләре турында әйттеләр. Бик озак киңәшкәч, ошбу кала кенәзенә илчеләр җибәрергә булдылар. Сылтавы да бар иде: кыпчак ханы Көнчакны үз араларына алганнар. Кияли кенәзе Мстислав Романович Көнчак ханны илчеләргә тотып биргәндә генә кире әйләнеп кайтачаклар иде. Ә алар юк та юк. Ләкин киткән илчеләр кире әйләнеп кайтмадылар. Сүбәдәй баһадир үз-үзенә урын табалмады, тагын бер көн көтте дә Җәбәй абасына килде.

— Җибәрик тагын ун кеше. Илчеләр башында үземнең Сөләй кишектинемне җибәрәм,— диде Сүбәдәй.

— Миннән дә биш кеше ал да җибәр. Әйтсеннәр: без сезгә орышырга һәм җирләрегезне яуларга дип килмәдек, без сезгә Көнчак ханны сорап килдек. Без беләбез, кыпчаклар сезгә күп зыян китергәннәр. Кушылыйк та, бергәләп сез бер яктан, без икенче яктан кыпчакларны кырып бетерик. Ни әйтәләр, шул булыр. Разый булмасалар, үзләренә үпкәләсеннәр. Калаларына кермәбез, яулаган далада җәйләмәбез, әмма орышмыйча да китмәбез.

Сүбәдәй баһадир абасына баш иде, аның белән килеште. Һәм яна көн туута илчеләрне елга аша чыгарып, Кияли каласына җибәрде.

Ике көн көтте Сүбәдәй баһадир илчеләрен, өч көн көтте, ахыр сабыры төкәнеп, янә абасы янына килде.

— Кайтмадылар илчеләр,— диде ул, юртага керүгә кишектиннән арак сорап алды.— Боларны да үтергән булсалар, нишләрбез?

Җәбәй абасы арак эчмәде, кымыз сорап алды.

---

[1] Бәлеш — алтын кисәге.

— Сугышчыларыбыз ял итә, атлар ял иткән, бер-беребездән ерак торабыз. Элемтә бар. Көтик, сабыр итик. Кайтырлар.

— Кайтмасалар, бөтенләй кайтмасалар дим?

— Кайтмасалар күз күрер, безне җинел генә ала алмаслар. Кыпчаклар белән урысларны бер-берсенә котыртып булмады дип уйла.

— Димәк, орышырга!

— Беренче тапкыр гына орышуын түгелдер бит?!

— Без бик ерак киттек, абам. Аннары безнең төп максат кыпчакларны куу түгел иде кебек...

— Бирелә җәйләүләр начармы?.. Бу далаларны хан күрсә, үзе калыр иде, йә синең белән миңа бирер иде. Яулаган Хәрәземшаһ җирләрен угланнарына өләште, сиңа, миңа ни?! Исән-имин әйләнеп кайтсак, бу җирләрне синең белән миңа бир дип, мин ханнан үзем сорармын.

Сүбәдәй баһадир яшел үлән белән капланган иксез-чиксез далага күз төшерде, бертын дәшми торды. Чынлап та, абасы әйткән чынга әверелсә?.. Ул хәзер үк монда калырга разы булыр иде. Янында Карлыгачы, киң дала, җәйлә, рәхәти кыл. Ләкин еракта-еракта томан эчендә Сөярсуы калды, ул нишләр анда?.. Әйе, ул аны онытмады, ул иленә әйләнеп кайтыр. Кайтыр да гаскәр туплар һәм Сөярсуын, һәм бөтен иш-кавемен алып бире килер. Карлыгач та янында булыр. Тора бит әле хан җидесигез хатын белән, ул да торыр.

— Мин китим,— диде Сүбәдәй баһадир.— Хәбәрләшеп торыйк.

— Урыс яу чыкса, башта Гөмәй бәк төмәненә ташланыр. Аннан ерак торма,— диде Җәбәй нойон, кит, дип кул селтәде.

Кулына Карлыгач төшкәч, Сүбәдәй баһадир да абасы Җәбәй һәм Гөмәй нойоннар кебек ыстан туктаган җирдә юрта куйдырта башлады. Кола айгырын юрта янына җитәрәк туктатты да, тезгенен иярга ташлап, җәяүләп юртасына юнәлде. Ишек янындагы кишектиннәре читкә тайпылдылар. Сүбәдәй япманы күтәреп, эчкә керде.

— Карлыгачым!

— Мин киенәм, иям,— диде Карлыгач чаршау артында.

Сүбәдәй аяк киемен салды, камчысын итекләре янына ташлады да түргә узып, мендәргә кырын төште.

Карлыгачны аның күргән саен күрәсе килеп тора башлады. Әле ул аны Сөярсуына охшатты, әле аның йөзендә бөтенләй башка кеше күрде.

Карлыгач чаршау артыннан чыкты, тыенкы гына елмайда һәм тынып калды. Кыз өстендә кыпчаклардан алган кызыл күлмәк, болгари итекләр иде. Күзләре ут кебек яна, юка иреннәрендә сәер елмаю, керфекләре калтыранып-калтыранып куя. Өске ирне җәя кебек дугаланып тора. Карашында нindидер курку да бар кебек, шул ук вакытта иреннәре нәүмизләнеп җәелергә торган сыман.

— Кил әле, тансыкладым үзеңне,— диде Сүбәдәй һәм Карлыгачка таба үрелде. Кыз тайпылмады, аңа таба да ымсынмады. Сүбәдәй аның үрелеп кулыннан тотты, янына утыртты.

— Син хәзер минем хатыным! Нигә битең каплыйсың.

Сүбәдәй баһадир кызның яулык чите белән каплаган йөзен ачты.

Карлыгач аның чапанын салдырды, түргә утыртты, чаршау артыннан бер касә кымыз салып китерде.

— Кымыз кем китерде?

— Бавырчың.

— Бавырчы!— дип кычкырды Сүбәдәй. Бавырчы керде, ишек янында туктады, баш иде.

— Моннан ары мин юкта минем юртага кермә.

— Баш өстем, баһадир.

— Ә хәзер миңа күп итеп кымыз китер. Шәбен, җиллесен!

Ул арада Карлыгач табын әзерләде, берсе артыннан берсе татлы ризыклар тезде.

Сүбәдәй бaһадир кымыз салды да эчте, салды да эчте, мәгәр кипкән җиләк-җимешкә бөтенләй кагылмады. Карлыгач аның каршына ризыкларны этәргәләп куйгалады.

— Күчермә минем янга, мин төче әйбер яратмыйм. Миңа казылык булсын, ит белән дөге. Карлыгач аны әзерли белә иде, аны пылау, диләр, Хәрәземдә торганда һәркөнне диярлек табында шул ризык булыр иде.

Ашап-эчкәч, Сүбәдәй бaһадир бавырчыны чакырып, табынны җыярга кушты. Аннары Карлыгачны янына чакырды.

— Кил, яңадан берәү дә кермәс. Син миннән курыкма.

— Мин синнән курыкмыйм,— диде Карлыгач.— Мин сиңа рәхмәтле. Шаһ кызын коткардың, ә ул ярәшелгән бала иде.

— Ул Болгарга китте, мин анда керермен. Син аны күрерсең.

— Анда керү кирәкмәс, Болгар бик ерак ил.

— Олуг Мөхәммәт Болгарга качкан, диләр. Мин аны табып, хан каршына алып кайтырга тиеш.

— Нигә сиңа ул шаһ?

— Шаһ үләргә тиеш. Хан кушты. Шунсыз аның иленә тынычлык килмәс. Шаһ гаиләсенә син каян килеп эләктең?

— Мине аңа сәүдәгәрләр сатты. Шаһ сатып алды. Соңыннан кызын карарга кушты. Карачы булып калдым. Синең сугышчыларың арасында минем якташларым да бар икән.

— Бар,— диде Сүбәдәй.— Кил инде. Ят. Курыкма дим миннән. Мин сине яраттым...

Сүбәдәй бaһадир кызны кочагына алды, талымсызланып, сөя-назлый башлады. Кызның сыгылмалы гәүдәсе тәненә елышуын тоюдан җаны эреп киткәндәй булды... Чалкан әйләнеп яткач, ул:

— Мин сине беркемгә дә бирмим, син минем хатыным,— диде.

Кыз дәшмәде, ул әсир кеше, иясенә карусыз буйсынырга тиеш. Бала чактан ук канына сеңгән шушы караш Карлыгачны чарасыз һәм язмышы белән килешергә мәҗбүр итәр иде. Сүбәдәйне яратмады ул, ярата да алмастыр, әмма бу хакта аңа әйтергә дә кыймады, әйтә дә алмастыр.

Иртәнге якта да илчеләр кайтмагач, Сүбәдәй бaһадир ашап-эчте дә Җәбәй абасы ыстанына китте. Ул килгәндә Гөмәй бәк анда утыра иде инде, алдында касә белән арак.

— Уз, утыр, Сүбәдәй,— диде аңа Җәбәй абасы.— Менә киңәшәбез әле. Нә кылыйк? Кыпчаклар белән урысларны талаштырып булмады. Хәзер аларның берләшеп, безгә ташланулары бар. Ә без төп ыстаннан шактый ерак киттек. Борылып китеп барыйк микән әллә дип утырабыз.

— Илчеләр кайтмыйча мин моннан беркая да китмим. Гөрҗи белән әрмәннәр дә берләшеп караганнар иде — җиңдек. Боларны да җиңәрбез. Калаларына кермәбез, әмма җиңми китмәбез дә. Калаларга керергә Чыңгыз хан кушмады.

— Туры сорнай син, Сүбәдәй,— диде абасы.— Чыңгыз хан да, Чыңгыз хан. Чаптарларыннан башка мин аның өч ел йөзен күргәнем юк инде.

— Ә без бу яктагы халыкны да белеп кайтырга тиешбез. Миңа ошый бу яклар, даласы, тугайлары, елгалары,— диде Сүбәдәй һәм үрелеп корт алды, авызына ташлады, иренчәк рәвештә чәйни башлады.

— Без урысларны алдый алмадык, хак,— диде Гөмәй бәк.— Аларның чынлап берләшеп куюлары бар. Кичә мин бер сәүдәгәрне туктаттым. Урыс. Киялигә кайта иде. Ул каланың диварлары биек, каланы ала алмассыз, диде.

— Ә мин калага керергә дә җыенмыйм, чыкканнарын көтәм. Тәннәрендә җаннары булса, түзмәсләр, чыгарлар. Иртәгә Гөмәй бәк Кияли каласы каршына барып ыстан туктар.

— Ярый, син дигәнчә булсын, Сүбәдәй,— диде Җәбәй нойон. Гөмәй бәк исә дәшмәде, ул гомумән агалы-энеле бу кешеләр арасында үзен ят тойды, аннары тел вә гореф-гадәтләре дә бер түгел, ул бөтенләй башка кавемнән иде. Аланнардан аерып, кыпчак ханнарын алдадылар, киялелә-

ргә килгәч, эшләр барып чыкмады. Чыңгыз хан дошманны алдауны «Яса»га ук керткән иде: «Мәлгун мәлгунне алдаган очракта аңа җәза бирергә, ә инде мәлгун дошманны алдый икән, изге хәлгә санарга».

Көнчак ханның киялиләргә килеп елышуы, житмәсә алар белән берләшүе Сүбәдәйнең җен ачуларын чыгарды. Чөнки аның күңеленнән бер мизгелгә шушы далаларның иясе булып, Кияли урысларыннан ясак җыеп яту хыялы туган иде. Бу хыялны аңа Җәбәй абасы бирде, рәхмәт аңа.

— Синең әсир иткән сәүдәгәрен кая соң? — дип сорады Гөмәй бәктән Сүбәдәй.— Мин айнан үзем сорау алыр идем.

— Ала күр, чакырт та сорау ал,— диде Гөмәй бәк, мина барыбер дигән кебек.

Күп тә үтми сәүдәгәр Микитаны юртага алып килделәр. Кызыл кафтанына төренә төшеп, баш ия-ия, бер жайдан чукына-чукына сәүдәгәр Микита төмәнбашлар каршына килеп басты.

— Кияли каласында нә атлы кенәз утыра? — дип сорады анардан Сүбәдәй һәм тылмачка текәлде, әйтерсең лә Микитаның ни әйтүе аны бөтенләй кызыксындырмый иде.

— Мстислав Романович. Олуг кенәз олы кеше инде. Горур вә тәкәббер, әмма туганнарын читләми, эшләренә дә бик тыкшынмый.

— Без сине кенәз алдына җибәрсәк?..

— Аллам сакласын, баһадир, мөмкин хәлме. Олуг кенәз мине кичермәс.

Сүбәдәй баһадир сәүдәгәр аяк астына бер янчык алтын ташлады. Сәүдәгәр янчыкны күтәрде дә уч төбендә сикертеп алды.

— Нә әйтергә тиеш инде мин олуг кенәзгә, баһадир? — Сәүдәгәр Җәбәй белән Гөмәйгә түгел, ни өчендер Сүбәдәйгә мөрәҗәгать итте. Аны барысыннан да өстенрәк күрде бугай. Һәм ялгышмады, нә Җәбәй, нә Гөмәй бәк сорауга кушылмадылар.

— Җибәргән илчеләрнең хәлен белеп кайт. Нә кылды алар белән кенәз? Калганы синең эш түгел. Әйләнеп кайтмыйсың икән, бөтен юлдашларың кылычтан уздырылыр, угланың да.

Сәүдәгәр Микита бу юлы Саксинга барганда үзе белән угланы Александрны да алган иде, уй-нияте изге иде, сәүдә һөнәренә өйрәнә торсын, юл газапларын үз күзе белән күрсен. Яңа унбиш язын тутырган Александр улы Гөмәй бәк кулында, угланны кишектиннәр күз карасыдай саклыйлар.

— Илчеләрнең язмышларын белеп әйләнеп кайтсаң, шуннан соң гына товарың һәм угланың белән юлыңда булырсың. Вәгъдә — иман! — диде Сүбәдәй баһадир.

Гөмәй бәк авызын ачып нидер әйтергә иткән иде, Сүбәдәй баһадир аны бүлдерде, кулын күтәрде.

— Мин риза, баһадир,— диде сәүдәгәр.

— Кайчан юлга чыгасың?

— Бүген ук.

— Көймәң бармы?

— Мине таныйлар, чыгып алырлар. Иншалла.

Сәүдәгәр Микита чукынып алды, тәпен-төпен артка чигә башлады.

— Болгар сәүдәгәрен дә шулай җибәргән идек,— диде Сүбәдәй баһадирның үзбаш хәл итүен ошатмыйча Гөмәй бәк. Ләкин аның иңенә Җәбәй нойон кулын куйды.

— Баш-аягы бер казан, китә бирсен. Кире әйләнеп кайтмаса, мин аның улын кулын-кулга, аягын-аякка бәйләп бүреләргә ташлаячакмын.

— Мин аргы якта алтын түбәле биек-биек биналар күрдем, халык мул яши булса кирәк, кенәзнең гаскәре дә аз түгелдер. Кенәзгә әйт, борнын чөймәсен, илчеләрне җибәрсен. Олуг кенәзнең туганы Митәй Үтәк Көнчак ханның кияве икән, ханны ул якласа да гаҗәп түгел, ә менә нигә кирәк олуг кенәзгә Көнчак хан, шул хакта сорарга онытма.



2

Сәүдәгәр баш ия-ия юртадан чыгып китте. Сүбәдәй кишектиннәренә сәүдәгәрне елгага хәтле озатырга, көймәгә утырып киткәнче, карап торырга кушты.

Киялинең олуг кенәзе Мстислав Романовичка җибәргән илчесе — сәүдәгәр Микита атна дигәндә генә аның юртасына килеп керде. Сүбәдәй баһадир тезендә утырган Карлыгачны чаршау артына кертеп җибәрде дә, ишектән керүгә туктап калган сәүдәгәргә текәлде. Ул аның һәр сырма төймәсен, һәр әгъзасын күздән кичерде. Сәүдәгәр туйга килгән кебек кара сакалын түгәрәкләп кыркыган иде, аягында яна итек, муенында тәре.

— Йә? — диде Сүбәдәй баһадир. Шулай диде дә янында тылмач булмавын искәреп, кишектине Хасдайга кычкырды.

— Хасдай, тылмач!

Күп тә үтми тылмач килеп керде, баш иеп исәнләште дә Сүбәдәйгә карады. Сүбәдәй сөйлә дип сәүдәгәргә ияк какты.

— Олуг кенәз Мстислав Романович беренче илчеләрне кылычтан уздырган, икенчеләрен суга батырып үтерткән, баһадир.

Сәүдәгәрнең бу сүзләре Сүбәдәйгә кинәт кенә барып җитмәде, барчасын да тылмач кабатлагач кына ул камчы сабын сындырып, Микитаның йөзенә ташлады.

— Югал күз алдымнан!

Сүбәдәй баһадир курыкмады, ул далада иде. Дала аныкы. Далада ул — кош, лачын, бер тапкыр да йөгән кигерелмәгән ат. Шул ук мәлдә ул үзен гомер буена дала буйлап чабып барган ат белән тиңләде. Ә бит нинди шәп ат булмасын, кайчан да булса ул да бер егылып үләчәк. Кола айгырга кадәр Сүбәдәй бик күп тулпарларның башына җитте. Ул хәтта янып егылган берничә атын күз алдына китерде. Башта ат каты итеп йөрәк кага башлар, аннары корсак астыннан касә-касә күбек тамарга тотыныр, шуннан күп тә бармый ат туктар, ыңгырашкандай кешнәп җибәрер һәм алгы аякларына тезләнер дә берьякка авып китәр, аякларын сузар, башын җиргә салыр да сыңар күзе белән күккә багар. Атның күзеннән яшь ага башлар... Ары таба Сүбәдәй баһадир үлеп яткан атларга карый алмас иде, ат бик авыр үлә, кеше якты дөньядан җиңелрәк китә, ди торган иде аңа атасы. Ул бик күп үлем күрде, ә үзе бер тапкыр да яраланып карамады. Аны орыш уртасына кергәндә дә тәңре саклады. Ә менә калган кешеләрнең гомерен ул берничә санамады. Шуның өчен кишектине Хасдайны чакырып алды да, сәүдәгәр Микитаны кылычтан уздырырга кушты, углы Александрны көймәгә утыртып аръякка чыгарып җибәрергә боерды. Сүбәдәй исәбе буенча, унбиш яшьлек Александр урысларга яман хәбәр җиткерергә тиеш. Аның Киялигә кайтуы кенәзне кызыксындырыр һәм кесәсеннән капчыкка салган үле елан табарлар. Калганын кенәз үзе дә аңлар. Димәк олуг кенәзне дә шундый ук үлем көтә. Кишектине Хасдайга шуларны кылырга кушкач, Сүбәдәй баһадир кола айгырына атланып, елга янына китте. Александрның аръякка чыгып җиткәнен, киялиләрнең тегене каршы алуларын, үз күзе белән күрәсе килә иде. Һәм барысы да ул уйлаганча булгач, кире юртасына әйләнеп кайтты, меңбашларын җыеп, хәрби уеннар башлады. Уеннардан соң аның башына янә бер уй килде. Ул тылмачын чакырып алды да, олуг кенәзгә хат язарга кушты.

«Без сезнең кала-кирмәннәрегезне яуламадык, хатын-кызларыгызны әсир итмәдек. Ә сез безнең илчеләрне кылычтан уздыргансыз. Сез безгә каршы яу чыгарсыз. Чыгыгыз. Тәңре кем ягында, шул җиңәр».

Икенче көнне Гөмәй бәкнең күчеп китүен белгәч, Сүбәдәй баһадир куанычыннан чак кына кычкырып җибәрмәде.

Ләкин кичкә таба бу куанычы, ачы кайгыга әйләнде. Гөмәй бәк гаскәре белән түбән таба төшә, ыстан туктый, юрта куйдырта һәм меңбашларына: «Ял итәбез»,— ди. Меңбашларның берничәсе сугышчыларын алып, тирә-якка таралалар. Авылларны таларга керешәләр, мал җыялар. Шул мәлдә урыс кенәзе Мстислав Удатный кыпчак ханы Көнчак

белән Гөмәй бәк ыстан туктаган җиргә һөҗүм итә, нойон янында калган сугышчыларны кырып, кача алганнарын таратып-сибеп, кызлар белән күңел ачып юртасында яткан Гөмәй бәкне әсир итә. Мәлгуннәргә җан ачуы каткан Көнчак Гөмәй бәй нойонны кылычтан уздыра.

Көтелмәгән бу хәбәрдән соң Сүбәдәй баһадир абасы Җәбәй нойонта чаба, тегенен дә гамьсез рәвештә кызлар белән күңел ачып ятуын күреп, эчке күлмәктән өч кыз арасында аунаган абасын эт урнына сүгеп ташлый, кызларны чәчеп-сибеп җибәрә дә тиз генә киенергә куша.

Иләсләнер дәрәҗәгә җитеп, акырынып-бакырынып юртасына килеп кергән энесенә абасының бер дә исе китмәде, яткан җиреннән мендәрләр арасына торып утырып:

— Ни булды, тилебәрән орлыгы ашадыңмы әллә?— диде.

Сүбәдәй баһадир абасының тынычлыгына шаккатты, әмма бераз сабырлана һәм:

— Гөмәй бәк нойон әсир төшкән, төмәнс тар-мар ителгән. Мстислав Удатный кенәз һөҗүм иткән, булган малларын, олауларын алып киткән.

— Нигә куа чыкмадың, җитәкләүне кулыңа алдың түгелме?— диде абасы. Торды, киемнәрен киде, ишек яры торган кишектиненә: — Юртаны җыегыз, олаулар тарафына кузгалабыз!— дип әмер бирде.

— Мин калыйммы?— диде тәмам үртәлеп Сүбәдәй баһадир.

— Теләсәң нишлә. Мин китәм.

## 29

Чакырылмаган «кунаклар»ны җиңү, нойон кадәр нойонны әсир итү, мал-туарын, байлыгын кулга төшерү, куштан кенәзләр арасында Мстислав Удатныйның дәрәҗәсен бермә-бер күтәрде. Хәтта Кияли кенәзе Мстислав Романович та аңа көнләп карады, башка кенәзләр турында әйтеп тә торасы юк.

Иртән олуг кенәз янына багучылары чаптырып кайтты.

— Олуг кенәз Мстислав Романович, алар качалар, качалар!— диде.

Әлегә кадәр икеләнебрәк торган Киев кенәзе Мстислав Романович мәлгуннәрне куа чыгарга әмер бирде. Өйлә тирәсендә елганы кичтеләр һәм мәлгуннәр артыннан куа киттеләр. Шактый юл үттеләр, атлар арыды, туктап ял итәргә булдылар. Шул чакта аларны кыпчак гаскәре куып җитте. Көнчак хан Гөмәй бәк нойонны әсир итеп, кылычын уздырганнан соң кинәнеп киткән, эрерәк сөйләшә, хәтта:

— Без алардан түгел, алар бездән кача хәзер!— дип мактанды.

Тәҗрибәле кеше буларак, Мстислав Романович дәшмәде, гомумән, ул мактануны яратмый һәм көтелмәгән дошман белән бик орышырга да теләми иде, күрәсең.

— Сезнең башка төшкән каһәр генә бу, Көнчак Көнчакович, аллаһы тәгалә җибәргәндер, әнә киттеләр дә,— диде кенәз.

— Иртәгә без аларны җитәрбез. Менә күрерсез, җитәрбез...

— Бирсен ходай,— диде кенәз.

Берничә көннән чынлап та мәлгуннәр күренде.

— Качмыйлар да, китәргә дә җыенмыйлар. Орышырга исәпләре,— диде олуг кенәз һәм калкурак җир сайлап, үзенең дружинасы өчен кирмән кебек корылма ясарга боерды. Яшь кенәз Удатный моны күрде дә:

— Далага кем кирмән кора инде, карт шайтан,— дип китеп барды.

Кенәз Удатный кебек, Көнчак хан да олуг кенәз Мстислав Романовичның борынгы скифләр сыман тәртә башларын бәйләп, казыклар утыртып, кала коруын ошатмады.

— Әллә кышларга исәбе инде бу Мстислав Романовичның,— диде Көнчак хан киявенә. Мстислав Удатный — Көнчак ханның кияве иде һәм алар яуга да бергә керергә булдылар.

— Киялиләр — кала кортлары, казык какмыйча аш та ашый алмыйлар,— диган булды кенәз Удатный бабасын куәтләп.

Моны ишеткән Мстислав Романович яшь кенәзнең әтәчләнүен ошатмады, ат башын сыйпый-сыйпый:

— Кем калыр, кем җиңәр, ходай хәл итәр,— диде.

— Мәлгуннәр безне көтәләр,— диде Көнчак хан.

— Бүген ял итсеннәр инде, иртәгә без аларны дала төлкеләренә ашарга калдырырбыз,— диде кенәз Удатный һәм өзәңгегә аягын куеп, очып диярлек ат өстенә менде.— Их, киттек моннан. Калсын кирмәнен саклап.

— Китә бир, ярпач,— диде олуг кенәз Мстислав Романович.— Китә бир. Авызың пешкәч, килерсең әле.

* * *

Кенәз Мстислав Удатный, бабасы Көнчак кебек, башын ияргә куеп кына йоклап алды. Ул бик иртә уянды. Үләнгә мул булып чык төшкән, күк йөзе аяз иде. Баш очында козгыннар очына. «Кай арада сизәләр»,— дип уйлады кенәз һәм мәлгуннәр ягына багып торган бабасы Көнчак ханга карады. Соңгы елларда гына тәвәккәл кушамат алган кенәз сикереп торды, быргычысына быргы кычкыртырга кушты. Күп тә үтми, аннан-моннан капкалап алган сугышчылар дружина-дружина булып кенәз кул астына җыелдылар. Көнчак хан үз гаскәрен сул канатка куйды. Ул арада багучы сугышчы кенәзгә:

— Мәлгуннәр сугышка әзерләр,— дип килеп әйтте.

Тәвәккәл кенәз Мстислав Удатный Кияли кенәзе Мстислав Романович кирмән корган калкулыкка күз ташлап алды. Анда бернинди дә хәрәкәт юк иде. «Димәк, олуг кенәз бергә орышырга теләми»,— дип уйлады кенәз. Киявенең нидер уйлавын күреп, Көнчак хан:

— Олуг кенәзнең дружинасын көтикме әллә?— диде.

— Ә ул орышырга дип килмәгән, арба тәртәләре аша безнең сугышканны күзәтмәкче. Күзәтсен, йөзенә оят килмәсә. Җиңгән хәлдә мал бүлешергә килер әле. Киттек. Аллага тапшырдык!

Мәлгуннәр таралып басканнар иде. Мстислав Удатный кенәз кылычын суырып чыгарды.

— Туганнар, ур-ра!

Кенәз Удатный дружинасы мәлгуннәрнең сафын җәя тартылгандай ерып керде. Сул яктан Көнчак хан һөҗүм итте. Уң яктан Даниил кенәз дружинасы дошманны кысырыклый башлады. Тузан купты, атлар кешнәде, очлымнар кояшта ялтырап алды, шул ялтырап алган яктылык эчендә кеше гомерләре өзелде, иртәнге чык төшкән үләнгә кайнар кан акты. Кычкыру, акыру вә бакыру, иярдән егылып төшүләр, ат өзәңгесенә эләгеп сөйрәлеп барулар, яшен чыбыркысы кебек кояшта ялтырап киткән кылыч йөзләре — барысы да буталды, тоташ мәхшәргә әверелде. Кенәзнең кыю сугышчылары мәлгуннәрне куа башладылар, ләкин тегеләр шундук кире борылдылар, кенәз дружинасын тулганага алдылар. Уртада калган кенәз батырлары белән тулганы ерып чыкты һәм олуг кенәзгә чаптарын җибәрде. Ә үзе өстәмә сугышчыларын алып янә орышка ташланды. Мәлгуннәр кенәзнең куәтен күреп, янә кача башладылар. Кенәз аларны куа китте, укка алды, кул җиткәннәрен кылыч белән чапты. Кинәт ул янә тулганага калуын сизде, борылды, сугышчыларын тулганаи ерырга чакырды. Көтмәгәндә мәлгуннәр өстәмә гаскәр керттеләр.

Беренче булып уң як канаттагы Даниил кенәз җитәкләгән гаскәриләре кача башлады. Күп тә үтми Көнчак хан сугышчылары тарала-сибелә чигенергә тотындылар. Тәвәккәл кенәз Удатный орыша-орыша батыр сугышчылары белән Кәлтә елгасына таба чигенде. Ул каты яраланды,

алай да аты белән елганы кичте һәм бары тик берничә йөз сугышчысы белән кача башлады. Аларны мәлгуннәр зур елгага кадәр куа бардылар.

Орыш барышында янә бер нәрсәне искәрде Сүбәдәй баһадир: урыслар каты сугышалар, бу якларга яңадан килергә булса, ике-өч төмән белән генә килмәскә.

Атна буена ял иттеләр, урысларның коралларын, киемнәрен җыйдылар. Кичү чыгаручы Плоскиня аларга олаулар табып бирде. Дала буш дисә дә, буш түгел иде, анда-санда күчмә халык җәйли, сәүдәгәрләр үтеп-сүтеп тора. Сүбәдәй аларның кайберләрен туктатты, кайберләренә тимәде, Чыңгыз хан, гомумән, сәүдәгәрләргә кагылырга кушмаган иде.

Атна үткәч, Җәбәй нойон энесе юртасына килде. Сирәк була торган хәл, абасы аңа килми торган иде. Сүбәдәй аны ачык йөз белән каршы алды, янында утырган авырлы Карлыгачны куып җибәрде, абасына түрдән урын күрсәтте. Бавырчы табын хәстәрләде, арак куйды.

— Эч әйдә! — диде Сүбәдәй касәсен күтәреп.

— Юк, эчмим,— диде Җәбәй абасы,— кәеф юк.

— Без җиңдек, дала безнеке, абам. Син котыртучы түгелме?..

— Миңа берни дә кирәкми. Илгә юнәлик, хан көтәдер.

— Мин ханга чаптар җибәрдем. Кыпчак-урыслардан гаскәр туплаган була, кылыйммы шуны, дип әйттем. Чаптар кайтып житсен, шуннан кузгалырбыз. Аннары безнең Болгарга кирәсебез бар. Олуг Мөхәммәт анда булырга тиеш.

— Җыйган малыңның исәбе-хисабы юк, һәр сугышчыда олау — минем яңадан сугышасым килми.

— Чыгып киткәндә ханга ни дип вәгъдә бирдек. Кайткач йөзебезгә төкермәсме?

— Төкермәс. Мин арыдым. Өч ел чит далаларда иза чигәбез.

— Мин арымадыммы? Ярты сугышчым орыш кырында ятып калды. Хан ризалык бирсә, мин башта сугышчылар җыячакмын. Аннары гына Болгарга кузгалырбыз.

— Ал Гөмәй бәк төмәнен, нишләптер миңа килеп кушылдылар. Минем аларны күрәсем дә килми. Минем, гомумән, орышасым килми! Китик бу яман илдән, Сүбәдәй, тәңре хакына...

Сүбәдәй баһадир касәсен куйды, камчысын кулына алды.

— Җәбәй нойон,— диде ул камчысын селкә-селкә.— Онытмасаң иде: нойон дәрәҗәсен кем бирде сиңа!? Хан, Чыңгыз хан! Һәм ул безгә ни диде: хәрәземшаһны тотмый кайтмагыз, диде.

— Кая соң ул шаһ?!

— Болгарда, Болгар ханында.

— Нинди Болгар ул тагын! Кемнең булганы бар анда?! Без икебезгә иге-чиге булмаган дала яуладык, тагын сиңа ни кирәк?!

— Болгар кая дисең,— диде Сүбәдәй, ак киез өстенә Юләй сызып биргән картаны җәйде.— Менә ул Болгар, менә! Юл өстендә диярлек. Сиңа билгеле булса кирәк, абам, без инде килгән юлдан кире кайта алмаячакбыз. Ул җирләр безнеке инде. Ә шаһ Болгарда, эчем сизә — Болгарда. Болгар сәүдәгәре Ярүкәй шаһ кызын Болгарга алып китте. Олуг Мөхәммәт йә кызын алдан җибәргән, йә үзе киткән. Ни генә булмасын, без аны табарбыз. Үле икән, мин аның башын кисеп булса да хан алдына кайтарып салырмын!

— Шаһ кызын тапсаң нишләрсең?

— Шаһ кызын. Туймадың кызлардан. Сиңа бирермен...

— Карлыгачны яраттың, ахрысы,— диде абасы, ниһаять, күзләрен күтәреп карады, чаршау артына күз ташлап алды.— Авырлы икән...

— Мин аңа өйләндем дип сана, абам. Карлыгач — минем хатыным.

— Минем Күрәлән буйларына кайтасым килә, туганый. Хан анда Гөлстанда кымыз чөмереп, кызлар өстендә аунап ята, без аның өчен ниндидер ахмак шаһны илләр буенча куып йөрибез. Кем ул хәтле Чың-

гыз?.. Оныттыңмыни кем камыт киген килеш атабызның алачыгында күрек тартты. Тимерҗан иде, күккә ашты. Чыңгыз булды.

Бу юлы Сүбәдәй баһадир дәшмәде. Абасы хаклы иде. Кем иде Чыңгыз хан. Белмәгән кеше булса бер хәл, алар аны беләләр. Бер кояш астында үстеләр. Аннары Сүбәдәй дә бөтенләй таш йөрәк түгел, ул да Күрәлән буйларын, сары әрем үскән далаларын сагына. Ә Сөярсуын, үзе юк чакта туган Күлкәнен... исенә төшерсә, бәгыре пәрә-пәрә теленә, йөрәге кысылып куя.

— Түзик, чаптар кайтсын. Кыпчак-урыстан гаскәр җыярга рөхсәт иткән булса, Болгарга керәбез. Итмәгән булса, менә бу кечек диңгез кырыннан хан янына кайтырбыз. Аннары күтәргә исәбеме безне, юкмы — ул нәрсә дә ачыкланыр.

— Кендек әби эзлә,— диде абасы һәм шул сүзе белән Сүбәдәйнең күңелен эретеп җибәрде.— Телисеңме үзем табып бирәм.

— Рәхмәт кылырым, тап. Карлыгач чынлап та тиздән бала табар.

* * *

— Кендек әбиме әллә? — дип сорады Сүбәдәй баһадир.

— Үзе,— диделәр кишектиннәр һәм чаптырып китеп тә бардылар.

Карчык җор телле булды, иң әүвәл ул Карлыгач белән танышты, шуннан соң гына Сүбәдәй янына чыгып:

— Баһадир, үзеңә бер юрта куйдыртсаң иде,— диде.

Сүбәдәй аны шундук аңлады, икенче көнне үк кишектиннәренә Карлыгач юртасы белән янәшә юрта куйдыртты. Сүбәдәй баһадир Болгар иле турында күп уйланды. Сәүдәгәрләрнең, Болгар илендә елгаларыннан сөт ага, ярларында кесәл җитешә, диюләре, башкаласы тиңсез зур, базарлары кәттә, дигән хәбәр ала торгач, абасына килеп, камчы сабы белән итек кунычына суга-суга:

— Абам, без Болгарга юнәләбез, аерылганны аю ашар, диләр, калмассың, шәт? — диде.

— Сиңа Болгар байлыгы кирәкме, әллә булмаса Олуг Мөхәммәтме?.. Миңа тегесе дә, монысы да кирәкми, Сүбәдәй. Гарык, түйдым.

— Якшы, мин сине тыңладым, хәзер син мине тыңла. Болгар белән орышмабыз. Бары тик ханга шарт куярбыз: мең алтынга булса да шаһны безгә биреп җибәрсен.

Җәбәй нойон энесенә күтәрелеп карады, яткан җиреннән торып, табындагы чүлмәктән бер касә кымыз салып эчте, әмма нигәдер энесенә тәкъдим итмәде.

— Олуг Мөхәммәт... Болгар ханы, кем диделәр әле сәүдәгәрләр, әйе, Илһам хан, алтынга алданып сиңа бирер дисеңме ул шаһны?.. Ул хәзер аның кодасы.

— Хәрәземшаһ вафат, Сүбәдәй, юкка кымырҗып йөрмә.

— Кем әйтте?

— Бер Болгар сәүдәгәре.

— Син аны җибәрдеңме?

Җәбәй нойон энесенә авыз чите белән елмаебрак карап алды.

— Чыңгыз хан сәүдәгәрләргә кагылырга кушмады бугай. Аннары ул миңа минем өчен гаять дәрәҗәдә житди вә мөһим булган сөенче китерде. Мин аңа тимәдем генә түгел, үзем ике бәлеш алтын бирдем.

— Күптән киттеме сәүдәгәр?

— Өч-дүрт көн булыр. Куып житәргә исәбең юктыр бит? Мин анардан сиңа кендек әби алып калдым. Куанасы ит.

Башта ул сикереп торып, сәүдәгәр артыннан кишектиннәрен җибәрергә иткән иде, утыра-уйлана торгач, бу ниятеннән кире кайтты. Нигә? Олуг Мөхәммәт чынлап та вафат булган булса, аларның бурычы бермә-

бер жиңеләя. Чыңгыз хан шаһның йә үзен, йә... башын алып кайт димәде кебек...

— Сәүдәгәр сине алдаган булса?

Җәбәй абасы тизләнеп утырды, кымыз чүлмәгенә үрелде, әмма чүлмәктә кымыз калмаган иде.

— Алдаган булса да, минем өчен сөенечле хәбәр. Аннары нигә соң әле ул мине алдасын, ди. Кем мин аңа? Мин аңардан, беләсең килсә, шаһ хакында гомумән сорамадым. Ул үзе әйтте. Димәк, дөрес. Житте, безне хан көтә, иртәгә үк аның янына юнәләбез.

— Ә Болгар иле, шаһ кызы?! — диде Сүбәдәй.— Шаһ кызына өйләнсәң, Җүси хан сиңа үз биләмәсеннән өлеш чыгарыр иде.

— Шаһ кызы Болгарда дип уйлыйсыңмы син?

— Ә кай тарафта булсын, мин аны үз кулым белән Болгар сәүдәгәренә биреп җибәрдем ич. Тиккә кан коярга теләмәсә, Болгар ханы безгә ул кызны бәлешсез дә биреп җибәрер.

— Карлыгачың биреп китәргә әллә исәбең?

— Карлыгачны да бирмим, шаһ кызын да сиңа алып бирәм,— диде Сүбәдәй баһадир тәвәккәл төстә торып басты.

— Яхшы, мин риза. Кайчан кузгалабыз?

— Тиздән. Мөхәммәт шаһның үлемен белгәч тә. Сәүдәгәр сиңа аны Хәзәр диңгезенең бер утравында вафат дип әйткән, мин анда кишектиннәрем җибәрәм. Тагын кем дә булса расласын. Шуннан соң кузгалырбыз.

Җәбәй нойон дәшмәде, ул тәңрегә ышана иде. Чыңгыз хан Хәрәземшаһка яу чыкканда изге тауга менем, өч көн тәңредән игелек сораган иде.

## 30

Бары тик тояш баегач кына, Сүбәдәй гаскәре инеш буена килеп житте. Сүбәдәй баһадир ыстан туктарга боерды һәм ике көпчәкле кибеттә барган Карлыгач арбасы янына килеп, япманы ачып карады.

— Хәлләр ничек, убырлы карчык? — дип сорады ул кендек әбидән, чөнки Карлыгачның тулгагы тота башлаган иде инде.

— Кодрәтең житсә, ярдәм ит, борчыма хатының,— диде карчык коры гына.

Кендек әби дә Карлыгач белән беренче көндә үк аның телендә сөйләшә башлады. Аннары Сүбәдәй баһадир үзе дә бу телне аңлау белән бергә, сөйләшергә дә өйрәнеп килә. Әйтик, такы-токы булса да Карлыгач белән аңлаша башлады. Иң мөһиме, Карлыгач — аны, ул — Карлыгачны аңлый. Кендек әби ни ул, кендек әби килер дә китәр, ә менә аңа Карлыгач белән яшисе, аннары аңа күпмедер вакыттан соң барыбер бире таба төянеп киләсе. Сәере шул иде, ул очраткан кыпчаклар да, хәзәрләр дә, угызлар да, уйгырлар да, кыргызлар да, болгарлар да, гаскәрләренә килеп эләккән берничә башкорт та бер-берсен аңлыйлар, бер телдә сөйләшәләр иде. Сүбәдәй баһадир бу халыкка өйрәнә башлады, күпләренә аларның туган телендә дәште. Кыпчак-урыс кулыннан һәлак булган Гөмәй бәк, әйтик, чыгышы белән угыз иде. Гәрчә Чыңгыз ханның тугрылыклы бәге булса да, Сүбәдәй аны якын итә алмады, әмма соңга таба хаталануын аңлады — Гөмәй бәк җиһангир булган. Чыңгыз хан ялгышмаган булып чыкты. Алар юнәлгән болгарларны да төрки халык, диләр. Сүбәдәй баһадир кайчак аптырый кала иде. Ничек инде бер диңгездән икенче диңгезгә кадәр таралган халык арасында бердәмлек юк?..

Торды, бавырчы ашарга керТте. Ләкин Сүбәдәй баһадир башын чайкады, бүген аның каз каны көне иде.

— Казлар азайды ич,— дигән булды бавырчы.

— Анысы синең эш түгел, бир миңа каз каны!

Каз каныи эчкәч, Сүбәдәй баһадир күрше юртадагы Карлыгач янына кереп чыкты. Ләкин япманы ачып керүе булды, кендек әби аны яңә куып диярлек чыгарды.

— Ярамый, ярамый дидем түгелме мин сиңа!

Сүбәдәй баһадир, гадәттәгечә, кендек әбине элеп ыргытырга иткән иде, Карлыгачның чаршау артында улап җибәргүен ишетеп, тиз генә чыгып китте. Атын чакырып алды да атланып, абасы янына юнәлде. Абасының кишектиннәре аны туктатмакчы иттеләр, әмма Сүбәдәй кишектиннәргә буйсына торган кеше идеме, ул аларга камчы сабын гына күтәрде, янәсе шым булыгыз! Юртаның япмасын ачты, күзе ияләнгәнче дәшмәде. Күзе ияләшүгә, абасының анадан тума шәрә кыз белән ятуын күрде дә, ачкан авызын яба алмый торды. Кылган чәчле бортчы Плоскиня табып биргән кыз абасының муеныннан кочаклаган да күкрәгенә башын куеп яткан, әллә йоклый, әллә абасын иркәли?.. Сүбәдәй кире чыгып китәргә дә, тамак кырырга да белми катып калды. Бу хәл бермәлгә генә шулай булды. Аны күрепме, кыз, алиһәдәй гүзәллеген яшермичә, чалкан төште, тулы күкрәкләрен: «Мә, кара»,— дигәндәй аңа төбәде. Сүбәдәй баһадир тәпен-тәпен артка чикте, япманы ачып тышка чыкты. Уң ягында да, сул ягында да кишектиннәр басып тора, Сүбәдәй баһадир әле берсенә, әле икенчесенә карады да:

— Бу кызны да Плоскиня китердеме? — дип сорады.

— Ул булмыйча. Бортчы[1] бәлеш җыя. Нойоннан унлап бәлеш сорып алды инде. Бу җиденче кыз. Нойон үзе туйгач, безгә сата. Бусысы бигрәк чибәр инде, баһадир,— диде өлкәнрәк кишектин һәм тамак кырып, мыекларын сыпырып куйды.

Баш бортчы ыстанына баһадир кадәр баһадир чабып килүен күреп, чатырыннан чыгып аны каршы алды. Сүбәдәй баһадир кишектиннәренә, чатырга якын килмәгез, дип камчысын күтәрде.

— Рәхим ит, баһадир, рәхим ит!

— Башта чатырыңа алып кер, сиңа йомышым бар,— диде Сүбәдәй һәм башын ия төшеп, чатырга алдан үзе кереп китте.

— Нә йомыш, баһадир? — диде аңа артыннан кергән бортчы.

— Син, син кирәк, Плюскәй,— диде Сүбәдәй баһадир һәм тамак төбе белән кеткелдәп көлеп алды.

Плоскиня баһадирның аягына төште.

— Тор! — диде баһадир.— Тор, тор! Мин сиңа яман ният белән килмәдем.

— Кунакка? — диде Плоскиня аягүрә басып.

— Телисең икән, кунакка.

Плоскиня артына әйләнми генә:

— Табын! — дип кычкырды.

Плоскиня кунакка төрдән урын күрсәтте. Ул арада табын хәстәрләделәр, калын-калын итеп дуңгыз мае кистеләр, ипи китерделәр. Сүбәдәй баһадир ипине алды, учына кысты, аннары авызына капты, иренеп кенә чәйни башлады. Шаһ илендә җәйпәк ипи пешерәләр, ипине ул анда ашарга өйрәнде, ә менә табын тутырып торган кабартманы күргәне юк иде әле.

— Ә син аны, баһадир, дуңгыз мае белән, дуңгыз мае белән, май тозланган курыкма, берни дә булмас.

— Эчеп куй әле шуны, баһадир.

Сүбәдәй баһадир ишек яры басып торган Хасдайга карады.

— Башта минем кишектингә салып бир,— диде Сүбәдәй. Ул утырмый, ул басып тора.

— Хуш, басып торсын. Менә монысын сез эчегез.

Плоскиня чүмечне тутырып, баһадирга бал салып бирде. Берне эчте Сүбәдәй, икене, өчне һәм әгъзаларына йомшак кына ою тарала башлавын тоеп, иснәп куйды. Ләкин йомышын онытмады.

— Тиздән Кара Иделгә җитәбез, Плюскәй, шулаймы?

— Ике көнлек юл калды, баһадир. Бик акырын барабыз бит.

---

[1] Бортчы — кичү чыгаручылар.

— Минем ашыгыр жаем юк. Күпме телим, шулай барам. Дала минеке,— диде исерә башлаган Сүбәдәй.

— Синеке, синеке, баһадир.— диде Плоскиня.— Синеке, баһадир. Тик, баһадир, Болгарга кагылабыз дисәгез, бераз елга буйлап өскә таба күтәрелергә туры килер. Бу тирәдәге кичүләргә өмет юк, тирән, кин бирелә елга.

— Кирәк икән, менәрбез. Хәзер әйт. Абама кызларны син каян табасың?

— Сәүдәгәрләр саталар, баһадир, сәүдәгәрләр. Мин бит жиде юл өстендә торам. Моннан Кияүкалага, Новгородка, Румның үзенә сәүдәгәрләр уза. Гарәп-фарсы илләре турында әйтеп тә торасы юк.

— Димәк, уңай урын?— дип сорады.

— Бик уңай, бик уңай, баһадир.

— Мин монда килгәч, сине үз кешем итәрмен.

Сүбәдәй баһадирның тел төбен аңламаган Плоскиня чукынып алды һәм:

— Тагын монда килергә исәпмени әле, баһадир?— дип соравын сизми дә калды.

— Бу минем жир,— дип жибәрде Сүбәдәй баһадир.— Бөтен дала минеке булачак, елгалар да, кичү чыгаручылар да.

— Һә,— диде Плоскиня ни әйтергә белми аптырап.— Һә, нә кушканы булыр, барысы да алла кулында.

— Алла да минем кулымда,— диде Сүбәдәй.

— Йа алла, синең кулыңда икән, синең кулыңда була күрсен.

— Абама матур кыз саткансың,— диде Сүбәдәй.

— Йа алла, йа хода, кызны аны сиңа да табам, баһадир.

— Миңа кыз кирәкми, минем Карлыгачым бар,— диде Сүбәдәй.

— Карлыгачны тота алырсыңмы икән соң, бик яман оча бит ул кош, баһадир.

— Мин тотмаган кош юк!— диде Сүбәдәй баһадир бала башы хәтле йодрыгын Плоскиняның борнысы янына ук китереп.— Менә бу кулдан кош түгел, син дә ычкына алмассың. Ә жыйган бәләшләреңне кире кайтар, абамнан алганнарын. Мин биргәнен калдыр, гадел хезмәт иттең. Ә менә кызлар сатып абамнан алган бәләшләрне!.. Хасдай!.. Ал кичү чыгаручыдан абам биргән алтыннарны! Ал, ал! Ничәне бирде ул сиңа?

— Жидене, жиде алтын бәләш.

Плоскиня чаршау артына кереп китте, бераздан бер янчык тотып чыкты һәм Сүбәдәй баһадирга бирде.

— Мә, баһадир. Игелегең онытмам.

— Онытма да, оныттаң — башың кисәрмен. Юк, мин сине үзем кылычтан уздырырмын. Беләсеңме мин ничек кешеләрне кылычтан уздырам, кешене бер чабуда ике итәм, бер чабуда!

— Бар соң икән әле, ходаем, бар соң икән,— дип чукына-чукына Плоскиня чакырылмаган кунакларын озата чыкты.

Карлыгач юртасына кереп барганда кишектине дәште. Сүбәдәй борылып карады. Кишектине янында карсак гәүдәле бер адәм басып тора иде.

— Мин бавырчы таптым, Кончак ханның үзен ашаткан,— диде кишектин.

— Кончак ханны?!— дип аптырабрак сорады Сүбәдәй.

— Үзе теләп килде, бу якның иң оста бавырчысы, дип мактана.

— Бавырчыга илтеп бир, эшкә керешсен,— диде Сүбәдәй баһадир һәм юртаның япмасын күтәреп, эчкәре керде.

— Карлыгач, жанкисәгем,— диде ул ачык чаршау эчендә яткан Карлыгачны күргә.— Миңа малай табып бирдең?

— Малай таптым, Сүбәдәй. Тик хәлем юк. Ничәмә көн иза чиктем, үләм дип торам...

Хатын елмаерга итте, әмма аскы ирене калтыранып китте, күзләре мөлдерәп яшь белән тулды.

— Елама, шатланасы ит, исән калдың. Син минем хатыным,— диде Сүбәдәй һаман бер сүзне кабатлап һәм беренче тапкыр бугай: «Ә соң ул миңа үзе теләп кияүгә чыктымы?» — дип уйлап куйды. Сүбәдәй хатынның кулына кагылды, юка бармакларын дәү учына алып, кыскандай итте. Карлыгач баланың битен ачты, Сүбәдәйнең яңа туган баланы беренче тапкыр күрүе иде, ни сәбәплеедер: «Бияләй хәтле генә үзе»,— дигәндәй, лепкәсенә кагылды. Кай ягы беләндер ул баланы үзенә охшатты. Аның артында торган кендек әби:

— Балага кагылма, сырхау китерүең бар,— диде.

Сүбәдәй аңа таба әйләнеп тә карамый юртадан чыгып китте. Нияте олыдан иде — Карлыгачның малай табу куанычыннан табын уздырырга. Абасын чакырыр, кайбер меңбашларны. Карлыгачтан чыккач, ул атын дәшеп алды да сугышчылары хәрби уеннар башкарган инеш буендагы болынга юнәлде. Биредә укчылар, сөңгечеләр, ыргакчылар бер-берсе белән алышалар, арырак кылычы кылыччыга каршы тора. Сүбәдәй баһадир укчылар янына тукталды. Мәргәннәргә бертын дәшми генә карап торды, арада шундаен оста мәргәннәр бар иде ки, кайберләренә көнләшеп карады. Ул еш кына уктан алучылар уенында үзе дә катнашыр иде, ләкин бүген бер атна сырхаулап яткангамы, күзәтеп кенә торды. Чаптырып Хасдай килеп туктады.

— Йә? — диде Сүбәдәй баһадир.— Нәрсә телең йоттың?..

— Әмерең үтәлде, баһадир.

— Телисеңме, Хасдай, мин сиңа бер кыз сатып алам. Абамда бер гүзәл күрдем.

Баһадирының бу сүзенә гомер аның янында йөргән Хасдай күзләрен акайтты, бертын ачкан авызын ябалмый торды. Ни әйтергә белмәвеннән иде, чөнки баһадир беркайчан да аның белән хатын-кыз турында сөйләшмәде. Авырып ятканнан соң баһадирны гелән алыштырып куйганнар сыман иде. Хасдайның югалып калуын күреп, Сүбәдәй баһадир:

— Карлыгач малай тапкан, шул куанычтан,— диде.— Йә, нигә телең йоттың? Алып кайтыйммы үзеңә кылган чәчле кызны?..

— Соң, баһадирым, абаңа ярагач, мина да ярар иде ул. Тик белмим, бирер микән ул сиңа аны. Кишектиннәре, кызның кочагыннан да чыкмый, диделәр.

* * *

Тылмач аңа күптән хезмәт итә иде инде. Ул аны Үргәнечтән үк үзе белән йөртә. Тылмач өч-дүрт тел белә, култык астында һәрчак китап булыр, жор телле, белмәгәне юк.

Эчкә керделәр. Сүбәдәй ишек янында калды, тылмачны түргәрәк этеп җибәрде.

— Карчыкның аты ничек? — дип сорады ул тылмачтан.

— Мин синең телең беләм, атым Бүдәнә,— диде карчык үзе.

— Карчык, телем белгәч, син чыгып китеп тор,— диде тылмачка Сүбәдәй.— Йә, карчык, нә бәягә сатасың малайны? Бала кая соң әле?

Чаршау артында ниндидер хәрәкәт булып алды, зәгыйфь кенә тавыш чыкты.

— Бала имә, Сүбәдәй,— диде Карлыгач.

Сүбәдәй баһадир карчыкка карады.

— Бүдәнә кош түгелме соң? Бу татар халкы хатын-кызына гел кош исеме куша икән.

— Хатын-кыз кошка тиң,— диде карчык.— Кияүгә чыкты исә, туган иленнән чит-ят җирләргә оча.

— Йә-йә, карчык, авызың томала. Баланы төреп бир дә...

— Мин нәрсә өстендә утырам, баһадир?

— Сандык өстендә.

— Сандык буш булса, малаең шәрә йөрер, гомеренә хәер сорашыр, ди.

— Хасдай! — дип кычкырды Сүбәдәй.— Сандыкны кием-салым белән тутырып китер. Затлы әйберләр булсын. Карчыкка җилән, кара шәл, тун. Тиздән кыш җитәр, олы кеше, кигән саен Сүбәдәйне исенә төшерсен.

— Татарларны кырып, үз кавемегезгә кушып бетердегез дә, изгелек кыласың,— диде карчык.

— Хак, кырып бетердек. Корал тотканнарын. Ә калганнары безнең белән. Исеңә төшерим, карчык, ханның ике хатыны татардыр, апалы-сеңелле.

— Кырып бетерә алмадыгыз. Биш йөз гаилә котылдык.

— Тый теленне, карчык, ханга тел тидермә. Телең кисеп этка ташлармын. Мин сиңа бүген изге ният белән килдем, башка вакытта бу сүзләрең әйткән булсаң кул-аягын бәйләп дала этләренә ташлаткан булыр идем. Сезне Чин императоры алдады, кавемегез белән ханга сатты. Сездән котылды. Чыңгыз ханга килеп капты. Күк йөзе алласы да ялгыша икән.

Чаршау артында тамак кырдылар, карчык эчкәре керде. Ул арада ике кишектин сандыкны күтәреп керделәр, юрта уртасына куйдылар.

— Ач сандыгын! — диде чаршау артыннан чыккан карчык. Аның кулында чүпрәккә төргән бала иде.

Сүбәдәй сандыкны ачты, иң өстә яткан җиләнне, кара шәлне карчыкка алып бирде, карчык, куеп тор, дип баш какты. Аннары янә чаршау артына кереп китте. Аннан ул ачык итеп:

— Чык, булачак батыр, якын кешең янчык китергән,— диде.

— Якын кешең яттыр, йөргән малы аттыр,— диде Сүбәдәй.

— Чык, батырым, атаң сандык китергән.

— Сандыгын сатсын, кылычын алып кайтсын.

— Чык, батырым, кылычың так биленә.

— Кылычым тактым, угым аттым, җәям тарттым.

— Чык, батырым, атаң килгән, сине күргән!

— Буем-сыным олпаттыр, тулпар атын сораттыр.

— Чык, батырым, тулпар атың тупылдый.

— Тулпар атка атланып, яуга чабар шатланып.

— Чыкты батыр далага, аты батыр агага. Мә атасы, ал балаң!

Карчык баланы Сүбәдәйгә бирде дә чаршау артына узды.

— Син минем хатыным,— диде чаршау артындагы Карлыгачка Сүбәдәй бик күп тапкырлар әйткән сүзен кабатлап.— Син минем иң яраткан хатыным, Карлыгач!..

Карлыгач дәшмәде, чөнки ул әсир ителгән хатын иде. Ул үзен елгага эләккән язгы боз хәлендә тойды. Кай тарафларга ага, нигә болай озак ага да ага? Килер бер көн, елга аны үзендә эретер һәм аның үзен түгел, исемен дә онытырлар. Сүбәдәйне яраттымы ул, белми, белмәс тә, иң мөһиме — аның баласы бар иде, куанычы, бәхете шул бала булыр.

Кендек әби баланы чыгып алды. Сүбәдәй баһадир Карлыгачның йөзенә кагылды да чыгып китте. Әйтер сүзен әйткән иде инде ул. Хәстәрләнгән табынга утырмыйча күрше юртада меңбашлары көтә иде. Хәзер алар баланың тәпиен юарга керешәчәкләр.

* * *

Бу хәл Сүбәдәй юртасында булмаган чакта кылынды. Кояш яңа гына күтәрелеп килә иде, йөзләгән кишектине белән Җәбәй нойон Хасдайның юртасын уратып алды. Юрта япмасы янында ике сакчы тора иде, Җәбәй нойон аларны икесен ике якка селкеп ташлап, атылып эчкә керде,

чаршауны тартып ачты һәм кылган чәчле кыз белән Хасдайны күрде дә камчысы белән әүвәл Хасдайга, аннары кызга сыдырды. Хасдайны урыннан гүя җил алды, кызны анадан тума шәрә килеш култык астына кыстырды да юртадан алып чыкты, ияренә аркылы ташлады, өзәңгесенә аягын куйды.

— Мин сине кылычтан уздырам, ахмак! — дип җикеренде ул.

Шулчак аның янында Сүбәдәй баһадир пәйда булды.

— Абам,— диде ул тыныч кына.— Мин ул кызны аңа үзем бирдем.

Җәбәй авыз эченнән генә сүгенеп алды, лачт итеп Сүбәдәй ягына төкерде.

— Кит юлымнан!

— Бу кызны янында күрсә, шаһ кызы сиңа кияүгә чыкмаячак! — диде Сүбәдәй.

— Нәстә! — дип җикерде Җәбәй.— Нәрсә?!

— Хасдай аңа өйләнде, сиңа биш бөлеш алтын бирә.

— Шушы «балык» өченме? Биш алтын бөлеш?!

— Хасдай аңа өйләнә. Күп тә үтмәс, без Болгарда булырбыз. Шаһ кызы турында онытма, абам!.. Биш бөлеш аз алтын түгел.

— Чыгып алсын, бөлешләрен чыгарсын да, чәчбине чыгып алсын.

Юртадан чыгып килгән Хасдай күренде, аның кулында күн янчык иде, ул сүзсез генә Җәбәй кулына янчыкны тоттырды да һуштан язып дәрәҗәдә иярдә яткан кызны күтәреп, юртасына алып кереп китте.

Җәбәй нойон һичкемгә карамый сикереп атына атланды, чаптырып китеп барды.

Сүбәдәй баһадир әкерен генә үз юртасына юнәлде. Керде дә түрдәге түшәккә ятты. Төрбә тишегеннән зәңгәр һава күренә, талымсызланып йөрәк кага иде.

Сүбәдәй баһадир пошаманга калды. Абасының ниндидер бер кыз өчен кишектине Хасдай белән бәхәскә керүе, җитмәсә камчы белән сугуы, ул гынамы, ишләре алдында мыскыл итүе нойон кешегә килешмәстәй хәл иде. Ул юртасыннан чыкты, атына дәште, атланды да абасы ыстанына чапты. Кишектиннәре ияргәннәр иде, аларга, калыгыз дип, камчысын селтәде. Абасы ыстанына җитәрәк атын тыя төште, бавырчылар аш хәзерлиләр, мал суючылар таганга асып, сарык туныйлар иде. Сүбәдәй баһадирны күргәч, җитмәсә кишектиннәреннән башка, алар барысы да эшләреннән бүленеп аңа карап тора башладылар.

Сүбәдәй табын янына утырды, әмма ризыкка үрелмәде. Табында буы чыгып торган ит тора иде.

— Син мине кичер,— диде ул абасына карамый гына.

— Син нәрсә әле, тутый кош кебек киендең? — диде Җәбәй абасы энесенең сүзләрен ишетмәгәнгә сабышып.— Килешми. Син баһадир кеше. Кыпчак ханы булырга исәбең юктыр ич?..

— Юкка рәнҗемә, абам. Тиздән син дә кыпчак киеменә күчәрсең. Җиңел, затлы, ипле, уңай. Кораллары да җай. Кылычлары белән селтәнгән саен селтәнәсе килә. Менә бу хәнҗәрнең сабын гына кара, ничекләр елан башын ясаганнар. Ә менә ук-җәяләре сыек. Мин болай уйлыйм, абам, сугышчыларыма кыпчак коралларын өләшергә. Корал сугышчыда булырга тиеш.

— Кыпчак-урыс коралы миндә дә унлап олау. Ләкин моны эшләргә ярамас, Сүбәдәй. Без мәлгүннәр, без үз коралыбыз белән җиңә килдек дошманны.

— Мин алай дип уйламыйм. Камил корал орыша, ир мактана, диләр.

— Кыпчак катының малай тапкач, бөтенләй үзгәрдең әле син, Сүбәдәй. Житеш, аша. Арак саласың килсә, арак сал, кымыз да бар. Нигә кишектиннәрең иярмәдең, Хасдаеңны...

— Хасдай яшь хатын белән мәшгуль. Кичер син аны, абам. Ул гаепле түгел, мин. Мин алып кайттым синең кызың аңа. Җае бар. Ханнан тиз арада әмер алып кайтты. Плюскәй сиңа тагын кыз табар.

— Плюскәйгә тимә,— диде Җәбәй нойон турая төшеп утырды.— Плюскәй безне кичүдән чыгарачак. Мин аңа ышанам. Аннары ул миңа Болгарга кермәскә киңәш итте.

— Әнә ничек икән,— диде Сүбәдәй.— Әнә кем котырта икән сине.

— Нигә миңа шаһ кызы? Үзең уйлап кара, мин кем дә, шаһ кызы кем?.. Аны миннән барыбер хан тартып алыр.

Сүбәдәй баһадир торып басты, итек кунычына камчысы белән суккалап торды-торды да:

— Кишектиннәрең ал да китә бир, түмәнең миндә калыр,— диде. Ул бу сүзләрен шулкадәр үз-үзенә ышанып әйтте ки, Җәбәй нойон сикереп торып ук басты.

— Хакың юк, Сүбәдәй, хакың юк!

— Хакың юк,— диде кинаялап Сүбәдәй.— Синең кызлар белән көнтөн юртада аунарга хакың бармы?! Меңбашларына шарт куям, синеңчә дә, минемчә дә булмасын: керергә телиләрме Болгарга? Керәбез дип әйтәләр икән, үзең генә китәсең.

— Мин ничек аннан соң хан күзенә кайтып күренем! Туганмы син миңа, юкмы?!

— Туган. Ләкин синең кебек куркак туганым булганчы... Әйтәм бит, мин Болгар ханына илчеләрем җибәрермен, шарт куярмын. Тора-сала орышырга тотынмабыз.

— Әрмән-гөрҗиләрнең туган җирләре түгел идеме, урыс-кыпчакның... Без аларны җиңдек, җиңдек!

— Кызма әле. Үзең уйлап кара, бездә хәзер байлыкның исәбе-хисабы юк. Шушы олау белән Болгарга кер, имеш. Мин сәүдәгәрләргә ышанып җитмим.

— Барып җитәрәк илчеләр җибәрерсез. Аннары мин ничәмә кешемне сәүдәгәрләргә ияртеп җибәрдем.

— Илчеләр җибәреп карадык түгелме соң инде. Үч — үчкә китерә. Никадәр сугышчы югалттык.

— Үч — үчкә илтми, үч акылга утырта. Мин Болгар ханы белән орышырга җыенмыйм. Мин аңа шарт куярмын. Ахмак булмаса, ул килешер, килешми хәле юк. Иртәгә иртән кузгалабыз. Хуш!

* * *

Сүбәдәй баһадир абасыннан йөрәге кабарып чыгып китте. Нә эшләде абасы, ни булды үзенә?.. Үлемнән курка башлады. Ә бит Олуг Мөхәммәт җирендә орышканда ук яңгыры астына ташланган чаклары булды.

Кайтып юртасына керүгә, тәүге кайгысын гүя җил алды, юрта уртасында Карлыгачы басып тора иде.

— Сине көтә,— диде хатын.— Сагынды катын.

Моңа кадәр хатын-кызның аңа шулай ягымлы вә үз итеп дәшкәне юк иде әле, хәтта Сөярсу да аңа бер тапкыр да сагындым дип әйтмәде. Сүбәдәй итекләрен салды да Карлыгачны кулына күтәрде, зырылдатып, юрта буйлап йөртте.

— Бик шаулама, баланы уятасың,— диде Карлыгач.— Яңа гына йокыга китте. Акырды-акырды да арыды, ахрысы.

— Нигә акырды?

— Анысын инде, Сүбәдәй, үскәчрәк сорарбыз. Нигә жылады микән? Миңа калса, ул сине чакырды, ә син юртаңда юк.

— Ач өстен, бер күзем белән генә булса да күрим үзен.

— Кара аны, күз тидерә күрмә.

— Минем күзем каты түгел. Йә, Карлыгач, исемен ничек кушабыз инде?

— Син атасы, син куш,— диде хатын.

— Ташбай булсын, таштай каты бәгырьле булып үссен.

— Каты бәгырьле булмасын. Ташбай дип исем кушарга телисең икән, Ташбай булсын. Мин аңа иртәгә үк Ташбай дип дәшә башлармын. Чишен ят, ял ит, иртәгә юл чыгасыз икән, минем шаһинәм...

— Мин сине ярата,— диде ул хатын теләндә, ничек тә аны бу уеннан бүлдерергә теләп.— Ә шаһинәң күрәсең килсә, күрерсең. Хәер, мин аны үзем синең янына алып китермен...

—Кирәкми, Сүбәдәй, ул анда кияүдә, минем кебек балага узгандыр, кирәкми аны иреннән аеру. Мине синнән аерсалар, нишләр идең?..

— Син минем хатыным, Карлыгач.

— Синең тагын бер хатының бар.

— Бар, Карлыгач, еракта-еракта, ә син минем янәшәмдә. Мин синең белән бәхетле. Малай табып бирдең. Малайны үз кулымнан алдым, исем куштык,— диде Сүбәдәй һәм: «Сөярсу да малай тапкан, зурдыр инде ул малай»,— дияce килгән иде, тыелып калды.— Чыңгыз ханның да ике хатыны татар. Чибәрләр, гүзәлләр. Син алардан да чибәр.

— Син ул хакта миңа күп тапкырлар әйттең инде. Кайту белән барыбер Сөярсуыңа китәрсең.

— Мин синең белән бәхетле, Карлыгач. Югалткан бүрекне табып була, югалткан бәхетне — юк. Минем сине югалтасым килми.

* * *

Иртәнге һава салкынча иде. Карлыгач бавырчы керткән шулпаны табакларга бүлде, Сүбәдәй каршына кисәк-кисәк ит куйды, кесәгә кымыз салды.

— Аша, Сүбәдәй, аша, көч җый.

Ишек япмасын Хасдай ачты, керде, исәнләште.

— Утыр табынга,— диде аңа Сүбәдәй.— Ашап алыйк, сүзең соңыннан әйтерсең.

Хасдай сырмасын тез астына кыстырып, табынга утырды. Карлыгач аңа да шулпа салды, түтәрәме белән ит куйды, касәгә кымыз койды.

— Эшләр яман, Сүбәдәй баһадир,— диде Хасдай ит кимерә-кимерә.— Бүген төнлә өч олау юкка чыккан.

— Сакчылар нә караган,— диде Сүбәдәй мәсьәләнең асылына төшенүдән битәр, ишеткән хәбәрне аңлап житкермәстән.— Сакчылар нә диләр? Сәүдәгәрләргә сатып җибәргәннәрдер әле.

— Сәүдәгәрләргә саткан булсалар, сакчылар исән булырлар иде. Ике сакчы үтерелгән. Хәнҗәр ярасы. Сакчылар тавыш та ишетмәдек, кычкыручы да булмады, диләр.

— Борын асларыннан олау кадәр олауны алып киткәннәр, ә алар күрмәгәннәр, ишетмәгәннәр, имеш!

Шуннан нәтиҗә, баһадир, олауларны сәүдәгәрләр алып китмәгән, ягъни сакчылар олауларны сәүдәгәрләргә сатмаганнар.

— Ярый, ачыкларбыз,— диде Сүбәдәй авыз-борнын сөртә-сөртә торды, итекләрен киде, аннары Хасдайга ияреп юртадан чыкты, атына дәште, аты килгәч, сикереп атланды һәм кишектиннәрен күздән кичерде, янә: «Кем бүген төнлә минем юрта янында сакта торды?» — дип сорарга иткән иде, тыелды, сорамады, ат корсагына итек үкчәсе белән төртеп, кузгалып китте.

— Йоклап ятасың,— диде аңа маскыллы-сабыр рәвештә баһадир.— Өч олавың алып киткәннәр. Ни төялгән иде олауларга?

— Кораллар, баһадир, кораллар,— диде ашыгыбрак яңа исенә килгән олаучы.— Ләкин минем олауларым исән-сау, тәңре саклады.

— Синеке исән,— диде Сүбәдәй һәм аның яныннан кузгалып китте.— Кемнәр барды олауларны эзләргә?!

— Без, баһадир, без,— диештеләр унлап сакчы һәм йөгереп килеп Сүбәдәй алдына бастылар.

Сүбәдәй баһадир һәр сакчыны да күздән кичерде дә, Хасдайга карады.

— Нә кыласың үзләре белән?

— Янадан эзләргә җибәрәм, тапмыйча кайтмасыннар.

— Башта камчы тәмен татысыннар. Унар камчы үзләренә. Аннары эзләргә китсеннәр,— диде Сүбәдәй.

Хасдай артында басып торучы кишектиннәренә ияк какты, тегеләр атларыннан төшеп, ун сакчыны арба көпчәкләренә бәйләделәр һәм шәрә артларына унар камчы сыптырдылар. Сакчылар кызарып чыккан артларын ыштаннары белән каплый-каплый атларына таба чаптылар.

— Томан таралу белән ике йөзбашыңны артларыннан җибәр, арбага канат куеп булмый, очыртып алып китмәгәннәрдер. Үзләре саткан булсалар... үзең беләсәң нишләргә, кире ыстанга кайтмасыннар.

Кишектиннәр башы Хасдай шул хакта җиткергәч, Сүбәдәй баһадир бик озак дәшми торды, шуннан соң гына:

— Өч арба нәрсә ул, бүген-иртәгә Болгарга кузгалабыз. Буш кайтмабыз.

— Товар түгел, ул арбаларда кораллар иде,— диде Хасдай. Әмма Сүбәдәй баһадир гүя аны ишетмәде дә, Болгардагы биһисап байлык турында сөйләргә керешге. Ахыр килеп:

— Болгарны яуласак, безнең һәрберебездә өчәр арба байлык булачак,— диде.

— Баһадир хаклы!— дип кычкырды меңбашлар.

Икенче көнне иртән-иртүк юрталарны җыйдылар, озын-озак кыланмыйча гына юл чыктылар. Гаскәриләр алдан китте, алар артыннан олау кузгалды, аларга көтү тагылды. Шулчак Сүбәдәй баһадир янына Хасдай чаптырып килде.

— Нә булды, меңбаш?— дип сорады Сүбәдәй баһадир кичәге хәл кабатланмагае дип Тәңрене исенә төшерде.— Нә булды, нигә телең йоттың?

Хасдай Карлыгач белән кендек әби утырган япмалы арбага күз ташлап алды, шуннан соң гына:

— Күңелсез хәбәр, баһадир, тагын өч арба юкка чыккан, унлап сакчы үтерелгән.

— Олаучылар, олаучылар исән калганмы?

— Олаучыларны да алып киткәннәр, сакчыларның гына мәетләрен таптык.

Сүбәдәй баһадир меңбашына бер сүз әйтмәде, атын камчылый-камчылый алдан кузгалган абасын куа китте, кишектиннәре аңа ияэде. Сүбәдәй баһадир Җәбәй абасын куып җитте, аның кызлар арасында шаһ түшәгендә ятуын күреп, арбачыга туктарга кушты.

— Төш әле, абай, сөйләшәсе бар.

— Шуннан гына әйтеп булмыймы. Минем йокым килә. Төне буена җыендык, яңа юл кузгалдык,— диде Җәбәй һәм авызын зур итеп ачып, иснәп куйды.

— Тагын өч арба юкка чыга, унбиш сакчы үтерелгән. Иң гаҗәбе арба эзләрен табалмыйбыз.

— Димәк, Тәңре шулай кушкан, Тәңре күккә ашырган,— диде Җәбәй, иренеп кенә өс-башына киде, арбадан төште, кишектине китергән атка атланды.

— Без Болгарга таба барабыз. Шулаймы?

— Шулай,— диде Сүбәдәй баһадир абасының ни әйтергә теләвен аңларга тырышып.

— Арба-олауларны болгарлар урлый. Табигый хәл. Гаскәр чит-ят җирдә хәрәкәт итә, син дә шулай итәр идең. Шулаймы?

— Кичә өч олау, бүген тагын...

— Әйберләрең кызганасыңмы?.. Без аларны кемнән таладык соң? Әрмән-гөрҗиләрдән, кыпчаклардан, урыслардан...

— Сакчылар арасында Чыңгыз ханның кардәше Чәчә Бәкәй дә бар иде. Җиде баласы юртада утырып калды.

— Кем аңа җиде бала белән яу чыгарга рөхсәт бирде? Минме, синме?.. Чыңгыз хан. Шулай булгач, синең дә, минем дә гаебем юктыр. Чәчә Бәкәй баеп кайтырга теләгән иде, кул астына унлап арба товар җыйды, нәфес дигән нәрсә. Сүбәдәй, кеше башына түгел, ат башына да җитә. Арбаларны эзләргә җибәрдеңме соң?

— Юк, җибәрмәдем. Әйтәм бит тегеләрен дә тапмадык. Җирмени бу! Урман-чокыр, елга-инеш, күл-сазлык. Нииндидер каһәрле җир бу!..

— Ә мин сиңа нә дидем. Кермик Болгарга димәдемме?! Хәзер соң инде. Ә арбаларны барыбер эзләргә туры килер, тирә-якны әйләнеп кайтсыннар. Хикмәт табуда түгел, хикмәт дошманнан курыкмауда. Арбаларын эзләргә җибәрмәсәң, дошманның бездән курка дип уйлавы бар. Нишләмәк кирәк, без Болгар җирендә, бирегә сәүдә итәргә килмәдек, ил яуларга килдек! Әллә соң Болгар базарына кереп, булган товарларың сатып кайтырга исәбеңме?..

— Куй әле, абам.

— Бар кит, якын-тирәне үзең урап кайт. Бер генә кеше очратсаң да миңа тотып китер. Үзең белән минем уң кулым Чиләби меңбашны ал. Без Болгар җирендә, шул хакта онытма!

— Арбаларны караклар урламаган дип уйлавыңмы әллә?

— Миңа калса, Сүбәдәй, безгә каршы Болгар ханы сугыш башлады инде. Бүген олауга һөҗүм итсә, иртәгә гаскәре белән килер. Тизрәк Кара Идел дигәннәренә житәсе иде,— диде Җәбәй нойон.

— Анда ни?

— Ни булсын, атаң башы. Кара Иделне кичүгә, дала башлана...

— Ә-ә,— диде Сүбәдәй баһадир абасын аңлагандай.

— Безне хәзер дала коткарса, коткара, Сүбәдәй.— Җәбәй нойон алга таба ияк какты.— Әнә күрәсеңме кем бара алда?.. Плюскәй. Менә кем безне коткарачак...

— Мин берәүдән дә курыкмыйм, абам. Багучыларым елгага кадәр кешесез калган авыллардан башка бернинди гаскәргә дә тап булмадылар. Багучыларым беркөнлек юлны алдан күзәтеп бара һәм миңа хәбәр итә торалар.

— Барыбер каты орыш булыр, Сүбәдәй. Болгар ханы хәзер Олуг Мөхәммәтнең кодасы. Анннары, беләсең булса кирәк, аларның телләре дә, диннәре дә бердер. Димәк, бертуганнар.

— Олуг Мөхәммәт вафат, үлгән.

— Кеше үлә, аты кала. Олуг Мөхәммәтне үзебез Болгарга кудык...

— Мин киттем,— диде Сүбәдәй абасының нотыгын ошатмыйча.— Мин дошманнан курыкмыйм. Без аларны җиңәрбез.

— Дала булса икән,— дип көрсенеп куйды Сүбәдәй белән янәшә барган Чиләби меңбаш.

— Дала күчеп йөрми, меңбаш Чиләби. Без күчеп йөрибез. Сугышчы, әгәр ул батыр сугышчы икән, һәр җиргә җайлашырга тиеш. Кара Идел елгасына бер көнлек юл калды, диде багучылар. Димәк, тиздән без дә дошман белән күзгә-күз очрашырбыз. Орыш урынын сайларбыз. Беренче орышуыбыз гына түгел, җайлашырбыз. Хасдай! — дип кычкырды Сүбәдәй баһадир.— Бире кил әле. Әрвахларга житкер, бүген ялга туктамыйбыз, төнлә дә хәрәкәт итәбез. Боерыгым абама да житкер, кичү чыгаручы Плюскәягә дә. Арбаларны төнлә урлыйлар иде, урламый торсыннар әле.

Меңбаш Хасдай һәммәсенә дә Сүбәдәй баһадирның әмерен житкерергә чапты. Сүбәдәй баһадир Чиләби меңбашка тирә-юньне чабып чыгарга кушты, ә үзе атын Карлыгач утырган арба үрәчәсенә бәйләде дә арбага менде.

— Еламыймы бәләкәч Ташбай? — диде ул. Кендек әбигә икенче арбага күчеп утыр! дип ым какты. Карчык тешсез авызын кыймылдата-кыймылдата, кемнедер тирги-тирги икенче арбага төшеп утырды.

— Шөкер ходага, еламый, — диде Карлыгач ир-канатына урын бирә-бирә, үрәчәгә таба елыша төште. — Сиңа охшаган, елак түгел.

Сүбәдәй балага үрелде, бала аның бармагыннан эләктереп тотып алды.

— Күр әле моны, ни тамаша ябыша, — диде Сүбәдәй куанычын яшермичә. — Батыр Ташбай булачак бу, Карлыгач дим!

— Атасына охшаса булыр. Тик бик ук атасына охшамасын иде. Тормышмени бу! Башы яудан кайтмый, гел юлда да юлда.

— Язмыш безнең шулай, ата-бабаларыбыз күчеп гомер иткән. Килер бер көн, туктарбыз. Бар илләрне дә буйсындыргач, бар илләрдәге халыкларга да ясак салгач. Безнең үз биләмәләребез, үз җәйләүләребез булыр.

— Бирсен ходай иде дә бит, — диде хатын һәм иргә карамый гына уфтанып куйды, аннары ирнең сакалына кагылып алды да: — Бүген ыстан да туктамаска булдыңмени? — диде.

— Юк, туктамыйбыз. Төне буена барачакбыз. Көндезен ял итәрбез. Хәрәкәттә — бәрәкәт, дигәннәр картлар. Олауларны урлый башладылар. Уяу гаскәр саклаган олауга кемнең генә кыюлыгы җитеп урларга килер микән? Башлары ике булса гына инде.

* * *

— Уян, уян, абам дим! Тор әле!

Җәбәй нойон күзләрен угалады, япманы камчы сабы белән ачып торган Сүбәдәй энесенә карады, шундук юрганын селтәп ташлады. Сүбәдәйнең карашы тәмам ялангач калган сары чәчле кызның ят җиренә төште, алсу ботларын капшап узып, калку күкрәгенә житте. Кыз куркынып, куллары белән күкрәкләрен капламакчы итте, әмма ачык тәне, сын-гәүдәсен яшерер вә каплар әмәл тапмагач, капланып ятты. Сүбәдәй шаркылдап көлеп җибәрде.

— Башың капладың, ә артың ачык, — дип кеткелдәде ул, шулчак Җәбәй абасы япманы төшерде, усал итеп энесенә бакты.

— Күзең төшсә, сатып ал, әмма мыскыл итмә! — диде ул житди генә. — Бәһасе ике бөлеш. Кенәз кызы. Үкенмәссең...

Сүбәдәй баһадир Хасдайга карап көлемсерәп куйды. Меңбаш мыек астыннан гына көлә иде.

— Хасдайга күпмегә саттың... Кенәз кызын бик очсызга бирәсең түгелме соң?

— Мин бәһане белеп бирәм, белеп сорыйм, — диде Җәбәй нойон.

— Анысы хак, кызлар мәсьәләсендә сиңа житүче юк, — диде Сүбәдәй. — Куеп торыйк әле кызларны, абам. Иртәгә Кара Идел дигән елгага житәбез икән. Безгә елга кичү өчен генә атнадан артык вакыт кирәк булачак.

Җәбәй итеген киде, мамык сырган сакалын сыпырып алды. Атын китерделәр, атка атланды.

— Елга шул хәтле киң микәнни?

— Бик киң, диләр.

— Дисәләр соң. Киң булсын. Кичәрбез. Беренче тапкыр гына елга кичүең түгелдер бит?.. Йокы бирмәдең. Кем инде төнлә хәрәкәт итә. Кичә дәшмәгән булган идем, бүген ачуым чыгып тора. Нигә кирәк булды төнлә хәрәкәт итү?

Сүбәдәй баһадир еракта күренгән ике куш тауга таба камчы сабы белән күрсәтте: — Әнә күрәсеңме кушылып житә язган тауларны, әнә-әнә, житүле атларга охшаганнар. Бортчы Плюскәй кичү шул төбәктә, ди.

— Шул төбәктә икән, шунда таба кузгалырга кирәк. Бераз ял итеп алабыз да. Кояш баер-баемас меңбашларны киңәшкә җыярга кирәк булыр,— диде Җәбәй нойон, идарә итүне үз кулыма алам, дигәндәй атыннан төште.— Бар, кит, син дә ял ит. Кич якта сөйләшербез. Йөрисең шунда эч пошырып.

Сүбәдәй баһадир ни сәбәпледер дәшмәде, бер уйлаганда абасы хаклы иде. Йончыган гаскәр белән дошманга каршы торып булмас.

Арба янына җитәрәк, ул бала елаган тавыш ишетте һәм борылды да кишектиннәренә калырга кушты. Кишектиннәре аны ничек сакларга беләләр, өйрәтеп торасы юк иде, меңбаш Хасдайга гына:

— Кич якта уятырсың,— диде. Ләкин аңа йокларга язмаган икән, башбагучы килеп туктады, атыннан төште, арба янына килде, тамак кырды.

— Кем бар анда?— дип сорады Сүбәдәй.

— Мин бу, башбагучы.

Сүбәдәй япманы ачты, багучыга карады.

— Йә, ни?

— Көтүчеләрдән башка берәү дә күзгә чалынмады, баһадир.

— Сәүдәгәрләрне дә очратмадыгызмы?

— Алар хәзер нindидер урыс кенәзлеге аша йөри башлаганнар икән. Без куркытканбыз. Төрле халык яши биредә. Көн күрүләре ташка үлчим, ярым-йорты юртада торалар. Юрталарын кәс-үлән белән каплаганнар.

— Нә ашап гомер итәләр. Кәсепләре?

— Балык, әпекәй, мал асрыйлар. Тук күренделәр. Нә сорасаң, шуны чыгарып бирәләр. Берсе ике бәлешкә кызын биреп җибәрде.

— Балык ашау гөнаһ. Димәк, монда гөнаһлы халык яши.

— Без балык ашауны языкка саныйбыз, алар санамыйлар. Сәер халык.

— Болгарларны бай дигән булдылар.

— Болар болгарлар түгел, нindидер башка халык, баһадир. Минем болгар кешеләрен күргәнем бар. Аннары болгарлар мөселманнар, ә болар нindидер потларга табыналар.

Сүбәдәй баһадир багучысын тыңлады, ә үзе уйланды. Болгар җире түгел бу. Болгар җире булса, каршы торырлар иде. Димәк, Болгар җире елганың аргы ягында. Әллә соң бу Болгар ханы бер-бер хәйлә корып ятамы?.. Кайда хан гаскәре? Елганың аръягындамы, бу яктамы?..

Баһадир сүзсез калгангамы, башбагучы Тәгәрил бер урында таптанып алды. Нидер әйтергә теләгәндәй хәрәкәтләр ясады.

— Йә, тагын нәрсә?— дип сорады баһадир башбагучының кыбырсуын күреп.

— Бер сәүдәгәрне туктаткан идек. Урыс сәүдәгәре, Киякалага барам, диде. Тимәгән булдык. Ул да Болгарны бик тә бай ил, диде.

— Ул нинди халык тагын?

— Болгарлар белән бергә яшәгән халык. Диннәре, гореф-гадәтләре бар, телләре, җырлары. Кыз алышалар, кыз бирешәләр. Кыпчакларның без яулаганнары урыслар белән аралашса, болары болгарлар белән аралаша.

— Тәгәрил агай, хәзер Җәбәй нойон башбагучысы Бүтәкәйгә бар, аның белән бергә минем янга килегез. Нә кылырга бергәләп хәл итәрбез.

* * *

— Баһадир, баһадир,— ди аңа ап-ачык итеп башбагучы Тәгәрил.— Баһадир, егыласың бит!

Сүбәдәй уянып китә, иярдән сөйрәлеп төшеп баруын сизеп, көч-хәл белән генә ияренә утыра, тезгенен җыебрак тота. Иллә янында берәү дә

юк, башбагучы Тәгәрил дә, Карлыгач утырган арба да. Сүбәдәй кычкырып җибәрүдән чак кына тыелып калып, артына әйләнеп карый. Арба әллә кая артта калган, ә ул аты белән алга киткән, башбагучылар Тәгәрил белән Бүтәкәй ана таба чабып киләләр. Юк, Бүтәкәй дә түгел, Тәгәрил дә түгел, ниндидер ят очлым кигән кеше. Очлым башында каурый җилферди. Кулында ук-җәя тезгенен җибәргән. Бу нихәл бу, уяныл җитмәвеме?!

Кисәктән Сүбәдәй баһадир уянып китә. Арба да янда гына, кишектиннәре дә шул тирәгә ауганнар — йоклап яталар. Колак яныннан гына сызгырып ук узды. Сүбәдәй яман итеп кычкырып җибәрде:

— Дошман! Дошман! Торыгыз!..

Мәгәр соң иде инде, алар өстенә уклар ява башлады. Күбесе йоклаган җирдә ятып калды, бары тик беришесе генә ат менәргә маташа иде. Ләкин ук дошман сайламый, алар да акыра-бакыра авалар. Ниһаять, ни кыласын белмәсә дә, Сүбәдәй баһадир атына менде, шундук аты берьякка ава башлады. Каушаудан булса кирәк, Сүбәдәй өзәңгедән аякларын ычкындыра алмыйча ат астында калды. Ат үлем белән тартышты, йөгән тимерләре белән аның йөзенә орды, Сүбәдәй баһадир җан ачуы белән кычкырып җибәрде, ат астында калган аягын чыгарырга маташты. Ләкин ат та тик тормады, торасы иттеме, әмма тора алмады, кире ятты һәм Сүбәдәйнен икенче аягын да астында калдырды. Тагын йөзе ат башына тиде, ат шул тиклем каты итеп башын чайкады ки, тимере белән Сүбәдәй баһадирның йөзенә шундаен иттереп орды ки, күзенә тимер тиюдән баһадир бакырып җибәрде һәм шундук аның җуйды.

Булган хәл турында аңа арбада яткан килеш Хасдай меңбаш сөйләде. Инеш буендагы агачлар артыннан көтмәгәндә берничә мең гаскәри килеп чыга. Алар, ташкын булып, йоклап яткан мәлгуннәргә ташланалар. Янгыр кебек ук яудыра-яудыра Сүбәдәй баһадир торган арбага якынлашалар. Хасдай меңбаш сикереп атына атлана, уянып өлгергән, ат менгән сугышчылары белән Сүбәдәй баһадир йоклаган тәбәккә таба килүче дошманны туктатмакчы була, әмма аларны бүлеп алалар һәм сибеп-таратып ташлыйлар. Хасдайның аты сөрлегә һәм ул ат башы аша мәтәлеп барып төшә һәм аңын җуя. Ул аңына килгәндә дошманның эзе дә булмый инде.

Сүбәдәй баһадир бәйләгән күзенә кагыла, күз чыдар әмәлләр калмыйча авырта, җитмәсә аяклар һични сизми. Аңа күзе дә кызганыч түгел, аягы да рәтләнер шикелле, ә кола айгыры кызганыч иде.

— Кола айгыр ничек, кола айгыр?..

— Аны бавырчылар алып китте, баһадир.

Сүбәдәй баһадир йөзен чытты, бәйләнмәгән күзеннән бер тамчы күз яше тәгәрәп чыкты. Кеше телен аңлый торган ат иде, менә кая килеп югалтырга язган икән мескенне.

Сүбәдәй белмәде, кайчан һәм кем аны елга аша алып чыккандыр... Ике-өч көн ашыгыч төстә юл баргач кына, ыстан туктадылар. Ниһаять, Сүбәдәй янына үз табибе белән Җәбәй нойон килде. Килде дә атыннан да төшми, арбада яткан энесенә карап торды. Сүбәдәйнең бер күзе бәйләнгән, икенче күзе рәнҗүле рәвештә абасына карап тора иде.

— Олауларың кая? — дип сорады ул абасыннан.

— Сугышчыларың диген, сугышчыларың, гаскәрен. Дошман мине ике тау арасына алдап алып керде, турадылар, тападылар, исән чыгучы булмады диярлек. Син әнә ат астына калгансың да котылгансың, ә мин гаскәрсез, олаусыз калдым. Барысы да синең аркада булды, — диде Җәбәй нойон һәм табибенә борылып, Сүбәдәйнең күзен карарга кушты.

Сүбәдәй күзен йомды, бик озак күзен ачмый торды, аның чарасыз калуын, гасабилануын күреп, табиб аңа тынычланырга кушты. Табиб аның аякларын карады, ниндидер төнәтмә белән уды, аннары кара чүпрәк белән бәйләгән күзен ачтырып карады.

— Күзе тишелеп аккан, яңадан күрмәс,— диде табиб Җәбәй нойонга карамый гына.

— Куанасы итсен, бер күзе күрә. Кеше гомергә дә бер күз белән яши әле,— диде Җәбәй нойон. Абасының кырыс сөйләшүеннән үк тойды Сүбәдәй, моннан соң ул аңа көн күрсәтмәячәк. Хәзер абасы Җәбәй ни сөйләсә дә хаклы булачак. Йөзләгән олау югала, меңләгән сугышчы әсир ителә, кичү чыгаручылар бары тик Сүбәдәйне арьякка күчереп өлгерәләр, болгарлар килеп җитеп, аларның барысын да укка ала, елгага батыралар. Көн салкынча булгангамы, табиб аның аякларын тирегә төрде, күзен бәйләде.

— Берничә көннән аякка басар.

— Аякка басты ни дә хәзер, басмады ни. Нә гаскәр, нә олау дошман кулында калды,— дип сукыранып алды Җәбәй абасы. Сүбәдәй күзен ачмады, аның абасын гына түгел, күк йөзен дә күрәсе килми иде. Исән-имин Чыңгыз хан янына кайтып җитсәләр, абасы барысы хакында да тәфсилләп Чыңгыз ханга сөйләр, ә хан макталган тимер батырына җирәнеп карар, йә булмаса баһадирлыктан мәхрүм итәр.

— Миңа оят, абам,— диде Сүбәдәй.— Оят миңа, абам.

— Бик югарыга күтәрелгән идең шул. Барыбыз өстеннән дә әмир булдың. Җиңелмәс баһадир... Исән калганыңа куанасы ит. Тиздән аякка басарсың, ат менәрсең...

Сүбәдәй йөзен чытты, янә исән калган сул күзеннән бер бөртек күз яше бите буйлап тәгәрәп чыкты. Энесенең елавын күреп, Җәбәй нойон йомшара төште.

— Кайгырма, барысы да әйбәт булыр, башта терел.

— Карлыгачым кая минем, абам?

— Карлыгачың...— диде Җәбәй ирнесен бүлтәйтеп.— Карлыгачың! Үзең котылганга шөкер ит. Карлыгачың олауларың белән бергә әсир иттеләр. Гаскәрең рәтләп орышмады да. Килмешәк сугышчыларың болгарлар ягына чыктылар, безгә каршы орыша башладылар, моны күреп, сугышчыларың коралларын ташладылар.

— Башбагучым Тәгәрил кая?

— Бер хода белә каядыр. Төлке ул, башбагучы түгел. Урманнарга керергә куркып йөргән, диделәр миңа. Ә болгарлар безне урманда качып көтеп торганнар.

— Синең башбагучың кая соң? Бүтәкәй меңбаш?

— Ул да юк. Аны да гүяки җир упты.

— Алар бергә киткәннәр иде.

— Елганы кичәргәме?

— Багырга. Ике тау арасына аларны мин җибәргән идем.

— Син аларны ике тау арасын багып кайтырга җибәргәнсең, ә алар кичү эзләп киткәннәрдер әле, йә булмаса дошман тырнагына барып капканнардыр.

— Күпме кешең исән калды?

— Кем белә. Котылганнары куып җитә торалар,— диде Җәбәй нойон һәм атыннан төшеп, кымыз сорап алды, эчте һәм Сүбәдәйгә салып бирде.— Эч. Тынычлан.

Сүбәдәй кымыздан баш тартты.

— Эчмәсәң — эчмә,— диде Җәбәй нойон.— Ачка үл. Син үлгәннән кояш чыгудан туктар дип уйлыйсыңмы әллә? Тиле беткән! Без әле синең белән бу төбәкләргә килербез, сине шул көнгә калдырган болгарлардан үч алырбыз...

— Алырбыз,— диде Сүбәдәй һәм яңак итен чәйнәргә иткән иде күзе авыртудан ыңгырашып куйды. Нинди хәтәр орышларда катнашмады Сүбәдәй баһадир — исән калды, тәңре һәрчак саклады. Кешеләрне авыр кылычы белән урталай чабар иде һәм кан эчендә икегә ярылып аунап яткан гәүдәне күрер иде дә, хәтта йөзен дә чытмас иде. Кеше каны аңа су белән тиң булды, ә менә үз каны коелгач, үз-үзенә кул салыр дәрәҗәгә

житеп ята. Барысы да аңа кызганып карый. Ә бит аның бер карашыннан калтыранып төшәрләр иде, хәтта Җәбәй абасы да аңа буйсыныр, аның боерыкларын тыңлар иде. Хәзер әнә кисеп ташлаган агачтай селкенергә дә куркып ята, аяклары, гүя, үзенеке дә түгел, һични сизмиләр.

Шулчак гүя дала кузгалды, кайдадыр атлар чабыша иде. Дөбердәү Сүбәдәй баһадир яткан арбага килеп иреште, дикъкатен читкә алды. Ыстан кузгалды, һәркем коралына ябышты, ат тезгеннәрен барлады. Җәбәй нойон өзеп-өзеп әмер бирде:

— Сөңгечеләр алга, укчылар уң якка, ыргакчылар сул якка!

Ат тояклары дөбердәвен ишетүгә, Сүбәдәй баһадирның йөрәге дөпдөп тибә башлады, җисми авырту кай тарафкадыр китеп югалды, күңелне гаса биләде. Аның күтәреләсе һәм тавыш килгән якка карыйсы килде. Ул акырын гына кузгала башлады, әмма кинәт аркасы чатнап китте, зиһенен җуйды.

— Э-э-э, Җә-бб-әй аб-бый!

Куркуы юкка булды, чабып килүчеләр болгарлардан котылган багучылар икән. Җәбәй нойонның да, Сүбәдәй баһадирның да багучылары исән-саулар иде. Сугышчылар ыстанга җиткәч, атларыннан төштеләр, ишләре белән кочаклаштылар, куаныштылар. Тәгәрил багучы Сүбәдәй баһадир яткан арба янына килде.

— Баһадир,— диде ул гаепле кеше сыман.— Син яралангансың икән. Без дә көчкә котылдык...

— Бу синме, Тәгәрил агай?

— Мин, баһадир, мин, башбагучың Тәгәрил.

— Минем Карлыгачым, балам кая, Тәгәрил агай?

— Белмим, баһадир, орыш кырына без әйләнеп килгәндә анда мәетләрдән башка җанлы адәми зат калмаган иде инде. Безне тулганага алдылар. Ырып-ерып качарга туры килде. Без җиңелдек, баһадир, беренче тапкыр җиңелдек. Болгарлар гаять дәрәҗәдә оста сугышалар. Мин карт инде, ары таба ошбу якларга килә алмам, килгән кешегә әйтеп каласым килә: Болгарга ике-өч төмән белән генә яу килү ярамас. Куәтле ил, гаскәре әзерлекле, атта орышалар, утчагырлары бар. Исәнимин аякка басып, бире таба килергә итсәң, шуларны исәпнән чыгармасаң иде, баһадир. Уңлап олау байлык җыйган идем, барысы да Болгарда калды.

— Мин дә бар олауларым да югалттым, Тәгәрил агай. Моның өстенә бер күзем акты, аякларым йөрмәс итте — ат астында калдым.

— Инде котылдың, баһадир. Тиздән хан янында булырбыз. Бу яклар миңа таныш, юл йөртүчеләрем бар. Куанасы ит, бер күзең исән. Атың кызганыч, атың адәм телен аңлар иде.

Сүбәдәй баһадир капшанып башбагучының кулын тотты, буыннары агарганчы кысты.

— Игелек сиңа, Тәгәрил агай. Ничә сугышчың алып чыга алдың?

— Аллага шөкер, без котылдык. Югалтулар булмады түгел. Безне Кара Идел аша Плюскәй чыгарды, аны болгарлар әсир иттеләр.

## 31

— Миңа шунысы мәгълүм булды, Илһам хан,— диде иренчәк кенә вәзир Камай.— Чыңгыз хан үзе Хәрәземшаһ җирендә калган икән, бире таба Җәбәй нойон белән Гөмәй бәкне җибәргән, аларга ярдәмгә моңа кадәр беркая да җиңелмәгән, корыч баһадир атын йөрткән Сүбәдәйне билгеләгән. Гөмәй бәк, Батай меңбаштан ишеттегез, урыс-кыпчак белән орышканда ятып кала, ә Җәбәй нойон белән Сүбәдәй баһадир җәйлиҗәйли бире таба хәрәкәт итә. Ул гынамы, бу ике кеше бертуганнар икән.

— Димәк, башта Сүбәдәй баһадирны юк итәргә кирәк. Моны кемгә йөкләтибез, вәзир Камай?

— Батый меңбаш татарларны тышкы яктан борчып торыр. Безгә, хан иям, дошман ыстанына үтеп керә алырдай кеше кирәк. Кем анда керә ала? Миңа калса, сәүдәгәр кеше. Татарларны сәүдәгәрләргә тими, диләр. Мин моңа ышанмыйм, мәгәр андый хәлләр дә булгалаган икән, тоткан сәүдәгәрләрдән бер тиен акча алмыйча җибәргәләгәннәр. Урыс-кыпчак белән орышта шактый сугышчысын югалткач, татарлар кыпчак вә башка халыклардан сугышчылар җыя башлаганнар. Таймас баһадир кешеләрен шул тарафка җибәрсәк, дошман арасына керә алсалар икән?

— Акыллы фикер, акыллы фикер, вәзир. Йә-йә, ары таба ничек, ничек тагын дошман ыстанына кереп була?

— Әйткәнемчә, сәүдәгәр йөзендә, хан. Бикколны җибәрергә кирәк. Үзе белән хатын-кыз алсын, асраулар, затлы товар. Без алар аша ыстанда булган хәлләр турында белеп торырбыз...

...Кичә Илһам ханга янә бер яңа хәбәр иреште. Атасының иң ышанычлы сәүдәгәре Биккол үзе белән әмир Хаҗи абасы угланы Галине дә алып кайткан икән. Аты Кол Гали, имеш. Өргәнечтә Пәһлеван Мәхмүттә белем-сабак алган. Шигырьләр яза икән, шәех дәрәҗәсен алган.

Бу хәбәр өчен генә түгел, татарлар ыстанына озату нияте белән Илһам хан Биккол сәүдәгәрне дәшергә кушты. Әйе, ул аңа йомышын җиткерер, әмма Кол Гали хакында бер сүз дә әйтмәс тә, сорашмас та. Хәер, ул аңа инанган иде инде, үткән мәҗлестә үк, артыннан шымчыларын җибәрсә дә вакланып тормады. Кайткан икән — яши бирсен. Бүгенге көндә Болгарга Өргәнеч тарафыннан агылган халыкның исәбе-хисабы юктыр. Тәхеткә утыргач, Илһам ханның Биккол сәүдәгәрне вәзире итәргә теләге бар иде. Кол Гали турында ишеткәч, бу уеннан кире кайтты. Камай вәзир, аллага шөкер, үз вазифасын җиренә җиткереп үти. Хак анысы, ялгышкан чаклары да булгалый, әмма кем ялгышмый бу дөньяда...

Илһам хан тәхетеннән торды, дисбесен чапан кесәсенә койды һәм бүлмә буйлап йөрергә кереште. Сәер, нинди көч белән хәрәкәт итә бу Сүбәдәй атлы баһадир? Нинди куәткә ия корыч баһадир атын алган кеше?..

Кич якта инде Илһам хан бар тарафларга да чаптарларын җибәргән иде.

Вакыт хәл итәр кебек ил язмышын, һәрхәлдә, соңгы көннәрдә шулай тоела башлады Илһам ханга. Ул вәзиренә күпләп казылык ясарга, ит тозларга, кулына корал тотардай һәр егетне хан гаскәренә чакырып, сөрән салдырырга кушты. Хан әмерен сөрәнчеләр каладан-калага, авылдан-авылга кычкырып, хәбәр итеп йөрделәр. Ахыр чиктә барысын да читкә куеп, Илһам хан сәүдәгәр Бикколны кабул итте. Ул аңа гаять дәрәҗәдә зур йөк йөкләде. Хан каршына килеп утырган сәүдәгәр моны көтмәгән иде, күрәсең, бик озак дәшми утырды.

— Нә булды, олуг сәүдәгәр, нигә дәшмәс булдың? — дип сорады аңардан Илһам хан.— Мин сине беләм, атама игелекле вә тугры хезмәт иттең. Бар нәрсәдән дә хәбәрдарсыңдыр. Белмәгән телең, күрмәгән илең калмагандыр. Ишеткәнсеңдер, үзең дә хәбәр иттең, Ил-Болгарга моңа кадәр күренмәгән дошман килә. Ул инде кардәш кыпчакларны, күрше урысларны җиңеп, мал-байлыкларын талап, безгә таба хәрәкәт итә башлаган. Бер дә курыкмый, үз даласыдай җәйли-җәйли килә икән.

— Безгә килерме икән соң ул татар дигәне, хан иям?

— Менә шуны белү өчен мин сине җибәрәм дә, Биккол агай. Гаять дәрәҗәдә җаваплы йөк, кеше иңе күтәралмастай йөк. Иллә нә чара кылыйм, бердәнбер таяныр кешем синдер.

— Иделне кай тирәләрдә кичәргә исәп тота икән соң ул Сүбәдәй дигән баһадир. Әүвәл шуны беләсе иде. Шунда гаскәр тупларга кирәк булыр, хан иям, мин разыймындыр. Тик миңа ике-өч көн вакыт кирәк булыр. Миңа ышанычлы кешеләр сайларга кирәк булыр.

— Мин сиңа ышанам, Биккол агай. Кул очыңа казнабаш Варданнан йөз алтын ал. Мал-товарны кызганып бирмәсеннәр. Ил саклаганда мал турында уйламыйлар, баш турында уйлыйлар.

* * *

Икенче көнне иртәнге якта ук җиләнен җилбәгәй җибәргән, очлымын да салмыйча жилләнеп каршына килеп баскан Җик Мәргәнгә Илһам хан сокланып карап торды. Җиңел гәүдәле, очлы күзле, кыю карашлы иде мәргән баһадир. Кысынкырак күзле булса да укны төз ата, даны Болгарга таралган.

Баһадир килеп керүгә, Илһам хан тәхетеннән купты, аңа каршы китте.

— Әйдүк, әйдүк, баһадир, рәхим ит,— диде Илһам хан һәм Җик Мәргәннең терсәгеннән алып, тәхеткә таба әйдәде.— Утыр, баһадир. Синең белән киңәшәсе сүзем бар. Ишеткәнсең булса кирәктер, илгә ниндидер татар атлы дошман килә. Күп илләрне буйсындырып, малмөлкәтләрен талап йөриләр икән. Хәзер Болгарга якынлашып киләләр. Син, баһадир буларак, һәрчак ил иминлеген сакладың. Өметем сиңа зурдыр, баһадир, иншалла, бүген дә, илгә шундый яман дошман якынлашканда да читтә калмассын дим...

— Мин кеше кешеседер, олуг хан. Бәем әмир Хаҗидадыр. Ул нә әйтер, шул булыр.

— Хуш, хуш, баһадир. Илгә дошман килгәндә, иншалла, абам да читтә калмас дип уйлыйм. Яңа утчагырлар ясатып ята дип ишеттем, кулланыр чаралары булырмы дигәндәй...

— Ул хакта мин хәбәрдар түгел, олуг хан. Мин аның бары тик баһадирыдыр.

— Баһадир, мин сиңа зур йөк тапшырырга булдым бит әле.

Җик Мәргән кузгалып алгандай итте, әмма дәшмәде, идәнгә тәртелеп торган кылычын рәтләгәндәй кыланды.

— Бездәй кешегә олуг хан йомышын йомышлау зур дәрәҗәдер, шөһрәтлем.

— Син биргә сугышчыларың белән килдеңме?

— Меңбаш белән. Ышанычлы меңбаш. Сугышчылары сайлап алынган кебек, олуг хан.

— Меңбашың кая соң?

— Сарай ишегалдында, олуг хан.

— Син шул меңбашың белән Иделнең аръягына чыгып, дошман белән очраша алыр идеңме, баһадир? Миңа һәркөн диярлек хәбәр килеп тора. Дошман Иделгә житеп килә. Димәк, безгә таба килүе хак.— Җик Мәргән җавап бирергә дип авызын ачкан иде, Илһам хан кам таягын кулына алды.— Ашыкма, баһадир, әүвәл ханың тыңлап бетер. Беләм, әйткәнеңчә, син кеше кешесе. Әмир Хаҗидан әмер кирәк булыр, диярсең. Әмер булыр, баһадир, борчылма. Безнең икебез өчен дә уртак дошман бар. Мин Иделнең аръягына Батый атлы меңбашны җибәрдем инде. Меңбаш татарларга шактый зыян китергән, олауларын урлаган, сакчыларын үлтергән. Корыч атлы Сүбәдәй баһадир пошаманга калган, дип әйтеп әйтәләр. Шулай була кала икән, синең анда килеп чыгуың янә бер куркыныч тудырыр иде. Әйтик, иң мәргән укчыларың белән баһадирның ыстанына һөҗүм итсәң. Ул арада без Җәбәй нойон гаскәрен Җигүлат тауларына котыртып кертер идек. Сиңа ярдәмгә Бачман баһадир, Җаббар бәк, Булат углан килер...

— Олуг хан, бер киңәш биримме?.. Кәртә кирәк булыр. Ил кәртәсе.

— Бар ул, бар, баһадир. Әнә кече өстәлдә ята.

— Шунда таба үтик әле, олуг хан.

Илһам хан моны көтмәгән иде бугай, бермәлгә икеләнеп торды, әмма Җик Мәргән өстәл янына таба киткәч, иярми дә булдыра алмады.

— Менә монда ук, елганың аръягында ук борчый башларга кирәк,— дип, Җик Мәргән картәдәге төбәкләрне күрсәтергә кереште.

— Мең азат беләнме, Баһадир?

— Мең азат белән, олуг хан. Орышта тәҗрибәле мең азат бер төмән дошман сугышчысына торадыр, олуг хан.

— Ә татарларда өч төмәнгә якын азат, диделәр.

— Булсын. Аның каравы алар хәрәкәт итәләр. Өч төмән бергә хәрәкәт итү мөмкин түгел. Аннары олаулар, көтүләр. Табигый, күчмә халык булarak, татарлар көтүләрен дә калдырмыйлар, юрталарын да. Орыш ачыктан-ачык булмас, олуг хан. Мин сезнең белән килешәм. Мин казак кеше, кайчан, кай вакытта дошманны борчырга уңай буласын да беләм. Аннары, олуг хан, без дошман җирендә түгел, үз җиребездә. Без түгел, алар бездән курыксын. Безгә Идел аръягындагы һәр елга-күл, әрәмәлек, урман-тугай таныш. Без аларны менә моннан ук борчый башларбыз, олуг хан,— дип картәдәге сызымнарны күрсәтте Җик Мәргән.— Без аларны Җигулат таулары арасына алдап кертербез, ә монда дошманны төп гаскәр көтәр. Тулганага шунда алырбыз.

Сәер хәл, баһадир нәкъ ул әйткән орыш әйләнәсен күрсәтә иде. Илһам хан Җик Мәргәннең иңенә кулын салды, аннары кәтибенә дәште.

— Кәтиб Хафиз, Хафизҗан, мондамы син! Бире чык әле!

Җай гына атлап кәтиб Хафиз керде, баш иеп, кунакка сәлам юллады.

— Мин сезне тыңлыйм, хан иям.

— Баһадир Җик Мәргән дә нәкъ безнеңчә уйлый икән. Дошманны Җигулат тауларына алдап кертергә һәм шунда тулганага алырга, ди.

— Мин Җик Мәргәнгә ышанам,— диде кәтиб Хафиз һәм баһадирга баш иде.— Болгар халкы синең батырлыгыңны онытмас, баһадир.

— Әйе,— диде Илһам хан.— Сиңа бездән фатиха, баһадир.

— Олуг хан, мин бит...

— Сабыр ит, баһадир, сабыр ит. Мин синең нә әйтәсең беләм. Әмир Хаҗи абама мин үзем баш иеп барырмын. Ышан.

Илһам хан шулай диюгә, кәтиб Хафиз аңа күтәрелеп карады, чынмы-ялганмы сөйли бу хан дип шикләнүе иде булса кирәк.

— Илгә яу килгәндә китап та гаилә низагларын читкә куеп торырга куша,— диде Илһам хан кайчандыр Ибраһим каласы Ягкуб бәктән ишеткән сүзләрне кабатлап. Ханның соңгы сүзе Җик Мәргәнгә дә нык кына тәэсир итте күрәсең, ул тураебрак басты.

— Олуг хан, мин ике-өч көннән Җигулат тауларына таба юл алырмын.

— Хәерле сәгатькә, баһадир. Иншалла, барысы да әйбәт булыр.

Илһам хан Җик Мәргәнгә кулын сузды, уңыш теләде.

— Кәтиб, мин иртәгә иртән-иртүк Шайтан каласына юл алырмын, йомышлы кешеләрне бусагабаш вәзиргә җибәрсен,— диде хан.

* * *

Урман кырына җиттеләр. Ханның аты сөрлекте, чак кына капланмады. Илһам хан атның тезгенен тартып куйды, ачуланып алды. Ат сөрлегүне яхшыга юрамыйлар, әмма бу хакта берәү дә ханга әйтергә кыймады. Борылып кайтырга кирәк иде югыйсә. Аты сөрлеккәннән соң Илһам хан атын тагы да куалый башлады. Аты кәҗәләп, кырын-кырын бара, ярсынып йөрәк кага иде. Ханга бу хәл бөтенләй ошамады, ул каты итеп атка камчысы белән сыдырды. Ат тәмам ярсынды, туктады, бармас булды. Шулчак җансакчысының берсе җилле генә юырттырып, алга чыкты, ә хан аты аңа ияреп, бераздан тәмам тынычланды.

«Дүрт аяклы хәйван, ә барыбер йөрәкле кешене яратмый, эче сизә»,— дип уйлады кәтиб Хафиз Илһам ханның атын рәнҗетүен ошатмыйча. Чулман буена килеп чыктылар, яр буйлап киттеләр. Арырак яр буенда бер кеше утыра иде, янәшәсендә аты утлый. Илһам хан аны күрде дә, камчы сабы белән төртеп күрсәтте: барып белегез, янәсе. Җансакчыларның икесе дә ят кешегә таба чаптылар, ни сәбәпледер атына атланырга өлгергән кеше җансакчылар якынлашуга туктап калды, танырга иттеме. Әмма үзе янына хан җансакчылары якынлашуын сизгәч, чаптырып тарлавыкка төшеп китте һәм шундук күздән язды. Аның артыннан ук тарлавыкка чабып төшкән җансакчылар берәүне дә таба алмыйча кире әйләнеп килделәр.

— Җитә алмадыгызмы?— дип сорады алардан Илһам хан.

— Гелән җир упты үзен. Рөхсәт ит, кан, төшеп эзлик?

— Кирәкмәс,— диде Илһам хан һәм инде күренә башлаган Шайтан каласына таба кузгалды. Кәтиб Хафиз атын куалый төшеп, хан белән тигезләште.

— Бу Шайтан каласын тәмам сер тубалы итте, абам,— диде аңа карамый гына Илһам хан.— Ишетәсеңме, кәтиб Хафиз!

— Ишетәм, хан иям.

— Ә миңа аның белән килешергә туры килер. Шайтан каласының иясе белән дим. Теге вакытта азатларым минлекләде дә алып калды, бу юлы үзем генә килергә булдым. Ике җансакчым белән сине әсир итсә генә инде.

— Кем, хан иям?

— Кем-кем, әмир Хаҗи. Кем бездән качты дип беләсең? Абам кешесе. Сакка куелган булгандыр, йә булмаса минем килүем турында ишеткәндер. Гәрчә мин бу хакта синнән башка берәүгә дә әйтмәсәм дә. Кыскасы, хәлләр шаклар катмалы, кәтиб Хафиз.

— Бәлкем әмир Хаҗи монда юктыр, хан. Гөнаһлы булмыйк дию-ем.

— Монда булмыйча кая булсын ул. Мин баһадир Җик Мәргәннең тел төбеннән үк аңладым: әмир Хаҗи монда, Шайтан каласында. Яңа утчагыр сынап ята.

— Рәхим итегез, олуг хан!— диде ясавыл.

— Меңбаш кая, нигә меңбаш каршы алмый!— дип сорады Илһам хан.

— Аны әмир чакыртып алды, хан.

— Әмир Кашандамы?

— Кашанда, хан.

Илһам хан әле булса атыннан төшмәгән кәтиб Хафизга карап алды, син ничек уйлыйсың, дигәндәй кәңәш сорады.

— Безгә Шайтан каласы түгел, әмир кирәк, хан,— диде кәтиб Хафиз ханның фикерен аңлап.

— Кашанга!— диде Илһам хан. Һәм ясавыл ягына әйләнеп тә карамый асма күпергә таба борылды.

Кашан каласының басу капкасын үтүгә, әмир Хаҗиның ясавыллары аларны каршы алды, болдырга кадәр озата килде. Әмир Хаҗи аларны болдырга чыгып, колачын җәеп каршы алды. Илһам хан һич тә моны көтмәгән иде, бераз шикләнә калды. Сарайны җыйнак, әмма матур итеп салдырган әмир Хаҗи, янында мөлаем генә хатын басып тора. «Ягкуб бәк кызы»,— дип уйлады Илһам хан.

Күрештеләр, әмир Хаҗи кәтиб Хафизны Илһам ханнан да ким каршы алмады. Әмир Хаҗиның сакалы агара башлаган, әмма сынгәүдәсе төз, тавышы көр. Шымчылары дөрес хәбәр итеп торганнар: Акбикә хатыны киткәнгә абасының ул чаклы исе китмәгән — гөрләп яшәп ята. Меңбаш Таймас кешеләре әмир Хаҗи сараенда булган хәлләрне түкми-чәчми Илһам ханга җиткереп торсалар да, мондагы манзараларны үз күзең белән күрү кызык иде. Әйтик, әмир Хаҗи абасы угланы Кол Гали турында белә микән? Белмәгән хәлдә аңа бу хакта әйтергә була.

Иллә абасы бу хәбәрне ничек кабул итәр?.. Бик ихтимал, абасы турында ул хәбәрдар булгач, ул да аның турында хәбәрдардыр. Чөнки белә иде, аның сараенда да абасының кешеләре бар. Хәтта бүген ни өчен баш иеп килүенә хәтле беләдер абасы. Әйдә, белсен, Илһам хан начар ният белән килмәде, нияте изге — дошманны каршы алу. Ә ул дошман яманнарның яманы, диләр.

— Яңгыр да явып алды, юл бик авыр булмадымы соң?— дип сорады анардан абасы.

— Юк, әллә ни чыланмадык.

— Әллә мәйтәм, башта мунча кереп чыгасызмы? Ә кәтиб Хафиз?— дип артка каерылып карады әмир Хаҗи.— Олуг хан ничек уйлый?

— Абам,— диде Илһам хан.— Минем белән алай сөйләшмәсәң иде. Без синең белән бер ата-анадан җан алган туганнар...

— Хуш, хуш, олуг хан, шулай итәрбез. Зөләйха, ничек уйлыйсың, миңа калса, Илһам туганым хаклыдыр?

— Хаклы, хаклы, әмирем,— диде хатын һәм алгарак чыгып, түр якка таба китте.— Минем олуг ханны күптән күрәсем килә иде инде.

Зөләйха түр якка үтеп туктаган, аларга йөзе белән тора һәм урын күрсәтә иде инде.

— Рәхмәт, җиңгәчәй, мең рәхмәт,— диде Илһам хан һәм кабартылган атлас мендәргә утырды.

— Назлыгөлнең угланы Хансөяр дә монда әле, сабак ала,— диде әмир Хаҗи.— Ушлы бала, миңа ошый. Акыл үзендә, исләрең китмәле... Әй, сөйләшүләр соңыннан, соңыннан. Башта мунчага. Әйдәгез-әйдә, анда сезне көтәләр инде.

Мунчага аларны ике хезмәтче озата барды. Алдан кәтиб Хафиз атлый, үзалдына сөйләнә.

— Мин бу мунчада бик күп гөнаһларым юдым инде. Тагын язган булып чыкты.

— Син дә үзеңне гөнаһлы затларга санасаң, ханнарга нә сан?

— Мин китап язучы, хан. Хан әйткән сүз — аткан уктыр, очар, кадалыр, туктар. Ә мин язган язуны балта да юна алмас, гасырларга китәр. Ялган тарих исә халкым ялган яшәргә мәҗбүр итәр.

— Миңа калса, син, кәтиб Хафиз, беркайчан да, берәүгә дә яманлык кылмагансыңдыр. Яван кызына өйләндең. Муеныннан тәресен ташлатып, көлһуалланы өйрәткән өчен генә дә син оҗмахның түрендә утырырга тиеш адәмсеңдер...

— Хан иям,— диде кәтиб сукмактан атлаганда.— Әмиргә угланы Кол Гали турында сүз катмасагыз иде.

— Нигә кирәк ул миңа. Минем кайгым Кол Галидә түгел, кәтибем. Әйе, аны Болгарда, диләр. Әйдә, яши бирсен. Теләсә атасы янына Кашанга килер. Инде килми икән...

— Кашанга килмәс ул, хан иям.

— Нигә?

— Ул бала, хан иям, яшьлек чорында ук бүген атасына кияүгә чыккан Зөләйха туташка гашыйктыр. Ишеткәнем хак булса, Кол Гали шәех вә шагыйрь кеше, йөрәге алла кулындадыр.

— Кәтибем, кәтибем,— диде Илһам хан, чак кына туктагандай итте.— Миндә бүген Кол Гали кайгысымы? Ил кайгысы! Ил!

Әмир Хаҗи мунчадан аларны болдырга чыгып каршы алды һәм түр якка алып кереп китте. Асрау кызлар табын хәстәрләгән, тыз-быз йөриләр, берәүсе ханга коры сөлге китерде, җиләнен салдырды, аякларына йомшак оек бирде, иңенә җилән элде.

— Рәхмәт, рәхмәт, балакай,— дигән булды Илһам хан.

Табынга утырыштылар. Зөләйха чәй ясап торды, абасы Илһам ханга кымыз салып бирде.

— Син дә рәхим ит, Хафизжан. Житешеп утырыгыз. Юлдан ачыкkансыздыр.

— Абам, син минем ни өчен, нинди максат белән каршына килүем хакында белмисендәдер әле?

— Беләм, хан, беләм. Мин сине тынлыйм, хан.

— Аллаһы тәгалә каһәремедер, безнен тарафларга мона кадәр күренмәгән яман дошман жибәргән. Татар атлы бу күчмә халык әрмәнгөрҗиләрнең гаскәрен тар-мар итеп, Тимер Капканы үтеп, аланнарны кырган, аннары кыпчакларны сибеп-таратып бетергән. Шул хәлдән соң кардәшебез Кончак хан урыс кенәзенең аягына барып егылган: «Безне тар-мар иттеләр, сезне дә читләтеп үтмәсләр, бергәләп яман дошманга каршы торыйк»,— дигән. Кенәз Кончак хан белән килешкән, татарларга берләшеп каршы чыкканнар. Иллә күп санлы кыпчак-урыс гаскәрен татарлар жиңгәннәр, әсир төшкән кенәзләрне җәзалап үтергәннәр. Хәзер әнә шул яман халык җәйли-җәйли безгә таба килә, диләр. Кәнәш ит, абам, нә кылыйм? Каламда көтеп алыйммы, дошманга каршы чыгыймы?

— Татарларның гаскәр башында мәрхүм баһадир Йәзүкәй угланы Чыңгыз хан тора икән. Чыңгыз хан үзен мәлгүн дип атый, диләр. Ләкин бөтен халык аларны татарлар, диләр. Мин дә бераз хәбәрдар ул халык турында, диясем килә. Миңа калса, бу халык турында кәтиб Хафиз да хәбәрдардыр. Илгә килгән бөтен мәгълүматларны ул җыя. Ә, Хафизжан, син нә әйтерсен?— дип сорады әмир Хажи.

— Ул халык турында былтырларны бер төрле итеп сөйләсәләр, быел икенче төрле итеп сөйләүчеләр бар, әмир. Бүгенге көндә Чыңгыз хан Гөлстан каласында ята, Олуг Мөхәммәт жирендә. Инде ихласи билгеле булды — Олуг Мөхәммәт вафаттыр. Чыңгыз хан аның угланы солтан Җәләлетдин белән орыша, диләр. Бире таба юнәлгән гаскәр башлыгы Җәбәй нойонның төп максаты әүвәл башта Олуг Мөхәммәтне кулга төшерү була. Хәзер шаһның вафат булуы аларга да ирешкән булса кирәк. Иллә Җәбәй нойон Олуг Мөхәммәтне тоту нияте белән генә кыпчак даласына чыккан булса, шаһның вафат булуын ишеткәч, кире Чыңгыз тарафына борылган булыр иде. Ә ул борылмый. Урыс-кыпчакның берләштерелгән гаскәрен жиңгәч, безгә таба кузгала. Ил язмышы сезнең кулда, Сәлим хан угланнары. Мин сезгә шуны гына әйтә алам.

— Мин сезне кәртә яныня дәшер идем,— дип күтәрелә башлады әмир Хажи. Илһам хан белән кәтиб Хафиз аңа иярделәр. Әмир Хажи түр яктагы чаршауны ачты һәм диванга кадакланган кәртәне күрсәтте.

— Кай тирәдә хәзер ул татар гаскәре? Кем тәгаен белә?..

— Миңа калса, татарлар хәзер Иделгә якынлашып киләләр,— диде Илһам хан.— Менә шул тирәләрдә булса кирәк.

— Әүвәл бер нәрсәне хәл итик,— диде Әмир Хажи.— Дошманны Иделгә кадәрме, әллә Иделне кичкәчме каршы алабыз?..

Абасы кәртәне бик тәфсилләп сыздырган иде. Әнә үз калалары, урысларныкы, Саксин, Суар, Ибраһим, Болгар, Юкәтау, Тубылгы тау, Казанга кадәр бар. Хәтта авыллар да төшерелгән иде. Елгалар-күлләр, тау-урманнар турында әйтеп тә торасы юк. Урыс белән Болгар чиген Сурә елгасы бүлеп тора. Кыпчак белән Болгар арасында чик юк. Бу ике халык күптән берләшеп яши инде, теле, дине, гореф-гадәте бер.

— Мин татарларны Иделнең уң ягында каршы алыр идем,— диде Илһам хан.— Татарларда өч тәмәнгә якын гаскәр. Оста орышалар, дип әйтәләр.

— Безнең азатлар да бер дә ким орышмыйлар, хан. Тик башта моның өчен безгә дошманның орыш серен беләсе килә.

— Ат өстендә орышалар, җәяүле азатлары юктыр.

Әмир Хажи йөренеп килде. Дошман хәтәр, әш хәтта анда да түгел. Иң хәтәре без аларның орыш ысулларын белмибез. Ә бу халык орыша беләдер, юкса ярты дөньяны яулый алмаслар иде.

— Әллә соң, олуг хан, кыпчак кардәшләре кебек, без дә күрше Ульдәмир-Сүздәл кенәзләре белән берләшәбезме?

— Мин сиңа баш иеп килдем, абам. Без ул татар дигән халыкны үзебез дә җиңәрбез. Мин урыслар белән кушылу ягында түгел, абам. Ә Калачыкны урысларга мәрхүм атамыз вәгъдә иткән иде. Халыклар уртак яшәсен, сәүдә итсеннәр, дип уйлагандыр. Иллә эт авызыннан сөяк алып буламы...

— Хәериең, хәериең, йа алла, олуг хан. Мин бары тик киңәш итеп караган идем.

— Сәнең игелегең алырга килүем иде, абам. Мин сәнең баһадирың Җик Мәргәнне дошманга каршы җибәрдем инде. Борчый торсын дидем.

— Мин ул хакта хәбәрдар, олуг хан. Сиңа тагын бер төмән гаскәр ышандырам. Бер төмәнем үз янымда калыр. Мин кенәзләргә ышанып җитмим, безнең Җигүлат тауларына таба орышка китүебезне ишетеп, илгә яу килүләре бар. Андый хәлләр булгалады инде. Килештекме, олуг хан. Ә мәҗлесеңә бара алмамдыр. Эшләрем күп. Рәхмәт.

— Безгә күптән берләшергә кирәк иде, абам,— диде Илһам хан күңеле тулыша башлавын тоеп.

— Кем соң әле безне аерды? Мин һаман бер хакыйкатьне кабатларга мәҗбүрмендер: мин үз калаларым, үз халкым белән бәйсез вә мөстәкыйль рәвештә идарә итәргә телим. Бары шул. Мин бәк-тарханнарыма да шундый шарт куйдым. Үз биләмәләренә үзләре ия.

Илһам хан күтәрелеп Зөләйхага карады, елмайгандай итте.

— Тагын чәй ясыйммы?— дип сорады Зөләйха. Тавышы ягымлы, нәзакатьле, саф, тыныч иде.

— Рәхмәт, җиңгәчәй. Ясап бирсәгез эчәрем.

Чәй табынына җиләк-җимеш китерелде, кәрәзле бал куелды. Илһам хан гасалы сөйләшүдән соң үзе дә аңламаган сусау тоеп, рәхәтләнеп, баллап чәй эчте. «Әллә җиңгәчәйнең кулы шифалы инде, тирләп үк чыктым»,— дип көлемсерәп алды.

* * *

Кайтыр юлда Илһам хан бер авыз сүз катмады. Әмир Хаҗи абасында кәтиб Хафиз авызын йомып утырмаса да, ул да сүз җебочын югалткандай дәшмәде. Табында утырганда шуңа игътибар итте Илһам хан: кәтиб Хафиз еш кына Зөләйха җиңгәчәсенә карап алды һәм хәтта нидер әйтергә ымсынды, сөйләшәсе, сорашасы килде бугай. Калага җитәрәк Илһам хан кәтибеннән әнә шул турыда сорады.

— Элек-электән таныш идеңме әллә җиңгәчәй белән, Хафизҗан дим?..

— Ягкуб бәк кызы Болгарда беренче булып кызлар мәдрәсәсе ача хан иям. Кыскасы, галимә кешегә өйләнгән әмир Хаҗи. Бәхете аягына урала диясем килә.

— Электән таныш идегезме әллә дим?

— Юк, хәтерләмим, хан иям. Күргәнем бар кебек, ләкин бик күптән инде.

— Нигә соң шул хәлләрне искә төшереп, әңгәмә тотмадың?

— Яхшысынмадым, хан иям. Ил турында сүз барганда, ничек инде балачакларны искә төшереп утырмак кирәк. Нинди китаплар укыды микән, сорашасым килгән идем. Ошбу галимә хан иям Тәтеш шәех язган әлифбаны камилләштерә һәм Болгар мәдрәсәләренә яздырып тарата. Әмир Хаҗи шундый галимәне канат астына алып әйбәт итмәгән. Илгә игелек китерә торган кеше бар нәрсәдән дә азат булырга тиеш, синең азатларың кебек.

— Абам ялгыз калды, кызгангандыр әмирне. Хатын-кыз кызгану аша ныграк ярата, диләр бит. Ялгыз ирне ялкын йолар, дигәннәр. Миңа калса, ошбу галимә хатынга өйләнеп, абам дөрес эшләгән.

— Тату яшәсеннәр, миннән теләк шулдыр, хан иям.

— Иртәгә мәҗлес. Мәҗлестән соң мин гаскәрем белән орышка чыгып китәм. Сарайда син каласың, кәтиб Хафиз.

— Ә вәзир Камай?

— Вәзир Камайны мин үзем белән алам,— диде Илһам хан һәм атын камчылый-камчылый басу капкасына таба чапты.

* * *

Чатырдагы учак әкрен генә сүнә бара. Түбә яклап кергән жил, бөтерелеп төшә, учак көлләрен очырта; елга яклап су тавышы ишетелә, ул да түгел якында гына ат кешнәп куя, кемдер, кемгәдер дәшә, янына чакыра. Еракта ат тояк тавышы ишетелә башлый, ул якынайганнан-якыная бара, ниһаять, чатыр янына ук житә, колак түрендә шаулап тора сыман. Ат менгән кеше туктый, тезгенен ярдәмчесенә ташлый һәм кычкырып:

— Хан мондамы?— дип сорый.

— Хан сезне күптән көтә инде, баһадир,— ди ана сакчы.

— Бу — мин, Жик Мәргән баһадир,— ди икенче сакчыга баһадир һәм чатыр япмасын ачып, эчкә керә.

Илһам хан учак яныннан күтәрелде, баһадирга кулын сузды.

— Рәхим ит, баһадир. Утыр.

Жик Мәргән хан каршына утырды, чыбык алып учакны актарды, учак җанланып, кабынып китте. Хан учакка чыбык ташлады.

— Хан, татарлар бары тик төнлә белән хәрәкәт итә башладылар. Көндез ял итәләр.

— Димәк, көндез ташланырга кирәк булыр.

— Көпә-көндезме?

— Көпә-көндез, баһадир. Көндез кеше саксызрак була. Бачман баһадир да килеп житте, чаптар көтә. Синнән билге булу белән һөҗүм итәчәк. Сүбәдәй баһадир синең өстә, Жик Мәргән. Әсирләр кайда?

— Миндә. Татарлар арасында төрки халык та күп икән.

— Ул халыкны ничек тә безнең якка аударырга кирәк, баһадир.

— Биккол сәүдәгәр дошман ыстанында. Бөтен мәгълүматны җибәреп тора. Сүбәдәй баһадир еш кына абасы Җәбәй нойон белән телгә килә икән. Сүбәдәйнең хатыны бала тапкан, Биккол кешесе кендек әби булып йөри. Күп мәгълүматны ул җибәреп тора. Чын мәлгуннәр яман халык. Ике сугышчыны әсир иткән идек, үз-үзләрен буып үтергәннәр. Икесе дә Сүбәдәйнең кишектиннәре булганнар диме. Җәбәй нойон иртәгә Иделне кичмәкче, имеш. Бүген дә төне буена килсәләр, иртәгә Иделгә килеп төртеләчәкләр, Җәбәй нойоң төмәне дим.

— Җәбәй нойонны мин үз кулыма алам. Син, Жик Мәргән, Сүбәдәй баһадир өчен җаваплы. Йә үлтер, йә әсир ит.

— Сүбәдәй баһадир нәрсәдер сизенә, әле абасына чаба, әле башбагучысын чакыра. Сораша, меңбашлары белән киңәшә икән.

— Димәк, көндез ял итәчәкләр. Төне буе килерләр-килерләр дә туктарлар, ял итәрләр. Елга кичәселәре бар. Җиңел эшме. Менә шунда син, күктән төшкән күк, Сүбәдәй баһадир ыстанына ташланырсың. Ә икенче яктан — Бачман баһадир. Барысы да без уйлаганча барып чыкса, баһадир, без аларны җиңәрбез, иншалла.

Илһам хан учакка тагын чыбыклар ташлады һәм келәмгә кәртәнә җәйде.

— Сүбәдәй баһадир менә бу инеш буена туктар сыман миңа. Инешнең арьягында әрәмәлек. Бачман баһадир шуннан һөҗүм итәр. Ә син

мәргәннәрең белән бу усаклык артында торырсың. Мин беләм, баһадир, дошман мәкерле, тәҗрибәле, беренче тапкыр гына орышуы түгелдер, бирешмәс, каушап калмас, әмма Сүбәдәй юк ителсә, меңбашлар тиз генә оеша алмаслар, дип өмет итик. Аннары елга буенда, менә шул төбәктә кичүчеләр туктады.

— Кичүчеләрне кем кулга ала?

— Җаббар белән Булат угланнар.

— Әллә соң, хан, Иделне кичсеннәрме?

— Юк. Иделне кичкәнче. Беришe кичә башласын, беришe бу якта калсын. Бачман баһадир да шулай диде.

— Ә ул монда киләме соң?

— Хәзер килеп җитәр.

Ул да түгел ат кешнәде. Бачман баһадирның калын тавышы ишетелде.

— Әнә килеп тә җитте, озын гомерле булыр,— диде хан.

— Әссәламегаләйкем, туганнар!— диде Бачман баһадир, керде дә хан белән дә, Җик Мәргән белән дә кул биреп күреште.

— Вәгаләйкем әссәлам, баһадир, утыр. Җик Мәргән килеште,иртәгә башлыйбыз. Әйе, аллага тапшырыйк, кылганы булыр.

— Иншалла, иншалла,— диде Бачман баһадир.— Минем багучыларым Сүбәдәй баһадирның багучыларына тап булганнар. Ике арада бәрелеш булып алган. Үлем-төшем булмаса да, яралылар шактый. Оста алышалар татарлар, хан. Мин болай уйлыйм,— Бачман баһадир кәртәгә текәлде.— Җигүлат таулары арасына мин чигенәм. Без урыннарны алышабыз. Сез гаскәрегез белән Җик Мәргәнгә булышка киләсез. Мин исә гаскәрем белән орыша-орыша тау арасына чигенәм. Дошман тау арасына керү белән гаскәремнең икенче өлеше дошманны тулганага ала. Ни өчен дип сорамагыз, хан. Шулай кирәк. Безгә башта Сүбәдәй баһадирдан котылу зарур. Ә Сүбәдәй баһадирда иң гайрәтле сугышчылар. Сездә дә Сүбәдәй белән орыш тигез җирдә барачак, миңа авырга килүе бар.

— Мин риза баһадир. Таң атыр-атмас, мин синең гаскәрең урынына күчеп китәрем. Безнең язмышны, баһадирларым, көтмәгәндә һөҗүм итү хәл итәчәк. Аллага тапшырдык...

* * *

Бачман баһадирдан хәбәр килде. Җәбәй нойон да Иделгә җитәр-җитмәс ыстан туктаган икән. Сәүдәгәр Биккол Җәбәй нойонга кызлар тәкъдим иткән, нойон ни сәбәпледер баш тарткан, Иделне кичкәч, дип әйтеп әйткән. Илһам хан бу хәбәрне китергән чаптарга рәхмәт әйтте.

— Хан иям, Җик Мәргән кузгалды.

Багучы сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, каяндыр таулар арасыннан кайтаваз булып, «у-р-р-а-а!» тавышы яңгырады. Илһам хан кулын күтәрде, гаскәрен алга әйдәде һәм ашкынып торган атын тау өстенә таба куалады.

Тоташ очлым, тоташ сөңге ташкын булып тауга менде, өздереп чаптырып түбән төшә башлады. Анда Сүбәдәй баһадир туктаган олау янында каты орыш бара иде инде. Көтелмәгән җирдән килеп чыккан болгарларны күреп, татарларның бер өлеше аларга каршы кузгалды. Ләкин болгарлар ташкыны аларны сытып, изеп икегә аерды. Күп орышларны күргән татарлар атка атланып кача башладылар, гадәттәгечә, дошманны алдап алып китәргә иттеләр, әмма бәхетсезлекләренә каршы баһадирлары күренмәде, меңбашлар исә башын югалткан елан кебек ары сугылдылар, бире сугылдылар да елгага таба сыздылар.

Илһам ханның аты колакларын йома төшеп, сөлек кебек сузылып чапты. Менә дошман гаскәре, алар да каршы борылды. Арттa куе тузан купты. Алгы сафлар бер-берсенә килеп орылды. Суеш-кырыш китте.

Илһам хан үзенә таба кылычын болгый-болгый килүче дошманны күрде дә, кылычын уң кулыннан сул кулына күчерде һәм атын уңгарак әйдәде. Бу хәлгә аптырый калган дошман аның сул ягына чыкмакчы итте, әмма соң иде инде: ат башлары тигезләште, Илһам хан бар көченә дошманга кылыч белән орды. Артына ул әйләнеп карамады, кылыч йөзе канга буялган иде. Тагын бер сугышчыны шулай алдады, әмма өченчесе хәйләкәррәк булды — Илһам хан ана житәрәк, атын үрә бастырды. Сөңгене ул соңгы мәлдә генә күреп алды, ат артына яшеренеп, дошман аны сөңгегә алырга иткән иде, әмма хан янында һәрчак жансакчылар була, шуларның берсе дошман атын укка алды, ат калтыранып кешнәп жибәрде һәм бер якка ава башлады. Сөңге атучы алай да сөңгене жибәрергә өлгерде, дошман сөңгесе Илһам ханның очлымына тиеп китте. Илһам ханның әйтерсең лә башына тәпәч белән суктылар, ул ат ялы өстенә капланды. Аны шундук жансакчылары уратып алды, якын килгән бер дошманга ук яудырдылар. Илһам хан бик тиз исенә килде. Башын күтәрде һәм колагына корыч-корычка орынган, акырынган-бакырынган, ат кешнәгән тавышлар ишетелде.

— Алга, алга!— дип кычкырды ул кылычын күтәреп.

Жансакчылары сибелә төште һәм Илһам хан янә бер дошман сугышчысын күрде. Куе кашлы, жәйпәк йөзле, кысык күзле, кәжә сакаллы батыр атлыгып аңа таба килә. Илһам хан кылычын әле уң кулына, әле сул кулына алды. Әмма дошман моңа бер дә игътибар итмәде. Ул шулхәтле тыныч килә иде ки. Илһам хан тирә-ягына күз төшереп алды, жансакчылары өермәдәй орыша иде. Алар дошманның уртасына килеп кергәннәр, тагын бер омтылсалар, ерып чыгачаклар иде. Аңа каршы килүче дошман искитмәгәндә сикереп иярenә басты, сөңгесен күтәрде. «Йа аллам, бармы син»,— дип уйларга өлгерде Илһам хан. Ул хәтта нинди дер мәлдә күкрәгеn тишеп кергән сөңгене тойгандай булды. Ләкин ияр өстенә менеп баскан дошманны соңгы мәлдә генә ниндидер мәргән укка алды. Күкрәгенә ук кадалган дошман ияр өстеннән түбән мәтәлде.

Илһам ханның, гүяки, икенче сулышы ачылды. Ул бар тавышына:

— Ур-ра!— дип, кычкыра-кычкыра азатларын алга әйдәде.

Илһам хан алдында кычкырышкан, акырышкан-бакырышкан ят йөзләр күренде, ул уңга-сулга селтәнде һәм кинәт бушлыкка килеп чыкты. Дошман урталай өзелгән иде. Илһам хан атын кире борды һәм:

— Тулгана!— дип кычкырды.

Болгарлар дошманны тулганга ала башладылар. Илһам хан тагын дошманга ташланды. Аны сакларга теләп, жансакчылары күкрәкләре белән сөңгегә капландылар, кылыч астына башларын куйдылар, ихахайлап егылган атлар астында калдылар. Тоякка тояк тиеп утлар чәчрәде, ыржайган ат авызыннан очкан күбекләр биткә чәчрәде, үлем алдыннан чыккан жан өзгеч тавышлар, кемнедер чакырулар, чәчрәгән кан исе, корсагы ярылган атлар, күкрәкләре тишелгән кешеләр орыш кырын чуарлады. Дошман кача башлады. Куа киттеләр. Ләкин дошман өер-өер булып качмады, сибелде, таралды. Болгарлар аларны куа барсалар да житә алмадылар. Ләкин орыш кырында ятып калганнары да исәпсез иде.

Ахыр чиктә, орыш сүрелә төшкәч, жансакчылары Илһам ханны калкурак жиргә алып менделәр, ул аннан күзәтергә һәм орыш белән житәкчелек итәргә тиеш иде.

Олаулар тирәсендә ниндидер ыгы-зыгы бара, карт-коры, бавырчысы, көтүчесе, хатын-кызы чыр-чу килә, акыра-бакыра егълыйлар, чәчләрен өзгәли-өзгәли, битләрен тырный-тырный болгарларны каргыйлар. Илһам хан түзмәде, олауларга таба кузгалды. Аңа каршы жансакчысы чаптырып килде.

— Кемнәр анда, нигә шаулыйлар.

— Ямаң халык, хан иям. Битләрен тырный-тырный сезне каргыйлар.

— Каргышлары карга башына. Үзләре күпме кешене рәнҗеттеләр микән, нигә шул хакта әйтмисез?!

— Хан иям, Биккол сәүдәгәр Җәбәй нойон белән Сүбәдәй баһадирның хатыннарын әсир иткән. Тегеләр буйсынырга теләмиләр, безне ханга күрсәтегез, диләр.

— Җик Мәргән кайда?

— Җик Мәргән Бачман баһадирга ярдәмгә чапты, хан иям.

— Сүбәдәй, Сүбәдәй баһадир, Җәбәй нойоннар?..

— Аларны кишектиннәре тулгананы ерып алып чыгып китте, хан иям. Сүбәдәй каты яраланган, диделәр. Җәбәй нойон исән-имин котыла.

Илһам хан олауга житәр-житмәс атыннан төште, жиргә намазлык җәйде дә, тезләнеп, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтен укыды. Бу хәлне күргән татарлар шым булдылар, шаккатып Илһам ханга карап тора башладылар. Бу хәлне аларның күргәне булмаган, күрәсең, ни кылырга белми аптырап калдылар. Әйе, нинди әмер бирер хан? Әллә, Сүбәдәй баһадирлары кебек, барысын да кылычтан уздырырга кушармы? Чыңгыз хан кылган төрле җәзаларны күргән бу халык чын мәгънәсендә куркуда иде. Ханның кыланышына котлары алынып, карап торулары бары тик шуннан иде.

Илһам хан исә, яман дошманны жиңү куанычыннан, күз яше белән елый-елый Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтен укыды. Аның бите буйлап яшь бөртекләре тәгәрәшә, сакал очыннан намазлыгына тама иде.

Ниһаять, Илһам хан торды, намазлыгын бөтереп, ияр капчыгына салды, бармак бите белән күз яшен сөртә-сөртә әсир ителгән һәм аның өчен ят булган татарларга карады. Аңа таба сабыр-тыйнак кына сәүдәгәр Биккол килә иде.

— Барысын да Болгарга алып кайтырга,— диде аңа хан.

— Лә-илләһә иллә-л-Лаһ, Мөхәммәдә-р-расүлү-Лаһ, шулай итәрбез, шулай итәрбез, хан,— дип, сәүдәгәр Биккол әсир ителгән һәм хан боерыгын көтүдән йөрәкләре өши башлаган әсирләргә юнәлде.

* * *

Меңбаш Артык һөҗүмгә алып барасы азатларны Җик Мәргән үзе тикшереп чыкты. Һәрберсенең коралын, әзерлеген карамаса да, сафлар алдыннан атын атлатып кына үтте, һәммә азатны күздән кичерде, кайберләренә хәтта елмайды. Аннары Артык янына туктады да:

— Синдә өмет, Артык,— диде.— Синең ермак алаең иң беренче булып Сүбәдәй ыстанына житәргә тиеш. Мәргәннәреңнен угы иң әүвәл Сүбәдәй баһадирга яусын. Аннары ничек тә баһадирның хатыны Карлыгачны кулыңа төшерергә тырыш.

— Нигә безгә ул хатын, баһадир. Минем кан дошманым Сүбәдәй баһадирдыр. Мин әүвәл бөтен көчемне аны юк итүгә салачакмын.

— Мин дә, мин дә, меңбаш Артык. Ләкин хатынын да күздән яздырма. Кишектиннәре оешып, каршы тора башласалар, Сүбәдәйнең хатынын коткарырга ташланырлар, без аларны бүлеп алырбыз. Баһадирның хатыны безнең өчен җим сыйфатын үтәргә тиеш. Әйе, без уйлаганча барып чыкса...

— Ярый, Җик Мәргән, мин аны ничек тә орыш кырыннан алып китәргә тырышырмын.

— Як-ягыңа иң оста мәргәннәреңне ал. Кем белә, әсир ителгән хатын Болгар өчен әманәт нисбәтен үтәве бар...

— Баш өсте, баһадир. Мин ул хатынны ничек тә кулга төшерергә тырышырмын.

— Рәхмәт сиңа, Артык. Орыш кырында төрле хәлләр булырга мөмкин, әсир итә алмасаң да, ышандыруың өчен рәхмәт.

Артык меңбаш уң кулында басып торган яшь мәргәнгә дәште.

— Мәргән Сафакай, син мәңгел баһадирыннан башка берәүне дә күрмисең. Һәр угың аңа төбәлгән булсын, һәр очкан угың аның тарафына юнәлсен. Мин сиңа ышанам, Сафакай. Ул кола айгырда булыр. Үзенә тигезәсеңме, атынамы — тигезүең хак булсын.

— Мин бер угымны да җилгә очырмам, меңбаш.

Шулчак урман-тауларны уятып, «ур-ра!» тавышы ишетелде.

Артык атына камчы белән сукты һәм:

— Азатлар, алга!— дип кычкырды.

Ачык җиргә атылып килеп чыгуга, җәясен алды, ук элде. Аты Сүбәдәй баһадир ыстанына таба очты.

Мәргән Сафакай алгарак чыкты һәм туп-туры сары чүпрәк каплаган арбага юнәлде. Аларга әйткәннәр иде инде: Сүбәдәй баһадирның хатыны сары чүпрәк белән капланган арбада, димәк, баһадир үзе дә аннан ерак түгелдер. Артык ат корсагына үкчәсе белән төрткәләде. «Тизрәк, тизрәк, тулпарым!»

Дошман ыстанында ыгы-зыгы купты. Әһә, әнә кола айгыр, димәк, Сүбәдәй баһадир — ыстанда. Татарлар ашыгыч төстә атларына атланалар, садакларын барлыйлар, җәяләрен рәтлиләр. Күбесе тезләнеп болгарларга ук яудыра башлады. Кемнәрдер атыннан егылып төште, кайсыныңдыр аты баш аша мәтәлде. Ләкин мәргән Сафакай алда, исән әле. Ул инде ук артыннан ук яудыра. Артыкның күзенә кола атка атланырга маташкан Сүбәдәй баһадир чалына, менә атланды да инде, камчысын күтәреп нидер кычкырды һәм нәкъ шунда аты бер якка ава башлады. Артык шул тарафка ук артыннан ук атты. Менә беренче сафтагы болгарлар татарлар белән бәрелештеләр дә инде. Китте сугыш, орыш, кычкырыш-бакырыш! Әнә Сүбәдәй баһадир хатыны утырган кибет, сары төстәге ефәк түбәле. Барчасыннан да аерылып тора. Ул килеп җитәрҗитмәс, арба кузгалып китте. Артык арттан килгән азатларына:

— Арбаны бүлеп алыгыз, җибәрмәгез!— дип кычкырды. Үзе исә арба җиккән атка атланып камчылаган арбачыга ук артыннан ук яудырды. Ниһаять, арбачының аркасына ук кадалды, ул бер якка авып төште. Ләкин ат һаман чапты. Кемдер арба эченнән җитәкли иде атны.

— Тукта!

Артык арбаны куып җитте, япманы кылыч белән ярып җибәрде. Дилбегәне ниндидер хатын тоткан иде, ул Артыкны гүя күрми дә, атына сызгыра, кычкыра, бу мәхшәрдән ераграк китәргә тели иде, күрәсең.

— Тукта!

Хатын аның ягына күз төшереп кенә алды да янындагы күн мендәрне Артык йөзенә атты. Аты өректе, кинәт читкә тайпылды, Артык ияреннән очып, җиргә аркасы белән барып төште, өстеннән арбалы ат үтеп китте, Артык аңын җуйды.

Орыш кырыннан аны ике азаты алып чыга. Аңына килгәндә ул ниндидер арбада, елга буенда ята иде инде. Орыш туктаган, тирә-якта сирәк-мирәк кеше тавышлары ишетелә, атлар пошкырына, төтен исе килә. Күк йөзе йолдызлар белән чуарланган, караңгы, елга яклап адашкан үрдәк кычкыра.

Арба янында берничә азат учак яга, үзара сөйләшәләр.

— Исәнме үзе?— дип сорады берсе.

— Исән шикелле, сулыш ала.

— Ук тимәгән әллә үзенә?

— Ук тимәгән, аты өркеп егылган, диделәр.

— Аттан егылмаган кешеме әллә меңбаш. Шундук торыр иде. Ат басkандыр әле. Былтырларны юлбасарларны куганда бер азатны ат басып үтергән иде, йөрәгенә туры килгән диме.

— Меңбаш ат басканнан гына үлмәс. Исәңгерәгәнгенәдер әле.

— Табиб кая соң, чакырттыңмы?

— Иртән булыр, диделәр. Орыш яңа бетте, табибләргә эш бетәме. Кайсына ук кадалган, кайсын кылыч өзгән. Орыш диләр аны.

— Арбада кем ята тагын?

— Ниндидер балалы хатын. Дәшми-тынмый, беркем белән сөйләшми. Баласын күкрәгенә кыскан да тик ята.

— Ашарга бирдеңме соң үзенә?

— Әсир хатын түгел, үзем дә ашамаган әле. Татар баһадирының хатыны, диделәр.

— Яуга нинди хатын сөйрәп йөрү икән ул, менә хикмәт, әй!

— Күчеп йөри диләр бит ул халыкны, бала-чагалары, көтү-маллары белән.

— Борын заманда болгарлар да күчеп йөргәннәр, диләр. Имеш, Таман якларына кадәр җәйләгәннәр.

— Ул Таманда бабаларыбыз дәүләт тотканнар, дип тә сөйлиләр.

— Бу катынны әйтәм, чибәр үзе, күз алмалы түгел. Күзләрен тутырып бер караган иде тәннәр чемер-чемер итеп китте, малай. Тәгаен сихерләде үземне, билләһи дип әйтәм, нә кушса, шуны кылыр халәттә калдым. Ипи менә.

— Баһадир булсын да чибәр хатын йөртмәсен. Ничәмә илне яулаган халык ди бит.

Шулчак алар янына бер карчык килде.

— Кайчан аласыз инде азатыгызны арбадан? — диде ул кыю вә әрсез рәвештә азатларны шаккатырып.

— Йөрмә әле монда, убырлы карчык, эч пошырып!

— Иртәгә азатыгыз алмасагыз бу арбадан, баһадирыгызга әйтеп артыгыз каезлатам мин сезнең!

— Күр әле моны, Буранай, ни сөйли. Дошман баһадиры хатынына урын тармы, бер арба житмиме! Бар юлыңда бул, убырлы карчык! — Азат торып басты. — Күрәсең менә бу куй канында кайнаткан камчыны!

Карчык азат кулыннан камчыны тартып алды һәм елгага ташлады. Азат ачкан авызын ябалмыйча тәмам югалып калды.

— Минем белән хан сәүдәгәре Биккол баш иеп сөйләшә, ә син авызыңда анаң сөте кипмәгән нәстәкәй...

— Буранай, Буранай, — диде арбадан күтәрелә төшеп, меңбаш Артык. — Булышма карчык белән. Кил әле монда, төшәргә булыш.

Азат арба янына ташланды, ләкин аны карчык туктатты.

— Тимә меңбашка, кагылма! Ятсын. — Карчык Артык янына килде, чәченнән сыйпады. — Ят-ят, батыр. Син безгә комачауламыйсың.

Азат ни кылырга белми сикереп атына атланды, китәргә итте. Карчык ялт итеп борылды да аның ат башыннан эләктереп алды.

— Кая болай китәргә исәбең, азат? Төш әле, төш атыңнан!

Азат атыннан төшмәде, ат исә пошкырына-пошкырына артка чикте. Карчык әче итеп сызгырып җибәрде һәм ат башын җибәрде, ат исә котырынып чабып китте. Икенче азат аның артыннан:

— Гатаулла, Гатаулла, тукта! — дип кычкырып калды.

— Нигә аңа кычкырасың, әйләнер дә кайтыр. Икенче тапкыр олы кешене рәнҗетмәс. Учагыңны кара әнә, утын ташла, — диде карчык һәм янә арба янына килде. — Ә син йокла. Йокла-йокла, бернәрсәгә дә игътибар итмә, — дип карчык торып утырган ананы тынычландырырга тотынды.

— Мин куркам алардан, куркам, — диде хатын. Азат исә аның төрки телдә сөйләшүенә аптырый калып, арбага якын ук килде.

— Безнең телне белә икән үзе!

— Татарларның кайберләре төрки телдә сөйләшәләр, балакай. Ни эзләп бирегә килгәннәрдер, бер алла үзе белә.

— Елыйсың тагын. Елама, күзең бетермә дидем түгелме мин сиңа. Балаң исән, үзең исән.

— Белмим, ни өчендер елыйсым килә, үкерепләр елыйсым килә. Сөярби әбекәй.

— Елый алсаң, күңелең бушаганчы ела да тынычланырсың. Тик кем өчен еларга исәбең?.. Баһадирың өченме?.. Ул сине кемнән алды, нә бирep?..

— Ул мине ярatты, Сөярби әбекәй...

— Ярaтты,— диде Сөярби карчык.— Яратты. Котсыз ул, имансыз һәм шәфкатьсез. Сине яратты, башкаларны кылычы белән урталай ярды. Аннары аның илендә хатыны бар икән. Хәер, ул хакта сиңа үзе әйтте бугай.

— Исән калдымы икән соң үзе?

— Эткә нә булсын, яраланган, кишектиннәре коткарганнар, диделәр. Бер шул дәҗҗални коткару өчен меңләгән кишектине орыш кырында ятып кала.

Хатынның күзләре мөлдерәп яшь белән тулган, ул баласын күкрәгенә кыскан да як-якка чайкалып, ни турындадыр уйлап утыра. Учак яктысында аның кара чәчләре аксыл тәскә керә һәм бу хәлгә шаккатып карап торган азатка чибәр хатын Сөярби карчыкка охшап китә.

— Синең баһадирың койган канны җыйсаң, күл булыр иде. Юкка җан атып утырма. Балаң имез дә ят,— диде карчык һәм хатынны яткырып, үзе меңбаш Артыкның өстен рәтләде, тире юрганын ян-ягына кыстыргалады.

— Әби, меңбашка берәр нәрсә кирәкмиме икән?

— Синең баһадирың, азат, иртәгә үк аякка басачак, аллаһы боерган итсә. Шушындый гүзәл хатын янында үлгән кеше терелер.

— Рәхмәт, әбекәй,— диде Артык.

— Әнә сөйләшә дә башлады, алланың рәхмәте. Кымыз бир син аңа. Кымызың бармы?

— Табарбыз аны, нигә тапмаска,— диде азат һәм кай тарафкадыр китеп барды.

— Сөярби әби,— диде хатын.— Ә ул сине нигәдер яратмады.

— Мине генә түгел, ул сине дә яратмады. Нәфесен тыю өчен генә тотты ул сине, юкса кылычтан уздырган булыр иде.

Хатын янә лышык-лышык елап ятты.

— Ба-а-ла-ны я-р-ат-кан и-иде-е...

— Яраткандыр инде, ярaтмый ни. Аңа орыш булсын. Җәбәй нойонны Болгарга керергә кем котыртты дип беләсең. Синең Сүбәдәең, корты коргыры. Әлдә җитмәсә: «Син кыпчак карчыгы, кара аны, Карлыгач кыз тапса, аягыннан арба тәртәсенә асып куям»,— дип янады. Кыз тапкан булсаң, асып куйган да булыр иде, бугазына сөяк кадаласы адәм, иблис токымы. Бер утырганда бер сарык ашап бетерер, майлы кулларын итек кунычына сөртер, шул куллары белән балага үрелер, эт кебек кан эчәр иде.

— Мин әүвәл аның белән аңлаша да алмый идем, соңнан тәрки телендә сөйли башлады. Үлтергәннәрдер инде аны, Сөярби әби?

— Кылыч корбан сайламый. Син исән, балаң исән, куанасы ит. Үзең күрдең орыш кырын, күз күресе мәет белән тулган иде. Әнә әле булса җыялар. Олуг хан болгарларны хөрмәтләп күмәргә, дошманнарны бүреләргә калдырырга кушты. Тагын арта икән кеше ашаучы бүреләр. Ул Сүбәдәеңне әйтәм, татар сүзен җирәнеп әйтер иде, янәсе ул мәлгүн, сасы козән. Татарны җиңдек без, дип мактанып иде. Ә үзенең түбәнендә һәр өченче азаты татар иде, җитмәсә әнә үлепләр татар кызын яратты. Сине, син диванананы. Ничәмә тапкыр пычак белән кадасы иттем, әллә нигә кулым күтәрелмәде. Көчем җитмәс дип, бәласе сиңа да кагылыр дип.

— Болгарга керәбез дә шаһ кызын алып, Олуг Мөхәммәт иленә китәбез, дип авыз суын корытыр иде. Тәңре язмаган булгандыр, күрәсең.

— Шаһ кызы аның өчен сылтау гына, кәсебе ил талау бит аның. Болгарның байлыгы турында ишетте ул, сәүдәгәрләр җиткереп торды. Шуннан күзе кызды. Үз башына ашкынган икән. Килә, күрә, җинә. Җиңдең әнә!

— Далада үлеп каласын күз алдына да китермәгәндер шул...

— Куй әле шуны, эчем пошырма. Беләсең килсә, мин аңа әйткән идем инде шаһ кызының суга батып үлүе турында, сәүдәгәрләрдән ишеттем, дип әйтеп әйттем. Ышанмады, үзе сорады. Алар да минем сүземне куәтләгәч, миңа: «Әгәр дә мәгәр бу хакта Карлыгачка әйтсәң, авызыңда бер тешең калдырмам»,— дип янады. Курыкмадым, минем авызымда болай да рәтле теш калмаган инде...

* * *

Иртән Артык уянганда кояш чыккан иде инде. Уянуы булды, бер азаты аңа касә белән кымыз китерде.

— Эч, меңбаш, эч-эч, мин аны күп итеп алып килдем.

Карчык уянды, күзләрен киң ачып, касәдән кымыз эчкән меңбаш Артыкка карап торды. Аннары авызын да каплап тормый киң итеп иснәде дә:

— Миңа да салып китер әле кымызың, азат,— диде.

Азат карчыкка да кымыз салып китерде. Карчык башта авызын чайкап алды, аннары сулыш та алмыйча бер касә кымызны эчеп куйды.

— Тагын салып биримме, әбекәй?

— Миңа җитте, ә менә яшь анага ярап торыр,— диде карчык һәм Карлыгачны селкетергә тотынды. Хатын йокламый икән инде, торып утырды, иплән кенә арбадан төште, елга буена төшеп, юынып менде. Юынып, йөзен ачыбрак яулыгын бәйләгәч, җитмәсә кымыз биргән егеткә мөлаем итеп елмайгач та хатын алиһәләргә охшап китте. Аннары ул агач савытларга салып, һәммәсенә дә ит бирде, касәгә шулпа койды.

— Ә меңбаш һаман йоклый,— диде ул акрын гына.

— Йокласын, батыр йоклап сихәтләнә,— диде карчык, авызындагы итне тешсез көйгә әле бер якка, әле икенче якка әвәләп. Хатын баланы имезде, күкрәген яшерә-яшерә бер читтәрәк томыраеп үзенә карап торган азатка күз ташлап алды.

— Баланы меңбаш йөзенә китер әле,— диде карчык.— Китер, китер. Кагылсын. Бала исен тойсын. Нарасый бала исе үзе дәва ул. Тырма әле шул меңбашны, Ташбай, тырма битен. Уян, батыр, диген.

Азат арба янына килде, кызыксынып карап тора башлады.

— Азат, хатының бармы, өйләндеңме, буйдакмы буй салып йөрисең? — диде карчык.

— Мин яшь әле, Сөярби әби. Яңа унҗиденче языма аяк бастым.

— Дәү икәнсең инде, дәү икәнсең. Өйлән менә бу Карлыгачка. Баласы да бар, чибәр дә. Йә, оялып торма инде, әйтер сүзеңне әйт. Ошадымы Карлыгач?..

— Чибәр,— диде, ниһаять, азат.— Ошады.

— Ошагач, бар, очлымың ки дә, чишмә белән киңәшеп кил. Бар, бар, су буена төшеп киңәш.

Азат карчыкның сүзенә ышанырга да, ышанмаска да белми, әле Карлыгачка, әле карчыкка карап торды. Аннары кинәт кузгалды да елга буена йөгереп төшеп китте.

— Мине нишләтерләр икән, Сөярби әби? — диде хатын йөгереп елгага таба төшеп барган азатка карап.

— Нишләтсеннәр, йә хан сараенда яшәрсең, йә кияүгә бирерләр. Синдәй чибәр затка ир табылмый буламы...

— Кем алсын мине, Сөярби әби. Балам бар, ил-кырым ерак, атам-анам юк.

— Сөйләмә юкны. Бала артык буламы. Балалы хатынның бәһасе бермә-бер артык була торган иде. Хәзер, хак анысы, хатын-кызны сатуалу тыела, әмма алырга теләгән кеше җаен таба ул.

— Мин куркам, болгарлар төркиләр булсалар да, мөселманнар икән ич. Өч-дүрт хатын белән торалар, ди.

— Кем өч-дүрт хатын белән тора, кемгә бирәү дә тими. Ашатаэчерә, киендерә-карый алсаң дүрткә кадәр өйлән... Ирек ул хакта, ирек.
—Сәнеч шаһ кызын Рабига Илһам хан угланы Булатка өченче хатын булып килгән иде. Язмаган булгандыр, күрәсең...

Ниһаять, меңбаш Артык уянды. Бертын тик ятты. Янәшәсендә генә чит яклардан килеп, әсир ителгән хатын бала имезә. Артык күзләрен ачкач, хатын аңа карап-карап торды да үз итеп елмайды, хатынның бит очларына «кәҗә тоягы» кунды, кашлары калтыраныи китте. Артык балага таба кулын сузды, хатын ашыга төшебрәк читкә тайпылды.

— Курыкма, мин сиңа тимим.

— Мин синнән курыкмыйм, батыр. Мин сине аттан ектым, ә син...

— Булды андый хәл,— диде Артык һәм торып утырды.

— Меңбаш торды, меңбаш торды! — дип учак тирәсендә маташкан азат аның янына килде.

— Миңа арбадан төшәргә ярдәм ит, Буранай.

— Ә сиңа, меңбаш, торырга ярамый,— диде арбаның түр башында утыручы карчык.— Калдыр меңбашны. Артыкмы әле атың. Калдыр Артыкны, азат. Китер бер касә кымыз. Китер-китер...

Азат Буранай бер касә кымыз китерде, меңбаш Артык аны эчте дә янә ятты. Меңбаш йөзенә кагылды һәм бармакларын иснәштерде.

— Әллә каян бала исе килә.

— Киләдер,— диде карчык көлемсерәп.— Менә кем сине уятучы — Ташбай. Йөзеңә кагылып-кагылып алды. Уян инде, батыр, диде.

— Табиб килә! — диде икенче азат.

Бер көпчәкле арба белән табиб килеп туктады. Исәнләште, Артыкның хәл-әхвәлләре хакында сорашты, аннары арбадан төшереп, киез җәеп, җиргә салырга кушты. Азатлар табибнең һәр әмерен җиренә җиткереп үтәп тордылар. Табиб Артыкны бөтенләй чишендерде, әйбәтләп һәр әгъзасын капшап чыкты, авызын ачтырды, күз кабакларын тартып карады. Аннары нindидер сыекча белән кай җирендер уды, шап-шоп суккалады, дару эчерде. Ахыр киендерергә кушты һәм аягына бастырды.

— Хәзер әкерен генә үзең үк арбага барып ят,— диде.

Артык чайкала төшебрәк арбага таба кузгалды, килеп җитте, урәчәгә тотынып торды һәм менеп урнына ятты.

— Иртәгә аякта буларсың, меңбаш,— диде табиб һәм атына солы ашатып торган азатка рәхмәт әйтеп, арбасына утырды да китеп барды.

— Бүген өйләдән соң Болгарга кузгалабыз, әзерләнеп торыгыз! — дип кычкырды табиб китеп барганда.

— Без җыенган, безгә җыенасы юк,— диде карчык, аннары меңбаш Артыкка: — Сине тагын бездә калдырдылармыни инде? — дип, әйбер-караларын җыештыра башлады.

— Атларны тотып китерә торыгыз,— диде Артык азатларына.

— Хатынының бәхете бар икән, меңбаш Артык,— диде карчык.— Бәхете аягына урала икән.

— Минем хатыным юк, Сөярби әби. Мәхрүм мин ул яктан.

— Бәрәкалла, өйлән менә Карлыгачка! Билләһи дим!

Артык хатын ягына күз сирпеп алды, көлемсерәп куйды. Хатынның йөзенә гүя ал комач капладылар.

— Ә нигә өйләнмәскә — өйләнәм.

— Күзең төшкән кызың бардыр әле. Меңбаш башың белән?..

— Менә анысы юк, Сөярби әби. Бер бабай миңа: «Балам, тозы булса, кызы булыр»,— дип әйтеп әйткән иде. Тозым да бар юкса...

— Карлыгач, йә, уйла. Тартып алучы юк. Үзең шул хәлгә төшердең, үзең дәвала да. Үлепләр яратсаң — терелер ул. Мәхәббәттә мең дәва бар, ди.

— Мин аңа барыр идем, Сөярби әби. Көлмәсә...

— Әнә күрәсеңме ни ди, меңбаш Артык, үзеңне теге дөньяга озата язган хатын. Килеш, соң булып куюы бар.

— Мин көлмим, Карлыгач. Кайбер сүзләреңне аңлап житкермәсәм дә иманым камил, син начар хатын түгелсеңдер.

Меңбаш Артык хатынның кулын тотты, йомшак кына итеп кысты, күзләренә карады. Хатынның күзләре мөлдерәп яшь белән тулган иде.

— Мин ничәмә төн синең өчен ут янып ятам инде, үләрсең дип котларым алынды...

— Тиз генә үлмим әле мин, Карлыгач, үлмим әле.

— Ул Болгар дигән калагыз еракмы соң?

— Өч-дүрт көн кайтасы булыр.

Ул арада сөрәнчеләр атларны җигәргә, юлга чыгарга дип сөрән сала башладылар. Азатлар атларны җиктеләр, кузгалып та киттеләр.

Хатын баланы кулына алды, тартына-ояла гына күкрәген чыгарып имезә башлады. Артык, үрелеп, баланың кулын тотты, уч төбендә әвәләде. Нәни генә кул, гүя, аның йөрәгенә килеп тоташты. Әллә ниткән хис күңелен хушландырып җибәрде, үзе дә аңламаган бер тәэссоратка бирелеп, баланың кулын үпте, бертын нәнинең кул исен тоеп торды.

Ләкин аркасына әйләнеп ятуга, Җик Мәргән баһадирның ошбу хатын ханга кирәк, дигән сүзе исенә төшеп, колакларына кадәр гөжләп китте, зиһене чуалды; хан Карлыгач белән кызыксынган? Нигә ул аңа? Димәк, ханның бер-бер уе бар. Өйләнәм дигәндә дә ул аны аңа бирмәс?.. Хикмәт, колак чыңлый, дулкын-дулкын булып, йөрәк сулкылдап куя.

* * *

Менә икенче көн кайталар инде, Артык арбадан төшеп атлап та баргалады, әмма буыннарда һаман да ныклык юк кебек әле. Ләкин җаны тыныч, Карлыгач аңа карый да елмая, карый да елмая. Үткән төндә битенә кагылды, сыйпады, назлады. Артык бөтен тәнендә ниндидер тетрәү тоеп ятты. Иделне кичкәч, алар янына табиб килде, Артыктан хәлен сорашты. Һәм арбадагы Карлыгачны күрде дә:

— Бу кем? — дип сорады.

— Хатыным,— диде Артык һич тә икеләнмичә. Аның бу сүзеннән түр якта утыручы Сөярби карчык көлемсерәп куйды, ә балалы хатын ни кылырга белми аптырап калды. Хатынның күзләре яшь белән тулган иде.

— Һэ,— диде табиб,— Яхшы. Терел. Мин киттем.

Туктады, кире килде һәм Артык колагына:

— Татарлардан әсир итеп алдыңмы әллә? — дип сорады.

— Юк, мәлгүннәрдән.

— Димәк, нойон хатыны. Нойоннар гына үзләрен мәлгүннәр дип йөриләр. Әсирләр арасында да барлар алар. Йә, хуш!

Болгарга якынлашкан көндә алар янына Җик Мәргән баһадир килеп туктады. Килер җайга сикереп төште дә, арба үрәчәсенә аркасы белән сөялеп торган Артыкны кочаклап алды.

— Котны алдың. Яраланган дигәч, котны алганнар иде. Исән икәнсең. Кичер, килә алмадым. Саксинга кадәр мәлгүннәрне кудык. Алар да кача белә икән, юл буена мәет тезелде. Хатынны да әсир иткәнсең икән. Котлыйм!

— Мин аңа өйләнергә булдым, баһадир!

Башта Җик Мәргән һични аңламый әле арбада утырган хатынга, әле меңбашы Артыкка карап торды, ахыр көлеп җибәрде.

— Болгарда кызлар беткәнме, Артык! Әсир төшкән балалы хатынга өйләнмәсәң, тузга язмаганны!

— Мин өйләндем инде аңа, баһадир.

Җик Мәргән читкәрәк китте, арлы-бирле йөренеп килде.

— Йә, куеп тор әле аны. Хәлең ничек соң?..

— Менә күрәсең, басып торам.

— Йә-йә, мин шат. Тиздән Болгарга җитәрбез. Халык көтә ди анда. Мине хан дәштергән, шунда чабуым...

— Туктарга, туктарга! — дип кычкыра башладылар сәрәнчеләр.

Азатлар атларны тугардылар, утларга җибәрделәр, казан астылар.

— Сезнең ашны көткәнче,— дип карчык арбадан төште һәм ике савыт алып, бавырчылар янына китте.

Артык Карлыгачка карап торды-торды да:

— Сиңа исемне кашларыңа карап биргәннәрдер, очып китәрләр сыман,— диде.

— Син мине якла, Артык бәгырь, якла. Мине әллә кемнәр алып китәр. Берәүгә дә бирмә, мин сиңа тугры хатын булырмын...

— Мин сине берәүгә дә бирергә җыенмыйм, Карлыгач.

Артык хатынның биленә кулын куйды, йомшак кына үзенә табарак тартты, битеннән үпте.

— Сөярби әби син хан әсире дип әйтә.

— Мин сине ханнан сорармын, Карлыгач. Кирәк икән алдына тезләнермен.

— Мин сине яратырмын, Артык. Син минем мәлгуннәр белән орышта һәлак булган абама охшагансың. Ул да синең кебек тәвәккәл иде. Ул да шулай аттан егылып ике көн буена урында яткан иде.

— Синең илеңдә беркемең дә юкмы?

— Безнең кавемне мәлгуннәр кырды. Мине әсир итеп алып киттеләр. Аннары мөселманнарга саттылар. Әнә шулай Хәрәземшаһ сараена эләктем. Шаһ кызы мине үзенә асрау итеп алды.

— Ә мин артык бала булып туганмын, шуңа Артык дип исем кушканнар.

Көлештеләр, бер-берсенә сыенып, тән җылыларын тоеп тордылар.

— Битеңнән үбим әле, Карлыгач.

— Бала күрер бит. Күрмисең карап ята. Мин сине үзем үбәм.

Хатын меңбашның битләреннән, иреннәреннән үпте.

— Мин сине яратырмын, Карлыгач, Ташбайны да...

Хатын елый башлады, тыела алмас булды. Артык аның аркасыннан сөйде, битләреннән үпте, иреннәрендә тозлы яшь тоеп, ни кылырга белми үрсәләнде.

— Һәй, нишлисез сез анда! Күр инде боларны. Яннарыннан китеп торырга да ярамый башлады,— дия-дия Сөярби карчык ике чүлмәк аш китереп куйды.— Төшегез, ашап алабыз, тары үрәсе китердем. Ит чиләктә.

Артык бераз тартыныбрак ашап утырган Карлыгачка күз төшергәләп алгалады. Ул хәзер аңсыз тора алмас, кайткач та никах укытыр һәм оста Дәүраннан өй салдыртыр. Акчасы булыр, мәлгуннәр бөтен җыйган байлыкларын ташлап качтылар. Илһам хан ул байлыкларны орышта катнашкан азатларга өләшергә вәгъдә иткән. Хак булыр, иншалла.

* * *

— Кайталар, кайталар, кайталар! Җиңүчеләр кайта, җәмәгать! Җиңүчеләр кайта!..

Кирмән-каланың капкалары каерылып ачылган, асма күпер төшерелгән. Алдан башкалага тимеркүк айгырга атланган Илһам ханның ат тоягы төште. Хан өстендә хәрби кием, башында алтын йөгертелгән очлым, түбәсендә тутый кош каурыйлары җилферди. Ат маңгае, күкрәк тирәләре тимер каплагычлар белән капланган. Ханның ике ягында ике җансакчысы, икесе дә бер ат башына кала төшеп килә. Алар артыннан ук Бачман баһадир белән янәшә Җик Мәргән килә. Капканы кергәч Илһам хан кулын күтәрде.

— Илһам ханга дан, Илһам ханга дан! Җиңүчеләргә дан! — дип кычкыра башлады халык. Ахыр: «Дан, дан, дан!» — дип тәкърарлауга күчтеләр. Тора-бара бу тавыш тоташ кайтавазга әверелде, кала урамнарын үтеп, Ага-Базарга җитте, мәхәлләләргә таралды.

Дошманны җиңеп кайтучы гаскәриләр узгач, орыш кырында яраланган азатларны алып кайтучы олаулар үтә башлады. Хатын-кыз, бала-чага, ир-атларын, ул-егетләрен эзләп, арбаларга ябырылды. Арбалар буйлап: «Таһирҗан, Җангәрәй, Бикбулат!» — дип кычкырып баручылар ишәйде.

Исән калган ирләрен, улларын, сөйгән егетләрен күрү куанычыннан елашкан халык төркеме белән гыйбрәт кылып йөргән Кол Гали: «Әсирләрне куалар, әсирләрне куалар!» — дигәч, алдагы төркемнән калып, капкага таба китте.

Халык әсирләрне тавыш-тынсыз гына каршы алды. Әсирләрнең күбесе яланаяк, кайсы баш киемсез, кайсы өс киемсез иде. Сөрәнчеләр халыкка Илһам ханның әмерен җиткергәннәр иде инде: әсирләрне халык хөкем итәчәк. Әсирләр җиңелү гарьлегеннәнме, башка бер-бер сәбәп беләнме, халыкка күтәрелеп карамыйлар, аска караган килеш атлый бирәләр. Дошман булгангамы, әсирләр берсеннән-берсе ямьсезләр сыман: кысык күзлеләр, җәйпәк йөзлеләр, чәчләре иңнәренә төшеп тора, кыска муенлылар. Чи тиредән тегелгән итекләре чәчкә аткан — тетелгән, җәяү йөрергә өйрәнмәгәнлектәнме, аякларын көчкә сөйрәп атлыйлар. Җиңелүгә өтәләнеп калган әсирләрне күп илләрне яулаган җиңелмәс гаскәриләр итеп күз алдына китерү кыен иде. Ләкин әсирләргә тамаша кылырга килгән халык арасында алар яулаган илләрдән Болгарга күчеп килүче мөһаҗирләр дә бар иде, аларның күбесе мәлгуннәрнең яманлыкларын үзләре күргән, шуңа күрә, арадан бер мөһаҗир әсирнең берсен эләктереп алды да егып салып тукмый башлады, әсирләрне саклаучы азатлар аны мөһаҗир кулыннан көчкә аерып алдылар һәм әрсезләнеп киткән халыкны:

— Якын килмәскә, якын килмәскә! — дип сөңге-камчы белән читкәрәк куа башладылар.

— Каһәр аларга, каһәр бәдбәхетләргә! — дип кычкырды халык.

Күп илләрне яулап, беркайчан да җиңелү белмәгән, ниһаять, Болгарга килеп җиңелгән һәм меңәрләп әсир ителгән мәлгуннәрне күпозын мәхәлләдән-мәхәлләгә йөрттеләр. Әсирләрнең сусаудан иреннәре чатнап ярылды, күпләре чарасыз калып, аяк астындагы күлләвекләрдән ятып су эчте, ачлык белмәгәннәре бала-чага ташлаган ипи кисәкләрен тузанын-комын да өрмичә авызына капты. Гаҗәпләнмәслек тә түгел иде, күптән түгел генә үзләрен гаять дәрәҗәдә горур тоткан, көтү-көтү мал йөрткән, ит-ризыкның кадерен белмәгән сугышчыларның бик тиз рухлары сынган, түземнәре җуелган, өметләре өзелгән иде. Алар өчен бу халык ят вә чит иде. Әсирләр бала итәкле, нечкә билле күлмәк кигән, муенына гәрәбә төймә таккан, толымнарында көмеш тәңкәләр зеңләгән, башларында алтын җеп белән чигелгән калфак булган хатын-кызларга кызыгып карадылар. Әле кайчан гына алар шундаен ак йөзле чибәрләрне бауга тезеп Чыңгыз ханга озатырлар иде, ә кайберләрен ай-ваена карамыйча яткырып көчләрләр иде. Хәзер әнә тәңреләре алардан гүя йөз чөерде — шул хатын-кызлар аларга җирәнеп карап торалар, ә кайберләре кыяфәтләреннән куркып, гүзәл йөзләрен күзләрен генә калдырып каплыйлар иде. Әсирләр өчен бу халык чынлап та ят иде. Нindидер тәрәзә капкачларына кадәр нәкышланган агач йортларда торалар. Киез юртада туып, мал-туар арасында аунап үскән, ачык далада җәйли-җәйли гомер кылган, мал асрап көн күргән, кымыз вә аракы эчеп бәйрәм иткән халык өчен урман-елгалы төбәкләрдә яшәгән халык чын мәгънәсендә ят күренгәндер. Аларга һәр җирдә:

— Татарларга каһәр, татарларга каһәр! — дип кычкырдылар.

Бу хәлнең Болгарда булганы юк иде әле. Болгарлар әсирләрне беркайчан да урамнарда халыкларга тамаша кылдырып йөртмәделәр. Хан аларны йә үз әсирләренә алыштырыр, йә өйләндереп, авыл утыртыр иде.

Кол Гали көнозын диярлек әсирләр артыннан йөрде. Күңелендә үзе дә аңлап житкермәгән ярсу иде. Ул әсирләр арасыннан күңеленә мәңге сеңеп калган, йөрәгенә җөйләнмәс яра салган мәлгун унбашын эзләде. Ачулы иде ул аңа. Өргәнечтән Болгарга сәфәр чыккач, аларны мәлгуннәр куып житте. Олауны туктаттылар. Бар булган байлыкны таладылар. Кол Галинең кульязмаларын алып киттеләр. Хан сәүдәгәре Биккол кулыннан шаһ кызын тартып алдылар. Биккол мәлгуннәргә ялынып-ялварып та карады — күрмәделәр дә, ишетмәделәр дә. Инде киттеләр дигәндә мәлгуннәрнең унбашы бер читтә басып, йөрәге янып торган Кол Гали янына килде. Атыннан төшми генә бермәл аңа ирен чите белән генә елмаеп карап торды. Аннары кылыч очы белән генә бүреген элеп алды да очыртып, урталай ярды. Кол Гали кымшанмады да, йөзендә бер эгъзабуыны да зеркемәде. Шуннан унбаш кылыч очы белән аның җилән бауларын кисте, күкрәгенә кылычын терәде. Кол Гали артка тайпылмады, унбашның аягына төшмәде. Аның каравы бу хәлне күреп алган Биккол унбашның аты алдына тезләнде, түшеннән янчык чыгарып сузды. Унбаш янчыкны кылыч очына элеп кенә тотып алды, авырлыгын чамалап карады. Канәгать калды, күрәсең, атын борды да китеп барды.

Кол Гали аның артыннан күздән язганчы карап калды. Ул аның йөзен, күз карашын, чыраендагы һәр буын-эгъзасын күңеленә сеңдереп калдырган иде.

Менә ни өчен ул көнозын әсирләрне озатып йөрде, әле алларына чыкты, әле артка калды. Унбашның йөз-кыяфәте әле булса аның күз алдында иде: сирәк тешләр, бүлтәйгән яңаклар, борыны юк хәлендә, күзләре кебек борын тишекләре алга карап тора.

Бүген әнә шул җиңелү белмәс сугышчылар Болгардалар. Аяк атлар җайлары калмаган, кикрикләре шиңгән, канатлары сәлперәйгән, берәүгә дә күтәрелеп карарга базмыйлар.

Кол Гали янына Биккол килде.

— Кайтыйк булмаса, житәр,— диде.

— Мин, Биккол атам, теге...

— Ул монда юк, булса мин дә аны таныган булыр идем, каһәр төшкәнне.

Әсирләрне хан мәчете янында туктаттылар. Халык җыелды, халык җыелды. Шунда Кол Гали якында торган арбага сикереп менде дә:

— Татарларга каһәр, татарларга каһәр! — дип кычкырды.

Халык аның сүзен элеп алды, барысы да: «Татарларга каһәр, татарларга каһәр!» — дип кычкыра башлады.

Тик ул чакта, киләчәктә бөек болгар-татар шагыйре исемен алган Кол Галигә белергә идеме: гасырлар үтеп, көтмәгәндә, аның үзен дә, халкын да ТАТАР дип атарлар дип...

Ә миңа, бу хакта тарихи әсәр язучыга, болгар халкының бөек шагыйре Кол Гали әле булса Болгар каласы урамнарында мәлгун әсирләрен озатып йөридер һәм: «Татарларга каһәр, татарларга каһәр!» — дип тәкърарлыйдыр кебек.

*Казан — Өргәнеч.*
*1980 — 1990 еллар.*

# ШИГЪРИЯТ



## Рифкать Закиров

### ГАМЬЛЕ МОҢ

ШИГЪРИ КЫЙССА

### Беренче бит

Күңелемдә минем йөри бер моң,—
Жанның тынып торган чагы юк.
Жиргә, гүя, юри килгәнмен мин
Яшәр өчен жирсеп, сагынып.

Киң дөньяда ник бер минем генә
Күкрәгемне сулыш-тын кыса?!
Юк, тын кысмый, ярсу йөрәгемне
Һәм жанымны сагыш-моң коча!..

Куяр урын тапсам мин башымны,
Кояр идем тамган яшемне...
Кем дә белми минем хәлләремне:
Яшәдемме жирдә, яшимме?..

Яшәмәдем, дисәм, адәм көләр,
Яшим, дисәм, әрнеп жан елар;
Сәерләрне аңламыйлар күпләр,—
Шагыйрь жанны аңлый алмыйлар.

Тик аларга карап, бетмәс ярап
Бәхетләрем минем ким, дисәм:
Бөтен дөнья сыя кочагыма,
Кояшы да сыяр... үрелсәм!

---

Рифкать ЗАКИРОВ (1938) — *шагыйрь. «Шахтер моңы», «Ай сөярмен, ел сөярмен», «Йөрәк уты» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Дәрьяларга төшсәм — күмелмим мин,
Асылынмыйм күккә — күк түбән!..
Оттырдыммы, белмим, оттыммы мин
Күкрәгемдә зур моң йөртүдән?..

Илтеп салсам әгәр диңгезләргә
Тоташ моңнан торган җанымны,
Кайный башлар иде диңгезләр дә,
Хәтерләтеп ярсу канымны!!

Тау булып тау аңлар иде мине,
Терәк эзләп ташка таянсам...
Мин нур-моңга күмәр идем җирне,
Йолдыз булып күктә яралсам!

Шуны белә торып кем чыдасын,
Шушы чиккә җитеп кем түзсен!..
Хәлләремне минем кем сорасын,
Кемлегемне минем кем белсен?!..

...«Яна калъбем, уты сүнми»,— диеп,
Йөргән әбкәм төшә хәтергә;
Кеше хәлен кеше белми, диеп,
Калды хәзер миңа әйтергә...

## Икенче бит

Сабырлыкны ходай белеп бүлгән —
Кемгә артык, кемгә ким тигән;
Ятимнәргә аны өеп биргән —
Әллә якын, әллә чит күргән...

Мин дә ятимлекнең авыр йөген
Тарттым төяп арык иңнәргә;
Авыр булган саен сабыр булдым,
Тик сарысы чыкты йөзләргә...

Ятим бала... бөтен йомыш аңа,
Булган барлык авыр эш аңа;
Кая кушсаң, шунда чыгып чаба,
Һәм ни әйтсәң шуңа ышана...

Әмма күпме генә эшләсәң дә,
Һаман сәлкәү — һаман ялкау син.
Колхоз көн-төн аттай эшләткәндә
Булса икән тик бер яклаучың!

Бар белгәнем кара эш булды да
Яшел үлән суы — аш булды;
Аш түгел лә, күбрәк таш булды да
Күзгә мөлдер-мөлдер яшь тулды...

Еллар кара... Җирдә сугыш бара...
Ник тапмыйлар шуңа бер чара?!
Мин — бала, дип, эшкә чыкмый кара,—
Кешелектән чыгар бичара...

Колхоз, аяп, икмәк бирми майлап
«Коры таяк» хезмәт көненә.
Ул елларда кемнең нинди таяк
Ашаганын бүген кем белә?!..

Тизелдек тә эшкә ялландык без,
Өзелдек тә көчкә ялгандык...
Берәү бәхет эзләп читкә китсә,
Төяп кайтты илгә ямаулык.

Балачакның тик исеме калды,
Сары төсе калды күзләрдә...
Ай күрде дә аны кояш алды,
Бер төсмере калды күзләрдә.

Без тормышка килдек — утка кердек,
Булмады да кебек бала чак...
Ә шулай да булган икән алда
Чын утларда дөрләп янар чак.

## Өченче бит

Күңеле дә, уе, хәтере дә
Артык тирән икән ятимнең;
Күптән үткәннәрне мин әле дә
Бүгенгедәй ачык хәтерлим.

Әти белән бары ике тапкыр
Мунча кергән көнем исемдә:
Берсе — майның аяз иртәсендә,
Икенчесе — июнь кичендә.

Мунча күл буенда... Күл суында
Бака авазлары: ч-ү-р дә ч-ү-р...
Тәрәзәдә — кояш!.. Нурда гына
Коенып әткәй мунча кергәндер.

Һәм мине дә нурда югандыр ул,
Күкрәгенә кысып сөйгәндер.
Иң зур шатлык хисен тойгандыр ул:
«Таянычым — улым!» — дигәндер.

Тагын кердек: июнь кичендәме,
Юк, ахры, июнь төнендә...
Кулыннан ул мине төшермәде,—
Кул җылысын тоям бүген дә!..

Иртән китте әти яуга чыгып:
Дәү үс, улым, тиздән кайтам, дип.
Бер ел узды, өч ел, дүрт ел узды...
Килде бер көн соңгы хат-конверт.

Көтмәгәндә соңгы хәбәр килде,
Аяз көндә яшен шикелле;
Тәнне куырып, аңны суырып алды,
Җирнең астын-өскә китерде.

Җирнең астын-өскә китерде дә,
Асты, кисте, суйды, үтерде!
Кояш сүнде, гүя, ай кителде —
Өзгәләнде өмет, киселде...

Узды шулай күпме айлар, еллар,
Кайтасылар һаман кайтмады.
Саргайдылар уллар, олгайдылар...
Тол әниләр тәмам картайды.

Ата — улга, ул — атага терәк! —
Белер идем, кайтса, кадерен!..
Шуннан бирле үзен күрү түгел,
Күргәнем юк хәтта каберен.

## Дүртенче бит

Ничек көттек аны... өзелеп көттек,
Газапланып көттек, интегеп.
Көтә-көтә без өтелеп беттек,
Өс киеме бетте тетелеп.

Ач-ялангач йөрдек; башны иеп,
Борын тартып хәер сораштык.
Тик һәр өйдә сулган йөзләр күрдек,
Моңлы күзләр белән очраштык.

Әткәй киемнәре бар иде дә...
Тырышсак та күпме сакларга,
Берәм-берәм саттык очсыз хакка,
Үләм-үләм дигән чакларда.

Дәү әнием аның һәр киемен
Сөеп-сыйпап кына кузгатты,
Елап күз яшенә чылатты да,
Күз нурына төреп озатты...

Хәтерлим мин, соңгы ак күлмәген
Ничек кочып-тотып йөргәнен:
Мөмкин булса, ул күлмәкне түгел,
Бирер иде йолкып йөрәген.

Шул чагында аны кызганудан
Кара каннар сауды йөрәккә.
Үз кайгым да авыр, әбекәмнең
Хәсрәте зур икән бигрәк тә?!

Ул тәрәздән-тәрәзәгә килде,
Улын көтеп һаман тилмерде.
Тышта елап-улап эт өрде дә,
Моржаларда дулап җил йөрде.

Мондый кайгы-газапларга бары
Түзсә түзә фәкать чын Ана.
Шулай булган һәрчак, һәм булачак,
Бу хакыйкать — сына-сынама!..

Андый ана соңгы сулышкача
Түгәдер дә яшен, көтәдер...
Юл ачам, дип, балам кайта калса,—
Үрәдер дә чәчен сүтәдер.

Сагыш барда күңел көн дә боек,
Сулыш барда җанга тынгы юк;
Шул аһ-зарлар күңелемдә оеп,
Тел төбемдә йөри моң булып.

## Бишенче бит

Яраткан да ходай ут, балчыктан,
Безне тигез итми ялгышкан...
Ул ялгышкан, әмма мин ялгышмам,
Узмышлар юк, дисәм, язмыштан!

Бар иде бит минем гүзәл сеңелем —
Рузалия... роза чәчәге!..
Кырау тиде аңа — иртә шиңде,
Өч кенә ел җирдә яшәде.

Ачлыктан ул ашка пешеп үлде,—
Ашыккандыр җаны, күрәсең...
Зур табакка башта ул үрелде,
Сөт дип белде тары өйрәсен.

Кинәт шунда әллә нәрсә булды,
Таяндымы табак читенә,
Егылды да кайнар ашка чумды —
Табак ауды аның өстенә?!..

Арык кулларында — буш кашыгы,
Тирә-юньгә ашы чәчелде;
Иренендә — кайнар аш тамчысы,
Күзләрендә ачы яшь иде...

... Бу кайгыга әни ничек түзде,
Болай гына ничек чыдады:
Елады да эшкә чыгып китте,
Кич кайтты да тагы елады...

Юк шул, озак чыдамады әнкәй:
Ауды... торалмады өч-дүрт ай...
Күпме үлем сорамады әнкәй,—
Ярый, тыңламады бер ходай!..

Сеңелем үлгәч, озак юксындым мин,
Юксынгандай ятим бер бәбкә...
Каберенә чәчәк утырттым мин,
Үзен күмдем, гүя, йөрәккә...

Кемдер яши җирдә тормышыннан
Тәмам туеп, гарык булганчы.
Ә бит сеңел туя яшәү түгел,
Ашамады хәтта туйганчы.

Яшь һәм садә бер гөл күптән гүрдә...
Таш басса да, менә мин исән!
... Сикерсәң дә үлгәч гүрдән-гүргә,
Язмышлардан узмыш юк икән...

## Алтынчы бит

Күңелемдә тирән моң йөргәнгә,
Тел очымда тибри әйтер сүз...
Әни исән, мин әнисез үсәм,
Үсәм, димәк, әти-әнисез.

Әни көн дә эштә, төн дә эштә,
Мескенне юк юньләп күргән дә...
Эш атыдай аны колхоз жигә,
Чәчкән дә — ул, урган, сөргән дә!

Йә куалар торф чыгарырга,
Йә куялар урман төпләргә;
Җыелыш саен түргә чакыралар,
Үрнәк итеп аны күпләргә.

Һәм вәссәлам, шуның белән тәмам...
Нәрсә ашый, нәрсә киенә,—
Ул турыда белү-күрүче юк,
Килмәгәндә тентү өенә.

Бура түгел, кесә төбендәге
Бер уч арыш яки борчакка
Аз да түгел, әйе, күп тә түгел,—
Биш ел төрмә иде ул чакта...

Күрше апа шулай ярма ярып,
Әнисенә ботка пешертә...
Шуның өчен үзе Себер китә,
Яшь баласы кала бишектә.

Малайлары кала кайсы-кайда...
Берсе — кырда, берсе көтүдә.
Әле алар кайчан өйгә кайта,—
Түзеп тору да юк, көтү дә:

Милиция аны йолкып ала,
Селкеп сала тимер арбага.
Ак яулыгы аның төшеп кала,
Шомырт кара чәче агара!..

«Ил байлыгы — халык!» — диләр дә бит,
Аннан нинди файда кешегә?
Иген игеп ачка үләргәме,
Дип уйлаган, ахры, күрше дә...

Эшләмичә, әйе, ашап булмый,
Ашамыйча яшәп буламы?..
Чоры шундый, моны уйлап тормый,—
Үтәлсен тик дәүләт планы.

## Җиденче бит

Үтәсен, дип, колхоз үз планын,
Әниемнең ниләр кылганын,
Берәм-берәм әйтсәм бар булганын,
Үрә торыр хәтта колагың!

Кыш буена үз сыерын җигеп,
Туйдырды ул колхоз малларын.
Үшән үгез белән сабан сөреп,
Уздырды ул яшьлек язларын.

Аты булса, ерак юлга йөрде,
Ат арыса, үзе җигелде;
Ат егылса, ялгыз тартты йөкне,
Андый чакта... ят та үл инде!

Андый чаклар әмма аз булмады,
Баштан ниләр генә узмады!..
Күпме атның җене өзелмәде,
Әнкәй-җаным түзде, чыдады!

Аты үлгәч, аның Бакалыдан
Җәяү кайткан төне хәтердә:
Караңгы төн... тоташ кара урман...
Мин калтырап куям хәзер дә.

Орлык ташыганда, ташуларда
Бозлар белән бергә акты ул;
Башын ташка бәреп ташлы ярда,
Җан тырмашып өйгә кайтты ул.

Ул тезләнеп кырда арыш урды,
Кич ындырда ашлык суктырды.
Колхоз аны чыбыркылап куды,
Бер урында үзе тик торды.

Колхоз торды... Әмма халык китте,—
Шәһәр йотты авыл баласын...
Ә әниләр калды, белә торып
Гомерлеккә ялгыз каласын...

... Сабыр аналарга табына да,
Балаларын авыл сагына;
Очрамыйча калмый бер ана да
Һәр заманның авыр чагына...

Кабат тусам... мин әнидән башка
Яши алмас идем өч көн дә!
Ул ил йөген йөртте үз иңендә,
Үзе бүген урын өстендә...

## Сигезенче бит

Калды ерак... Калды, хуш-әлвидагъ,
Кыңгыраулы мәктәп елларым;

Тоела мина шулар якынрак,
Ераклашкан сиең юлларым...

... Чоры нинди — мәктәбе дә шундый...
Кан-суештан гарык — заманы...
Эчтә, гүя, арык, ач эт шыңшый,
Соңгы ыштан кырык ямаулы.

Ач баланың күзе — төпсез кое,
Күңеле боек аның — моң тулы...
«Уку» түгел, «ипи» бөтен уе,
Уйлый шуны озын көн буе.

Тик шулай да артык сынату юк:
Фән урләрен «яулап» җан-фәрман,
Кибеп-көйгән тәндә бары чыгып
Җиталмәгән ярты җан калган...

Көненә мең үлеп, бер терелеп,
Без йөрибез өшеп-күшегеп;
Кем вакытсыз кала өйдә үлеп,
Кем бәхетсез — килә шешенеп.

Күпләребез тишек чабатадан,
Яланаяк чаба кайсыбыз.
Утка баскан сыман яна табан,
Ап-ак карда яшьле-канлы эз.

Хәлләремне минем белде бары
Мөгаллимә апам — күз нурым:
Ач үлемнән мине йолып калды,
Күпсенгәндә күпләр... үз улын...

Аңа — шигырь... кызларга җыр яздым,
Качып кына яздым, качырып;
Әмма сер ачылып, чыкты даным,
Ашка пеште авызым... ашыгып!..

Зурлар көлде: «Син,— дип,— язарлыкмы
Шундый хатны? Син бит шыр надан!»...
Наданлыкмы?.. Гамил Афзаллыкмы —
Әйтә алмыйм моны мин һаман...

... Вакытында сүзне әйтмәвемә
Үкенеп, мин әйтәм өздереп:
— Без укыган авыл мәктәбенә
Рәхмәтемнән бүтән сүзем юк!

## Тугызынчы бит

Кечкенәдән шаян-жор булдым мин,
Ут борчасы белән бер булдым;
Яна-яна кыздым... суындым мин:
Эчтән — ялкын, тыштан боз булдым...

... Жиде яшьтә инде мин көтүче,—
Кырда җирсеп гомер итүче...
Бөтенесе истә: төтен исе,
Коры кизәк, җылы сөт исе.

Язгы ләйсән. Кәккүк тавышы. Урман.
Күкрәп койган җәйге яңгырлар.
Ялгыз тирәк. Сыек рәшә. Томан.
Күзге юеш, җепшек кар-бозлар...

Мактанмыймын, унбер яшь тулгач та
Атландым дип «менеп туратка»;
Юк, мин атланмадым туры атка,
Арба җиктем тотып бер атка.

Йөк тартканда шул ат текә үргә,
Кешни-кешни җиргә тезләнеп,
Ат кызганып, яшем белән бергә
Чәчри иде ике күздән ут!

Тик юаштан юан чыга диләр,—
Атым батса, алдым өстерәп!
Юл йөргәндә атлар, чыдам ирләр,—
Атка егәр, иргә көч кирәк!..

Безнең көч тә, хәл дә бер чамада,
Уртак булгач хак вә хокуклар...
Без ич Ир-Ат!.. Димәк, бер чанага
Җигелсәк тә парлап, хокук бар!

Парлап өздек күпме камыт бавын
Һәм туздырдык күпме ыңгырчак!..
Җигеп-җигелеп үтте балачагым,
Йөгереп килеп җитте үсмерчак.

...Кайсылары иткә, кайсы читкә
Китеп беткәч җиккән атларым,
Истә: түзәлмичә кайгы-хискә,
Шашар чиккә җиткән чакларым.

Шуннан бирле җикмәдем мин ат та,
Дилбегә дә хәтта тотмадым;
Яшьсез генә ат елаган чакта,
Күпме генә кан-яшь йотмадым?!..

## Унынчы бит

Күз алдыма килә үсмер чагым,
Көлемсерәп, сабыр елмаеп:
«Юксынырсың мине күпме тагын?
Гомер буе сабый булма!» — дип.

Сабыйлыгын сабый түгел дә бит,
Еш чумамын тирән хискә мин;
Юксынмамын диган идем дә бит,
Юксындыра икән, үскәнем!..

...Әле дә истә: җәйге айлы кичтә
Барып керәм арыш кырына;
Арлы-бирле атлыйм, әйтерсең лә,
Урын тапмыйм басып торырга...

Йә күмелеп тоныкай нурына,
Йә коенып якты сагышка,
Хәлдән таеп кайтам авылыма:
«Кайт, улым! Кайт!..» — дигән тавышка.

Арып-талып ятсам кич йокларга,
Төшләремдә күрәм һаман су,
Өннәремдә көп дә эш коткара,
Кичләр җитсә, үләм — ямансу!..

Аһ, ул аҗаганлы алсу кичләр...
Үзәгемне тәмам өзделәр;
Йөрәгемдә нинди ярсу хисләр
Дөрләвен тик кызлар сизделәр!

Җыелдылар көн дә безнең турга,
Шаярдылар чыр-чу килешеп;
Кушылмаган өчен мин уенга,
Таралдылар моңсу көлешеп...

Уйнау кая!.. Китә минем һушым,
Оялтканда чая ут күршем:
Киерә төшеп юри тыгыз түшен,
Күрсәткәндә юеш тел очын...

Яшь идем шул... мин кызларга гына
Кызыкканмын диеп йөргәнмен...
Ә чынлыкта, сусап чор ямена,
Чөмергәнмен туган җир гамен!..

Бу гадәттән әле дә арыну юк,
Бу халәттән ахры айну юк;
Бу гомерлек чиргә, димәк, җирдә
Мәхәббәттән гайре дару юк.

## Унберенче бит

Авыруы да бергә, даруы да...
Сөймәс җирдән, иркәм, сөярсең!
Сөярсең дә... дөрләп-көярсең дә,
Нигә сөйдем икән, диярсең...

Сөялерсең барып тал-тирәккә,
Дәрьяларга аннан багарсың,
Савылганда кара кан йөрәккә,
Дәваларын каян табарсың?

Дөнья ярып кычкырырсың шунда,
Сискәндереп җирләр-күкләрне.
Чыкмас тын да... Дөнья шул бу, дөнья,
Аңламыйлар күпләр... күпләрне?!

Үз утында үзең янарсың да,
Үз кузында үзең көйрәрсең...
Очкыннарың калса, аннан соң да
Очратырсың тагын берәрсен.

Һәм син дөрләп кабынырсың тагын,
Кабат көяр өчен шул утта.
Бер дә янып-көймәгәннәр, җаным,
Булмаган да җирдә һәм юк та!

Агуы да бергә, даруы да,
Тик кем белгән — кайсы күбрәк?
Кичерергә шуны, сыйдырырга
Бирәү түгел, кирәк куш йөрәк.

...Куш йөрәкле чагым, егет чагым,
Кылны ярыр чагым кырыкка!..
Күргәнем юк ләкин кыз кочагын —
Кызганыч та хәлем, кызык та.

Кызык: чүгеп-чүгеп биегәндә
Тыкырыкта яшел чирәмдә,
Кысып кулымнан да, билемнән дә,
Бөтерелгәндә кызлар тирәмдә.

Һәм кызганыч: әле бик тирәнгә
Керүләр юк, җитми кыюлык,—
Сүз белән дә кызлар, күз белән дә,
Үп! дигәндә... үбәм тыелып...

Их!..
Кызлар биле сыек тал икән лә,
Өздергәндә өзеп ал икән!
Сөйдергәндә сөеп кал икән дә,
Сөелгәндә сөелеп кал икән!..

## Уникенче бит

Егет чагым!.. Әле яшьлекнең дә
Һәм елның да нәкъ яз уртасы.
Әй, шул серле-моңлы май төнендә
Яр кочканны ничек онытасы!..

Тәнгә саулык булса, җанга сафлык,
Май төненең мәй күк һавасы!
Ала җанны телеп әллә сак-сок,
Әллә ялгыз күккүк авазы...

Гармун уйный кемдер сузып-сузып,
Төн диеп тә тормый, таң дип тә...
Ә мин, шыпырт кына, тыным кысып,
Торам посып куе таллыкта.

Пышылдый да, гүя колагыма,
Унда-сулда уйнап күләгә,
Чулт! итә дә шунда суга чума,
Әйткән сыман: «Юкка эзләмә...».

Охшаш үзе ул су анасына,
Ягъни гүзәл пәри кызына...
Ә карасам, суга бата-чума
Ай-йолдызлар гына коена.

Пәри түгел, көтәм күрше кызын...
Орчык хәтле генә шул кызчык,
«Син гаепле, диеп, күрше, үзең» —
Сихерләде тәмам, чукынчык!..

... Ә исеме аның Лүбә иде,
(Чын дөресе Люба булгандыр);
Мин оялсам, үзе үбә иде,—
Минем өчен генә тугандыр!

Минем өчен генә тугандыр да,
Өметләнеп, очып йөргәндер;
Минем өчен өшеп туңгандыр да
Минем өчен янып-көйгәндер...

Аның өчен мин дә үләр булып,
Әйтә идем: «җаным җәл түгел...»
Әмма язмыш чыкты юләр булып,
Әйтте үзе: «сез, дип, пар түгел!»

Бәхилләшеп... күршем, йортын сатып,
Китте читкә ерак-еракка.
Яшькә батып калдым мин озатып,
Мәңгелеккә, озак-озакка...

## Уночынчы бит

Ялгызлыкның, кимлек-ятимлекнең
Бар ачысын шунда тойдым мин...
Яр сөймәмен, диеп әйтмим, ләкин
Җан сөйгәнен мәңге җуйдым мин.

...Күршем китте... Яшьлек дәвам итте,
Йөрәк аша күпме кыз үтте;
Бер елатты алар, бер көлдертте,
Бер тилмертте — күпме тилертте!

Ир асылы идем мин, ахрысы...
Шуны гына әйтәм, фаразан:
Елмайдылар кызлар яшь аркылы,
Мин күз сирпеп, «тишеп» карасам.

«Кызлар биле сыек тал икән лә,
Сылу кызлар соеп кал икән...
Өйләнгәндә иң матурын түгел,
Акыллысын сайлап ал икән!» —

Диеп кенә җырлап йөргән чакта,
Кызлар сайлап алып кочакка,
Кемнәр белгән, керәм дип оҗмахка
Керәсемне тәмуг-учакка!

Күзне буды тиң яр... Узды туйлар...
Ә туйдан соң, диләр, дөмбергә!
Ә туйдан соң кемнәр гел бергә дә,
Аерылыша кемнәр гомергә...

Бер ел торгач, юравым юш килде:
Улым туды! Улым, ниһаять!..
Бәхет җиңде... Әмма язмыш килде:
«Былбыл кошым» итте хыянәт!

Әйтерсең лә, кинәт җире, күге
Кыл урталай шартлап ишелде!
Мин болай да күргән идем күпне,
Шулар җиткән иде ич инде?!..

Яратмаслык булгач мине үзең,
Бу дөньяга нигә яраттың?
Бармы әллә миндә берәр үчең,
Нишләвең бу синең, йа раббым?!

Белмәгәнмен шуны мин ни гаҗәп —
Менә нинди икән хыянәт!..
Юктыр җирдә (булса да кыямәт)
Хыянәттән дә зур җинаять!

## Ундүртенче бит

Сөю барда сөенеп яшә, бәндә,
Дөнья тормый һаман бер төрле.
Сөю мәңге үлми яшәгәндә,
Хыянәт тә озын гомерле.

Сөеп-сөешеп кал! Бу хәятта
Яшәү белән үлем бер рәттә;
Күпме кодрәт булса мәхәббәттә,
Шул ук көчкә ия нәфрәт тә!..

Сөю уты җирне нурга төрә,
Утка чорный нәфрәт ялкыны...
Әйбәте дә бергә, гайбәте дә —
Бар да уза йөрәк аркылы.

Йөрәк яна!.. Түзә барсына да,
Хыянәткә генә түзәлми:
Ярыла да чатнап, ачыла да —
Яралары озак төзәлми.

Хыянәтче хатын һәм ир-атта
Иман түгел, булмый оят та,
Әйләнә дә куя ярың — ятка,
Дус — дошманга, туган — «братка».

Хәтта алар үтеп йөргән җирдән,
Курыккандай сабый өрәктән,
Юк, мин, куркып түгел, җирәнүдән
Урап узам читтән — ерактан...

Ах! Чыннан да күпне кичердем мин,
Акылдан да, шөкер, язмадым!
Хаклык эзләп таулар күчердем мин,
Казыганда күмер базларын.

Шахтер булып төштем җир астына,
Чөелгәндә «чүпләр» күкләргә...
Шунда башны кинәт таш басты да,
Таулар инрәп ауды иннәргә.

Таба идем хакны мин, янәсе,
Таш-тау чыдап торса чак кына...
Хаклык-гаделлекнең чын бәһасе
Тора, димәк, дөнья хакына!

Иман яңартырга һәм тагын да
Чын кешелек хисен тоярга:
Кирәк икән җирнең карынында
Бер изелеп, кабат туарга!..

## Унбишенче бит

Кабат аккан сыман язгы сулар,
Кабатланган сыман яз, кышлар:
Кабатлана икән ялгышулар,
Кабат кага икән язмышлар.

Барысы үз кулыңда булса әгәр,
Бөтен эшең торса бер синнән,
Булыр иде кешеләр дә, мәгәр,
Шәфкатьлерәк берсе-берсеннән.

Кая инде!.. Җептәй чияләнеп,
Бар язмышлар бергә ялганган;
Араларны өзеп, өзгәләнеп,
Аера кеше чынны ялганнан...

Ялган-чынны әле дә аермасам,
Ялганчыны аерыр идемме?
Улым өчен әллә кайгырмасам,
Пар канатын каерыр идемме?!

«Асыл кошны» байлык кызыктырды...
Мин улымны алдым күтәреп!
Кем отты да монда, кем оттырды —
Уйлыйм, вакыт хөкем итәр, дип...

Баш сау булса (исән дип тә була),
Башка, диләр, бүрек табыла.
Бала белән җыендык та юлга,
Чыктык-киттек Урал ягына.

Каерылып калды сыңар «канат»,
Бер борылып карап соң кабат:
Калды канап бергә очар канат,—
Ялгыз калу үзе меңгазап!

Ә без икәү идек!.. Тигез булдек
Бер газапны — тиде яртышар...
Улыма да шулай җитте килеп
Үз башымнан узган язмышлар.

Аны — ана, имеш... мине — сугыш
Гомерлеккә итте ким-ятим;
Мин түзгәндә, син чыдарга тиеш,
Нишләтим соң, улым, нишләтим?!

Тереләтә яксалар да утка,
Күмсәләр дә илтеп зиратка,
Болай авыр булмас иде хәтта,
Хур-оятка калган ир-затка!..

## Уналтынчы бит

...Хуш-бәхил бул, сау бул, туган ягым!
Күрешербез микән без тагын?..
Рөхсәт итсәң, истәлеккә алыйм
Җилләп үскән әрем ботагын.

Ачы язмыш белән әче әрем —
Бабамнардан калган мирастыр...
Шуннан башка, ахры, аш-су тәмен,
Яшәү гамен тоеп булмастыр.

Әрем тәме, язмыш ачылары
Тоз булган да сеңгән каннарга.
Куган безне тормыш кануннары,
Китсәк тә без әллә кайларга...

«Кара сакал» бергә һәрвакытта,
Булмый аннан качып калып та;
Татар халкын кертми чын тарихка,
Кыскан язмыш «корыч калыпка»!..

Җан кыелып, шуннан кан сыгылган,—
Җәелгән дә шул кан таралган...
Кем — иленнән, кем теленнән язган,
Кан бозылган — маңкорт яралган.

Һәм бүген дә изге телебезне,
Көл иткәндәй кузлы күмерне:
Туздырыпмы кат-кат, төкерепме,
Күпләр таптап хурлый түгелме?!

Чәчмиләрме илтеп шуның көлен
Җиде юл чатына — җилләргә?..
Әмма үсмиләрме шулар бүген
Гөлләр булып төрле җирләрдә!

Әле ничек кенә үсә, иптәш,—
Тармакланып үсә як-якка!..
Тел дә үлмәс илдә, гөл дә шиңмәс,
Җир йөзендә татар бар чакта!

...Мин дә якташларга сыендым да
Тау-ташларга менеп сөялдем;
Кая баш иргә килү монда,
Таш тишәргә хәтта өйрәндем!

Тел, иманын саклап гомер итсә,
Ходай кушса, халкым яшәр ул!..
Асыл ташны ваклап кая сипмә,
Шунда балкып нурын чәчәр ул!

## Унҗиденче бит

Берәүләргә кирәк сүз сөйләргә,
Юләрләргә кирәк көләргә:
«Төшә, диеп, шахтер җир астына
Кочак-кочак акча кырырга».

Кемгә — байлык, кемгә — хаклык кыйммәт...
Бер мин генә кемнән ким икән:
Төштем хаклык эзләп, ә ул «мөртәт» —
Таш астына сеңгән ком икән!

Учтан очкан торна кош икән ул,
Күк гарештән иңгән өн икән;
Төштә күргән сихри төш икән ул,
Төптән килгән серле моң икән...

Йөрсә дә ул үзе гел тирәмдә,
Тамырлары, ай-һай, тирәндә!
Тамырлары моңның, һай, тирәндә,
Үлчәп булмый ниләр белән дә!..

Шуны тапмый торып, чигену юк,
Акса да кан күздән ургылып...
Тамырына моңның мин үрелеп,
Ярачакмын ташны... җыр булып!

...Ярдым ташны... Тик үземнең башны
Аңа хәтле күпме ярдылар:
Хакыйкатьне бутап күтле-башлы,
«Күзле-башлы» булган абзыйлар...

Андыйларның тоеп, сизеп тордым
Ни эшләвен, кая басканын;
Һәм тауларны этеп сикереп тордым
Туксан тугыз катлам аша мин!

Тик барыбер алар күрмәделәр,
Көнләштеләр әллә күреп тә;
Илһам кошын буып, җирләделәр,
Очар чакта җәйрәп иректә...

Аннан — бары аз-маз шигырь булып,
Каурый гына калды коелып...
Ә моңнары җанны уеп-уеп,
Йөрәгемә барды жыелып.

Булыр идем микән бүген исән,
Җыр үлгәндә башны мин исәм?
...Сабырлыкның төбе алтын түгел,—
Аңларсызмы,— сагыш-моң, дисәм...

## Унсигезенче бит

Дөнья булгач, кем сагынмас кемне,
Яшь шагыйрьләр сагына, чал ирләр...
Җир астыннан... якты, аяз көнне
Сагынып чыга хәтта шахтерлар!

Бу хисләрдән әллә мине генә
Алла мәхрүм иткән дисезме?
Их, үз урыныма тик бер көнгә
Куеп карар идем мин сезне!..

...Кайтам ел да туган ягыма мин,
Үлә язып, күптән сагынып.
Китәм кабат торган ягыма мин,
Үлсәм — туып, сүнсәм — кабынып!

Тик киткәндә алга бер карасам,
Мең борылып карыйм артыма;
Мин җәй уртасында юлга чыгам,
Ә чигәмә... көмеш кар куна...

Болай гына сагыну газабына
Чыдап, яшәп булмый бит инде,
Азан әйтеп дәшкән Казаныма
Егылдык без кайтып бер көнне.

Казан үзе үги итмәсә дә,
Үсте улым «үги ул» булып;
Яшен көн дә кыеп үтмәсә дә,
Баш очында йөзде гел болыт...

Йөртмәсә дә тибеп очтан-очка,
Этка салган сөяк шикелле,
Язмыш мине керттерде дә «йортка»,
Тар почмакка сөяп киптерде!..

Читтә түгел, бу бит үз илемдә,
Иделемдә, изге җиремдә.
Бик киләдер үз җир-нигеземдә
Гөл буласым бәлки минем дә!..

Ярый әле улым ил чигендә
Хезмәт итә. Әнкәй авылда...
Без өчебез илнең өч җирендә
Талкынабыз җилдә-давылда.

Ярый әле шуңа шөкер итәм:
Афәт тынды Әфганстанда.
Югыйсә, без ятар идек күптән
Өчебез өч каберстанда...

## Унтугызынчы бит

Әй, сынады язмыш, һай, кыйнады,
Гөнаһтан да куркып тормады;
Баштан сөеп-сыйпар чакта да ул
Чәчне-кашны йолкып, тырмады...

Күп тырышып, эш пешмәсен белгәч,
Мин куймагач аңа һич тә юл,
«Таныш булыгыз,— дип, фәлән иптәш!»,—
Очраштырды әҗәл белән ул.

Әҗәл сөенеп, әрсезләнеп килде,
Белеп кайчан, ничек киләсен:
Башта ачлык булып өйгә керде,
Каерып ачып ишек келәсен.

Аннан соңра чир, йә бәла булып
Чыга торды аяк астыннан;
Йә буранда, яшь кыз бала булып,
Адаштырды әйдәп артыннан...

Ашатып ул миңа учлап-учлап
Борчак белән ап-ак агуны,
Биш көн һушсыз яткырса да, чынлап
Алалмыйча калды җанымны!

Мал көткәндә сөзде шул албасты...
Күкрәгемә аннан ат басты;
Һәм таш басты! Җылы туфрак-кабер
Була язды салкын таш асты.

«Кызык» итеп, бик еш килеп-китеп,
Әҗәл тәмам хәлдән тайдырды;
Чир калдыра торгач өеп-өеп,
Чыдамады йөрәк... ярылды?!

Ярылса да йөрәк, чыкмады җан!—
Могҗиза бу шаклар катарлык!..
Тән кыйналып, тузган саен гәүдәм,
Ныгый, димәк, рухым сафланып!

Ун кат үлми торып, бер гомернең
Беләм димә икән кадерен;
Үз башына җиттем йөз үлемнең,—
Үлемсезлек көтәм хәзер мин!

Күпләр тиңләр мине сәер затка,
Кемдер тиңләр Хозыр Ильяска...
Мин үзем дә моны тоям хәтта:
Якынрак торам кояшка!..

## Егерменче бит

Керсез җаным, саф вөҗданым белән
Барып керсәм шәһәр эченә:

Тәүбә! Мин ни күрәм, жаным, үләм,—
Юл да бирми кеше — кешегә?!

Берәү сөйли, ятлап куйган кебек,
Туган телне ватып-җимереп;
Якын туганымны җуйган кебек,
Карап торам аңа тилмереп.

«Моңлы Казан, нурлы Казан»мы бу,
Тукай зурлап язган Казанмы?
Кызлар су коенган Кабанмы бу,
Әллә сазлыктагы кабанмы?!..

Ачык яра булып ята Болак:
Төптә — каны, өстә — үлеге...
Тора янда гарип Бина[1] елап,
Ә арырак — «сабын күбеге[2]».

Төтен-корым сарган күкләрендә
Ай ничәү дә, күпме алтын хач?
Ни өзелмәс шунда күкрәгеңдә,
Күзләреңә ничек яшь тулмас?!..

Чит кавемнән исем алганнар да
Меңнән артык урам, мәйданнар:
Нәфрәтләнеп сатлык, вак җаннарга,
Тораташтай катып калганнар.

Читләп узып Черек күл ягыннан,
Чыгам күкнең биек ягына;
Күрәм: халык Ирек мәйданыннан
Агыла якты ирек таңына!

Анда халкым тоткан байраклар да
Җанга якын — аклы-яшелле!
Җанга шатлык бөркеп, бар якларга
Өмет нуры балкып чәчелде!..

Һәм яктырып китте күз алларым:
Дөнья хәлен яңа аңладым;
Кичерегез мине, сез, җаннарым,
Һәм гафу ит син дә, Казаным!

Уйлыйм, дисәң, ирек, ил хакында,
Уйланырлык хәлләр бар монда —
Сүрелмәгән әле ялкынын да,
Коры икән, халкым, дарың да!..

## Егерме беренче бит

Ак намусым, пакь күңелем белән,
Халык арасында буталып,
Йөргәндә мин уйлыйм гел эчемнән:
«Кая чаба, диеп, бу халык?».

---

[1] Театр бинасы.
[2] Цирк бинасы.

Алга-артка, уңга-сулга чаба,
Урам охшап кала мәхшәргә.
Уң булсын дип, инде соң булса да,
Мин дә чабам — кирәк яшәргә!

Булсын — буран, булсын җәйге чиллә,
Диварларның шакыйм ишеген...
Гомер буе шулай, әйтерсең лә,
Хәер эстәп йөргән кеше мин?!..

Түрә: «Үз кеңеңне үзең күр», ди,
Үлә язып, авырып йөрсәм дә.
Хәлләремне минем беркем белми,
Җаннарымны ярып бирсәм дә!

Шулай эзләп тә бит... эзләп табып
Булмаганны каян аласың? —
Оҗмах түгел, хәтта почмак та юк,—
Өтә «тәмуг» адәм баласын.

Китап туса, дөнья күрми ята,
Җыр язылса — чыкмый кирәге...
Моңа хәтта түзмәс иде таш та,—
Шартлар иде, булса йөрәге.

Кара кайгыларга батып-чумам,
Кара каеннарга сыенам;
Кара судан, кара аккош сыман,
Кара җиргә чыгып егылам...

Кара җирдән — туган туфрагыннан
Миндәй шахтер яки шагыйрьгә,
Аерылып яшәү чит-ят җирдә
Булыр иде нинди фаҗига!..

Әллә иртә, әллә соңлап кайттым,
Хаклык, гаделлеккә сусап мин? —
Илем кочагында урын тапмыйм,
Идел уртасында су тапмыйм?!

«Ник ошамыйм әрсез-«кыюларга»,
Булмас микән бу баш хур?», дисәм:
Гамь-моңнарга артык коенганга,
Эчем-тышым тоташ нур икән!

## Егерме икенче бит

Үч-мәкерсез, саф вә керсез җанга
Җир йөзендә урын тар икән...
Моңлы башым сыймый киң җиһанга:
Гүяки, мин — соңгы могикан!

Юкса үзем бары — Рифкать тә,
Кануннарым — корьән, шәригать;
Табынганым — Тәңре, хакыйкать тә,
Бар иманым — җаным-шигърият!

Мин, юл сабып киткән-килгәннәргә,
Булмасын, дип, һичбер авырлык,
Йөрим азык булып «тилгәннәргә»,
Ә үзләре... тик бер кабымлык!..

Кая керсәм, шунда түргә менеп
Кунаклаган чит-ят килмешәк.
Утыра шул Ишәк түрә булып,
Күңелсе — таш, телгә гел йомшак...

Тирә-ягын сырып алган аның
Гамьсез-ыспай, әрсез-алабай;
Этлекләрен битлегеннән таныйм —
Кайсы мәнсез, кайсы — ялагай.

Урыс дисәң, урыс түгел алар,
Охшамаган әрмән, башкортка.
Әйләнгәнме әллә шулай татар
Фәлән-фәләнский маңкортка?

Маңкорт булса татар — эшләр хәтәр:
Уйга — кыска, сүзгә оста ул;
«Вәгъдә — иман» барын оныта ул,
Үз татарын изә-сыта ул.

«Эш пешәр»,— дип, уйлап син йөрмә дә,
Эшең төшсә андый түрәгә;
Алышыныр барысы бер тирәдә:
Көнең — төнгә, илең — төрмәгә...

Нәкъ шундыйлар вакыт тапмадылар,
«Вак» диделәр һәрбер хак эшне,
Соры масса итеп вакладылар,
Таптадылар күпме шәхесне!

...Кабат туа алсак бу дөньяга,
Яши калсак тагын бер кат без,
Булмас идек болай чын диванa,
Булыр идек акыллырак без!..

## Егерме өченче бит

Күрәчәкне күрми — түргә кермиo,
Кайда да шул адәм баласы...
Язмыш аңа артык өлеш бирми,
Килсә дә бик тартып аласы.

Өлешемә тигән көмешемә
Өстәп бары гамь дә моң алдым;
Гомерлек гамь алып мин үземә,
Мәңгелеккә моңга уралдым.

Гади түгел, шушы «терекөмеш»
Әвереллдереп мине «сәергә»;
Күрәчәгең булса, тере килеш
Кертүе бар этеп тар түргә.

Шундый уйлар түндергәндә башны,
Күп хәлләрне тоймыйм-анламыйм,
Бөтенесе, гүя, өсле-аслы,
Әллә — Айда, әллә кайда мин?!..

Йөрим, гүя, ят бер планетада,
Күпкә түздем, азга түзим, дип.
Бәргәләнә җаным кыл уртада,
Гәүдә-тәнем, ягъни, үзем — юк.

Элек җирдә булган төрле җаннар
Күк-гарешкә менеп тулганнар;
Баскыч-баскыч җиде күк катына
Тезелешеп килеп кунганнар.

Көнчел, түбән бәндәләрнең аста
Газаплана кара җаннары:
Берсен-берсе өтеп, каттан-катка
Яна-яна тама каннары!..

Рухи гарипләрнең кәрлә җаны
Әйләнгән дә елак эт җанга:
Сагынып җирдә калган дәрәҗәне,
Ялкын йота, сусап уч, канга...

Керсез җаннар монда ак күбәләк,
Яннарымда оча тирәләп!
Бу — киләчәк... Моны без күрәчәк,
Белдегезме инде, менә вәт!..

...Шулай булгач, нигә кайберәүләр
Катыралар әле дә бу башны? —
Итәк белән каплап кына сүнәр
Диләр микән әллә кояшны?..

## Егерме дүртенче бит

Сүнмәсә дә кояш, җылысы аз
Булды аның, канга буялгач...
Узды гомер күрми бер җылы наз,
Ялган белән дөнья уралгач.

Коммун, коммунизм төзибез, дип,
Комнан үреп аркан «иштеләр».
Без нишләсәк, шуңа түзегез дип,
«Этләр» бал-май һәм кан эчтеләр...

Бушка эшләп һаман, бушка яшәп,
Юкка чыкты бөтен бер буын.
Әмма: «алда гөл дә... артта чәчәк»,
Диеп әйтмәс идем мин бүген.

Юк, бүген дә әле кичәгедән
Китмәдек без алга бик артык;
Һәм мин яшим: гарьлек-үртәлүдән
Кыска гомерне дә кыскартып.

Инде хәзер миңа нәрсә кала,—
Сагыну кала, җирсү, моң кала;
Һәм мин моң-аһәңнән эзлим дәва,
Урыныннан йөрәк купса да.

Сагынсам мин, уй-хыялга батып,
Сагынамын барсын берьюлы;
Ачы-төчеләрне бергә татып,
Басам бераз әрнү, борчуны.

Сагынам мин мәрхүм әбекәемне...
Бер гөнаһсыз сабый чагымны...
Бүгенгедән мәхрүм әткәемне...
Пешеп үлгән сеңелкәемне...

Газап чиккән газиз әнкәемне...
Яшен кискән ялгыз каенны...
Яшьли көтү көткән һәр җәемне...
Ятим үскән сабыйкаемны.

Артык ямьле булса, сагынам гамьне,
Гамьле чагым булса — бәйрәмне;
Куяр урын юкта җанны-тәнне,
Сагынам хәтта кайчак... әҗәлне?!..

...Булсак та без җирдә кунак кына,
Бөтен сые — әрнү, янудыр...
Яшәү үзе — соңгы ерак юлга
Гомерең буе әзерләнүдер.

## Соңгы бит

Бу кыйссамны мин сызланып язам,
Моң кысамы, тынмы — буылам...
Тын да, моң да кысып, киң дөньядан
Аерылырга, гүя, җыенам.

Укып, моңлы, көйле бу юлларны,
Кем көләр дә әле, кем елар.
Күрсәм дә күп үзем дус-дошманны,
Белүче юк хәлне күп еллар.

Ахыры үтә-ачык күргәнгәдер,
Белгәнгәдер кемнең кемлеген:
Күпләр шуннан качып йөргәнгәдер,
Япа-ялгыз калдым мин бүген...

Мин күргәнне берүк төшеңдә дә
Күрсәтмәсен ходай, үтенәм.
Ник аз дусым? — димим мин шуңа да,
Нигә тудым диеп үкенәм.

Белим дисәң күбрәк үз-үзеңне,
Үз ишеңне өйрән танырга!
Үзем булып яшәп, мин сүземне
Телим бары әйтеп калырга...

Тик яздыммы сүзнең кирәген мин,
Кузгаттыммы уйның тирәнен?
Сизәм: һаман ярсу хис-давылның
Уртасында дөрли йөрәгем!..

Күпме булса юллар арасында
Сүзләремнең сыймый калганы,
Нәкъ шул кадәр, йөрәк ярасында
Хисләремнең ургый кайнары!

Күп ачысын татып шушы чорның
Узды инде бөтен гомерем.
Әнкәм бишек тибрәткән моңның
Бер дәвамы минем бу җырым.

...Вакыт җитте, гүя, поезд китте,
Китте поезд юллар буйлатып.
Минә җыр да бетте... моңсу итте:
Төрле-төрле уйлар уйлатып...

Ничек булыр җырның киләчәге,—
Юлыгырмы җылы кулларга?..
Замананың бизгәк тоткан чагы,
Кемнәр чыгар олы юлларга!...

*Казан-Переделкино-Казан.*
*1991—1992 еллар.*

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Рашат Низамиев**

# КЫЗЫЛ КАР ЯУГАЧ

ПОВЕСТЬ

*Җәүдәт абый истәлегенә.*

Автор.

*Әллә күктә, әллә җирдә тирбәлә ул — йөзе кан белән юылган яралы егет моны анык кына белә алмады. Бер мәлне һавада кояшның утлы тәгәрмәче шәйләнде, бу сурәт маятник сыман чайкала һәм: «Яшим... Юк...», «Яшим... Юк...»— дигән сүзләрне колакка өнсез генә пышылдый иде. Язмыш егетне тиктомалдан көчсез, чарасыз кылды. Аңарда соңгы сулыш өчен көрәш хокукы гына калган иде.*

*Томан пәрдәсе кинәт юкка чыкты да күкне тутырып кызыл кар ява башлады... Адәмнәр нинди мәрхәмәтле: әгәр теләсә, алар җирне һәм тормышны гөлбакча итә алалар. Адәмнәр нинди явыз: ният итсә, алар бер селтәнүдә табигатьне, тормыш кырларын пыран-заран туздырып ташларга да сәләтле. Адәмнәр коралга ябышты, автоматтан, туптан, танктан атып, самолеттан снаряд һәм бомбалар ташлап Гиндекуш тауларын дер селкетте, кеше белән кешеләрне, кыя белән кыяларны маңгайга маңгай чәкештерде, ут белән җир-суларны, шәһәр-авылларны көйдерде. Шуның кәсафәте буларак, инде менә адәмнәр каны булып җиһанда кызыл кар ява!*

*Кешенең соңгы минуты — тулы бер гомер. Гомерне якты уй, кылган гамәл белән исәплиләр. Егетнең аңында, кинотасмадагы йөгерек агым булып, гомеренең кайбер сәхифәләре яктырып уза иде...*

### 1

Дүрт яшьлек Шаһинурга көннәрнең берендә әтисе туп бүләк итте.

— Менә, улым, рәхәтләнеп уйна,— диде дә сумкасындагы тупны идән уртасына чөеп җибәрде. Кояшның үзе шикелле түм-түгәрәк, зәңгәр төстәге буяулары белән нур чәчеп тора иде бу уенчык. Резин тупның идәнгә бәрелгән тавышы баштарак көчле яңгырап чыккан булса, аннары әкрен-әкрен генә йомшакланып сүнә барды. Өйдә яңгыраган өр-яңа музыка, серле аһәң иде бу. Тагын шунысы гаҗәп: зәңгәр тупның уртасына аклы-кызыллы тасма рәвешендәге бизәк тә төшерелгән иде. Туп

---

Рашат НИЗАМИЕВ (1950) — *әдип. «Боек сер», «Яралы керпе», «Фәрит Яруллин» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

сикерә-сикерә идән буйлап тәгәри киткәндә бу бизәк өйне салават күпередәй балкыш белән тутырды.

Шаһинур караватка таба тәгәрәгән йомры тәтине куып житте дә куанып, очынып-канатланып, аны тагын идәндә сикертә башлады. Сикерә, йөгерә, тәгәри, кагылмасаң исә бер почмакта тып-тын оеп утыра торган бу нәрсә анын яраткан уенчыгына әверелде. Алар дуслаштылар. Ләкин туп телсез иде, сикергәндә гажәеп авазлар чыгарса да, ул сөйләшә белми һәм үзе турында бер ни дә әйтә алмый иде. Ничек шулай сикерә ала соң ул, ни хикмәт белән яши? Анын эчендә нәрсә булырга мөмкин?

Уяткыч сәгать тә тәмам аптырашта калдырган иде аны берзаман. Әтисе яки әнисе кичтән үк сәгатьнең колагын борып куялар да, иртә белән әй чаң кагарга тотына тегеl Сикерә-сикерә, стенага бәрә-бәрә чылтырый. «Уяныгыз!»— дип каравыл кычкыра... Моның эчендә тәгаен бер-бер кош баласы посып ятадыр. Малай әнә шулай дип уйлады һәм, аулак өйдән файдаланып, уяткыч сәгатьнең эчен тикшереп карарга булды. Артындагы түгәрәк капкачны салдыргач та нәни бармаклары белән сәгатьнең эчен жентекләп-жентекләп актарды. Кош баласы урынына исә ниндидер шөрепләр, вак-вак тешле тәгәрмәчләр, һәм күпме кыссаң да янә үз хәленә кайта торган пружина килеп чыкты. Малай биш-алты минутта дигәндәй сүтеп аткан сәгатьне әтисе, соңыннан, ачулана-ачулана ярты көн эчендә көчкә жыеп бетерде.

Тупның эчендә ни барын беләсе килү теләге шулкадәр көчле иде ки, түзмәде Шаһинур — өй бүрәнәсе ярыгына кыстырылган очлы безне тупның шома корсагына батырды. «Пыш-ш-ш...» итеп нибары һава сызылып чыкты аннан һәм өйгә әчкелтем резин тәме таралды. Тупның тәне шәлперәеп төште, ул хәтта зәңгәр кәләпүшкә охшап калды.

Ул көнне тубын югалтса югалтты, әти-әнисеннән әр ишетсә ишетте, әмма үзе өчен нәни генә ачыш ясады Шаһинур: тупның эченә һава тутырганнар икән!..

Бервакыт малай тыкрык астындагы инеш буена килеп чыкты. Уртасыннан су агып, ә инде яр читләрендә юеш комлык жәйрәп яткан күренеш аны таң калдырды. Ком өстендә — бака кашыклары. Әйтерсең, аш кашыкларын кара-каршы китереп каплаганнар, саплары гына күренми боларның. Иң кызыгы — нәни дулкын булып, ком өстендә сызык-сызык эзләр уелып калган. Кем эзе йөрткән, кем хәрәкәткә китергән боларны? Менә шушы үжәтлек, кызыксыну белән Шаһинур комлык уртасына атлап керде. Кытыршы кабыклы, көрәнсу төстәге бака кашыгының берсен учына алды. Бу тылсымлы «йомры» сулый, анын эчендә жан бар иде. Талчыбык белән каерып карагач, кашыклар эчендә гөмбә тәнедәй аксыл бер нәрсә күренде. Ул селкенә һәм, нигә мине борчыйсың, малай актыгы! — дигәндәй хафалана иде шикелле. Тал чыбыгын читкә ташлады да, бака кашыгын яңадан ком өстенә утыртты Шаһинур.

Тыкрык асты, инеш, сулар чупылдавы һәм яшел чирәм — дөнья белән танышуның дәвамы иде. Су өстенә төшеп утырган кояш әллә ничаклы төсләр белән жемелди, кызыктыра, су асты патшалыгына чакыра һәм сүзсез бер өн белән гамьсез булмаска өнди иде.

Бу фани дөньяга кемнәр генә килеп, кемнәр генә яшәп китмәгәндер,— малай боларны белми һәм ул үзенә бер яңь-яшь, бәйсез дәүләт шикелле яши башлады.

Дөньяны аңлыйсы килү хисе аңа ходай тәгалә тарафыннан камил дәрәжәдә бүләк ителгән иде. Ул, үзе дә сизмәстән, сораулар чолганышында басып калды. Бу үләннәр, яфраклар нигә мең-мең төрле икән? Алма өзелеп төшә, ә күктәге ай ничек жиргә егылып төшми? Көн тугач та төн кая китеп бара? Сорау арты сорау кыңгырау сыман чыңлап кына тора... Ул, гөнаһсыз күзләрен зур итеп ачып, чиста ак кәгазь битедәй сукмакларда ялантәпи эз калдыра-калдыра, билгесез дөнья каршына йөгерде. Үзе

әле аңлап бетермәсә дә, аңарга терекөмештәй житезлек, хакыйкатькә сусау дигән куәтле бер көч иңдерелгән иде.

Җилләр күзле, бик тә тынгысыз Шаһинур әти-әнисен сорау арты сорау белән күмеп ташлый. Зурлар бу дөньяның бөтен хикмәтләрен беләдер шикелле тоела аңа. Аның мондый кыбырсык булуын, сорау бирә-бирә аптыратуларын әтисе дә, әнисе дә бик яраталар, әлбәттә. Ничек сөенмисең ди: бала әнә зурлар да җавап бирә алмастай катлы-катлы сораулар белән аларның гадәти генә агып яткан тормышын бизәп, үзгәртеп, төрләндереп җибәрә, эчке бер горурлыкларын уята. Ходай сәламәтлек кенә бирсен, күз карасыдай кадерле уллары берзаман үсеп җитәр, ил-көнгә файдалы егет булыр, иншалла!

Шаһинурның инде әллә кайчан чынлап та зур булып үсәсе, меңаваз белән кайнап торган тормышның уртасына ташланасы килә. Зурлар бит әнә ат җигеп печән ташый, тракторга утырып буразна ера, машина рулен уңга-сулга әйләндерә, очы-кырые күренмәгән басуларда комбайн белән иген суктыра. Берзаман Шаһинур зур булып үсәр,—үзе генә белгән хыяллары чынга ашкач та авылдашлары янына әйләнеп кайтыр һәм әйтер:

— Сез мине таныйсызмы? Мин бит сезгә карап зур кеше булдым, рәхмәт!— дияр.

Күрше Кирам абый сокланып, зуп-зур булган Шаһинурның аркасыннан сөеп:

— Энем, мин башта ук рәт чыгар бу малайдан, дигән идем. Тәки ышанычымны акладың бит, маладис!— дияр.

Ә хәзергә Шаһинур — сабый бала, өлкәннәрнең башына да килеп карамаган сораулар белән дөньяны үзенчә танып-белмәкче, хакыйкать җимешләрен үз авызы белән тешләп карамакчы ул.

Кич җитә, эңгер-меңгер төшә, һәм авыл өстендә эреле-ваклы йолдызлар кабына.

— Мин кайчан йолдызларны тотып-тотып карармын икән?

— Кызыл кар яугач,— ди әбисе, дисбе төймәләрен тарта-тарта, мәгънәле итеп кенә.

Зәп-зәңгәр күкне, берән-сәрән болытларны сөзеп, авыл өстеннән самолет очып уза. Офыклар артына кереп күмелгәч тә аның тавышы әле бик озакка колак төбендә утырып кала.

— Мин кайчан очучы булам да, самолет йөртә башлармын икән?

— Кызыл кар яугач,— ди әнисе, он иләгән җиреннән көлемсерәп кенә.

Телевизордан галәм корабының ничек күтәрелгәнен күрсәтәләр. Кибән чаклы утлар тузгытып, шомартылган бүрәнә кебек алагаем бер нәрсә һава ярып, пошкыра-пошкыра өскә күтәрелә.

— Мин кайчан әнә шундый корабка утырырмын икән?

— Кызыл кар яугач...— ди әтисе, гәҗит укыган җиреннән елмаеп. Аннары болай дип тә өсти әле: — Авылда үсеп, сиңамы соң, улым, андый нәрсәләр турында хыялланырга?

Мондый сүзләр ачуын кабартмый Шаһинурның. Киресенчә, үҗәтләнәсе, теше-тырнагы белән эчтән генә каршылык күрсәтәсе килә башлый аның. Ап-ак карларның ничек яуганын әллә ничә тапкыр күзәткәне бар аның, ә менә кызыл кар яуганны берничек тә күз алдына китерә алмый ул.

Кызыл кар була димени? Өлкәннәрнең шаярып кына, кызык өчен генә әйтелгән сүзләредер бу...

## 2

Биш яше булгач, сөенәсе урында, киресенчә, күңелсезләнеп калды Шаһинур. Моның бик тә җитди сәбәбе бар иде, әлбәттә. Аның белән бергә су коенган, качышлы уйнаган, йөгерешеп йөргән иптәшләре, берен-

че сентябрь житү белән, китап-дәфтәр салынган сумкаларын аркага асып, мәктәпкә сабакка киттеләр. Чөнки алар барысы да мәктәп яшенә җиткән, ягъни җиде яшьне тутырганнар иде.

Иптәшләреннән бер дә калышасы килмәде малайның. Инде азмы-күпме укый белә, чатлы-чотлы хәрефләр белән хәтта исемен дә әллә ничә тапкыр язып караганы бар. Ул инде ашыктырып, ялвара-ялвара әнисеннән әллә кайчан күн тышлы сумка, дәфтәр һәм каләмнәр алдыртып куйган иде. Хәзер менә әтисенә ялварып чак җитте: мәктәпкә тизрәк илтеп куйсын ул Шаһинурны һәм укырга рөхсәт алсын.

— Әти, минем мәктәпкә йөрисем килә...

— Әти-әти, укырга барыйм инде!

Бу сүзләр, бу ялварулар әтисен тәмам туйдырды булса кирәк, икенче көнне үк улын җитәкләп мәктәпкә сугылды ул. «Зинһар, берничә көн генә дәресләрегездә утырсын инде, йөрер-йөрер дә, күте басылгач, туктар»,— дип гозерен сөйләп бирде. Укытучы хәлне аңлады, һәм Шаһинур дигән малайга алдагы буш парталарның берсеннән урын күрсәтте. Малайның әтисе — авылда абруйлы кеше, колхозның хуҗалык мөдире. Ул әллә ничә амбарга хуҗа. Шуңа да аның сүзен санга сугалар иде.

Бер атна узды. Шаһинур мәктәптән көн саен кош тоткандай сөенеп, куана-куана кайтып керә! Күренеп тора: укудан бизәргә тамчы да исәбе юк монын. Җиде яшьлекләр арасына ул гәүдәсе белән дә, уй-фикер йөртү йөгереклеге белән дә бик таман гына кереп утырды.

Янадан очрашкач, әтисе белән укытучы арасындагы сөйләшү, билгеле инде, Шаһинурның ничек укуы турындарак барды.

— Комачау итмиме соң, кыенлык китермиме? Бәлки, туктатырга вакыттыр аны...

— Юк, юк! Әйбәт кенә укып китте ул. Хәтта иптәшләреннән дә уздырып җибәрә әле.

Шушы ике-өч минутлык сөйләшүдә Шаһинурның язмышы хәл ителде: ул мәктәптә калачак, укуын дәвам итәчәк иде.

Кара тактага акбур белән ак нурлар сызып, сүзләр һәм саннар язарга өйрәнде ул. Үз кулы белән язган саннар артында ачылмаган өр-яңа дөнья, билгесез һәм серле мәгънәләр посып ятканын төсмерләде. Аның тирә-ягын сүз һәм саннар болыты чорнап алган иде. Боларны аңлар һәм аңлатыр өчен, ай-һай, үзеңдә күпме көч һәм җегәр тупларга кирәк булачактыр әле!

Класс бүлмәсендә Шаһинурны иң нык кызыксындырган бер нәрсә бар — ул да булса глобус. Күчәргә утыртылган бу нәрсәкәйгә бармакларың белән аз гына кагылдыңмы, җай гына хәрәкәтләнә башлый ул. Бу мәлдә хыялыңны кайларга гына алып китми дә, җир шарының кайсы почмакларына гына илтеп ташламый үзеңне! Рәхим ит, алдында Африка тора әнә. Анда казык тешле крокодиллар, агачтан агачка сикереп уйнаучы маймыллар, крандай озын муенлы жирафлар яши, имеш. «Америка» дигән сүзләрне дә укый Шаһинур, тик анда ниләр, кемнәр яшәгәнен генә күз алдына ачык китерә алмый. Кызыл-көрән төстәге тезмәләрне тау дип чамалый. Ә инде кан тамырыдай зәңгәрләнеп сузылган сызыклар, һичшиксез, елга булырга тиеш. Әнә, зәп-зәңгәр океан — аның кочагында ничаклы пароходлар йөзеп йөриләр! Чиклəвек кадәрле шар белән очланган күчәр астында Антрактида җәйрәп ята. Ак төстәге бозлар иле. Кардан әвәләп ясалган сыман ак аюлар әнә шунда яшиләр.

Австралия, Азия, Европа дигән тагын әллә нинди илләр, исемнәр күзгә чалына. Шуңысы үкенеч: дәрескә чакырып кыңгырау чыңлый да, хыялый сәфәреңне иң кызыклы җирдә өзә дә куя...

Шаһинурның күңелендә яшерен бер уй өлгерде: глобусны өйгә алып кайтырга да, рәхәтләнеп уйнарга! Беркем комачау итмәс, хыялый сәфәрен бүлдермәс аның. Тик бирәүгә дә сиздерми генә ничек алып чыгасы аны һәм кая яшерәсе? Хәттин ашкан кызыксыну, мавыгу үзенекен итте — көннәрнең берендә, мәктәпкә иртәрәк килүеннән файдаланып, туп кадәр-

ле йомры глобусны сумкасына тыкты ул. Мәктәп ишегалдында рәшәткәләр белән уратып алынган бакча бар иде. Глобусны әле яфраклары да коелып бетмәгән карлыган куаклары төбенә яшерде. Сумкасы бушады, ләкин Шаһинурның күңеленә бер йомарлам курку кереп оялады. Әйтү кыен: глобустагы Европа һәм Африканы яхшы ният белән урлавын гаепкә санаргамы, әллә нәни бер батырлык дип бәяләргәме аның?

Куркуы юкка түгел икән шул: шкаф өстендәге глобусның юкка чыгуын укытучы беренче дәрестә үк сизеп алды.

— Балалар, күрәсезме, глобус югалган,— диде ул борчулы тавыш белән.— Кем алды икән аны? Болай ярамый ич...

Класста сәер тынлык урнашты. Бөтенесе телсез-өнсез калганнар иде. Аннары гына шаулашырга, эзләргә керештеләр. Хаҗәткә барган җиреннән ике малай аны очраклы төстә карлыган төбеннән табып алдылар да укытучы өстәленә кертеп куйдылар. Оят, шулкадәр оят иде Шаһинурга! Ярый әле гаепләнең кем икәнен белми калдылар, юкса идән ярыгына кереп качарга әзер иде ул бу минутларда.

Курку, фаш булу тойгысы көчлерәк иде. Үз эченә бикләнеп, курку һәм оятын эчкә йотып булса да, онытылмаслык сабак алды ул көнне Шаһинур. Бу аның беренче һәм соңгы тапкыр чит әйбергә кагылуы, гаеп эшләве иде.

Түбәгә яисә агач башларына үрмәләгән саен ул аяк астындагы җир шарының ничек, ни рәвешле түгәрәк булуын күзалларга тырышып карады. Җир дигән чынбарлык исә бинибая зур, карандаш белән сызгандай офыклар гап-гади авылда яшәп яткан татар малае өчен искиткеч ерак иде әле шул.

### 3

Өченче класста укыганда Шаһинур үзләреннән бер-ике ихата аша гына торган гармунчы Кирам абый белән дуслашып китте. Сугышта булган, күпне күргән, чәч агарткан өлкән кешенең яшь-яшь малайны шулай үз итүе юкка түгел иде, билгеле. Аның үз балалары, үсеп-канатланып дигәндәй, инде әллә кайчан читкә таралган. Моңайган чаклары күп була Кирамның, сугыш хәлләрен дә, балаларының читтә дөнья куып ятуларын да еш кына исенә төшергәли ул. Менә шундый чакта кулына гармун ала. Менә шундый чакта тыңлап торучы, моң-зарын азмы-күпме уртаклашырдай кем дә булса кирәктер, күрәсең, аңа. Ә Шаһинур дигән малай шулкадәр ихлас, хөрмәт белән караучы күңелле әңгәмәдәш ки, әле күп нәрсәләрне аңлап бетермәсә дә, аның каршында күңеленне бушатып, әйтер сүзеңне әйтеп була ичмаса.

Кирам абыйның үзенә каратырлык, магнит сыман тартып китерә торган бер хикмәте бар иде шул. Фашистларга каршы сугышта яраланган ул. Уң кулының, әйе-әйе, нәкъ менә гармун уйный торган кулының бармаклары өзелгән. Хәрби бинтәрен җилкәсеннән салып, аның хөрмәтенә ачылган бер «чикүшкә»не бушатып алгач, күңеле нечкәреп, елап җибәргән. Нишләргә, алга таба ни кылырга, солдатка киткәнче авыл кичләрен яңгыратып уйный торган гармунына өзелеп карап кына утырсынмы ул хәзер? Аның бит гармуны — Теләче базарыннан кышлатып суйган сарык акчасына сатып алынган тальян гармуны мировой иде! Яшьләрне кич саен җырлатты-биетте, аулак өйләрнең ишеген ачтырды, моңы белән кызлар толымына кагыла-кагыла табын түрендә утырды...

Кайчандыр бармакларын югалтса да, гармунын һәм үзенең менә шушы абруен югалтасы килми иде Кирамның. Юкса әнә тальянны тез башларына китереп утырткан иде, сул кулының бармаклары «бакалар» өстеннән йөгереп узды узуын, ә менә дүрт бармагыннан мәхрүм сәербичара уң кул ни хәрәкәт кылырга белмичә һавада асылынып калды. Гитлер снарядының кыйпылчыгы гүя тальянга да килеп тигән һәм ул

аны телсез-монсыз калдырырга маташа. Утны-суны кичкэн Кирам моның белән килешергә теләмәде. Йөрәгенең әллә кай төшләрендә яткан үҗәтлек белән гармунны унга-сулга әйләндергәләде һәм бераүнең дә башына килмәстәй чишелешне эзләп тапты...

Берничә көннән соң Кирам өздереп-өздереп гармунда уйный башламасынмы! Авылдашлары бу хәлгә шаккаттылар һәм белделәр: тальянның уң ягын — сул кулга, сул ягын уң кулга көйләп-үзгәртеп куйган икән Кирам. Дошман танкларын йөз сиксән градуска әйләндереп салган егет буларак, гармунның баш-башларын кирегә әйләндергән дә, исән калган сул бармакларын унике тел өстендә биетә башлаган. Уң кулының баш бармагын исә ходай иң кирәкле вазыйфа — каеш элмәкле планканы тартып-сузып йөртер өчен генә исән калдырган, күрәсең.

Кирамның сугыш аркасында бүленгән, ләкин хәзер инде аерата бер моң, ачыну белән өртелгән уйнавы авыл өстендә кабат яңгырый башлады. Югалту һәм сугыш җәрәхәтләренә карамастан, авылның күпмедер дәрәҗәдә яңадан яши һәм килер көнгә өмет белән карый башлавы иде бу.

Боларны Шаһинур җентекләп белмәде, әмма Кирам абыйсының гадәттән тыш бер кеше икәнлеген күңеле белән аермачык тоя иде ул. Аның бит хәтта чәчләренә хәтле бераүнекенә дә охшамаган. Куетыгыз булып тырпаеп тора, ә иң гаҗәбе — чем-кара шушы чәчләрнең урта бер җирендә чикләвек зурлыгындагы ак тап чекерәеп, күзгә бәрелеп тора.

Түзмәде, очрашуларның берсендә Шаһинур әнә шул хакта сорады. Кирам абый баштарак көлемсерәп куйды, бер ноктага озак-озак текәлгәндәй итте дә, аннары гына житди итеп сөйләп китте:

— Курск дугасында кеше күмелерлек тирән окопта яткан чаклар иде бу минем... Свастикалы танкларның берсен безнең снаряд чәнчелдереп ташлады. Икенчесен мин ничектер граната белән туктаттым. Ә менә көтмәгәндә өченчесе ажгырып өстемә килеп чыкты. Килеп тә чыкты һәм, үтүк белән бастыргандай итеп, окопны айкарга кереште. Чәчләргә, муенга, аркама кайнар балчык кереп тулды, сулышым бугазыма төелде... Беттем дип уйладым шул чакта. Әмма ләкин кинәт җир астыннан тальян тавышын ишеткәндәй булдым... Эчкә җылы керде. Табаннарны пешереп, колагыма хәтле урылган шушы моң исән калдырды да бугай мине. Әмма чәчнең урта бер җирендә чикләвек кадәрле тап уелып калган иде. Курку ак төстә була микәнни дип, кайчакны әле хәзер дә гаҗәпләнеп куям...

Тартма кадәрле генә, ләкин унике теле белән унике төстә балкып торган гармун Шаһинур өчен яңа дөнья иде. Кирам абыйсы кулларында кош булып сайраган бу хикмәтле тартма аны тәмам әсир итте, йөрәген жилкетте. Шаһинур үз-үзенә шулкадәр нык ышанды ки, аның уенча, бармакларын йөртә башлау белән гармун үзеннән-үзе уйнап китәргә тиеш иде. Шулай булып чыкты да. Кирам абыйсы лапаста сыерга башак болгатып кергән арада ул инде биш-алты каптырмалы бер «көй»не үзләштереп тә өлгергән иде.

— Ярканатка парашют, сандугачка курай кирәкми шул,— дип, хикмәтле генә әйтеп куйды Кирам абый шул чакта.

Аның белән сөйләшү үзе бер рәхәт иде. Шаһинурның дәртләнеп, тәм табып, гармун телләрен «аксатып» уйнавын ул ахырга кадәр бирелеп тыңлый, сөенә, уйга батып утыра. Аннары вакыты беткәненә, ниндидер ашыгыч эше көткәнлегенә ишарәләп, үзенчә бер хәйләкәрлек белән:

— Йә, күңелең күкәй салдымы инде, энекәш?— дия-дия, җиңелчә генә итеп малайның аркасыннан кага.

Әтисе тальян гармун сатып алгач та Кирам абыйсына йөрүдән туктамады Шаһинур, җай килгәндә һаман аның тирәсендә бөтерелде. Яңа гармунны исә Кирам абый бик җентекләп күздән кичерде, уйнап карады һәм малайның колагына болай дип әйтте:

— Гармунны чыңлатып, кешене сөйләтеп беләләр, энем!

Шуңа күрәдерме, Кирам абый сөйләшергә, тегесен-монсын сорашырга бик ярата иде.

— Шаһинур, син күбәләкнең ни өчен очканын беләсеңме?

— Беләм. Канатлары бар ич аның.

— Ә синең канатларың юкмыни?

— Канатларым бар. Ләкин мин җирдән күтәрелеп китәргә ашыкмыйм әле. Әти-әни мине эзләп юксынырлар.

— Син бит терекөмеш шикеллерәк. Кая китсәң дә югалмассың, чәчрәп килеп чыгарсың...

— Ә минем чит планетага китеп югаласым килә. Аннары, кайчан да бер әйләнеп кайтырмын да, «Исәнме, Кирам абый!»— дип сезгә дәшәрмен.

— Ай-яй-яй, матур хыял бу, энем! Ә без сине кайдан, ничек эзләп табарбыз икән соң?

— Йолдызлар арасыннан...

Бу хәтле хыялый, тапкыр җавапларны ишеткәннән соң, Кирам абый куе чәчләрен сыпырып ала. Шаһинур барып җитәсе йолдызны күрергә теләгәндәй, башын кыйгайтып күккә карый. Юкка гына биш яшеннән мәктәпкә китмәде шул, сөйләшә белә бу малай! Акыл теше иртә чыккандыр моңа. Сабагын әйбәт укый, гармунда уйнарга да тиз өйрәнде. Инде менә, авыз тутырып, йолдызлар багына сәфәр турында сөйләшә...

— Йолдызлар артыннан дисең инде,— дип, малайның сүзләрен кабатлый Кирам абый.— Адашмассынмы соң? Бихисап күп ич алар...

— Ә мин дәфтәремә йолдызлар картасын ясадым!

— Менә монысы яхшы. Икенче бер килгәндә миңа да күрсәтерсең әле... Тимер казык йолдызның кайдалыгын беләсеңме?

— Көндез күренми ич ул.

— Төнлә йолдызларны кем дә күрә ала. Аларның кайдалыгын көндез дә чамалый белергә кирәк. Кояшны күрәсең бит әнә... Менә шуннан ике тәртә озынлыгы сулга таба каерсаң, Тимер казык йолдызның нәкъ өстенә килеп чыгасың!

Бу урында Кирам абый кояшка таба төртелгән имән бармагын үзе әйткәнчә, чама белән ике тәртә озынлыгы сулга таба күчерә һәм шул ноктада туктalып кала. Үч иткәндәй, шул тирәдә болыт кисәге эленеп тора икән. Әгәр ул булмаса, бәлки, йолдызның үзен үк күргән булыр иде алар бу минутта.

Кирам абыйның акыл сынамыш дәресләре һәрвакыт күңелле, һәрвакыт истә кала. Әллә нинди кызыклы сүзләрне кайдан гына табып бетерәдер ул? Шулай беркөн Шаһинур, үзе дә сизмәстән, кечкенә генә гаеп эшләде, ләкин гаебен танымаска маташты. Кирам абыйның шелтәсе берничә сүзгә сыйган иде:

— Эт койрыгы кебек туры син, энем...

Икенче бервакыт Кирам абыйның сарай почмагында бау ишеп торган чагына юлыкты ул. Аның ярты кул белән дигәндәй әллә нинди хәрәкәтләр, элмәкләр ясый белүенә шаккатты.

— Нәрсә күзеңне сигез тиен акча кебек итеп карап торасың?

«Сигез тиенлек акча буламыни?..»— дип сорарга уйлаган иде Шаһинур, тыелып калды. Кем белә, бәлки, чынлап та бардыр ул.

Берсендә Кирам абыйның гәҗит укып торган чагына туры килде. Ишегалдындагы бүкән өстенә утырган да, гәҗитне урталай ачып салган. Әллә малай ишетсен дип, әллә үзалдына шунда:

— Аның экономикасе хет ашарга ярый, ә менә политикасы берничгә дә ярамый шул...— дип әйтеп салды.

Йолдызлар һәм гармун белән шашкан Шаһинур мондый сүзләрнең мәгънәсен аңлап бетермәде, билгеле.

## 4

Күзәтә белсәң, йолдызларны көндезен дә табарга мөмкин икән. Һәм елның, вакытның теләсә кайсы фасылында.

Көз көне бакча буендагы миләшләр ут булып өлгерә. Кагылсаң, кулың пешәр сыман. Мәрҗән-мәрҗән укмашкан бу тәлгәшләргә ничек инде кагылмыйсың да, аларны уч төбенә салып сикертмисең ди! Шундый мавыгуларның берсендә Шаһинур үзенең ачышына таң калды: йомрытыгыз миләш бөртекләренең һәркайсына бишпочмаклы нәни генә йолдыз сурәте уелган иде.

Кышын яуган кар бөртекләре аклыгы, күплеге, бер-берсенә бәрелеп тә ватылмый торган үзенчәлеге белән гаҗәпләндерә. Челтәрле бизәкләрнең муллыгын, нәфислеген аңлап-аңлатып кына бетерерлек түгел. Җиргә төшеп яткач, кояш нурында аларның һәркайсы йолдыз булып җемелди. Басу-кырлар, ишегалды, койма буйлары йолдыз белән түбәләмә тулган. Алар хәтта тәрәзәгә дә барып кунаклаган. Тәрәзә пыяласындагы тропик урманнар, кар абагалар сурәте саен да очкын-очкын көләч йолдызлар җемелди.

Трактор кабызганда аның беләк юанлыгы торбасыннан иң элек бер көлтә йолдыз фонтаны чәчелеп чыга. Балта кайраганда аның йөзлегеннән кыштыр-кыштыр килеп, ярыша-ярыша нәни йолдызлар коела.

Галәм чагылышын җирдәге тагын-тагын бик күп нәрсәләрдә күзәтергә мөмкин иде. Әнә, кура чыбыклары арасында пәрәвез челтәре эленеп тора. Уртасыннан башланган боҗралар һаман саен киңәя, колачлана бара. Орбита сызыгындагы кара нокталар — билгесез планеталар тезмәсе. Кем белә, бәлки, галәмнең, иксез-чиксез галактиканың кечерәйтелгән сурәтедер бу пәрәвез?

Көннәр әкрен генә уза торды.

Вакыт тәгәрмәче, көннәрне үз күчәренә салмак кына урый-урый, һаман әйләнмәктә иде.

Шаһинур үсеп, ныгып китте. Тән-гәүдә ягыннан нык, сәламәт, таза бәдәнле иде ул. Йорт-җир тирәсендәге төрле эшләрдән курыкмыйча үскәнгәме, мускуллары кабарып, тулыланып китте. Төкселек һәм карангылыкны яратмады, кирәк чакта табигый бер балкыш белән елмая белә иде. Шундый чакта ак мәрҗәндәй тигез итеп тезелгән тешләре дә ялтырып, балкып китә. Болар бар да табигатьнең ансат кына чишелеп китми торган сере, матурлыгы иде, күрәсең.

Сентябрь урталарында гаҗәеп җылы, ягымлы көннәр була. Бакчада бәрәңге өлгергән, көзге муллыкның тагын бер кат балкып алыр чагы бу. Менә шундый чакта авылның олысы-кечесе дигәндәй, гаилә белән кубып, бәрәңге бакчасына ябырыла. Тимер көрәкләр толым-толым сузылып яткан мул буразналарны «сүтә» башлый. Казыган саен туфрак астыннан йомры-таза бәрәңгеләр тәгәрәп чыга. Кара туфраклы бакча өсте кинәт яктырып китә. Гүя буразна өстенә эре-эре ак йолдызлар коелган! Авылны дәртләндергән, алга таба яшәргә ымсындырган үзгә бер матурлык бу...

Җиләгән, көн яктысында күпмедер «чиркәнчек» алган бәрәңгене төштән соң кар базына урнаштыру кирәк. Әнисе чүпләгән өч чиләк бәрәңгене капчыкка сала да базга юнәлә Шаһинур. Базның квадрат рәвешле, каралып күренгән авызы һәм озын такталардан кораштырылган улак башы шәйләнә. Капчык төбен бушату белән саргылт-йомры бәрәңгеләр дөбердәп, куышып, бер-беренә бәрелә-бәрелә аска томырыла. Менә шул чакта аларның күбесе имгәнеп, яньчелеп, кабыклары суелып кала. Әнисе әйтүенчә, андый бәрәңге акрынлап черри башлый, чери янсә зәгыйфьләнә, төсен-тәмен югалта.

Түзмәде, менә шушы хәлгә чик куярга булды Шаһинур. Ничек итепме? Хыялга, уйга бирелә башласа, әллә ниләр уйлап чыгарырга сәләтле иде ул.

Кичтән үк эш коралларын һәм кадак, ыргак, божра, бау ише нәрсәләрне әзерләп куйды. Кар базы өстендә келәт сыманрак нәни генә бер каралты утыра иде. Иртән менә шунда балта-чүкеч тавышы яңгырады... Сиртмәле коены кара: ничек телисең, шундый тизлектә аска төшерергә була чиләкне. Шаһинур да нәкъ менә шуңа охшаш җайланма ясады. Бик гади үзе: баз өстенең матча бүрәнәсенә комбайннан калган әйләнмәле тәгәрмәч беркетелгән. Шундагы ыргаклы бауның икенче очы йөзле кадак белән стенага кагып куелган.

Улакның кирәге бетте хәзер, йолыккалап, аны кире тартып чыгардылар. Киндер капчыктагы бәрәңгене Шаһинур капылт кына аска тотып селкеми хәзер, ыргакка эләктерә дә җайлап кына баз авызына төшерә. Аннары, баскычтан төшеп, какмый-сукмый гына бушату берни түгел аны. Мондый ачышны әтисе бик югары бәяләде:

— Вәт ичмасам яңалыкъбу, молодец!

— Каян гына башларыңа килде, рәхмәт, улым!— диде әнисе барлык куанычын белдереп.

Шундый холыкны кайлардан гына алгандыр ул: азмы-күпме эләгә торган мондый мактаулардан эреп китми Шаһинур, үзен әллә кемгә санап масаеп та йөрми. Нидер уйлап таба һәм шуны хыялы кушканча эшләп ташлый икән, аның өчен бар да шулай булырга тиеш кебек сыман. Һәр эшнең, һәр мәсьәләнең артында аның үзенә генә туры килә торган чишелеше бар. Менә шуны эзләп таптыңмы,— син үзеңне ачылмый яткан серләргә үтеп кергән җиңүче, көчле һәм бәхетле кеше дип хис итәсең.

Серләр ачылу өчен сәбәп, нинди дә булса сорауның маңгаеңа килеп төртелүе һәм шуңа җавап табу өчен үҗәтлек кенә кирәк. Шаһинур менә шушы хикмәткә төшенә башлаган иде.

Бәрәңгеләр көзен әйбәт кенә төшеп урнашты урнашуын, саламъһәм калын такта түшәлгән базда кышны да исән-сау чыктылар. Март аенда беркадәресен орлыкка һәм ашарга аерып алганнан соң, шикәрдәй бәрәңгене әле җәй буена салкынча һәм караңгы базда үрдермичә, сыйфатлы итеп саклый белергә дә кирәк. Җир кешесе моның хикмәтен тапкан. Халыкта «базга кар салу» дип атала торган бу эшләр, гадәттә, март аенда башкарыла. Инде утырган, тыгызланган, дым тартып авырайган кар көртләрен агач көрәк белән шакмакларга бүлгәлисең дә берәм-берәм баз авызына ыргытасың. Квадрат яктылык рәвешендәге кар кисәге көрәктән шуып-очып дигәндәй аска томырыла да ухылдап шартлый! Аның авазы яз килгәнен, муллыкның ишек кагуын, тормышка сусау хисләренең мәңгелеген искәртә кебек...

Быел исә кыш бик сәер килде: октябрьдә үк җир-сулар бозланып туңуга карамастан, декабрьгә кадәр кар төшмәде. Кешеләрне шатлыктан мәхрүм итмим дигәндәй, Яңа ел төнендә урап-урап, катлы-катлы итеп кар яуды да, тагын өзеклек, таң ата да кич була торган игезәк көннәр китте. Кыскасы, кар аз иде, ул елны юньләп кар төшмәде. Кар бабай яисә кар-крепость ясауның тәмен белгән балалар чын кышның ни икәнен тәмам оныта яздылар. Рәшәткә биеклеге көртләрнең булмавы бала-чага һәм өлкәннәр өчен дә күңелсез бер хәл иде.

Әмма кар базында салкынчарак торырга һәм бәрәңге җәй буе әйбәт сакланырга тиеш.

...Шаһинур уклауны хәтерләткән, әмма аңардан озынчарак лом белән кизәнә дә кизәнә. Күтәрелеп суккан саен очлы лом астыннан зәңгәрсу-яшькелт төстәге боз кисәкләре чәчрәп-очып чыга! Аларга ияреп, шулчак тирә-якка ак йолдызлар тузаны да сибелешә. Челтер-челтер килеп боз катламы кыела, һаман кыела бара. Уч төпләре генә түгел, уң бармагы белән ломны кысып тотудан маңгае да тирләп чыга Шаһинурның. Бераздан тимер ломны әтисе кулларына ала. Селтәнүе көчле һәм саллырак булганга күрә, боз кантарлары мулрак умырылып чыга. Алар инде кечерәк тау хәтле булып өелде.

Тирән эчле көрәк белән Шәһинур шуларны җигүле ат чанасына төйи башлый. Үрәчәләргә кадәр күтәртеп, чана төбенә брезент торыпша җәелгән. Боз кисәкләре — елгыр балык сыман: аз гына саксызлык күрсәттеңме, көрәк йөзеннән шуа да чыга. Әйтерсең, качышлы уйнарга телиләр. Барыбер кызыклы, мавыктыргыч эш бу. Кайчандыр су коенган елга өстендә аягүрә басып тор һәм шуның бозлы халәтен үзеңә буйсындырып кара әле син!

Тагын да мөһимрәге — әтисенең кар юклыкка кат-кат пошынуын ишетеп, Шәһинур олыларча бер җилкенү белән тәкъдимен әйтеп салган иде:

— Елгада боз житәрлек ич, әти. Әллә шуны ташып карыйк микән?

Әтисе бу тәкъдимгә соклануын сиздерергә ашыкмады, серле итеп мыек астыннан елмайды гына, аннары бераздан:

— Әйе шул... Боз кисәкләре озаграк та сакланачак әле,— дип, килешүен белдерде.

Ат чанасын түбәләмә итеп, берничә мәртәбә боз алып кайттылар. Йөкнең кайткан берсен түкми-чәчми кар базына бушата бардылар. Ярты көн дигәндә бәрәңге, каймак, сөт-катык кебек ризыклар саклanaсы тирән «суыткыч» әзер булды.

## 5

Бишенче сыйныфта «утырып» калган Мәхмүт Шәһинурлар классына әләкте.

Хикмәт нәрсәдә булгандыр, Мәхмүтнең әтисе — телсез, әнисе чукрак иде. Хәер, авыл кешеләре моңа тәмам ияләшкән инде, ир белән хатынның үзләре генә белгән телдә аңлашуына бигүк исләре китми. Табигать аларны ни өчен рәнҗеткән, ни өчен сөйләшү-ишетүдән мәхрүм иткән — күпме эзләп тә әлеге сорауга җавап тапканы юк Мәхмүтнең. Йөзенә бәреп әйтмәсәләр дә, кызлар-малайлар аны читтән генә бармак төртә-төртә үрти һәм мыскыл итәләрдер төсле тоела. Шуларны уйлый-уйлый да, Мәхмүтнең күңеленә кайчак ачулы хисләр, гарьләнү бәреп керә. Андый чакларда дөньяга рәнҗеп алса да, үпкәсен белдерми, эчкә йотарга тырыша. Мәхмүтләр ихатасында — җилкапка, кышын аны кар-буран күмеп китә, җәйләрен яңгыр яуганда ышыкланыйм дисәң, ни түбәсе юк. Үсеп кенә җитсен, шыгыр-шыгыр килгән җилкапканы берниндн буран күммәслек, җил-яңгыр тимәслек биек түбәле, имән баганалы менә дигән өр-яңа капка белән алыштырачак Мәхмүт. Аның уенча, балта-пычкы тотар өчен яхшы уку мәҗбүри түгел.

Уку димәктән, гаиләдә берләнбер малай булганлыктан, йорт эшләренең байтагы Мәхмүт җилкәсенә төшә. Кар көрәү, коедан су ташу, мал асларын җыештыру аның өчен берни түгел үзе. Киресенчә, хезмәттән, әти-әнисенә булышудан тәм таба ул. Тик менә дәрес әзерләргә вакыты аз кала. Әзерлим дисә дә өйгә бирелгән күнегү һәм мәсьәләләрнең очына чыга алмый. Әти-әнисенең дә ярдәме тиярлек түгел. Дәресләргә, Мәхмүт үзе укуны чын-чынлап яратмый, «икс-игрек» кебек нәрсәләрне исә бөтенләй өнәми.

Нәтиҗә аянычлы иде: авыл йортларының иң читендә яшәп яткан Мәхмүт бишенче класста бер елга утырып калды. Күңеленнән нык ояса да, тора-бара бу хурлыкка күнегә төште. Авылда башлангыч сыйныф кына булганлыктан, бишенче класска күрше авыл мәктәбенә йөреп укышлы иде. Бередәге мәктәп сукмагын инде бер ел чамасы таптаган Мәхмүткә юлдаш булып тагын өч малай өстәлде: Шәһинур, Госман, Ильяс. Аларның укулары әйбәт, күндәлекләрен яхшы билгеләр бизи. Дәрестән соң бергәләп кайталар кайтуын, әмма арадан Мәхмүтнең эчен еш кына корт кимергәли: алар кем дә, син кем, янәсе...

Ике чирек буена түздә Мәхмүт, аннары түземе шартлады. Бөртекләп җыелган барлык ачулары күңеленә таш булып утырган иде аның. Беләге таза, көче җитәрлек, өстәвенә яше дә зуррак — өч иптәше арасында Мәхмүт үзен кинәт кенә командир шикеллерәк тота башлады. Сүзен тыңлыйлар ич әнә, буйсыналар, хәтта бераз куркалар да шикелле. Шушы уйлары ныгый төшкәч, көннәрнең берендә Мәхмүт каты җәза уйлап чыгарды: моннан соң кем дә кем «биш»ле ала икән, кайтканда шуны юлда тотып кыйнарга!

Беренчеләрдән булып җәзаны Шаһинур татыды...

География дәресе иде. Кара такта уртасына җирнең ярымшарлар рәвешендәге географик картасы эленгән. Үткән дәресне сөйләтер өчен укытучы такта янына Шаһинурны чакырды. Таулар һәм аларның төзелеше, үзенчәлеге турында сөйләде Шаһинур, «тау менгән» саен төртелеп калгандай итте: сүзләре, җөмләләре буталды... Чөнки «дүрт»легә дә риза булачак иде ул. Укытучы, үч иткәндәй, аның җавапларыннан канәгать иде шикелле. Ләкин ул, гадәтенчә, өстәмә сорау бирүне кирәк тапты.

— Әгәр картадан Гиндекуш тауларын күрсәтеп бирсәң, бүгенге җавабыңа «биш»ле куям, Нәҗмиев.

Класста тынлык урнашты. Күз-колак ишетмәгән бу тауны эзләп табармы, юкмы Шаһинур? Ул әнә, күрсәткеч таягын кулында бөтерәбөтерә, картага төбәлгән. Аның уйларын тоткарларга, игътибарын читкә тартырга теләгәндәй, нәкъ шул чакта зәңгәрсу Тын океан өстенә бер чебен килеп кунды. Чебен түгел, әйтерсең, озынча бер кара нокта. Менә ул салмак кына хәрәкәтләр белән Австралия кыйтгасы яныннан шуып узды. Кара нокта түгел, гүя су асты көймәсе өскә калкып чыккан да, Һиндстан якларына таба йөзеп бара.

Шаһинурның кул бармаклары тирләп чыкты...

Әллә төпкә батты шунда — бераздан картадагы «су асты көймәсе» юкка чыккан иде. Ә укытучы, тәрәзә аша еракка төбәлгән дә, җавап көтә. Гиндекуш тауларының кайдалыгын белмәскәме! Картадан ничәмә тапкыр караганы бар: әнә каршыда, кул сузымы җирдә генә ич ул. Еракеректагы таулар артыннан вулкан кратерлары карап тора сыман. Укыганы һәм ишеткәне бар Шаһинурның: күп кенә тауларның кочагында утлы-давыллы вулканнар посып ята. Аларның кайчан, ничек уянасын берәү дә төгәл генә белми. Әллә шулар хакында сөйлисе микән?

Шаһинур, керфекләрен йомып, бер мәлгә күзләрен аска төшерде. Ләкин бу мизгел генә иде. Аның бит «биш»ле аласы килми. Сүзне вулканнарга таба борып җибәрсәң, темадан читкә китү булачак. Укытучы моны сизми калмас һәм билгене дә түбәнәйтеп куяр, бәлки?

— Гиндекуш — Азия материгындагы иң зур тауларның берсе. Анда вулканнар тезмәсе урнашкан,— дип сөйләп китте Шаһинур.— Вулканнар булган җирдә кеше тормышына куркыныч яный...

— Нәҗмиев, син ялгыш сөйлисең. Әфганстан җирендә вулканнар юк.

— Бар, апа, бар! Булырга тиеш,— дип, күзен дә йоммый бәхәсләшергә, үзе уйлап чыгарган фаразны чын-чынлап якларга керешге Шаһинур. Сүз көрәштерү әле тагын берничә минут дәвам итте. Укытучы Гиндекуш тезмәләрендә вулканнар бармы-юкмы икәнен үзе дә ныклап белми иде, күрәсең, шуңа күрә ул:

— Материалны әйбәт сөйләгән өчен түгел, үз фикереңне яклый белгәнең өчен «биш»ле куям, Нәҗмиев! — диде дә класс журналы өстенә иелде.

...Дүрт малай мәктәптән кайтып бара. Юлның очы авылга барып тоташкан, анда күренер-күренмәс булып ак квадрат рәвешендәге түбәләр, йорт-каралты теземнәре шәйләнә. Сөйләшми атладылар. Ничектер үзеннән-үзе шулай килеп чыкты — аркасындагы сумкасын терсәге белән төзәткәләп, Шаһинур алдан бара. Арада яшерен бер чик барлыкка килгән

иде инде. Дөресрәге, икс якның уртасында, ызгыш алмасыдай йомарланып, «биш»ле билгесе ята.

Көн жылымса, җепшегрәк иде. Башлаучы Мәхмүт булса кирәк, кар йомарламының беренчесе аркадагы сумкага килеп тә бәрелде. Аннары икенчесе... өченчесе... Шаһинурның җилкәсендә кар-ядрәләр ешрак шапылдый башлады. Берничәсе колак төбеннән дә сызгырып узды. Ул да түгел, кемдер аяк чалып, Шаһинурны юл читенә мәтәлдерде. Ике кулы белән битен каплавы, бөгәрләнеп ятуы кая, аркасында киез итекләр уйнап алды.

Кыен, бик кыен иде аңа бу минутларда... Аркасына түгел, гүя шәрран ачык йөрәгенең уртасына китереп типтеләр. Тешләрен кысып булса да еламаска, тырышты Шаһинур, тик барыбер күзләреннән ике бөртек яшь тамчысы атылып чыкты. Битендә эрегән кар тамчысы белән кушылып, алар муенга, яка эченә таба тәгәрәделәр.

Ничек тиз башланган булса, әлеге ямьсез кыйнашу шулай тиз генә төгәлләнеп тә өлгерде. Мондый җәза эшендә беренче тапкыр катнашкан Госман белән Ильяс, эшнең азагы шулай тиз бетүгә куаныпмы шунда, җинел сулап куйдылар. Шаһинур күңелендә исә эчке бер рәнҗү сулкылдый иде: нигә үзендә өчәүгә каршы торырлык көч тапмады ул?..

Яман эш телләреннән тоттымы, тагын байтак кына сөйләшми бардылар. Авылга кайтып җитәрәк Мәхмүт малайларны туктатты, сүзен башлаганчы иң элек йодрыгын уйнатып алды.

— Әгәр берәрегез әти-әнисенә яки укытучыларга әләкли икән, яхшылык көтмәгез! Сатлык җанның кем икәнен бик тиз ачыкларбыз.

Дүрт малай арасындагы бу ямьсез һәм яшерен сер тагын күпмегә барыр иде икән — әйтү кыен. Яхшы гына укып йөргән Госман белән Ильяс ялгышып «биш»ле алмас өчен җан-фәрман тырышалар. Шаһинурга исә укуын төшерергә һич тә ярамый. Аның үзе генә белгән әллә ничаклы хыяллары, уй җитмәс планнары бар...

Көтмәгәндә хәлләр үзгәрде дә куйды.

Балта остасы булачак Мәхмүт, сыерчык оясының иң матурын ясаганга күрә, хезмәт дәресеннән «биш»ле алып куймасынмы!.. Үзе уйлап чыгарган уенның корбаны Мәхмүт алдан атлый әнә. Сәбәп чыкканга, рольләр алмашынганга куаныпмы, Госман белән Ильяс беренче йомарламны тегенең аркасына чәпәп тә өлгерделәр. Өчәүнең берләшүеннән шүрләгән, күрәсең, Мәхмүт озынча муенын яка эченәрәк яшергән, юашланып калган. Үзе генә түгел, аның хәтта искерә төшкән бүреге һәм пәлтәсенә чаклы мескенәеп калган. Шаһинур ни кылырга белмәде. Кар-ядрәләр, нәкъ элекке чактагыча итеп, гүя аның аркасына килеп төшәләр иде. Шаһинурның тәне чымырдады. Йомарлап тоткан кары, кулыннан төшеп китеп, урталай ярылды. Аның күңеле дә, уйлары да әнә шулай кап урталай бүленгән иде бу минутларда.

Тегеләр Мәхмүтне аяк чалып типкәләргә керешкәч тә түзмәде, бар көченә кычкырып җибәрде:

— Нишләвегез бу? Туктагыз!

Госман белән Ильяс икесе тиң берьюлы тынсыз калдылар. Вакыйганың мондый борылыш аласын көтмәгәнлектән, аптырау-гаҗәпләнү тулы күзләре шар ачылган иде. Баштарак аңлаешсыз, өзек-өзек авазларны авыз эчендә әвәли торгач, ниһаять, телгә килделәр:

— Шул кирәк аңа!

— Безне җәлләдеме соң үзе???

Шул арада Мәхмүт егылган җиреннән күтәрелде. Аның учында да бер йомарлам кар кисәге иде. Әллә нинди сәер, кызганыч кыяфәттә басып тора ул, буш кулы белән җиңендәге карларны каккалый.

— «Ике»ле алган өчен булса бер хәл,— диде Шаһинур, дулкынлануын һаман да тыя алмыйча. Малайлар аны-моны уйлап өлгергәнче, ул да иелеп кенә аяк астыннан кар йомарлап алды. Дүрт малайның кулында — дүрт кисәк кар йомгагы. Шаһинур аларның барысын бергә кулына алды

да күкрәгенә кыса-кыса, кулларында әвәли-әвәли зур яңа йомарлам ясады. Классташларына төбәп әйткәне бик гади, аңлаешлы һәм барысының күңелендә туып килгән хисләргә тәңгәл килә иде:

— Киләчәктә безгә менә шулай бердәм, тату булырга кирәк!

Күренеп тора: Шаһинурның бу кыюлыгы, тапкырлыгы һәркайсына ошаган иде. Кызыксынып, аңлашу эзләп бер-берсенә караштылар. Кар салкыны Шаһинурның ялангач кулларын туңдырган иде, ләкин ул моны сизмәде дә кебек. Иң куандырганы — арадагы салкынлык, бер-береңә ышанмау, куркып-шикләнеп караулар юкка чыккан иде.

Әле исеме дә табылмаган бер хис туды күңелләрендә. Әле ныклап торып татымаган бу хис, кояш нурларына бәрелеп, нечкә авазлы кыңгырау сыман чеңли иде.

## 6

Малайлар ни өчен агач башына үрмәләргә ярата? Алар күккә күпмедер якынайган кебек булалар. Ә ни өчен песидән дә уздырып түбәгә үрмәлиләр? Чөнки йорт түбәсеннән дөнья бөтен барлыгы, тулылыгы белән ачылып китә. Күгелҗем-зәңгәр офыклар артында нинди тормыш кайный, анда тагын нинди авыллар һәм шәһәрләр бар икән? Күкнең бер-бер чите, очы-кырые була микән? Канатлы булса, карлыгачтай җитез очып кына, кеше иң элек менә шушы сорауларга җавап эзләр иде, мөгаен. Хыялында күккә якынайган саен күк, киресенчә, синнән хәйләкәр бер төстә ерагая гына бара. Менә шушы хәл — аңлашылмый торган нәрсәләрне аңларга тырышу хисе күңелдә хәттыйн ашкан үҗәтлек тудыра. Соңгы вакытларда Шаһинур уенчык парашют ясау уе белән җенләнә. Сызымын үзе уйлап тапты, кәгазьгә төшергәнче аны кат-кат төзәтте, камилләштерде. Уенчык кына булса да, түбәдән ташлау белән ул чын парашют сыман ачылып китәргә, салмак кына йөзеп җиргә төшәргә тиеш иде. Шаһинурның уенда шулай, ә чынлыкта ничек килеп чыгар бит әле: гөмбәзе ачылырмы, кулдан ычкындыру белән утын агачыдай туптуры җиргә мәтәлеп хур итмәсме?

Һәрхәлдә, сораулар күбрәк туган саен, парашютны ясап карау теләге көчәя генә барды. Аның гөмбәзен йә җиңел ситсадан, йә ныклы юка кәгазьдән ясау дөрес булачак. Уйлады-уйлады да, шәһәрдә кондитер фабрикасында эшләүче туганнары биреп җибәргән юка, җиңел, ләкин ертылуга тиз генә бирешми торган кәгазьне сайлады Шаһинур. Шәлъяулык зурлыгындагы кәгазьне гармун күрегедәй бөкләп, җыйнап китергәннән соң, аның өске өлешен ак җеп белән тегеп куйды. Очыш вакытында гөмбәз туптай кабарып торсын өчен нишләргә? Моның да җаен тапты «яшь конструктор»: урта өлешләрне берничә урыннан ярып, анда өстәмә кисәкләр ябыштырды. Җиңелгә килсен дип, парашют баулары кәтүк җебеннән эшләнде. Баш, муен, кул-аякларын азмы-күпме рәвешкә кертеп, коры утын кисәгеннән агач солдат сынлы бер нәрсә әмәлләгән иде Шаһинур. Шуны китереп таккач, скрипка кылларыдай тартылып, ак җепләрдән челтәрле конуска охшаш сурәт пәйда булды.

Күңелле, тамашалы, иҗдиһатлы эш иде бу. Гомердә парашют күрмәгән авыл күге шаккатсын әле!

Бераздан Шаһинур түбәгә үрмәли иде инде.

Җирнең беренче ясалма иярченен очырганда галимнәр нинди хис кичерсә, аны да әнә шундыйрак уй-хисләр биләп алгандыр бу минутларда. Очармы, юкмы?..

Көнозын кояш астында ятып, түбә такталары мич стенасыдай җылынган. Җәйге йомшак җил чәч төпләрен кытыклый. Урамның аулак чагы икән, анда кош-корттан гайре җан иясе күренми. Боларны тойса, әллә ни игътибар итми генә күздән кичерсә дә, Шаһинурның уйлары парашют тирәсендә бөтерелде, әлбәттә: бауларны ничек тә чуалтмаска

кирәк. Очышны сузу ләззәтен туктатырга һәм тәвәккәлләргә вакыт. Бер... Ике... Өч!..

Шаһинур көткән могҗиза булырмы? Өскә таба җинелчә чөеп җибәргән парашют аска тартылу белән мизгел эчендә ачылып китте! Кабарынкы гөмбәз бауларына асылынган агач солдат сизелер-сизелмәс чайкалып алды, әйтерсен, беренче очышы уңаеннан дулкынлану кичерә иде ул. Ак парашют, Шаһинурның уйларын үзенә ияртеп, бәрәнге бакчаларына таба йөзеп китте. Әллә каян гына җил исеп, аны ызан уртасында үсеп утырган карт тупылга таба куалый башлады. Менә ул һава сөзеп, мәгърур бер салмаклык белән шуның киң, биек, чатлы-чатлы ябалдашлары өстенә якынлаша.

Тизрәк җиргә төшәргә, артыннан барырга кирәк!

Төшү-менү өчен җайлы булсын дип, түбә почмагына баскыч сөяп куелган иде. Егылмаска тырышып, сак-сак адымнар белән Шаһинур түбә сыртыннан шунда таба ашыкты.

Бәрәнге бакчасына атылып чыгу белән ни күләргә, ни еларга белмичә аптырап калды баштарак. Күпме көч куеп ясалган парашютны чиллә җиле тупыл ябалдашлары кочагына илтеп ташлаган иде. Әнә ул гөмбәзе, баулары-ние белән ботаклар әсирлегенә эләккән. Уч төбедәй яфраклар арасында, күренер-күренмәс булып, агач солдат тыпырчына... Шулай бервакыт кинода парашют белән сикергән хәрби очучының агач башында чарасыз-нисез эленеп торуын күрсәткәннәр иде... Кинодагы хәлләр тормыш дөреслегенә туры килә, күрәсең.

«Агач солдат»ны, дөресрәге, парашютны коткарырга тырышуның нәтиҗәсе булмады. Колга белән үрелсәң дә, агач башына үрмәләсәң дә кул җитмәс биеклектә уралып калган иде ул. Парашют җиргә төшмәде, яфраклар һәм яңгыр шавын тыңлый-тыңлый әле бик озак күктә, ачык һавада яшәүгә дучар ителгән иде...

Мәктәп китапханәсеннән «Техника молодежи» дигән журнал яздырып алгач, Шаһинурның уе тагын да алгарак, ераккарак китте. Нинди генә сызымнар, нинди генә мәгълүматлар юк иде анда! Теләгең генә булсын, бу дөньяда әллә ниләр уйлап чыгарырга мөмкин икән ич. Күргәне бар Шаһинурның: калтырча бер комбайн урып киткәннән соң аның артыннан басуда күпме башак, ничаклы бөртек әрәмгә коелып кала. Ашлыкның бөртеген дә югалтмый торган яңа комбайн уйлап табарга сүз бирде ул үзенә. Тик моның өчен белем кирәк. Русча журналдагы күп кенә сүзләрне, баш әйләнгеч терминнарны еш кына аңлап та бетерми ул. «Нигә татарча, үзебезчә итеп шундый журнал чыгармыйлар икән бездә?» — дип гаҗәпләнә иде кайчакны.

Шулай да бер көн, «Ялкын» журналы алгач, кош тоткандай куанып йөрде ул. Балалар өчен чыга торган бу журналның соңгы битендә телевизор антеннасының сызымы бирелгән һәм аны ничек, нәрсәләрдән ясарга кирәклеге дә өйрәтелгән иде. Дөрес, хәзергә телевизор колхоз рәисе һәм партоешма секретаренең өендә генә бар. Аны табу читен, авыл кешеләренең акчасы да санаулы гына. Тормышны һаман алга бара, диләр ич,— телевизорлар да сатуга күбрәк чыга башлар, авылның кесәсе дә бөтәеп китәр берзаман. Шулай булгач, антенна ясый торуның зыяны юк.

Тимер-мазар әйберсен, чыбыкларны бер-берсенә ялгау өчен канифоль кирәк — моны яхшы белә Шаһинур. Кибеттә булмый калмас, дип уйлады һәм урамга чыкты. Маңгаендагы язуын яңгыр юып төссезләндергән, тәрәзәләренә тимер рәшәткә калакланган кибет авылның югарыгы башында иде. Аңа әле тәпиләп байтак менәсе бар. Урам буш, өлкәннәр эштә, тиле Галиәхмәт йорты тирәсендә генә берничә малайның туп уйнавы күзгә чалынды.

Галиәхмәт абый өйдә түгелдер, күрәсең, юкса таяк тотып бик тиз чыгып җитә ул һәм йорты тирәсендә уйнаган малай-шалайны пыр туздырып куа башлый. Кура һәм шомырт котырып үскән бакчасына каракълар төшмәсен, янәсе.

Һәр авылның, кимендә, бер акыл иясе, бер юләре була, дигәннәр. Галиәхмәт абый соңгылар җөмләсеннән иде. Табигать аны ни өчен рәнҗеткән, башкалар төсле гаилә корып, бала-чага үстереп, адәмчә яшәү бәхетеннән ни өчен мәхрүм иткән — аңламассың. Акылны, саулыкны, язмышны сорап алып булмый шул аны. Тавык кетәгедәй йортында берьялгызы яшәп ята ул. Кешеләр белән әллә ни аралашмаганга күрә, аның кайчан, ничек, ни нәрсә ашаганын белүче-күрүче юк. Дөрес, күршетирә камыр ризыгы пешергән чакта бәлеш катысы, гөбәдия, кабартма ише нәрсәләр эләккәли аңа. Галиәхмәт абыйның тагын бер сәерлеге — «уфалла» арбасын өстерәп чыга да җәй озын елга буйларыннан, амбар һәм ферма тирәләреннән ботак-сатак, иске такта, ташландык агач кисәкләре җыя. Урамда аунап яткан тазарак йомычка кисәкләрен дә арбасына сала. Үзенә күрә авылны, санитар шикелле, әнә шулай чүп-чардан, артык нәрсәләрдән чистарта ул. Җыйган малын кечкенә генә ишегалдының бер читенә бөртекли-бөртекли шулкадәр пөхтәләп өя ки, утынлык оясы түгел, печән чүмәләсе диярсең. Андагы төрле «сорт» утыннар кыш буе өен җылытачак аның.

Галиәхмәт абый мал-туар асрамый, әмма арт бакчасында бәрәңге үстерә. Мал-туары булмагач, җир ашлардай тиресе дә юк аның. Менә шуңа күрә юл тузанында сыер яисә ат тизәге күреп алдымы, бушка килгән бу «хәзинә»не тизрәк иске чиләгенә тутыра... Хәер, мал димәктән, мәчесе бар икән әле аның. Анысына тикле сәер: онда коенып чыккандай ап-ак бу мәченең бер күзе яшел, икенчесе зәңгәр иде.

Тиле Галиәхмәт бакчасын әйбәт саклый саклавын, әмма малайларда да усаллык җитәрлек. Җай килгәндә йә ишек-тәрәзәсен шакып китәләр, йә бакчасына таш атып узалар. Андый чакта Галиәхмәт абыйның тавышы яшен яшьнәгәнне дә күмеп китәрдәй хәтәр була. Андый чакта кулына эләгәм димә, кызулык белән имгәтеп ташларга да күп сорамас ул.

Шуларны уйлап, Шаһинур малайларга таба якынайды.

Арадан кемдер әллә юри, әллә саксыз кыландымы шунда: уктай очып барган туп Галиәхмәтнең тәрәзәсенә килеп бәрелде. Шуның артыннан ук авыл өстендә «яшен» яшьнәде! Галиәхмәт абый яшелле-күкле тавышлар белән кычкырып ихатасыннан чабып чыкты һәм малайлар өстенә ташланды.

Тиле Галиәхмәтнең кулында... агач саплы тимер сәнәк иде!

Куркудан малайларның берсе чалбар балагына «җылы су» җибәрде. Башы-күзе тонган малайлар, чебендәй сибелешеп, шундук җан-фәрман йөгерделәр. Гаебең булмаса да, урам уртасында берүзең басып калу хәтәр иде. Тиле тукталыр, сине тыңлап торыр дисеңме! Әнә бит ул ничек ярсыган, йөзе куркынычлы кыяфәттә чалшайган. Кулындагы сәнәк очлары һаваны ертып-ертып ала шикелле...

Бу уйлар, күренешләр, кинодагы шикелле, мизгел эчендә чагылып узды. Ак-караны аермас хәвефле сәнәктән котылу өчен Шаһинур да бар көченә йөгерә башлаган иде. Тезләрен каната-каната, малайларның берничәсе капка астыннан кереп шылды. Әнә, Самат та үзләренең капкасыннан кереп югалды. Сулышың бугазыңа ябышам дип торганда тагын күпме чабарга мөмкин болай? Шаһинур, кырт борылды да, Саматлар капкасына бәреп керде. Аяк астына керә язган тавык чырайлап читкә атылды. Өенә кереп бикләнгәндерме, Самат суга салгандай юкка чыккан иде. Кай төшкә качарга да, башны кая гына илтеп тыгарга? Бу мәлдә Шаһинурның уйлары яшеннән дә җитезрәк хәрәкәт итә иде.

Үч иткәндәй, тиле Галиәхмәт нәкъ менә Саматлар ишегалдына килеп керде һәм кергән шәпкә туп-туры лапаска узды. Шаһинур лапастагы печәнлеккә качып өлгергән, өстен печән белән томалап, бушрак бер почмакка поскан иде. Тәгәрмәчтәй бөгәрләнеп яткан, сулышын тигезли алмый азаплана. Борында печән һәм коры тузан исе.

...Галиәхмәт абый нидер мыгырдана-мыгырдана агач баскычтан күтәрелә.

...Ямьсез итеп, гадәтенчә, кызу-кызу гына сүгенеп тә алгалый... Менә аның сәнәге печән арасына батып керде... Коры печәннең сабак-яфракларын тишеп үтте дә, әле тегендә, әле монда кыштырдый сәнәк... Корбанын эзләп капшана!

Дүрт япьле сәнәк очына Шаһинурның язмышы эленгәндер, бәлки?

Бер гаепсезгә җәза алу — ахмаклык, ап-ачык дөреслекне аяк астына салып таптау була түгелме?

Шуңа охшаш, шундый мәгънәгә якын сораулар умарта күчедәй кайнаса да, аларга җавап бирергә тамчы да вакыт юк иде. Курку, хәвеф, ниндидер илаһи көчкә ялвару, нәфрәт, яшисе килү — болар бар да нәни бер йөрәккә төшеп укмашкан һәм аны сикереп чыгардай дәрәҗәдә тибәргә мәҗбүр иткән иде...

Бәхеткә күрә, тиле Галиәхмәтнең сәнәге Шаһинурга кадәр барып житмәде. Язмыш аны килер көннәр, яшәү һәм үлем көрәшенең әле тагын да рәхимсезрәк булачак мизгелләре өчен саклап калασы итте, күрәсең.

Иң кыйммәтлесе — Шаһинур кешенең акыл һәм физик кимчелегеннән көләргә ярамаганлыгын аңлады.

## 7

Тугызынчы класста укыганда Шаһинур хәйран гына буй тартып, үсеп, ныгып китте. Йорт эшләрендә булышуны әйтәсе дә юк, уйлап карасаң, хәтта гармунда уйнау да аның өчен бер дигән физзарядка, мускул чыныктыру иде. Менә шуңа да мускуллары күзгә күренеп тыгызлана, йомрылана төште. Ходай биргән тазалык янына күңел көрлеген дә китереп кушкач, аңарда кара чәчле, бите һәм күз-кашлары дөрес утыртылган түгәрәк йөзле, уйчан, сирпеп кенә елмая белгән, киң карашлы күңелгә ия булган яшүсмер шәхесен тоярга мөмкин иде.

Авылда мотоцикл күренә генә башлаган еллар. Таза тормышлы, акчалы, техниканың рәтен белгәннәр аны район үзәгенә бара да сатып ала. Кош канатыдай ике якка җәелгән руль, елкылдап торган фара һәм төтен уздыргыч торба, күн тышлы озынча утыргыч, бозау башына охшашлы бензин багы... Махсус педаленә аяк белән тибәсең, гөрләп кабына да китә! Зәңгәрсу төтен бөркеп, тузан тасмасы калдырып урамнан мотоцикл белән узу — бәхетле җаннар эше.

Шаһинур акча тупларга булды. Җәйге каникул житү белән бригадир аңа кулыннан килердәй эш кушарга вәгъдә бирде. Сука ярдәмчесе, аннары атлар көтү... Ләкин моның акчасы бик аз, тиенләп кенә төшә, чөнки хезмәткә күп очракта ашлык белән түләү каралган иде.

Нәкъ шул көннәрдә авылга ерактагы Мурманск шәһәреннән «Тәпәччәй» кушаматлы Сәетҗан кайтып төште. Солдатта булган жиреннән шунда эшкә калган бу. Өйләнмәгән егет. Өстендә яхшы киемнәр, аягында затлы шиблет моның. Гармунчы буларак, Шаһинур кызлар-егетләр арасына иртәрәк барып керде. Дөресрәге, кичләрен җырлата һәм биетә ул аларны. Сәетҗан авыл кичләренә, туган як җырларына бик тә сусап кайткан иде. Клуб идәннәре үзен истә калдырырлык итеп нык басып, җегәр белән, бөтерелә-бөтерелә биеде ул. Шаһинурның гармунда уйнавын, зурларча сөйләшә белүен яратты. Әллә шуңа инде, бер көн көндез егет булып килгән үсмерне үзләренә чакырып кертте.

Ишегалды бакчасында җәйлеккә дип ясалган такта өстәл бар иде. Шунда кереп утырдылар.

— Ну, Шаһинур, сөйләп җибәр, синдә ни хәлләр?

— Тагын бер ел укыйсым калды.

— Укырсың. Башыңны түгәрәк, диләр ич синең.

— Анысы инде, Сәетҗан абый, берәүнең дә башы шакмак түгел.

Кунакка кайткан Сәетҗан бу тапкыр сүздән рәхәтләнеп көлде генә. Аннары әйтә куйды:

— Шулаен шулай. Ләкин сәләт, осталык дигән нәрсәне Ходай төрле кешегә төрлечә өләшеп чыккан шул... Бу хакта мәзәк тә ишеткәнем бар минем. Врачлар ике генералның баш миен тикшереп караганнар, ди. Беренчесендә сырлар хәйран мул икән. Икенчесендә нибары бер сыр ярылып ята, ди. Беләсеңме нинди эз ул?

— Юк.

— Фуражка эзе, тәпәччәй!

Бу юлы Шаһинур елмайды: фуражка киеп йөрүдән бүтәнне белмәүче бушбугаз генералдан ачы итеп көлеп тә караганнар соң... Үзенә кушамат булып ябышкан «Тәпәччәй» сүзен исә Сәетҗан әнә шулай кәефле яисә бик нык ачулы чакларында гына әйтә, диләр.

Сәетҗан абый берничә минутка гына югалды да өеннән балык кисәге алып чыкты. Түтәлдән генә йолкып яшь, таза, йомры суган әрчеде. Божра-божра итеп туралган балык, суган һәм яшел кыярдан табигать муллыгы, юмартлык бөркелеп тора иде.

— Яшел төс яшисене, кызыл төс ашыйсыны китерә,— дип, суган кыякларын тәлинкәдәге ризыклар өстенә салды.— Яшисе килгәндә ашыйсы килә инде ул.

Кызыл төс дигәне балыкка карата әйтелгән иде. Шаһинурның кызыл балыктан беренче тапкыр авыз итүе. Үзе тозлы, үзе татлы, токмачтай кисәкләрен тел астына салсаң, тәмам эри дә китә!

— Бал эчәсеңме? Корт балыннан әти ясаган.

— Юк,— диде Шаһинур уңайсызланып.

— Әйдә, ярты стаканнан гына тешең кителмәс әле, дару булсын,— дип, Сәетҗан кружка төбенә бераз бал койды.

Клубта, кеше арасында ни сорашып булсын соң, менә хәзер чит җирләр турында рәхәтләнеп сөйләтер чак иде Сәетҗан абыйны. Кунак егет үзе дә, тыңлар кеше барлыгына куанып, сүз арты сүзне борчактай сипте генә:

— Андагы байлыкны белсәң иде син, энем! Ул балык, ул урман дисеңме! Аяк астында аунап яталар дисәң дә ялган булмас, валлаһи. Хәтта җир куеныннан гранитка хәтле чокып чыгаралар. Каенны бездә генә үсә, дип уйлый идем мин элек. Анда да каеннар күп икән.

— Ә балыкны үзегез тотасызмы? — дип бүлдерде Шаһинур, чөнки бу минутта күчтәнәч балыкның койрык тирәсен каезлап маташа иде ул.

— Алдар хәлем юк, мин үзем балык комбинатында эшлим. Без анда тотып китерелгән мал белән кайнашабыз. Мичкәләп тозлау, ыслап киптерү, консервлау дисеңме — төрлесеннән эш иткән бар.

— Сәетҗан абый, алайса кылыч балыкны да күргәнең бардыр синең?

— Бар, әлбәттә. Музейларда яткан елтыр кылычтан ким түгел алар.

— Ә ике күзле камбала буламы?

— Була, ник булмасын, андыйлары күбрәк дингез төбендә яшиләр...

Мавыктыргыч булды Сәетҗанның сөйләгәннәре. Бер урында Шаһинур үзе дә гыйлемен күрсәтеп алырга җай тапты.

— Беләсеңме, Сәетҗан абый, Арктика бозлары елына өч миллиметр тизлектә коры җиргә таба якынаялар икән.

— Китче, менә бу кызык! Тә-әк...— Сәетҗан ничәмә-ничә балыкны саңагыннан алган бармаклары белән чәч артын кашып куйды.— Шулай да ул бозлар Мурманскига килеп җитсен өчен фәлән миллион ел кирәк булачак икән әле.

Тагын байтак сөйләшеп утырдылар. Шуны ачык сизде Шаһинур: аның авылдашы тегендә акчаны мул эшли булса кирәк. Мотоцикл гынамы сиңа, машина алырга ук җыенадыр әле ул, белмәссең. Шаһинур мотоцикл алырга теләге барлыгын, шуңа күрә урак өсте җиткәч тә комбайнчы ярдәмчесе булып эшләячәген сөйләп бирде. Бу сүзләрне Сәетҗан үтә игътибар белән, күзләрен каядыр еракка төбәп тыңлады. Аның хөкеме кискен, ышандыргыч иде:

— Алай икән... Ә беләсеңме, колхозда чәчең белән җир себерсән дә кулыңа рәтле-башлы акча кермәячәк синең... Иң яхшысы, давай, безгә эшкә кил син!

Көтелмәгән бу тәкъдимне Шаһинур икеләнү катыш куанып, дулкынланып кабул итте. Менә бит нинди зур кешегә саный аны Сәетҗан абыйсы!

— Танышлар, дуслар күп минем анда. Сиңа яраклы гына эшне табарбыз,— дип тә өстәде әле.

Тагын бер кат бар ягын үлчәп киңәшкәннән соң мәсьәлә хәл ителде: Шаһинур Мурманскига эшкә китәчәк! Барып житми торып, бу хакта әти-әнисенә әйтмәскә булды. Үндүрт яшьлек улларын тора салып ни йөрәк белән шундый ерак юлга җибәрсен ди алар. Соныннан, шәһәргә барып урнашкач, Шаһинур хат белән хәбәр итәр, тынычландырыр, хәлне аңлатып бирер үзләренә. Тәвәккәллек — изге эш, дигәннәр ич.

Сәетҗан юлга бераз акча калдырды һәм ике көн алданрак китеп барды. Мәскәүдә керәсе җирләре, күрәсе кешеләре бар икән аның. Шундагы адресын язып калдырды. Алар, сер саклый белгән ике авылдаш, Мәскәүдә очрашырга, юлның калган өлешен аннары бергәләп дәвам итәргә сөйләштеләр.

Казандагы туганнарына кунакка дип киткән Шаһинур аларның бересенә дә кереп тормады, билгеле, автобустан төшү белән шәһәрнең тимер юл вокзалына ашыкты. Касса тәрәзәсенә чират зур иде, түзде, ахыргача басып торды. Ярым авылча, ярым шәһәрчә киенгән үсмергә бөдрә сары чәчле түти кырын карап алды да Мәскәүгә хәтле бер билет бирде. Шунысы гаҗәп: Шаһинур үзен гаять тыныч, иплe һәм зурларча тота, күңелендә курку дигән нәрсәнең әсәре дә юк иде. Моңа аның сабыр холкы, һәм үз акылы белән эзләп тапкан тәҗрибәсе ярдәм итә — чөнки ул үтә кайгырган, борчуга сабышкан чакларда йөрәк һәм баш миендәге күзәнәкләрнең ныграк тузасын яшьтән үк аңлап алган иде.

«Казан — Мәскәү» поезды китәргә ике сәгать чамасы вакыт бар әле. Казанда беренче тапкыр гына булуы түгел, якындагы колхоз базарын тамаша кылып килде, коньяк кояшының нурын эчеп үскән карбыз телеменнән авыз итте. Аннары чират морожныйга житте... Татлы, тансык ризыклар кәефенә хуш килде.

...Менә, ниһаять, келтер-келтер килеп, билгесез авыл һәм станцияләрне артта калдырып, поезд Мәскәүгә чаба. Вагон тәрәзәсеннән чит-ят җирләрне, аның минут саен алышынып торган чуар манзараларын күзәтеп барган Шаһинур юлдашларына игътибар да итмәде. Тегеләр дә артык сүз катмыйча, кайсы китап укып, кайсы пешкән йомырка ашап, янсә шулай ук тәрәзәгә төбәлеп, һәркайсы үзенә бер шөгыль тапты. Юл барганда кайчак уйланып, тик утырып барудан да зуррак шөгыль юк.

Күрше бүлемнәрдә кемнәрдер сөйләшә, кәрт суга. Ятак-утыргыч капкачларының шапылдап ачылганы ишетелгәли. Радиоданниндидер моң агыла. Кич якынлаша. Вагон эчендә ярым караңгы утлар кабына...

Шаһинур костюмын салып элде, өске каттагы урынга үрмәләде. Яшь чакта ястык кирәкме соң — төшләр дә күреп тормыйча, сәламәт йокы белән иртәнгә кадәр гөмләп йоклады ул.

Перронга килеп төшкәч тә кешеләрнең һәм поездларның күплегенә хәйран калды. Мәскәү чынлап та зур иде, ят һәм таныш түгел иде аның өчен. Мәһабәт биналар, шуларның күккә чөелгән гөмбәзләре сине сиздерми генә кысрыклый, өстеңә аварга тора шикелле. Мәйданда күпмедер басып, тирә-юньне күздән кичереп чыкканнан соң, Шаһинур костюм кесәсенә үрелде. Адресны алырга, шунда өйрәтелгәннәр буенча тизрәк Сәетҗан абыйны эзләп табарга кирәк.

Чү! Түш кесәдә ни адрес, ни акча күренми иде. Кесә төбендә җилләр генә уйный... конверты-ние белән барысын бергә чәлдереп киткәннәр... Хәерсез сәфәр булып чыкты микәнни бу?

Мондый чакта чәбәләнү, уңга-сулга чәчелү килешмәячәген аңлады Шаһинур. Бер белмәгән кешеләр уратып алырлар да: «Ни булды?» — дип сораша, кызыксына, ахыр чиктә кызгана башларлар. Кирәкми, алга таба нәрсә эшләсен Шаһинур үзе уйлап табар...

Иң яхшысы — милициягә хәбәр итү. Юкса болай бер тиен акчасызнисез, ярты-йорты русчаң белән кем каршына барып сүз кушмак, ярдәм сорамак кирәк?

Озын буйлы, җитди кыяфәтле, кулына aклы-каралы махсус таяк аскан бер сержант машиналар хәрәкәтен барлап-күзәтеп тора иде. Чарасыз калган Шаһинур, ике дә уйлап тормастан, аңа таба атлады. Төз-төз басып килде дә яланбаш килеш кенә честь биреп, әйтеп салды:

— Товарищ милиционер, мои деньги сп.........!

Бу урында Шаһинур авыл мужикларыннан ишеткән һәм нәрсәңнедер урлаткан чакта гына әйтелә торган «урычча» сүзне авыз тутырып әйтеп ташлаган иде шул.

Сержант яшь кенә бу «визитер»ның кыланышын баштарак аңламый торды. Аны баштан-аяк күздән кичергәч, кайдан икәнен сорагач кына хәлнең нидирәк булуын чамалады: аның алдында йә адашкан, йә өеннән чыгып качкан үсмер басып тора.

...Нәкъ шул сәгатьләрдә Шаһинурның әнисе әле яңарак суелган, чиста ак чүпрәккә төрелгән сарык түшкәсен күтәреп Казанга китте. Исәбе — шуны сатып, мотоцикл маясына бераз акча юнәтү, каладагы туганнарының хәлен белү, аннары улы Шаһинур белән өйгә әйләнеп кайту иде.

Шәһәр халкы, бигрәк тә мөселман өммәтеннән булса, суйган итнең сыйфатын, төс-кыяфәтен аера белә. Сарык түшкәсен базарда чират торып, тиз арада алып та бетерделәр. Эше беткәч тә Сафия апа иң элек Бишбалтадагы ир туганына юл тотты. Шаһинур аларда юк иде. Хәләхвәл белешкәч, сөйләшә-сөйләшә чәйләр эчкәч, Суконный ягында яшәүче кыз туганнарына кузгалды. Шаһинур анда да юк иде. Саулыкиминлек сорашкач, чынаяк тәлинкәләре бушагач, тәгаен шуларда ятадыр әле, дип уйлап, Спартак урамындагы өченче туганнарына ашыкты.

— Исәнмесез! Шаһинур сездәме? — диде керә-керешкә, тегеләрнең сәламне алганнарын да көтеп тормыйча.

«Юк» — дигән сүзне ишеткәч, Сафия апа тәмам коелып төште, ике кулы белән йөзен каплады.

— Ни булды соң, аңлатып сөйләче, туганкаем?

Сафия базарга килүен, Бишбалта һәм Суконныйда булуын, аңа кадәр бер көн элек Шаһинурның Казанга китеп баруын түкми-чәчми сөйләп бирә дә, инде нишләргә дип, туганнарына инәлә. «Улың — эскерт арасына төшеп югалган энә түгел, табылыр»,— дип юаталар аны. Кул астындагы телефоннан шундук милициягә шалтыраталар. Эзләнү, дежур оперативникларны аякка бастыру — болар бернинди дә нәтиҗә бирми.

Төн уртасында Мәскәү Казан милициясе белән элемтәгә керә.

Сафия апа улының табылуына бер куанса, икенче яктан аның Мәскәү тикле Мәскәүгә ни өчен китеп баруын аңлый алмыйча газаплана.

Шулай итеп, Мурманскига сәфәр тоткан Шаһинур, ярты юлдан борылып, ике-өч көн дигәндә киредән туган авылына тып итеп кайтып төште.

## 8

Авылның үзенә хас яшәү рәвеше, үз моңы, үз ритмнары бар. Нинди генә авазлар белән тулыланмый ул! Сыер мөгрәве, кәҗә-сарык тавышы, каз-үрдәк һәм әтәчләр кычкыруы, машина-трактор гөрелтесе, тимер чыңы, чалгы зеңләве, балта-пычкы җыры, яфрак шавы, сулар челтерәве,

кешеләр сөйләше — шуларның барысын да үзендә туплап, түкми-чәчми мөлдерәмә саклап тора авыл. Әгәр кешеләр ныклап аңлый һәм күрә белсәләр, авылның мең авазлы орган сыман гүләп торуына төшенми калмаслар иде.

Бөтен бәла шунда: аларның моны аңларга теләкләре дә, вакытлары да юк. Иртәдән кичкә кадәр диярлек эшкә, хезмәткә, дөньяның эреле-ваклы мәшәкатьләренә күмелгәннәр. Аларда тормышка сусау, хезмәттән тәм табу, дөнья рәхәтлекләрен татып калу омтылышы көчлерәк шул. Алар өчен хакыйкать — өй түрендәге миләш, абзар читендәге ак мунча, лапас артындагы бәрәңге бакчасы кебек гап-гади бер нәрсә. Шагыйрь яисә музыкант зәңгәр күктә тургай күрсә, аңа башындагы эшләпәсе төшкәнне дә сизмичә озак-озаклап мөкиббән китәр иде. Игенче сыйфатындагы авыл агаеның болай «кәнфитләнеп» торырга теләге дә, мөмкинлеге дә чамалы — ул җир сукалый, ашлык чәчә, буразна ерта. Шулай да тургай җырының мәгънәсен ачык төшенә, сүзсез-нисез генә җанына сеңдерә ул: игеннәр уңа күрсен дә еллар имин торсын!

Башаклар тулышканга кадәр әле бәрәкәтле итеп яңгырлар ява, күзгә күренеп үлән күтәрелә, болында тыгызланып печән өлгерә. Җәй уртасы җиткәнне искәртеп, печән өсте якынлаша...

Шаһинур аякларын салындырып арбага утырган. Тезләрендә каешлы гармун чайкала. Арбада әле тагын дистәгә якын ир-егет бар. Һәркайсының кулында — өскә каратып бастырылган чалгы. Чүкелгән, кайралган, әле кичә генә ярты болынны айкап салган шома чалгылар һавада яшен укларыдай елтырашып бара. Күңелле, дәртле сәфәр. Әнә шулай күмәкләшеп болынга печән чабарга барышлары. Мондый чакта ничек инде җырламый түзәсең, ди! Арадан кемдер көчле тавыш белән җыр башлый:

> Җир шарлары түгәрәк.
> Шул түгәрәк эчләрендә
> Яшик, дуслар, бергәләп.

Аның сүзләрен башкалар күтәреп ала. Җыр дәртләндерә, күңелләрне якынайта, зур эшкә тотынып алдыннан беләкләргә көч өсти. Хатын-кыз, яшь-җилкенчәк утырган арбаларда бөтенләй икенче күренеш: көнозын покос арасында уйнаклыйсы кул тырмалары иртәнге һаваны сөзеп бара. Шул яккарак карап, ирләрнең берсе җыр теләндә аларның йөрәгенә ут салырга тели:

> Алан җирләр тал гына,
> Кызлар аузы бал гына.
> Кызлар аузын суырып үпсәң,
> Сырхау башын сау була...

Кызлар уңайсызланып, хатыннар исә шелтә катыш елмаю белән җавап бирәләр. Ир-егетләр дә бер-берсенә карашып, мәгънәле генә елмая, күзләрендә мутлык, йөзләрендә горурлык чалымы. Җыр, уен-көлке болын уртасына төшеп җиткәнчегә кадәр дәвам итә.

Берзаман болында чалгылар чыжлый башлый.

Хатын-кыз покос арасында җиңел тырмаларын уйната.

Үсмер малайлар, ярыша-ярыша, ат белән печән тарттыра.

Өлкән агайлар, билгеле инде, кибән салу кебек дәрәҗәле эш белән мәшгуль.

Ак күлмәкле ирләр, җилкәнле көймәләрдәй тезелешеп, соңгы тугайлыкка кереп китәләр. Чалгысын гайрәтле селти-селти, иң алдан көрәшче Гайнулла бара. Бер-беренең үкчәсенә басардай булып, аның артыннан башкалар хәрәкәтләнә. Кулында чалгы икән, аның белән селтәнүнең

мәгънәсе булырга тиеш. Ул мәгънә — синең табигать баласы булуың, рухыңның азат, тәнеңнең сәламәт булуында. Газраил кулындагы чалгы беркайчан да андый мәгънәләрне аңлата алмый. Печән чабу — гаять авыр эш. Ләкин ул туйдырмый, киресенчә, рухыңны күтәрә, килер көнгә ышаныч өсти. Кешеләрне берләштерә, якынайта, мәрхәмәткә өйрәтә сыман...

Быел печән чабуда беренче тапкыр чын-чынлап катнашкан Шаһинур шундыйрак уйлар кичерә иде.

Покосны таза, көчле ирләр кебек киң алдыру турында хыялланасы юк аңа. Ләкин көченнән килгәнчә селтәнә бирде. Чалгыны йөрткәндә аз гына төгәлсезлек җибәрдеңме, ул сөрлегеп китә, үткер очы белән җиргә кадалырга да күп сорамый. Менә шушы осталыкны саклау һәм башкалардан калышмас өчен күп көч куярга туры килә. Шаһинурның маңгае тирләп чыкты, күлмәге аркасына ябышты. Берничә сәгатьтән соң ул хәйран гына талчыкканын сизде. Ярый әле вакытында: «Әбәткә!» — дип кычкырып өлгерделәр.

Төркем-төркем кайсы кая урнашып, түгәрәкләнеп, бар булган ризыкларын табын уртасына чыгарып, әбәт ясадылар.

— Ашаганны сеңдерә белегез, черем итеп алсагыз да ярый,— дип, малай-шалайга киңәш бирде Гайнулла абый һәм, берничә иптәшен ияртеп, су буендагы таллыкларга таба китте. Анда алар кичә кичтән үк шалаш корып, төбенә хуш исле коры печән түшәп куйганнар иде. Шалаш икән шалаш, әмма ял вакытында аның тирәсенә берәүне дә якын җибәрмәделәр.

Шадра йөзле, чәчләрен кыйгач косынка белән бәйләгән Фаягөл апаның таллыкның икенче башына кереп киткәнлеге күренде. Баласы булмауны сылтау итеп, күрше авылдагы ире аерып кайтарган, дип сөйлиләр аны, «Чая гөл» дип тә җибәрәләр үзен. Бу хатын турында төрле «легенда»лар да ишетелгәли. Ләкин, кемдә кемнең эше бар дигәндәй, сөйлиләр дә оныталар, тормыш үз көенә ага бирә.

Киткәндә Шаһинурның колагына: «Ярты сәгатьтән шалаш янына килергә онытма...» — дигән иде Гайнулла абый, бер читкәрәк ымлап. Нигә чакырды икән? Әйтер сүзе бардыр. Гармунчы булгангамы. Шаһинурны үз итәләр ич. Зурлар арасына эләгүнең үз кызыгы, дәрәҗәсе бар: әллә ниләр күрәсең, әллә ничаклы яңалык ишетәсең.

Башкалар игътибарын җәлеп итмәс өчен, Шаһинур иң элек Мишә буена төште. Аннары яр астыннан барды-барды да, сөзәк урындагы комлыкны кистереп, таллыктагы шалашка таба атлады. Таллык эчендә рәхәт, җиләсрәк иде. Яшел өчпочмакны хәтерләткән шалаш эченнән, чалбар сәдәфләрен төймәли-төймәли, Гайнулла абый чыгып килә иде.

— Килдеңме, молодец,— диде ул һәм ялангач тәненә нык ябышкан печән кисәкләрен кулы белән кагып төшерде. Аннары, шалаш авызына ишарәләп, ярым пышылдауга күчте:

— Син инде тартынма, бала-чага булма... Кайчандыр барыбызның да баштан кичкән эш...

Шаһинур, ниһаять, аның бу ымын аңлады, ләкин тыштан аңламамышка салышкан кыяфәт ясады.

— Бар, бар! Сынатасы булма... Курыкма, миннән сүз чыкмас!

Шаһинур үзен кулга алырга тырышты. Ләкин башында: «Нишләргә? Керергәме, юкмы?» — дигән утлы сораулар туктаусыз бәхәсләшә иде. Чынлап та, нишләргә соң? Керми каласың икән, җебегән дип күзеңне дә ачырмаслар. Керәсең икән, анда үзеңне ничек тотачагың турында уйларга кирәк. Шаһинур гаҗәеп бер тәвәккәллек белән соңгысын сайлады. Ахыры ни белән бетәсе дә ачык булмаган билгесезлек аны үзенә суырып алды. Керми калуга караганда шалаш ишегеннән атлап узу күп яктан дөресрәк булачак иде.

Печән сабакларын кулы белән аерып, эчкә узды. Ярым караңгы шалаш эчендә, дөресрәге, печән түшәлгән урталыкта, Фаягөл апаның

йөзе-гәүдәсе шәйләнде. Гаҗәп: ул, аккош канатыдай аксыл беләкләрен ике якка ташлап, тигез сулыш алып, тынсыз, хәрәкәтсез ята иде. Болай торараштай басып торуының мәгънәсе юк, нидер эшләргә кирәк, билгеле. Шаһинур аңа якынрак килде, янәшәсенә килеп тезләнде. Хатынның ярым ялангач тәненнән кайнарлык бөркелә иде. Менә ул күзләрен ачты, кулы белән кофтасын һәм юбка итәген төзәткәләп, тәнен каплаштырды. Юк, теләсә ничек уйласыннар — чит бер кешегә, мондый гадәттән тыш эшкә Шаһинурның... кулы күтәрелми. Акылы һәм ихтыяр көче кушканча, ул аның белән турысын, күңелендәгесен әйтеп сөйләшергә тиеш. Бары шул. Күрәсен күргән, тормыш тәҗрибәсен җитәрлек туплаган Фаягөл апа аны, шөт, аңламый калмас.

— Фаягөл апа...

— Әү, үскәнем!

— Сез миңа ачуланмыйсызмы?

— Юк, юк, сөйлә... мин сине рәхәтләнеп тыңлыйм.

Хатын, күтәрелә төшеп, Шаһинурны максатсыз-нисез җиңелчә генә кочып алды, ләкин кайтарып бер сүз дә әйтмәде.

— Сезгә, Фаягөл апа, бер генә кешегез булса, яхшырактыр иде...

— И акыллым, яхшы ирләр теләсә кайда аунап ятмый шул, бик беләсең килсә.

— Юкса үзегезгә читендер болай яшәүләр дим...

— Абау, җаным, бу дөньяда мине дә аңларга тырышучылар бар икән әле! — Бу юлы хатын торып ук утырды һәм йөзен куллары белән каплады. Аның кул бармаклары арасыннан пышылдап диярлек әйтелгән ачынулы сүзләр саркып чыкты: «Ир хатыннарыннан әр ишетеп яшәүләр әллә бик җиңел дип беләсеңме миңа?»

Фаягөл апа, әнә шул хәлендә үсмернең тезләренә капланды, эчтән генә үксеп елый иде бу минутта. Менә сиңа «Чая гөл» апа! Кеше күңелен аңламассың...

Тәкъдир кушуы белән инде ир куенында булып өлгергән хатын Шаһинурның яшь икәнен дә, намуслы булуын да аңлый иде. Шуңа да ул табигый сафлыгын саклый белгән үсмергә ачуланмады, сүз әйтмәде, нәкъ менә шушы халәтендә генә була ала торган әлеге эчкерсез сөйләшүне берәүгә дә чишмәскә, сер итеп сакларга эчтән генә ант итте. Тынычлангач, саубуллашыр алдыннан:

— Син әле алда үз мәхәббәтеңне табарсың, мин ышанам,— диде.— Ә хәзер бар, кеше-кара күргәләгәнче, тизрәк иптәшләрең янына йөгер...

Шаһинур шалашка атлап керер алдыннан да мондый ук тетрәнү, дулкынлану кичермәгән иде. Ул сагышлы төсләрдән торган ниндидер ачыш ясады үзе өчен, ләкин моны тел белән берничек тә аңлату мөмкин түгел иде.

Җен кебек көчле Гайнулла абый каерылып-каерылып соңгы покосларны чаба. Гаҗәп зирәк кеше булып чыкты ул: соңыннан шалаштагы хәлләр турында ни Фаягөлдән, ни Шаһинурдан тел тибрәтеп берни сорашмады. Аңа әлеге көнге чын дөреслекне белергә язмаган иде, күрәсең.

## 9

Урта мәктәпне тәмамлагач, Шаһинур кулына өлгергәнлек аттестаты алды. Бу вакытта аңа унбиш яшь тулган иде. Нинди һөнәр сайларга, кая гына укырга китәргә соң, дип төрлесен уйлап-уйлап карады да, Казанның музыка училищесына барырга булды.

Училищеның адресы кулда иде. Анда иң элек нинди дә булса уен коралында уйнатып карыйсылар икән. Менә шунысын да җиңеп чыга алсаң, аннары алдагы имтиханнарга уздырачаклар, ди. Шаһинур, тальян гармунын да үзе белән аласы итте — анда әллә бар, әллә юктыр ул, кем белсен. Сафия апа Шаһинур барып керәсе туганнарына хәл кадәренчә

авыл күчтәнәчләре төреп тыкты, күп итеп сәлам әйтергә кушты. Озата чыкканда үзенә генә ишетелерлек итеп әйтте:

— Син тагы, улым, теге чактагы кебек, югалып, безне борчулы итә күрмә, зинһар!

— Юк ла, әни,— диде Шаһинур, ул чактагы гаебе өчен хәзер кызарып.— Кулдагы гармунны күрәсең ич, мин бит бу юлы тәгаен укырга дип китеп барам.

Олы юлның кирпеч будкасы каршына автобус килеп туктады. Шаһинур шундагы буш урыннарның берсенә кереп урнашты. Йоклыйм дисәң дә, уйланып барам дисәң дә вакыт җитәрлек иде. Алда утырган бер әби кулына кечерәк кенә каен себеркесе тоткан. «Машина исе ярамый кана, күңел болганмас өчен шифасы бар» — дия-дия себеркесен әледән-әле иснәп куйгалый. Урман-кырда саф һава иснәп, чишмә сулары эчеп, чын икмәк ашап үскән әби-бабайларның машина исләрен өнәп җиткермәве табигыйдыр, күрәсең.

Машина моторының тигез гүләве тәнне оета, ләкин Шаһинур йоклап, йокымсырап бара торганнардан түгел. Ул үз уйларына бирелде, шулай иткәндә юл да кыскара төшә.

Шаһинурның Казанга укырга җыенасын белгәч, әтисе, тегеләй бул, болай бул, дип акыл сатып маташмады, сүзен кистереп әйтте:

— Бик кәҗәләнеп торсалар, ялынма, улым. Тот та кире әйләнеп кайт! Авылда үги булмассың...

Нигә болай шик белдерде әтисе? Улына ышанмавымы, әллә бүтән сәбәпләр бармы? Керер, әйбәт кенә укып та китәр, зур музыка дөньясына аяк басар — менә шуңа ышана Шаһинур. Әгәр ышанмый икән, Казанга болай күтәренеп, дәртләнеп баруыңнан ни мәгънә.

Кызык: моңа кадәр Шаһинур үз киләчәге турында болай ук ныклап, бөртекләп уйламый иде. Мәктәп һәм балачак еллары гамьсезрәк булган, анда ничектер сорау-җаваплар ташкыны алдыңа күпкакыт әзер килеш бирелә иде. Хәзер менә күп нәрсәләрне үзбаш уйларга, хәл итәргә кирәк. Курчак кына көнозын шөгыльсез-нисез бер почмакта утыра ала. Ә кешегә эш, һөнәр, мавыгу һәм барыннан да элек тормышны ярата белү кирәк. Мин кем? Минем урыным кайда булырга тиеш? Бер телем икмәк ашыйсың икән, ул бурычыңны кайчан, ничек кайтарырга уйлыйсың? Кешенең үз-үзен һәм үзендәге мөмкинлекләрне эзләве шулай башлана булса кирәк.

Өч сәгатьлек юлны җилдереп узганнан соң, автобус шәһәргә килеп керде.

Тукталышларның берсендә Шаһинур трамвайга күчеп утырды. Берадан ул Суконный урамындагы туганнарында ак май ягылган булки белән чәй эчеп утыра иде.

Икенче көнне музыка училищесын һәм андагы үзенә кирәк бүлмәләрне эзләп тапты, документларын тапшырды. Коридорда күбесе нәкъ аның шикелле яшьләр иде, хәер, олыраклар да күренә. Кызлар аллыгөлле итеп матур киенгән, арадан берсенең ак, озынча бармаклары аеруча нәфис күренә. Яшенә күрә шактый тулы-таза бу кызның өстендә алды ерыклы кара юбка иде. Йөрешләре дә нәфис икән моның. Юбка ерымы ачылып-ачылып киткән чагында, ымсындырып, шалкандай ак тез башлары күренеп ала. Күзәтүчәнлеге өчен оялып, син монда шуны күрер өчен килдеңме дип, Шаһинур үзен эчтән генә битәрләп тә алды.

Конкурс бүлмәсенә керәләр дә чыгалар. Кемдер елмаеп, кемнәрдер елап-мышкылдап чыга.

Менә Шаһинурга да чират җитте, аны чакыралар. Бүлмә эчендә кызыл постау җәелгән өстәл артында бер ир кеше, ике хатын-кыз утыра иде. Бер почмакта чем-кара төстәге пианино.

— Исәнмесез...

Тегеләр баш кагып кына җавап кайтардылар. Кулындагы гармунын Шаһинур тартмасы-ние белән бер читкәрәк куеп торды. Үзе өстәл кар-

шындагы ялгыз урындыкка килеп утырды. Русчалатып сорау бирә башладылар.

— Яраткан композиторларың?

— Салих Сәйдәшев.

— Тагын кем?

— Рус композиторы Чайковский.

— Тагын?..— диде иң кырыйда утырган хатын һәм, җавап биргәнне дә көтмичә, сүзен дәвам итте:— Нәҗип Җиһанов иҗатын яратасыңмы, нинди әсәрләрен беләсең?

— «Алтынчәч» операсын.

— Ярар... Ә нинди уен коралларында уйный беләсең?

— Гармунда,— диде үсмер егет тыенкы горурлык белән.

— Уйнавын тыңлап карыйк булмаса,— дип тәкъдим кертте ир кеше.

Шаһинур урыныннан торды, гармун тартмасын чертләтеп кенә ачты да кулына тальянын алды. Нәрсә уйнарга? Мондый җитди сынау вакытында үзенең иң яраткан көен уйнарга тиештер ул, әлбәттә. Шаһинур шулай уйлады, бер-ике теленә баскалап гармунның сулышын тикшергәндәй итте дә уйнап җибәрде. Тальян күрекләре арасыннан тургайлар күтәрелеп чыкты да канат җилпи-җилпи сайраша башлады шикелле. Бүлмәдә яңгыраган дәртле, көмеш авазларга кояш нуры, тәгәрмәчләр келтерәве, чалгы чыңы, сабантуй сөлгеләре җилфердәве, гомер мәгънәсе — тагын-тагын әллә ничаклы моңнар кереп тулган иде. Тегеләр ни чек аңлагандыр, үзенең уйнавында әнә шул төсмер-бизәкләрне барлык күзәнәге белән тоеп, үсмер егет «Алмагачым» көен өздерә иде...

Янындагы ике хатынның ис китми генә битараф утыруларын күреп, ир кеше хәлне төзәтергә ашыкты:

— Инде хәзер озынрак көй уйнап кара.

Эретәсе, эретәсе иде бит бу хатыннар йөрәгендәге битарафлык бозын! Шаһинур сыгылмалы-салмак хәрәкәтләр белән «Таң атканда» көен сызып җибәрде... Боз хәйран гына эреде кебек. Хатыннарның берсе үзалдына саран гына елмаеп та куйды. Ләкин икенчесенең маскадай йөзендә үзгәреш сизелмәде.

— Аттестатыңа җырдан «бишле» билгесе куелган. Ә нота дәресләре кердеме соң сезгә?— диде ул, сөрмә тарткан күзләрен зур ачып.

— Юк, дәрестә безгә яңа җыр гына өйрәтәләр иде.

— Димәк, көйләрне нотадан карап уйный белмисең?

— Юк.

Бу хатын шушы өчәүнең арасында башлык иде булса кирәк. Шаһинурның соңгы җавабыннан соң нәтиҗә ясарга ашыкты:

— Иптәшләр, мин кандидатурасы үткәрә алмыйм.

— Алевтина Сергеевна, егетнең ишетү һәм тоемлау сәләте искиткеч югары күренә, бәлки, чыгарма рәвешендә...

Ир кешенең әйтә башлаган сүзләрен бүлдерүне кирәк тапты хатын:

— Безгә имтихан кагыйдәләрен бозарга ярамавын яхшы беләсездер. Инструкция!

Шаһинур эшенең барып төртелгәнен, инде аны алга таба берничек тә этеп булмаслыгын аңлады. Кешенең язмышын, теләк-омтылышларын ярты юлда бер сүз белән менә ничек җиңел генә туктатып була икән! Әлеге инструкция дигәннәрен җиңә яисә үзгәртә ала торган көч юк микәнни соң дөньяда?

Тынлык урнашып алды. Ир кеше сүзенең үтмәвенә уңайсызланды булса кирәк, кул хәрәкәте белән Шаһинурны үзенәрәк дәште.

— Син, егет, борчылма,— диде ул бу юлы саф татарчага күчеп.— Күңелеңне төшермә. Музыкага сәләтле икәнеңне күрәм. Безнең көйләрнең тәмен тоеп, үзеңчәлекле итеп уйныйсың. Нотага өйрәтмәгәннәр икән, монда синең гаебең юк. Училищега шунсыз алмыйлар бездә. Нишлисең бит, инструкция кушмый.

Чү, әтисе нәрсә дигән иде әле: «Кәҗәләнеп торсалар, ялынма, улым...». Йөз чакрым читтәге Казан каласынданиләр буласын алдан ук белеп торды микәнни ул?

Үгет-нәсихәтнең икенче өлешен дә исенә төшерде: «Авылда үги булмассың».

Инструкция кушса-кушмаса да, Шаһинурның тизрәк урамга чыгасы килә иде...

## 10

Туган авылына кайтып, бер ел чамасы клуб мөдире булып эшләде Шаһинур. Ходай бирмеш бәхет белән буй-сын, гәүдә, ныклык ягыннан кайбер иптәшләрен уздырып та җибәргән иде инде ул.

Ә аннары язмышы бөтәнчәрәк юлдан китте аның. Күршедәге Куштөбәк сигезьеллык мәктәбенә физкультура укытучысы кирәк икән. Уналтысын тутырып, әле яңарак кына паспорт алган Шаһинурны шунда эшкә чакырдылар. Мәктәп директоры Садри Сәлмәнович ипле, кешенең хәленә кәрә һәм тел яшермичә турыдан сөйләшә торган педагог иде. Бер утырып сөйләшүдә уртак тел таптылар. Яшь кенә булса да, егеттә сәләт һәм тырышлык барлыган бер күрүдә аңлап алган иде ул. «Өметле, перспективалы кадр булачак»,— дип нәтиҗә ясады.

Боерык язганчыга кадәр, киңәшеп алгандай итте:

— Сәгатьләрең әллә ни күп чыкмый, энем. Әллә җыр дәресләрен дә сиңа өстикме?

— Юк, Садри Сәлмәнович, балаларны надан калдырасым килми,— диде укытучы буласы егет, үгетләргә урын калдырмаслык итеп.— Махсус белемле кеше табылыр әле. Үземнең аңыз пешкәне бар...

Яшереп тормады Шаһинур, узган ел музыка училищесына баргач, ярты юлда ничек итеп абынганын сөйләп бирде.

— Эһем-м...— диде мәктәп директоры, егетнең ихлас сөйләвенә сокланып һәм мәгънәле генә тамак кырып.— Музыка белеменнән дипломы булганнар авыл мәктәбенә бик тәтеми шул ул.

— Ә болай, әгәр кирәксә, баян бар минем. Тәнәфестә һәм концертларда уйнармын анысы,— диде Шаһинур.

Баян гына түгел, ул инде бер ел эчендә мотоцикл сатып алырга да өлгергән иде. Авыл эчендә әллә ни күп йөри алмыйсың, ихтыяҗ юк. Менә кайчан кирәге чыкты «тимер мөгезле» матайның! Көн дә иртән мотоциклына атлана да мәктәбенә чаба Шаһинур. Ике тәгәрмәчле матаен биш чакрым ераклыктагы Куштөбәк мәктәбе каршындагы Кәримә әбиләргә кертеп куя, болонь плащын салып өстен-башын кага, чистарына да дәресләренә китә.

Садри Сәлмәновичның яратып, кат-кат әйтә торган сүзләре бар коллективка.

— Плансыз дәрес, иптәшләр, балтасыз килеш урманга агач егарга барган шикеллерәк,— дип кабатларга ярата ул.— Андый дәреснең мәгънәсе югала. Моны сезгә рәсми төстә әйтәм.

Мәктәп директоры болай әйтү белән генә чикләнми, кайчакны сайлап кына укытучыларның дәрес планнарын да тикшергәли. Физкультурадан план төзүнең бер авырлыгы да юк Шаһинур өчен. Дәресләр күпвакыт урамда, спорт мәйданчыгында үткәнлектән, пунктлап яза да куя: бару, фәлән-фәлән күнегүләр эшләтү — шуның белән вәссәләм! Дәресләрнең программасы, ел буена житәрлек итеп, галимнәр тарафыннан әллә кайчан билгеләп куелган инде — йөгерү, граната ыргыту, турникта күтәрелү, арканда менү, тагын әле биеклеккә яисә озынлыкка сикерү һәм башкалар.

Дистә еллар калыплашкан әзер программаның ике яклы нәрсә икәнен аңлады Шаһинур. Беренче карашка, дәресләр ныклы программага

салынган булса, икенче яктан укытучыга бернинди иҗади мөмкинлекләр бирелми, ул — дүрт яктан кысалар эчендә утырырга тиеш. Эчке кагыйдәләр аңа тукып тора: программаң үтәлсен, шуның кысаларыннан бер кәррә дә читкә тайпылма! Әйтик, озынлыкка сикерү урынына малайларны татарча көрәштерсәң, ни булган? Юк, ярамый, чөнки программада андый нәрсә каралмаган. Кәҗә-сарык куганда кыз балаларга хәтле әллә кайчан ераклыкка да, биеклеккә дә сикереп өлгергән була инде.

Уйлады-уйлады да Шаһинур тәҗрибә ясап карарга булды.

Беркөн шулай физкультура дәресендә 6 «А» классын елга буена алып китте. Елга димәсәң, хәтере калыр, астагы тасма чаклы гына ерганакның як-ягын үлән каплаган, суы юньләп күренми дә диярлек. Өстә исә коры яр сузылып киткән, киңлеге ике-өч метр чамасы булыр. Шуның бер борылышында, ике ярны тоташтырып, бүрәнә салынган иде. Кулындагы кызыл флагчыкларны биреп, кыз балаларны эстафеталы уйнарга җибәрде Шаһинур. Малайларны исә бер сафка тезде дә әйтте:

— Сез барыгыз да солдат буласы кешеләр. Ныклык һәм осталыкка табигать шартларында өйрәнеп үсик. Бүгенге дәреснең максаты — егылмыйча-нитмичә генә бүрәнә аша теге як ярга чыгарга өйрәнү. Игътибар белән карагыз, иң элек үзем йөреп күрсәтәм...

Шаһинур бүрәнә өстеннән атлап китте. Як-якка ике канаттай җәйгән куллары, үлчәү тәлинкәләредәй әле аска, әле өскә таба тибрәнеп, аңа гәүдәсен туры һәм ышанычлы тотарга ярдәм итә иде. Киредән чыкканда бу якка янә мәчедәй җитезлек белән йөгереп диярлек атлады ул. Чыккач тагын бер кат киңәшләрен кабатлады:

— Бүрәнә аша чыкканда гәүдәне иркен тотарга, аякларны дөрес күчерергә тырышыгыз. Башладык...

Осталыгыңны сынап карау гына түгел, малайлар өчен хис-тойгыларны алмаштыру, тәвәккәллек дәресе дә иде бу. Берәүнең дә сынатасы килмәде. Теге якка һавадан баргандай атлап-йөзеп чыкканда шатлык янәшәсендә кечкенә генә курку да, курку янында эчке бер җиңү ләззәте дә бар иде. Алар өчен яңалык, үзгәреш иде бу. Ләкин дәрес азагындарак күңелсез хәл килеп чыкты. Чираттагы бер малай, бүрәнәне кичеп чыгам дигәндә генә, гәүдә тигезлеген саклый алмыйча... читкә очып төште! Гәүдәсенә зыян-фәлән килмәсә дә, уңайсыз килеп төшүдән малайның сул аягы каймыккан иде. Аны мәктәпкә култыклап алып кайттылар да медпункттан фельдшер Сания апаны чакырдылар.

Директор бу хәлләрне белмичә калмады, билгеле. Яшь укытучыны шундук үзенең бүлмәсенә чакырып алды. Йөзе кырыс һәм борчулы күренә иде аның. Рәсми тонга күчеп:

— Менә, күрәсезме, иптәш Нәҗмиев,— диде ул, Шаһинурның план дәфтәренә күз салып чыкканнан соң.— Плансыз дәреснең кая барып чыгачагы турында мин кат-кат әйтә киләм. Безнең илдә плансыз бер генә нәрсә дә эшләнми. Әле җитмәсә программадан читкә тайпылгансыз. Бүрәнә өстеннән йөриләр, имеш. Каян килгән кыр кәҗәләре! Бу — мәгариф министрлыгы инструкцияләрен икеләтә бозу дигән сүз. Алга таба мондый хәлләр кабатланмас, дип ышанам! Онытма: минем өстән дә начальство бар...

Нәрсә әйтсен Шаһинур? Уйлап карасаң, гаебе чыннан да бар шул аның. Дәрес планын төзеп маташмады — бер. Программадан читләште — ике. Малайның аягы каймыкты — монысы булды өч... Әле дә ярый малайның әти-әнисе эшне зурга җибәрмәделәр.

Монда да инструкция килеп чыкты әнә. Күрәсең, җәмгыять тормышына өзелергә торган җеп-мазар түгел, көчле аркан белән ныклап бәйләп куелган ул.

Үгет-нәсихәт укып, шелтәләп алса да, мәктәп директоры соңыннан Шаһинурга карата мөнәсәбәтен үзгәртмәде. Яшьлеге, чибәрлеге, хәтта уйлау сәләте һәм эш-гамәлләре белән өлкән укытучылардан шактый нык

аерылып торган бу егет тагын әллә кай яклары белән үзенә ихтирамлы караш сакларга мәҗбүр итә иде.

Менә шуңа күрә дә Садри Сәлмәнович, хезмәт укытучысы ныклап авырып киткәч, аның дәресләрен тотты да Шаһинур җилкәсенә йөкләде.

— Программаны аксату килешмәс,— диде ул.— Син давай, энем, хезмәт дәресләрен дә үз кулыңа ал әле.

Алды Шаһинур, укучылар белән бергә, үзе дә мәктәпнең кечкенә генә остаханәсендә мәш килде. Остаханә өтерге, чүкеч, игәү, балта, пычкы, агач эшкәртү өчен көйләнгән станок ише нәрсәләр белән тиешенчә җиһазландырылган — нәрсә ясарга тотынсаң да, эш кораллары җитәрлек. Яңалыкка сусап торган Шаһинур мондагы дәресләренә дә байтак кына үзгәрешләр кертте. Инде бер кат авызы пешкәнлектән, бу юлы директор белән килешеп, дәрестә укучыларны көрәк саплау, балта сабы һәм кечкенә урындык ясау кебек тәҗел эшләргә өйрәтә башлады. Авыл баласы өчен беренче чиратта шулар кирәкле. Юкса аларның программаны үтәү һәм матурлык өчен генә такта кисәкләре ышкылавыннан, күргәзмәгә куяр өчен генә тимер детальләрне тишеп-шомартып куюларыннан ни файда?

Шаһинурның уенча, дәресләр тормышка якынайтылган булырга тиеш. Тын кабинетларда туган программа һәм инструкцияләр, шул ихтыяҗны исәпкә алмаганга күрә, тормыштан шактый дәрәҗәдә ерак тора иде.

Мәктәпнең математика бүлмәсен бизәү өчен өчпочмак, конус, квадрат ише геометрик фигуралар кирәк булып чыкты. Шаһинур тәкъдим иткәнчә, хезмәт дәресләрендә шуларның һәммәсе дә укучылар көче белән эшләнде.

Үзең генә хыялланып йөргән зур, бөек эшләргә дәртләнеп китү өчен акыл ияләре әйткән сүз һәм идеяләрне белеп-ишетеп тору да кирәк бу дөньяда. Сүз гомер буе хәтердә калырга мөмкин. Мәктәп залында эленеп торган акыллы, канатлы сүзләр укытучы әйткәннәргә караганда да ныграк истә калучан.

«Укырга, укырга һәм укырга!»

Мәгънәсе беркайчан да искерми торган бу сүзләрне Шаһинур беркайчан да онытмаячак.

Ул эшләп яткан Куштөбәк мәктәбе коридорына исә эре-эре кызыл хәрефләр белән әнә нинди сүзләр язып куелган: «Без табигатьтән рәхимлекләр көтеп тора алмыйбыз. Аны аннан алу-безнең бурыч» (И. Мичурин).

Педсовет утырышларының берсендә Шаһинур, иң азактан сүз сорап, мондый тәкъдим кертте:

— Иптәшләр, безгә кайбер иске лозунглардан арынырга вакыт түгел микән? Узган-барган чакларда игътибар итәсездер: коридор түрендә Мичуринның мәгълүм сүзләре эленеп тора. Бүгенге көнебезгә тамырдан каршы килә торган фикер бу. Без үзебезгә кирәкне табигатьтән артыгы белән сыгып алдык инде. Газеталар көн-төн шул хакта яза. Табигать кешеләрдән мәрхәмәт көтеп яткан чагында андый лозунгның тәрбияви әһәмиятен күрмим мин. Алыштырасы иде аны...

Көтелмәгән бу тәкъдим озак еллар эшләп, мәгариф өлкәсендә чәч агарткан өлкән укытучыларны да сискәндереп җибәрде. Биология укытучысы Надыйр абый гына урыныннан чәчрәп чыкты:

— Син нәрсә, энем, яшь-яшь башың белән җиләк-җимешнең өч йөз сортын уйлап чыгарган Мичурин бабаңа кизәнәсен? — Кызып сөйләүдән аның хәтта йөнтәс кашлары өчпочмакланып килгән иде.— Аның тәгълиматы белән бакчачылык эшендә тирән революция ясалды. Тәрбияви әһәмияте юк, имеш. Белмим, нинди шайтан котыртадыр сине?..

— Надыйр абый, мин бит аның хезмәтләрен юкка чыгармыйм, кире дә какмыйм. Аерым фикеренең бүгенге көн өчен искергәнен генә әйтергә телим. Бары шул.

Ботканы күпертмәс өчен, Садри Сәлманович кинәт башланган бәхәскә акыллы итеп нокта куярга ашыкты:

— Кем нәрсә әйтсә, шунын сүзләрендә, һичшиксез, күпмедер хаклык була, диләр. Мин сезнең икегезне дә аңладым. Әйдәгез, шулай килешик: бу мәсьәләне хәл итү хәзергә минем өстә калсын.

Мондый чишелеш белән барысы да риза булдылар. Икенче көнне Надыйр абый да суынган, үз эзенә кайтып төшкән иде. Кат-кат уйланган, күрәсең. Шаһинурга:

— Син, энем, үзең әйткән тәкъдимне үзең түгәрәкләп бетер инде. Мин Садри Сәлманович белән сөйләштем...

Берничә көннән соң мәктәп коридорынын ике башында ике лозунг пәйда булды:

ДӨНЬЯДА ХЕЗМӘТ АША АЛГАН БЕЛЕМНӘН ДӘ КӨЧЛЕРӘК КОРАЛ ЮК.
СОКЛАНУ ӨЧЕН БЕР МИНУТ ТА ЖИТӘ, Ә ИНДЕ АЧЫШ ЯСАР ӨЧЕН ЕЛЛАР КИРӘК.

## 11

Ноябрь башларында туңдырып жибәрде, аяк астындагы уйдык-уйдык күлләвекләр ялтырап торган көзге кисәкләренә әверелде. Ябалак-ябалак кар яуганнан соң декабрь бураннары котырып алды. Куштөбәк авылы да кышка керде, кышкы мәшәкатьләр белән сулый башлады. Кечке тәрәзәләрдән йорт-койма буендагы көртләр өстенә төшкән яктылык авыл тормышын серле, мәгънәле итә, иминлек һәм яшәү турында мөкатдәс уйлар уята иде.

Шаһинур инде байтактан Кәримә әбиләрдә куныш яши. Шимбә көннәрендә, әлбәттә, туган авылына кайтып китә. Шулай итеп, аның күңелендә хәзер ике авыл яши. Куштөбәкнең соңгы вакытларда Шаһинурны үзенә аеруча тартып, ымсындырып торуында җитди бер сәбәп бар иде шул.

Шаһинур күңелендә мәхәббәт йолдызы кабынган иде.

Ул аны беренче тапкыр клубта күрде. Бөтен кеше пәлтә-мазардан йөргәндә нишләп бу кыз гына башына чуклы-бизәкле шәлъяулык бөркәнеп, үзен шулай хуҗаларча иркен тотып йөри икән, дип гаҗәпләнде. Мөслимә исемле бу кыз клуб мөдире булып чыкты. Шәлъяулык астыннан артка таба шома итеп таралган коңгырт чәченең бер өлеше күренеп тора. Маңгае якты, тигез. Туры диярлек сызылган кара кашлар. Ике як битендә һәм иреннәрендә алсу шәүлә посып тора. Ә күзләрендә берәүне дә кабатламый торган шатлык катыш моңсулык... Ул аны әнә шулай итеп күрде.

— Гармунда уйна әле, Шаһинур, клубка ямь керсен,— диде Мөслимә ничектер үз итеп.— Юкса гармунчы егетебезне армиягә алдылар.

Шаһинур уйный башлагач, клубка, чыннан да, ямь кереп китте. Баштарак кызлар гына биегән булса, аннары уенга егетләр дә кушылды. Арадан берсе аеруча оста бии икән, кызларны беләгенә алганнан соң зыр-зыр әйләндереп, аларны бер кычкыртмыйча туктамый. Кара-каршы басып, җырлый-җырлый «наза» уйнаганда Шаһинур белән Мөслимә парлашып бастылар. Кызның куллары тансык, кайнар һәм йомшак иде.

Соңыннан Шаһинур аны өенә кадәр озата китте... Аяк астында кар шыгырдый. Бүгенге кичнең матурлыгына хәйран калып, әллә күктә йолдызлар кыштырдый микән? Тос-кыяфәтен һәм кайда эшләвеннән ары тормышының әле бер генә почмагы да ачылмаган яңа юлдаш белән янәшә атлап бару кызыклы иде. Мөслимә бер дә юашлардан түгел, сөйләшергә һәм сораулар бирергә ярата торган кыз булып чыкты.

— Безнең авыл сиңа ошыймы?— дип сорады ул.

— Ошый, билгеле. Ошамаса, инде әллә кайчан китеп барган булыр идем.

— Сер булмаса, кая?

— Андромеда томанлыгына...

— Ай-һай, еракка икән! Рөхсәт итәрләр микән соң?

— Мине кем тотсын ди, мин бит ирекле кош.

— Менә без тотарга уйласак, нишләрсең икән? Кызлар белән сөйләштек, син безгә кирәк булачаксың.

— Минем гайбәтне сатарга кай арада өлгердегез шулай?

— Юк, гайбәт түгел, әйбәт... нәрсә турында сөйләштек. Безгә «Галиябану»да Хәлил ролен уйнаучы кеше кирәк. Син шуңа риза булсаң иде, Шаһинур!

— Артистлыкка исем китми китүен. Әгәр инде Галиябануны үзең уйнасаң, уйлап карармын.

Мөслимә тыенкы гына көлеп куйды.

— Анысын карарбыз инде, Шаһинур.

Сөйләшә-таныша торгач, шунысы да ачыкланды: Мөслимә әнисе белән генә яшәп ята икән. Сугыштан кайткан әтисе, ярасы кузгалып, кызына өч яшь тулар-тулмас вакытта дөньядан китеп барган.

— Сугыш әтиемне тартып алды минем...— диде Мөслимә бөтенләй үзгәреп, тулган айдай моңсуланып. Еламас өчен иреннәрен кысканга күрә, ул озак кына сөйләшмичә барды... Шаһинур репетицияләргә йөри башлады.

Атна-ун көн чамасыннан соң белдерүләр тактасында мондый игълан пәйда булды: «Бүген кич клубта авыл үзешчәннәре көче белән Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасы күрсәтелә. Рәхим итегез!»

Колхоз эшенә дисәң — амбар-фермада, үз хуҗалыгында дисәң, терлек-абзар тирәсеннән бушамаган, эшнең үзен куркытырлык итеп батырып эшли белгән апайлар рәешкә генә саклап тоткан яхшы киемнәрен киеп, клубка җыйналдылар. Саф-саф тезелгән агач урындыкларның алгы рәтләрендә, чөкердәшеп, хәл-әхвәл сорашып, алар утыра. Урманда, басуларда җәй буе умырып эшләгән ир-атларга кышын эш-мәшәкать шактый кими төшкән була. Шуңаргамы, әллә узып барган яшьлекләрен озайту өченме, кышын алар клубны аеруча үз итәләр. Спектакль, концерт-мазар булганда урынны арткырак рәтләрдән сайларга тырышалар, чөнки анда бүрекне салмыйча да утырырга мөмкин. Сәхнә алдын тиктормас малай-шалай шөпшәдәй сырып алган. Барысы да түземсезләнеп пәрдә ачылганны, могҗиза башлануын көтәләр. Әйе-әйе, җырга, сәнгатькә сусаган авыл халкы өчен сирәк куела торган спектакльләр көтелмәгән бәйрәмгә, могҗизага тиң!

Менә ул дүрт күз белән көткән минутлар: сәхнәгә кадәр сузылып төшкән авыр пәрдә, дулкын-дулкын тартылып урталай бүленә дә, ике якка салмак кына ачылып китә. Бәдри абзый өе. Кич. Урамнан «Галиябану» көенә гармун белән җырлап, сызгырып, кул чабып үткән тавышлар ишетелә. Яулык япкан, чуар алъяпкыч бәйләгән Галиябану, чигү чиккән җиреннән, түземсезләнеп шушы авазларга колак сала.

Залда «шылт» иткән тавыш юк. Бер тын белән һәммәсе спектакльне тамаша кыла. Эчтәлеген, андагы хәлләрнең ни белән бетәсен чамаласа да, беренче кат күргәндәй сихерләнеп, йотылып карый халык.

Вакыйгалар куера, төенләнә бара. Бай егет Исмәгыйль авылның бер чибәре булган Галиябануга күз атып йөри икән. Ләкин Галиябану сөйгән егете Хәлилгә вәгъдә биреп өлгергән инде. Менә алар очрашалар...

Хәлил-Шаһинур. Тәрәзәнне ачып куеп,
Кемгә күлмәк кистең син?
Кара кашым, карлыгачым,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Кем бәхетенә үстең син?

Галиябану-Мөслимә. Быел, быел дигәнем,
Быелгы ел көйгәнем.
Җаныем, бәгърем, сылуым-иркәм,
Кулларына гармун тоткан
Егет минем сөйгәнем.

Залда утырганнар моны сизәме, юкмы — Шаһинурның да, Мөслимәнең дә күңелләре икегә бүленгән бу минутларда. Бер яктан алар тыпыр-тыпырышып сәхнәдә уйнаса, икенче яктан әнә тормыштагы үзләре генә белгән яшерен уйларын да җыр телендә уртаклашалар. Кыен да, рәхәт тә шулай урталай бүленеп, берьюлы ике төрле халәттә яшәүләре!

Әйе... Әкиятләрнең генә азагы әйбәт һәм бәхетле бетә. Монда әнә көндәше Исмәгыйль тарафыннан Хәлилнең бер гөнаһсыз гомере киселде! Сөйгәне өстенә иелгән Галиябану җан ачысы белән өзгәләнә: «Хуш, җаным, Галиябануына кавышу шатлыгы урынына синең җеназаң янында елап утырырга туры килә инде...»

Тамаша беткәндә күп кенә кыз-хатыннарның күзен яшь пәрдәсе каплаган иде.

Спектакльнең уңышлы чыгуы куаныч китерсә, Шаһинурны күңелсез бер хәл дә көтеп торган икән ул көнне. Ыгы-зыгы арасында, күрәсең, кемдер гармун күрегенә... пәке белән кереп чыккан иде. Гөнаһсыз-бичара гармун, телләренә басып тарткач, сырхау сыманрак гыжлаудан ары китә алмады, хәерлегә булсын. Бер-берсен сынар өчен, яхшылык һәм явызлык янәшә йөри, диләр. Шулмы бу? Шушындый кара, түбән эшкә кайсының кулы күтәрелде икән?

Шаһинур кәефе кырылганны бүтәннәргә сиздермәскә тырышты.

Сөенми торсыннар әле, ул бит тиз генә җебеп төшә торганнардан түгел. Шулай да, капка ышыгында икәүдән-икәү генә калгач, Мөслимәдән читләтеп кенә сорыйсы итте:

— Авылда «Исмәгыйлең» юктыр ич синең?

Төртмәле, ләкин ихластан әйтелгән бу сорауның мәгънәсен Мөслимә аңлады, билгеле.

— Юк, Шаһинур! Яшермим, сүз кушып караучылар булгалады, ләкин мин аларның һәркайсын кире кактым. Ошамадылар. Бала-чага кебек тоталар үзләрен... Син менә бөтенләй икенче... Синең белән бәрашып сөйләшкән саен мин канатланып китәм.

Шаһинур, «ышанам» дигәнне аңлатып, Мөслимәгә җылы караш ташлады. Аскы төймәсе эләктерелмәгән пәлтәдән эчкәре кера-кера, аны биленнән үк кочып алды. Кышкы салкын уртасында басып торган кызның куены җәйге чиллэдән дә хәтәррәк иде!

Юк, алар вәгъдә бирешмәделәр, еш кабатлап, «яратам-сөям» дигән тылсымлы сүзнең кадерен җибәрмәделәр. Икесе янәшә булганда, икесе аңлашканда алар үзләрен бәхетле хис итәләр, бер-берсенә кирәк булуларын тоялар — бары шул гына. Яшәү формуласы һәм аның кануннарын эзләп меңнәр-миллионнар баш ваткан, ләкин мәхәббәтнең асылы гадилектә, эчкерсезлектә икәнен әйтергә тиешле кешеләрнең бу хакта уйларга, гадәттә, вакытлары да, мөмкинлеге дә булмый.

Унсигезгә аяк баскан яп-яшь егетнең инде акыл утырткан егерме бер яшьлек Мөслимәне үзенә каратуы авыл халкын баштарак гаҗәпкә калдырды, әлбәттә. Тик бу аерманы алар үзләре бөтенләй сизмәде диярлек, чөнки Шаһинурның үз яшенә карата иртә өлгерүе, кызның исә бераүгә дә охшамаган бу егетне аңлый һәм бәяли белүе арада гаҗәеп бер дуслык, тиңдәшлек, якынлык тудырган иде.

Шаһинур, энекәш дигән чикне атлап узды да, абый булды.

Мөслимә, апа дигән яшерен сызыкны сикереп чыкты да, сеңлекәшкә әверелде.

Ике йөрәк аралашканда йолдыз атыла икән, бу — гомернең кыскалыгына ишарә, аның кадерен белегез, дигән кисәтү билгесе.

Шаһинурга тиздән унсигез яшь тулачак. Шуннан соң ул солдат хезмәтенә китәргә тиеш иде. Ә аңа кадәр...

Аңа кадәр ул һаман да балалар укытты, мәктәп тормышы белән мәш килде. Дөнья бит бу, укытучылардан әле кемдер авырып китә, әле кемнедер белемен күтәрү курсларына яисә профсоюз укуына чакыртып алалар. Программада каралган дәресләрне «тозларга» ярамый: программа көтә, аны үтәргә кирәк. Шундый чакларда мәктәп директоры, шахмат тактасында оста маневр ясаган шикелле, расписаниегә үзгәрешләр кертә, укытучыларның вазыйфасын төрләндерә. Сәгатьләр алмашына, рольләр алмашына. Иң мөһиме — программаны үтәүдә өзеклек килеп чыкмасын.

Садри Сәлмәнович үтенече буенча, тора-бара Шаһинур физика, алгебра фәннәрен дә укыткалый башлады. Моңа аның көче, әзерлеге җитә иде. Вакыт ягы кысылды, җаваплылык артты. Җанын еш кына тынгысызлап, хәзер Шаһинурны бердәнбер сорау борчый: ул укыткан, ул өйрәткән белемнәр киләчәктә балаларга файда бирерме? Мәктәптә алган гыйлемне тормышта дөрес һәм тулы итеп куллана белерме алар? Юкса шәкертләренә һәм аның үзенә дә вакыт уздырудан, ыштан туздырудан ни мәгънә?

Шәхси тәҗрибәсеннән чыгып, Шаһинур янә бер кат аңлады: уку-укыту программасы, педагогика әлифбасы тормышка бөтенләй якынайтылмаган иде. Киресенчә, кемнеңдер күренмәс куллары белән тормыштан шулкадәр ерагайтылган, нәтиҗәдә — мәктәп үзе бер эздән, тормыш үзе бер киңлектән җай гына агып ята иде шикелле. Үзе дә аңлап бетермәстән, авыл баласы туган җир сулышы, аның һәр үлән-яфрагы, чишмәсулар тибеше белән яши. Аңа шушы нәрсәләр кыйммәт, шушы нәрсәләр якын. Чишмәләрне пычранудан, елгаларны коргаксудан, җирне ерганак һәм язгы сулар һөҗүменнән ничек итеп сакларга, басу-кырлардан җыелган уңышның бәрәкәтен ничегрәк озын гомерле итәргә — кызганычка күрә, дәреслекләр бу хакта берни сөйләми. Авыл баласы өчен бик күп фәннәр, гамәлгә кермичә, үги булып читтә кала. Әлбәттә, бөтен кешенең игенче яки космонавт булуы мәҗбүри түгел. Ләкин һәркайсы үз эшенең, үз һөнәренең серләрен яхшы белергә тиеш — шунда гына җәмгыять алга китәчәк. Әйтик, комбайн-трактор штурвалы артына утырачак кешегә Пифагор теоремасын, Эйнштейнның нисбәтлелек законын белү ни дәрәҗәдә кирәк? Аның өчен агрономия фәне, һичшиксез, күп тапкыр мөһимрәк. Авылдан да менә дигән рәссамнар, композиторлар яисә архитектор, физика-математика фәннәре остасы да әзерләп буладыр. Моның өчен ике генә нәрсә — мөмкинлек һәм остаз кирәк. Һәм тагын баланың талантлы булуы. Булсын иде көчең, мөмкинлегең, хакимиятең — үзләре теләгән, үзләре аеруча яраткан фәннәрне генә сайлап, көчәйтеп укытасы иде балаларга! Юкса бөтенесен бер аршин астына куып кертәбез дә, һәммәсеннән курчактай игезәк, тәңгәл кешеләр әзерләп чыгарабыз...

Шаһинурның башына еш кына әнә шундый уйлар да килгәли. Биектәге уйлар бу. Анда кадәр күтәрелү һәм юлдагы киртәләрне, алай гынамы — җитмеш җиде кат кирпечтән салынган әлеге туң стенаны узып чыгар өчен вакыт, тәҗрибә, белем, көрәш һәм максат ныклыгы кирәклеген дә аңлый, чамалый Шаһинур. Болар, ул тели дип кенә, әкияттәге сыман бер селтәнүдә генә хәл ителә алмый, әлбәттә. Түл җыярга, акыл тупларга кирәк. Әле байтак нәрсәләр, тормышның ачылыр-ачылмас күп кенә серләре алда көтеп торадыр кебек.

Укытучылар өчен мәктәп тормышы ел урталай итеп дүрт кисәккә бүленгән. Дөресрәге, дүрт чиреккә. Аның беренчесе сентябрь шатлыгына урала да, аннары кара көзнең яңгырлары, басуда колхоз бәрәңгесен алышу кебек моңсу-михнәтле көннәр белән тәгәлләнә. Икенчесе Яңа ел тантанасы һәм кышкы каникуллар шаукымы астында күмелеп кала. Дүртенче чирек — иң күңеллесе, иң мәшәкатьлесе, чөнки монысында уку

елы төгәлләнә, эшләнгән эшкә йомгак ясыйсың. Ләкин аңа кадәр тагын бер баскыч бар — өченче чиреккне түгәрәклисең, уку елы азагына чыгачак билгеләрне барлыйсың.

Бүген өченче чирек нәтиҗәләре буенча педсовет утырышы.

Завуч белән мәктәп директоры моңа инде ныклап әзерләнеп куйганнар. Соңгы нәтиҗә хәзергә шушы ике кеше кулында. Шунардан чыгып, алар инде кай урында кемне мактарга, кемне тәнкыйтьләргә икәнен әллә кайчан килешенеп куйганнар. Садри Сәлмәновичның кулында таблица — анда һәр классның, һәр укытучының ничә процент өлгереш бирүе амбар кенәгәсендәге төгәллек белән җентекләп язылган. Бу саннарны берничек тә кире кага алмыйсың, алар директор ясаган таблицага аяусыз булып теркәлгән инде.

Садри Сәлмәнович коллективны өченче чирек нәтиҗәләре белән таныштыра башлады. Укытучылар, үзара пышын-пышын сөйләшүдән туктап, аның шактый кабатлана торган кереш сүзен тын да алмый тыңладылар.

— Иптәшләр, менә өченче чиреккне дә тәмамладык. Безнең алга зур максат куелган: балаларга ныклы белем бирү, югары өлгерешкә ирешү. Яхшы билгеләр — бу безнең яхшы эшләвебез дигән сүз. Начар билге исә безнең тиешле югарылыкта эшләмәвебез турында сөйли. Чирек нәтиҗәләре белән без үз хезмәтебезгә үзебез үк бәя дә куябыз. Безнең беребезгә дә артта калу хокукы бирелмәгән. Ватан һәм партия, гражданлык бурычыбыз һәркемнән югары өлгереш таләп итә, иптәшләр!

Директор таблицадагы саннарны, процентларны укый башлагач, Шаһинурның уйлары шушы саннар артында посып яткан чынбарлыкка барып төртелде...

Район мәгариф башлыгы директордан югары өлгереш таләп итә. Үз чиратында, Садри Сәлмәнович коллективны җай гына «чыбыркылап» тора: яхшы укытканны раслыйсыбыз килә икән, чирек ахырында бер генә балага да «начар» билгесе чыкмаска, тиеш. Беркайда язылмаган шушы кагыйдә укытучының йөрәген келәшчә кебек кысып, богаулап тора. Коллектив кадәр коллективта берәүнең дә артта каласы, начарлар исемлегендә йөрисе килми. Менә шуңа күрә дә класс җитәкчеләре арасында яшерен ярыш бара: кемдә ударниклар күбрәк, өлгереш проценты кемдә югарырак?... Әлеге «процент чире» укытучының нервысын вата, аның абруена, кешелек һәм педагогик дәрәҗәсенә суга. Чөнки ялкаулыкта аты чыккан укучы белеп тора — тартып-сузып булса да барыбер ябык кына бер «өчле» куячаклар аңа. Шушы шаукымга бирелеп, Шаһинурның үзенең дә гөнаһка кергәне булды ич! Сигезенчедәге Гарифуллинны физикадан өстәмә сораулар белән кысып-кысып карады да, әйтергә мәҗбүр булды:

— Ярый, Гарифуллин, тартып-сузып «өчле» куям. Ләкин аң бул: алган белемең барыбер «икеле»дән узмый синең...

Теләсәң нишлә, теләсәң ничек укыт, ләкин сиңа ышанып тапшырылган бала классында утырып калырга тиеш түгел. Бу — мәктәп өчен, коллектив өчен хурлык. Бу хурлык башта — район, аннары республика мәгарифендәге кара тап булып, Мәскәүгә үк барып җитә, имеш... Менә бит — бер укытучының эшләп җиткермәве аркасында куелган начар билге никадәрле озын юл үтәргә мөмкин икән! Мондый хәл булмасын өчен зур уяулык сорала. Мәктәп директоры, кораллы солдат сыман, мәгариф сагына куелган. Аның коралы — инструкция, циркуляр хатлар. Өлгереш һәм процент мәсьәләсендә тамчы да чигенергә хакы юк аның.

Кәгазьдә язылганнардан тыш, телдән әйтелә торган инструкция-күрсәтмәләр дә барлыгын белми иде Шаһинур. Шулай да Садри Сәлмәновичның, яхшы гына педагог булу өстенә, өстән кушканны төгәл үтәүче, башкаручы роленә керүен соңгы вакытларда хәйран гына аңлап өлгергән иде.

Менә шуңа да түзмәде ул, гадәттәгечә кызып-җанланып киткән утырышның урта бер җирендә сүз алды. Юк, укытучыларга да, мәктәп директорына да бәрелүне максат итеп куймады, бары тик шушы күренешнең зарарлы, ялгыш икәнлеген искәртергә тырышты:

— Без саннар һәм процентлар белән мавыгабыз. Нәрсә, мәктәпме бу, әллә бухгалтериями? Белем һәм билге — болар икесе ике нәрсә ич. Алар турыдан-туры тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Югары өлгереш һәм яхшы күрсәткечләр артыннан куып, без, ирексездән, укытуның дәрәҗәсен түбәнәйтәбез. Укучыларның чын белемгә булган омтылышын сүндерәбез. Нәрсәнедер үзгәртәсе, борылыш ясыйсы иде... Безне, мәсәлән, унынчы класста астрономия фәненнән укыттылар. Әмма күктәге йолдызларны ничек, ни рәвешле табарга — безне моңа өйрәтүче булмады. Астрономия дәресләренең берәрсе төнлә үткәрелсә, бәлки, күбрәкне үзләштергән булыр идек, дип уйлыйм.

Житди генә барган педсовет утырышы бу урында елмаю-көлешү белән чуарланды. Шаһинурның бу фикерен укытучылар аңлады, хәтта Садри Сәлмәновичка хәтле мыек астыннан тыелып кына елмая иде бу минутта.

— Син җәмгыять өчен иртә өлгергәнсең, ахры,— диде директор, егетнең сүзләрендә хаклык барын ирексездән танып.

— Юк, җәмгыять үзе өлгермәгән...— дип җавап бирде Шаһинур. Кинәттән генә әйтелгән бу сүзләрнең мәгънәсен ныклап үзләштерергә берәүнең дә вакыты, теләге юк иде....

## 13

Хушыгыз, авыл күгендәге ап-ак болытлар!

Хушыгыз, ничә буын аунап үскән, беркайчан төсен үзгәртми торган яшел чирәмнәр! Юл капчыгын асып, Шаһинур бүген бик күпләрнең башыннан кичкән гади дә, серле дә, әлегә шактый билгесез дә тоелган ерак сәфәргә кузгалды.

...Хәрби комиссариатның шактый таныш бинасы бу юлы тимер рәшәткәле дәү тәрәзәләре белән күзеңә туры карап, кырыслык чәчеп каршылады. Районның хәрби башлыгы подполковник Ишмуратов, эш кәгазьләрендә актарына-актарына, Шаһинур Нәҗмиев дигән егетнең килүен иртәдән бирле дүрт күз белән көтеп тора иде. Ул инде аның барлык документларын, анкета мәгълүматларын җентекләп, кат-кат карап чыкты. Шаккатырлык хәл! Армия хезмәтенә чакырылган бик күп үсмерләрнең әле мыек асты да ныклап кибеп өлгермәгән була. Моның исә шәхси папкасындагы рәсеменнән үк житдилек, өлгергәнлек, ир-егетлек чалымнары бөркелеп тора. Тагын да гаҗәбе — ул инде өч ел буена сигезьеллык мәктәптә эшләргә, хәтта физика һәм математика кебек фәннәрне укытырга да өлгергән... Андыйларны «вундеркинд» диләр бугай. Врачлар теркәгән мәгълүматлар да егетнең физик яктан көчле, әзерлекле булуы турында сөйли.

«Мондый егетне теләсә кая җибәреп югалтмаска кирәк»,— дип уйлады подполковник һәм Шаһинурны очучылар әзерли торган хәрби авиация училищесына тәгаенләп куйды.

Ул көнне комиссариат хезмәткәрләре, көндәлек мәшәкатьләрне исәпкә алмаганда, Шаһинур өчен генә эшләделәр диярлек. Кичке якта барлык документлар хәрбиләрчә төгәллек белән тәртипкә салынган иде.

Казанның кызыл кирпеч вокзалы. Җәйге челләдә халык кырмыска оясыдай кайный. «Дөмберт» итеп вагоннар бәрелешкәне ишетелә. Саубуллашу авазларын поезд гудоклары күмеп китә...

Шөгер тирәләрен узып киткәннән соң поезд күрше өлкәнең урманкырлы киңлекләре буйлап алга таба чапты да чапты. Шәһәр арты шәһәр,

поселок һәм эреле-ваклы станцияләрне артта калдыра торгач, Сизрән шәһәренә килеп туктады.

Биредә Шаһинур өчен чын-чынлап яңа тормыш башланган иде.

Училищега узардай һәр курсантны энә күзеннән үткәрә белгән врачлар аның сәламәтлеген яхшы дип таптылар. Шулай булмый хәле юк: барлык әгъзалары сау-сәламәт, йөрәк тибеше әйбәт күрсәтә, нерв системасы ышанычлы. Бигрәк тә тешләреннән, аларның тигез-матур һәм таза булуыннан канәгать калдылар. Набор вакытында моңа зур игътибар бирелә: чөнки тешләре зәгыйфь кешенең киләчәктәге юлдашы — йөрәк һәм нерв авыруларын... Андыйларны күккә, авиациягә якын җибәрмәвең мәслихәт. Кечкенәдән түбәгә үрмәләгән, агач башларында һәм турникта атынып үскән Шаһинур әйләнмәле тәгәрмәчтә йөзтүбән әйләнеш ясауларны да уңышлы үтте. Керү имтиханнарын тапшыргач, аны училищега кабул ителүе белән котладылар.

Әй, рәхәт һәм күңелле иде бу минутларда!

Алар, төрле-төрле сынаулар иләге аша узып, тулы хокуклы курсант булдылар. Энәдән-җептән генә чыккан өр-яңа хәрби киемнәрен кигәннән соң баштарак бер-берсен танымыйчарак аптыраштылар. Как бер төсле киемдәге бу егетләрнең килеш-кыяфәте генә түгел, битләренә хәтле бер камырдан әвәләнгән сыман тәңгәл иде. «Тәртип өчен яхшыдыр бу, әмма үз-үзеңне югалтмау турында да истән чыгармаска кирәк»,— дип уйлады Шаһинур.

Хат язарга ярата иде ул, вакыты булган саен хатлар язды. Бер-ике ай узды микән, шундый хатларның берсендә авылга Шаһинурның фотосы килеп төште. Өстендә хәрби кием, очучылар фуражкасы кигән, түшенә разряд билгеләре тагып өлгергән бу егетнең карашында, ни хикмәттер, Гагарин елмаюына охшаш төсмерләр бар иде. Мондый рәсем Мөслимәгә дә килгән иде. Ул аны, иң зур шатлыгыдай кадерләп, альбомының беренче битенә үк ябыштырып куйды. Хәзер Мөслимәнең бөтен юанычы — хатлар. Аның уйларын, тетрәнүләрен, шатлык һәм борчуларын сөйләү өчен тән утырып хат язудан да көчлерәк чара юк, чөнки кыз Шаһинурны югалтудан курка иде...

Шаһинур исә хәрби кешегә әверелде. Ул очучылык һөнәрен үзләштерә. Метерология һәм вертолет йөртү дәресләре. Хәрби техника һәм һава гаскәрләре төзелеше. Парашюттан сикерүләр. Шартлы «дошман» белән сугышырга, җиңәргә, илне сакларга өйрәнү. Дәресләргә Шаһинур бөтен күңелен, сәләтен, омтылышын салды, шуңа да ул яхшылар рәтендә йөри иде. Туган телен белмәгән кеше — ярты кеше. Советлар Союзының Камчаткадан алып Брестка кадәрге гигант биләмәсендә рус теле дәүләт теле буларак яши һәм гамәлдә тора икән, аны белмичә ерак китә алмыйсың. Авиация эшендә инглиз теле халыкара тел дип кабул ителгән. Бер ел дигәндә Шаһинур инглиз телен дә ярыйсы гына үзләштерде. Аның татар, рус, инглиз телләрендә иркенләп сөйләшүенә командирлар үзара шаккатып карасалар, иптәшләре яхшы мәгънәдәге көнләшү белән сокланалар иде Шаһинурга.

Иптәшләреннән берсе курсант Марат Янчурин Оренбург өлкәсеннән иде. Ачык күңелле, соңгы сыныгын да уртаклаша белгән бу егет белән беренче көннәрдә үк дуслашты Шаһинур. Ләкин егетнең йомшак ягы бар икән — ул беренче айларында ук шүрләп төште: шушы кадәр авыр, катлаулы уку программасына көче җитәрме, кире бормаслармы, янәсе... Җитмәсә, нәкъ менә шундый борчулы көннәрендә сөйгәненнән бер хат та килеп төшкән үзенә! Ул аның өч ел укыганын көтеп тора алмый, башка бирәүгә кияүгә чыгарга җыена, имеш...

— Син аны яхшы беләсеңме? — дип сорады Шаһинур, икесе генә калган аулак бер сөйләшүдә.

— Өч ай...— диде Марат, бик күп сорауларга урын калдырып.

— Соң сине көтә белми икән, нигә аңа ялынырга? Чыксын, яши бирсен. Безнең бит барысы да алда әле.

— Әгәр укуны жиңә алмасам, мин ничек әйләнеп кайтырмын да, кеше күзенә ничек күренермен?

— Менә шуның өчен дә тырышырга, югалып калмаска кирәк безгә! Мин сиңа булышырмын, якташ!

«Якташ» дигән сүздән татар егетенең күңеле балавыз сыман эреде. Ул инде эченнән генә яхшы укырга, мәхәббәт мәсьәләсендә салкын канлы булырга ант итеп өлгергән иде.

Шлемофон кию, жилкәгә планшет асу, парашют янчыгы белән гәүдәнең кушылып китүләре Шаһинур өчен гадәти бер тормышка әверелде. Дөресен әйткәндә, ул жир белән күк арасында яши башлады.

Шаһинур бүген чираттагы очышка бара...

Таш плитә белән түшәлгән, кояш астында тәмам кызып өлгергән аэродром мәйданчыгында дәү яшел чикерткәне хәтерләткән вертолетлар. Әйтерсең, шахмат тактасындагы фигураларны шушында тезеп куйганнар. Алар, кемнеңдер кулларына кагылганны көтеп, тып-тын гына хәрәкәтсез торалар. Оеп утырган бу куәтле машиналар кеше кулы, кеше акылыннан башка, чыннан да, берни эшли алмый. Алар кешегә буйсына. Адәм баласының акылына, максатына буйсына.

Без жирдә яшибез. Күккә менәр өчен никадәр акыл, омтылыш, жегәр кирәк. Теләсә кемнең кулыннан киләме бу? Алай дисәң, иген игү яисә кемнеңдер йөрәгенә операция ясау шулай ук һәркемнең көченнән килә торган эшме? Агач үстерү яисә алты почмаклы өй салу өчен дә аерым бер галант кирәк. Ә инде кемнеңдер йөрәген уч төбенә салып терелтү яки саннар, таблица-формулалар телендә дөньяны аңлар һәм аның белән идарә итәр өчен тагын да зуррак талант көче кирәк. Шаһинурга мәктәптә икс-игрек, синус-косинусларны өйрәттеләр — боларны ул заманында кирәкмәгән бер мәшәкать дип кабул иткән иде. Аннары, мәктәптә үзе математика фәннәре укыта башлагач, «Авыл баласына шушы кирәк микәнни?» — дип аптырашта калган иде. Менә хәзер аңлады: белемнең бер генә кәррәсе дә, дөньяны танып белүнең бер генә тамчысы да артык түгел икән. Уйлап карасаң, алар — дөрес яшәү, дөньяны тулырак аңлау һәм киләчәгеңне ачыграк күзаллау өчен менә дигән хәзинә, гыйлем бакчасы икән ләбаса!

Шаһинурның бүген истә кала торган аерым бер көне. Остазлары күзәтчелеге астында күпме чакрымнарны буйсындырганы, әллә нинди жилләрне жиңеп кайтканы бар аның. Ә менә бүген ул күк белән бергә-бер очраша һәм вертолеты белән дә күзгә-күз калачак...

Такыр кырда басып торган вертолет фезюляжының йомрыланып килгән кайбер өлешләрен кызлар иңсәсенә охшата иде ул. Менә сиңа юләр чагыштыру! Нәп-нәфис кызлар һәм дюральдән эшләнгән унике тонналы очкыч арасында нинди уртаклык булу мөмкин? Берсендә — йомшаклык, икенчесендә күкләрне дер селкетерлек дуамал көч юкса!

Вертолет кабинасы ябылды. Гүелдәп мотор кабынды. Жирне һәм таш плитә арасындагы үләннәрне дер селкетеп, корыч машина жинел бер этәрелеш белән һавага күтәрелде. Колачлы канатлары белән тыгыз зәңгәрлекне ишә-ишә һәм шуның кайнар агымын койрык винты белән вак-вак кисәкләргә тураклап, Шаһинур кулындагы очкыч көнбатышка таба йөзеп китте.

Биш йөз метр чамасы күтәрелгәч, Шаһинур төп маршрут сызыгына төшеп ятты. Вертолет алга бара, ә жир шары әкрен-әкрен генә артка таба шуыша кебек. Аста (бер генә сәхнәгә дә сыйдырып булмастай гажәеп декорация): еландай борма-борма елгалар, уйдык-уйдык әрәмәләр, линейка белән сызылгандай квадрат басулар... Уенчык шакмаклардан ясалгандай шәһәр сурәте... Аерым бер утрауны хәтерләткән жыйнак-жыйнак авыллар... Жирдә кешеләр яши. Алар дөнья куа, нәсел үрчетә, тормыш матур булсын дип тырышалар. Ләкин дөньяны матурлау, камиллеккә якынайту өчен теләк кенә аз. Теләк дигәннәр чынга ашсын өчен вакыт

кирәк, иман ныклыгы һәм рухи жегәрең белән вакытны үзенә буйсындыра алуың кирәк.

Шаһинурга биеккә күтәрелү бәхете бирелгән. Күктә уйлар үзеннән-үзе зураеп, колачланып китә. Очкычка утыргач, биектәге һава бураз-налары киңлегеннән тормышның, яшәүнең могжиза икәнен аңлыйсың. Кеше нинди көчле! Күз карашы, хыял житезлеге белән ул мизгел эчендә дөньяны колачлый ала. Зиһен куәте белән әллә ничаклы табышмакларны чишә, ачыш ясый, хакыйкать катламына үтеп керә.

Жирдә яшәгәндә күкнең ни икәнен теләсәң дә белә алмыйсың. Күктә оеп, яшеренеп яткан фәлсәфәләр биектә генә ачылырга мөмкин. Жирдә чакта мәңгелекнең чалымнарын тоеп бетермисең икән, ә менә күктә бу нәрсә аермачык сиземләнә. Жирдә без ишекләргә, таш йортларга, табигать корып куйган манзараларга килеп төртеләбез. Күктә мондый киртәләр юк. Сине анда мәңгелекнең шәрран ачык капкалары көтеп тора. Очсыз-кырыйсыз киңлекләр кочагына очсыз-кырыйсыз уйларың тарала...

Очыш вакытында Шаһинурның уйлары да әнә шундый талпыныш кичерә.

Вертолет моторы тигез генә гүелди. Приборлар тактасында төрле төстәге утлар яна. Машинаның йөрәк тибешен белдереп, уклар тибрәнә. Очкыч инде күптән гәүдән һәм жанының бер өлешенә әверелгән. Аңа ышанырга кирәк, чөнки ул үзе дә сиңа ышана. Һавага ышанырга кирәк, чөнки ул, жаваплылыктан курыкмыйча, сине үз биләмәсенә күтәреп алган инде. Биеклек сине үз баласы иткән, аңа да ышанырга кирәк. Күктә әйбәт, рәхәт. Ләкин күңелнең кайсыдыр кыллары белән барыбер жиргә тартыласың. Күңелнең бер төпкелендә кешеләрне сагыну, шулар арасына ашыгу хисе дә утырып тора.

«Читтә күпме генә ашлар ашасаң да тозсыз була, улым»,— дигән иде сукыр Бибижиһан карчык, Шаһинурның армия хезмәтенә китәсен белеп. Чынлап та, әнисе пешергән өреле ашларны еш сагына Шаһинур. Их, менә хәзер вертолет белән авылның ындыр артына булса да кайтып төшсәң иде ул! Шлемофонны саласың да, шуны кулга тотып, авылдашларны сәламлисең. Очкычны малай-шалай чебен урынына сырып алачак, билгеле. Бөтен кеше белән рәхәтләнеп, күңеле булганчы сөйләшер иде Шаһинур. Бибижиһан карчыкның да хәлен белергә керер, чын тавык шулпасыннан авыз итәргә кайттым, дип әйтергә дә онытмас иде.

Кичен, әлбәттә, Куштөбәк авылына юл тотар. Мөслимәне күреп сөйләшер. Сөйләшер сүзләр исә күп жыйналды, хатка гына язып бетерү мөмкинме соң аларны! Мөслимә Шаһинурның йөрәгендә моң булып яши. Егеткә мәхәббәт канатлары куйган бу кызга мең рәхмәт. Беренче тапкыр үбешү, кыз баланың кайнар сулышын тою, йөрәк тибешен ишетү, икәү генә белгән уртаклык тойгылары — болар яшь кешегә кайчан да булса килергә тиешле рухи хәзинә, хыял-романтика белән өртелгән янача яшәеш. Болар үзеңне кеше итеп тояр, иман ныклыгын һәм күңел сафлыгын раслау өчен кирәк.

Уйлары белән Шаһинур шундый биеклеккә күтәрелде ки, яшисе килү хисе көчле дулкын булып һавада кайта-кайта тирбәлә иде.

## 14

Авылда Мөслимә үз уйлары белән яшәп ята.

Аңа, бердәнбер кыз һәм таяныч булырак, әнисен берничек тә ташлап китәргә ярамый. Шуңа да ул язмышына күнде, шәһәргә ашкынмады, тотты да клуб мөдире булып эшкә урнашты. Шаһинур белән танышу-аралашу аның тормышын бизәп, балкытып жибәрде. Әтисез үскән кыз өчен ир-егетләр затыннан булган Шаһинур тансык та, кадерле дә иде аңа. Ләкин көннәрдән бер көнне егетнең ил сагына китеп баруы, хәрби

училищеда укып очучы булырга җыенуы аның бөтен уйларын чуалтып ташлады...

Кызның күңелендә сагыш чишмәсе челтери иде. Шаһинур хәзер еракта — ул очучылык һөнәренә өйрәнә. Аның каядыр күктә очып йөрүләрен күз алдына китергән саен Мөслимәнең йөрәге чемердәп, талпынып куя. Җирдән исәпләсәң — бер ерак, инде күккә менеп йөрүләре аны Мөслимәдән тагын да ныграк ерагайтадыр кебек. Шагыйрь әйтмешли, ниләр булмас анда — очсыз-кырыйсыз күк бит ул! Илаһи өнсезлек белән уратылган, хәтта Гагарин кебек легендар шәхесләрне дә аямаган серле, төпсез киңлек... Авыл өстеннән гүләп самолет уза икән, баскан җирендә кадакланып, кыз аны күз карашы белән офыклар артына кадәр озатып кала. Күңеленнән генә теләк тели: берүк Шаһинуры исән-сау йөри күрсен, хәвеф-хәтәргә юлыкмасын!

Хәрби училищеда Шаһинур быел соңгы елын укырга тиеш. Яхшы укыганы өчен, вакытлы ял биреп, берничә тапкыр авылына җибәрделәр аны. Хәрби киемнән, очучылар гына кия торган зәңгәр каюлы фуражкадан кайтып төшкән зифа буйлы егетне күргәч, Мөслимә генә түгел авылга кунакка кайткан шәһәр кызлары да берьюлы «аһ» иттеләр! Ләкин Шаһинур Мөслимәнеке иде. Кичен алар аулакта калып туйганчы серләштеләр, берсен-берсе бүлдереп, әле авыл яңалыкларын, әле хәрби тормыш хәлләрен сөйләштеләр. Шаһинур ялга кайткан саен шулай була иде. Соңгысында мотоцикл белән болынга ук төшеп киттеләр. Төн. Учак. Йолдызлар багына кушылып, сусыл үләннәр дә, тәңкәдәй чәчәкләр дә, уймак әрәмәләр дә, Мишә елгасы һәм икәүнең күкләргә ашкан тыелгысыз җаны да дөнья киңлегендә талгын бер әйләнеш ясады ул төндә! Табадай түгәрәк учак урынында исә соңыннан бары аксыл көл пәрдәсе утырып калган иде...

Соңгы вакытларда Мөслимә суырылып, үз эченәрәк бикләнеп калды. Күңеленең кай төше беләндер сизенә ул — очу һөнәренә өйрәнгән Шаһинурның берзаманны кул җитмәстәй ераклыкка китеп баруы да бик ихтимал ич. Яңа җирдә яңа кешеләр белән танышкан саен Мөслимәне бөтенләй онытып җибәрмәсме ул? Арада никадәр киртәләр ята: яшь аермасы, Мөслимәнең авылда утырып калуы, әнисен ташлап китә алмавы, кая да булса укырга кереп белгечлек сайламавы... Ах, әтисе исән булсамы! Кыз, күп кенә иптәшләре кебек, шәһәргә китәр, эшкә яки укырга керер, тормышын түгәрәк итәрдәй һөнәр сайлар иде. Нинди мөмкинлекләре була торып та, язмыш аңардан кайбер нәрсәләрне кызганган шул. Ә шулай да Шаһинурны очрату бәхете белән бүләкләгән, анысына рәхмәт! Хәзер бөтен өмет, юаныч борчулар, киләчәкнең нинди юлдан китеп барачагы — һәммәсе Шаһинурга бәйле. Ләкин язмыш тәгәрмәчен чут төймәседәй уңга-сулга үзең теләгәнчә генә йөртеп булмый икән шул. Кызның уйларын билгесезлек томаны баскан иде.

Шаһинур укып бетерер, яшь лейтенант сыйфатында аны кая да булса хәрби хезмәткә җибәрерләр. Ә Мөслимә нишләр? Һаман шулай көтеп утырсынмы? Шаһинурның гаилә кору турында ныклап торып авыз ачканы да юк. Минем әле иң элек укуны тәмамлыйсым бар, вакыты җиткәч, дип әйтү белән чикләнә, юатырга тотына. Эреп китсә китә, ләкин юашлардан түгел иде Мөслимә. Язмышы үлчәү тәлинкәсенә салынырга торганда ул битараф бер сурәттә басып, читтән карап торсынмы?... Булмас! Сүзеңне вакытында өздереп әйтә белү, үз бәхетең өчен үзең көрәшү кыйммәт.

Шулай уйлады Мөслимә. Декабрь киче иде. Тышта тавыш-тынсыз гына бияләй-бияләй кар төшә иде. Декабрьнең шушы аулак кичендә Мөслимә, озаклап утырып, Шаһинурына хат язды. Озын хат иде бу. Кызның мәхәббәте, шикләре, шатлык һәм борчулары, тагын-тагын әллә ничаклы хисләре мөлдерәмә сыйган иде аңа.

*«Шаһинур!*

*Минем бу хатымны алып укыгач, гаҗәпләнмәссең. Кайчагында, телдән әйтүгә караганда, әйтәсе килгән сүзләреңне кәгазь бите аша ансатрак әйтеп була. Мин бүген күңелем булганчы бушанырга, чайпалып торган хисләремне тукмичәчми сиңа җиткерергә телим.*

*Ай-яй, еракларга китеп бардың да соң инде! Әле дә ышанмыйм:*[1] *ялга кайтып, минем янга килүләрең тылсымлы бер төш кебек шикелле. Беренче очрашулар искә төшә дә, уйлап куям: син мине сагындырыр өчен генә дөньяга яратылгансың, ахры. Әйе, турысын әйтим, мин гел сине сагынып яшим. Рөхсәт тә сорап тормастан, төшләремә киләсең дә керәсең. Гомер булмаган хәл: кичә беренче тапкыр үз гомеремдә төсле төш күрдем. Син яшькелт кительдән, зәңгәр каймалы фуражкадан. Кулларыңда ут шикелле кызыл розалар иде... «Нишләп нәкъ менә розалар икән, алар безнең якларда үсми ич?» — дип гаҗәпләндем.*

*Менә шундый хәлләр. Ни генә эшләсәм дә, уйларым тота да сиңа әйләнеп кайта. Син мине биеккә — сөю күкләренә кадәр күтәрдең. Күңел күзләремне ачтың, әмма маңгай күзләремне сукыр иттең. Синнән башка бүтәннәрне күрер хәлдә түгел идем мин. Безнең очрашу-күрешүләр, бәхәсләр, аяк чалып көрткә егулар, болында тездән үлән ерып атлаулар — үзе бер бәхет иде. Мәхәббәттә рәхмәт әйтелми бугай ул, тик мин сиңа мәңге рәхмәтлемен. Сөю шатлыгы белән таныштырганың өчен, хисләремне баетканың өчен... Мин синең белән үткән көннәремнең тамчысы өчен дә үкенмим. Мин инде гомернең матур бер өлешен яшәдем кебек.*

*Беләсеңдер, мин коелып төшкәннәрдән түгел: аның калган өлеше дә матур булыр шикелле. Чү, нигә үз-үземне алдалыйм соң әле болай? Киләчәкнең ничек буласын кемнең әле алдан ук белеп торганы бар? Бигрәк тә кыз баланың. Кызлар язмышы һәрчак сынау астында. Кечкенә генә гаеп җибәрсәң, ул синең гомерлек хатаң булырга мөмкин. Хәер, сезгәме соң безнең хәлне аңлау! «Кыз баланың күңелен аңлар өчен егетләргә әни булып карарга кирәк», — дигәнне ишеткәнем бар минем. Хак сүзләр күрәсең.*

*Менә бит уйларымның чуалчыклыгы! Бөтенләй икенче якка кереп китеп, егетләргә гаеп өя башлаганмын лабаса... Әйтәсе килгән сүзләрем бүтән иде. Ничек башларга? Шаһинур, соңгы вакытларда безнең арага ниндидер билгесезлек кереп тула шикелле. Минем аны туктатыр көчем юк. Шуңа да синең белән ачыктан-ачык киңәшәсем, уйларымны уртаклашасым килә. Менә тиздән укуыңны тәмамларсың. Хәрби кеше буларак, син инде хәзер үзеңнеке дә, минеке дә түгел: кая кирәк дип тапсалар, шунда хезмәткә җибәрерләр. Мин сине көтә-көтә шушылай саргаермын, авылда утырып калырмын микәнни? Бүтәнчә чарам юк, чөнки язмыш мине кысып тоткан, һәм беркая да җибәрмәскә тырыша. Уйлап кара: япа-ялгыз әниемне калдырып китәргә хакым бармы соң минем? Әйе, синең хакка мин аны калдыра алам. Ләкин мондый адым, әнкәйне санга сукмау, гомерлек газабым булачак.*

*Мин синең гади кеше түгеллегеңне акрынлап аңлый килəм. Очучы булу бәхете теләсә кемгә эләкмәгәнен дә беләм. Шуңа күрә кайчакны, буй җитмәстәй биеклеккә үреләмме әллә дип, үз-үземне битәрләп тә куям. Ләкин без бар бит, безнең врату хисләребез, уртак кичләребез бар! Мин шушы чынбарлыктан беркая да качып котыла алмыйм. Син еракта. Синең әле тагын даераграк җирләргә китеп баруың ихтимал. Синдәй кешегә юлыңда нинди генә чибәрләр очрамас... Бөтен борчылганым: син мине үзеңә тиң күрмәссең кебек. Моны кичерү миңа кыен булачак, аңлыйсыңдыр.*

*Юк, юк, сине гаепләргә җыенмыйм! Уем аек, хисләрем генә шулай котырта мине. Хисләр колына әвереләдем. Ике хис бәхәсләшә миндә — сине югалтасым да килми, авыр-кирәксез йөк сыман, язмышыңны богаулап та торасым килми. Кайсы җиңәр — белмим, әйтә алмыйм. Көчсезлегемне тойган саен күңелсезләнеп алам, үртәләм. Уйларымны юатыр өчен әле җирдә сабырлык бар.*

*Шаһинур! Хәзергә безнең «сер»не белүче юк. Аңлыйсыңмы, мин бит ут эчендә яшим... Син миңа, шатлык белән бергә, татлы газап та бүләк иткәнсең икән. Шушы газап мине, беләсеңме, нинди уйларга этәрә? Сиңа үтенәм, ялварам, со-*

*рыйм — зинһар, икенең берсен сайла: йә мине, йә авиацияне. Алга таба да мондый билгесезлектә яшәү кыен, бик кыен миңа.*

*Синнән тиз көндә җавап көтеп,*

*Мөслимә».*

Шаһинурдан җавап хәбәре, чыннан да, тиз килеп җитте. Ләкин хат бик кыска иде.

*«Мөслимә!*

*Хатны бик ашыгыч язганым өчен кичер мине. Хәзергә шунысы бара торсын дим. Хикмәт шунда: тизләтелгән программа үтү өчен безне ерактагы икенче бер пунктка алып китәләр бүген. Барып төшү белән яңа адресны хәбәр итәрмен.*

*Хатны язып та карагансың, рәхмәт! Мин сине аңлыйм, аңларга тырышам. Тормыш бит бу, мең сорау һәм меңләгән ачышлары белән һәркемгә төртелергә генә тора ул. Ике юлның берсен сайларга кушып, таләпне, ай-һай, каты куйгансың үзең... Безнең халык арасында катгый бер канун бар — очучылар беренче остазын беркайчан да онытмыйлар. Син — беренче мәхәббәтем, беренче очышларым. Мин сине үлгәндә дә (тфу-тфу) онытачак түгелмен! Син дә мине аңла: авиацияне ташлап китүем мөмкин эш түгел. Ләкин бу катгыйлык безнең сергә, безнең мөнәсәбәтләргә аяк чалырга тиеш түгел. Үзеңне сакла, бу — мине дә саклавың булыр.*

*Калганын тулырак итеп икенче хатта язармын.*

*Сине үбеп, Шаһинур.»*

## 15

Яшәү, мәхәббәт, тормыш-көнкүреш, акча, хакимият, туу һәм үлем дигән нәрсәләрдән тыш, дөньяда сәясәт дигән серле, яшерен һәм куәтле бер көч бар иде әле.

1980 елның октябрендә лейтенант Шаһинур Нәҗмиевне, ул чактагыча әйтсәк, «интернациональ бурычын үтәү өчен», Әфганстанга җибәрделәр. Көз. Аэропорт. Салкын, таш плитәләр кибән кадәрле хәрбитранспорт самолетының кайнар сулышы астында җанланып, кайнарланып китте. Янәшәдәге урманнан җил куып китергән коры яфраклар дулап-бөтерелеп артка таба шуышты. Корыч канатлар җирдән аерылу белән, кайдандыр сары яфраклар өерелеп чыкта да, һава дулкынына ияреп-ияреп, самолет артыннан йөгерә башлады... Гүя туган илнең һәм табигатьнең эчкерсез нәни илчеләре өрлектәй таза, яшәүнең әле ни икәнен дә ныклап татып өлгермәгән бу егетләрне читкә, еракка, билгесезлеккә һәм хәвеф кочагына җибәрмәскә тели иде!

Әфганстанда әле күпләр белми торган чын сугыш бара иде.

Туган ил күгендә тыныч «һава буразнасы» сызасы егетләрне кем соң ут эченә илтеп тыкты — моны берәү дә анык кына белмәде. Сугышның күпмегә сузылачагын һәм нинди нәтиҗәләр белән бетәчәген белмәүләре, бәлки, хәерлерәктер? Нинди милләттән, нинди төстә һәм кайда яшәвенә карамастан, халыкларның бөтенесе дә бер үк нәрсәгә — яшәүгә омтыла. Шулай булгач, нигә инде сугышырга, бер-береңнең чәчәктәй гомерен кисәргә? Бу сорауларга ачык кына җаваплар күренми. Дөньяда хәрби боерыктан да көчлерәк нәрсә юк. Хәзергә барысын да Мәскәүдән җибәрелгән фәрман, яшерен код һәм телефонограммалар хәл итә.

Шаһинур хезмәт итә торган хәрби часть әфган сулышы белән яши башлады. Хәрби романтика — кырыслык, мәшәкатьле хәтәр көннәр белән алмашынды.

Әфганстан дигән илдә яңа тәртип, советчага тартым тормыш кагыйдәләре урнаштыру авырдан бара иде. Гади халык бәхетле тормыш корырга тиеш. Сан ягыннан чикләнгән совет гаскәрләре менә шушы максат белән күрше илгә аяк бастылар. Әмма да «каты чикләвек» икән

бу әфган жире! Чалмалы, чапанлы, аягына резин галош кигән халык читтән китерелгән, ислам диненә каршы булган тәртипләрне кабул итәргә бөтенләй теләмәде. Тауларга качты. Менә шунда килеш алар үз жирен, үз динен, үз иманын яклау өчен көрәшкә күтәрелде. Гиндекуш таулары йокысыннан уянды. Гиндекуш... Нинди таныш исем! Бу исемне Шаһинур ин элек география дәреслегеннән укып белгән иде. Гажәп бит: инде менә шул таулар синең аяк астында жәйрәп ята. Синең кулларына буйсынып очкан вертолет күләгәсе Гиндекуш тезмәләре өстеннән шуыша... Шаһинур ирексездән география дәресен хәтеренә төшерде.

«Гиндекуш — Азия материгындагы ин зур тауларның берсе. Анда вулканнар тезмәсе урнашкан...»

Теге чакта, «биш»ле алмас өчен, вулканнар турында әнә шулай арттырып сөйләгән иде Шаһинур. Уйлап карасаң, чынлап да дөрес сөйләгән ич ул! Әфган халкының нәфрәте янартау булып күтәрелә түгелме? Бу вулканны нинди генә утлар-сулар белән сүндерү мөмкин икән?

Бүген Шаһинурлар экипажы ашыгыч боерык алды: алар Ширбар тарлавыгындагы десантникларга азык-төлек һәм сугыш кирәк-яраклары илтергә тиешләр. Безнең егетләр анда менә икенче көн инде тарлавык аша узасы КамАЗлар колоннасын саклый. Дошман дигәнең бик мәкерле. Таш арасын ярып чыккан үләндәй, алар көтмәгәндә калкып чыгалар да колоннаны утка тоталар. Чит бер илнең кыяташлары арасында төзек корал, уяу күзләр, житезлек, тәвәккәллек кирәк. Гомерең кыл өстенә куелганда синнән бары тик батырлык, егетлек сыйфатлары гына сорала. Сугыш куркаклыкны гафу итми.

Вертолет моторы талгын гына гүелди. Һава ярып барган винтларның гөжләве киртләч-киртләч таулар өстенә барып сылана. Очучы-штурман Шаһинурның уйлары исә очкычныкыннан да хәтәррәк тизлек белән алга йөгерә. Чит жир, чит таулар, пәке йөздәй үткер кыялар... Әгәр шушында егылып төшәргә, челпәрәмә килеп ualырга язган булса!.. Аннары йөрәк туктап калырга тиешме? Тормыш синнән башка гына дәвам итәчәкме? Ә бит дөнья искиткеч кин икән, аның шатлык-сагышлары һәркемгә житәрлек икән! Менә шуларны күрми-татымыйча калу нинди аяныч булачак...

Шаһинурның кан тамырларында яшисе килү хисе тибә иде. Ничек инде үлем турында уйларга мөмкин — аңа һәм аның кебек егетләргә яшисе дә яшисе бит әле.

Экипажда алар өчәү. Һава машинасының сул ягында экипаж командиры капитан Саша Скворцов утыра. Бернидән курыкмый торган шәп, кыю, тәвәккәл иптәш. Тумышы белән Рязань якларыннан. Өйләнгән, хатыны белән биш яшьлек кызы илдә калган. Шуларны сагынудан еш бәргәләнә егет, яшь гаиләсенә хатларны яудырып кына тора.

Борттехник Толя Пашкевич — белорус егете. Гажәп тә сабыр, итагатьле, ярдәмчел. Аның киң күңелле булуына бер Шаһинур гына түгел, частьтагылардан һәркем соклана. Шуңа да егеткә аерым хөрмәт белән карыйлар. Пашкевич өйләнмәгән, ләкин ул сөйгәненнән хатларны алып кына тора. Хәер, туган як һәм сөйгән яр дигәндә, Шаһинур үзе дә хатлар белән яши ләбаса!

Кинәт нәрсәдер булды. Ниндидер көч күзгә күренмәс йодрык белән вертолетка китереп сукты. Эре калиберлы зенит пулеметыннан бәрделәр булса кирәк. Бензин багы тирәсендә ялкын телләре күренде. Ак-караны аермаучы кайнар ядрә кеше үтерү өчен туган иде. Һәм шундый ядрәләрнең берсе Шаһинурга килеп тиде. Бу хәлләр мизгел эчендә булды ки, Шаһинур баштарак яралануын, бите буйлап кан агуын да сизмичә калды. Кулы белән ирексездән, урынындамы дигәндәй, парашютының бөжрасын капшап алды.

— Сикерегез! Ә мин машинаны жиргә төшерәм! — дип боерды экипаж командиры. Аның катгый тавышы яралы Шаһинурның аңына ядрәдәй чәчрәп керде, гәүдәсендәге көчне хәрәкәткә китерде.

Кабина ишегеннән һавага ташлану белән мотор тавышы егетнең йөрәгенә күчте... Калганы исендә түгел. Ул бары ниндидер куе, тыгыз томан эчендә йөзә, тирбәлә, чайкала. Яңакларны ачыттырып, чигә тирәсендә кайнар-жылы чишмә тибә кебек...

Үзен томан эченә кереп күмелгәндәй хис итсә дә, Шаһинурның уйлары аек иде. «Без барысы өчен дә җаваплы»,— дигән әрнеш сулык-сулык итеп төптән актарылып менә. Тарлавыкта аларны сугышчан дуслары көтә. Алар янына ничек кенә барып җитәргә соң? Туган илдә аны әти-әнисе һәм Мөслимә көтә. Исән-сау әйләнеп кайтып, аларны сөендерәсе иде бит... Ул хәтта үзенең гомере өчен дә җаваплы, чөнки тормышта түлисе бурычларының әле тамчысын да юньләп кайтарганы юк ич Шаһинурның.

Әллә күктә, әллә җирдә ул — йөзе кан белән юылган яралы егет моны анык кына белә алмады. Бер мәлдә күзенә кояшның утлы тәгәрмәче шәйләнде, бу сурәт маятник сыман чайкала һәм: «яшим — юк», «яшим — юк» дигән сүзләрне колакка өнсез генә пышылдый иде. Язмыш Шаһинурны тиктомалдан көчсез, чарасыз кылды. Аңарда с о ң г ы  с у л ы ш  өчен көрәш хокукы гына калган иде.

Томан пәрдәсе кинәт кенә юкка чыкты да күкне тутырып кызыл кар ява башлады... Уйласаң, адәмнәр нинди мәрхәмәтле: әгәр теләсә, алар җирне гөлбакча итә алалар. Адәмнәр нинди явыз: алар бер селтәнүдә табигатьне, тормыш кырларын пыран-заран туздырып ташларга да сәләтле! Адәмнәр коралга ябышты, автоматтан, туптан, танктан атып, самолеттан снаряд һәм бомбалар ташлап Гиндекуш тауларын дер селкетте, кеше белән кешеләрне, кыя белән кыяларны маңгайга-маңгай чәкештерде, ут белән җир-суларны, шәһәр-авылларны көйдерде. Шуның кайтавазы буларак, инде менә адәмнәр каны булып җиһанда кызыл кар ява...

Хәтер почмагында балачакның бер вакыйгасы яңарды. Шаһинур күрше малае белән абзар артындагы көрттә уйный. Буран, киртләч-киртләч итеп, лапас артына өр-яңа көртләр өйгән. Кылыч йөзедәй очланып килгән биек көртнең уртасын тишеп, икесе ике якта килеш, чиратлап кына кар эченнән таяк шудырып уйныйлар. «Кар күзе» тишегеннән таяк, көмеш балыктай атылып чыга да, аяк астына килеп төшә. Кызык була. Берсендә, таяк озак кына күренми торгач, Шаһинур сакланып-нитеп тормастан тишек авызына иелде. Иелеп кенә өлгергән иде, нәкъ шул мәлдә уклаудай шома таяк каш өстенә китереп бәрде! Авыртуга түзә алмыйча, күз яшьләре белән кычкырып елады Шаһинур. Кар өстенә кан һәм күз яшьләре бергә кушылып тамды. Йолдыздай чәчрәп төшкән кызыл тамчылар куркытып җибәрде аны. Ә менә күз яшьләре ни өчен төссез икән? Бәлки, кайгы-хәсрәт хәтердә уелып, күзгә бәреләп тормасын өчендер... Әгәр күз яше кешенең битен, өс киемнәрен буйый торган булса, ничек ямьсез һәм күңелсез булыр иде. Күз яше эз калдырмый, чык тамчысыдай тиз кибә. Кызыл кар табы исә, әнә, бер кисәтү рәвешедәй, хәтер почмагында уелып калган.

«Кызыл кар яугач...» Шушы сүзләрне балачакта күпме ишетергә туры килде аңа. Чынга ашмастай нәрсә турында өлкәннәр әнә шулай хәйләкәр генә, читләтеп кенә әйтә белгәннәр. Шаһинурның бик күп хыяллары чынга ашты. Апа да, сеңел дә була белгән Мөслимә аңа беренче мәхәббәт хисләре бүләк итте. Күңеле күкләргә ашкынган Шаһинур, ниһаять, очучы булды, самолет штурвалын кулына тотты. Язмыш җилләре аны чит бер илгә илтеп ташлады, зур сынаулар аның шәхесен чарларга уйлады. Кул тимәгән көннәр, Ватанга тугры хезмәт итү, гаилә корып балалар үстерү — бөтенесе, бөтенесе алда иде әле.

Тик нигә соң һаман ява бу кызыл кар? Асылда бит кызыл кар яумаска тиеш, чөнки өлкәннәрнең хикмәтле бу сүзе — чынга ашмастай хыялларга ишарә генә. Шаһинурның хыяллары күп ич әле. Алар шушы кызыл буран, кызыл ташкын эчендә күмелеп калыр микәнни? Юк, үлемнән курыкмый да шикелле ул. Ул үлем белән бәхәсләшергә, яшәүнең

мәңгелек көч икәнен якага-яка торып исбатларга әзер. Юк, курка да бугай ул үлемнән. Аның йөрәге тибүдән туктаса, тормыш үзе дә туктальп калыр сыман. Шаһинурдан соң аның кебек итеп кем яшәп китәр, кем яратыр, дөнья гамьнәрен кем шулай нәкъ менә Шаһинурча итеп канатландырып торыр?!

Егетнең уйлары чуалды, кызыл кар ташкыны белән буталды. Ниндидер көч аны үҗәтлек белән аска, тирән упкынга өстери. Шулкадәр авыр, газаплы ки, бу упкыннан ансат кына чыгу мөмкин түгелдер шикелле. «Сау булыгыз, мин яраткан кешеләр...» — дип пышылдады Шаһинурның канлы иреннәре. Һәм ул әнисенең якты йөзен, әтисенең каты-таза кулларын, күрше Кирам абыйның гармунда уйнавын, Сәетҗан белән бакчада утыруларын, Мөслимәнең «Галиябану» спектаклендә моңлы итеп җырлавын берәм-берәм аңыннан уздырды. Шул ук мәлдә Скворцов белән Пашкевичның йөз чалымнары да хәтерендә тирбәлеп алды... Егетнең хушлашу-бәхилләшүе шушы иде.

Кешенең соңгы минуты — тулы бер гомер. Гомерне исә якты уй, кылган гамәл белән исәплиләр...

Татар кавеменнән булган Шаһинурның гөнаһсыз каны чит җиргә, чит туфракка тамды.

## Эпилог

Авыл үз мәшәкатьләре белән яшәп ята иде. Кышлыкка дип, лапас эчләренә хуш исле печән өелде. Кыяр сабаклары саргаеп картайды, көзнең муллыгын сиздереп, бакчада тыгыз-сусыл помидорлар кызарды. Механизатор халкы көне-төне диярлек кырда кайнашты, колхозның келәт-амбарларын яңа ел уңышы белән тутырдылар. Муллык, туклык, килер көнгә ышаныч өстәлгән менә шушы көннәрдә Шаһинурның цинк табутка салынган гәүдәсен кайтардылар.

Улының һәлак булу хәбәрен ишеткәч тә, әнисе Сафия апа бермәл мингерәүләнеп калгандай булды. Коточкыч бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Дөрес хәбәр түгелдер дип, күңелендәге сагышларын төпкә йотарга тырышты. Цинк тартма ишегалдына кайтып кергәч, түзмәде, күз яшьләре белән илереп елап җибәрде. Аның улы шушы тартмага гына сыярлык идеме соң? Чит бер җирдән туфрак итеп кайтару өчен үстердемени ул газиз баласын! Ир кеше буларак, Шаһинурның әтисе үзен кырыс тотты. Стакан белән вакланасы килмичә, яшереп-саклап тоткан яртысын ачу белән алюмин чүмечкә берьюлы салып эчте. Ни гаҗәп: ул тамчы да исермәде, тик икенче көнне аның чәчләре генә яртылаш диярлек агарып чыккан иде.

Күмүнең бихисап мәшәкатьләре, ниһаять, артта калды. Шаһинур истәлеге булып, авыл зиратының бер почмагында әр-яңа кызыл таучык һәм нәни миләш куагы калыкты.

Шулай бит ул: көндезен кешеләрнең кояшка күтәрелеп карарга вакыты юк, җитмәсә тагын аның яктысы күзләрне чагылдыра. Ә кичен, кояш баеганда, олысы-кечесе дигәндәй, алсуланып өлгергән офыкка текәлә — ниндидер моң, моңсулык били күңелне. Кеше вафаты да шулайрак икән... Үлгәч кенә адәмгә башлар иелә, дип дөрес әйткәннәр. Шаһинурның кем икәнлеген ныклап торып сизми йөргәннәрнең дә кинәттән ус-гаме күзгалды, гомер тәме дигән хакыйкатькә азмы-күпме рухи якынайдылар. Барлык борчуларын читкә куеп, Шаһинур атлы егет хакында сөйләштеләр.

— Кемнең итәгенә ут төшсә, шул яна,— дип, егетнең әти-әнисен кызгандылар.

— Кеше өч көн сөйли дә оныта, бөтен хәсрәт — бу баласын тапкан анага,— дип Сафиянең кайгысын уртаклаштылар.

Кичке якларның берсендә Куштөбәк авылыннан Мөслимә дә килеп китте. Кече якка кереп, күлмәк кесәсендәге икс кульяулыгын да күз

яшьләре белән манма итеп коендырды. Аның эче тулы ялкын, үкенеч иде: чөнки ул киләчәкне дә уйларга кирәк, дигән куркудан, булачак баласыннан «котылырга» өлгергән иде шул...

— Сугыш мине ятисез калдырды, инде минә сугышның икенчесе... мәхәббәтемне дә тартып алды! — дип бәргәләнде Мөслимә, күз яшьләренә төелеп.

Мәрхүмнең гәүдәсенә ятып елый да алмады кыз. Менә тәкъдир дигән: ә чынлыкта ул, моннан берничә ел элек, «Галиябану» спектаклендә шушы эшне эшләп өлгергән икән ич. Сәхнәдә Хәлилнең гомере өзелгәч, сөйгәне өстенә иелеп, Галиябану сыйфатындагы Мөслимә: «Хуш, җаным... Кавышу шатлыгы урынына, синең җеназаң өстендә елап утырырга гына калды инде...» — дип өзгәләнгән иде ул чакта. Чынбарлык дигәнең сәнгатьтән дә көчлерәк, күрәсең.

Моннан берничә ай элек кенә кинәт сукыраеп киткән Бибиҗиһан карчык авыл өстеннән самолет-мазар очып киткән саен һаман күккә төбәлә һәм күрер-күрмәс күз карашы белән аларның һәркайсына хәерле юл, исән-иминлек теләп кала иде. Гап-гади авыл карчыгының күңелендә әчке бер шатлык, горурлык посып ята иде: алар авылыннан да бер очучы егет чыксын әле менәтерә! Шаһинурның вафаты турында ишеткәч, карчык имәнеп китте, белгән догаларын авыз эченнән кыймылдатты. Ишегалдына чыгып, таяк белән капшана-капшана йөргәндә күктә тагын очкыч гүләвен ишетте.

— И-и ходаем, Сафия малае үлгәннән соң да оча микәнни бу сәмәлүт дигәннәре? — дия-дия ләхәүләсен укырга керешти.

Авыл өстенә ишелеп төшкән кайгыны Кирам абый да авырдан кичерде.

— Авылның нинди кешесен харап иттеләр бит, әх! — дип, кемнәрнедер кычкырып сүкте ул һәм, әлбәттә, фәлсәфәгә бирелде: — Бу егет тыныч эш белән шөгыльләнергә, иген чәчәргә, антенна башлары куярга тиеш иде югыйсә. Сизенепме, әллә сизенмичәме, әллә кая, зәңгәр биеклекләргә ашкынды шул. Гармунга үзем өйрәткән идем, ә ул мине картаймаска өйрәтте. Гармун белән мин картаяммы соң! Авыл үзе картайды әнә — урамда гармун тавышы ишетелми. Клубны төсле музыка, рокнрол авазлары басты. Алар да яшәсендер, әмма авылның үз матурлыгын нигә кыерсытырга?

Сул кулына яраклаштырылган гармунын гына түгел, дөньясын да йөзтүбән әйләндереп салырга сәләтле Кирам абый Шаһинурның малай чактагы сүзләрен искә төшерде һәм:

— Йолдызлар арасыннан эзләгез мине, дигән иде, бит, балакаем. Шулкадәр дә белеп әйткән, әүлия булган икән... Кичен мин аның карашын йолдызлар арасыннан эзләп табам,— дип, үзенчә нәтиҗә ясады.

«Ходай бу егетне сөеп бирде, сөеп алды...» Авылның мулласы Шаһинур турында уйлап һәм аның рухына дога укып, шушы уйларының дөреслегенә иман китерде.

Табигать вә хәят кочагында меңәрләгән сер, бихисап сораулар яшеренеп ята. Шуларның берсе — чәчәктәй гомере әле ачылып кына килгән Шаһинур язмышы иде. Ил буйлап сибелгән йорт, авыл, шәһәр төбәкләрендә миллион-миллион кешеләр яшәп ята, буын арты буыннар алмашына. Тормыш мәйданына гаять кызыклы, үзенчәлекле, әхлакый сафлык белән өртелгән, җәмгыять файдасына өр-яңа ачышлар ясарга сәләтле яшьләр килә тора. Андыйлар, гадәттә, шәхес буларак иртә өлгерәләр. Ләкин бөтен фаҗига шунда ки, безнең фәкыйрь җәмгыять андыйларны үстерергә, кабул итәргә әзер түгел! Шаһинурга да менә шуның зәхмәте кагылып үтте булса кирәк.

Чынлап та шулай икән шул: әкиятләрнең генә азагы күңелле-матур бетә...

*1980 — 1992.*
*Казан — Олы Мишә.*

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# КАҺӘРЛӘНГӘН ХӘРӘКӘТ, КАҺӘРЛӘНГӘН ТЕМА...

Иж-Буби мәдрәсәсенең тарихын өйрәнүгә мин бик очраклы килеп кердем. Бу минем өлкәм түгел иде. Гыйльми җитәкчем мәрхүм Хатыйп Госман миннән мондый буталчык тарихны түгел, марксизм-ленинизмның әдәбият-сәнгать теориясен таләп итә иде. Ләкин Казан университетының гыйльми китапханәсенә бер килеп кергәч, мин аннан инде чыкмадым: киңәш бирүчем, юл күрсәтүчем Альберт Фәтхи булды. Исмәгыйль ага Рәми, Мәхмүт ага Бөдәйли, Габделхак ага Кудашев белән күп еллар буе залда утырдык. Алар мине эшкә өйрәттеләр. Баян Гыйззәт белән дә өстәлләребез рәттән иде, ул да күп юнәлеш бирде. Аларның барысы да җир куенында инде. Авыр туфраклары җиңел булсын.

Мин Октябрь борылышына кадәр чыккан бөтен татар вакытлы матбугатын картотекага алып, битләп, авторлап укып чыктым. Шунда «Буби процессы» дигән гаҗәеп бер теманы ачтым. Һәм 1966 елның көзендә бу турыда мәкалә язарга утырдым. Буби процессында рус адвокатларының да катнашканын белгәч, Россия юриспруденциясе буенча күп хезмәтләр укыдым. М. Гернетның «Россия төрмәсе тарихы»н, адвокат Н. Маклаков, А. Бать һ. б. юристларның китапларын, нотыкларын өйрәндем, мәшһүр адвокат Ф. Плевако хезмәтләре белән таныштым. Мәкаләм буш урында барлыкка килмәде: Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Г. Мансуров һ. б. шәхесләрнең Буби мәдрәсәсе турындагы совет чоры мәкаләләрен бик нык өйрәндем. Архивка кереп чумдым. Анда Буби мөгаллиме Котдус Абдрахманов турында байтак материал бар. Хәтердә балачактан бер чаткы елтырап алды: Советлар Союзы герое, диңгезче Асаф Абдрахмановның әтисе Котдус бит. Шуннан соң мин, Кара диңгез флоты Политуправлениесенә хат язып, Асафны эзләдем. Табып бирделәр. Хат яздым — җавап килде. «Да, арестованный по процессу бубинцев Кутдус Абдрахманов — это мой отец»,— дип язган иде герой. Аның ул озын хатын узган ел мин ИЯЛИ (ТӘТИ) архивына тапшырдым. Бераздан Р. Мостафин үзенә килгән хатларны матбугатта бастыра: М. Җәлил турындагы китабына мактау хатлары икән. Авторларның берсе имзасын «Чиңгиз» дип куйган. Хатын-кыз. Тукталә, тукталә... Р. Мостафинга язган хатында ул бабасының Әгерҗе ягыннан булуын әйтә, хат — Владивосток маржасыннан. Бубилар процессында исә Ризван Чыңгыз «эше» дә бар. Ул кеше Әгерҗедә почта-телеграф начальнигы булган һәм процесс вакытында аны «дознание»гә тартканнар. Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларга Төркиядән нинди хатлар, бандерольләр килә иде? Кемнәр белән язышалар иде?

Р. Мостафиннан әлеге маржа апаның адресын эзләтеп алам да Владивостокка хат язам. Гаҗәп! Әлеге ханым, туган-туфрагын сагынып, әнием сөйләвенчә, дип, тел белмәгәненә үкенеп, истәлекләр яза: әйе, ди, минем бабам Ризван Чыңгыз, элемтәче булган, әнием аның турында күп сөйли иде, ул ниндидер процесста гаепләнеп, судларда йөргән...

Буби процессы буенча мин совет матбугатыннан да байтак әйбер җыйдым, басылган мәкаләмдә ул чыганаклар барысы да күрсәтелгәннәр иде, күп еллар узгач, яшь галимнәр мин тапкан ул чыганакларны бик җиңел файдаланып,

аларны үз табышлары итеп теркәп, ксерокста берничә данә китап та бастырдылар, анда бер урында минем дә фамилия бар иде кебек.

Ләкин теге алтмышынчы еллар азагына кайтыйк әле. Бубилар эшенә күмелеп, мин кафедра планына диплом эше итеп бу теманы да керттердем. Максатым — Лобачевский исемендәге китапханәдә саклануы Г. Буби кульязмаларын (алар, билгеле инде, гарәп графикасында) һәр елны берәр студенттан күчертеп, шуңа сүз башы, текстологик анализ, сүзлек биреп, ахырдан бу кыйммәтле хәзинәне аерым китап итеп әзерләү иде. Г. Бубиның мәдрәсә тарихына, мәдрәсәнең туу-үсү һәм патша властьлары тарафыннан тар-мар ителүе тарихына кагылышлы беренче дәфтәрен без эшләп чыктык. Гарәп графикасындагы кульязмаларның текстын укуда минем көчем мактанырлык түгел. Шуңа күрә мин бу эшкә мәрхүм Мостафа Ногманнан фарсы дәресләре алган Ф. Казнина дигән студентканы сайладым (ахырдан ул шул ук китапханәдә Альберт Фәтхи янында эшләде). Дипломница бу эшне намус белән башкарып чыкты. Г. Бубиның беренче дәфтәре тулысынча безнең графикага күчерелгән, сүзлек төзелгән иде. Диплом яклау процессын тыңлап утырам. Бәлки үзем үк Дәүләт имтихан комиссиясе (ГЭК) әгъзасы булганмындыр әле. Саллы гына эш ГЭК әгъзаларының алдында ята иде. Һәр комиссия утырышында өчтән алып җидегә кадәр эш карала. Безнең эш тә тыңланды. Әйбәт узды, сорау бирүчеләр бәйләнмәделәр, диярлек. Ләкин диплом эшенә бәя куярга тотынгач ГЭК әгъзалары аптырап калдылар. Эш саллы һәм кирәкле, практик яктан әһәмиятле иде. Ә мондый эшне университетның татар бүлегендә беркайчан да яратмадылар. Яз син анда «апчхи, һаптүчи» дигән ымлыкларның килеп чыгышы турында, эзлә син анда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан социалистик реализм элементларын, әгәр диплом эшенең фәнни җитәкчесе кафедра мөдире яки теләсә-кемнең бугазына ябышырга сәләтле берәр доцент-профессор икән, ул диплом эшенә бары тик «биш»ле генә куялар. Әгәр инде кафедра мөдиренең берсе җитәкләгән бер эшкә «бишле» куелган икән, икенче кафедра мөдиренекенә дә, һичшиксез, «бишле» куела. Гомумән, кафедра мөдирләре җитәкләгән эшкә «бишле» куелмаган очракны мин хәтерләмим. Бичара студентлар! Белсә иде алар ябык ишекләр артында билгене аларның фәнни эшенә түгел, ә җитәкчеләренә куеп утырганны! Университетта утыз ел укытып мин бер генә тапкыр да, бер генә студентыма да югары билге сорап көрәш мәйданына чыкмадым. ГЭКтагы иптәшләрнең хөкемен гел тыңлап кына утыра идем — студентларым мине гафу итсеннәр. Утыз елга, ихтимал, бер йөз диплом эшенә җитәкчелек иткәнмендер, «бишле» куелган өчме-дүртме эшне генә хәтерлим.

Әлеге «Буби мәдрәсәсе тарихы» дигән эшкә дә тартып-сузып «дүртле» куйдылар. Оппоненты мәрхүм А. Фәтхи «бишле» тәкъдим итүгә карамастан.

Инде мин язган мәкаләгә әйләнеп кайтыйк. Мәкаләне яздым, «Казан утлары» журналына илтеп бирдем. Журналда ул елларда яңалыкны яратучы Рафаэль Мостафин редактор иде һәм аның тәнкыйть бүлегендә Фәрваз Миннуллин тәкъдиме белән кыю-кыю мәкаләләр басыла иде. Берсен хәтерлим, хәтерлим генә түгел, архивымда саклыйм, ул — Альберт Фәтхинең «Мәгърифәт төбәкләре...» дигән искиткеч сенсацион мәкаләсе иде. Бу мәкаләсе өчен аңа, һичшиксез, тарих яки филология фәннәре кандидаты дигән дәрәҗә бирелергә тиеш иде, ләкин... «бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү»? Бу мәкалә без ул елларда яклаган бер дистә кандидатлык диссертациясенә тиң иде юкса.

Шулай, шул атмосферада «Буби мәдрәсәсе» дә басылып чыгар сыман иде. Ләкин ул заманда «главлит» дигән кара цензура бар һәм ул, белүемчә, Обком бюросы әгъзасы буларак, С. Батыев «ведомствосы»на карый иде. Шуның өстенә С. Батыев Мәскәү тарафыннан куелган курчак президент та иде. (Татарстанда андый хезмәт урыны юк, С. Батыев Татарстан АССР Югары Советы Президиумы рәисе иде, ләкин Батыев трибунадан сөйләгәндә «миңа фәлән илдән хат килде, господин президент, фәлән сорауга җавап бирә алмассызмы, дип язалар»... — дип телгә алырга бик ярата иде). Главлитның иң тугрылыклы кешесе — татар халкының милли хисен бастырыклап торучы Д. Шакирҗанова булды. Мәкаләм, әлбәттә, аның кулына килеп кергән һәм ул аны тикшереп, карар чыгару өчен фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге институтына җибәргән. Баштарак ул аны әллә кемнәр-әллә кемнәргә укыта, рецензия яздырта. Ул рецензияләрнең авторсызлары да булды кебек. Мәкаләмнең кырыйларында күп кешенең искәрмәләре бар. Бу искәрмәләрнең авторларын почерклары буенча мин хәзер чамалыйм. Искәрмәләр төп ике төркемгә берләшә: а) «Бубилар хәрәкәте» дигән төшенчә дөрес түгел. «Хәрәкәт» бары тик революцион гына, пролетариатча гына була ала; б) Бубиларның эшчәнлеге сыйнфый характерда булмаган: монда пантюркизм, панисламизм идеяләре көчле булган һ. б. һ. б.

Миндә Х. Хәсәнов белән С. Алишев рецензияләре генә сакланган. С. Алише-

вныкы зыянсыз. Х. Хәсәновнекен исә укучылар хөкеменә тапшырам. (Мәкаләдән соң китерелә. Ред.)

Мәкаләне институтта укуны Ф. Миннуллин оештырды. Институтның тарих секциясе утырышында философлар да катнашты. Тикшерү озак барды, бәхәсле булды. Мәкаләне басарга дип бирәү дә тәкъдим кертмәде. Барысы да койрык болгадылар. Ахырдан йомгаклау сүзен сектор мөдире Җәмил Гыйльманов алды. Ул, бөтен галимнәргә рәнҗеп, минем мәкаләмне яклап, озак сөйләде. Чыраенда үзенең коллегаларына бик нык үпкә сизелә иде. «Мондый мәкаләне дә басмасак, без кая барабыз инде» — дип сүзен тәмамлады ул. Һәм мәкаләне матбугатта бастырырга, дигән карар чыгаруга ирештe. Куркынып кына риза булдылар.

Ф. Миннуллин: «Болай булгач хут ачылды»,— дип шатланып, эшенә йөгерде.

Мәкалә 1969 елның ахырында «Казан утлары» журналында басылып чыкты. Тынлык. Миңа беркем бернинди фикер әйтми. Шулай бер-ике ай уза. Ни мактаган, ни сүккән кеше юк. Мин курка башладым. Чөнки 1968 елның кышындамы икән, әлеге институтта Татарстан культура-әдәбияты турында бер фәнни конференция булып, анда пантюркизм мәсьәләләре күтәрелгән һәм Бубиларны шул шаукымда исәпләү сүзләре сөйләнгән иде. Бу конференциядә бик нык караггруһчыл докладлар белән К. Фасеев, Х. Хәсәновләр чыктылар. К. Фасеев белән мин (яшь әтәч, ахырын уйламыйча) бәрелешеп тә алган идем.

Һөҗүм озак көттермәде. Ул заманнарда Обком язучыларны, сәнгать кешеләрен аена бер мәртәбә семинарга җыеп, язучыларны — ничек, нәрсә язарга, артистны ничек җырларга, уйнарга, рәссамны ничек рәсем ясарга өйрәтә иде. Шундый семинарларның берсендә, 1970 елның февраль ае булса кирәк, С. Батыев та доклад сөйләгән. Мин төш вакытында Бауман урамы буйлап Кремльгә таба бара идем, күрәм, каршыма тротуар тутырып танышлар килә: язучылар, композиторлар, журналистлар, артистлар... Кайберләре белән кул биреп үк күрешәм, ләкин сизәм: миңа хәтәр елмаеп карыйлар... Бәла-казага минем күңел аеручан сизгер. Нидер булган, нидер булган...

Шунда «Совет мәктәбе» журналы хезмәткәре Вакыйф Зыятдинов минем белән күрешкәндә бөтен мәһабәт буена, битенә елмаеп, хәтта шатлангандай болай диде:

— Ну, малай, Батыев кирәгеңне бирде! Ну, яндың да инде...

Мин Бауман урамындагы бер диварга сөялдем дә калдым.

Күпме кеше узгандыр яныннан, ул вакытта бөтен газета-журнал идарәләре Баумандагы Матбугат йортында иде, танышларым миңа карап уздылар. Батыев теленә кара төс белән керү турыдан-туры КГБ күзәтүенә алыну дигән сүз иде, мин моны яхшы аңлый идем.

Тораташ хәлемнән «Чаян» редакторы Альберт Яхин уятты.

— Керик әле миңа,— диде. Баскычтан менгәндә үк: — Берни дә юк, тыныч бул,— диде.— Куркыныч юк.

Һәм ул бүлмәсенә кереп чишенгәч, трубкасын тимерчыбык белән озаклап чистартып, тәмәке кабызды. Аннан өзек-төтек җөмләләр белән кыйссаны сөйләп бирде.

— Болай... Значит, болай. Батыев әйтте. Болай диде. Батыев әйтә: мин ди, «Казан утлары»нда «Буби мәдрәсәсе» дигән мәкаләне укыдым. Яшь галим язган. Шәп мәкалә. Кызыклы. Авторы да яшь, талантлы. Ләкин бер хата киткән. Мәһдиев анда Буби мәдрәсәсен тәмамлаучылар арасында Юныс Вәлидов (җир эшләре наркомы — М. М.) исемен телгә ала. Юныс Вәлидов бит — солтангалиевче. (Ю. Вәлидовка реабилитация турындагы материал «Соц. Татарстан» газетасында 1991 елда басылды.)

Альберт шуннан бүтән берни дә әйтмәде.

— Сине өркетүчеләр табылыр, син тыныч бул,— диде.

А. Яхин миңа иң авыр чакларымда күп тапкыр ярдәм кулын сузды. Кешегә ярдәм итү — аның төп сыйфаты иде, мин аңа рәхмәтле.

Бу мәкаләне уздырган өчен, күрәсең, Батыевтан главлит мөдире Д. Шакирҗановага эләккәндер, әлеге чиновница миңа гомергә дошман булды, һәм хәлиткеч яманлыгын ясап үлде: минем докторлык диссертациясе булырга тиешле монографиямне чыгып ятканда туктатты. «Буби мәдрәсәсе» басылып чыкканнан соң, һәм бигрәк тә Батыев «замечаниесеннән» соң, минем өстә кара болытлар куерды. Миңа бөтен редакцияләрдә сак карый башладылар. «Социалистик Татарстан» да Флорид Әгъзамов бүлеге аша (М. Әмир, К. Гыйззәтев мәкаләләрендә) миңа суктырып узулар булды. Акрынлап мин, пантюркизмны аклаучы булачак, рәсми фикергә кердем. Журналда чыгып яткан повестемны («Кеше китә — җыры кала») туктаттылар, минем мәкалә аркасында (Гали Рәхим турында)

Д. Шакирҗанова кафедра җыентыгын, чыгып ятканда, сүттереп таратты һ. б. һ. б.

Ләкин Бубилар турындагы мәкалә яши иде инде. Аны күпләп-күпләп Урта Азиягә соратып алдылар. Бераздан ул чит илләрдә дә укыла. Төркия матбугатында, татар тарихына кагылышлы Европа китапларында да күренә аңа ишарәләр. Ул безнең тарихчыларның да (хәтта, минем карьерама аяк чалучыларның хезмәтләрендә дә) гел уңай яктан телгә алына. Алмый хәлең юк, чөнки ул мәкаләдә — шул чорның вакытлы матбугат материаллары белән жандармерия архивы материалларының синтезы. Аларны җыяр, туплар өчен гомер, энергия, үҗәтлек кирәк. Ул елларда боларның барысы да миндә җитәрлек иде...

Бубилар тарихы — якты тарих. Ләкин фаталь рәвештә каһәрле тарих. Әллә ниткән кабатланулар бар анда. Бубиларны үзләренең иң якыннары — үз мөгаллимнәре сата. Болар — Фаиз Даутов (Оренбургтан килгән), Мирсәет Юнысов (Уфа губернасы Бирский өязеннән). Безне дә бит иң якыннар сатып яшәде.

Бубилар «эшендә» төп гаепләрнең берсе булып мәдрәсәнең класс бүлмәсендә патша портретының (кәгазь) ертылуы тора. Малайлар укыган класста рогатка булмый каламы инде? «Буби мәдрәсәсе» дигән мәкалә авторы өчен бик таныш хәл бу. 1955—60 елларда мин Арча районы Казанбаш урта мәктәбендә эшләгән идем. Бу мәктәп донос-анонимкалар чыганагы буларак бөтен республикага дан алып, монда атнаның башында, шимбәнең... дә, берәр комиссия эшләми калмый иде. Белүемчә, бу мәктәпкә шикаять тикшерергә БМОдан Даг Хаммаршельд кенә килми калды. Анонимкаларны язучы бер хатын-кыз, ә аны кыздырып торучы ярты коллектив бар иде. Менә бер көнне чираттагы шикаятьне тикшерергә КГБдан майор Әхмәтшин килеп төште. Жалоба минем өстән иде. Озак та үтмичә, шул ук оешмадан капитан Кужахметов килде. Гаеп миндә: мин җитәкләгән классның стенасына ябыштырылган Ленинның кәгазь портреты мүк турысыннан (ике бүрәнә уртасындагы уентыкта) тишелгән иде. Күрәсең, рогаткадан. КГБ офицеры капитан Кужахметов бөтен коллектив белән җыелыш уздырды: КПССның XX съезды шәхес культын фаш итмәгән булса, мин беткән идем. Үзем партиясез, әтием, «халык дошманы» буларак, 1938 елда атылган һ. б. Әмма КГБда сирәк кенә юньле кешеләр очрый икән. Җыелышка йомгак ясап, капитан Кужахметов әйтте:

— Это дело не стоит выеденного яйца...

Ул хәзер отставкада, Түбән Камада яши, мин аңа гомергә рәхмәтле.

Бубилар эшендәге патша портреты мәсьәләсен ул вакытта мин әле белми идем. Нииндидер фатальлек...

Һәм тагын. Бубилар тарихын язу — каһәрле хезмәт. Сиксәненче еллар ахырында Иж-Буби мәктәбеннән музей директоры һ. б. иптәшләр миңа телефоннан һәм хат аша мөрәҗәгать итәләр: мәдрәсә тарихы кирәк, аны сез эшләгәнсез икән. Әйе, эшләдек, мин түгел, ә студентка Ф. Казнина. Анда бу текст бар, тик инде базар мөнәсәбәтле заман, сатып алсагыз иде. Ф. Казнинага хат язам, ул текстын алып минем киңәш буенча А. Фәтхи янына килергә җыена, текстны бергәләп тикшереп чыкмакчылар. Ул арада аның янына Иж-Бубидан вәкил дә килә, хакын да сөйләшәләр. Ләкин башка иптәшләр моңа юл куймыйлар һәм текстны, бәлки тагы да шәбрәк итептер инде, шул ук текстны, кабат күчерәләр. Күрәсең, шулай файдалырак. Мин монда Иж-Буби тарихындагы фаталь ямьсезлекне кабат сиздем.

Алай гынамы? 1991 елның 20 июнендә Иж-Бубида бу мәшһүр мәгърифәт учагының юбилеен уздырып ятабыз, трибунадагы һәрбер кеше «бу тарихны мин ачтым» дигән сымаграк сөйли, без Альта Мәхмүтова белән (ул, Иж-Бубидагы хатын-кызлар мәдрәсәсе тарихын язып, бик күп шлагбаумнарны узган иде) президиумда бер-беребезгә карашып алабыз, сугыштан соң геройлар бит күп була, монда да геройлар күп! Шул вакытта безгә хәбәр килә: Казанда Җәмил Гыйльманов үлгән! «Буби мәдрәсәсе» дигән мәкаләнең язмышын уңай хәл итүгә җаны-тәне белән кәрәшкән асыл зат дөньядан киткән! Юбилей кинендә...

Килер бер көн, Әгерҗедә һәм Иж-Бубида Габдулла, Гобәйдулла, Мөхлисә Бубиларга мәрмәрдән һәйкәл куярлар әле! Ә хәзергә, хөрмәтле укучы, мәшһүр галим Хөсәен Хәсәновнең минем теге мәкаләгә язган рецензиясен укыгыз әле. Татар кешесе — эшчеме, игенчеме, зыялымы ул — үз хезмәт хакыннан «подоходный налог» түләп, менә андый галимнәрне дә асрады, тамакларын туйдырды. Рецензиягә мин бәя бирмим. Тукай әйткәнчә, «ходай гадел, ходай хаким...»

*Сентябрь, 1992.*

# М. Мәһдиевнең «Тарихның бер тармагы»

## дигән мәкаләсенә рецензия

М. Мәһдиев иптәш тикшерү өчен сайлаган тема, һичшиксез, игътибарга лаеклы. Фәнни эшчеләр арасында бу турыда фикер йөртүчеләр бар, ләкин ул темага язылган хезмәтләр әлегә күренми. Тема гаять катлаулы, шунлыктан ул тирәнтен эзләнүләрне, тарихи документларны җентекләп тикшерүне таләп итә.

Бу мәкалә исә бер яклы язылган. Автор Буби мәдрәсәсен һәм аның җитәкчеләренең эшчәнлеген бары тик уңай планда гына яктырткан. Буби мәдрәсәсе — типик җәдит мәдрәсәсе. Шулай булгач, аны җәдитчелек хәрәкәтеннән һич тә аерырга ярамый. Дөресрәге, Буби мәдрәсәсенең тарихта тоткан урынын күрсәтү өчен барыннан да элек җәдитчелекнең социаль нигезен билгеләргә, аның нинди сыйныф максатларына хезмәт иткәнлеген ачыклап китәргә кирәк. Шунсыз Буби мәдрәсәсенең һәм аның җитәкчеләренең идея юнәлешен дөрес аңлап булмаячак.

Җәдитчелек хәрәкәте — либераль-буржуаз хәрәкәт. Ул татарлар арасында капиталистик мөнәсәбәтләр урнашу чорында килеп туган. Билгеле, иске тәртипләр, иске кануннар бу чорга, бу формациянең башында баручы сыйныф теләгенә җавап бирә алмаганнар. Катлаулы техника белән җиһазландырылган завод-фабрика хуҗаларына дини фанатиклар түгел, бәлки дөньяның нәрсә икәнен аңлаучы, фән һәм техника өлкәсендә азмы-күпме белемле кешеләр кирәк булган. Бу заман уку-укыту өлкәсендә генә түгел, бәлки көнкүрештә дә Европа культурасына иярүне таләп иткән, яңа сыйныф ихтыяҗларына туры китереп дини реформа ясау бурычын куйган. Ләкин боларның барысын эшләү өчен искелеккә, ягъни кадимчелеккә каршы кискен көрәш алып барырга туры килгән. Җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында ул көрәш Октябрь революциясенә кадәр диярлек дәвам итә. Урта гасыр идеологиясе булган кадимчелеккә каршы көрәштә җәдитчелек, һичшиксез, уңай роль уйный. Моны раслау өчен мәктәп-мәдрәсәләрне мисалга китерү дә җитә. Кадим мәктәп-мәдрәсәләре укучыларның миен дин белән агулау юлында хезмәт итсәләр, җәдит мәктәп-мәдрәсәләре укый-яза белүче, теге яки бу күләмдә фәнни белемнәрне үзләштерүче кешеләр хәзерләгәннәр. Ләкин моңа кадәр алар тулысынча дөньяви уку йортлары булып китә алмаганнар. Хезмәт ияләрен изүдә динне корал иткән буржуазия җәдит мәктәп-мәдрәсәләрендә дин укытуны саклаган, дәвам иттергән. Шулай булгач, Буби мәдрәсәсен демократик позицияләрдә торучы «мәгърифәт учагы» дип бәяләү фәнни яктан һич тә нигезле түгел. Билгеле бер тарихи шартларда барлыкка килгән татар буржуазиясе беркайчан да революцион роль уйнамаган. Шушы сыйныф идеологиясе буларак формалашкан җәдитчелекне мәгърифәтчелек белән дә, демократчылык белән дә бутарга ярамый. Бу хәрәкәтнең җитәкчеләрен жандармериянең эзәрлекләве фактыннан чыгып, «патшаның кара реакциясенә каршы көрәштә Г. Буби һәм аның мәдрәсәсе алгы сызыкта торуы һәм самодержавие бинасының стеналарын какшатуда үзенә күрә бер көч булуы» дип белдерү — бу инде, аз дигәндә, фәнни чаманы югалту дигән сүз. Шуны да истә тотарга кирәк, патша хөкүмәте Йосыф Акчура, Рәшит Ибраһимов, Гаяз Исхаков кебек милләтчеләрне, хәтта клерикал Галимҗан Барудины да төрмәгә яптырган.

Типик җәдит мәдрәсәсе булган Буби мәдрәсәсенең сыйнфый максатларын ачык күрә алмаганлыктан, автор аның тарихи урынын билгеләгәндә шактый җитди хаталар ясый. Хәзер шулардан кайберләрен күрсәтеп үтик.

1. М. Мәһдиев «үзләрен турыдан-туры «Татар-яшь социал-демократлар комитеты» дип атаучы шәкерт оешмалары да булды» дип расный. Әмма шул чорны өйрәнүче тарихчылар өчен мондый оешма барлыгы билгеле түгел, ә автор исә ул турыда нинди дә булса документаль материаллар барлыгын күрсәтми. Аннары шуны да онытырга ярамый, Казанда социал-демократик оешма милли оешма формасында түгел, бәлки гомуми оешма төсендә барлыкка килә. Алдынгы рус, еврей, татар һәм бүтән милләт эшчеләре шушы гомуми оешмада член булып торганнар.

2. «Кадимчелеккә, патша реакциясенә каршы көрәштә зур роль уйнаган белем учакларының иң күренеклесе Буби мәдрәсәсе иде» дигән фикер белән тулысынча килешеп булмый. Бердән, Буби мәдрәсәсе патша реакциясенә, ягъни самодержавие хөкүмәтенә каршы ачыктан-ачык көрәшмәгән. Безнең кулыбызда андый материаллар юк. Әгәр бу карашны яклау өчен автор мәдрәсәдәге тентүләрне, кулга алуларны, ниһаять, суд процессын мисалга китерә икән, бу аңа нигез, аргумент булып хезмәт итә алмый. Чөнки ул эзәрлекләү патша Росси-

ясенең шул вакыттагы политикасы белән, Балкан сугышы башлангач, пантюркизм, панисламизмга каршы көрәшне тагын да көчәйтүе белән бәйләнгән. Икенчедән, кадимчелеккә каршы көрәш байрагын беренче булып Буби шәкертләре түгел, бәлки шул заманның алдынгы мәдрәсәләреннән саналган «Мөхәммәдия» (Казан), «Хөсәения» (Оренбург), «Галия» (Уфа) шәкертләре күтәргән (биредә аларның беренче рус революциясе чорындагы чыгышлары күздә тотыла).

3. М. Мәһдиев, Бубилар хәрәкәте ике фронтка: татар кадимчеләренә һәм самодержавие хөкүмәтенең милли-колониаль политикасына каршы көрәш фронтларына аерылды, дигән буталчык фикерне әйтә. Дөрес, шәкертләр хәрәкәтендә төрле агымнар, мәсәлән, уң агым (мөселман иттифакы тарафдарлары), үтә сул агым (эсерчылык) һәм урта-сул агым («Ислахчылар») була. Әмма кадимчелек белән царизмның милли-колониаль политикасына каршы көрәшне бер-берсеннән аеру фәнни дөрес була алмас. Шәкертләр, шул җөмләдән Буби мәдрәсәсе укучылары да, ул замандагы политик көрәшкә турыдан-туры катнашмаганнар, чөнки аларның аңы ул дәрәҗәгә үсеп җитмәгән. Ләкин алар татар хезмәт ияләрен караңгылыктан, каты изү астында тоту өчен патшага уңайлы корал булып хезмәт иткән кадимчелеккә каршы актив көрәшкәннәр. Аңлашыла ки, кадимчелеккә каршы көрәш — ул фактта царизмның милли-колониаль политикасына каршы көрәш дигән сүз. Минәни өчен кадимчелеккә каршы көрәшне милли азатлык көрәшеннән аерырга ярамый.

4. Безнең карашыбызча, Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар мәгърифәтче дә, демократ та түгелләр, бәлки либераль буржуазия вәкилләре. Нинди теләктән чыгыптыр, М. Мәһдиев аларны татар халкының күренекле культура эшлеклеләре итеп күрсәтергә тырыша. «Бубилар күтәргән азатлык, белемлелек өчен көрәш,— ди ул,— пролетариат революциясенә килеп тоташты һәм әгәр дә татар җәмәгатьчелеге октябрь революциясе көннәрендә кулына корал алып алпавытларга, буржуаларга каршы көрәшкә килгән икән, бу зур ташкынны әзерләүдә Бубидагы белем һәм фикер учагының өлеше дә бар иде (32—33 битләр). Аннары автор, бер кешенең (В. Мансуровның) фикеренә таянып, шактый олы нәтиҗә ясый. «Г. Бубиларның татар халкын агартудагы прогрессив эшчәнлегенә совет-партия матбугаты,— дип яза ул,— заманында югары бәя бирде». Ләкин авторның бу фикере нинди дә булса фактик материалга нигезләнмәгән. Әйткәнебезчә, Бубилар либераль буржуазия вәкилләре, җәдитчелек хәрәкәтенең идеологлары. Алар Солтан Төркиясендә укыганнар һәм шул ил белән тыгыз бәйләнеш тотканнар. Әгәр дә патша жандармериясе аларны панисламизм, пантюркизмда гаепләгән икән, бу бер дә гаҗәп түгел. Безнеңчә, Бубилар җәдитче татар либераль буржуазиясенең политик программасыннан еракка китмәгәннәр. Үзенә-үзе каршы килеп булса да, автор урыны-урыны белән моны танырга мәҗбүр. Гобәйдулла Буби, ди ул, фән белән динне килештерергә тырыша... Бу инде дини реформаторлык, ләкин шуннан да артык түгел» (5 бит). Бераз түбәнрәк М. Мәһдиев болай дип яза: «Г. Бубиның күп хатынлыкны яклавы да аның чын буржуа вәкиле булуын күрсәтә». Әгәр дә боларга Бубиларның уку-укыту өлкәсендәге реформаторлыкларын да китереп өстәсәк, җәдитче татар буржуазиясенең тулы бер программасы күз алдына килеп баса.

5. М. Мәһдиевнең дин мәдрәсәсе астына яшерелгән бу мәдрәсә асылда дөньяви мәктәп-гимназия булырга омтыла» (8 бит) дигән фикере белән дә килешеп булмый. Җәдитчеләр диннән баш тартмаганнар, киресенчә, аны буржуа сыйныфы өчен файдалы корал итеп саннаганнар һәм шул сыйныф ихтыяҗларына туры китереп үзгәртү юлында эшләгәннәр. Яңа методлы мәктәп-мәдрәсәләрдә диндә шактый зур урын бирелү очраклы хәл түгел. Бары тик Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов кебек мәгърифәтчеләр, ә алардан соң Г. Камал, Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан кебек демократлар гына чын мәгънәсендәге дөньяви, фәнни мәктәп-мәдрәсәләр булдыруны кайгыртканнар.

6. Бубиларның «алдынгы» дөньяви мөдәррис булуларын Ф. Кәрими, Р. Фәхретдинов һ. б. фикеренә таянып расларга маташу ышандырырлык дәлил түгел. Буржуаз милләтчеләр, Мөселман иттифакы партиясен төзүдә актив катнашучылар булганлыктан, алар үз максатлары өчен көрәшкән кешеләрне яклаганнар.

7. Җәдитче буржуа вәкиле Риза Фәхретдиновны алдынгы фикер иясе итеп күрсәтү шулай ук фәнни яктан нигезле түгел. Ни өчен авторга түбәндәге бәяне бирергә кирәк булган: «күренекле тарихчының (аның беркайчан да күренекле тарихчы булганы юк) ике ат йөге кульязма материаллары тентү вакытында алып китеп юкка чыгарыла. Хәлбуки, болар Россия татарларының тарихы, мәгърифәт һәм галимнәр тарихы, Р. Фәхретдинов тарафыннан күп еллар тырышлык белән җыелган документлар иде» (15 бит). Буржуаз милләтчегә шундый югары бәя бирүнең сәбәбе безгә ачык аңлашылып җитми.

Өлкән гыйльми сотрудник **Х. Хәсәнов.**

*3 январь, 1968 ел.*

Дискуссия дәвам итә:

*БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ.*

**Гурий Тавлин**

# ИМАН ЯҢАРТКАНДА

Октябрь инкыйлабыннан башланып, җиде дистә елдан артыгракка сузылган тоталитар режим чорында, карга йөрүен өйрәнә-өйрәнә үз йөрүен оныткан саескан күк, без дә татарны татар иткән үзебезгә генә хас сыйфатларыбызны онытып, тәмам урыслаштык. Бу — телебезгә, мәдәниятебезгә, иманыбызга, милли традицияләребезгә — буыннардан-буыннарга сакланып килгән гадәт-йолаларыбызга, әхлак нормаларына кул селтәүгә, аларны үгисетүгә китерде. Эш шуңа барып җитте ки: татарлар үз балаларына уйлап-нитеп тормыйча Альфред, Фердинанд, Феликс, Мэлс, Рево, Ким, Ленар, Иоланта, Луиза, Аида, Эльбурс, Казбек, хәтта Трактор, Комбайн, Динамо, Руслан, Рим, Люция һәм башка бик күпятышсыз исемнәр куштылар. Мәрьям — Марго, Фәрид — Зигфрид, Нургали — Нэрик, Сәлим — Серый, Фатима — Феня һәм башкалар булып китте. Халкыбыз милли йөзен көннән-көн югалта барды. Өлкән «туганыбыз» нәрсә әйтсә, без шуңа шатланып ләббәйкә тордык. Тарихыбыз бозып күрсәтелде, бабаларыбызга, гомумән, милләтебезгә яла ягылды, мәскәүле «абзыйларыбыз» кубызына биеп, әйтергә оят, хәтта әдәбиятыбыз җәүһәре, милләтебезнең горурлыгы булган тиңдәшсез «Идегәй» дастаныннан да: «Ул — канкояр ханнарга мәдхия җырлаучы, безгә ят, зарарлы әсәр»,— дип җиңел генә баш тарттык. Татарлыгыбызны яклаган күпме кешегә мәсхәрәле милләтче мөһере сугылды, милләтчелектә гаепләнеп күпме кешенең гомере киселде, күпме туганнарыбыз Сталин лагерьларында җәфа чикте. Хәзер бу турыда уйлаганда тамакта тозлы төер оешып сулыш кабына, күз аллары караңгылана.

Без гаҗәеп заманда яшибез. Алда телгә алынган башбаштаклыкларның күбесенә инде чик куелды дияргә була. 1990 елның 30 августында республикабыз бәйсезлеккә иреште — Татарстан суверен дәүләт дип игълан ителде, телебез дә, кәгазьдә урыс теле белән тигезләнеп, дәүләт теле статусын алды. Шулай итеп, урыслар монополиясенә акрынлап авызлык киертелә. Ана телебездә униаган яңа газеталар, байтак кына яңа журналлар чыга башлады. Аларда тарихыбызга, гореф-гадәтләребезгә, телебезгә, ата-бабаларыбызга, дингә, гасырлар дәвамында кыерсытылган, кимсетелгән милләтебезгә багышланган язмалар, мәкаләләр, шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, повестьлар, романнар бер-бер артлы дөнья күрде. Милли аңыбызның уянып тернәкләнә баруы Җир шарының барлык почмакларына сибелеп яшәүче күпмиллионлы халкыбызны куандыра. Бу былтыр Казанда үткәрелгән Бөтентатар конгрессында да бик ачык күренде.

Әйе, милләтебез үзенә киертелгән авыр богаулардан акрынлап арына бара. Әмма милли бәйсезлегебезгә каршы көчләр үз позицияләрен җиңел генә бирергә җыенмыйлар әле. Безгә, иң әүвәл, каныбызга сеңдерелгән коллык чиреннән арынырга, үзебез теләгәнчә яшәргә омтылырга кирәк. Милләтпәрвар җанлы һәр татар моңа күпмедер күләмдә үз өлешен кертә башлады инде.

Шул уңайдан Фоат Садриевның «Казан утлары» журналының 10 һәм 11 саннарында басылган «Таң җиле» романына бераз тукталасым килә. Ул —

тырыш һәм карусыз авыл эшчәннәре турында ихластан, кемнәргәдер ярарга тырышып түгел, йөрәк кушканча һәм милли рухта язылган әсәр. Андагы образларның һәркайсы тормыштагыча үзенә генә хас сыйфатларга ия. Алар берберләреннән, соңгы елларда дөнья күргән кайбер күләмле әсәрләрнең геройлары кебек, тик исем-фамилияләре белән генә түгел, холык-фигыльләре, уй-фикерләре, хис-тойгылары, дөньяга карашлары, омтылышлары, тышкы кыяфәтләре белән дә аерылалар. Әсәр җиңел, йөгерек тел белән язылган, ул башыннан ук укучыны мавыктырып, үз эченә алып кереп китә һәм ахырынача кызыксынып укыла.

«Таң җиле» авыр фаҗигадән — һич көтмәгәндә кеше тормышы киселүдән башланып китә. Колхоз рәисе йөк машинасында эшләүче шофер Гарифҗанны, салмыш икәнен белә торып, үз шәхси ихтыяҗлары өчен бүрәнәләр китерергә урманга җибәрә. Гарифҗанның эчкәнлеген әнисе Хәдичә дә, урманга машинага бүрәнәләр төяшергә барасы ирләр дә күреп торалар...

Гарифҗан машинасын, җан-фәрман куып, текә таудан төшкәндә капландыра һәм колхозның иң тырыш, иң ярдәмчел кешенең — ике бала атасы, шат күңелле Рәмзинең башына җитә. Үзе дә имгәнеп, авыр хәлдә, шифаханәгә эләгә... Әйе, безнең бүгенге тормышыбыз әнә шундыйрак.

Ә бит элек эчү безнең бабаларыбыз өчен бернинди кирталәргә дә сыймый торган бозыклык исәпләнгән! Аракы, шайтан суы саналып, татар халкының көндәлек тормышында кулланылыш тапмаган, аны эчкән кеше милләттәшләребез өчен хәрам мал дуңгыз белән бер итеп каралган. Исерткеч эчемлекләрдән араланган аек тормыш исә бабаларыбызның рухи керсезлеген, намус критерийларын билгеләгән. Хәзер исә эчү, тарту, сүгенүләргә табигый хәл дип карыйбыз. Тартуны, уйнашчылыкны, фәхешне, эчеп теләсә кайда аунап ятуны хурлыкка да, оятка да санамыйбыз. Ирләребезнең генә түгел, хәтта хатын-кызларыбызның да исерткеч эчемлекләрдән йөз чөермәүләре, аннан ләззәт табарга тырышулары, күзләрен алаландырып тәмәке пыскытулары берәүне дә гаҗәпләндерми. «Төшерүне» гадәтләренә әверелдергән, аракыдан тәм, юаныч эзләгән күпме ата-аналарның гарип, акылга зәгыйфь балалар тудырулары беребезгә дә сер түгел. Үзен хөрмәт итмәгән, сәламәтлегенә төкереп караган бәндәнең башкаларга хөрмәт белән карауын да көтеп булмый. Кайберәүләр моны, бу — динне санга сукмау, аны көндәлек тормышыбыздан чыгарып ташлау нәтиҗәсе, диләр. Аларның хаклылыгы, әлбәттә, бәхәссез. Дингә ышанган, намаз укыган кеше алладан эшләгән гөнаһларын ярлыкауны сораудан бигрәк, үз-үзенә эшләгән эшләре өчен хисап бирә бит. Ә җаваплылык хисеннән мәхрүм кешенең кеше түгел, тонык шәүлә генә икәне кемгә дә аңлашыладыр.

Бу сөйләшүнең үзәгенә куелган «Таң җиле» романы эчүчелек турында түгел, әлбәттә. Бүгенге тормышта бәхетсезлеккә китергән бер деталь генә булып килеп кергән ул аңа. Андагы төп тема — дөреслек белән ялган көрәше. Әсәрдә фаҗига, табигый буларак, эзсез генә үтеп китми. Аны китереп чыгарган сәбәпләрне тикшерергә авыл советына прокуратурадан ап-ак чырайлы, пеләш башлы, калын кысалы күзлек кигән, ябык кына тикшерүче килә һәм шоферның исерекме, айныкмы булганын ачыкларга керешә. Әмма шунысы мөһим: ул үз алдына хакыйкатьне тантана иттерү бурычы куймый, ә колхоз рәисе Хөснуллинның җинаятен йолып калырга тырыша. Хөснуллинның басымы астында тикшерүчегә чакырылган һәр кеше: «Шофер Идрисов эчмәгән, айнык иде»,— дип, бер үк сүзне кабатлый. Колхоз рәисе районадагы үз кулындагы врачлардан «Гарифҗан айнык килеш руль артына утырган булган» дигән белешмә алган. Чөнки ул аларга даими рәвештә колхозның түшкә-түшкә итен, чиләк-чиләк балын, капчык-капчык икмәген озатып тора. Әсәрендә автор бер нәрсәне дә бармактан суырып язмаган, барысы да — тормыштагыча, барысы да чынбарлыктагыча.

Совет хакимияте тудырган түрәләр белән аларны исән-имин асраучы кара халык — бүгенге коллар арасындагы мөнәсәбәтләр дә калку итеп гәүдәләндерелгән. Менә шунын җанлы мисалы: «Хөснуллин ялгыз түгел! Халык җилкәсендә кәеф-сафа корып җинаять өстенә җинаять кылып, үз башларын гына саклап яшәүчеләр шушы идарә йортыннан алып Мәскәүгә кадәр бер-берсе белән бәйләнгәннәр. Моны күреп торса да, соңлабрак аңлады Нуриасма. Гомер буе фермада эшләп буыннары кәкрәйгән Мосаллия үз гомеренә бер мәртәбә ындыр артындагы Бәкер санаториена да бара алмады. Йә, путевка юк, диделәр, йә, урынына кеше табып булмый, диделәр. Ә житәкчеләр үзләре елның теләсә кайсы вакытында хатыннары, хәтта балалары белән бергә Кара диңгез буена санаторийга очалар. Болар халыкның күз алдында эшләнә, боларны яшерә торган түгел. Әгәр бөтенесе бер булмасалар, ничек инде алар өчен генә андый җай бар да, колхозда бил бөккән кешеләргә ул юк? Берәүләр кол хәлендә, икенче берәүләр патша

кебек. Гомере буе беркатлы булганга, нәкъ әнә шул әйберләрне сонарып аңлаганга күрә дә Нуриасманың үз-үзен битәрләве аяусыз, тегеләргә карата нәфрәте чиксез иде... Шуна күрә Хөснуллинның артын сөртергә кәгазьләр әзерләп йөрүче бу кешегә ул ачу белән карап торды. Тикшерүче әллә аның ни уйлавын чамалады, «син миңа алай ямьсез итеп карама» дип кисәткәндәй, ручкасы белән өстәлгә шак-шок сугарга керешге».

Нуриасма тикшерүчегә, башкалардан аермалы буларак, Гарифҗан эчкән иде, дип дөресен әйтә. Тикшерүче аны «игә китерергә», ялганлатырга төрлечә тырышып карый. Ләкин Нуриасма карчык нык тора, сүзеннән кайтмый.

Ялганның аяклары кыска, ул әллә кая китә алмый, ди безнең халык. Әмма, минемчә, ул бу мәкале белән ялганны тәмам азындырды шикелле. Чөнки кая карама, һәр адымда ялганга юлыгасың хәзер! Бу әсәрдә дә кешеләрнең күбесе инде шулкадәр каешланган, алар көндәлек тормышларында ялганны гадәти хәлгә исәплиләр. Гарифҗанның салмыш булуын белә торып, бернинди тартынусыз, «ул аек, эчмәгән иде», дип баралар. Хәттә ире Рәмзине югалтып, ике баласы белән тол калган Мәдинә дә, колхоз рәисе Хөснуллин аны ферма мөдире итеп куйгач, үзенең башта күрсәткәннәреннән танып, Гарифҗан исерек түгел иде, ди. Менә бусы да — безнең бүгенге тормыш! Бусы да — без үзебез!

Әсәр башлыча, авыл хатын-кызлары тормышын гәүдәләндерүгә багышланган. Аларның иң уңышлысы — Нуриасма образы. Автор аны дөреслек символы итеп күрә. «Аны фәрештә дип уйларга мөмкин иде. Кардай ак озын күлмәк, кардай ак яулыгы астыннан күренеп торган кардай ак чәчләр... Ак фәрештәдәй, ул ямь-яшел Ык буена барып басты, чыкта юешләнгән чүәкләрен бер-берләренә тери язып якын китерде...» Бу сурәтләү күз алдына искиткеч саф, илаһи образ китереп бастыра. Әмма автор яраткан героинясын һичнинди гөнаһсыз, сөттән ак, судан пакь итеп кенә гәүдәләндерми. Нуриасманың, аңа гына хас бик күп уңай сыйфатлары янәшәсендә үк, күзгә бәрелеп тормый торган житешсезлекләре җитәрлек. Аның иң сөймәгән, иң өнәмәгән нәрсәсе — шәһәр. Нуриасма, кешенең күзенә карау белән, аның күңелендә ни ятканын чамалый белә торган зат.

Әмма әсәрдәге әлеге уңай образны икенче бер персонаж белән чагыштырып карау бик кызык фикерләргә китерә. Безнең бүгенге тормышны күзаллау өчен әлеге икенче образ шулай ук мөһим. Ул образ — Хәдичә. Нуриасма белән Хәдичә бала чактан ук бер туфракта аунап үскән ахирәт дуслар. Алар гомерләре буе бергә фермада эшләгәннәр. Хәдичәнең улы Гарифҗан белән Нуриасманың төпчеге Мизхәт тә аерылмас дуслар. Алар арасында аерма тик шул гына: Гарифҗан инде өйләнгән, ике бала атасы, Мизхәт әле буйдак.

Нуриасма белән Хәдичәнең икесендә ике холык: берсе сабыр, инсафлы, икенчесе кызу канлы, дорфа. Нуриасма тикшерүче яныннан кайткач ук, аның янына ярсып Хәдичә килеп керә. Аңа инде ахирәтенең Гарифҗан файдасына сөйләмәгәнен җиткергәннәр. Ул ишектән керә-керешкә, Нуриасманың йөзенә төкергәндәй:

— Гарифҗанда ни үчең бар?! Гомер буена сиңа аш белән аткан балага ник син таш белән атасың?! — ди.

— Сиңа яхшы атлы булам дип дөреслекне яшерә алмыйм мин. Ачулансаң ачулан, үпкәләсәң үпкәлә, — дип җавап кайтара аңа Нуриасма.

Әмма Хәдичә югалып калмый, аның үз тугызы тугыз.

— Авылны кычкыртып талаганда, кычыткан ашап, сыерыңның соңгы кашык сөтен ач-ялангач балаларыңның авызыннан өзеп, налог түләү өчен сатканда, кайда иде соң ул синең дөреслегең?! Әтиеңне төнлә нахакка алып киткәндә кайда иде?! — ди ул ярсып.

— Ул чаклар күптән үтте бит..

— Үтмәде! Абзарыңнан сыерыңны җитәкләп алып чыгып киткән, бәрәңге бакчаңны кискән елларны оныттыңмыни? Колхозның акчасын капчыгы-капчыгы белән кара йөз шабашникларга биреп җибәргәнгә әле кайчан? Үзенең бөтен өере белән безнең канны эчеп симергән чабата кашлар ялгыз агачмы, урманмы? Шулмы синең дөреслегең? Ал син аңлатмаңны, кеше көлдермә.

— Ул риза түгел шул, — дип җавап кайтара бу тәкъдимгә Нуриасма елмаеп.

— Кем? — ди аңа Хәдичә күзләрендә өмет чаткылары кабызып.

— Йөрәк, — ди Нуриасма тыныч кына.

Романнан китерелгән бу өзектә кешене уйландырырлык нәрсәләр җитәрлек. Монда: дөреслек бар җирдә ялганга урын юклыгы, аларның бер-берләреннән башка яши алмаулары, дөреслекнең йөрәк, ялганның исә акыл җимеше икәнлекләре басым ясап әйтелә.

Менә шушындый үтә мөһим мәсьәләләрнең калку итеп күтәрелүе белән, бу роман безнең чор укучыларында, минемчә, кин яңгыраш табачак. Чөнки алар — бүген бик күпләрне борчыган, дулкынландырган проблемалар.

Хәдичә Нуриасма белән гомере буе килешә алмый. Моның төп сәбәбе: Нуриасманың башкалардан аерылып торырга омтылуы. Бөтен жирдә — фермада, урамда, җыелышта, мәҗлестә, һәр көн, һәр сәгать, һәр минут ул үзен күрсәтергә тырыша. Ул тырышкан саен, Хәдичәнең аңа котырып ачуы килә. Нуриасма — эш аты. Ул эшләгән эшен жиренә житкерми кала торган кеше түгел. Аның таянычы — намус. Нуриасма өчен тормышта иң мөһим нәрсә: намусыңа тап төшермәү!

— Кем өчен ертыласың, кемнәрнең табанын ялыйсың?! — дип кычкыра аңа Хәдичә бервакыт бөтен ферманы яңгыратып.— Бушка бит, бушка! Сизмисеңмени: иелгән саен, бил бөккән саен ныграк мыскыл итәләр, ныграк җәберлиләр!

— Ә нишләргә соң?! — ди аптырап Нуриасма.

— Тураеп басарга! — ди Хәдичә.— Без дә кешеләр, без дә яшәргә тиеш. Син җиде кат тиреңне тунаганда рәхмәт укып торасың, әле балаларыңныкын да тунатасың. Ә менә мин үзем туныйм! Миңа әшәкелек кылалар икән, карап торыйммы?! Ә син чиста калмакчы булып кыланасың, макталасың килә.

Менә бу урында без тагын бер гаять актуаль мәсьәләгә килеп терәләбез. Тормышның үзе өчен мөһим проблемага. Әйе, авыл халкының күбесе, фуражын да, печәнен дә, башкасын да әз генә булса да өенә алып кайтырга тырышты. Моны урлашу дип әйтергә мөмкинме икән? Юктыр. Бу бары тик бер нәрсә — исән калу өчен иде. Ә соң аларның исән калырга хаклары юк идемени?! Бар иде, хәзер дә бар! Чөнки алар үз хезмәтләре өчен тиешлесен ала алмадылар! Ә башкасы? Еллар буе ял итмичә, авыруыңа-ниеңә карамыйча, ачлы-туклы яшәү? Эшләү? Бик күпләр кебек Нуриасма да бозауларына печән бетсә, чалгы тотып үзе болынга китә. Авырса да, түшәктә ятмыйча эшләп йөри торгач, ике як үпкәсенә дә салкын тидерә. Аңа башкача ярамый — ул алдынгы! Ул Хәдичәләргә үрнәк күрсәтә...

Ләкин шунысы бар: әгәр дөнья ни кушсалар шуны башкаручы Нуриасмалардан гына торса, әгәр йонны кирегә сыпыручы һәм гаделсезлек тераүләрен астан төрлечә какшатучы Хәдичәләр булмаса, кем белә, бәлкем, авыл бүген дә таякка алданып утырыр иде әле!

«Күп кенә тырышсалар да, дөньяны Нуриасмалар үзгәртмәде»,— ди кебек автор. Аныңча, аны бармаклары үзләренә таба кәкре, эшкә эленке-салынкы караган, фермадан колхоз терлекләренә дигән азыкны, комак күк, аз-азлап өенә ташыган Хәдичәләр үзгәрткән булып чыга. Бәхәсле фикер. Бу — егерменче еллар азагында һәм утызынчы еллар башында, бөтен ил күләмендә авылларда күмәк хуҗалыклар төзү чорында, көчен һәм вакытын кызганмый көне-төне эшләп, тормышын көйләгән хәлле крәстиянне кулак-байгура ясап, хурлыклы төстә йорт-җирен, терлек-туарын, мал-мөлкәтен талап алып, үзен авылдан сөрү сәясәтенә авазлаш яңгырый. Ә бит колхозларда Нуриасмалар булмаса, без чирек гасыр элек үк инде өстебездә данлы кызыл байрак җилфердәтеп, иңнәребезгә саилче капчыгы асып, хәер эсти идек!

Чатаклы чынбарлыгыбызның кешеләрне ничек итеп гарипләндерүе Фоат Садриев романында Бәрия Кирамова образында бик ачык гәүдәләнә. Бәрия күз өстендә каш булып үсә, кечкенәдән үк гел күзгә каршында бөтерелә, үзен көннән-көн матуррак итеп күрергә тели, чәчләрен бөдрәләтә, каш-керфеген төзәттерә, концерт-мазар куйганда таш курчак төсле бизәнә, аның матурлыгын күреп кешеләрнең «аһ» итүләренә күнегә. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганда аның борынына ис кергән, авылда иң чибәр кыз икәнлеген үзе дә сизгән һәм аңлаган була.

Аны укытучылары да, авылның башка бик күп кешеләре дә: «Син сәхнә өчен яратылгансың, артистлыкка укырга кит»,— дип дәртләндерәләр. Моңа әти-әнисе дә каршы килми. Тик авылдан чыгып китәргә белешмә кирәк. Ә колхоз рәисе булып эшләүче, бер аягын сугышта калдырып кайткан чатан Закирҗан белешмә сорап килгән Бәрия белән шукланып сөйләшә, аның өчен әле очрашып озаклап гәпләшергә кирәк, караңгы төшкәч тау башындагы ындыр табагында эшем бар, шунда менәрсең, ди. Алар очрашалар һәм Бәрия шул ындыр табагында кыз чагы белән хушлаша...

Елап туктаганда ул инде икенче кеше була, балага узганын белгәч, өченче кешегә әверелә. Көз көне Бәрия көмәненнән арынып өчен Урта Азиядә яшәүче туганнарына китеп бара. Юлга чыгып, үз гомерендә беренче мәртәбә чит-ят кешеләр белән аралаша башлагач, ул аларның аны бар дип тә белмәүләрен, санга

сукмауларын күреп, тиресеннән чыгардай була. Аны этәләр, төртәләр, аңа сүгенеп кычкыралар, кимсетәләр. Моңа кадәр кешеләрнен аның һәр теләгән үтәргә күнеккән Бәрия өчен бу коточкыч хәл була. Аны бер карчык көменennән коткара, тик Бәрия мәңге балага узмый торган бер мәхлук булып кала. Үзенә баш иярга теләмәүче гаделсез дөньяның астын өскә әйләндерәсе, буйсындырасы килә Бәриянен. Һәм ул, нинидер бер эчке тоемы белән, ин көчле үч алу чарасын таба. Бу — алдау.

Бәриянен эшләгән этлекләре бик күп. Ә бит аңарда да татар каны ага! Бәлки Бәрия Фоат Садриевнын тыелгысыз фантазиясе җимеше генәдер?! Юк шул, Бәрия һәм аның ишеләр хәзер буа буарлык. Алый гынамы, сабыйларын бала тудыру йортында калдыручылар, үзләре эчеп кәеф-сафа кылып йөреп, өйләрендәге балаларын ачка интектерүчеләр, әтиләрен яки әниләрен картлар йортына тапшырып, ул йортка бүтән эз дә басмаучылар, караклык белән көн итүче чибәрләр, фәхишәләр — тагын әллә кемнәр бихисап бит! Алар барысы да татар дөньясына «яңалык» керткән мактаулы социализм җимешләре. Боларны ерак бабаларыбыз ничектер белә калсалар, мәсхәрәләнүләреннән ләхетләрендә йөзтүбән әйләнеп ятарлар иде. Кем белә, бәлки бу хатын-кызларның ирләр белән «бертигез» хокук яулаулары нәтиҗәседер?..

«Таң җиле» романындагы иң чирканыч тип — колхоз рәисе Мәҗит Хөснуллин. Ул — кешеләр турында түгел, үзе турында гына кайгыртучы җитәкче. Колхоз Хөснуллинга район үзәгендәге берәр җитәкче постка үрмәләү юлында трамплин хезмәтен генә үтәргә тиеш. Ул инде анда йорт та салып куйган булган, әмма эш өметләнгәнчә барып чыкмагач, аны саткан.

Ул — баштанаяк ясалма кеше. Менә шуның бик ачык мисалы. Урманга бүрәнәгә барганда аның аркасында һәлак булган Рәмзине җирләгәндә «хөрмәтле» Мәҗит Харисович алга чыгып, тар маңгае өстендәге җирән чәчләрен артка сыпыра да, партком секретареннан нинидер кәгазь алып укырга керешә.

— Иптәшләр! Рәхимсез үлем безнең колхозыбызның иң яхшы кадрларыннан берсе булган Рәмзи Әкмал улы Шаһиевны...

— Әкрәм улы... — ди партком секретаре аның колагына иелеп.

— Нәрсә?!

— Әкмал улы түгел, Әкрәм улы...

— Машинкада бастырырга иде, понимаешь! — дип мыгырданып алгач, Хөснуллин укуын дәвам итә: — Рәмзи Әкрәм улы Шаһиевны алып китте. Колхозның яңа төзелгән кайсы гына корылмасын карасак та, аңа Рәмзи Шаһиевның фидакарь хезмәте кергән...

Зиратка килгән кешеләр аның бер генә сүзен дә тыңламыйлар, аңламыйлар, аңларга да теләмиләр. Рәмзинең үлеменә турыдан-туры гаепле кешенең аның мәете өстендә сүз сөйләргә батырчылык итүе аларны тынсыз-өнсез итә. Ярый, ул Рәмзинең җеназасына килсен дә ди. Ләкин бит ул башын иеп, кешеләргә күтәрелеп карарга тартынып, читтә мескен булып кына торырга тиеш иде!

Ул тотлыга-тотлыга укыган сүзләрнең кабыгы гына Рәмзи рухына туры килә, ә аларның асылында бу җинаятьтән коры чыгарга теләү ята. Үзең үлеменә сәбәпче булган кешенең изге рухын, җеназа мәрәсимен аның якыннары алдында, халык каршында үзеңне аклау өчен файдалану кебек гөнаһны эшләү өчен ни дәрәҗәдә намуссыз булырга кирәк?! Сүзен тәгәлләгәч, Хөснуллин кульяулыгы белән күзләрен каплап бер адым артка чигенә, кульяулыгы белән күпме генә сөрткәләсә дә, Хөснуллинның керфексез күзләрендә яшь тамчысы түгел, дым әсәре дә булмый. Ахырда ул, зираттан акрын гына таралучы кешеләрнең өстенә тузан бөркеп, машинасында җилдереп китеп бара. Шуннан да ары кабахәтлек эшләү, белмим, мөмкинме икән? Хөснуллин ялгыз, үзе генәме? Юк, һич юк, күп авылларда дилбегә Хөснуллин ишеләр кулында, алар үзләренә каршы чыккан кешеләрне, аларга буйсынырга теләмәүчеләрне чәйнәми йотарга әзер торалар. Фоат Садриевның партократлар калдыгы Хөснуллин образын романында гәүдәләндерүе бик тә вакытлы булды.

Дөреслеккә тугры калуы Нуриасма карчыкны аяктан егып, урын өстенә менгереп яткыра. Ә көндәлдә борчулы уйлар. Ата-бабаларыбызның телен, гореф-гадәтләрен белүче, моңын-җырын аңлаучы оныкларының шушы нигездә дөнья көтәчәкләренә ышанып үләргә хакы юкмыни аның? Моңа тагын кемнән рөхсәт сорарга? Чыгып бетмәгән җаныбызны әз генә булса да калдырыгыз, үзебезчә яшәргә, ана телебездә сөйләшергә, үзебезчә җырларга-биергә рөхсәт итегезче, дип салган уртак сөрән бөтен ил буенча яңгырамыймыни? Анда бит бер татарларның гына тавышы түгел. Юк, җитте! Нәселнең соңгы тамырын корытырга ирек бирмәскә кирәк...

Дөреслек һәм ялган... «Авылны күтәрәбез, чәчәк аттырабыз»,— диделәр. Күтәрелмәде дә, чәчәк тә атмады авыл! Инде җитмеш елдан артык авылны талаганбыз, җитте, аякка бастырабыз, диләр тагын... Ялганлаган саен кызарып та карамыйча, тагын ни йөзен белән халык, ил каршына чыгарга мөмкин? Моның өчен нинди вөҗдан, нинди намус кирәк?! Ник болай? Кайчанга кадәр? Халык ничек түзә? Ник элекке ялганнарны аклап, һаман яңа ялганнар уйлап чыгарыла тора?! Ә югарыдан төшкән һәр сүз һаман да изге карала. Әз генә түзик, тиздән барысы да үзгәрәчәк, дигәнгә кемнең җаны эремәсен. Инде менә катлы-катлы ялган пәрдәләрен астан да, өстән дә умыра башлагач, бу коточкыч хәлгә гаҗәпләнергә генә калды. Ә ялган үзе, аңа төртеп күрсәтүгә карамастан, көчәйде генә, дип уйлый Нуриасма. Ул исе-акылы китеп, үзен сәер тойгы биләп алуын тоя. Гүя, аның өстенә коточкыч дивар акрын гына ава...

Ата кызны, ана улны белмәс дәрәҗәгә җиткән, яшьләрнең картларга, балаларның ата-аналарына хөрмәтләре төкәнгән безнең болгавыр чорда Фоат Садриевның «Таң җиле» романы чыгу үткәннәребезгә кире кайтырга, мәсләгебезне яңартырга әле соң түгел, дигән сүз. Омтылышларыбыз әле сүнмәгән, исән дигән сүз. «Таң җиле», минем фикеремчә, милли әдәбиятыбызда татар тормышын элекке эзләренә кайтаруны башлап җибәргән беренче карлыгачлардан. Афәрин, аягы җиңел булсын. Иман яңартканда бүгенге укучы өчен мондый әсәрләр бик кирәк.

**Хөрмәтле укучылар!**

«Безнең тормыш. Безнең әдәбият» дигән сөйләшү дәвам итә. Соңгы елларда басылган әсәрләр турында сездән хатлар, мәкаләләр көтәбез.

Ибраһим Нуруллин

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙГА ЙОГЫНТЫ

ӘДИПНЕҢ ТУУЫНА 115 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Академик Н. Конрадның әдәби бәйләнешләрне өйрәнүче кеше өчен күкрәккә бөти итеп тагарлык фикере бар. «Йогынты һәм үзара йогынты теге яки бу милли әдәбиятның мөстәкыйльлеген юкка чыгармый гына түгел, киресенчә, аның милли үзенчәлеген арттыра һәм калкурак итә»,— ди ул. (Конрад Н. И. Запад и Восток. «Наука» нәшрияты. 1972, 249 бит.) Карап торышка пародоксаль фикер! Чит әдәбиятның чит йогынтысы безнең әдәбиятның үзенчәлеген арттырсын, имеш! Пародоксаль, әмма гаять дөрес һәм тирән фикер. Чынлап та, әдәби йогынты үсеш-үзгәрешнең әһәмиятле факторы икән, бүтәнчә була да алмый. Чөнки үсеш-үзгәреш — ул гади үсү, гади арту түгел, ә бәлки сыйфат үзгәреше. Шуңа күрә әдәби йогынты алга киткән әдәбиятның сыйфатларын күчереп алып, үзеңнекен югалтуга түгел, бәлки, киресенчә, элек үзеңдә булмаган яңа сыйфатлар хисабына баюга алып барырга тиеш. Бу фикерне ныгыта торган һәм күңелгә беренче килгән мисал — Тукай. Дөресрәге, аның түбәндәге сүзләре: «Мин бу «Шүрәле» хикәятен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирләрендә сөйләнгән хыялый хикәяләрене язуларына истинадән (нигезләнеп) яздым». Үрнәк алган, өйрәнгән, әмма бу хәл «Шүрәле» поэмасындагы милли рухка һәм халыкчанлыкка аз гына да зыян китермәгән.

Әдәби йогынтының асылын татар халкының бер әйтеме дә гаҗәеп төгәл ачып бирә: «Кеше әйткәнне ишет, үзеңчә эш ит». Кырыгынчы һәм илленче елларда, әнә шул хакыйкатьне искә алмау сәбәпле, тикшеренүчеләр рус әдәбиятының татар әдәбиятына бәрәкәтле остазлык итүен, йогынтысын калкытып күрсәтү максаты белән, аермадан бигрәк охшашлык эзлиләр иде. Әнә шуңа күрә дә, татар әдәбияты рус әдәбияты арбасына асылган дегет чиләге булып кала иде.

Мәгълүм булганча, XIX гасырның икенче яртысында, төгәлрәк әйтсәк, соңгы чирегендә татар әдәбиятында яңа дәвер башланды. Беренчедән, әдәбият бөтенләй дөньяви эчтәлек алды. Икенчедән, ул реализм юлына керде. Дөрес, бу әле аның, ягъни реализмның, соңыннан мәгърифәтчелек реализмы дигән исем алган баскычы гына иде, ләкин шулай да реализм иде. Әдәбият тарихындагы бу борылыш һәм сыйфат үзгәреше, барыннан да бигрәк, социаль-экономик һәм идеологик характердагы эчке факторлар тәэсирендә булды. Мәгълүм ки, Россиядә, шул исәптән татарлар яшәгән территорияләрдә, кызу темп белән үсеп киткән капитализм җирлегендә татарларда да мәгърифәтчелек хәрәкәте барлыкка килә һәм аның идеологиясе формалаша.

Дөньяның барлык бүтән мәгърифәтчеләре кебек үк, татар мәгърифәтчеләренең уенча да, җәмгыятьне үзгәртеп корырга сәләтле көч итеп акыл-аң һәм мәгърифәт алга сөрелде. Татар мәгърифәтчеләре исә, билгеле бер тарихи сәбәпләр аркасында, ике нәрсәне аеруча басым ясап язалар иде. Берсе — фәнни-техник прогресс (аннсыз ничек экономиканы күтәрәсең һәм кешеләрнең тамагын тук, өстен бөтен итәсең), икенчесе — әхлак төзәтү (азып-тузып, бер-береңә бүре булып яшәсәң, муллыкта ни мәгънә һәм әле аңа ирешеп буламы). Моннан инде әдәбиятның иҗтимагый роле мәсьәләсе килеп чыга. Мәгърифәтчеләр әдәбиятның төп бурычын әхлак төзәтүдә күрәләр иде. Бу исә әдәбиятны дидактизмга этәрә.

Мәгърифәтчелек реализмы стадиясен үткән барлык әдәбиятларда да күзәтелә бу хәл. Дидактизм исә персонажларны кискен итеп тап икегә аеруда, үрнәк итеп кую өчен уңай персонажларны идеаллаштыруда, тискәре персонажларны гыйбрәт өчен беркадәр калкытуда. Конфликт исә гыйбрәт өчен уңайлар файдасына хәл ителә иде. Яхшы булсаң, әнә шулай бәхетле, начар булсаң бәхетсез буласың!

XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты да мәгърифәтчелек реализмының әнә шундый принципларын тормышка ашырырга тиеш булды. Әмма ул принципларны өр-яңадан уйлап чыгарырга хаҗәт юк иде. Мәгърифәтчелек реализмы стадиясендәге яисә аны инде узган әдәбиятлар барында нигә янадан велосипед уйлап чыгарырга? Андый әдәбиятларның берсе — XVIII гасыр рус әдәбияты булса, икенчесе — төрек әдәбияты иде. Соңгысының тәҗрибәсен үзләштерүне аеруча тел якынлыгы җиңеләйтә иде. Әнә шул закончалыклы хәлгә безгә кадәрге тикшеренүчеләр дә игътибар иткәннәр. Гаять талантлы һәм тирән белемле Җамалетдин Вәлиди, мәсәлән, хәзерге Европа фәне дигәнгә матур әдәбиятны да кертеп, болай дип яза: «Хәзерге заман Европа фәне белән без төрекләр һәм руслар аша таныштык». (Джамалетдин Валидов. Очерк истории образованности и литературы татар. Госиздат, Москва, Ленинград, 1923, 118 бит.) Яисә менә Габдрахман Сәгъди фикере: «XIX йөзнең икенче яртысының соңнарында татар матур әдәбиятында да ул (реформачылык, яңарыш) үзен чагылдыра башлый. Бу да, бер яктан, турыдан-туры рус, икенче яктан госманлы әдәбият тәэсире аркылы килеп керә». (Габдрахман Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Дәреслек-кулланма. Татарстан дәүләт нәшрияты, 1926, 76 бит.)

Чынлап та, бездә XIX гасырның икенче яртысында, бигрәк тә аның соңгы чирегендә, рус әдәбияты белән кызыксыну арту белән бергә, төрек әдәбияты белән мавыгу (уку, тәрҗемә итү, ияреп һәм үзгәртеп язу) массовый төс ала. Моның мисаллары күп булса да, иң характерлы булган берничәсен генә китереп узам. «Әбугалисина» кыйссасы», мәсәлән, 1872 елда төрек язучысы Зыятдин Сәет Яхья әсәреннән үзгәртеп эшләнгән. Яисә менә билгесез автор тарафыннан ияреп язылган һәм 1895 елда дөнья күргән «Комедия Чистайда» пьесасы XVIII гасыр рус әдәбиятына — Екатерина II нең «О время» исемле комедиясенә барып тоташа. Кем белә, бәлки әби патша пьесасы да, французчага ияреп язылган әсәр булып, татар язучысына дәверләр буена Франция йогынтысында яшәгән Төркия аша килеп кергәндер. Хәер, моны әле тикшерәсе бар.

Атаклы төрек язучысы, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Нәмык Кәмалнең «Зәваллы чужык» пьесасының тәрҗемә ителүе һәм «Кызганыч бала» исеме астында соңрак татар сәхнәсендә уңыш белән баруы да югарыда әйтелгән закончалыкларның татар әдәбияты тарихына да туры килүен расласа кирәк.

Ниһаять, башлангыч иҗат чорында Тукайның күп кенә шигырьләрен төрек телендә язуы да очраклы хәл түгелдер дип беләм.

Болары иҗади элементләр булды. Ә соң әдәби йогынтылар үзенчәлекле милли әдәбиятның үсүенә хезмәт иттеме соң?

Хезмәт итте, әлбәттә. Моңарчы исе дә булмаган яңа бер әдәби төрнең — драматургиянең барлыкка килүе, «Хисаметдин менла», «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә», «Олуг гөнаһлар», «Сәлимә» һәм «Әсма» (Р. Фәхретдинов) кебек европачыл типтагы реалистик повесть һәм романнарның мәйданга килүе, ниһаять, Фатих Кәрими, Закир Һади һәм Гаяз Исхакый каләмнәреннән чыгып, гөрләп үсеп киткән чын мәгънәсендә милли һәм халыкчан проза әнә шул бәрәкәтле йогынтыларның җимешеннән бүтән нәрсә түгел.

Татар әдәбияты 1905 елгы революциягә кадәр мәгърифәтчелек реализмы стадиясендә үсүен дәвам итсә, Беренче рус революциясе һәм аннан соңгы елларда яңа стадиягә адым ясау — тәнкыйди реализм стадиясенә күчү ихтыяҗы көн тәртибенә килеп баса. Бу күчеш тә, башлыча, эчке факторлар тәэсирендә булды, ә тышкы тәэсирләр исә ярдәмче роль уйнады.

Эчке фактор дигәнебез асылда иҗтимагый фикернең яңа баскычка күтәрелүенә кайтып кала иде. Революция дәвамында татарлар да самодержавиене аударып, демократик республика урнаштыру, җирләрне казна һәм чиркәү кулыннан тартып алып, крестьяннарга бирү идеясен алга сөргән, үзәген Г. Исхакый юлбашчылыгындагы таңчылар һәм Фатих Әмирхан җитәкчелегендәге ислахчылар тәшкил иткән революцион-демократик хәрәкәт барлыкка килде һәм революцион-демократик иҗтимагый фикер формалашты. Ул фикер әдәбиятның бурычы әхлак төзәтү белән генә чикли алмый иде инде. Әдәбият халыкны сәяси яктан тәрбияләргә, ягъни яшәп килүче тәртипләрне үзгәртү омтылышы тәрбияләргә тиеш булды. Кыскасы, революцион-демократик, иҗтимагый һәм шундый ук эчтәлекле әдәби-эстетик фикер үсү әдәбиятны иҗтимагый-политик стройның асылын тән-

кыйть итүче, нигез ташларын какшатучы реализмга, ягъни тәнкыйди реализмга этәрә иде. Күршедә генә тәнкыйди реализм стадиясен узган рус әдәбияты булганда, бу иҗат методының принципларын шулай ук уйлап чыгарасы юк, үрнәк аласы гына бар — ул иҗат принципларын иҗади үзләштерергә генә кирәк иде. Менә ни өчен 1905—07 елгы революция һәм аннан соңгы реакция елларында әдәби ориентация төрек әдәбиятыннан рус әдәбиятына күчте. Рус әдәбияты белән мавыгу монарчы һич күрелмәгән колач алды. Яшьләр арасында рус әдәбиятын уку, аның турында сүз сөйләү зыялылык билгесе итеп карала башлады. Русчадан тәрҗемә ителеп һәм русчага ияреп язылган әсәрләрнең бу чорда исәбе-хисабы юк. Аеруча характерлы һәм әһәмиятле хәл исә шул: игътибар үзәгендә нәкъ менә рус тәнкыйди реализмының корифейлары Н. Гоголь, И. Тургенев, Л. Толстой, А. Островский, А. Чехов.

Әдәби йогынтының яңа сыйфатлар белән баюына килсәк, Г. Исхакыйның, Ф. Әмирханның, Ш. Камалның һәм Г. Камалның житлеккән әсәрләреннән күренгәнчә, татар әдәбиятында ул чорда дидактизм тәмам юкка чыга һәм тәнкыйди реализмның төп сыйфаты — кешене социаль-экономик мөнәсәбәтләрне эченә алган тирәлек белән сәбәпле (причинно-следственный) бәйләнештә күрсәтү принцибы уңышлы рәвештә тормышка ашырыла.

Мәкаләнең темасына кайтып, Г. Исхакыйның 90 нчы еллар иҗатына карасак, бу әдипнең татар әдәбияты узган юлны узганлыгын, шундый ук эволюция кичергәнен күрербез. Аерма булса да, Г. Исхакыйның бу юлны кыскарак вакыт аралыгында үткән булуында гына күренер. Г. Исхакый да, билгеле инде, төрек әдәбиятын читләтеп үтә алмаган. А. Горький музеенда саклана торган автобиографиясендә үзе үк болай дип яза: «1887 елга кадәр мәдрәсәдә укуымның бөтен дәвамында (Күл буе мәдрәсәсе турында сүз бара — И. Н.) башлыча төрек романнарын бик күп укыдым. Оригиналларын да, француз теленнән тәрҗемә ителгәннәрен дә».

Г. Исхакыйның мәгърифәтчелек реализмы кысасыннан читкә чыкмаган башлангыч чор әсәрләрендә төрек әдәбияты йогынтысы үзен бик нык сиздерә. Бу яктан аеручы «Кәләпүшче кыз» повесте, «Бай угылы» романы һәм «Өч хатын белән тормыш» пьесасы характерлы. Аларда да әхлак төзәтүне максат итеп язу, уңай геройларны идеаллаштыру, тискәреләрне каралтыбрак бирү һәм конфликтны уңайлар файдасына хәл итү күзгә ташланып тора.

Әмма озакламый Г. Исхакый, беренче үк булмаса да, беренчеләрдән булып, рус-европа мәдәниятен үзләштерми торып, милли әдәиятны алга җибәреп булмый, дигән фикергә килә. Г. Исхакыйның игътибарын барыннан да элек рус әдәбиятында реализмны башлап җибәргән Пушкин һәм Гоголь җәлеп иткән. Ул заманда Пушкинның тууына 100, Гогольнең тууына 90 һәм үлүенә 50 ел даталарын билгеләп үтүнең дә монда роле булган, билгеле. Искелек белән яңалык тартышы да руста һәм татарда якынча бер төслерәк булган бит.

Гогольнең крепостнойлык укладыннан үсеп чыккан күренешләрне, гореф-гадәтләрне фаш иткән әсәрләре татар тормышындагы искелеккә, уртагасырчылыкка каршы көрәшкә җин сызгана башлаган Гаязның игътибарын үзенә җәлеп итми калмаган. 1900 ел тирәләрендә аның А. С. Пушкинның «Капитанская дочь» повестен тәрҗемә итүе һәм Гогольнең «Старосветские помещики» повестен татар тормышына борып, үзгәртеп эшләве дә очраклы хәл булмаса кирәк. XX гасыр башында инде Г. Исхакый татар әдәбиятын алга таба үстерүдә Гогольдән өйрәнүнең нинди зур әһәмияткә ия булганын тирәнтен аңлаган була. Моны без аның «Әлгасрелҗәдид» журналында басылган «Борынгы алпавытлар» повестена язган керешеннән беләбез. «Безнең милләтемезгә дә,— ди ул анда,— Гоголь тарзында (рәвешендә, стилендә — И. Н.) яза торган мөхәррирләр бик кирәк иде, чөнки безнең халыкта да бетәсе тиеш яман холыкларның иге-чиге юктыр. Әгәр шул начарлыкларны тасвир кылып, үземездә күрсәтелсә, көзгегә караган маймыл кебек, үземездән үземез куркып, ярамаган холыкларымызны ташлар идек». (1906, № 1.)

Яшь Исхакый Гогольнең «тарзы» турында да уйланып, аның үзенчәлеген шактый дөрес тотып алган. Бөек рус тәнкыйтьчеләре һәм рус әдәбияты тарихчылары фикеренчә, Гогольнең төп үзенчәлеге — гади кеше, «кечкенә» кешеләр тормышына мөрәҗәгать итүе һәм шулар тормышын күз яше аралаш көлеп тасвирлауда. Яшь Исхакый да Гогольнең үзенчәлеген якынча шулай аңлаган. «... Көлсә дә, көлүдән максаты мыскыл итү түгел иде, бәлки аларның (кешеләрнең — И. Н.) шул начарлыкларын кайгыра-кайгыра арып бетканнән соң, башкача аңлату мөмкин улмадыгы өчен, көлеп, кешенең хоббе нәфесен (самолюбиесен — И. Н.) сындырыр өчен вә башка гаепләрен дә елдырыр өчен (бетерү) бер юл гына иде». («Әлгасрелҗәдид», 1906, № 1.)

Иң башлап яшь Исхакый үзе Гоголь рухында язарга керешә. Дөрес, аның бу юнәлештәге беренче тәҗрибәләре ияру һәм механик күчерү рәвешендәрәк иде. Мондый әсәрләрнең берсе — «Борынгы алпавытлар» повестен без инде әйтеп киттек. Икенчесе — «Калуш» исемле хикәя. Эчтәлеге болай. Бер фәкыйрь шәкерт иске галошына су үтеп, аягы туңуга һәм пычрануга тәкате калмагач, дәресләр биреп һәм тамагыннан кысып җыйган акчасына яңа галош сатып ала да, аны харчевняда урлата. Гогольнең «Шинель» повесте ич бу! Әйе, Исхакый «Шинель» сюжетын күчереп алган. Гоголь тарзының «Шинель»дә чагылыш тапкан төп сыйфаты да «Калуш» хикәясенә күчкән, билгеле. Шәкертнең бәхетсезлеген автор фәкать юмор аша тасвир итә. Ә моннан соңгы күп кенә әсәрләрендә инде ияру бетеп, йогынты урын ала. Ягъни, Г. Исхакый Гоголь методының гомуми принципларын гына файдаланып, тулысынча милли үзенчәлекле әсәрләр тудыра башлый. «Башкорт бәхете» исемле хикәядә, мәсәлән, фәкыйрь башкорт карты, «мин» исеменнән хикәяләүчене утыртып барып акча эшләү өчен, атым яхшы, арбам тимерле дип, алып китә. Арык ат көчкә атлый, тәгәрмәчләре тәгәрәп барудан бигрәк, квадратлап хәрәкәт иткәнгә, утырып баручыларны үрле-кырлы сикертә. Бүтән атка күчеп утырганда, әлеге «мин» башкортны битәрләп әйтә: «Атым яхшы, арбам тимерле, — диден бит». Карт, арбасында калгып чыгып торган бер тутыккан кадакка күрсәтеп, салкын кан белән: тимерле шул, әнә бит, дип җавап бирә. Күз яше аралаш көлү дими, ни дисең инде моны!

Тора-бара Г. Исхакый, механик кабатлауны бөтенләй ташлап һәм Гоголь принципларын иҗади файдаланып, татар тормышының бөтен үзенчәлеген, җанлы рухын чагылдырып язылган әсәрләрен берәм-берәм дөньяга чыгара башлый. Менә, мәсәлән, «Кәтелгән бикәч» хикәясе. Аның герое малай чагында ук бер кыз балага гашыйк. Илдәге мәктәп баскычларын узгач, малай күп еллар буе чит илдә укый. Күңелендә сөйгәненең якты сурәтен кадерләп йөртә, мәхәббәте куәтләнә генә бара. Менә ул бер заман буй җиткереп Ватанга кайта, ашыгып, түземсезләнеп сөйгәне янына бара. Әмма гүзәл кыз урынына табак битле, ләпшердәп юанайган хатын күреп, йөрәге ярылып үлә.

Гоголь йогынтысында язылган әсәрләрнең иң характерлысы «Сөннәтче бабай» повесте булды дисәк, шаять ялгышмабыз. Кечкенә кеше драмасын күз яше аркылы көлеп тасвирлау принцибы анда гаять уңышлы һәм тулы тормышка ашырылган. Әмма әсәрнең герое, һичшиксез, татар авылында гына житешә, татар язучысы каләменнән генә чыгарга мөмкин булган тип.

Сөннәтче бабайның яшәвенә мәгънә бирә торган, үз алдында үз абруен күтәрә торган кәсебе бар. Андый-мондый гына һөнәр түгел: ата-бабаларыннан, бик борынгыдан мирас булып калган һөнәр. Бик кадерләп саклана торган шәҗәрәгә ышансаң, картның нәселе Аксак Тимергә генә түгел, хәтта Мөхәммәт галәйһиссәламга ук барып тоташа икән. Дөрес, шәҗәрәне ишан хәзрәт кушуы буенча бер талир тәңкә бәрабәренә бер шәкерт кенә язып биргән. Шулай да, шәҗәрәнең хаклыгына карт үзе ышанган кебек, авыл халкы да шик белдерми. Сөннәтче бабайның җаннан газиз тагын бер нәрсәсе бар — анысы чалгы пәкесе. Ул да бик борынгы икән, хәтта Мөхәммәт кулына да кереп чыккан. Сөннәт вакыты җиттеме — бабайның иң бәхетле көннәре башлана. Иртән торып, битен-күзен юып, ул чәч-мыекларын төзәтеп, сап-сары агач череген пөхтәләп төреп тыга да, салаватлар әйтеп пәкесен ала да, авыл буйлап йөрергә чыгып китә. Әмма бер заман Сөннәтче бабайның тормышы көйсезләнеп китә, чөнки бер җан, бер тән булып яшәгән карчыгы үлеп киткәч, ул ялгызлыкка һәм аркасы туңуга түзә алмыйча, өйләнә. Ул мән белми торган затсыз карчыкка тап була.

Көннәрдән бер көнне җомга намазыннан кайткач, ни күзе белән күрсен, әлеге карчык аның изге пәкесе белән бәрәңге әрчеп утыра. Карт тилереп китә, кычкырына, җикеренә, җылый, карчыкны өеннән куа башлый, аннары һушы китеп егыла. Бер-ике көннән аны авылдашлары карчыгы янына үзе казып куйган каберге күмеп кайталар.

Рус классикларының берсе әйткән: «Без барыбыз да Гогольнең «Шинель»еннән чыктык». Безнең Исхакый да Гогольнең «Шинель»еннән чыккан икән, ләбаса!

Билгеле инде, кулына каләм алгач, ул шул шинельдән чыккан бүтән рус язучылары белән дә кызыксынырга, аларны укырга, өйрәнергә тиеш иде. Әлеге автобиографиясендә ул болай яза: «Бу вакытларда (учительский школада укыганда — И. Н.) рус телен мин шул дәрәҗәдә үзләштергән идем ки, рус язучыларының әсәрләрен мин оригиналында укый башладым. Иң зур йогынты ясаган язучы миңа Тургенев булды. Соңра Толстой белән мавыга башладым. Достоевскийны исә җенем сөйми иде».

Г. Исхакыйның Толстой бит рус реализмы үсешендә соңгырак этап санала. Ул, Чернышевский фикеренчә, рус реализмын күңел диалектикасын тасвирлау дәрәҗәсенә ирешкән психологик анализ хисабына баеткан. Татар әдәбияты да, шул исәптән Гаяз Исхакый прозасы да, үзенең билгеле бер баскычында әнә шундый психологик анализ алымын кирәксенә иде. Г. Исхакый, күрәсең, бу очракта да мондый анализның кирәклеген сизеп алучыларның беренчеләреннән булган. Толстойны яратуы, аның белән мавыгуы ни дәрәҗәдә булганы үз сүзләреннән дә күренә. Толстойның Фуад Туктаров тарафыннан тәрҗемә ителгән «Карма» исемле әсәрен «Әлгасрелҗәдит» укучыларына тәкъдим итеп язган кереш сүзендә ул болай ди: «Толстойның әсәрләре шулкадәр галидер ки, аларны укыр өчен генә дә рус телен өйрәнерлек бар». Янсә менә «Теләнче кызы»романы геройларының берсе — прототибы Г. Исхакый үзе булган Мансур әдип Толстойның «Война и мир» һәм «Воскресенье» әсәрләрен изге нәрсәләр итеп саклый.

Толстойдан нәрсә алган, нәрсәгә өйрәнгән соң Г. Исхакый? Толстойны бүтән рус классикларыннан аерып торган төп үзенчәлеген алган ул, әлбәттә. Чернышевскийны укыганмы, әллә ул үзенчәлекне үзе аңлап алганмы, моны төгәл генә әйтеп булмый. Без аның «Воскресенье» романы тәэсирендә язылу ихтималы булган «Теләнче кыз» (1900) романында ук күңел диалектикасын биргән көчле тасвирлама белән очрашабыз. Моңа ышану өчен бай улы Габдулла тарафыннан көчләнгән Сәгадәтнең күңеленнән узган уй-тойгылар өермәсе турындагы урынны гына укырга кирәк. Соңрак психологик анализ Г. Исхакый иҗатында милли үзенчәлекне баета торган органик рәвеш ала. Бу яктан аның аеруча характерлы әсәрләре түбәндәгеләр: «Тормышмы бу?», «Ул әле икеләнә иде» һәм «Бер тоткынның саташуы». Л. Толстойның Г. Исхакыйга йогынтысы булуын менә бу дәлилләр раслый: 1) Г. Исхакыйның Толстойны укуы, белүе, аннан өйрәнүе; 2) Г. Исхакыйга кадәр татар прозасында күңел диалектикасын ачуга кадәр күтәрелгән психологик анализның булмавы.

Әлбәттә, «рус әдәбиятының Г. Исхакыйга тәэсире» дигән зур мәсьәләне бер мәкаләдә иңләп һәм ачып бетерү кыен эш. «Г. Исхакый һәм Тургенев» дигән тема, мәсәлән, үзе бер хезмәт сорый. Аның өчен минем күзәтүләрем дә, материалым да юк дип әйтерлек. Ә бит әдип үзе Тургенев тәэсирен таныган. Бәлки бүтәннәр, бу темага алынырлар һәм Гаяз Исхакый иҗатын тулырак, дөресрәк аңлауга өлеш кертерләр.

**Булат Солтанбәк**

# ГАДЕЛСЕЗЛЕК ТАНТАНАСЫ

Житмеш ел тирәсе вакыт узгач, сез беренче тапкыр КПССның иң яшерен һәм серле документларыннан берсенең — милли мәсьәләләрне хәл итүнең сталинчыл үрнәге җиңеп чыгу белән тәмамланган, 1923 елның 9—12 июнендә Мәскәүдә узган 4 нче Киңәшмә стенограммасының текстын укый аласыз. «Кульязма хокукында», «Фәкать партоешмалар өчен генә» һәм, ниһаять, «Үтә яшерен»[1] дигән өч катгый тамга сугылудан чыгып кына да (соңрак мондый билгеләрне фәкать атом-төш коралына кагылышлы документларга гына куйганнар) бу материалларны кеше күзеннән ерактарак тотуга никадәр әһәмият бирелүен аңлап була. Киңәшмә карарлары исә нык үзгәртелеп һәм шомартылып коммунистлар өчен үзенә күрә бер инҗил[2] булып хезмәт иткән «КПСС резолюцияләрдә...» дигән җыентыкта аерым өзекләр рәвешендә басылып чыга. Бу документларны мөһимлекләре буенча съездлар һәм аеруча җитди пленумнар дәрәҗәсенә куя күп нәрсә хакында сөйли. Әле күптән түгел генә «Үтә яшерен» дип мөһер сугылган нәрсәләрнең күбесен белергә өлгергән бүгенге укучы, матбугатта дөнья күргән документлар белән танышып, үзе тиешле нәтиҗәләр ясар, әлбәттә. Солтангалиевне аклау өчен әзерлек эшләре алып барганда авторга Политбюроның күп кенә документлары һәм Сталинның архивы белән танышырга туры килде. Шуның нәтиҗәсендә без ул чактагы вакыйгаларга карата гомум кабул ителгән бәяләмәләрдән аермасы булган үз фаразларыбызны бәян итү мөмкинлеге алдык. Ләкин хәзер 1923 елга әйләнеп кайтыйк.

Бу киңәшмә милли сәясәттә яңа чор башлануын хәбәр итте. Аңа кадәр узган партиянең XII съездында башлыча Ленин мәсләге җиңеп чыкты һәм сүздә генә булса да республикаларның мөстәкыйльлегенә хөрмәт белән карау, аларның үзенчәлекләрен исәпкә алу принциплары алга сөрелде. Аңардан соң аерым республикаларда суверенлыкны гамәлгә ашыру, икътисадны торгызу юнәлешендә мәгълүм күләмдә чаралар да күрелә башлады. Шуңа бәйле рәвештә үзәк идарә органнары һәм беренче чиратта Җир Эшләре Халык Комиссариаты, Финанс Халык Комиссариаты белән җирле хакимиятләр арасында даими рәвештә низаглар чыгып торды. Бу мәшәкатьле мәсьәләләрне хәл итүгә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы, Оештыру бюросы һәм Секретариат та тыкшынырга мәҗбүр булды. Бу чорда Федераль җир комитеты рәисе, Милләтләр эше Халык Комиссариаты коллегиясе әгъзасы һәм, республикалардагы күп кенә житәкчеләрнең раславына караганда, Сталинның иң якын кешеләреннән берсе Мирсәет Солтангалиев милли сәясәттә төп фигураларның берсенә әверелә.

1923 елда урыннарда җир фондларын бүлүдә килеп чыккан вак-төяк мәсьәләләрне дә үз кулына алырга маташкан Җир Эшләре Халык Комиссариатының тупас гамәлләрен җайлау максаты белән, Солтангалиев Үзәк Комитетка һәм Халык Комиссарлары Советына еш мөрәҗәгать итә. Аның җирдән файдалануда зуррак мөстәкыйльлек бирүне сораган Башкортстан, Татарстан, Төркестан рес-

---

СОЛТАНБӘКЕВ Булат (1928) — *галим, тарих фәннәре кандидаты. «Генсекның беренче корбаны» китабы һәм йөздән артык гыйльми хезмәт авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

[1] Бу киңәшмәдә ясалган чыгышларның өзекләре беренче тапкыр ачык матбугатта Антонов-Овсеенконың 1980 елда Нью-Йоркта басылып чыккан «Тиранның портреты» дигән китабында дөнья күрә.

[2] «Инҗил» — дини китап («Евангелис»).

публикаларын, Калмык һәм Чуваш өлкәләре теләкләрен яклап чыгуы Халык Комиссарлары Советындагы, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетындагы һәм бигрәк тә Җир Эшләре Халык Комиссариатындагы кайбер житәкчеләрнең ачуын чыгара. Мәсәлән, РСФСР Җир Эшләре халык комиссары К. Мохтаров житәкләгән даирә Татарстан хөкүмәтенең Идел буенда һәм Казан тирәсендә XVI гасырда Казан ханлыгы алынганнан соң юк ителгән татар авылларын яңадан торгызу турында карарын ризасызлык белән кабул итте. Тарихи гаделлекне торгызу омтылышы «милли тайпылыш» дип бәяләнә һәм Үзәк моңа каршы яшерен көрәш оештыра.

Солтангалиевнең Милләтләр Эше Халык Комиссариаты коллегиясендә, Кырымда, Калмыкстанда, Татарстан һәм Башкортстанда йөргәндә ясаган чыгышлары, 1922 елның декабрендә РСФСР Советлары съезды фракциясендә һәм 1923 елның апрелендә партиянең XII съездында кыю сөйләве[1] Сталинның ачуын китерә. Республикаларны сортларга бүлүгә кискен каршы чыгу һәм Сталинның гамәлләренә дә тискәре бәя бирү Солтангалиевнең сәяси язмышын хәл иткән дә булса кирәк. Әле моңа кадәр дә республикаларга кирәгеннән артык ташламалар ясалды дип уйлаучы һәм яңаларын төзүгә каршы чыккан Н. Крестинский, Е. Преображенский кебек зур йогынтылы партия-дәүләт эшлеклеләренә һәм ГПУның Шәрык бүлеге житәкчесе Я. Петерска Солтангалиевнең эшчәнлеге бер дә ошамый. 1922 елның урталарында һәм 1923 елның башларында Солтангалиевне Мәскәүдән жибәрергә ике омтылыш ясап карала. Беренче тапкырында аны партмобилизация уздырырга дигән булып, Тифлиска озаталар, икенче мәртәбә халык комиссары урынбасары Бройдо шикаяте буенча коллегия әгъзасы вазифаларыннан азат итәләр. Бройдоның соңрак тануына караганда, шикаять Сталинның турыдан-туры күрсәтмәсе һәм басымы астында языла. Ләкин республикалардагы вәкилләрнең ярдәм каршы килүе аркасында эш барып чыкмый. Сүз уңаенда шунысын да әйтеп китәргә кирәк, безнең уебызча, милли эшлеклеләр бу ыгы-зыгыларны урта кул Мәскәү чиновниклары чыгарган дип уйлаганнар булса кирәк. Ә Сталин исә бу уңышсызлыкларны үзенең абруен төшерә, мин-минлегенә тия торган житди җинелү дип кабул итә.

1923 елның башында Солтангалиев Сталин өчен генә түгел, башкалар күзендә дә бүтәннәргә начар йогынты ясарга сәләтле, үзенә күрә буйсынмау символына әверелгән дигән тәэсир кала. Хакимиятнең югары даирәләрендә Солтангалиев «эшен» һәм аның бәлале хатларын республикалар, беренче чиратта мөселман республикалары лидерларының «үҗәтлеген» сындыру өчен файдаланырга тели. Троцкийның истәлекләренә караганда, Каменев үзләренең Солтангалиевне «корбан итеп» Сталинга күренекле эшлеклененең «канын ялап карарга» рөхсәт биреп һәм аңарда җәзасыз калачагына ышаныч тудырып, зур ялгыш эшләүләреннән бик еш зарлана торган була. Ләкин Лев Борисович бу хакта үзенең баш очында да Сталин кылычы уйный башлагач кына искә төшерә шул. Ә моңа кадәр, күпмедер күләмдә Троцкийны искә алмаганда, ул да, башка күренекле эшлеклеләр дә, готтентотлар һәм империализмның башка корбаннары турында кайгыртуны өстен куреп, ил эчендәге милли проблемаларга бармак аша гына карыйлар. Бу урында Ленинның партиянең VIII съездында Бухариннан ничек әче итеп көлүен искә алыйк. Бөтен гавәм дөнья революциясен көткәндә нинди дә татарлар яки калмыклар белән баш ватарга димени инде?!

Солтангалиевне пычратырга нык ук әзерләнәләр. ГПУның Шәрык бүлеге (1919 елда аны төзүгә Ленин каршы чыга, 20 нче еллар башында ризалаша) «2 нче парламент», дигән киң күләмле чекист операциясен башлап жибәрә. Аның эшчәнлегенә Үзәк Комитет әгъзаларын һәм хөкүмәт башлыкларын да кертеп, Шәрык республикаларының күп кенә эшлеклеләре тартыла. СССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе урынбасары Н. Наримановны да кертеп, мөселман республикаларының дистәләгән лидерлары ачыктан-ачык һәм яшерен күзәтү астына алына. Солтангалиевнең үзенә килгәндә, аны бик яхшылап «эшкәртәләр». Гаилә серенвән алып вак-төяк гайбәтләргә кадәр барысы да теркәлә һәм фаш ителә. Шымчылар буйсынмас комиссарның иң якын иптәшләре даирәсенә үтеп керәләр.

1923 елның 4 маенда эш көне тәмамланып килгәндә Солтангалиев Ильинка урамындагы 21 нче йортка, Үзәк Контроль Комиссиясенә чакырыла. Монда коллегия секретаре Шкирятов аны партиядән чыгару һәм инде «элеккеге» ком-

---

[1] Үзәк Комитет карары, ягъни (Сталинның әмере) белән аны 1920 елның 1—8 сентябрендә Бакуда узган Шәрык халыклары съездына жибәрмиләр. Съездда Бакуга килгән Әнвәр паша белдерүе игълан ителә. Съездның кайбер утырышларында бу вакыйгага кадәр Башкортстан житәкчесе постын калдырып киткән З. Вәлиди дә катнаша.

мунистны ГПУ кулына тапшыру турында алдан әзерләп куелган карарны укый. Ул чакта ГПУ кулга алынуны аңлаткан. Аны моннан Лубянканың[1] эчке төрмәсенә алып китәләр.

Милли эшлекләләр катнашында киңәшмә җыю фикере Солтангалиев кулга алынып берничә көн узгач туа. Башта милли низаглар аеруча кискенләшкән республикалар һәм өлкәләрнең җитәкчеләрен генә чакырырга уйлыйлар, ләкин Политбюрода һәм Оештыру бюросында күп тапкырлар тикшергәч, сабак бирер өчен барлык милли берәмлекләрнең җитәкчеләрен катнаштыру дөрес булыр дигән нәтиҗәгә киләләр. Шунысы гыйбрәтле, Политбюро карарында капмакаршы мәсләкләрдә торучыларны һәм берсе икенчесенә дошман кешеләрне чакыру каралган була. Сталинның бу тәкъдиме үз халыкларының хокукларын яклау өчен республикалар һәм өлкәләрнең лидерлары берләшүен булдырмау максатына хезмәт итәргә тиеш була. Ул-бу чыга калса, ярдәм итәрләр, дип өстәмә рәвештә урыс милләтеннән 15 өлкә комитеты секретарьлары да чакырыла. Май ахырына Солтангалиев эше тәмам тикшерелеп бетүгә, ГПУ рәисе урынбасары В. Менжинскийның әйтүенә караганда, аны сак астында тоту ихтыяҗы калмауга карамастан, киңәшмә башланганда ул әле азат ителмәгән була. Моны киңәшмәдә катнашучыларга өстәмә рәвештә психологик басым ясау һәм «куркыту» өчен эшләнгән нәрсә дип әйтергә тулы нигез бар. Шулай ук Политбюрода һәм Секретариатта бу сәяси картаны ничек итеп «уйнату» хакында сүз булуы да күренеп тора. Дзержинскийның Политбюро йомышын үтәмәве һәм Солтангалиев «эшен» тикшерүне үз өстенә алмавы, Менжинскийның Солтангалиевнең төрек һәм әфган дипломатлары белән бәйләнгән булуына һәм башка дәлилләргә шик белдереп Сталинга язган яшерен хаты, Солтангалиевне тиз арада азат итү турында Политбюро карарын тормышка ашырудан баш тарткан Куйбышевның һәм Ярославскийларның «көтмәгәндә» ясаган белдерүләре бу фаразларымны раслый дип уйлыйм.

1923 елның мае ахырында киңәшмәне чакыру хакында соңгы карар кабул ителә.

Ул 9 июньдә кич белән ачыла һәм 12 июньдә кич белән тәмамлана. Җиде утырыш була, шулардан алдагы икесе тулысынча Солтангалиев эшенә багышлана, хәер, «Милли мәсьәлә буенча партиянең XII съезды резолюцияләрен тормышка ашыру буенча гамәли чаралар» турында дигәннәрендә дә ул игътибар үзәгендә тора. Хиваны санамаганда, киңәшмәгә барлык республикалар һәм милли өлкәләрдән 58 кеше килә. Киңәшмә эшендә Үзәк Комитетның 24 әгъзасы һәм әгъзалыкка кандидаты, Үзәк Контроль Комиссиясенең 6 әгъзасы, Милләтләр Эшләре Халык Комиссариаты һәм Коминтерн хезмәткәрләре катнаша. Шунысы гыйбрәтле, РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросына кергән 11 әгъзаның һәм әгъзалыкка кандидатларның 9 ы катнаша. Авыру Ленин һәм Халык Комиссарлары Советы эшләре белән мәшгуль Рыковтан[2] кала, барысы да җыела. Чынлыкта бу Үзәк Комитетының тулы вәкаләтле пленумы була.

Киңәшмәдә теләкләре булган барлык кеше чыгыш ясый, кайберәүләр хәтта берничә тапкыр сүз ала. Мөнбәргә барлыгы алтмышлап кеше күтәрелә. Солтангалиев «эше» һәм милли сәясәт буенча төп докладларны В. Куйбышев һәм И. Сталин сөйли, Политбюро әгъзалары Л. Троцкий һәм Г. Зиновьев нотык тоталар, киңәшмәне Л. Каменев алып бара.

Фикер алышуларга «без иминлек түгел, ә кылыч китердек» дип белдергән В. Куйбышев юнәлеш бирә. Инҗилдән алынган бу сүзләр киңәшмәнең рухына бик тә туры килә. Чыгыш ясаучыларның барысы да Солтангалиевтән баш тарталар, Лубянка «шәүләсе» үзенең эшен эшли. Ләкин аларның кайберләре (Мохтаров, Халиков, Фирдәвес, Рыскулов һ. б.), Солтангалиевнең элеккеге хезмәтләрен билгеләп үтеп, республикалардагы чирле күренешләрнең сәбәпләрен ачарга тырышып карыйлар. Яңа икътисади сәясәт белән бәйләп, алар бөек урыс шовинизмының киң фронт белән һөҗүм итеп килүен күрсәтәләр һәм моны бөтен бәлаләрнең башы дип аңлатырга тырышалар. Ләкин андыйларның тавышы мөстәкыйль фикер йөртә белә торган эшлеклеләрне чәйнәп әзәргә әзер торган күпчелек (Ибраһимов, Сәетгалиев, Нимвицкий, Орджоникидзе, Шамигулов, Микоян һәм башкалар) басып китә. Мәсәлән, Кырым АССР Халык Комиссарлары Советы

[1] Бу хакта автор үзенең «Генсекның беренче корбаны. М. Солтангалиев. Язмышлар, кешеләр, вакыт» (Казан, 1991) дигән китабында җентекләбрәк яза.

[2] Чакырылучылар арасында Н. К. Крупская булмаса да, ул аерым утырышларда катнашкан. Киңәшмә турында өзек-өзек кенә булса да хәбәрләрне Ленин аның аша алган булса кирәк. Ленинның «Биохроникасында» аның 3—19 июньнәрдәге эшләре һәм биргән йомышлары теркәлгән.

рәисе Сәетгалиев (1921 елның җәендә Советлар съездында аны Татарстанда шундый ук урыннан алып ташлыйлар һәм ул «азәрлекләнә» торган комиссарга шәхси үч саклый) «солтангалиевчелек» турында сөйләгәндә аның кин таралуын күрсәтергә кирәк дип белдерә, низагның кысаларын «шәхси эш»тән киңәйтергә омтылган Куйбышев һәм Сталин тегерменәнә су коя. Татарлардан кала, башкорт эшлеклеләре дә үтә кыен хәлгә төшәләр. Алардан үзләренең Вәлиди белән элемтәдә торуларын һәм басмачылар хәрәкәтенә теләктәшлек белдерүләрен тануны таләп итәләр. Бу эштә өлкә комитеты секретаре Нимвицкий аеруча зур тырышлык күрсәтә. Ул хәтта башкортларга битараф булган Троцкийның да ачуын чыгара. З. Вәлидинең 1923 елда зур хат белән Ленинга мөрәҗәгать итүе Сталинга да, гомумән, Политбюро әгъзаларының барысына да мәгълүм була инде. Ленинга һәм партиянең башка кайбер эшлеклеләренә югары бәя биреп, ул Үзәк Комитетта эшләүче күп кенә бәндәләрнең шовинист булуларыннан, аларның җирле халык мәнфәгатьләрен аңламауларыннан зарлана, партиянең Шәрыктә алып барган сәясәтен шик астына ала. Хатында З. Вәлиди үзенең теләсә нинди сәяси тормыштан читләшергә теләвен һәм гомерен чит илдә гыйльми эшкә багышларга җыенуын сиздереп куя. Хат: «Сак булыгыз, җибәрелгән хаталарның башы Сезнең үзегезгә барып тоташмыймы икән?»[1] — дигән сүзләр белән тәмамлана. 10 мартта Вәлиди Совет җиреннән чыгып китә. Ләкин киңәшмәдә аны Ташкентка һәм Уфага сугыш белән килергә җыенган Төркестан басмачылары башлыгы дип тәкъдим итәләр. Залда утыручылар күзендә бу хәл Солтангалиевнең «гаебен» тирәнәйтергә тиеш була.

Киңәшмә барганда башка сәяси җәнҗаллар һәм бәрелешләр дә булып ала. Аларда Скрыпник, Мануильский, Троцкий, Фрунзе һәм башкалар катнаша. Киңәшмәдә әлегә кадәр Шәрыктә алып барылган милли сәясәтнең нәтиҗәсезлеге ачыла. Украина һәм Кавказда бара торган процесс һәм каршылыклар үз эчләренә генә «куып кертелеп», аларга чик куя алмыйлар. Сталин һәм аның тарафдарларының хәтта чикләнгән фикер төрлелегенә, шул исәптән, милли мәсьәләдәгесенә, нокта куярга вакыт җиткәнлеге аңлашыла башлый. Башка гамәлләр заманы килеп җитә.

Бу киңәшмәдә Сталинның доклады, башка чыгышлары кебек үк, гомумән алганда тыныч рухта була. «Боевиклар» ролен башкалар үти. Ул хәтта киңәшмәдә элек үзен бөтен республикаларның дошманы итеп таныштырган Шәмигулов кебек үтә кызыл интернационалистның, Вәлиди, Солтангалиев, Алкин, Бүкәйхановка карата йомшаклык күрсәттең, дигән дәгъваларына кискен күтәрелеп бәрелми.

Киңәшмәдә кабул ителгән карарларга уңай бәя бирергә була. Аларның ни рәвешле шәрехләнүләренә һәм гамәлгә ашырылуларына килгәндә — монысы икенче мәсьәлә. Солтангалиевнең шәхсән үзенә кагылып, Сталин аны күп гөнаһларда гаепли, ләкин аның ачуын китергән нәрсә — Солтангалиевнең шундый бөек кешегә рәхмәтле булмавы, һәр әйткән сүзен җөпләп тормавы дип уйларга кирәктер. Сталинның «төрек илчесе... аның өчен партиябез Үзәк Комитетыннан кулайрак» дигән сүзләре икейөзлелекнең иң югары дәрәҗәсе булып яңгырый. Чөнки мондый белдерү ясаганда аның сейфында ГПУның яшерен оператив идарәсе башлыгы Менжинскийның Солтангалиевкә ягылган бәлаләрнең дөрес түгеллеге хакында язу ята. Аның чыгышындагы тагын бер нәрсәгә игътибар итегез. Сталин милли мәсьәлә буенча Үзәк Комитет үткәргән киңәшмәләрнең тарихын искә төшергән булып маташа да, монысының 1918 елдан алып дүртенче булуын әйтә. Ана 1918-19 елларда уздырылган Шәрык коммунистлары һәм коммунистик оешмалары съездларын гади киңәшмәләр дип атау кулайрак. Әйтерсең лә, аларда үзәк органнар сайланмаган, Ленинның котлаулары булмаган, ә Политбюро әгъзасы Калинин, туып килә торган Шәрык компартиясен котлыйм, дип әйтмәгән. Әйе! Гражданнар сугышы җиңү белән тәмамлангач, хәзер инде тәкәллеф саклап тормасаң да мөмкин.

Солтангалиевнең шәхси язмышына кагылып, җан тиргә батып фаш итүләр белән маташкан җете кызыллардан аермалы буларак, Сталин аны суд тәртибендә трибунал аша җәзага тарту артык, ди.

Безнең карашка бу киңәшмә генераль секретарь сыйфатында Сталин тарафыннан җентекләп әзерләнгән һәм җиңү китергән беренче эре бәрелеш була. «Грузин эшеннән» ул сәяси яктан «өтелеп» чыга. «Татарныкында» исә тулы җиңүгә ирешә. Киңәшмә ябылып берничә көн узгач, Солтангалиевне төрмәдән чыгаралар. Сентябрьдә аны Сталин кабул итә һәм гражданнар сугышы турында хатирәләр уртаклашкач, бер елдан соң аңа партиягә яңадан керергә булышырга вәгъдә итә. Аңа коминтернда эш бирергә ышандыралар һәм ул, яңа вазифага

[1] Зәки Вәлиди Туган. Истәлекләр. Истанбул, 1969. 463 бит, төрек телендә.

әзерләнгәндә, «өченче» дөньяның геополитик мәсьәләләрен өйрәнә башлый. Аның бу эшчәнлеге XX гасырның сәясәт фәнендә үлемсез эз калдыра. Бер ел узгач, аны партиягә алудан баш тарталар һәм шушы көннән башлап Солтангалиев өчен кулга алулар, сорау алулар һәм җәзалаулар белән чиратлашкан сәяси сукбай, хәерче чиновник тормышы башлана. Бу хәл 1940 елның гыйнварына, Лефорт төрмәсе камерасында «әйберләрсез генә чыгарга!» дигән боерыкны ишеткәнче дәвам итә.

Киңәшмәдән соң булган вакыйгалар турында берничә сүз. Рекорд саналырлык кыска гына вакыт эчендә Киңәшмәнең стенограммасы бастырыла һәм урыннарга таратыла[1]. 1923 елның июль-август айларында Үзәк Комитет вәкилләре катнашында документлар барлык республикаларда һәм өлкәләрдә тикшерелә. Казанда мондый киңәшмә июльдә була. Өлкә Комитеты исеменнән аны җирле ГПУ җитәкчесе Шварц ача һәм алып бара. Бу үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли торган күренеш.

Бөтен Союз күләмендә мондый киңәшмәләр башка уздырылмый. Сабак онытылырлык кына булмый. Дөрес, Калининның кушуы буенча, 1926 елда Мәскәүдә РСФСР Халык Комиссарлары Советы рәисе урынбасары Торар Рыскулов җитәкчелегендә киңәшмә уздырыла. Аңа фәкать РСФСР республикалары вәкилләре генә чакырыла. Ул милли азчылык белән эшләүне яхшырту буенча гомуми күрсәтмәләр эшләүгә һәм вак мәсьәләләрне хәл итүгә генә кайтып кала.

1992 елның җәендә Казанда Мирсәет Солтангалиевнең туына 100 ел тулу уңаеннан халыкара конференция, күргәзмә кебек дәрәҗәле чаралар уздырылды, аңа багышланган тантаналы кичәне кереш сүз белән Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев ачты. Бөтендөнья татарлары конгрессы көннәрендә дә Мирсәет Солтангалиевнең исеме еш кабатланды. Аның хезмәтләре һәм аның хакында китаплар басылып чыкты. XX гасырда кешелек җәмгыяте үсешендә милли хәрәкәтнең роле турында ул әйтеп калдырган фикер һәм фаразларның күп очракта аклануы көннән-көн күренәрәк төшә. Ләкин безнең илебездәге тоталитар режим шартларында аларга колак салучы гына булмады. Режим аны һәлак итте, ә идеологиянең куштан ялчылары исемен явызлык символына әвереләрде. Солтангалиев исеме дөнья үсешенең катлаулы һәм каршылыклы милли характерын аңлауга ирешкән һәм безне низагларга, кан коюга китерә торган хаталардан сакларга омтылган күренекле сәясәтчеләр һәм фәлсәфәчеләрнең исемнәре белән беррәттән тора. Милли мәсьәлә буенча фәнни әдәбиятта аның фикерләренә таяну, исемен искә алу ешлыгы ягыннан ул... Ленин һәм Сталиннан кала, өченче урында тора һәм бу хәл үзе генә дә аның дөньяда булган зур абруе хакында сөйли. Ул элеккеге Рәсәй империясе җирлегендә милли-дәүләт берәмлекләрен төрле сортларга аермаганда гына мондагы халыкларның тыныч һәм имин яшәвен тәэмин итәргә мөмкин, дип исәпләде. Партиянең XII съездында чыгыш ясап, Солтангалиев милли мәсьәләне Сталинча куюның зур хата булуын һәм җәмгыятьнең бу мәсьәләгә даими рәвештә әйләнеп кайтачагын әйтте. Бу кисәтүнең заманча яңгыравын укучыга исбатлап торасы юк. Республикаларның, шул исәптән, Татарстанның чын мәгънәсендә суверенлыгы белән бәйле күп мәсьәләләр фәкать безнең көннәрдә генә хәл ителә башлады. Ә аны шушы фикерләре өчен теләсә ничек пычраттылар һәм ботарладылар. Мөстәкыйльлек мәсьәләсе бүген дә фаҗигале шартларда хәл ителә, чөнки тәмам азган чирне дәвалау җиңел түгел. Солтангалиев үзенең 1920 еллар уртасында ясаган икенче кисәтүендә дә хаклы булып чыкты. Ул бу чорда, әгәр большевиклар партиясе җитәкчелегендә Совет җәмгыяте империячел үсеш юлын сайласа, аны да моңа кадәр булган империяләрнең язмышы көтә, дип белдергән иде...

Солтангалиев үз заманының улы һәм ул якты киләчәк турындагы безнең хыялларның күбесен уртаклашты. Ләкин ул бер нәрсәдә хаклы булып чыкты. Маркс тарафдарлары раслаганча, милли мәсьәлә сыйнфый критерийлар белән йотыла алмый икән. 60 нчы еллар уртасында дөньядагы милли хәрәкәтнең иң бөек эшлеклеләреннән берсе, колониаль бәйлелектән азат булган Алжирның беренче президенты үзен, хәзерге Шәрыкнең башка лидерлары кебек үк, Солтангалиев идеяләре тарафдары дип санаган Әхмәт Бен-Белла аның туына 100 ел тулу уңае белән җибәргән котлавында: «Безнең планета һәм кешелек дөньясы Солтангалиевкә күп нәрсәдә бурычлы!» — дип белдерде. Бөек гражданинабызга бирелгән шушы кыска һәм ачык бәя белән килешми мөмкин түгел.

---

[1] Стенограмманың бер нөсхәсе В. И. Ленинга да җибәрелә. Кара: В. И. Ленинның Кремльдәге китапханәсе. Каталог. М., 1961, 138 б.

# СОЛТАНГАЛИЕВ ЭШЕ

Милли республикалар һәм өлкәләрнең җаваплы хезмәткәрләренә

## ҮЗӘК КОМИТЕТ ТЕЛЕГРАММАСЫ

**Үзәк Комитет җиденче июньдә пәнҗешәмбе көнне милли мәсьәлә буенча резолюцияне үтәү өчен кирәк булган гамәли чараларны билгеләүгә бәйле мәсьәләләр буенча милли өлкәләр һәм республикалар җаваплы хезмәткәрләренең киңәшмәсен чакырырга карар бирде. Шуның белән бергә, киңәшмәдә партиягә һәм советка каршы эш алып баруда гаепләнгән һәм партиядән чыгарылган Милләтләр эше буенча халык комиссариаты Коллегиясенең элеккеге әгъзасы Солтангалиев эше буенча ҮКК рәисе докладын тыңлауны тәкъдим итәргә карар кылынды.**

**Киңәшмәнең көн тәртибе:**

**1. Солтангалиев турында ҮКК доклады.**
**2. Милли мәсьәлә буенча XII съезд резолюцияләрен үтәү буенча гамәли чаралар;**
**а) Союз Үзәк Башкарма Комитетының икенче палатасын төзү һәм Республикалар Союзы Халык Комиссариатларын оештыру белән бәйле мәсьәләләр:**
**б) Җирле халыктан хезмәткә яраклы затларны партия һәм совет төзелешенә тарту чаралары:**
**в) Җирле халыкның мәдәнилеген күтәрү буенча чаралар;**
**г) Милли-көнкүреш үзенчәлекләре күзлегеннән милли республикаларда һәм өлкәләрдә хуҗалык төзелеше:**
**д) Милли гаскәри частьлар оештырудагы гамәли чаралар турында;**
**е) Партия-тәрбия эшенең куелышы;**
**ж) Милли мәсьәлә буенча XII съезд карарларын үтәү җәһәтеннән партия һәм совет хезмәткәрләрен сайлап алу.**
**Чакырылган иптәшләргә үзләре белән түбәндәге мәсьәләләр буенча материаллар алып килергә тәкъдим ителә:**
**1. Җирле телләрдәге мәктәпләрнең хәле турында саннар китерелгән мәгълүматлар.**
**2. Җирле хезмәт ияләрен тәэмин итү күзлегеннән җиргә кагылышлы мөнәсәбәтләр.**
**3. Милли тормыш-көнкүреш белән бәйле дин, хокем һәм башка учреждениеләрнең хәле.**
**4. Партия оешмаларының тулаем милли һәм социаль составы, шулай ук аларның югары һәм түбәндәге җитәкчелек органнары турында былтыргы һәм быелгы мәгълүматлар.**
**5. Дәүләт учреждениеләре, профсоюз оешмалары, кооперативлар һәм мәдәни оешмаларның милли составы былтыр һәм хәзер.**
**6. Нилектәндер файдаланылмаган җирле хезмәткәрләр резервы.**
**7. Мәскәүдәге үзәк учреждениеләр белән үзара мөнәсәбәтләр һәм шушы җирлектә туган низаглар.**
**8. Җирле халыкның Кызыл Армиягә мөнәсәбәте.**
**9. Партия һәм Совет эшендә милли мәсләк буенча җирле низаглар.**
**10. Җирле телләрдә чыга торган вакытлы матбугат саны.**
**11. Партия һәм дәүләт учреждениеләрендә эш кәгазьләре нинди телләрдә алып барыла.**
**Киңәшмәгә вакытында килеп җитү сорала.**

**ҮК секретаре И. СТАЛИН.**

*25/V—1923 ел.*

## Беренче утырыш

*(1923 елның 9 июнь киче)*

Рәис (Каменев.) Политбюро кушуы буенча киңәшмәне ачык дип белдерәм. Бу киңәшмә гадәти үк түгел, партия ихтыяры тогәл һәм анык төс алган

XII съездда милли мәсьәләне әле генә тикшергәннән соң, шушы кыска вакыт эчендә махсус киңәшмә чакыру кирәк тә түгел кебек тоелырга мөмкин. Ләкин XII съезд тәмамлангач, Үзәк Комитетта дәүләт һәм партия төзелеше мәсьәләләре буенча күп кенә сораулар туды һәм бу хәл яңа киңәшмә җыярга мәҗбүр итте. Үзәк Комитет чиратта торган бу проблемаларны төрле яклап тикшерергә тәкъдим итә һәм шушы җирлектә тулы аңлашу булыр дип өметләнә.

Политбюро бу киңәшмәнең көн тәртибенә ике мәсьәләне куйды: беренчесе — Солтангалиев турында ҮКК доклады, икенчесе — XII съезд карарларын үтәү. Бу соңгы мәсьәлә берничә практик тәкъдимнәргә бүленде.

Киңәшмә составы турында түбәндәгеләрне хәбәр итә алам: Үзәк Комитет барлыгы 60 кешене чакырган иде: әлегә 51 кеше килде, 7 кеше килә алмый, ләкин аларның бер өлеше башкалар белән алыштырылган, 6 кеше юлда. Хивадан кала, барлык республикалардан һәм өлкәләрдән чакырылучылар килде. Шулай итеп, киңәшмәне вәкаләтле дип санарга нигез бар һәм без эшкә керешә алабыз. Әгәр көн тәртибе буенча тәкъдимнәр бар икән, әйтегез.

Урыннан тавыш. Белүемчә, көн тәртибендә төп мәсьәлә булып XII съезд карарларын үтәү тора. Ә хәзер көн тәртибенә беренче булып куелган мәсьәлә алай ук зур әһәмияткә ия түгел, шуңа күрә мин аларның урыннарын алыштырырга тәкъдим итәм.

Троцкий. Политбюрода без моны тикшерсәк тә һәм беренче карашка мантыйк бар кебек тоелса да, минем уемча, бу тәкъдим ялгыш. Чынлыкта маҗаралар гадәти генә түгел — күренекле иптәшләребезнең берсе, нәкъ менә шуңа бәйле рәвештә, ягъни милли мәсьәлә буенча тоткан мәсләген сәбәп итеп Милләтләр Эше Халык Комиссариаты Коллегиясе әгъзасы партия сафларыннан чыгарылды. Безнең алга таба принципиаль фикерләшүләребезгә йогынты ясамасын өчен, бу проблеманы беренче чиратта хәл итәргә кирәк. Шуңа нигезләнеп, Политбюро бу җәнҗалны башта тикшерергә карар бирде.

Урыннан тавыш. Мин тәкъдимемне кире алам.

Сәетгалиев. Ип. Троцкий дәлилләренә каршы килүе кыен булса да, барлык төбәкләрдән җыелган җаваплы хезмәткәрләр киңәшмәсендә мондый мәсьәләне беренче планга чыгару гаепләнүче өчен артык зур дәрәҗә булыр иде. XII съезд карарларын үтәү белән чагыштырганда, бу мәсьәлә алай ук әһәмиятле түгел. Киресенчә, киңәшмә Солтангалиев эше буенча тиешле нәтиҗә чыгарганчы, милли төбәкләрдән килүче эшлеклеләр практик тәкъдимнәрен әйтеп, үзләренең сәяси йөзләрен ачсыннар. Әгәр Солтангалиев эшен беренче итеп куйсак, аны гаепләргә җыенганнар авызларына су кабып утырачаклар, чөнки иртәгә үзләрен дә партиядән чыгарудан куркачаклар. Шуңа күрә мин мәсьәләләрнең урыннарын алыштыруны сорыйм.

Рәис. Бер кеше яклый, икенчесе — каршы. Тавышка куям. Кем дә кем Солтангалиев турында ҮКК докладын көн тәртибенә икенче мәсьәлә итеп кертү ягында? Азчылык. Шулай итеп, көн тәртибендә беренче пункт булып Солтангалиев турында доклад кала.

ҮКК исеменнән сүз ип. Куйбышевка бирелә.

Урыннан тавыш. Вакыт ягын ничек чиклибез?

Рәис. Иптәшләр, гадәттән тыш мөһим мәсьәләләр буенча фәкать ике генә докладчы булганга, аларның вакытларын чикләмәү дөрес булыр. Шулай килешик, иптәш Сталин доклады буенча фикер алышуларда урыннардан килгән иптәшләргә 15 минут вакыт бирәбез, ә аннары 10 минутлык гадәти чыгышларга күчәбез... Хәл кылынды дип исәпләргә рөхсәт итегез.

Сүз иптәш Куйбышевка бирелә.

Куйбышев. Иптәшләр, мин докладымны Солтангалиевне партиягә һәм совет дәүләтенә каршы күп кенә җинаятьләрдә гаепләү өчен нигез биргән материалларны хронологик тәртиптә бәян итүдән башлыйм.

Солтангалиевне партиягә һәм Советка каршы җинаять эшләүдә шик уята торган беренче мәгълүмат ГПУ органнарына очраклы рәвештә килеп эләккән хат булды. Ул «Рөстәм» имзасы куелган һәм Иранның сәяси эшлеклеләреннән берсе, коммунист Таҗи-Бахшига адресланган иде. Бу хатта, читләтеп кенә булса да, Россиядә нindидер бер оешманың яшәвенә ишарә ителә. Аның максаты — милли мәсьәләдә Коминтернга һәм Совет властена каршы сәясәт тоту. Бу оешма, бер яктан, Россиянең мөселман коммунистларын, икенче яктан төрек һәм фарсы сәяси эшлеклеләрен, партиялеләрне һәм партиясезләрне үз тирәсенә туплау белән шөгыльләнгән, имеш.

Сонрак, «Рөстәм» имзасы куелган бу хатның Солтангалиевнеке икәне беленде. Күрсәтмәләрендә Солтангалиев моны таный. Сонрак башкорт иптәшләренең

берсе Солтангалиевтән Башкортстанга хат алынуы, аның төп нөсхәсе юк ителүе хакында ГПУга хәбәр итә. Ул хатның эчтәлеген хәтерендә калдырганча сөйләп бирә. Бу мәсьәлә буенча Солтангалиевтән сорау алу мөмкинлеге чыккач, ул, ҮК адресына карата сүгү сүзләреннән башкаларын, үзе язуын таныды. Бу хатта Солтангалиевнең партия әгъзаларыннан һәм партиясезләрдән торган оешма төзергә теләве анычрак чагылыш таба. Ул бу оешманы Совет властена каршы кую, милли мәсьәлә өлкәсендә үзәк партия органнары үткәргән чараларга каршы көрәшү өчен файдаланмакчы була.

Алга таба эшне ачыклауда мөһим роль уйнарлык тагын бер житди эпизод хакында әйтеп китү кирәк. Бу хат ип. Сталинга да мәгълүм булды. Аны хәтерендә калганнар буенча башкорт иптәшләренең берсе әйткән. Ип. Сталин ГПУдан кергән шушы мәгълүмат нигезендә Солтангалиевкә хат яза һәм аны куркыныч уен башларга маташуда кисәтә. Әдһәмов исеменә Башкортстанга җибәрелгән хатның акгвардиячеләр теле белән язылуын һәм аңа карап хөкем йөрткәндә Солтангалиевнең дә Вәлидинеке рәвешендәге оешма төзергә җыенуы күренүен әйтә. Ип. Сталинның бу кисәтүләреннән куркып, Солтангалиев Казанга, Башкортстанга һәм Кырымга хатларының хөкүмәт, партиянең үзәк органнары кулына эләгүе, сак булырга кирәклеге, кайсы хатының кулга төшүе, аның беренче нөсхәме яки копияме икәнлеге хакында кисәтеп юллама җибәрә. Кайбер урыннардан, аерым алганда Казаннан, Мохтаровтан кергән яшерен хәбәрдән хатның юк ителүе мәгълүм була. ГПУда сорау алганда Солтангалиев бу хакта үзе әйтә. Шундый ук шифрланган хат Башкортстан ГПУсы кулына да төшә. Бу хәл очраклы рәвештә була, Солтангалиевнең монда бер катнашы да юк. Солтангалиев Эчке Россия һәм Себер Мөселманнары Диния Нәзарәте әгъзасы, партиясез Тәрҗемановка сургуч мөһер сугылган адрессыз пакет бирә һәм аны Башкортстанга алып кайтуын үтенә. Алга таба мондыйрак хәл була. Бу хакта партиясез Космасов сөйләп бирә. Ул үз эшләре белән Мәскәүгә килә һәм танышы гр. Хәсәнев Закир бүлмәсенә туктала. 31 мартта шимбә көнне Сандунов мунчаларына бара. Монда ул Уфа буенча танышы Эчке Россия һәм Себер Мөселманнарының Үзәк Диния Нәзарәте әгъзасы Тәрҗеманов Кашшафетдинне очрата. Тәрҗеманов аңардан, бу көннәрдә Уфага баручылар юкмы, дип сорый. Бу сүзгә каршы Космасов дүшәмбе көнне, ягъни 2 апрельдә үзенең Уфага җыенуын әйтә. Шуннан соң Тәрҗеманов аңардан юл уңаенда Уфага хат алып кайтуын үтенә. Космасов риза була, үзенең Мәскәүдәге адресын бирә һәм хатны шунда китерергә куша. Якшәмбе көнне, 1 апрельдә, Космасов өстәлдә ике ябык хат күрә. Аларның берсе Уфага, Тәрҗемановның хатынына адресланган, ә икенчесе адрессыз һәм аңа танып булмый торган мөһер сугылган була. Хатлар янында зур булмаган юллама да ята. Анда татарчалап икенче хатны, Башкортстанның Халык мәгариф комиссары ип. Әдһәмевнең үз кулына тапшырырга, диелгән була. Язма: «Бу язуны ертып атыгыз» дигән сүзләр белән тәмамлана һәм имзасыз була. Космасов 1923 елның 2 апрелендә Мәскәүдән Уфага кайтып китә. Юлда бизгәк эләктерә һәм 5 апрельдә түшәккә егыла. 8 апрельдә аның янына күптәнге танышы ип. Богданов Закир килә. Космасов хатны тапшыруын үтенеп аңа мөрәҗәгать итә. Ип. Богданов хатның кемнән булуын сорый һәм аны Тәрҗемановның җибәрүен белгәч, хатны алачагын, ләкин тиешле адрес буенча тапшырмаячагын, үзендә шик тууын әйтә. Хатлар Богданов тарафыннан ачыла һәм ГПУга тапшырыла.

Тәрҗеманов Әдһәмевкә дип биргән адрессыз хат шифрланган булып чыга. Аның Солтангалиев тарафыннан язылуы ачыклана. Бу шифрның Солтангалиевне фаш итә торган төп материал булуын искә алып, мин аны сүзгә сүз укып чыкмакчы булам. Ул зур түгел. Бәләкәй генә кереш: аны ГПУ чаралары белән укый алдылар. Шифр гади, аңа ачкыч табуы да ансат була. Хатның Солтангалиев кулы белән язылуы экспертлар тарафыннан расланды. Менә ул хат:

«Үзең генә укы һәм яндыр. Сталин миңа минем тарафтан башкорт эшлекләләренә язылган «яшерен» хатларымның берсен үзенә тапшырулары хакында әйтте. Имеш, анда Мәскәүдә партия белән көрәшү өчен төзелгән Зәки Вәлиди рәвешендәге яшерен оешма турында әйтелә. Мине кулга алу тәкъдименә Сталин каршы чыккан. Хәзер мине бик нык күзәтәләр. Минем сиңа һәм Халиковка язган хатларымның юк ителүе яки ителмәве хакында кичекмәстән хәбәр ит. Бу хатның яки аның күчермәсенең ничек ят кулларга эләгүен ачыкла. Мин аның төп нөсхәсеме, әллә күчермәме икәнен белергә тиеш. Әгәр сиңа язган хатның төп нөсхәсе юк ителгән булса, кичекмәстән Татарстан вәкиллегенә шартлы телеграмма сук. Юмахуҗинны Татарстан вәкиллегенә күчерүгә каршы килмим, дип яз. Мин Сталинга үземнең Халиковка бер хат язуымны һәм анда беренчи шикле урын-

нар булмавын әйттем. Анда кем хаинлек белән шөгыльләнүен белергә тырыш. Сак, уяу һәм нык булыгыз, сезнең арттан да күзәтәчәкләр. Сталин хатның икенче нөсхәсен комиссариатка җибәрергә ышандырды. Саубуллашканда сак булырга кушты. Боларның барысы турында да фәкать Морзабулатовка һәм Бикбавовка гына сөйли аласың.

Халиков эше түгел микән бу? Мирсәет. Постскриптум: Советлар Съездыннан соң минем янда Сәлимҗанов, Теләүбирдин, Төгәлбаев, Солтанов һәм Мортазин булдылар. Аларның өчесен Төхвәтуллин тәкъдим итте. Бу кешеләргә ышанырга буламы? Төркестанда, Бохарада басмачылар хәрәкәте көчәя. Язга оешканрак төстә чыгыш ясарга җыеналар, дигән хәбәрләр бар. Шуңа бәйле рәвештә, үзәк милли мәсьәләдә зур ташламалар ясый. Зәки Вәлиди белән элемтәгә кер. Бик тә сак бул. Элемтә арадашчы аркылы яки шифр белән. Минем өчен борчылмагыз — ахырга кадәр нык торачакмын». Бу хатны тапшыргач һәм шифрны ачыклагач, ГПУ бу хакта ҮККгә хәбәр итте һәм шуннан соң Контроль Комиссиясе партия әгъзасы Солтангалиевкә каршы эш кузгатырга карар кылды. Аның электәге эшчәнлегендә, шифрланган хатларында партиягә каршы корткычлык күзгә күренеп тора иде. Партия эшләре буенча Коллегия йөзендә ҮКК 4 майда Солтангалиевнең шәхси аңлатмасын тыңлады һәм түбәндәге карарны чыгарды: «Партиягә һәм Советка каршы элемент буларак, Солтангалиевне партиядән чыгарырга. Билгән барлык партия һәм совет постларыннан алып атарга. Материалларның бер өлеше ачыкланып бетмәгәнгә, эшне тикшереп тәмамларга, Солтангалиевне ГПУга тапшырырга».

Аның хаинлеген ахыргача фаш итүне кирәк санап, ГПУ Солтангалиевне кулга алды. ҮКК карары исә ҮКның оештыру бюросында карау өчен керде. Оештыру бюросы: «Солтангалиев эше буенча аны партиядән чыгару һәм җаваплы совет эшеннән төшерү турында ҮКК карары белән килешергә»,— дигән фикергә килде.

Солтангалиев кулга алынып ГПУга тапшырылды һәм анда аңардан сорау алынды. Аның җаваплары каршылыклы булуын әйтеп китәргә кирәк. Башта ул гаепләренең күбесен кире какты, аннары таныды. Үзен аеруча фаш итә торган документны, Әдһәмев адресына язган хатны, ул баштан ук кире кага алмады. «Бу хат минем кулым белән түгел, ә абый кулы белән язылган»,— дип расларга маташты. Моның белән ул хатның эчтәлеге өчен җаваплылыкны үз өстеннән төшерергә теләде һәм бигрәк тә постскриптумның үзе тарафыннан язылмавына ышандырырга тырышты. Шулай да Солтангалиев Әдһәмевкә язган хатның нигездә, үз фикерләренә аваздаш булуын таныды.

Болай дип раслауның мәгънәсезлеге аерымачык, чөнки постскриптумдагы һәм хаттагы юлларның бер үк кул белән язылуы сукыр күзгә дә күренеп тора. Ахыр чиктә Солтангалиев моны үзе дә таныды. Ул бу гамәлен башкорт иптәшләрне Вәлиди белән элемтәгә кертү һәм аны Совет ягына тарту өчен эшләдем, дип расларга маташты. Ләкин аның бу сүзләре постскриптумдагы юлларга һич тә туры килми. Монда басмачылык хәрәкәтенең үсүе һәм Вәлиди белән элемтә урнаштыру арасында бәйләнеш ярылып ята. Хатта акка кара белән Төркестанда басмачыларның көчәюе, шуның аркасында үзәкнең күп кенә ташламалар ясавы хакында язылган.

«Вәлиди белән бәйләнешкә кер»,— дигән тәгъбирдә Зәки Вәлидине Совет власте ягына тарту нияте ята, дип расларга маташу да чеп-чи ялган...

Мин Солтангалиевнең соңгы күрсәтүләре хакында бераз соңрак әйтермен. Хәзер исә кайбер мөһим нәрсәләргә тукталам. Алар Солтангалиевне партиядән чыгару турында карар эшләгәндә Үзәк Контроль Комиссиясе тарафыннан исәпкә алындылар. Партиягә һәм Совет властена каршы оешманың булуы яки аны оештырырга тырышуның булуы Солтангалиев эшендәге барлык документлар белән дә раслана. Үзенең җавапларында ул: «Габдулла Әдһәмевкә җибәргән хатымда мин, оештыру эшләре дигәндә, безнең төркем арасында элемтә урнаштыру һәм хәбәрләшү өчен кирәкле чыгымнарны күздә тоттым. Советларның X съезды вакытында (бу съезд тәмамлангач) без Әдһәмев белән элемтә һәм хәбәрләшеп тору хакында килештек. Искә алынган хатта мин, чыннан да, йомышчылар җибәрү буенча барлык чыгымнарны Татар вәкиллеге үз өстенә ала, дидем. Мин аның тулы вәкаләтле вәкиле идем».

Күргәнегезчә, үзенең кассасы булган оешманың яшәве күзгә күренеп тора. Бу факт Башкортстанда гына түгел, ә Россиядә һәм Советлар Союзының башка төбәкләрендә яшәүче оешма әгъзалары арасында бәйләнешләр булуы хакында сөйли. Элемтә өчен тотылган чыгымнарны бүлешү дә нәкъ менә шуны раслый...

Партиялеләрдән һәм партия эчендә укмашса, аны фракция дип атап булыр иде,— монда партиядән тышта партиялеләр һәм партиясезләр оешмасы барлыкка килгән. Солтангалиев, инде әйтеп киткәнемчә, Үзәк Комитетның үзен эзәрлекләве хакында партиядә тормаучы ике башкорт эшлеклесенә хәбәр итүне үтенә. Документларга карaганда, ул очраклы рәвештә үзенә мәгълүм булган Үзәк Комитет кабул иткән яшерен карарларны да шуларга белдерергә рөхсәт итә. Алда әйтелгән хатта ул төрле мәсьәләләр буенча Үзәк Комитет әгъзаларының позицияләрен бәйнә-бәйнә язып чыккан, аны партиясез Бикбавовка тапшырудан да тайчанып тормаган. Беренче тапкыр сорау алганда ул, мин Бикбавовның фиркадә тормавын белмәдем, дип расларга маташты, ә бераздан моны танырга мәҗбүр булды. Оешманың йогынтысын Совет Республикасы белән генә чикләп калдырмау омтылышы хатлар белән дә раслана. Хәер, Солтангалиев моны үзе дә инкарь итми:

«Мин, Совет хөкүмәте әгъзасы, Иран коммунисты Таҗи-Бахши һәм Төркия коммунисты Җәләл» белән яшерен хатлар алышуымны таныйм. Бу эшнең Россия коммунистлар партиясе һәм Коминтерн мәсләгенә туры килмәвен аңлаган хәлдә, мин шифр кулланырга булдым».

Солтангалиев үзенең Вәлиди белән элемтәгә керергә тырышуын башта кире какты, ләкин ахыр чиктә, түбәндәгеләрне танырга мәҗбүр булды:

«Мин, Совет власте дошманы, басмачылар хәрәкәте җитәкчеләренең берсе Вәлиди белән элемтәгә керергә тырышуымны, бу эштә ярдәм итүен сорап ип. Әдһәмевкә мөрәҗәгать итүемне, яшерен хат язуымны, бу гамәлемне, Совет хөкүмәтеннән яшереп калдыруымны законсыз эш дип табам. Иптәш Сталиннан кисәтү алуыма да карамастан, шифрлы хат җибәргәндә мин моны аңламый идем әле. Хәзер исә, Зәки Вәлиди белән бәйләнеш урнаштырылган очракта, моның совет хөкүмәтенә каршы акт булуын, Вәлидинең моннардан үзенчә нәтиҗә чыгарырга маташачагын төшенә башладым. Мин, Әдһәмев белән Вәлиди арасында элемтә булырга тиеш, дип фараз иттем. Хатны язганда бу ике кеше фикерле дуслар булырга мөмкин дигән уй башыма да килмәде».

Дәвам итәм:

«Гамәлләремнең партиягә һәм Совет властена каршы канунннан тыш һәм җинаятьчел икәнен таныган хәлдә, ихлас күңелдән үкенәм. Мине кулга алу законлы. Әгәр атырга хөкем итсәләр — бу да законлы булачак. Мин моны чын күңелдән әйтәм».

Шулай итеп, Солтангалиевкә карата белдерелгән барлык гаепләр эштәге материаллар белән дә, Солтангалиевнен күрсәтүләре белән дә тулысынча раслана.

Солтангалиев эше тар контрреволюция генә түгел. Моңа һич тә шик юк. Ул — безнең милли сәясәт, бу өлкәдә барган шау-шу төрле тискәре күренешләр белән бәйле. Солтангалиев эшен шундый абруйлы җыен алдына чыгарганда Үзәк Комитет һәм Үзәк Контроль Комиссиясе нәкъ менә шулардан чыгып эш итте. Бу фактлар булмаса, аны гап-гади РСФСР гражданины итеп кенә хөкемгә тартырлар иде. Ул чакта болай озаклап һәм җентекләп сөйләшүнең һәм фикер алышуның хаҗәте дә калмас иде. Халыкара капитал акчалары исәбенә яши торган контрреволюцион басмачылар хәрәкәте җитәкчесе белән элемтә урнаштырырга тырышучы кеше белән ГПУ яисә революцион трибунал теле генә булырга мөмкин. Ләкин, бу күренешнең тамырлары тирәнгә китүен һәм аларны ачыклау мөһим бурыч икәнлеген яхшы аңлап, мин, Солтангалиев эшен без алып бара торган милли сәясәт ясалышында каpарга чакырып, Политбюрога кердем һәм шундый абруйлы киңәшмә җыярга тәкъдим иттем. Республикаларда һәм өлкәләрдә эшләүче җирле хезмәткәрләрнең милли тайпылышлары нигезендә милли тигезсезлек һәм бөек державачылык калдыклары ятканын без бик яхшы беләбез.

Бу киңәшмәнең төп максаты — бөекдержавачыл шовинизм калдыкларына каршы рәхимсез көрәш ачарга һәм милли тигезсезлек эзләрен бетерү өчен хәлиткеч эш җәелдерергә чакырган XII съезд карарларын тагын бер кат басым ясап аңлату, күрсәтү. Солтангалиев эшен тикшергәндә бу җәһәттән күп нәрсәләр күзгә ташлана. Әйтик, әгәр республикаларда һәм өлкәләрдә XII съезд карарларына тиешле игътибар булса, милли тайпылышлар белән нәтиҗәле көрәш оештырылса, чын интернационалистлар тәрбияләүгә тиешле шартлар тудырылса, Солтангалиев эше бу кадәр тирәнгә китмәгән һәм партия тарафыннан шундый югары урынга куелган кеше, үзенең хаинлеген нигиләр партия эчендәге низаглар белән аңлатып, Совет дәүләте дошманы белән элемтә урнаштырырга тырышмаган һәм җинаять эшләмәгән булыр иде.

Солтангалиевнең «Вәлиди белән элемтә тотарга омтылуымны мин революциягә каршы гамәл дип уйламадым»,— дип раславы чын күңелдән әйтелгән

сүзме-юкмы — белмим. Миңа калса, ул ялганлый. Ничек кенә булмасын, урыннардагы кайбер иптәшләр, басмачылар юлбашчысы белән бәйләнешкә керүне зур гөнаһ дип санамыйлар, дип уйларга нигез кала. Шуңа күрә без, Солтангалиев эше буенча карар чыгарганда, республикаларда һәм өлкәләрдә чын мәгънәсендә интернационалистлар, чын коммунистлар тәрбияләүне, аларны милләтчелек тайпылышларына каршы куюны партиянең урыннарда алып бара торган төп сәясәте булырга тиешлеген калку итеп чагылдырырга тиешбез. Үзәк Контроль Комиссиясе киңәшмә каравына түбәндәге карар проектын тәкъдим итә.

«Үзәк Контроль Комиссиясенең Солтангалиев эше турында докладын тыңлагач, киңәшмә:

1. Партия тарафыннан җаваплы урынга куелган Солтангалиев (Милләтләр Эше Халык Комиссариаты Коллегиясе әгъзасы), үзенең хезмәт урынындагы мөмкинлекләреннән, элемтәләреннән файдаланып, җирле эшлеклеләргә партиянең милли сәясәт өлкәсендәге чараларын бозып күрсәткән яшерен хатлар язган, үзәк партия органнары уздыра торган чараларга каршылык күрсәтү өчен республикаларда һәм өлкәләрдә эшләүче кайбер тотрыксыз һәм аумакай элементлардан яшерен оешма төзергә маташкан.

2. Партиягә каршы булган бу яшерен оешманың эшен Солтангалиев элек изелгән милләтләрнең урыс пролетариатына карата ышанычын какшатуга, Совет властеның яшәве һәм шәрык илләрен империализм көчләреннән азат итүнең төп шарты булган шушы бердәмлекне өзәргә юнәлдерергә тырышкан.

3. Милли мәсьәләдә Совет власте үткәргән сәясәткә каршы җирлектә тупларга омтылып, Солтангалиев буржуаз мөселман дәүләтләренең сәяси эшлеклеләре (Иран, Төркия) белән яшерен элемтә урнаштырып, үз оешмасын Советлар Союзы чикләреннән тыштa да киңәйтергә маташкан.

4. Солтангалиевнең партиягә каршы көрәшү өчен оешмасы алдына куйган бурычлары аны Совет строен бәреп төшерүгә юнәлдерелгән контрреволюцион көчләр белән хаиннәрчә килешү эзләү юлына китерде. Бу халыкара империализмнан матди һәм рухи ярдәм алган Бохара-Төркестан басмачылар хәрәкәте җитәкчеләренең берсе Зәки Вәлиди белән элемтәгә керергә маташуы белән дә раслана.

5. Алда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, киңәшмә, Солтангалиевнең партиягә һәм аның бердәмлегенә, шулай ук Совет Республикасына карата мөнәсәбәттә җинаятьчел гамәлләрен искә алып, аны коммунистлар партиясе сафларында калдырырга мөмкин түгел, дип саный.

6. Киңәшмә республикаларда һәм өлкәләрдә эшләүче җирле хезмәткәрләрнең бер өлешендә очраган милли тайпылышларны бөек рус шовинизмына каршы үзенчәлекле реакциянең чирле чагылышы дип бәяли. Солтангалиев эшчәнлегенең беренче адымнарында да бу бик нык сизелә. Урыннардагы урыс эшлеклеләре дә, саксыз кыланып, милли сәясәттә тупас хаталар җибәрделәр һәм алар белән көрәшү партиянең чираттагы бурычлары арасында беренче планга чыга. Шул ук вакытта киңәшмә шәрык республикаларында, бигрәк тә солтангалиевчелек күпмедер күләмдә таралып өлгергән Татарстанда һәм Башкортстанда, җирле эшлеклеләрнең үз көче белән милли тайпылышларга каршы эзлекле һәм кискен көрәш алып барылса, Солтангалиевнең партиягә һәм советка каршы эшчәнлегенә юл куелмаган булыр иде, дип саный.

7. Шуңа күрә киңәшмә республикаларда һәм өлкәләрдә азмы-күпме битараф булган җирле зыялылардан, Совет эшенә тартырлык сәләтле җирле эшлеклеләрдән чын мәгънәсендә интернационалист-коммунистлар тәрбияләүне партиябезнең мөһим бурычы дип саный. Алда әйтелгән зыялылар меньшевикчел-буржуаз милли йогынтылардан азат һәм милли тайпылышларга каршы кискен көрәш җәелдерерлек дәрәҗәдә әзерлекле булырга тиешләр.

Кемдер монда: «Бары шул гынамы?» — дип кычкырды. Партия киңәшмәсе Солтангалиев безнең сафларда каламы-юкмы дигән мәсьәләне генә ачыклый һәм моңа үзенең фикерен белдерә. Солтангалиевнең язмышын хәл итәр өчен хөкүмәт тә, Үзәк Контроль Комиссиясе дә, Үзәк Комитет та миңа вәкаләтләр бирмәде. Ләкин, миңа калса, ялгышын тануын һәм чын күңелдән үкенүен искә алып, аны төрмәдән һәм суд җаваплылыгыннан азат иткәндә, Республика бер нәрсә дә оттырмас иде. Аның эшчәнлеге (ихтималы бик аз) республикаларда һәм өлкәләрдә аяныч нәтиҗәләргә китермәс, дип уйлыйм. Үзе җинаятьчел төстә алдаган сафлардан чыгарып атылгач, мескеннәрчә яшь бирсен — аны каты җәзага тарту Солтангалиев исеме тирәсендә исәпсез-хисапсыз легендалар тууга китерер, аларны юкка чыгару авыр, ул риваятьләрне инкарь итәрлек исбатлы дәлилләр табу кыен булыр иде. Шәхсән мин үзем доклардан соң булачак сөйләшүләр, фикер

алышулар Үзәк Контроль Комиссиясе карарын раслау белән тәмамланырга тиеш, дип уйлыйм.

Рәис. Фикер алышуларга күчәбез. Сүз ип. Рыскуловка бирелә.

Рыскулов. Беренче чиратта Солтангалиев эше турында. Иптәш Солтангалиев үзе генә авыр хәлдә калмыйча, күрсәтүләрендә башка эшлекләләр өстенә дә нигезләнмәгән пычрак гаепләр ташлый. Үз вакытында мин дә Милләтләр Эше Халык Комиссариатында Коллегия әгъзасы идем. Солтангалиев белән сирәк очраштык, бергә эшләмәдек. Аны якыннан белмәдем диярлек. Шулай да агымдагы ел башларында Ташкентта чакта Советлар съезды алдыннан мин аңардан бер хат алдым. Анда Солтангалиев җирле милләтләр мәсләген яклаучы «иптәшләрне» Советлар съездында партиянең милли сәясәтенә бердәм рәвештә каршы чыгарга чакырган иде. Ул ышанычлы иптәшләрне җыеп съездга килергә тәкъдим итте. Минем Солтангалиев белән карашларыбыз хакында беркайчан да сөйләшкәнем булмады, моны кирәк дип тә тапмадым, ә шулай да аңардан бик тә сәер хат алдым. Бу хатта ниндидер яшерен оешма турында ләм-мим юк, ә фәкать оппозиция хакында гына искә алынган иде. Ул минем белән элемтә урнаштырырга теләве хакында язган һәм хатларны махсус йомышчылар аркылы йөртергә тәкъдим иткән иде. Мин җавап бирмәдем һәм, әүвәлгечә, моны кирәк санамадым. Солтангалиев турында читтән ишеттем, аның эшчәнлеген дә башкалар аша гына күзаллый идем. Ул елларда Солтангалиев Шәрык Халыклары Үзәк Бюросы рәисе иде. Чынлыкта бу оешмада Шәрык халыкларының бер генә вәкиле дә булмады, аны Үзәк Россиядән татар эшлекләләре баскан иде... Гомумән алганда, Шәрыктә, бигрәк тә Төркестанда, татар милләтеннән булган эшлекләләр күп кенә хаталар ясадылар. Бохарада һәм Хәрәземдә яшәүче халыкта алар хакында әйбәт истәлекләр калмады. Берәр татарны шушы төбәкләргә эшкә җибәргәндә аптырап бетәсең, чөнки аны кабул итәргә теләмиләр. Моны татарларның Россия җирлегендә үсүе һәм Шәрыкны белмәүләре белән аңлатырга кирәк. Бу Солтангалиевкә дә кагыла. Ул да хәзерге Шәрыктан хәбәрдар түгел...

Мәскәүгә килгәч, мин Солтангалиев белән очраштым, ләкин озаклап сөйләшеп тормадык. Ә соңрак аның сорауларга җавап биргәндә минем белән Сталин арасындагы очрашуны телгә алуын ишеттем. Ул ГПУ хезмәткәрләренә: «Рыскулов миңа Сталин белән әңгәмәсе, Сталинның мине Вәлиди белән элемтә урнаштырырга маташуда шикләнүен әйтте»,— дип раслаган. Ә эш болай булды: Минем Сталин белән очрашуымны белгәч, Солтангалиев безнең нәрсә хакында сөйләшүебезне бәян итүне үтенде. Мин аңа фәкать ип. Сталинның Төркестанда эш алып баруга кагылышлы фикерләрен, XII съезд карарларын тормышка ашыру, кадрлар сайлауда сак булу кирәклеге турында киңәшләрен генә житкердем. Сталинның Вәлиди белән бәйләнышка керергә омтылуда Солтангалиевтән шикләнүе хакында сүз булмады. Киресенчә, Солтангалиев үзенә карата дошманлык көчәя баруын, ГПУ инде эш тә ачуын,тиздән кулга алынуы ихтималлыгын белдерде. Бу минем Сталин белән очрашуыма кадәр үк булды. Күрәсең, ул бүтәннәрне үзе белән бәйләргә, йогынтысының киң җәелүен күрсәтергә теләгәндер. Кабатлап әйтәм, миндә Солтангалиевнең хаты саклана. Ул анда минем белән беренче тапкыр элемтәгә керүе хакында язган. Бу хатны мин материал сыйфатында ҮККгә бирергә җыенам...

Сәетгалиев. Резолюциядә, Солтангалиевне хөкем итәргә, партиядән куарга, диелгән. Аның турында мин җәелеп сөйләргә җыенмыйм. Исемен атаганда да, фәкать җыелма мәгънәдә генә искә алачакмын. Тарихка кереп калыр өчен, борынгыларның берсе кыйммәтле бинага ут төрткән (Залдан тавыш: Герострат). Бу очракта Солтангалиев җүләрлек эшләде. Тарих битләренә эләгер өчен Совет властен сатты. Ләкин барып чыкмады һәм барып чыкмас та дип уйлыйм. Шуңа күрә Солтангалиев турында сөйләүдән бигрәк солтангалиевчелек хакында сүз алып барырга кирәк.

Резолюциянең икенче өлешендә җирле эшлекләләрдән чын коммунистларны һәм интернационалистларны үстерү турында сөйләнә. Без бу җәһәттән ике зур хата җибәрдек. Беренчедән, моның әһәмиятен авызыбыз пешкәч кенә аңладык, икенчедән — Советларның IX съезды барган көннәрдә ип. Молотов рәислегендә уздырылган губерна комитетлары секретарьлары утырышында минем керткән тәкъдимемә колак салучы булмады. Мин мәсьәләне алдан күреп Шәрык халыклары арасында революцион хәрәкәтне өйрәнүнең зарурлыгын дәлилләдем, моның Үзәк Комитет өчен мөһимлеген расларга тырыштым. Үзәк Комитет кем белән эш йөртүен белеп торырга тиеш. Ни өченме? Белгәнегезчә, безнең Үзәк Комитетта кадрларны исәпкә алу һәм эшкә билгеләү бүлеге бар. Ә чынлыкта алар икәү. Солтангалиев житәкләгән Татар вәкиллеге моны мөстәкыйль баш-

кара. Аның үз кассасы, аппараты, хезмәткәрләргә кагылышлы бөтен рәсми документлары бар. Үзәк Комитетның мондый битарафлыгы һәм кул кушырып утыруы кадрлар белән эшли торган өченче бүлек ачарга мәҗбүр итте. Аны интернациональ кадрлар бүлеге дип атарга мөмкин. Ләкин Солтангалиев бүлеге белән бу ике бүлек арасында күк белән җир аермасы. Беренчесенең акчасы, мөмкинлекләре, йомышчылары, элемтә чаралары бар, ә калган икесендә бернәрсә дә юк...

Хәзер бөек урыс шовинизмына мөнәсәбәт турында. Монда мин бу төшенчәне шәрехләү зарур дип саныйм. Күп кенә иптәшләр ип. Куйбышев укыган резолюция бөек урыс шовинизмына карата мөнәсәбәтнең чагылышы дип бәялиләр. Моңа ачыклык кертергә кирәк, иптәшләр. Бездә партия, совет аппаратында эшләүче бер төркем житәкчеләр һәм эшче-крестьяннардан торган масса бар. Бөек урыс шовинизмына кем, кайдан һәм ничек карый соң? Бөек державачыл шовинизм кемне кыйный? Моны ачыкларга кирәк. Әгәр теге яки бу эшлекләне милләтчелектә гаепләп урыныннан алсалар һәм моны бөекдержавачылыкның һөҗүме дип аңлатсалар, бу — бер мәсьәлә. Әгәр урыслар тарафыннан азчылык милләтләр яшәгән тулы бер волостьларның, өязләрнең, губерналарның хокуклары кысылса, бу — чыннан да, бөекдержавачылыкның чагылышы булыр иде. Бу күренешнең тамырына балта чабу — бөтен партия эше...

Мин монда милли республикаларны гомумән инкарь иткән һәм аларны буржуаз дөнья галәмәте дип атаган иптәшләр бар дип раслыйм. Шундый бер иптәш бу залда да утыра. (Т а в ы ш: кем ул?) Шәрыктан килгән берәү. Ләкин андыйлар бармак белән генә санарлык. Ләкин Шәрык эшлекләләренең бөтен төркемен алсаң, алар партиянең үзеннән, съезд карарларыннан, Үзәк Комитет күрсәтмәләреннән, партиябезнең асылыннан бер тамчы да сулрак түгел. Без «интернационалист» һәм «милләтче» сүзләрен фәкать сөйләшкәндә һәм хатларда гына кулланырга мәҗбүр булабыз. Бу очракта интернационалистлар унга да, сулга да тайпылмаган чын коммунистлар гына. Ләкин, икенче яктан, бездә басмачылар белән элемтә урнаштыруга кадәр барып җиткән милли тайпылыш та бар икән.

Мин Татарстан республикасында азык-төлек җыю планын 103 процентка арттырып үтәүне татар халкын талау рәвешендә аңлату белән очраштым. Безнең «Мәскәү тарафыннан куелган интернационалист юлбасарлар» дип атауга кадәр барып җиттеләр. Башта без моны поплар агитациясе дип уйлаган идек, ләкин соңрак бу этлекнең РКП әгъзалары тарафыннан эшләнүенә ышандык. Татар авыллары ачтан үлүгә РКП яки Бөек Россия гаеплемени? Бу бөекдержавачылык шовинизмымы? Дөрес, азык-төлек җыйганда гаделсезлек булды. Ул нәрсәдә күренде соң? Урыс крестьяны кәбестәсен, кыярын, чөгендерен утыртты, яшелчә җыеп алды, ә татар көн саен токмачтан башка нәрсә ашамый. Аның яшелчә бакчасы юк. Көн саен ул бер кадак он болгатып умач эчә, урысның кәбестәсе бар. Ә азык-төлек җыю кәбестәгә кагылмады, икмәк кенә алынды. Татар гаиләсе һәр көнне ашка бер кадак он бутый, ә елга бу тугыз пот он дигән сүз. Шулай итеп, татардан икмәк бермә-бер артыграк җыелды...

Без татарга токмач өчен он калдыра алмадык шул инде. Ул чакта моңа юл куярга ярамый иде... Гражданнар сугышы шартларында урыс белән татар арасындагы тигезсезлекне кем тикшереп, исәпкә алып торсын. Азык-төлек буенча халык комиссариаты хезмәткәрләре халыкларның көнкүрештәге үзенчәлекләрен бөтенләй белмәделәр. Кәбестә утырткан өчен генә урыс крестьянын кулакка кертеп булмый ич инде. Монда кемне гаепләргә мөмкин? Интернационалистларныимы, безнең Азык-төлек комиссариатынмы, бөтен партиянеме? Юк, бу тормыш таләбе иде, барысына да гражданнар сугышы гаепле...

Хәзер тагын бер мәсьәлә: XII съездан соң аның карарларын үзенчәлекле шәрехләү, аларны ничек кирәк шулай боргалау дулкыны узды. Аерым алганда, хәзер урыннарда эшләүче иптәшләр Троцкийны үзләренең яклаучылары һәм химаячылары дип раслыйлар, ә аларның күбесе Солтангалиев тарафдарлары... Бу кешеләр, Троцкий аларны һәр эштә хуплый, дип баралар.

Т р о ц к и й. Ип. Ленин белән бергә.

С ә е т г а л и е в. Шулайдыр. Ип. Ленинның хаты төрлечә шәрехләнде, аны тиешенчә аңламадылар. Кулдан-кулга йөреп, телдән-телгә күчеп, ул тәмам бозылып бетте һәм ахыр чиктә аның нигезендә Совет эшендә дә, партия эшендә дә сәламәт сәясәт уздырмаслык хәлгә килде...

Ниһаять, «татар крестьяннарын талаучы» дигән мөһер сугып һәм «Мәскәү ялчысы» дип атап мине 24 сәгать эчендә Татреспубликадан сөрделәр. Монда солтангалиевчеләрнең һәм кайбер карт большевикларның кулы уйнавында ши-

гем юк. Сонрак аларның бер ишеләре мине кууның дөрес булмавын танырга мәҗбүр булды. Шуннан соң мин тәмам аптырап калдым. Һәм 4 сорау белән Владимир Ильичка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдым. Алар минем ул чактагы халәтемне ача кебек. Безгә, чыннан да, күп нәрсә аңлашылмый иде. Хатның эчтәлеге белән сезне дә таныштырмакчы булам.

Кадерле Владимир Ильич!

Вакытыгызны алмас өчен, Сезгә мөрәҗәгать итүемнең сәбәпләрен бәян итеп тормыйм, ә түбәндәге сорауларыма җавап бирүегезне түбәнчелек белән үтенәм:

1. Россия Совет Федерациясендә, гомумән, вак автономияле республикалар, аерым алганда, Татарстан, яшәргә хаклымы?

2. Әгәр «әйе» икән, күпмегә кадәр, ягъни башкача әйткәндә, нинди бурычларны үтәгәнче һәм нинди максатларга ирешкәнче?

3. Милли мәсьәлә буенча партиянең X съезды резолюциясен дөрес аңлаганда, аны тормышка ашырганда элек хакимлек иткән милләтнең коммунистлары (ә алар башка халыкларның коммунистларыннан бер башка өстен торалар) элеккеге изелгән халыкларга һәм алар арасыннан чыккан большевикларга мөнәсәбәттә укытучылар, остазлар, нәнкеләр ролен уйнарга, соңгыларының аны үсә бару процессында алар үзләренең урыннарын шәкертләренә һәм варисларына бирергә тиешләр дип уйлап, мин хаталанмыйммы?

4. Барлык автономияле республикаларда, бу очракта Татарстанда, җирле татар коммунистлары арасында бер-берсеннән тамырдан аерылып тора торган ике төркем яши. Аларның беренчесе сыйнфый көрәш мәсләгендә тора һәм җирле халыкларны алга таба да сыйнфый билгеләр буенча аеру өчен омтыла, ә икенчесе — вак буржуа милләтчелеге идеологиясен алга сөрә. Соңгы 4 елда без аның ачы җимешләрен татырга да өлгердек инде.

Әгәр мин Россия коммунистлар партиясе һәм аның иң югары органнары төркемнәрнең беренчесен якларга тиеш дип расласам, хаклы булырмынмы? Икенче төркем (алар да саф күңелле һәм пролетар революция өчен эшләргә әзер торалар) исә файдаланылырга гына тиеш. Аларны саф интернациональ рухта тәрбияләү эшен туктатмау зарур булыр иде. Ләкин чын коммунистларны милләтчеләрдән түбән күрү һич тә ярарлык эш түгел. Ә Татарстанда хәлләр нәкъ шулай тора».

Мин ни өчен мондый сораулар куйдым? Чөнки мин милли тайпылыш авыруы белән авырган кешеләрне республикаларга җитәкчеләр итеп җибәргәндә милли сугыш һәм низаг чыгасын, нәтиҗәдә Татреспубликаның яшәвенә куркыныч янаячагын алдан күрдем. Минем бу дүрт соравыма ип. Ленин кыска, ачык җаваплар бирде, үзеннән рөхсәт булмаганга, мин аларны сезгә җиткерә алмыйм.

Урыннан тавыш. Укуыгызны сорыйбыз.

Сәетгалиев. Әгәр киңәшмә таләп итә икән...

Рәис. Владимир Ильич сезгә генә җавап бирмәгән.

Сәетгалиев. Менә Владимир Ильичның җаваплары:

Иптәш Сәетгалиевкә:

Беренче сорауга — «әйе».

Икенче сорауга — «әле бик озакка».

Өченчесенә — «укытучылар да, нәнкеләр дә түгел, ә ярдәмчеләр».

Дүртенче сорауга — «ике агым турында төгәл, кыска, ачык фактлар китерүегезне сорыйм».

Имза: Ленин.

Бу фактлар хакында язганда Владимир Ильич авыру иде инде. Хат 1921 елның 18 июлендә язылды. Алда бәян иткәннәрдән чыгып фикер йөрткәндә, интернационалист, чын коммунист кадрларны тәрбияләү эшен һич югы өч ел элек башларга кирәк иде. Үзәк Контроль Комиссиясе докладында китерелгән фактлар белән көрәшкә дә иртәрәк тотынырга булган...

Минем тәкъдимем мондый. Резолюциядәге бөек урыс шовинизмына каршы үзеннән-үзе килеп чыга торган милли тайпылыш дигән өлешне монда, ягъни киңәшмәдә, төшереп калдыру уңайсыз була, мин аның рәвешен үзгәртеп язарга киңәш итәм. Милләтчелек — бөекдержавачыл шовинизм китереп чыгарган нәрсә түгел, аның асылы шул, ул һәрвакыт шулай булды һәм булып кала, чөнки төрки федерация төзергә омтылган хәрәкәт бар, аны гамәлдән сызып ташларга ярамый. Ул панисламизм, элеккеге кадетлар һәм башка шуныңише әтрәк-әләмнәр белән бәйле... Партия кискен төстә бу хәлләргә чик куярга тиеш.

Ибраһимов. Ип. Сәетгалиев татар эшлекләләре турында мәсьәләне шактый киң яктыртты, мин бераз тулыландырмакчы булам. Эш шунда ки, монда ип. Куйбышев тарафыннан тасвирланган хәрәкәтне тарихка күз салмыйча бәяләп

булмый. Әгәр революциягә кадәр Шәрык халыклары арасында яшәп килгән хәрәкәтләрне алып карасаң, анда без аермачык ярылып яткан панисламизм һәм пантөркизмне күрербез. 1905 елдан соң милли хәрәкәт яралгылары барлыкка килә, шул ук чорда революцион аң уяна башлый. Ул гына да түгел, Шәрык халыклары арасындагы мәгариф эшенә күз салсаң, уку йортлары белән шушы хәрәкәтләрнең җитәкчелек итүен күрәсең. Мәсәлән, Оренбург мәктәпләренә пантөркистлар, Уфаныкына — панисламистлар җитәкчелек итте. Шулай итеп, сез монда хәтта мәгарифнең дә билгеле бер агымга корылуына шаһит булырсыз. Аларның икесе дә Совет власте өчен яраксыз, ләкин Солтангалиев аларны мактап телгә ала һәм шушы панисламизм һәм пантөркизм хәрәкәтләре белән көрәшкән өчен коммунистлар партиясен гаепли.

Иптәшләр, бу хәрәкәтләр февраль түңкәрешеннән соң һәм Октябрь революциясе башларында, коммунистлар партиясе сафларында Шәрык халыкларыннан чыккан большевиклар булмаганда яшәп килделәр. Мин монда Әзербайҗанны (Баку), грузиннарны һәм әрмәннәрне күздә тотмыйм, чөнки бу төбәкләрдә эшче коммунистлар булды һәм алар яшерен эш алып бардылар. Һәм менә Октябрь революциясеннән соң бу хәрәкәт тарафдарлары партиягә керделәр. Мин 1919 елда Мәскәүдә узган Шәрык халыклары коммунистларының беренче съездын яхшы хәтерлим... Чәршәмбе көнне утырышка килгәч, мин анда Солтангалиевне очраттым. Ул нәрсә сөйләде соң? 1919 елда Солтангалиев Шәрыктәге коммунистлар партияләрен оештыру программасын тәкъдим итте. Мине Шәмигулов белән Сәетгалиев иптәшләр дөресләр. Ни өчен ул бу чорда аерым программасы булган Шәрык коммунистлары партиясен оештыруны күтәреп чыкты? Чөнки Солтангалиев ул вакытта ук Россия компартиясенә, аның элек изелгән халыкларны якты тормышка алып чыга алачагына ышанмады. Мондый ышанмау аңарда әле 1919 елда ук бар иде. Шуңа күрә бүген ип. Куйбышевның Солтангалиевнең революциягә, партиягә каршы эш алып баруы хакында сөйләгәненә гаҗәпләнергә кирәкми. Милләтчеләр тумыштан була дип әйтеп, Сәетгалиев күпмедер күләмдә хаклы. Солтангалиевне алыйк. Революциягә кадәр ул — Бакуда чыга торган контрреволюцион монархистик «Каспий» газетасы хезмәткәре. 1917 елда партиягә керә. Ә 17 нче елдан башлап нәрсә эшли? Сез, ул азчылык милләтләрне сыйнфый бүлү сәясәтен уздыра, дип уйлыйсызмы? Мондый бер генә нәрсә дә булмады. Россиянең ерак төбәкләрендә яшәүче хезмәт ияләре арасында сыйнфый аерымлану процессын акрынлап башлап җибәрү хакында аның бер генә мәкаләсе бармы соң? Ә ул заманында бик күп материаллар язган кеше бит. Юк, ул моны эшләмәде. Ул гына да түгел, 1922 елда татарлар арасында (мин татарларны мәдәниерәк һәм матди яктан тәэмин ителгәнрәк булганга алам) милләтне сыйныфларга бүлү һәм партиягә вак буржуа элементларын тартуны хөкем итү хакында сүз чыккач, Солтангалиев моңа теше-тырнагы белән карышты һәм мин тәкъдим иткән резолюцияне хакарәләү юлына басты. Ни өчен? Чөнки ул башы-аягы белән вак буржуа психологиясенә кереп баткан. Ул аны безнең партия сафларына да сөйрәп керде, милләтне сыйныфларга аеруга каршы төште. Бу Солтангалиевнең гаебе. Шуның аркасында без 100 меңнән артык эшче булган, урыс белән аралашып яшәгән, мәдәниятле һәм матди яктан шактый хәлле татарлар арасында сыйнфый аерымлануны гамәлгә ашыра алмадык...

Хәзер, турыдан-туры Солтангалиев эшчәнлегенә күчик, мин монда бу хакта аз әйтелде, дип белдермәкче булам. Хикмәт Солтангалиевтә генә түгел, әгәр сүз аерым шәхес хакында гына барса, мәсьәләне бу дәрәҗәдә киңәйтмичә, аны трибуналга бирү яки Духонин штабына җибәрү дә җитәр иде. Ләкин Солтангалиев белән күпләр һәм күп нәрсәләр бәйләнгән. Татарстан Республикасында аны зур гына төркем татар эшлеклеләре яклый. Кулга алынырга бер көн кала, ул комсомолның мактаулы әгъзасы итеп сайлана. Казандагы барлык газеталар аның рәсемнәрен бастыралар... Солтангалиевнең хаталарын танымаганнарны, аны контрреволюционер дип атамаганнарны партиядән сибереп түгәргә кирәк. Безгә мондый эшлеклеләр ярамый.

Солтангалиев эшчәнлегенең нәтиҗәләре менә мондый. Татар-башкорт халкы арасында дини мәктәпләр белән көрәшү хакында мәсьәлә куелды. Моннан нәрсә килеп чыкты дип уйлыйсыз. Без, татар-башкорт массалары яхшы әзерлекле һәм аларга Совет мәктәпләрендә дин укытмасаң да ярый, дип әйтәбез. Тәрҗеманов (мөселман шурасы әгъзасы) килә дә: «Халык баш күтәрәчәк, дин укытуны рөхсәт итәргә кирәк», — дип белдерә. Эш тамга җыюга кадәр барып җитә. Миндә 25 төбәктән кергән шундый гаризалар бар... Шунысын да искәртәм, 25 тамга кәгазенең 20 се Солтангалиев лидер булган Татарстан Республикасыннан. Мин бу резолюцияләрдә куелган таләпләрне сезгә дә укымакчы булам:

1. Яшьләренә һәм теләк белдерүчеләрнең санына карамастан, барлык мөселманнарга ислам кануннарын укытуны рөхсәт итәргә;
2. Яңа икътисадый сәясәт кертелү унаеннан дини мәктәпләрнең биналарын «халыкка« кайтарып бирергә;
3. Халыкны диңгә өйрәтүдә эчке Россия һәм Себер мөселманнары Диния Нәзарәтенең, казыйларнын һәм муллаларнын эшчәнлеген чикләмәскә, яшәп килгән декретны гамәлдән чыгарырга;
4. Руханиларга, мәчетләргә патентны бетерергә;
5. 18 яшькә житмәгән мөселман балаларына да дин сабагы укуны рөхсәт итәргә;
6. Мөселманнарнын мәдәниятен күтәрүдә иң әһәмиятле фактор буларак, Ислам диненә тулы ирек бирергә;
7. Аерым дини мәктәпләр (мәдрәсәләр) төзү, тулы дин тоту иреге;
8. Муллаларга никах, аерылышу, мирас бүлү кебек дини йолаларны башкарырга рөхсәт бирү;
9. Руханиларны тулы хокуклы гражданнар һәм юридик затлар итеп тану;
10. Дин тотучыларны һәм руханиларны партия һәм Совет власте тарафыннан төрле кысуларны туктату;
11. Матбугат иреге. Дини идарәгә һич югы бер гәзит чыгарырга рөхсәт итү;
12. Дини идарәне юридик зат итеп тану.

Менә ул халык сораган, таләп иткән нәрсәләр. Һәр тамга кәгазенә 200 дән артык кеше кул куйган, шуларнын 20 се, әйткәнемчә Татреспубликадан.

Мәктәпләр хакында сөйләгәндә мин Төркестанда сәясәт бер төрле, Татарстанда башкача булырга тиеш дип уйлыйм. Татарстан мәктәпләрендә дин укытылмаска тиеш, ләкин иптәшләрнең кайберләре моны «сул коммунизм» дип бәяли. Ип. Рыскулов безне шул җәһәттән гаепләсә, мин риза түгел. Милләтчеләр генә булып, интернационалистлар бөтенләй булмаса, бу эш тагын да зуррак төс алыр иде. Ул чакта без йөзләгән Солтангалиев белән якага-яка килер идек. Шулай булгач, сул хәрәкәтнең булуы кирәк һәм хәтта зарур. Сүземне тәмамлап килгәндә, мин ерак төбәкләрдәге республикаларда эшләүче кешеләрнең составын тагын бер кат карап чыгарга тәкъдим итәм. Моны резолюциягә дә кертергә кирәк. Татар һәм башкорт эшлекләләренең составын барлау бик мөһим. Аларның барысы белән дә аерым-аерым сөйләшергә кирәк. Солтангалиевнең җүләр фикерләрен башларыннан чыгарып атмасалар, андыйларга партиядә урын булмаска тиеш.

Ш ә м и г у л о в. Иптәшләр, бүген бу трибунадан вак республикалар яшәмәскә тиеш, дигән фикер тарафдары хакында әйттеләр... Мин бу хакта 1917 елдан бирле ишетеп киләм инде. Мине бухаринчы дип тә атадылар (көлү). Ул чакта мин ип. Сталинга, Үзәк Комитет тарафыннан тәкъдим ителгән республикаларны төзергә кирәкми, дип күрсәткән идем. Бу минем шәхси фикерем һәм мин, партия әгъзасы буларак, партия Үзәк Комитет карарына буйсынам...

Ул чакта мин яңа төзелә торган республикаларда революцион пролетариатнын һәм коммунистлар партиясенең булмавыннан чыгып фикер йөрттем. Мондый көчләр яңа җәмгыять төзү һәм аның белән идарә итү өчен зарури. Ә алар Шәрыктә юк иде. Мин, республикалардагы милләтчеләр эш башына менеп утырып, Совет властена каршы корткычлык белән шөгыльләнә башларлар, дип курыктым. Һәм шикләнүем урынлы булып чыкты. Вәлиди кебек бәндәләр менә ачык мисал. Алар Совет властенын башын әйләндерделәр һәм ахыр чиктә дошман ягына чыктылар.

Хәзер сүз бара торган оешманы шәхсән Солтангалиев төземәгән. Ул инде Октябрь революциясенә кадәр үк яшәп килгән һәм аның тамырлары февраль көннәренә барып тоташа. Әгәр без Солтангалиевне партиядән куып чыгарсак, аның яраннары идән астына китәчәк. Аннары аларны табып фаш итү кыен булачак. Бу кинәшмә Солтангалиевкә җәза биреп кенә калмыйча, аның тарафдарларын да хөкем итәргә тиеш. Бездә революцион хәрәкәт үсеше күзлегеннән чыгып фикер йөрткәндә, милләтче коммунистларның зарары зур булды дияргә нигез бар. Үз вакытында аларга тиешле бәя бирелсә, без бүгенге көнгә көнелсез хәлләр белән бәрелешмәгән дә булыр идек. Ләкин ҮК нигәдер тартып-сузып килде. Шәрыктә яшь коммунистлар белән эшләмәде. Ип. Ибраһимов сулларны бер дә юкка ачык авызлар дип атауга нәфрәтләнүе белән күпмедер күләмдә хаклы. Мин моңа кушылам. Бервакыт Сталин да мине «ачык авыз» дип атады. Аныңча барсак, Вәлиди белән көрәшмәскә, аңа оешырга мөмкинлек бирергә идемени? Мин, җирле эшлекле буларак, Вәлидинең кем булуын һәм кая каеру-

ын күреп тордым, бу хакта ип. Сталинга да җиткердем. Дөрес, соңрак Сталин моны аңлады. Вәлидине чакырып алырга җыенды, ләкин ул качты һәм хәзер басмачылар фронтын оештырып йөри. Ә бит Оренбург һәм Уфа губерна комитетлары Вәлидине каты хөкемгә тартуны сораганнар иде. Менә шушы хәлләрдән соң башка төрле уйлар килә. Әгәр Солтангалиев белән шундый уен уйнасак һәм аның башыннан сыйпасак, без икенче фронт алдына килеп басмыйбызмы? Бөтен контрреволюцион элементлар Солтангалиев тирәсенә тупланачак...

Соңгы биш елдагы тәҗрибә безне күп нәрсәгә өйрәткәндер дип ышанам, шуңа күрә киңәшмә мин тәкъдим иткән юлны сайларга тиеш. Үзәк Контроль Комиссиясе резолюциясе зур хата булачак. Моңа юл куярга ярамый.

Монда күп кенә партия эшлеклеләрен суллыкта, дәрәҗә артыннан кууда гаепләделәр. Ләкин сулларның әле беркайчан да партиясезләр белән блок оештырганнары юк, уңнар гына теләсә кем белән кочаклашырга һәм үбешергә әзер торалар. Резолюциядә Үзәк Комитетка кадрларны тикшереп, кемнең кем булуын ачыкларга тәкъдим итә торган юллар бар. Үзәк Комитет моны, һичшиксез, эшләргә тиеш. Киләчәктә без бүген тикшерә торган мәсьәлә киңрәк колач алырга мөмкин. Аның шаукымы бөтен Шәрыккә җитәчәк. Белгәнегезчә, 1918—1919 елларда Солтангалиев оешмасы ярдәм мөселман дәүләте төзү бурычын куйган иде. Материалларны өйрәнгәч, ҮК моны үзе дә күрер әле. Әгәр Солтангалиевне хәзер азат итсәләр, ул икеләтелгән көч белән эшкә тотыначак. Ә бүгенгә көнгә кадәр эленке-салынкы йөргән милләтчеләр, йөзләрен яшереп, идән астына китәчәк һәм чынлап тырыша башлаячак. Мин киңәшмә әлегә кадәр булган хаталарны кабатламас дип уйлыйм. Бу оешманың революциягә каршы булуын, Шәрык хезмәт ияләре арасында коммунистик идеяләрне таратуга зыян китерүен искә алып, Солтангалиевкә һәм аның тарафдарларына карата иң каты һәм рәхимсез чаралар күрүне сорыйм.

Е н б а е в. Беренче чиратта үзем белән таныштырыйм. Татарстан турында күп кенә куркыныч нәрсәләр сөйләнде. Мин менә шушы республиканың эшлеклесе булам инде. Миңа калса, без бүген кызабыз, мәсьәләне ип. Куйбышев тәкъдим иткәнчә тирәнгә төшеп тикшермибез. Һәр иптәш үзен акыллы, хаклы итеп күрсәтергә тырыша. Һәрхәлдә, миндә шундый тәэсир калды.

Миңа калса, Үзәк Контроль Комиссиясе Солтангалиевнең контрреволюцион эшчәнлеге турында җитәрлек материал җыйган. Шуңа күрә трибунал ясарга хаҗәт өстәмә мәгълүматлар безгә ярдәм итә алыр иде микән? Ип. Куйбышев әйтеп узганча, бу мәсьәлә партия Үзәк Комитеты әгъзаларын да, безне дә бик нык кызыксындыра. Ләкин монда ип. Ибраһимов биргән тарихи материалларга таянып кына аны хәл итеп булырмы икән? Без мәсьәләне боргаламыйча, туптуры куярга тиешбез, ягъни партия милли билгеләре буенча таралырга тиешме, әллә аның бердәмлеген саклап калыргамы?..

Солтангалиевкә кагылышлы бу мәсьәлә нәкъ менә шушы җирлектә туды. Ул чуан кебек акрынлап тулды. Яңа икътисадый сәясәт кешеләр, шул исәптән коммунистлар аңында да, төрле шөбһәләр, болганчыклык китереп чыгарды. Иң яхшы иптәшләребезнең берсе булган Солтангалиевнең сөртенүе һәм егылуы нәкъ менә шушы шартлар йогынтысында булды. Ул моны үзе дә таный. Тарихның борылышлы чорларында мондый хәлләр булды һәм булачак. Сул эсерлар восстаниесен, Брестны, Кронштадт фетнәсен алыйк. Без монда менә дигән иптәшләрнең нинди зур хаталар ясавын үз күзебез белән күрдек. Яңа сәясәт шартларында да мондый сөртенүләр булмый калмас. Бу очракта да хата ясалды һәм безнең иптәшебез аны чын күңеленнән таныды. Мин моны Солтангалиевнең бик нык аруы, йончуы белән дә аңлатыр идем. Җир турында законны тикшергәндә ул миңа үзенең шигырьләрен күрсәтте. Солтангалиев һинд һәм гарәп җырлары хакында язган иде. Аларны бәяләвен сорагач, мин аңа, синең кәефең юк, җаның таланган һәм борчулы, дип әйтергә мәҗбүр булдым, үзен кулга алырга киңәш иттем. Мин пәйгамбәр булып чыктым. Ул яңа икътисадый сәясәтнең болгавырлыгын уздырып җибәрә алмады, сынды һәм төрле хаталар җибәрде. Ләкин ул ялгышларын таныды.

Резолюциягә килгәндә, ул берникадәр күләмдә трибунал рухында язылган, һәм аны үзгәртергә мөмкин булыр иде...

Эш һәм ҮК әгъзаларына мөрәҗәгать хакында берничә сүз. Без һәрвакыт мәсьәләләрне хәл итүдә иң югары авторитет итеп ип. Ленинны санадык. Милли мәсьәләдә ип. Сталин һәм ип. Троцкий сүзеннән чыкмадык. Моны ип. Сталин үзе дә раслар. Ул безне кайчандыр кабул итмәде, нәрсәгәдер каршы килде, дип беркем дә әйтә алмас. Ип. Сталин бер кешегә дә якты йөзен кызганмый. Монда:

«атабыз», — дип кычкыралар. Нәкъ шулай (көлүләр). Шуна күрә болганчык судан балык тотмыйк, ул мәсьәләне катлауландыра гына.

Әйтергә теләгәннәрем кыскача шулар. Солтангалиев эшенә килгәндә, без хатанын булуын танып, мондый хәлләрнең киләчәктә дә кабатланырга мөмкин икәнлеген күрсәтергә тиешбез. Моңа кадәр ул озак еллар буена революция өчен файдалы эшләр башкарды. Кайчакта дүрт аяклы ат та абынуын онытмыйк.

Хыдыралиев. Иптәшләр, мин Солтангалиев эше турында берничә сүз әйтмәкче булам. Минем уйлавымча, Үзәк Контроль Комиссиясе тәкъдим иткән резолюция йомшак. Әгәр ул партия эшендә хата җибәрсә яисә фракция төзү белән генә чикләнсә, аңа каты җәза бирмичә партиядән чыгару да җитәр иде. Ә Солтангалиев исә басмачылар, Вәлиди белән элемтәгә керергә омтылыш ясый, шуңа күрә аңа карата кискенрәк чаралар күрергә кирәк. Ул большевик булырга лаек түгел, һәм безнең сафлардан куылырга тиеш. Ул гына да түгел, аны Совет судына тартырга кирәк, чөнки бу бәндә, хөкүмәт әгъзасы буларак, хезмәт урыныннан явызларча файдаланган. Милләтләр Эше Халык Комиссариаты Комиссиясе әгъзасыннан шифрланган хат алгач, урындагы эшлекләләр моңа ничек карарлар һәм безнең хакта нәрсә уйларлар икән? Алар, һичшиксез, Мәскәүдә, хөкүмәтнең һәм партиянең үз эчендә гауга бара, берәүләр аны хуплый, икенчеләре риза түгел, дигән фикергә киләчәкләр...

Монда «суллык» һәм «уңлык» турында сөйләделәр. Җинаятьчегә карата боларның икесе дә туры килми. Үзләрен уңнар дип атаучылар да, суллар да хаталар ясамый калмадылар. Ләкин бу тинтәклекләр чиктән ашып китеп ачык контрреволюцион төс ала икән, моңа кичерү юк, моның өчен атарга кирәк. Бу очракта да, Солтангалиевнең шәхесенә кагылмыйча, аның эшчәнлеген генә хөкем итеп, без кискен карар чыгарып, аны революцион трибунал кулына тапшырырга тиешбез. Әгәр аны партиядән куып төрмәдән азат итсәң, ул янадан үзенең корткычлык эшенә тотыначак. Урыннарда аның тарафдарлары күп әле. Җирле хезмәткәрләр дә бу карарны үзләренчә кабул итәчәк һәм безгә кешеләр белән эшләве бик авыр булачак. Башкаларга сабак бирер өчен без Солтангалиевнең каты җәзага тарту турында резолюция чыгарырга тиеш.

Икрамов. Иптәшләр, монда уңлык яки суллык мәсьәләсе тормый. Сүз безнең партиянең һәм Совет властеның сәясәте турында бара. Һәм бу мәсьәләне хакимлек итүче партия карашыннан чыгып тикшерергә кирәк. Мин монда бер үзбәк мәкален язып алдым: «Чит кешене күмәргә җыелганнарның һәркайсы үзенең күптән үлгән якыннарын сагынып елый». Уңнар — сулларны, суллар уңнарны гаепләү дә нәкъ менә шуңа охшаган. Минемчә, ике як та хаклы түгел. Нәрсә соң ул солтангалиевчелек? Солтангалиевнең үзе турында мин 1920 һәм 1921 елларда ишеттем, ләкин аның нинди кеше булуын ачыклый алмадым һәм хәзер дә белмим. Ә солтангалиевчелек хакында беләм. Ул монда бәян ителгән материалларда бик әйбәт тасвирланган.

Ул әле ип. Зиновьевның Бакуда уздырган Шәрык халыклары съездыннан ук башланды. Бу съездан соң партия карарлары белән килешмәгән төрле элементлар көрәш юлын сайладылар. Ләкин аларның барысын да контрреволюционерлар дип аңларга кирәкми. Мәсьәләгә тирәнрәк күз салыйк. Беренче карашка, аларның бер көче дә юк кебек, ләкин кайдадыр җирлек табалар бит! Аларны ниндидер чыганак туендыра. Бу чыганак безнең дөрес сәясәт үткәрә алмавыбыздыр кебек. Аерым алганда, Үзәк Комитет ваграк мәсьәләләрдә тиешле эшлеклелек күрсәтә алмый, милләтчеләр моннан оста файдаланалар. Сәбәпләр шул. Моңарчы ҮК республикаларга күрсәтмәләр һәм әмерләр җибәреп яту белән канәгатьләнде...

Безнең партиядә 20-30 ел Маркс теориясен өйрәнгән, төрмәләрдә чәчләре агарган, патша самодержавиесе әзәрлекләүләрен кичергән теоретиклар да, үзләренең икътисади мәнфәгатьләрен яклап партия сафларына килгән гади эшчеләр дә әгъза булып тора. Ә республикаларда мондый кешеләр юк. Бәлки татарларда, аз күләмдә башкортларда бардыр, ә Кыргызстанда һәм Бохарада юк. Коммунистлар безгә кайдан киләләр соң? Беренче чиратта — ярлы катламнан. Алар Совет властеның үзләре өчен нәрсә эшләвен күрәләр һәм безнең сафларга кушылалар... Ләкин икенче элемент — солтангалиевчеләр дә бар. Алар Совет власте аша автономия алырга, республикаларны бәйсез мөстәкыйль мәмләкәтләр ясарга хыялланалар. Монда эшнең асылын аңларга кирәк...

Хәзер зыялыларны файдалану турында. Кайбер иптәшләр бу хакта борын җыерып, мәсхәрәле елмаеп сөйләшсә дә, аларны республикаларда эшкә тартырга кирәклектә шик юк. Болай итмәгәндә, алар безгә каршы күтәреләчәк. Алар — революцион көч. Харьковта ясаган чыгышында ип. Троцкий әйткәнчә, милли

мәсьәлә — хәлиткеч көч һәм без аны үз мәнфәгатьләребездә файдаланмасак, контрреволюция файдаланачак. Ә бу көч революцион рухлы зыялыларда тупланган...

Тагын бер зур кимчелеккә тукталам. Безнең республикаларда сез Совет власте һәм партия уздырган сәясәттән канәгать бер генә эшлекләне дә очратмассыз. Ул өстән аңлатма ала алмый, ә югарыга мөрәҗәгать итәргә курка... Аның фикеренчә, өстәгеләр аны, һичшиксез, кулга алырга, атып үтерергә тиеш. Съездда миңа шактый җаваплы урын биләгән, дөресрәге, республикаларның берсендә хөкүмәткә җитәкчелек иткән иптәш белән танышырга туры килде. Ул милли мәсьәлә буенча тәкъдимнәр язган икән. Без ип. Рәхимбаев белән аңардан: «Нәрсә язасың?» — дип сорадык. Ул: «Милли мәсьәлә буенча фикерләремне».— ди. Аннары як-ягына каранып: «Әгәр мин аларны тәкъдим итсәм, ачуланмаслармы икән?» — дип өсти. Ул үзенең хаклымы-юкмы икәнен белми, ә беренче чиратта әрләмәсләрме икән, дип сорый. Моңа да игътибар итәргә кирәк.

Мин мондый иптәшләргә карап: әнә грузин һәм украин иптәшләрдән үрнәк алыгыз, дияр идем. (Көлүләр). Сез моны партия стеналарыннан читтә эшлисез, ә моны партия кысаларында эшкә ашырырга кирәк, ул чакта сездә солтангалиевчелек булмас.

Солтангалиевчелеккә килгәндә, мин ип. Хыдыралиев тәкъдимен хуплыйм. Әгәр без аны бүген җибәрсәк, озакламый икенче Зәки Вәлиди алачакбыз, ул безгә Төркестанда эшләргә комачаулаячак...

Хуҗанов. Иптәшләр, мин кыска тотам. Ип. Икрамов биргән бәягә өстәп, берничә тәкъдим генә кертәм. Солтангалиев эше бу киңәшмәдә хөкем учреждениесе процессы рәвешендә, ягъни Солтангалиевне хөкем итәргәме, әллә акларгамы, дигән яссылыкта куелмый. Без аның контрреволюцион эшчәнлегенә бәя бирергә тиешбез. Бу күзлектән чыгып фикер йөрткәндә, монда сөйләгән иптәшләр Солтангалиевкә һәм аның эшчәнлегенә кискен каршы торалар. Без бу сызыкны каттый рәвештә хөкем итәргә тиеш...

Башта солтангалиевчелекне һәм аңа охшаш хәрәкәтләрне өйрәнергә, бөтен шифрларны ачыкларга кирәк. Аннары солтангалиевчелекне тудырган шартлар белән кызыксынырга. Өстән һәм читтән караганда, бу зыялылар уенына охшый. Бер зыялы уң булырга теләгән, икенчесе — сул, берсе Солтангалиевкә әверелгән, икенчесе акыллы булып чыккан һәм сәясәт шуннан гыйбарәт дип уйлыйлар. Ник дигәндә, җәмгыять тормышы билгеләре булмаган җирдә партиялелек тә юк, чөнки партия үзе дә җәмгыять җирлегендә туа. Шуңа күрә солтангалиевчелекнең башлыча Шәрык туфрагында чәчәк атуына гаҗәпләнәсе юк. Чөнки анда Совет власте урнашмаган, җәмгыять уянмаган.

Шәрык бүгенге көнгә кадәр колония булып кала, аңа никадәр генә Совет ярлыкларын ябыштырсаң да, моннан аның асылы үзгәрми. Һәм моны даими истә тотарга кирәк.

Солтангалиевчелекнең асылы нидән гыйбарәт соң? Ул урыс капиталы белән сәүдә капиталы сугышы.

Тавыш. Һәм дәүләт капиталы да.

Хуҗанов. Әйе, дәүләт капиталы да. Көндәшләр өчен үз дошманының нинди юлдан баруы һәм нинди битлек астында эш итүе барыбер. Татар һәм урыс миссионерларының Шәрыкка ябышып ятуларын ничек аңларга? Аларны безнең кыргызлар аеруча яхшы белә. Алар мәгариф, мәдәният таратабыз дигән булып нинди максатларга омтылдылар? Базар эзләделәр, базар бүлештеләр. Революциядән соң афиша гына үзгәрде, ә сәүдә капиталы эшен һаман дәвам итә. Ерак төбәкләрдә урнашкан республикаларда солтангалиевчелек мондагы колониаль тәртипләр җирлегеннән килеп чыга. Дәүләт капиталымы ул, аерым шәхеснекеме — ярлы халык өчен барыбер. Шуңа күрә халык арасында канәгатьсезлек килеп чыга һәм арадашчы иптәшләр моннан бик оста файдаланалар.

Шул ук панисламизмның нигезендә дә икътисадый мөнәсәбәтләр ята. Аның тарафдарлары Көнбатышка бәйле булмаган базарлар булдыру хакында хыялланалар. Ә моның өчен Шәрык капиталына юл ачарга кирәк. Мондый панисламизм хәзер дә яшәп килә, ә безнең кайбер дөрес булмаган адымнарыбыз үзләре үк моңа нигез тудыра. Без панисламизм белән көрәшүне туктатмаячакбыз, билгеле, ләкин безнең дошманнарыбыз да бу коралдан оста файдаланачак. Моны исәпкә алырга кирәк. Бу очракта партиянең колонияләрне бетерү, чын мәгънәсендә мөстәкыйль Совет республикалары төзү турында карары яхшы нәрсә һәм Солтангалиев шуны ук тукып тора һәм аны гади юриспруденция күзлегеннән чыгып караганда гаепләве дә авыр. Ник дигәндә, ул XII һәм X съезд карарларына ышыклана ала (Көлүләр).

Болар бар да иске заманда эре капиталдан азат булырга омтылган арадашчы-сәүдә капиталының шушы ук файдалы эшчәнлеген хәзер дә дәвам итүен күрсәтә. Бу юлда ул Ислам дине абруен да, феодализм калдыкларын да, коммунистлар партиясе съездлары карарларын да үзенә эшкә җигәчәк. Менә Шәрыкнең төп чире шул һәм бу җирлектә солтангалиевчелек кенә түгел, ә теләсә нинди авантюралар үсеп чыгарга мөмкин. Туфрак йомшартылган, аннан нәрсә булса да чыкмый калмый.

Солтангалиевне ике нәрсә тудырды. Беренчесе, ерак төбәкләрдә безнең нык ошкан партия юк әле. Бу турыда ип. Икрамов бик дөрес әйтте. Ул булмаганда ялган пәйгамбәрләр килеп чыгасын көт тә тор. Без мондый алыпсатарларның корбаны булудан туйдык инде, шуңа күрә партия кирәк, ә аны әзерлекле җәмәгатьчелектән һәм активтан башка оештыру мөмкин түгел. Шәрык зыялыларының бай тарихы бар. Ип. Сталин белән бергә мин алар каршында баш иергә әзер, ләкин аларның кимчелекләре хакында да әйтми кала алмыйм. Шәрык зыялылары — арадашчы элемент, алар Шәрыктә колонизаторлар коралы булдылар һәм шулай булып калалар. Безгә зыялыларны идеаллаштыру кирәкми, минемчә... Дөнья зыялылар җилкәсендә генә тора икән дип уйлау дөрес түгел. Әгәр алар үзләрен чыннан да дөньяның кендеге итеп тоя башласалар, бу һич тә яхшыга илтмәячәк. Шулай да мин аларны файдалану ягында, ләкин күзәтү астында...

Мин резолюцияне тулаем кабул итәргә, солтангалиевчелекнең сәяси авантюра булуын һәм мондый күренешләрнең якын киләчәктә дә котылгысызлыгын, аны китереп чыгарган шартлар белән көрәшергә кирәклегенә басым ясарга кирәк дип уйлыйм. Солтангалиевнең үзенә килгәндә, мин аны атаргамы, коткарыргамы дигән мәсьәләне резолюциядә күрсәтмәскә тәкъдим итәм.

Х а л и к о в. Солтангалиевнең соңгы эшләре хакында мин монда килер алдыннан гына ишеттем. Ләкин аның кайсыдыр гамәлләрен күпмедер беләм дия алам. Советлар съездына дип безгә килгәч, ул минем кыюсызлыгыма ишарәләде, аерым алганда, урыс иптәшләр белән бер булып эшләвебезне ошатмады. Ул миңа ныграк булырга киңәш итте. Аннары мин аңардан нәни генә язу алдым. Ул анда «безнең X съезддагы чыгышыбыз эзсез үтмәде. ҮК ахыр чиктә икенче палата төзү турында карар кабул итте» дип язган иде. Ул язуда игътибарга лаек башка нәрсә юк иде. Ләкин ул, бу язу белән бергә, йомышчы аша монда ип. Куйбышев искә алган хатны да җибәрде. Аны алып килгән кеше миңа бу хат турында әйтте һәм без аны укыдык. Ул башка иптәшкә адресланган иде. Анда ип. Куйбышев бәян иткән нәрсәләр язылган булып чыкты. Хатны укыгач мин шикләнә калдым: ҮК әгъзасы булмый торып, аның Үзәк Комитетта барган бәхәсләрне җентекләп тасвирлавына аптырадым һәм, дөресен әйтәм, хатка ышанмадым. Хат буенча нинди чаралар күрергә кирәк икән, дигән уй да килде. Ләкин шунда ук үземне туктаттым. Беренчедән, бу хатка ышанырга ярамый, икенчедән, чаралар күрү өчен дә җитәрлек нигез юк. Һәм мин аңа: хатыңны алдым, хәбәрләрең өчен рәхмәт, ләкин бу мәсьәлә буенча өзеп кенә бернәрсә дә әйтә алмыйм, съездга килгәч фикеребезне үзебез белдерербез, дип җавап яздым. Шуның белән эш беткән кебек булды. Ләкин хат шулай да шикле иде. Үтә яшерен булганга, без аның турында бернәрсә дә сөйләшмәдек. Менә шушы фактлардан чыгып, мин Солтангалиев легендар эшләр эшли, ахры, дип уйладым.

Бу хәлләрдән соң ул шифрланган хат җибәргән, анда партиясезләр белән элемтәгә керергә тәкъдим иткән һәм Вәлиди белән бәйләнеш урнаштырырга кушкан булып чыкты. Мин эшләр шулай тирәнгә китәр дип фараз кылмаган идем... Теге яки бу чараны уздырганда урыс иптәшләр басымы аркасында алар белән гаугалар чыккалады. Без моңа битараф калмый идек, билгеле. ҮКка еш-еш мөрәҗәгать иттек, хатлар яздык, аптыраттык... Ә менә Солтангалиев бөтенләй башка юлны сайлаган. Ул Вәлиди белән элемтәгә керергә, Дини Идарә, Төркия, Иран белән бәйләнешләр урнаштырырга чакыра икән. Без болар хакында беркайчан да уйламадык...

Шулай да бу урында теге яки бу басым аркасында, бөекдержавачыл шовинизм күренешләре нәтиҗәсендә канәгатьсезлекнең булуын әйтеп китәргә кирәк. Солтангалиевнең тамырын корытканда моңа игътибар итмичә булмый. Мин эш Солтангалиев белән генә бетмәс дип уйлыйм, шуңа күрә мәсьәләне «уңнар» һәм «суллар» яссылыгында гына карау дөрес булмас. Солтангалиев йөзендә уңнар кармакка килеп капты, дип аларны туздырырга керешү ярамас.

Башкортстанда гына түгел, башка республикаларда да панисламчыл оешмалар оештыру аркасында түгел, ә бөекдержавачыл шовинизм җирлегендә туган канәгатьсезлек яшәп килүен истән чыгару акланмас... Мин өлкә комитетында булган күпсанлы бәхәсләргә һәм гаугаларга кагылып тормыйм. Ләкин

хәлләр шактый катлаулы. Соңгы вакытта бездә ҮК вәкиле булып китте. Ул Советлар съезды пленумында ясаган чыгышында, башкорт милләтчеләре һәм башкорт милләтчелеге эшкә аяк чала, дип белдерде. Ә бит утырышта партиясезләр дә, чакырылган партиясез зыялылар да бар иде. Бу хакта өлкә комитетында, партиялеләр арасында сөйләргә ярый, ләкин партиясез урыс зыялылары каршында төкерек чәчү бер дә урынлы түгел. Мондый белдерүләрдән соң безнең халык арасында нинди абруебыз калсын?

Тагын бер мәсьәләгә тукталасым килә. Безне «вәлидичеләр» дип атап күзебезне ачырмыйлар. Югыйсә, без былтыр «Вәлиди — барып чыккан контрреволюционер, Совет властеның гына түгел, ә башкорт халкының да дошманы», дигән өндәмә белән чыккан идек. Вәлиди белән элемтәгә керү уебызга да килгәне юк, Урта Азия Бюросының аны аклавы хакында хәбәрне без нәфрәтләнеп укыдык. Бу хәбәр Төркестан гәзитләрендә басылган иде. Үзебез бу кешене контрреволюционер, башкорт халкының дошманы дип игълан итәбез, шул ук вакытта Урта Азия Бюросы аны аклый да Совет җиренә чыгарып җибәрә — моннан соң безнең нинди абруебыз калсын инде? Мин ип. Куйбышев резолюциясен кабул итәргә кирәк дип исәплим, ә менә интернационалистлар тәрбияләргә дигән өлешне уң яки сул төркемнәр төзүгә урын калдырмаслык итеп төзәтү начар булмас иде.

Фирдәвес. Иптәшләр, минем үз фикеремне Бөтенроссия съездларында һәм киңәшмәләрендә белдерү бәхетенә ирешкәнем юк иде, аны бүтән иптәшләр генә Үзәк Комитетка җиткереп тордылар. Мин берьюлы Солтангалиев эше буенча да, гомуми мәсьәләләргә дә кагылып сөйләргә телим.

Иптәшләр Солтангалиев мәсьәләсендә бер урында таптаналар. Монда ике караш булырга мөмкин. Беренчесе — суд тәртибендә тикшерү, бу очракта аны киңәшмәгә куярга да кирәкми иде. Икенчесе — ул партия эчке эшенең бер юнәлеше итеп карала һәм аны монда тикшерү табигый. Үзәк Контроль Комиссиясе һәм Үзәк Комитет мәсьәләне партия тормышы яссылыгында куя һәм шуңа күрә фикер алышу да шул кысада барырга тиеш.

Кайбер иптәшләр монда Солтангалиев эшчәнлегенең төрле кырларын бутадылар. Беренчесе — Вәлиди белән хат алышу, икенчесе — башка эшлекләләр белән хәбәрләшеп тору. Болар икесе ике нәрсә. Татарстан Республикасы һәм Башкортстан белән бәйле Солтангалиев Вәлиди турында хатлар алышырга вәкаләтле иде. Монда башка этәргеч көчләр дә булырга мөмкин. Үз вакытында Солтангалиев, партия Үзәк Комитеты рөхсәте белән, яшерен юллар аша башкорт частьларын Совет власте ягына чыгаруны тәэмин иткән иде. Моннан тыш, Солтангалиев белән Вәлиди — сабакташлар, икесе дә Башкортстаннан. Мин алар арасында хат язышу өчен төрле, шул исәптән, шәхси сәбәпләр дә булырга мөмкин, дип әйтмәкче булам. Аларның Совет һәм партия мәнфәгатьләреннән караганда ни дәрәҗәдә законлы булуы — монысы икенче мәсьәлә.

Солтангалиевнең Вәлиди белән элемтәгә керергә маташуын Төркестан, Кавказ белән, башка иптәшләр белән бәйләргә ярамый...Чөнки ул Кырымга хат язган очракта, анда Вәлиди мәсьәләсен күтәргәндер дип уйламыйм. Моның булуы мөмкин түгел. Язышуларның һәммәсен бер өемгә өяргә ярамый — моңа ачык хисап бирүебез хаҗәт.

ҮК Солтангалиевкә каршы йомшаклык күрсәтә, дигән иптәшләрне мин аңлый алмыйм. Эш болай тора. Үзенең резолюциясен нигезләр өчен Үзәк Контроль Комиссиясе бернинди дә анализ ясамаган, Солтангалиевнең эшчәнлеген, солтангалиевчелекне китереп чыгара торган шартларны һәм сәбәпләрне өйрәнмәгән. Чыгыш ясаган иптәшләр хәлгә социаль-икътисадый анализ бирергә тырышып карадылар, билгеле. Ә гомумән алганда, нигезле тикшерү булмады...

XII съездга кадәр милли мәсьәлә сәясәтендә бер читтән икенче читкә ташланулар күп булды. Бездә декларатив платформа гына бар иде. Моңа кадәр хәтта җитәкче органнарда эшләүче хезмәткәрләр дә анык кына бернәрсә дә белмәделәр. XII съезд исә боларның барысын да үз урыннарына утыртты. Бер генә мисал китерәм. Берзаман югары даирәләрдә Милләтләр Эше Халык Комиссариатын бетерү хакында шаулашып алдылар. Озак бәхәсләрдән соң аны әлегә калдырырга карар кылынды. Хәзер бу мәсьәлә яңадан алга килеп басты. Чөнки автономияле республикалар вәкилләкләренең икенче формасы барлыкка килде. Мин бу мисалны безнең милли сәясәт өлкәсендә анык кына юлыбыз булмавын төшендерү өчен китердем.

Шәрыктә пролетар революциясе үсешенә һәм андагы эшлекләләргә Мәскәү һәм Петроград эшчеләре каланчасыннан карарга кирәкми. Мин монда көнчыгыш эшлекләләрен «уңнарга» һәм «сулларга» бүлүнең мәгънәсезлеген күрсәтмәкче

булам. Сул эсерлар белән әшнәлек итүдә уннарны сүгеп килгән суллар, бу эсерлар партиягә кергәч, алар белән союз урнаштырдылар. Берләшү өчен алшартлар, нигез кайда монда? Билгеле, бернинди нигез дә юк.

Ип. Ибраһимовның чыгышы хакында берничә сүз әйтмәкче булам. Ул безнен арада дөньяда тиңе булмаган сул буларак танылды. Әгәр аның килеп чыгышын, Мәскәү белән элемтәсен барласаң — бу закончалыклы. Ләкин ип. Ибраһимов тәхет шаүләсен, Кырым тәхетен шәйләп өлгерүгә үк үзенең мәсләген үзгәртте. Ибраһимовның мина Татреспубликада да, үзәктә дә эшләргә ирек бирмәвен барыбыз да беләбез. Һәм шушы хәлләрдән соң ул үзенең элеккеге тарафдары Сәетгалиевне бәреп төшерү өчен жирлек әзерләргә тәкъдим итеп хат яза, кирәк булса, партиясезләрдән оппозиция тупла, дип киңәш бирә. Бу хакта материаллар бар, үз вакытында мин аларны Үзәк Комитетка тапшырдым. Мин моны ип. Ибраһимовны гаепләр өчен түгел, ә «уңлыкта» да, «суллыкта» да чикләрнең ачык билгеләнмәгән булуын күрсәтү өчен генә сөйлим. Көннәрдән бер көнне бу суллар уңнар белән берләшергә яисә шунын капма-каршысын эшләргә мөмкиннәр. Бу Шәрыктә милли сәясәтнең адым саен абынуыннан килеп чыкты. Шуңа күрә бу киртәләрне узу өчен революцион үсешнең һәр чорында муафыйк формалар сайларга кирәк булды. Ә аны табуы бик кыен. Мин, әле Солтангалиев белән танышканчы ук, Симферопольдә үзәктәге кебек Мөселман Комиссариаты төзедем. Ул нәкъ Петроградтагы, Мәскәүдәге һәм Идел буендагы комиссариатларның нигезәге кебек иде. Суллар теш-тырнаклары белән моңа каршы чыкты. Аннары Колчакка каршы сугышу чоры. Мөселман частьлары төзү хаҗәте туды. Суллар тагын күтәрелеп бәрелделәр. Аларның азмы-күпме тыйнаклык күрсәтүләре нигилизмнарында һәм анархист булуларында гына күренде. Алар, бернинди милли мәсьәлә дә юк, барысы да үзеннән-үзе бара, дип уйладылар. Бу дөрес түгел.

Мин тәмамлыйм, иптәшләр. Монда чыгыш ясаучыларның күбесе Солтангалиевнең фәкать Вәлиди белән элемтәгә керергә тырышуына гына тукталдылар. Аның бу омтылышын бөтен Советлар Республикасына фаш итүдән мәгънә юк. Солтангалиев рәсми кеше, ул Сталин белән дә, башка эшлекләләр белән дә элемтәдә торды. Мин Сталинның, Кавказга килгәч, аңа хат язуын бик яхшы хәтерлим. Шуңа күрә аның барлык бәйләнешләрын шик астына алу һич тә дөрес түгел. Солтангалиевнең Вәлиди белән элемтәгә керергә маташуын тикшерү — криминалистлар эше. Әгәр без аны партия тәртибендә тикшерәбез икән, хөкем карары чыгарырга кирәкми. Без мәсьәләне идеология яссылыгында куябыз.

Р ә и с. ...Иптәшләр Вәлидовны аклау турында хатны укуны сорыйлар. Менә ул:

«Үзенең кылган гамәлләре өчен үкенүе хакында Вәлидидән хат алынгач, Урта Азия бюросы мәсьәләне тикшерде һәм РКП Үзәк Комитетына: «Вәлидов акланган очракта, әйләнеп кайту хокукын югалтып, Урта Азиягә сөрелергә тиеш», дип хәбәр итте. Бернинди дә амнистия булмады. Хыдыралиев».

Искәрмәләр

1. Әдһәмов Габдулла (1897—1968) — 1920 елдан партия әгъзасы. 1921—1923 елларда Башкортстанның эчке эшләр, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау халык комиссары. 1930 елда «Солтангалиев эше» буенча 5 елга хезмәт белән төзәтү лагерена хөкем ителгән.

2. Әхмәтзәки Вәлиди (1890—26.VII.1970). 1917—1918 елларда Башкортстан хөкүмәтенә һәм аның кораллы көчләренә житәкчелек итә. 1919 елның февралендә Совет хөкүмәте белән килешү нәтижәсендә (сөйләшүләрдә М. Солтангалиев тә актив катнаша) аның ягына чыга. РКП(б)га керә, күп тапкырлар Ленин һәм Сталин белән очраша, Башкорт Совет республикасын төзүдә күренекле роль уйный, аның Хәрби-революцион комитеты рәисе була. 1920 елның җәендә, Башкортстанның хокукларын чикләү мәсьәләсендә Үзәк белән сәяси низагка кереп, кайбер хөкүмәт әгъзалары белән берлектә, протест йөзеннән үзенең постыннан китә. 1920 елның август ахырында һәм сентябрь башында яшерен рәвештә Бакуга килә һәм монда шәрык халыклары корылтаенда катнаша, М. Собхи һәм Әнвәр паша белән очраша. 1920 елның сентябреннән 1923 елның мартына кадәр Урта Азиядә Совет властена каршы кораллы көрәштә катнаша. Соңрак Иранда, Берлинда, Парижда, Боннда, Истанбулда укытучылык хезмәте һәм фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнә. Истанбул университе-

тында укыта. 1953 елда Истанбулда Ислам тикшеренүләре институтына нигез сала. Тюркология һәм мөселман дөньясы үсешенең гомуми проблемалары өлкәсенә караган 300 дән артык хезмәт яза.

3. Тәржеманов Кашшаф (1877—1942) Уфада мөселманнарның диния нәзарәте рәисе урынбасары. Күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, галим. Әдәбиятчы, мөфти Р. Фәхретдиневнең якын хезмәткәре. 1936 елда кулга алына. Тоткынлыкта үлә.

4. Җәләл Садретдин. Солтангалиевнең чит илдәге адресатларыннан берсе. Аңа атап язылган хат ГПУ кулына төшә. Төрек коммунисты, Истанбул университеты укытучысы. Коммунистик эшчәнлеге өчен укыту хокукыннан мәхрүм ителә һәм 1925 елның августында, Назыйм Хикмәт һәм бер төркем тарафдарлары белән, Анкара трибуналы тарафыннан озак вакытка төрмәдә утыруга хөкем ителә.

5. Рыскулов Торар (1894—1938) — 1917 елдан партия әгъзасы. 1923 елда Төркестанда житәкче партия-дәүләт эшендә. Соңрак РСФСР Халык Комиссарлары Советы рәисе урынбасары. 1938 елда атып үтерелә.

6. Сәетгалиев Сәхипгәрәй (1894—1938) — 1917 елдан партия әгъзасы. 1923 елда Кырым АССР Халык Комиссарлары Советы рәисе. Соңрак партия һәм хуҗалык эшләрендә. 1938 елда атып үтерелә.

7. Ибраһимов Шаһимәрдән (1899—1957) — 1915 елдан партия әгъзасы. 1921—1923 елларда Кырым эшләре буенча РСФСР Халык Комиссары Советы һәм Үзәк Башкарма Комитет комиссиясе рәисе. Соңрак РСФСР Үзәк Башкарма Комитеты каршында Башкортстан вәкиле, ВКП(б) Үзәк Комитеты инструкторы, Төрекмәнстан Компартиясе ҮК секретаре.

8. Духонин Николай (1876—1917) — генерал-лейтенант. ХКС таләбен үтәргә теләмәгән өчен солдатлар тарафыннан атып үтерелә. Гражданнар сугышы елларында «Духонин штабына жибәрү» үлемгә хөкем ителү символы була.

9. Шәмигулов Гали (1890—1959) — 1910 елдан партия әгъзасы. 20 нче еллар башында Башкортстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы рәисе, Шәрык халыкларының коммунистик оешмалары бюросы әгъзасы, соңрак хуҗалык эшендә.

10. Енбаев Гариф (1892—1937) — 1919 елдан партия әгъзасы. 1923 елда Татарстан АССРның жир эшләре халык комиссары урынбасары, Татарстан Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы. «Солтангалиев эше» буенча 1929 елда кулга алына. Атарга дигән хөкем 10 ел хезмәт белән төзәтү лагерьларына алыштырылгач, Соловки махсус лагерында утыра, шунда ук атып үтерелә.

11. Хыдыралиев Инагожан (1896—1937) — 1919 елдан РКП(б) әгъзасы, Төркестан ҮБК рәисе.

12. Икрамов Акмал (1898—1938) — 1918 елдан партия әгъзасы. Төркестан Компартиясе ҮК секретаре. Соңрак Үзбәгестанда житәкче партия эшендә. 1938 елда атып үтерелә.

13. Хуҗанов Солтанбәк — 1920 елдан РКП(б) әгъзасы. 1922—1925 елларда Төркестанда төрле җаваплы вазифалар башкара.

14. Халиков Муллаҗан (1894—1940) — 1919 елдан партия әгъзасы. 1923 елда Башкортстан Халык Комиссарлары Советы рәисе. Соңрак хуҗалык эшендә. 1937 елда репрессияләнә.

15. Фирдәвес Исмәгыйль — 1917 елдан партия әгъзасы. 1923 елда Кырым АССРның гаделия халык комиссары. Соңрак хуҗалык һәм идарә эшләрен башкара. 1929 елда кулга алына. «Солтангалиев эше» буенча атарга хөкем ителә. Үлем карары алыштырылгач, Соловки махсус лагерында утыра. 1937 елда шунда ук атып үтерелә.

Ахыры киләсе санда

# МОҢ ТУЛЫ ЯЗМЫШ...

ӘХМӘТ ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Аяз төндә күк гөмбәзенә күз текәп сокланмаган кеше бармы икән? Анда бихисап йолдызлар. Араларында чәчрәп балкып торганнары да аз түгел.

Әгәр халкыбызның әдәбият-сәнгатен мәгълүм бер микъдарда күк гөмбәзенә охшатып фикер йөртә алсак, андагы иң якты йолдызларның берсе, милләтнең паспортын тәшкил итүче затлардан булган Әхмәт Фәйзине дә күрер идек.

Ул — бөек Тукайга әдәби һәйкәл салышып, аның хакында беренче романны биргән шанлы прозаик.

Ул — күп санлы каһарман образларын зур осталык белән гәүдәләндерә алган драматург.

Ул — тапкыр телле, уен-көлкегә дә, чәнчү-чеметүләргә дә бай шагыйрь.

Ул — дәртле-ялкынлы публицист.

Ул — бер укудан хәтер түренә кереп оялардык итеп балалар өчен язган күркәм шагыйрь.

Ул — опера һәм балет сәнгатен татар җирлегендә булдыру өчен җан аямый тырышкан фидакарьләрнең берсе, милли опера, милли балет өчен либретто язуның тәүге үрнәкләрен биргән шәхес, классик музыка һәм совет музыкасы авторларының вокаль әсәрләре сүзләрен туган телебезгә тәрҗемә итүче оста.

Ул — музыкаль сәнгать әһелләренең якын дусты, музыкаль сәнгатебезнең бүгенгесе һәм туар таңнары турында ихластан борчылып гомер кичергән олы җанлы сәнгать эшлеклесе.

Күрәсез, аңардагы талант, белем, тоемлау, тәҗрибә һәм күрәзәлек дистәләгән сәләт иясенә җитеп ашкан иде.

Әхмәт Фәйзи минем күңелемә беренче тапкыр 1939 елда кереп, түрдән үк урын алды. Шул елның язында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында аның «Тукай» драмасы сәхнәләштерелде. Тамашаның эчтәлеге дә, артистларның башкару осталыгы да мине тетрәндергән иде. Тукай яшәп киткән чор реаль гәүдәләндерелгән. Халык шагыйрен җанлы шәхес итеп сурәтләгән, аны пьедесталга күтәрмичә генә бөеклеген ассызыклаган авторны күрәсем, аңа ихластан рәхмәт укыйсым килде. Әмма ул чакта күрешү-сөйләшү насыйп булмады.

Әхмәт Фәйзи исеме Җәүдәт Фәйзи гаиләсендә телдән төшми иде.

— Кичә Әхмәт Фәйзи килгән иде, бик кызык әңгәмә кордык...

— Әхмәт Фәйзи опера өчен «Сафа» дигән либретто язып тәмамлаган...

1944 елда Җәүдәт Фәйзинең «Акчарлаклар» музыкаль комедиясе сәхнә күрде. Бу әсәр тамашачы күңеленә чын мәгънәсендә хуш килде. Әхмәт Фәйзи иҗат иткән либретто моңга-көйгә бай, яшәү дәрте белән сугарылган музыка өчен уңдырышлы туфрак, таянырлык җирлек булып чыкты. Спектакльдәге «Зәйтүнәкәй», «Кәккүк» җырларын халык бик тиз отып алды, үз итте, өзми дә куймый җырлый башлады. Фәйрүзә ариясе концертларда еш яңгырады. Бу премьерадан соң Әхмәт Фәйзине күрү теләгем отыры көчәйсә дә, тиз генә күрешергә язмаган икән.

Әхмәт абый белән бары тик 1945 елның җәендә, ул Мәскәүдән кайткач, Татарстан радиотапшырулар комитетының әдәби тапшырулар редакциясендә таныштык. Сөенечлесе шул, беренче күрешүдән үк дуслар булып киттек. Бу дуслык, музыка сәнгате өлкәсендә бергә киңәш-табыш итеп эшләү Әхмәт абыйның соңгы көннәренә кадәр дәвам итте.

Әхмәт абый Фәйзи Мәскәүдә яшәде, әмма Казанга еш кайтып йөри иде.

Татарстан башкаласына кайтканда — без гел бергә була идек, ул Мәскәүдә чагында исә ике арада хатлар өзелмәде.

1945—1958 еллар. Бу — безнең үзара мөнәсәбәтләр өчен гаҗәеп бер чор: Әхмәт абыйның «Тукай» романының беренче китабын тәмамлавы, «Рәүфә» драмасын иҗат итүе, «Җәлил» операсының һәм «Кисекбаш» балетының либреттоларын язуы, нәфис фильм текстларын татарчага тәрҗемә кылу чоры. Без бу чорда бик аралашып яшәдек. Әле генә санап киткән хезмәтләре өстенә, «планнан тыш» мәшәкатьләр дә өелә торды. Яңа җыр текстлары язылды, байтак классик җыр, романс сүзләре татарчага тәрҗемә ителде.

Казанга килгән көннәреннән байтагын Әхмәт абый Тукай замандашлары белән очрашуга багышлый иде. Мин аның Вафа Бәхтияров, Габбас Сәйфуллин белән берничә тапкыр очрашуларын хәтерлим.

Тукай турында истәлекләр туплауның шактый авыр булуын, бу шөгыльдә сабырлык, түземлек кирәклеген Әхмәт абый үзенә генә хас бер юмор белән сөйли иде.

— Яңа Бистәдә берничә таныш карчыгым бар. Алар Тукайны хәтерлиләр. Шулар янына барам. Күчтәнәчсез булмый инде. Мәскәүдән дөге, йөзем алып кайтам үзләренә.

Ул шул карчыклар белән сәгатьләр буе сөйләшеп утыра икән, кайчагында үзенә кирәк бер сүз дә ишетмичә кайтып та китә икән.

Иртәнге-көндезге сәгатьләрдә Әхмәт абый иҗат итә. Эшләп арыгач, кичкә таба, дуслар белән очрашулары була. Опера җырчысы Шәфика Котдусова, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең беренче сәнгати җитәкчесе Зөләйха Әхмәтова белән аеруча еш очраша. Сүзләрдә төп тема, мәгълүм инде, музыка, матур әдәбият. Бик гадәти-табигый хәл, Зөләйха Әхмәтова хор өчен яңа җырлар язуын үтенә. Шул рәвешле алар озын-озак итеп гәпләшәләр. Мин исә андый вакытларда читтәрәк сүзсез генә утырам.

Әдип ансамбльнең хор җырчылары белән дә еш очраша, алардан «онытылган» көйләрне искә төшереп җырлауларын гозерли, үзе җыр осталарына яңа шигырьләрен укый...

Әхмәт Фәйзи халыкның музыкаль иҗаты белән тирәнтен кызыксына иде. Шуның бер күркәм дәлиле — «Рәүфә» драмасына «Сибелә чәчәк» җырын кертүе.

1956 елда Бөтенсоюз радиосыннан музыкаль комментатор килгәч, Әхмәт абый аның белән татар халык көйләреннән төзелгән концертны русча аңлата барулы тапшыру оештыру хакында сүз алып барды. Моның максаты гаять бай музыкаль хәзинәбезне бүтән халыкларга да төшендерергә омтылу иде, әлбәттә. «Татар халык музыкасының гүзәллеген башка халыклар белән уртаклашыйк. Көйләргә комментарийларны үзем хәзерлим»,— диде. Хәзер инде өзеп кенә әйтә алмыйм, нинди дер сәбәп белән ул теләк-омтылыш гамәлгә ашмый калды.

Опера дөньясының атаклы башкаручысы Шәфика Котдусова өендә Әхмәт абый белән берничә мәртәбә булдык.

Шәфика ханым — яхшы пианистка. Үзе уйнап җырлый. Алябьевның Әхмәт абый тәрҗемә иткән мәшһүр «Сандугач» романсын рәхәтләнеп башкара, аннары куанып көлә...

1952 елның соңгы кичендә Әхмәт абый, артист Камал III, мин — өчәү Шәфика Котдусова өендә булдык. Күңелле генә гәпләшеп утырганда, сүзебез яшәү һәм үлем мәсьәләсенә күчте. Фидакарь хезмәт кешене үлемсез итә дигән фикергә ялгап, Шәфика бер француз язучысының әсәрендәге сүзләрне хәтергә төшерде: яшьләй вафат булган зат кешеләр күңелендә мәңге яшь, матур булып саклана. Картаеп үлгән кеше хәтердә карт булып калачак... Мин яшьләй үлү ягында, тик хезмәтең зур булсын, ди. Кешеләр рәхмәтен ишетерлек, гадел, югалмас хезмәт...

Әхмәт абыйның бу фикергә мөнәсәбәте тәгаен генә истә түгел, әмма хезмәтнең зур булырга тиешлелеге белән ул, һичшиксез, килешкәндер дип беләм.

Ул көнне без кичке тугызларда таралыштык. Яңа 1953 елны һәркем үз гаиләсендә каршыларга теләде.

Менә хәзер дә радиодан Әхмәт Фәйзи шигырьләренә Җ. Фәйзи, Н. Җиһанов, А. Ключарев җырлары башкарыламы, Ф. Яруллинның «Шүрәле», Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетларыннан өзекләр уйналамы, күз алдымнан дулкын-дулкын булып онытылмас күренешләр уза башлый.

Әхмәт абый. Озын буйлы, ыспай гәүдәле, ак йөзле. Зәңгәр күзләре күзлек артына яшеренгән. Иреннәре кабарынкы. Карлыкканрак калын тавыш белән мөлаем сөйләшә. Җиңел хәрәкәтләрендә, кешеләргә мөрәҗәгатендә, зәвыклы киенүендә зыялылык күзгә ташлана.

Казанга килгәндә, сеңелесе Зәйнәптә тора. Зәйнәп апа — язу машинкасында оста басучы. Ул — Әхмәт абыйның иң якын ярдәмчесе, иҗаты өчен уңай шартлар булдыручы. Алар Казан каласының үзәгендә — Бауман урамында торалар, заманында иске Казанның Европача бай җиһазландырылган «Бристоль» номерлары булган йортта. Әмма бу ташпулатның күркәмлеге югалган инде. Кайчандыр балкып торган кунакханәнең бер кечкенә бүлмәсендә Әхмәт абый бирелепонытылып, ихластан мавыгып, тәм табып иҗат итә. Бүлмәдә гади бер өстәл, гапгади карават, китаплар этажеркасы кырыенда телефон. Бирелә Н. Җиһанов, Ә. Еники, Х. Сәлимҗанов, Камал III бик еш булалар. Ә «Бристоль»га каршы йортта (хәзер ул йортның беренче катында Татар ашлары йорты кибете), икенче катта, безнең гаилә яши иде. Фатирларыбыз каршы күрше булгангамы, Әхмәт абый миңа: «Зәйнәп күрше!» — дип эндәшүчән иде. Кышларын көндез эшләп талчыккан Әхмәт абыйның мине шәһәр урамнарыннан урап кайтырга чакыру гадәте бар иде. Ул: «Зәйнәп күрше, әйбәт күрше, әйдә чык урамга, үзеңне көтәм, Кремль буйларында йөреп, саф һава сулап кайтыйк», — диючән иде. Очрашкач, мәгълүм инде, хәл-әхвәл сорашу китә, көнелле гәпләшү, уен-көлке башлана. Әхмәт абый телгә гаҗәп җор, фикергә-сүзгә искиткеч тапкыр, теләсә кайсы сорауга диярлек бик тиз җавап бирүчән зат иде.

Әхмәт Фәйзи ага сырхаулап киткәч, аның янына, язучыларның «Аккош күле»ндәге дачаларына барганым хәтердә. Күңелен бераз күтәреп булмасмы диптер инде, аның өс-башын мактый башладым.

— Әхмәт абый, Сез бүген үтә зәвыклы киенгәнсез, билләһи! Зәңгәр буй-буй пижама, чалбарыгыз куе зәңгәр, зәңгәр күзләрегезгә бик иш, бик тә килешә.

— Зәңгәр Әхмәт булып чыгам! — диде ул. — Безнең әдәбиятыбызда Кара Әхмәт бар. Менә инде Зәңгәр Әхмәт тә булды!..

Янә дә кайбер хатирәләр.

1951 елның җәе. Без Обсерватория урманы аланлыгында. Игътибарны тарткан ромашкаларның җилдә талгын гына тибрәнүләре. Әхмәт абый күләгәдә ятуны хәерлерәк күрде. Ерактан Шәфика Котдусова тавышы ишетелде. Ул, Алтынчәч ариясен жырлый-жырлый, Әхмәт абыйга якынлаша.

— Урманда, болында тавыш үзеннән-үзе чишмәдәй агыла. Җырлавы җиңел, рәхәт! Гаҗәп хәл: ария бер тавышка жырлана монда. Күңелле бит?!

Әхмәт абый елмая. Җырчыдан Алябьевның «Сандугач»ын жырлавын гозерли. Табигать үзе сәхнә дә, оркестр да...

1956 елның 21 апрелендә без, бер төркем әдәбият-сәнгать әһелләре, Казан аэропортында Мәскәүдән Шәфика Котдусова табутын алып кайтучы самолетны көтәбез. Әхмәт абый Шәфика ханымның яшьли үлү хакындагы сүзләрен хәтерендә яңарта:

— Мәрхүмә яшьләй үлүне яклаган иде. Безнең күңелләрдә ул мәңге яшь, һәрвакыт көләч, һәрвакыт шат Шәфика, олы сәнгатькә бар булдыгы белән гашыйк Шәфика булып сакланыр, — диде.

Олы әдипнең кешеләргә бик игътибарлы һәм ихтирамлы булуын, кайгыртучанлыгын, дуслыкка тугрылыгын ассызыклап әйтәсем килә. Берзаман көтмәгәндә Нәкый ага Исәнбәткә карата янә һич урынсыз гаепләүләр кузгалды. Партия өлкә комитетыннан зәһәр җилләр исте. Әхмәт абый шул көннәрдә Казанга килеп төшүе белән әйтте:

— Зәйнәп, мин бүген үк Нәкый ага янына барам. Аның янында булырга кирәк, хәленә керү зарур, — диде.

Мин аның Кави Нәҗми үлемен авыр кичерүен хәтерлим.

Якшәмбе көн иде. Көндезге сәгать өч тирәсе. Телефон шылтырый. Трубкадан калын карлыкканрак тавыш килә. Әхмәт абый икән.

— Зәйнәп, дусларыбызга, бер-беребезгә игътибарлы булыйк, — ди. Бу сүзләрнең ник әйтелүен төшенә алмый тордым. Дәшмәдем.

— Бик якын кешебезне югалттык, — диде шуннан соң Әхмәт абый. — Хәзер генә Кави үлгән...

Әдип миннән гел республикабызның музыкаль тормышы яңалыкларын сорашучан иде. Спектакльләрне бергәләп караганда да андагы музыка турында җанлы фикер алыша идек. Әйтик, Нәҗип Җиһановның «Зөһрә» балетының беренче спектаклен бергә карадык. Кайту юлында сүз гел шул хакта булды. Ә берничә көннән «Кызыл Татарстан» газетасында икебезнең уртак фикеребез — рецензия дөнья күрде.

Бер әңгәмә онытылмый.

— Әхмәт абый, — дип мөрәҗәгать иттем мин мөхтәрәм әдипкә. — «Тукай һәм музыка» дигән темага концерт-лекция оештырырга тәкъдим иттеләр. Тыңла-

учыларны мавыктырырлык итеп сөйлисе иде. Башланып китүе-үк үзенчәлекле булсын иде. Ничек башлыйм икән лекциямне?

— Ә син Тукайның үз сүзләре белән башла,— диде бик тыныч-сабыр гына ул.— «Мин кечкенәдән үк җырчы идем» дип башласаң, тыңлаучы шундук колак салыр. «Халык әдәбияты» турындагы мәкаләсенең эпилогы-хатимәсендә ул бит шулай — «Мин кечкенәдән үк җырчы идем»,— ди.

Нәкъ Әхмәт абый киңәшенчә эшләдем. Концерт-лекцияне халык яратып кабул итте.

1955 ел. Татарстан композиторларының II съездында миңа республикада музыкаль пропаганданың торышы турында доклад ясау йөкләтелде. Әлеге җавапгы чыгышым да Әхмәт ага Фәйзинең эшлекле ярдәме белән әзерләнде. Ул үзе дә съездда таләпчәнлек белән сугарылган бай эчтәлекле чыгыш ясады.

Башкортстан радиосы белән бәйрәмнәргә багышланган алмаш концертлар оештырырга карар иттек. Беренче концерт. Аны ничегрәк башларга? Әхмәт абыйдан башкорт дусларга котлау сүзе әйтүен үтендем. Ул ризалык бирде. Әхмәт Фәйзинең «Әдипнең эрудициясе» дигән җыентыгында басылган «I Май тәбриге» (216—217 битләр) дигән җылы дуслык, туганлык тойгысы белән сөйләнгән чыгышы әнә шулай язылды.

Әхмәт абыйның Казанга килүен (төгәлрәге — кайтуын) без, Татарстан радиокомитетының музыкаль редакциясе хезмәткәрләре (музыка белгече Мәһинур Җиһаншина, композитор Исмай Шәмсетдинов, мин), һәрвакыт бик көтеп, зарыгып-сагынып каршылый идек. Ни гаҗәп, кәефләребезнең нинди генә чагы булмасын, ул килеп кердеме, күңелләребез күтәрелеп китә иде. Чөнки ул юморга бик бай, сөйләшүендә уен-көлке ташып тора, матур итеп шаяра һәм шаярта белә иде. Аның юморында үзебезгә карата үткен тәнкыйть тә ишетә идек. Хаталарны кабатламас өчен кыйммәтле киңәшләр дә бирә иде ул. Акыллы кисәтүләр ясаудан да тартынып тормас иде. Шул ук вакытта безнең музыкаль әсәрләргә карата уй-фикерләребезне белешерге дә өлгерә иде.

1957 елның язы. Әхмәт абый Фәйзи безнең редакциягә кечкенә гәүдәле, түгәрәк йөзле бер кеше белән килеп керде.

— Язылып ята торган «Кисекбаш» балеты авторы, профессор Г. И. Литинский шәкерте, композитор Рәшит Гобәйдуллин,— дип таныштырды.— Яңа балетның музыкасы белән иң әүвәл сез танышыгыз әле...

Тапшырулар студиясенә күтәрелдек. Рәшит Гобәйдуллин яңа балетыннан өзекләр уйнады. Ә шаяру-мәзәк яратучы Әхмәт абый балет персонажларының берсе булып бии. Куллары югары күтәрелә, аяклары әле як-якка сузыла, әле бер урында тыпырдый...

Җитди сүзгә күчтек.

— Музыка бию өчен җайлымы?

— Музыкада Тукай чоры аһәңнәре ишетеләме?

— «Кисекбаш» поэмасындагы сатира балетта ничегрәк чагылыр икән?

Яшь композиторга Тукай дәверендә яңгыраган, бөек шагыйрь үзе искә алган халык көйләрен тыңлаттык. 1958 елның сентябрендә «Кисекбаш» балеты Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә куелды. Ни үкенеч, Әхмәт абый ул балетны күрә алмады. Репетицияләр барганда ул инде каты авыру иде, ә август аенда без әдип белән мәңгегә хушлаштык.

Радионың музыкаль редакциясендәге очрашулар, гадәттә, шагыйрьгә үтенечгозер, тәкъдимнәр белән очлана иде.

— Әхмәт абый, редакция тынычлык турындагы җырларга бик мохтаҗ, ярдәм итсәгез иде?

— Сезнең белән киңәшкәннән соң Салих Сәйдәшев турында спектакль әзерләүне планга керттек. Сценарий язуны тизләтә алмассызмы?

Сөйләшүләрнең берсендә һәм миңа язган хатында Әхмәт абый мондый фикер әйткән иде: «Үлгән чагында аның баш очында торган бердәнбер кеше буларак, миңа бу тема бик якын... Сәйдәшне аның мещаннарча баш иючеләреннән аерып алып, музыка өлкәсендә еракка-еракка күзе җиткән кеше иттереп бирсәк, ничек булыр?» Шәхеснең олылыгына бик тирән караш иде бу!

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары «Салих Сәйдәшев» радиопостановкасын ифрат тырышып әзерләделәр, бик бирелеп уйнадылар. Әлеге постановка сөекле композиторыбыз образын сәнгатьчә гәүдәләндерүдә беренче адым иде.

Бервакыт Әхмәт абый Фәйзигә:

— Менә бу классик романсларны татарча җырлатасыбыз килә. Текстларын тәрҗемә итәргә вакыт таба алмассызмы? — дип мөрәҗәгать иттек.

Казанга килгәч, аның вакыты сәгатьләп бүлеп куелган булса да, ул музыкаль сәнгатебез өчен мөһим эштән баш тартмады. «Ярый, тәржемәләрмен»,— диде һәм вәгъдәсендә торды.

Халык көйләренә сүзләр язуы белән дә бик мәгълүм Әхмәт абый. Хәзерге заман көйләреннән «Аккош» һәм «Умырзая»ны халык аның сүзләре белән жырлый.

Аның тагын бинниһая зур бер хезмәте хакында әйтми булмый.

«Патриот шагыйрьгә — музыкаль һәйкәл!» — «Җәлил» операсын киң җәмәгатьчелек шулай югары бәяләде. Композитор Нәҗип Җиһанов белән Әхмәт Фәйзинең гаять зур уртак тырышлыгы гүзәл нәтиҗәгә китерде. Опера-монолог иҗат ителде. Үзәктә бер герой — шагыйрь. Муса Җәлил күпкырлы холык иясе булып сурәтләнә анда. Иң мөһиме — көчле рух, сынмас ихтыяр, илгә, туган халкына керсез мәхәббәт.

Музыкаль һәм әдәби яктан жиренә житкереп, нәфис эшләнгән бу әсәр Казанда гына түгел, Мәскәү Зур опера театрында һәм Прага опера театрында да куелды.

Татар дәүләт опера һәм балет театры үзенең яшәешен Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы белән башлап җибәргән иде. Композитор исеме белән янәшә либретто авторы Әхмәт Фәйзи исеме тора. Халкыбызның азатлык өчен көрәше — татар крестьяннарының Пугачев явында актив көч булуын чагылдырган опера либреттосыннан соң Әхмәт абый тагын бер тапкыр тарих төпкеленә мөрәҗәгать итте, татар һәм башкорт халыкларында киң таралган «Зөлхәбирә бәете» һәм «Картада оттырылган Зөлхәбирә» исемле легендага таянып, «Зөлхәбирә» дигән драматик поэма язды. Бу әсәр композитор Мансур Моззаффаровны опера язарга рухландырды. (Мансур аганың иң соңгы әсәре булган бу операны — «Зөлхәбирә»не — Казан консерваториясе студентлары 1992—1993 уку елында киң җәмәгатьчелеккә күрсәтергә җыеналар. Алар үзләренең күмәк хезмәтләрен профессор Мансур Мозаффаровның 90 еллыгына багышлыйлар).

Күренекле әдип Әхмәт Фәйзинең иҗат эшчәнлегендә классикларыбыздан Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Әмирханның татар музыкасына житди игътибарының, профессиональ музыка сәнгатен булдыру, аны үстерү хакындагы ихластан кайгыртуларының дәвамы чагылыш таба. Бу җәһәттән караганда Әхмәт Фәйзи Муса Җәлил белән янәшә тора. Күңелләребездә дә бу ике гигант янәшә яшиләр, яшәячәкләр.

**Зәйнәп ХӘЙРУЛЛИНА,**
Татарстан Республикасының
атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Латин графикасы нигезендә*
*татарча уку күнекмәләре*

Бу санда без Мәҗит Гафуриның «Совет әдәбияты» журналында (№№ 9—10, 1936 ел) моннан 57 еллар элек басылып чыккан хатын урнаштырабыз. Редакция искәрмәсеннән күренгәнчә, ул хат журнал редакциясенә шул чорда гына килеп ирешкән булган. Хат текстындагы бер биш-унлап сүзнең бүгенге укучыларга аңлашылып җитмәве дә мөмкин, әмма без аларны шәрехләп торуны кирәк тапмадык, чөнки аннан гына эчтәлеккә зыян килми дип исәплибез.

Хат тексты, техник сәбәпләр аркасында, бераз гына кыскартылып бирелә.

Редакция искәрмәсе.

## MƏÇID ƢAFURI XATЬ

Ataqlь tatar xalьq şaƣire Məçid Ƣafurinьꞑ əsərləren, qul-jazmalarьn ʙarlav, likşery, tərtipkə salu həm anьꞑ içadьn ɵjrəny ʙujьnca Ufada ʙer nicə iptəş (Səjfi Qudaş, Zəhrə Ƣafuri h. ʙ.) nьq eş alьp ʙaralar. Məçid Ƣafurinьꞑ ʙu xatь „Sovet ədəʙiatь“ redaksiəsenə Səjfi Qudaş həm Zəhrə Ƣafuri (şaƣirneꞑ tormьş iptəşe) iptəşlər tarafьnnan çiʙərelde.

Patşa oxrankasьnьꞑ Məçid Ƣafurinь ezərləve turьndaƣь qajser materiallar moꞑarcь da matʙuƣatqa cьƣarьlƣannar ide (məsələn, „Sovet ədəʙiatь“ ƶurnalьnьꞑ 1934 nce jьlƣь 11nce sanьnda Qəvi Nəçmi iptəş materiallarь) Şaƣirneꞑ ʙu xatь menə şuşь məs'ələne lşƣьn da kiꞑrək rəveştə jaqtьrta həm anьꞑ tormьş julьn, içadьn ɵjrənydə ʙik qimmətle material ʙulьp tora.

Redaksiə

«— Ƣatл tuƣan![1]

Minem ʙu markasьz məktyʙemne alƣac şajət ʙeraz ƣəçəpsenersen. Lə-kin alaj ƣəçəplənerlek eş juq. Şəʙəʙen də, məktypne uqьp ʙetergəc anlarsьn.

Kuş, ʙez avьldan ijylneꞑ ʙişendə qajttьq. Ijylneꞑ 15 lərenə qədər qɵm-rebez, yzeꞑ ʙelgəncə, qadi həm tьnьc ytte. Yzemneꞑ Orenʙurqa kityem də ʙulьp ide. Ijyl 15 nnən soꞑ mine xɵkymət çasuslarь hər qajdan soraşьp jərgənleklərе iştelə ʙaşladь. Çasuslarnьꞑ mərkəzenə ʙarƣan inaʙətlerək kešelərdən mine soraşqannar. Həm də taʙьp ʙirergə quşqannar. Xəlʙuki minem qacьp jərgənem juq. Şunnan soꞑ fatir xuçasьna kilep ike rət mine soraşьp kitep, ɵcence mərtəʙə kilylərendə domaşnьj knigaпь alьp kitkən-

---

[1] Ƣata Isxaqof iptəş, M. Ƣafuri ʙelən, Trojski şəhərendə uqьƣan jьllardan alar ʙəjləneş tota ʙaşlьj. Ul şaƣirneꞑ jaqьn dus'arьnьꞑ ʙersenə əjlənə. Ƣata Isxaqof xəzergə kendə də uqьtucь. Urta məktəptə tatar tele həm ədəʙiatь uqьte. S. Qudaş

nar. Bolaj belderep jəri başlaqac min inde tenty-fələn bulmasnь acьq beldem. Bulsa inde xibes diep, şunь kətəm. 18 nce ijyldə minem qajnaqanь sysknoj otdelenieqa, jəqni şul uŋ çasuslarnьŋ mərkəzenə caqьrqannar. Annan mine təmam soraşьp, minem fatirьmnь kyzmə kyz kyrsəterga təklif qьlqannar. Ul вicara qurqubnnan tənnə səqət 10 da kilep kyrsətergə məçвyr bulqan. Yze tənnə səqət 11 də bezgə kilep, sorap, kyrep kitkənnəren, yze kyrsətergə məçвyr bulqanlьqьn вəjan qьldь. Min inde вygen motlaq mine xibeskə alьrlar dip kətep tordьm. Ul вicara Zəhrə təne вujь qurqьp cьqtь. Ləkin haman вer nərsə də вulmadь. Mine nigə тава almьj haman soraularьna вer məqnə вirergə də вelmədem.

Menə 22 nce ijyl irtyk вer straznik kilep minа povestka вirde.

Bu povestka вelən mine sudeвnьj sledovatel caqьrtqan. Səqət 12 də anda вardьm. Kery вelən minnən: вəten tormьş və xəjatьmnь sorap jazьp aldь. Şunnan son Qazan prokurorьnnan mine təftiş itərgə əmer kilgənlekne вəm minnən çəvap alьrqa quşqannь вəjan qьlьp, minem xaqtaqь eşne aldь.

Minem xaqtaqь eş, zur qьna вer kitap qədəre вulqan. In əvvəl Qazan prokurorьnьŋ mine qəjeple itkən reşeniesen uqьdь.

Monda mine «Millət məxəввəte» məçmuqəsendəge «1906 ncь jьldan 1907 nce jьlqa vasiət» digən şiqerem өcen 129 ncь statjə вelən qəjeple itkənnər. Bu şiqer Qazan professorь Qatanof tarafьnnan tərçemə qьlьnqan. Mine вaşqa allə nindi statjələr вelən prokuror qəjeple itep cьqarqan. Tərçəmələrne də, вaşqa minem xaqtaqь eşlərne də sudeвnьj uqьp cьqqac minnən çəvap ala вaşladь.

Anьŋ səallarьnьŋ вaşlьcalarь şular:

1) Bu şiqerne sin jazdьŋmь? 2) Nigə jazdьŋ? 3) Xalьqnь qotьrtu maqsatь вelənme? Qajda jazdьŋ? Kemgə sattьŋ, kypmegə sattьŋ? Nicə meŋ nөsxə вasarqa? Əlx... Min səallarqa вer də jəşermi, qurьqmьj təmam tuqrьsьn вəjan qьlьp çəvap вirdem. Şunnan soŋ: «Yzeŋne qəjeple dip вeləseŋme?» dide. Min: «Min yzemne qəjeple dip вelmimen» didem. Bu səal, çəvaplar 3 вit вuldь. Çəvaвьmnь yzemə uqьp kyrsətte. Nihajət sudeвnьj şuşь syzlərne əjtep mine cьqarьp çiвərde: «129 ncь statjə вujьnca qəjeple. Binaən qələjhi eşeŋ sudqa вirelə. Palatada sud вulьr. Şuŋarcь pod nadzor politsiə torьrsьŋ». Min cьqьp qajtьp kittem.

25 lərendə taqьn kilep вəten tormьşnь jazьp, castqa вarьp atna sajьn şimвə kөn kyrenep torьrqa qul qujdьrьp aldьlar. Menə inde politsiə nəzaratьnda, Ufada torьrqa, şul sudnь kөtərgə məçвyr вuldьm. Sudnьŋ nihajəte, nəticəse jə nəçat, jə xiвes. Xətta xiвes tarafь quətle. Bu eşlərneŋ вuluь ıxtimal. Xiвes-fələnneŋ вulьp kitye kynlemne zərrəcə də вorcьmьj. Kynlemdə qurqu, aqьrlьq ity juq. Fəqət Zəhrə вeraz вorcьldь. Inde ul da өjrənep вara. Ləkin вu məs'ələlər və вaşqa hər çirdə minem şiqerləremne çiьp aluları maddi çəhəttən nihajət zur zarar itte. Inde naşirlər minem şiqer məçmuqələremne aludan—nəşer itydən qurqalar, almьjlar. Xəlвuki minem

jaꞑa şiqerlərem ʙar ide. Iskeləren də taqь ʙastьrьrqa vaqьt çitkən ide. Anьꞑ өstenə Orenʙurqa da kitep ʙulmьj tora. Menə ʙu eşlər ʙarьʙer ʙaşqa çiьlqac ʙik zur tə'sir itte. Ber çəhəttən, nəzarət astьnda toru, ikence jaqtan, məqişət çəhətennən avьrlьq kyry əlʙəttə ʙik çiꞑel tygel. Ləkin min ʙu avьrlьqlarnь ʙer kemgə də sizdermi, fəqət ʙerence rət siꞑa jazьp utьram. Sud soꞑьnda alaj-ʙolaj ʙulьp qalsa ʙigrək tə Zөhrəgə qiьn ʙulьr keʙek kyrenə. Minem tormьşьm inde nacarlьqnьꞑ cigenə çitte, ləkin saʙьrlьqьm monь qaplьj, juqalta. Hic kem aldьna ser ʙelderep ʙarasьm kilmi. Həm alaj ʙarьrlьq ʙer keşem də juq. ʙəqze duslarьm inde ʙeznen өjgə kilergə də qurqalar. Ecem poşa, ləkin kytərə alam. Ec poşuь xiʙes itelydən, fələnnən qurqьp tygel, menə şundьj vaqьtta ʙer iptəş juqlьqь. Bu eşlərdən son minem fikrem juqarьlana qьna, dərt arta qьna ʙara. Məqişət çəhətennən ʙu xəlgə qaluьma da qəçəpsenmimen. Dөnja yzeneꞑ məqsuden içra itsen, min şulaj ʙicara rəveşle jөrermen əle dip qujam. Qata tuqan! Bu xəqiqət serlərемne siꞑa qьna ʙelderəm. Menə inde markasьz məktyp çiʙəryemneꞑ xikmətеn ʙeldeꞑme? Sin, tuqan, ʙu kyꞑelsez xatnь uqьp kyꞑelsezlənmə. Bolar həmməse qadi, ʙik keckenə eşlər. Ber də xafalanьrlьq tygel. Inde yzeꞑ nişləp torasьꞑ? Haman şulaj kyꞑelsez tormьşta torasьꞑmь? Tuqan, qajqьrma, sine haman təqdir itə almasalar kity julьn qarasaꞑ da zarar juq, dөnja kiꞑ. Qajqьrma, tuqan, xafalanma, jaqьn dustьm. Acьq kon ʙulьr, ʙer acьlьr. Bu əsrarnь yzenneꞑ eceꞑdə genə saqla. Xuş, tuqan. Fatir ʙorьnqь çirdə.

**M. Qafuri.** 1 nce avgust, 1911 nce sənə.

PS. Monda şunь da əjtəm əle, xөkem vaqtь haman ʙilgele tygel. Bəqze keşelər, advokat jalla, dip əjtsələr də minem hic ʙer alaj itəsem kilmi. Anьꞑ өstenə nərsə ʙelən advokat jallarqa? Ni ʙuьsa şulaj kөtep torьrqa. Nəçat, xiʙes ikese mosavьj».

## ТАТАРСТАН: РОССИЯ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮЛӘР

Шушы елның 21 гыйнварында Мәскәү шәһәрендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы делегацияләренең очрашуы булды.

Сөйләшүләрдә Россия Федерациясе Президенты Б. Н. Ельцин һәм Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев җитәкчелегендәге ике як вәкилләре катнашты.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ СОВЕТЫНЫҢ МИЛЛИ МӘСЬӘЛӘЛӘР ҺӘМ МӘДӘНИЯТ БУЕНЧА ДАИМИ КОМИССИЯСЕ БЕЛДЕРҮЕ

«Россия» дәүләт телерадиокомпаниясенең «Вести» информацион программасының 1992 елгы 7 ноябрь һәм 20 декабрь тапшыруларыннан һәм «Известия» газетасының 1992 елгы 11 ноябрь санында басылган «Бүреләр» исемле мәкаләдән Мәскәүдә гамәлдәге властьлар белән көрәшү максатларында «Муса Җәлил» исемендәге интербригада төзелүе билгеле булды.

Үзәк массакүләм информация чаралары интербригаданы хәрби вакыйгаларда катнашу өчен Сербиягә җибәрергә әзерләүләрен дә хәбәр иттеләр.

Муса Җәлилнең гаиләсе — хатыны Әминә, кызы Чулпан һәм оныгы Татьяна «Известия» газетасының 1992 елгы 11 ноябрь санында гаиләсенә һәм Ватанына тугрылыклы шагыйрьнең исемен шикле сәяси ыгы-зыгыларда файдалануны кискен гаепләп чыктылар.

Татарстан Республикасы Югары Советының милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе татар халкының милли герое шагыйрь Муса Җәлилнең исемен Конституциягә каршы булган сәяси максатларда файдалануга катгый протест белдерә.

## ВЕНГР ДУСЛАР ҖИРЕНДӘ

Татарстан белән Венгрия арасында икътисади, фәнни һәм мәдәни бәйләнешләр көннән-көн ныгый. Мәгълүм булганча, үткән ел Республикабыз җитәкчеләре Венгрия хөкүмәте белән дәүләтара килешү төзегән иделәр. Шул килешүнең бер нәтиҗәсе буларак, Венгриядә халык хуҗалыгы белгечләренең кыска сроклы укулары оештырылды.

Январь аенда Татарстанның йөздән артык вәкиле авыл хуҗалыгы буенча Венгриянең казанышларын өйрәнделәр, лекция-консультация уздылар, тәҗрибә уртаклаштылар.

Бу курсларда шулай ук утыздан артык журналист, нигездә, республика газета-журналларының баш мөхәррирләре дә катнашты. «Казан утлары»ның баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин да, башка журналистлар кебек үк, шул курсларда укып кайтты, Урта Европа икътисади өйрәнү институтының диплом-сертификатына лаек булды.

Журналистлар, бу курсларда укудан тыш, Венгриянең төрле төбәкләрендә булдылар, Будапештта радио, телевидение һәм матбугат органнары җитәкчеләре белән очраштылар.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ЗУР БӘЙРӘМЕ

Гыйнвар аенда К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында күренекле шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеевка 60 яшь тулу тантанасы үткәрелде. Ул, гадәти тантаналардан аермалы буларак, күтәренке-моңлы музыка һәм күпсанлы тамашачыларга бик билгеле «Резидәкәй» җыры белән башланды. Бу җырны җырчы Гөлзада Сафиуллина зур осталык белән башкарды. Җыр тәмамлануга, шагыйрь Рәдиф Гаташ тәбрик сүзе әйтте. Аннары, җөмһүриятебезнең мәдәният министры урынбасары Мөҗип Низамиев әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә зур өлеш керткән юбилярның күпкырлы фидакарь эшчәнлеген югары бәяләп, аңа министрлыкның Мактау грамотасын тапшырды.

Әдипне Татарстан композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин һәм җөмһүриятебезнең Язучылар берлеге рәисе урынбасары Зиннур Мансуров та котлады.

Халыкның сөекле җырчысы Илһам Шакиров чыгышы күңелләргә аеруча нык тәэсир итте. Ул «Яшь наратлар» җырының һәм көенең (Җ. Фәйзи) кызыклы тарихын сөйләде һәм җырлады.

Бу кичәдә мәшһүр артистларыбыз И. Биктаһиров, М. Галиев, А. Вәлиев, В. Гыйззәтуллина, Р. Ибраһимова, З. Сәхәбиева да катнашты.

Юбилярны Балтачтан Г. Мөхәммәтшин, «Сөембикә» журналыннан Р. Камалетдинова, мәдәният музееннан И. Минһаҗева, радиодан Р. Нуруллин, шагыйрьләр Ш. Галиев, Р. Миңнуллин, Р. Корбанов, Р. Зәйдулла һәм башкалар котладылар.

## АЛАР СЕБЕРДӘН КИЛДЕ

17—26 гыйнварда республикабызда Пермь өлкәсенең Барда районы мәдәнияте көннәре үткәрелде.

Пермь өлкәсендә, Россиянең башка төбәкләрендәге шикелле, бик күпсанлы татарлар яши. Алар өлкә үзәгенең үзендә, башка шәһәрләрдә, шулай ук Октябрь, Уен, Орда, Березовка, Лысьва, Пермь, Көнгер, Суксун һәм башка районнарда күп яши. Барда районында исә татарлар белән башкортлар саны барлык халыкның 90 проценттан артыгын тәшкил итә. Шулай булгач, Барда ягы халкының борынгыдан ук татарның үзәге булган Казан ягы белән икътисади һәм рухи элемтәдә торуы гаҗәп түгел.

Бардалылар килгәч, Татарстанда истә калырдай вакыйгалар күп булды. Барда халык театрының Сәет Шәкүров әсәре буенча куелган «Карт гашыйк» спектакле дә, Казанның мәдәният сарайларында һәм Зеленодол, Арча, Әтнә районнарында булган концертлар, күңелле кичәләр дә, кунакларның «Татарстан» мәдәният үзәгендә бирелә яшәүче якташлары белән очрашулары да һәм, ниһаять, Г. Камал исемендәге академия театрында узган йомгаклау концерты да — һәммәсе якты бәйрәм төсендә кабул ителде.

## ТЕАТРДА ЯҢАЛЫК

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы тамашачыларын тагын бер яңа спектакль белән шатландырды, яшь автор Гафур Каюминың «Һинд кызы» исемле әсәрен сәхнәләштерде.

Кинокомедия жанрында эшләнгән әлеге спектакль барышында тамашачы һинд биюләре, йөрәккә ятышлы көйләр белән якыннан таныша. Спектакльдә театрның яшь артистлары Илсөя Төхфәтулла, Гүзәл Шәрәфи, Илдус Габдрахман, Раушан Шәриф, Фәридә Мирхафиҗан, Ләйсән Мәхмүтова белән бергә, инде тамашачыга яхшы таныш булган Равил Шәрәфи, Шамил Барый, Рәшит Шамкаевлар да катнаша. «Сантон» һинд клубы биючеләре Фаил Бикмуллин, Альбина Гайнанова, Ирина Жарова, Регина Сөләйманова, Наташа Попова чыгышлары да җылы тәэсир калдыра.

Әсәрне сәхнәгә яшь режиссер Ринат Әюпов, балетмейстер Гөлчәчәк Исмәгыйлева куйган. Композиторы — Азат Хәсәенов. Тамаша тәмамлангач, спектакль спонсоры — Арча район администрациясе исеменнән артистларга акчалата бүләкләр тапшырылды.

Театр коллективы күренекле драматург Шәриф Хөсәеновның «Көфер почмагы» исемле комедиясен сәхнәгә куярга әзерләнә.

## ТАТАР УЛЫ ИДЕ

Бөтен дөнья сәнгате мәшһүр биюче Рудольф Нуриев белән хушлашты. Ул Англия Королевасы балеты театры сәхнәсендә — Лондонда 25 ел биеде, аннары Парижга күчеп, «Гранд Опера» театрында баш балетмейстер вазифасын башкарды.

Рудольф Нуриев элеккеге Советлар иленнән 1961 елда киткән иде. Әнә шуннан соң инде ул бию буенча бөтен дөньяны таң калдырган йолдызга әверелде һәм сәнгать күгендә озак еллар буена сүрелмичә балкыды.

Атаклы биючене соңгы юлга озату хакында сөйләгәндә Россиянең информация чаралары аның кайсы милләттән икәнен әйтмәскә тырыштылар. Мондый «тырышлык» әдәп-әхлак дәрәҗәсенең нинди югарылыкта торуын аңлата булса кирәк.

## САГЫНУ КОНЦЕРТЫ

Үткән ел азагында Мәскәүдә мәшһүр композиторыбыз Сара Садыйкова истәлегенә багышланган зур концерт булды. Ул көнне Мәскәү тимер юлчыларының мәдәният сарае тамашачылар белән шыгрым тулы иде. Күңелләрне иркәләп берсеннән берсе матур җырлар, моңнар яңгырады. Программаны шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева алып барды. Концертта җырчылар Зөһрә Сәхәбиева, Хәйдәр Бигичев, Зиннур Нурмөхәмәтов, Миңгол Галиев, Сәнифә Рангулова катнашты.

Михнәтле заманда шундый матур һәм җанга якын концерт куйганнары өчен Мәскәү тамашачылары Казанның сәнгать осталарына зур рәхмәт хисләрен белдерделәр.

Әйе, халыкның сөекле композиторы һаман милләте белән бергә яши, аның куаныч һәм кайгысын уртаклаша. Иҗат кешесе өчен иң олы бәхет шул түгелмени?

## ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

Моннан ун еллар элек Мамадыш районының «Чулпан» колхозында күренекле язучы Шәйхи Маннур исемендәге премия булдырылган иде. Ул һәр елның 15 гыйнварында, әдипнең туган көнендә, үзләрен танытып өлгергән яшь язучыларга һәм колхозның хезмәт алдынгыларына тапшырыла.

Быел әлеге истәлекле бүләккә, колхоз идарәсе утырышының махсус карары нигезендә, хуҗалыкның алдынгы механизаторлары Габделхак Вилданов һәм Вакыйф Шәрипов, шофер Фарил Хисмәтов, бозаулар караучы Нурия Ханова иптәшләр лаек дип табылды.

Язучылардан исә Ш. Маннур премиясе «Карурманнан чыккан юлчылар» повесте һәм төрек әдибе Азиз Несин хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итүдәге уңышлары өчен Нәзифә Кәримовага, балалар шагыйре Рафис Корбановка, «Мин — шигырьдән» дигән китабы өчен яшь шагыйрь Рөстәм Сүлтигә бирелде.

Премияләрне һәм лауреат дипломнарын тапшыру тантанасында Ш. Маннурның иҗат мирасы комиссиясе рәисе шагыйрь Илдар Юзеев, Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты, шагыйрь Рөстәм Мингалим, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Рашат Низамиев, Ш. Маннур иҗат мирасы комиссиясе сәркатибе публицист Шаһинур Мостафин иптәшләр катнашты һәм әдипнең якташлары алдында чыгыш ясадылар.

Мамадыш районы хакимият башлыгының беренче урынбасары Револь Гыйззәтуллин, «Чулпан» колхозы идарәсе рәисе Фә-

рит Хисмәтов, Олыяз авыл Советы башкарма комитеты рәисе Юрис Мөхлисов яңа лауреатларны ихлас күңелдән котладылар.

Яңа лауреатлар Ш. Маннур күмелгән Тулбай авылы зиратында булдылар, шагыйрь исемен йөртүче китапханә һәм андагы музей белән таныштылар, мәктәп балалары белән очраштылар.

### ТАТАР МОРЗАЛАРЫ ТУПЛАНА

1992 ел ахырында Уфа шәһәрендә «Татар морзалары мәҗлесе»н (татарское дворянское собрание) оештыру җыелышы үтте.

Татар морзаларының язмышы, татар милләтенең тарихы кебек үк, фаҗигале һәм аяныч. Татарның өч дәүләте хәрабә булып таркалгач, бу рәхимсез канлы сугышлардан исән калган морза вәкилләре урыс дәүләтенә хезмәткә барырга мәҗбүр була. Ләкин үз милләтенә һәм ислам диненә тугрылык саклап кала. Шул сәбәптән, 1713 елда падишаһ Петр I чукынудан баш тарткан татар морзаларын утарларыннан һәм биләмәләреннән мәхрүм итә. Морзалар, казенный крестьян катламына языйып, «лашман» тартырга теркәләләр.

Россия тәхетенә бөек императрица Екатерина Алексеевна килгәч, татар морзаларының язмышы үзгәрә. 1784 елгы указ нигезендә, татар морзалары Россия дворян катламына кайтарыла. Россия мәркәзеннән 1774—1800 елларда Уфа губернасындагы буш җирләргә күчеп, бу катлам татар, башкорт халкына күп мәгърифәт яктысы китерә.

Әлеге җыелышта устав кабул ителеп, рәислеккә Сәид морза Еникеев бәк сайланды, аксакаллар шурасы расланды. «Дворян клубы» да нигезләнде.

### ҮТКӘН ЕЛ КЕШЕСЕ

Кембриджадагы халыкара тәрҗемәи хәл үзәге фикер ияләре арасында ел кешесе дип Зөфәр Фәтхетдиновне атады. Ул — юридик фәннәр докторы, Мәскәү дәүләт университеты профессоры, язучы, күп кенә китаплар авторы.

Укучылар хәтерли торгандыр, бу әдип безнең журналда үзенең маҗаралы берничә повестен бастырды һәм алар әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан җылы каршы алындылар.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

# ЕВРОПАНЫ УРЛАУ

Уфада яшәп иҗат итүче татар рәссамы Васил Ханнанов үзенең әсәрен әнә шулай кыска һәм анык кына итеп исемләгән. Журналыбыз тышлыгының беренче битендәге ул рәсемгә игътибар белән рәк карыйк әле. Әйе, рәсемнең сюжеты күпләргә таныштыр. Борынгы грек мифларыннан азмы-күпме хәбәрдар булган кеше, әлбәттә, бу мифны да укып яки ишетеп, яки танылган рәссамнарның — әйтик XVII йөз итальян рәссамы Гвидо Рени һәм рус рәссамы Валентин Серов әсәрләре аша күзаллап беләдер.

Төрле илләрдә, төрле чорларда сәнгатьнең барлык тармакларында чагылыш тапкан, һаман кабатланып килгән миф Васил Ханнановны да илһамландырган. Әйдәгез, рәсем турында фикерләшүгә кадәр әлеге мифның сюжет-эчтәлеген тагын бер кат искә төшереп узыйк.

Борын-борын заманда Финикия патшасының Европа исемле бик гүзәл кызы була. Бу гүзәл кыз Азия кыйтгасының Сидон дигән каласында яши икән. Аллалар алласы бөек Зевс, кызны күргәч, аның гүзәллегенә таң кала һәм шундук гашыйк та була. Ул Европаны урларга карар кыла һәм, үгез кыяфәтенә кереп, кызны сыртына сала да диңгезгә ыргыла. Зевс үзенең мәгъшукасын Эгей диңгезендәге Крит утравына алып килә. Тора-бара Европа Зевска берсеннән-берсе чибәр өч баһадир малай табып бирә. Соңыннан Зевс улларының берсе — Минов исемлесе — атау халкын дер калтыратып куркуда тоткан бик усал үгезне җиңеп, халык батырына әверелә. Ә Азиягә тоташып киткән әлегәчә исемсез кыйтганы, Европаны хөрмәтләү йөзеннән, аның исеме белән атап йөртә башлыйлар — Европа дип.

Менә шундый матур миф-әкият...

Рәссам Васил Ханнанов исә бу әкияткә үзенчә эчтәлек сала, аны үзенчә сәнгать чаралары белән сурәтли.

Рәсем бик анык, аңарда төсләр дә, сурәтләнә торган әйберләр дә аз. Бу саран аныклык әсәрнең идея эчтәлеген ассызыклап тора. Ачык саргылт төстәге символик үгез,— ул үз чиратында Азия кыйтгасын гәүдәләндерә,— үгез сыртына аркылы салынган хатын-кыз силуэты, анысы да шартлы, стильләштереп бирелгән. Хатын-кыз гәүдәсе — кара төстә. Европа кыйтгасындагы кара туфраклы җир төсе дә, кара төн төсе дә ул. Үгезнең саргылт мөгезе бер үк вакытта чалкан яткан ярым айны да хәтерләтә. Әлеге ярым айдан өстәрәк, караңгы яшькелт күк йөзендә Чулпан йолдыз балкый. Яшел фондагы Чулпан йолдызлы ярым ай, әлбәттә инде, безнең аңда шәрык илләренә — ислам дәүләтләренә ишарә булып төсмерләнә. Күңелдә үзеннән-үзе:

*Ай янында — якты йолдыз,*
*Сөйгән йолдызым гына;*
*Таң алдыннан ул да сүнә,*
*Калам ялгызым гына...*

— дигән халык җыры уяна.

Рәсем сәнгате телен белсәң, аның ачкычын тапсаң, бары тик берничә сызыктан, өч-дүрт төстән генә торган, математик формула кебек җыйнак булган әсәрдән дә никадәр бай рухи азык алырга мөмкин икән!

Васил Ханнановның рәсеме, беренче карашка, хәрәкәтсез, катып калган шикелле тәэсир ясый. Әмма шул ук вакытта үгез сыртындагы сыгылма гәүдәле кыз, ярым түгәрәк сызыкларның геометрик төгәллеге үзенә бер аһәң бирә, әсәр ниндидер эчке бер киеренкелек белән сулый башлый. Бик декоратив, аппликатив яссы бу сурәт татар халык сәнгатенә хас миллилекне дә төсмерләтә. Шулай итеп, «Европаны урлау» әсәрендә без иректә импровизация — хыял уенын да, дөньяны романтик — сагышлы итеп күзаллауны да күрәбез.

Рәссамның фәлсәфәсе тирән дә, гади дә: мәңге какшамас капма-каршы ике як бар — Европа һәм Азия, Шәрык һәм Гареп... Шул ук вакытта ул төн белән көн, яхшылык белән явызлык, тән белән җан да... Васил Ханнанов яшәү белән үлем серләрен үзе өчен әнә шулай ача, дөньяви байлыкларның рухи байлыклар белән яраша алмавын таба. Рәсемдә рәссамның киләчәктәге ниндидер куанычларны тоюы-төсмерләве сизелә. Әйтерсең, рәссам кешелекнең «иртәгәсенә» күз ташлый. Анда исә, киресенчә, Европаны Азия үзе урлыйдыр, мәңге серле Шәрык Гареп илләрен үз орбитасына аладыр: ярым ай өстендәге Чулпан йолдыз — таң йолдызы шуңа ишарә түгелмени? Әсәрнең төп фәлсәфи чишелеше дә шунда, безнеңчә.

Васил Ханнанов бик үзенчәлекле рәссам. Аның һәр әсәре — кубизм стилендәме ул, символик реализм яки авангард стилендәме,— һәрвакыт үзенчә көтелмәгән тирән фәлсәфи һәм эстетик эчтәлеккә ия. Бу җәһәттән, ул бүгенге татар рәсем сәнгатендә иң нечкә, иң тирән интеллектлы рәссамдыр, ахрысы.

Васил Ханнанов 1956 елда Башкортстанның Октябрьский шәһәрендә дөньяга килә. Уфа сәнгать училищесын тәмамлый. Соңгы елларда ул — татар рәссамнарын берләштергән «Чыңгызхан» төркемендә. Әсәрләре байтак күргәзмәләргә куелды, төрле музейлар тарафыннан сатып алынды.

Уңышлар сиңа, Васил!

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,**
сәнгать белгече

**Тышлыкның беренче битендә:** В. Ханнановның «Европаны урлау» исемле рәсеме.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Мәгъсум Хуҗин.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосурәтләре.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Татарстан китап нәшриятында яшь язучыларның беренче җыентыклары даими рәвештә басыла килә. Күптән түгел яшь шагыйрь Рөстәм Сүлтинең «Мин — шигырьдән» дип исемләнгән тәүге җыентыгы дөнья күрде. Китаптагы: «Чын мишәрең булалмадым инде, моңсу мишәр шул мин, Шыгырдан...» — дип башланып киткән беренче әсәр үк бу авторның гаять үзенчәлекле рухи дөньясы турында сөйли. Чыннан да, Рөстәм Сүлти матбугатта басылган беренче шигырьләре белән үк җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итте. Бу китапка бай романтик рухлы, халыкның образлы сөйләменә корылган, хакыйкатьне күзгә карап әйтә торган шигырьләр һәм «Тәрәзә» исемле поэма тәкъдим ителгән.





Республика матбугатында Зөлфәт Хәкимнең кызыклы да, гыйбрәтле дә хикәяләрен укып сокланмый калган кеше бар микән? Соңгы елларда бигрәк тә сатирик һәм юмористик әсәрләре белән укучы мәхәббәтен казанды ул. Әле күптән түгел Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән җыентыгына исә Зөлфәт Хәким «Ышанырга кирәк...» дигән исем куйган. Яшь автор үзенең көлкеле әсәрләрендә заманның төрле тискәре күренешләрен шактый шәп камчылый.

Бу китапларны якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, түбәндәге адрес буенча соратып алырга була:

**420066, Казан шәһәре, Чистай урамы, 3 нче йорт, «Төрки китап» кибете, «Книга-почтой» бүлеге.**

Бәясе 20 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог